ISSN 0206—4189

# Казан утлары

10.2000



# КИТАПЛАРДА—КӨРӘШ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**Республика Татарстан: Новейшая история. События. Комментарии.** Оценки *(Татарстан Республикасы: Өр-яңа тарих. Вакыйгалар. Аңлатмалар. Бәяләмәләр.)*— Казан: НПО «Медикосервис», 2000 ел.—415 бит. Тиражы—2000 данә.




«Татарстан XXI гасыр бусагасында» сериясендә чыгачак ике томлыкның беренче басмасы бу китап. Томлык Татарстан Республикасының дәүләт бәйсезлеге турында Декларация кабул ителүнең 10 еллыгы алдыннан дөнья күрде.

Төзүче авторлар: Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм Дәүләт Советы Матбугат үзәге житәкчесе Любовь Агеева.

Жанры буенча хрестоматия булган бу җыентык, 1988 елның гыйнварыннан башлап, соңгы 12 елда республикабызның төп әһәмиятле үсеш этаплары белән таныштыра. Анда Татарстан тормышына зур йогынты ясаган Советлар Союзы һәм Россия Федерациясе тарихы вакыйгалары турында сүз бара, республикабыз һәм Россия Федерациясен үстерү юллары турында күптөрле фикерләр тупланган.

Китап «Казан» журналы редакциясенең компьютер үзәгендә биткә салынып, «Идел-пресс» нәшрият-полиграфия үзәгендә басылып чыккан.

В. ЯКУПОВА. **100 историй о суверенитете** *(Суверенитет хакында 100 хатирә).*— Казан: «Идел-пресс», 2000 ел.—236 бит. Тиражы—5000 данә.




Казан мэриясе булышлыгы белән нәшер ителгән китапка әлеге тарихи вакыйгада катнашучыларның хатирәләре, истәлекләре тупланган.

1993 елда китап авторы (Венера Якупова—«Казанские ведомости» газетасының баш мөхәррире) «Молодежь Татарстана» газетасы битләре аша, халкыбыз суверенитет даулаган көннәр хакында үз фикерләрен җиткерүләрен сорап, укучыларына мөрәҗәгать иткән иде. Китапның нигезендә укучы-ларның әлеге хатлары ята. 1994 елда бу «сериал» Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы оештырган «Канатлы барс» республика конкурсында премия дә алган иде.

# Казан утлары
# Qazan utları

2000

# 10

(936)

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

***Татарстан хөкүмәте,***
***Татарстан Язучылар берлеге,***
***редакциянең хезмәт коллективы***

*БАШ МӨХӘРРИРЕ*
**Равил Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*
**Харрас Әюпов,**
**Зилә Вәлиева,**
**Фоат Галимуллин,**
**Тәлгат Галиуллин,**
**Миркасыйм Госманов,**
**Аяз Гыйләҗев,**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Флүс Латыйфи**
*(баш мөхәррир урынбасары),*
**Салих Маннапов,**
**Туфан Миңнуллин,**
**Хатип Миңнегулов,**
**Ринат Мөхәммәдиев,**
**Гәрәй Рәхим,**
**Булат Солтанбәков,**
**Ренат Харис,**
**Розалина Шаһиева.**

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Наис Гамбәр, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Марс Шабаев.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Альбина Әхмәтова, Гөлзадә Бәйрәмова, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәслимә Сибгатуллина, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова, Асия Рәхимова** (баш бухгалтер).

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир — 49-36-60.
Баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09.
Җаваплы сәркәтип һәм компьютер үзәге — 43-56-12.
Бүлекләр: шигърият, фән, сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар, әдәби тәнкыйть — 49-36-63,
гамәли хезмәткәрләр — 49-36-65.
Исәп-хисап бүлеге — 43-56-12.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Рауль МИРХӘЙДӘРОВ. Иртәләгән сагыш. *Роман* ..... 5
Ренат ХАРИС. Һарут белән Марут. *Поэма* ..... 78
Алмаз ГЫЙМАДИЕВ. *Хикәяләр* ..... 186

ДРАМАТУРГИЯ

Илдар ЮЗЕЕВ. Эзләдем, таптым, югалттым... *Ике пәрдәле драма* ..... 91

ВАХИТ ЮНЫСКА 70 ЯШЬ

Разил ВӘЛИЕВ. Гомерлек мосафир ..... 108
Вахит ЮНЫС. Ибрай абзый «кардиуны». *Әсәрдән өзек* ..... 109

ПУБЛИЦИСТИКА

Рафаэль МОСТАФИН. Татар Зоргесы ..... 116

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Ир-ат турында ..... 133

КОРЪӘН ТАТАР ТЕЛЕНДӘ

3—Гыймран *(Мәрьямнең атасы)* сүрәсе ..... 140

СӘНГАТЬ

Наилә ШӘРИФУЛЛИНА. Зур иҗат балкышлары *(Композитор Алмаз Монасыйповка 75 яшь)* ..... 156

ТАТАР ШИГЪРИЯТЕ АНТОЛОГИЯСЕННӘН

Шәмсетдин ЗӘКИ. Шигырьләр *(Р. Гаташ кереш сүзе белән)* ..... 165

ФӘН

Лилия ИБРАҺИМОВА. Дастаннарда— халык язмышы ..... 167
Рәмзи ВӘЛИЕВ. Туры сүзле, баш бирмәс шәхес *(Тарихчы галим Әгъдәс Борһановка 80 яшь)* ..... 178

ЗАҺИР БИГИЕВНЕҢ ТУУЫНА 130 ЕЛ

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Бәхтияр әдип ..... 171

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан ..... 191

*Журнал выходит один раз в месяц*

## В НАШЕМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: окончание романа Р. МИРХАЙДАРОВА «Ранняя печаль»; поэма Р. ХАРИСА «Харут и Марут», рассказы А. ГИМАДИЕВА.
«Драматургия»: драма И. ЮЗЕЕВА «Потеренная любовь».
«К 70 - летию Вахита Юныса»: отрывок из произведения юбиляра «Аккордеон фронтовика Ибрая» *(с предисловием Р. ВАЛИЕВА).*
«Публицистика»: очерк Р. МУСТАФИНА о жизни и деятельности «татарского Зорге» - Шамиля Хамзина.
«Литературная критика»: статья М. ВАЛИЕВА «О настоящих мужчинах».
Коран на татарском языке.
«Искусство»: статья Н. ШАРИФУЛЛИНОЙ посвящена творчеству композитора А. Монасипова.
«Из антологии татарской поэзии»: стихи поэта Ш. ЗАКИ.
«Наука»: статья Л. ИБРАГИМОВОЙ «В эпосе - судьба народа» и Рамзи ВАЛЕЕВА к 80 - летию ученого-историка А. Бурганова.
«К 130- летию З. Бигиева»: статья Х. МИННЕГУЛОВА.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Последний государь Казанского ханства—Ядгар хан»—работа художника Н. Хазиахметова; поэтесса Э. Шарифуллина.

## IN OUR ISSUE:

*The magazin edits monthly*

"Prose and poetry": the ending of R. MIRHAIDAROV 'S novel «The early grief», poem of R.HARIS «Harut and Marut»; A. GIMADIEV 'S stories.
"Dramatics": I. UZEEV 'S drama «The losed love».
"Commemorating the 70 th anniversary of Vahit Unus": the fragment of jubiler's work «The accordion of front - line soldier Ibrai» (with R. VALIEV'S preface).
"Journalism": R. MUSTAFIN'S essay about life and activity of Shamil Hamzin.
"Literary criticism": M. VALIEV'S article «About real men».
"Koran in Tatar"
"Art": N. SHARIFULLINA 'S article devoted to A. Monacipov's creati works.
"Literary heritage": Sh. ZAKI 'S verses.
"Science": L. IBRAGIMOVA'S article «In epos - people's fate», Ramzi VALEEV'S article devoted to 80th anniversary of scientist-historian A. Burganov.
"Commemorating the 130 th anniversary of Z. Begiev" : H. MINNEGULOV 'S article.
The diary of social and cultural life.
In our covers: «The last khan of Kazan state Yadgar khan»-N. Haziahmetov 's work; poet A. Sharifullina.

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 49-36-62 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянен компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.
Басарга кул куелды 25.09.2000 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы $70X108^1/_{16}$.
Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Тиражы 7542 Заказ Э-379
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы № 7.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2000 ел.

## Чәчмә әсәрләр

**Рауль Мирхәйдәров**

# ИРТӘЛӘГӘН САГЫШ

РОМАН

### XXXIV

Рушан Дасаевнын, дөрестән дә, ижат сәләте бардыр, юкса аны мондый сораулар, мөгаен, борчымас иде. Үткәннәрен уйлап утырганда, ул үзенең балерина Валентина Ганибаловага язмышын алдан әйтеп бирә алганын исенә төшерде, әмма үз тормышын һәм кайбер эш-гамәлләрен башкачарак яктыртырдай шундый ике очракны онытып жибәргән булып чыкты.

Алтмышынчы еллар уртасында ул Ташкенттан ерак түгел, бер сәгатьлек юлда, әле исеме танылып та бетмәгән Заркент шәһәрендә химия, сонрак металлургия комплекслары төзүдә эшләде. Белгечләр өчен салынган «Яз» кунакханәсендә айлар буе яшәде.

Шәһәр зурдан кубып салына, проектлаучылар фикеренчә, ул социализм маякларынын берсе булырга тиеш, шунлыктан анын бина-фәләннәре һушларынны алырлык итеп эшләнә иде. Мәсәлән, шлак сибелгән юллы, ул вакытта Уфадан кала илдә икенче, үз мототреклары бар иде. Язларын анда атаклы узышчылар, исемнәре дөньяга танылган осталар жыела: Борис Самородов, Игорь Плеханов, Юрий Черканов, Фәрит Шайнуров һәм легендар Габдрахман Кадыйров—спидвей буенча унике мәртәбә дөнья чемпионы. Бу спортчылар да озаклап «Яз» кунакханәсенә туктала иделәр.

Рушанга ул чагында Заркентнын рухи тормышы шул абруйлы кунакханә тирәсендә кайный төсле тоела иде. Яна шәһәрләр ниндидер романтика белән өретелгән, аерым бер кызыксыну уята, аларга багышлап шигырьләр языла, жырлар жырлана, яна совет кешесенен гармоник шәхесен тәрбияләр өчен бөтен шартлар тудырылган, киләчәк шәһәрләренен өлгесе, дип мактала торган Заркентка сугылып китү мөмкинлеген Ташкентка килгән мәшһүр артистлар да ычкындырмыйлар иде.

Төзелеш бинибая колачы һәм кинлеге белән тан калдыра: шәһәрдә менә дигән спорт заллары, житмәсә пайтәхетле калалар да көнләшерлек бик шәп Спорт сарае бар, гажәеп бай итеп зиннәтләнгән ике заллы

---

Ахыры. Башы 8-9 саннарда.

Сәнгать йорты да аңардан калышмый. Заркентка еш килүче атаклы артистлар да шул «Яз» кунакханәсен яратып өлгерде—талантлы архитекторлар, сынчылар, рәссамнар, химия һәм металлургия өлкәсендә күренекле белгечләр, төзелешләрнең яшь житәкчеләре оясы иде ул кунакханә. Житәкчеләр бигрәк тә күп булып, алар үзләрен социалистик яшь шәһәрнең хужалары итеп тоялар иде.

Төзүчеләр арасында андый ижади күтәренкелекне Рушан башка беркайчан да, беркайда да очратмады, юкса үз гомерендә ил буйлап күп йөрде, күп төзеде. «Яз» кунакханәсе чын мәгънәсендә яз, янару билгесе булды. Аның тәрәзәләре таңга кадәр балкып тора, ресторан яки барда башланган әңгәмә-бәхәсләр бүлмәләрдә дәвам итә—нәрсәләр турында гына бәхәсләшмиләр дә, ничек кенә хыялланмыйлар иде анда!

«Яз» кунакханәсендә даими торганлыктан, Рушан шул чорда бик күп танылган спортчылар һәм журналистлар, актерлар һәм эстрада йолдызлары, хәтта киләчәк шәһәрен күрергә ашкынып килгән язучылар һәм шагыйрьләр белән дә танышып өлгерде.

Шәһәр халкының гомуми мавыгуы спидвей ярышлары булды. Башка бик күпләр шикелле, Рушан да Габдрахман Кадыйровка мөкиббән иде, аның кызыл шарфы һаман күз алдында тора һәм гомер онытылмастыр, мөгаен. Соңрак ул жирле футбол командасы «Металлург» өчен «авырый» башлады, ул командада, Ташкент «Пахтакор»ыннан күчеп килеп соңгы елларын уйнаучы атаклы Станислав Стадник, грузин «варяглары» Джумбер Джешкариани, Роберт Гогелия һәм Тамаз Антидзелар бик оста уйный иде.

Эше тыгыз булуга карамастан, Рушан күп укыды, чөнки тирәюньдә даими рәвештә театр һәм китаплар, кино һәм музыка, рәсем сәнгате һәм архитектура, музей һәм күргәзмәләр турында сүз алып баралар—хәзерге күзлектән караганда, менә шундый иркен-хөр, хыял канатлы сәер заман иде ул. Каттан-катка, бүлмәдән-бүлмәгә журналлар, китаплар, хәзер «самиздат» дип тамгаланган кулъязмалар кулдан-кулга күчеп йөри, кайда барма: «Ә син укыдыңмы әле?.. Ә син күрдеңме әле?..»—кебек сораулар явып кына тора иде.

Китаплар тирәсендә илдә туып килгән ыгы-зыгылы шаукым ул якларга әле барып житмәгән, теләсә нинди китапны итәк астыннан түгел, ә кибетләрдән иркен сатып алып була, ирекле сатуда бик сирәк очрый торган, хәзергечә әйткәндә, раритет басмалар да булгалый иде.

Әгәр дә ахырына кадәр хакны сөйләсәк, китаплар белән шулай мавыгуда өстенлек чит ил әдәбиятына бирелеп килде. Рус әдәбиятының матурлыгын һәм көчен, барыннан да бигрәк Бунин ижатының тәмен Рушан соңрак аңлаячак иде әле, Бунин шуннан соң бик озак кына калган байтак язучыларны томалап торды. Әдәбият белән кызыксынуның аннан соңгы чираттагы әйләнешендә ул совет авторларына юлны үзе эзләп тапты, аларга күп кешеләр кул селтәп кенә карыйлар иде бит, ә Рушанның өстәленә Катаев, яшь Казаков, Распутин китаплары озакка менеп кунаклады, ул үзе өчен Битов һәм Фазыл Искәндәр, Тимур Пулатов һәм Грант Матевосян, Белов һәм Можаев, Трифонов һәм Макашин исемнәрен ачты... Кызганыч, бу исемлектә бер генә татар язучысының да исеме юк, чөнки Рушан алар ижатыннан бихәбәр иде...

Ничектер эштән кайтышлый, ул урам чатындагы сатучыдан бик матур итеп чыгарылган калын бер китап сатып алды—»Условия человеческого существования» («Кешенең яшәү шартлары»). Бу роман исеме аңа таныш булмаган япон язучысы Дзюнпей Гомикаваныкы булып чыкты, юкса Рушан шундый ук исемдәге башка бер китапны белә, аңысының авторы танылган итальян язучысы иде. Әлеге мең битле диярлек калын романны,—Аллага шөкер, хәзер андыйларны язмыйлар инде!—ул берничә көндә төн йокыларын калдырып укыды һәм тәки жинеп чыкты. Китап аны тетрәндергән иде, ул әле хәзер дә төп геройның исемен хәтерли—Кадзи.

Шактый вакытлар узгач, әдәбиятыбызда социалистик реализмның унышлары һәм унышсызлыклары турында матбугаттагы әдәби бәхәсләргә килеп төртелгәндә,—ә ул бәхәсләргә югары уку йортлары студентлары гына түгел, хәтта мәктәп укучылары да тартылган иде,—Рушанның күз алдына ирексездән әлеге калын китап, аның рәссам тарафыннан самурай кылычларына охшатып, шул ук вакытта иероглифларга да тартым итеп, көмешсу фольга белән басылган озын исеме килә һәм ул совет әдәбиятында социалистик реализм ысулы дигән нәмәрсәне уйлап чыгарган яна идеология тарафдарлары һәм ил житәкчеләре, мөгаен, нәкъ менә шундый тулы канлы, сыгылмас, принципларга һәм идеалларга турылыклы, үрнәк булырлык герой турында хыялланганнардыр, дип уйлый иде. Әгәр дә аның үзеннән: «Соцреализм калыбына туры килердәй идеаль геройны нинди итеп күрәсез?»—дип сорасалар, ул һич икеләнүсез япон китабының баш герое Кадзи исемен атар иде. Япон язучысы ул романын берниндн идеологик тышауларсыз, нинди дә булса сыйнфый карашларсыз безнең гасыр башында ук язган, ихтимал, шунлыктандыр, аның герое барлык чорлар һәм барлык халыклар өчен дә яраштлы чын герой булып чыккан.

Ул китап Рушанның исен китәргән иде һәм ул аны барлык дусларына-танышларына укырга тәкъдим итеп йөрде, әмма, ни сәер, роман берәүне дә ул кадәр сокландырмады, дәртләндермәде. Янә бер егерме еллар үткәч, поездда кемнәндер алып торган «Иностранная литература» журналының бер санында «Культура и искусство» дигән бүлектән Рушан Кояш чыгышы иле—Япония язучылары ассоциациясе Дзюнпей Гомикаваның «Кешенең яшәү шартлары» дигән романын егерменче гасырдагы иң яхшы япон китабы дип таныганлыкларын укып белде. Ул үзенең яшьлектәге сизгерлегенә шул чакта бик куанган иде, дөньяда иң күп укый торган ил СССР түгел, ә барыбер Япония икәнен дә белә иде инде.

Ә тагын бер биш елдан соң, ул әлеге китап белән бәйле янә бер шатлык кичерде—«Советская культура» журналыннан япон телевидениесенең шул роман буенча егерме серияле фильм төшергәнен, аны инде дистәләрчә илләр сатып алганлыгын укыды. Әмма сатып алучылар исемлегеннән Рушан үз дәүләтенең исемен юкка гына эзләп маташты—алар арасында СССР юк иде.

Бәлки, кайчан да булса, гадәттәгечә бик соңлап, бер ун елдан әлеге фильм безнең телевизор экраннарында да күренер, әнә, төшерелүеннән соң илле ел үткәч һәм бөтен дөнья сокланып туйгач, «Унесенные ветром» фильмын сатып алдылар бит. Менә шул чакта, мөгаен, нинди дә булса пенсионер карт моннан кырык еллар элек Заркентта Рушан исемле яшь прорабның әлеге романны укытырга тырышып, кайнарланып йөргәнен исенә төшерер: «Анарга кул гына селтәп караганнар иде, алай итәргә кирәк булмаган икән»,—дияр.

Барысы да булырга мөмкин, бернәрсә дә эзсез узмый, һәрнәрсә үзара бәйле, иртәме-соңмы ул билгеле була, барысы да үз урынына утыра, моның дәлиле—илебез тарихы, безнең бөтен тормышыбыз. Әле күптән түгел генә, чирек гасыр үткәч, Рушан яшьлегендә исен китәргән әлеге романның яңа басмасына тап булды. Һәр нәрсә кабатлана...

Җәйге бию мәйданчыгында Валя Домарованы чәчен сарыга буяткан маржа итеп күргән җәендә Рушан инде мастер булып эшли һәм Мартукка беренче хезмәт ялын үткәрергә кайткан иде. Ничектер әбәт алдыннан урамда йөреп керергә чыкты да, районүзәк өчен шактый бай булган китап кибетенә барып керде, шунда «Егерменче гасыр чит ил романы» сериясендә чыккан йомшак яшел тышлы юка гына бер китап сатып алды. Китап өч ел элек чыгарылган, хәзер бәясе төшерелгән һәм нибары егерме тиен тора иде. Ни китап авторы Фрэнсис Скотт Фицджеральд, ни романның исеме «Великий Гэтсби» («Бөек Гэтсби») Рушанга бер нәрсә дә сөйләми, бары тик сериясе һәм китапны чыгарган «Художественная литература» нәшрияты гына таныш түгел исемгә ышаныч тудыра иде.

Китапны ул өенә кайта-кайта ук укый башлады, аннары сатып алганнан соң ике сәгать эчендә укып та чыкты. Шул көнне үк Рушан кибеткә янадан килде һәм, сатучы кызларның шатлыгына, китапның калган барлык нөсхәләрен алып бетерде—нәкъ ике дюжина, ягъни егерме дүрт данә иде.

Ташкентта ул китапларны әдәбият сөючe дуслары һәм танышларына бүләк итеп таратты. Япон китабы белән булган шикелле үк, янә беркем бер сүз әйтмәде: ни мактаучы, ни яманлаучы булмады. Бу романны да «оныттылар». Ләкин Фицджеральдны, Гомикаваны көткән кебек, егерме ел көтәргә туры килмәде Рушанга: бер дүрт елдан соң аның «Назлы төн» романы басылып чыккач, ә бәлки, башка сәбәптәндер, иллә Фицджеральд китапларына ябырылдылар, аңа кадәр Хэмингуэйга шулай ябырылган иделәр. Шуннан соң «Бөек Гэтсби»ны үзе бүләк иткән байтак дуслары, романны соңлап булса да укып чыккач, Рушанга ул китап өчен рәхмәт әйттеләр...

Менә шундый сәер генә хәлләр килеп чыга тора аның тормышында. Гомерем бушка узды, ачышларсыз-эзсез узды, дип уфтанган авыр минутларда шундый юк кына нәрсәләр дә күңелгә бер юаныч була. Үткән гомеренә шулай йомгак ясый-ясый, Рушан тагын бер җавап табылмастай сорау белән газаплана: ни өчен ул Гомикава, Фицджеральдлар һәм хәтта Германиянең берләшәчәге хакында алдан күрә килде дә, ни өчен Лом-Али Хәкимов белән бергәләп Эллочка Изместьеваны киләчәктә прокурор һөнәре үләчәк, безнең җәмгыятьтә хокук органнарына эш калмаячак, дип ышандырып маташты һәм... бик каты ялгышты?

Ихтимал, шунлыктандыр, гадәт буенча «Ленин-Сталин балалары» дип йөртелеп килгән алар буыны яшь социалистик реализмның барлык күңелсез яклары—караңгы капиталистик үткәннән калган мирас, тирә-юньдәге барлык тискәре күренешләр, шул исәптән, җинаятьчелек тә чит идеологияне онытып бетермәгән өлкән буын китеп бетү белән үзеннән-үзе бетәчәк, дип ихластан ышана иде.

Рушан бервакытта да сәясәт белән артык кызыксынмады, нинди дә булса идеологиянең колы булмады. Әлбәттә, башкалар шикелле, ул да пионер, комсомол булып йөрде, әмма сәясәт аны мавыктырмады, үсеп җиткәч, һәр нәрсәне үзе уйлап хәл итәргә өйрәнде, бик тырышып үгетләсәләр дә, партиягә кермәде, кесәсендә партия билеты йөртмәде.

Хәзер күпләр, КПСС әгъзасы булмасаң, ни фәнгә, ни сәнгатькә, ни башкасына үрләп булмый иде, дип расларга тырышалар. Ахыр чиктә, үз буыны турында Рушан прорабларча туп-туры ярып әйтә ала: карьера ясар өчен, түрә булып, җылы кәнәфидә утырыр өчен керәләр дә инде партиягә. Сиңа партбилет тоттырырга теләүчеләр дә артык тел яшереп тормый, ачыктан-ачык әйтәләр иде: начальник буласың килсә, чит илләрдә эшләп кайтырга теләсәң—партиягә кер! Рушан кермәде, түрә булмады, чит илләргә чыгып «акча сугып» йөрмәде, әмма гомере буе прораб булып калуына тамчы да үкенми иде.

Рушан Дасаев эчке бер тоем белән сизенә: кешенең җирдәге бурычы—нәрсәгәдер-кемгәдер аркаланып-ышыкланып яшәү түгел, ә үзен кемдер булу, иҗтиһат итү, бар итү—әнә шул табигый ир-егетлек башлангычы аны дөньяны үзгәртеп кору, җирдә иң гадел җәмгыять төзү, гармоник шәхес булырлык яңа кеше тәрбияләү дигән купшы шигарьләр белән «өлкәннәр уены» уйнаучыларга кушылып китүдән тыеп тора да иде. Һәр почмакта, һәр рәсми бинаның маңгаенда чекрәеп торган атаклы Ленин сүзләрен акылы булган кешеләр партиягә пародия итеп кенә кабул итәләр иде бит. Чынлап та, көлке түгелме: «Кешелек дөньясы туплаган барлык белемнәрне үзләштереп бетергәч кенә коммунист булырга мөмкин»,—имеш. Мөмкин эшме соң бу?!

Нишләптер, тормышта бер генә андый хикмәтле коммунистны да очратканы булмады әле Рушанның. Рәсми саннар буенча коммунистлар иллә егерме миллионга якын дип исәпләнсә дә, юри җыйган кебек, ана

гел генә томаналары, наданнары, явызлары, аллакчылары очрап торды. Бәлки, сәясәткә карата нәфрәт хисе дә нәкъ шул Ленин сүзләрен укыганнан соң тугандыр әле. Рушан күзенә ул сүзләр бик иртә чалынды һәм ул аны ниндидер ялган-ясалма, тормышка ашмастайны чынбарлык итәргә теләү дип кабул итте.

Мөгаен, ни Ленин, ни партия турында Рушан исенә дә төшереп тормас, ничек булса да, аларсыз да яшәр иде әле, әмма бүген җәмгыятьтә шундый таркалу барганда, һәрбер җирдә сүз-бәхәсләр бары тик партия һәм аның юлбашчысы яки юлбашчылары тирәсендә генә бөтерелә— алардан һич качып котылып булмый...

Үзгәртеп коруның беренче юбилей елында,—аны да хәзер бишьеллыклар белән генә исәпли башладылар!—Рушан профсоюз санаториендә ял итте. Бер өстәлгә җитди ир-атлар туры килде. Арада иң яше Рушан, калганнары инде күптән илледән узган кешеләр иде. Һәм, әлбәттә, бар сөйләшкәннәре партия, үзгәртеп кору, Горбачев, Ленин—Сталин, бүгенге чын һәм ялган лидерлар-җитәкчеләр турында булды. Дасаев бу усал һәм буш әңгәмәләрдән бик тиз туйды, шуңа күрә ашарга алданрак та, соңга калыбрак та килеп карады, әмма көн саен була торган әлеге бәхәсләрдән котыла алмады. Җитмәсә, Рушаннан калганнар һәммәсе дә коммунистлар булып чыкты. Шуларның көнгә өч мәртәбә үз партияләрен ничек итеп әрләгәннәрен күрсәгез-ишетсәгез икән сез! Рушан берсендә түзмәде, сүзгә кушылды:

—Мин партия әгъзасы түгел,—диде.—Аңа мәхәббәтем-фәләнем дә юк, тормышыбызда партияне тиргәрлек җитәрлек җирлек булса да, мин аны каһәрләмим. Ләкин сезгә ачыктан-ачык әйтәсем килә: гомеремдә дә үз оешмасын сезнең кебек зәһәр күрә алмаучы кешеләрне очратканым булмады. Ни өчен соң сез, аны яратмыйча, аны мәсхәрәләгән хәлдә, һаман да партия әгъзасы булып торасыз? Ихтимал, сезнең берегез дә партия билетын тапшырмагандыр әле? Партия үзен күрә алмаучы, аның карашларын уртаклашмаучы кешеләрдән торганга күрә куркыныч та, миңа шулай тоела. Ул авыру партия, аны йә дәваларга, йә аңа тынычлап үләргә мөмкинлек бирергә кирәк...

Бу кайнар нотыгыннан соң Рушанга икенче өстәлгә күчеп утырырга туры килде.

...Ике иякле ленинчылар,
үлгәч тә кушылмам мин сезгә...—

кара әле, шагыйрьләр бу хакта да язганнар икән шул инде.

## XXXV

Совет дәүләтенә нигез салучы юлбашчының һәйкәлләрен илнең төрле почмакларында ваткан-җимергән көннәрдә Рушан Ленинның тууына йөз ел тулу уңаеннан булган бер вакыйганы исенә төшерде. Көнбатыш Украинада ничек итеп юлбашчының мәһабәт һәйкәлен кыйратканнарын телевизордан карап утырганда хәтеренә килгән иде ул вакыйга. Ә телевизор экранында коточкыч күренеш: муенына корыч элмәк кидерелгән таш Ленин, ә тирә-якта—куаныч, шатлык һәм... юлбашчыны яклап сүз әйтүче ник бер коммунист булсын!

Шул вакытта Рушан сәер бер халәт кичерде: әлбәттә, әлеге кыланмыш чеп-чи ясалма бер нәрсә иде, ләкин шул ук вакытта күңел түрендә ниндидер зур фаҗига эшләнгәнен тою хисе дә бар иде. Гадел, хак җәмгыять төзү мөмкинлегенә булган иман-ышанычның җимерелү фаҗигасе иде бу. Шулай ук андый җәмгыятьне төзеп булмыймы икәнни? Янә вә янә юлбашчыларны бәреп төшереп, һәйкәлләрен шулай кыйратырга туры килерме? Менә шулай уйланып утырганда, Рушан моннан ун еллар элек булган вакыйганы исенә төшерде дә инде.

Мең тугыз йөз җитмешенче ел. Юбилей елы язы—Советлар дәүләтенә нигез салучы бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның тууына 100 ел тула. Йөз ел—зур юбилей! Рушан зур гына бер төзү-монтаж идарәсендә эшли иде. Күрәсең, яшь булгангамы, аны профкомга сайлап куйдылар, сан булсын өчен генә эшләнгән гамәл иде бу, чөнки Рушан гел генә командировкаларда йөри иде. Менә шул чагында, юлбашчының юбилее алдыннан аңа җәмәгать эше йөкләделәр...

Профком җитәкчесе, бергә читтән торып укып йөргән курсташы Фарух Зарипов иде, Ташкент егете. Дасаев аны коридорда очраклы гына килеп төртелде.

—Ә менә безгә кирәкле кеше үзе дә! Куян сунарчыга таба чаба, диләрме әле?—дип, шатлыклы тавыш белән сөйләнә-сөйләнә, бер читкә тартты аны Фарух.—Тыңла әле, Рушан, тресттан бик дәһшәтле телефонограмма бар: Ленинның туган көне хөрмәтенә күргәзмә агитация материаллары кирәк, диләр...

—Юк, мин ни яза, ни рәсем ясый белмим,—диде Рушан, профком рәисенең шатырдатып кысып тоткан кулыннан ычкынырга тырышып.

Фарух елмаеп куйды:

—Ә мин синнән андый корбаннар сорамыйм. Партком кирәкле адресын да бирде: бөтен республика өчен стендлар—күргәзмә такталар ясый торган үзәкләштерелгән оешма бар икән.

—Ә фирма себеркеләр бәйләмиме?—дип үчекләп алды Рушан.

—Син ничек дип уйлаган идең? Партия бер эшне дә үз агымына калдырмый,—дип җитди җавап бирде Фарух.—Анда зур чираттыр әле, әзергә бәзер бер без генә түгелдер, блатсыз гына эш пешмәс. Дөрес, мине ул остаханә директорының фамилиясе шатландырды: Гольданский. Хәтерлисеңме, ул элек «Регина» ресторанында Хәлил белән бер оркестрда барабаннар сугып утыра иде, син бит яшьлегеңдә шәһәрнең барлык джазменнары белән аралаша идең, Кашгар егетләрен дә беләсең. Менә шулар майтара икән анда эшне. Марик Гольданский, җир тетрәгәнче, Үзбәкстан урамында—синең дустың Нариман белән бер ишегалдында яшәгән бугай. Кыскасы, бөтен өмет синдә. Юбилейга бер атна калды, табып алып кайт шул тактаны—беләсең бит, андый эшләр өчен таләп катгый. Шуны булдырып чыксаң, бурычның мөһимлеген истә тотып, үзеңә беренче чиратта диңгез буена юллама булыр...

Ничек баш тартмак кирәк? Марикны да күрәсе килә, «Регина» ресторанын, Хәлилне, Үзбәкстан урамындагы ишегалдын искә төшереп утырасы иде—шул ишегалдында атаклы футболчы Геннадий Красницкий да үскән бит әле...

Әлеге остаханә өлкә Офицерлар йорты каршындагы кайсыдыр ишегалдында булырга тиеш икән. Түр ишекләре мәрмәр баганалы, зиннәтле заллары, салоннары, рестораны булган бу мәһабәт бина кайчандыр Төркестан Дворяннар җыенынык булып, анда еш кына кичләрен Николай Икенче галиҗәнабләренең туганнан туганы, бөек кенәз Николай Константинович бильярд уйнарга йөргән, анда бик еш бал-кичәләр үткәрелгән, дәрәҗәле кунаклар кабул иткәннәр.

Рушанның яшьлек елларында өлкә Офицерлар йорты атаклы бакчасы, матур чәчәк клумбалары, галәмәт зур розарие, ачык һавадагы җәйге рестораны һәм бию мәйданчыгы белән дан тота, анда җитди, абруйлы халык җыела, якшәмбе көннәрендә оркестр уйный иде.

Элекке Дворяннар җыены йортында хәзер ни рәсемнәр галереясе, ни кайчандыр залларга, коридорларга, баскыч араларына күпләп тезеп куелган, сирәк очрый торган мәрмәр һәм бронза сыннар да күренми. Зал диварларын бизәп торучы гобелен келәмнәрнең уналтысыннан бары тик берәү генә сакланып калган, анысы да ике-өч җирдән тәмәке уты төшеп яндырылган. Аяныч күренеш, әлбәттә...

Мондагы бильярд залына революциягә кадәрле үк йөргән, күпне күргән бер карт сөйләгән иде: биредә гаҗәп бай китапханә булган,

кунаклар кабул иткәндә һәм бәйрәм көннәрендә өстәлләргә өч йөз кешелек фарфор һәм көмеш сервизлар—савыт-саба куела торган булган. Әмма хәзер юк тек юк инде, ярый әле, фоторәсемнәре сакланып калган. Шулай таланып, туздырылып беткән булса да, бу йорт илле елдан соң да сокланырлык иде әле, Рушан монда килергә ярата иде.

Остаханәгә барышлый ул, әле бер, әле икенче оешма һаман да җирен кишәрлекләп кисеп ала торгач, елдан-ел шигрин күн шикелле кечерәя барган бакча аша узды.

Ә бит элекке Дворяннар җыены йортының бу бакчасы Ташкентта атаклы бер рус ландшафт архитекторы, бакча-парклар белгече проекты буенча нигезләнгән бердәнбер бакча булгандыр—хәзерге ярлы тормышыбыз андый сүзләрне дә, андый һөнәрләрне дә белми инде. Бер нәрсәне дә рәтле-юньле төзи, иҗат итә белмәгән килеш, элгәрге буыннардан калган бай мирасыбызны, алга-артка карамыйча, вәхшиләрчә җимерә, юк итә барабыз—күңелсез хәл...

Җир тетрәүдән соң әлеге йортның роза түтәлләре каршысына ук килбәтсез бер галәмәт бина салып куйдылар—янәсе, милли ашлар ашханәсе. Урыны, әлбәттә, унайлы: Алай базары янәшәдә генә, бер квартал аша—Революция скверы. Рушан, пыяла һәм бетоннан ясалган, теләсә кем кереп-чыгып йөри торган бу тартма ашханәгә карый да, мондагы элгәрге биек мәрмәр болдырларын таш арслан саклап яткан ике катлы кызыл кирпеч йортны күз алдына китерә. Халык училищеләре смотрителе яшәгән ул йортта гимназист Александр Керенский үскән, В. И. Ленинның йөз еллыгын бәйрәм иткән көннәрдә ул карт Парижда мөһаҗирлектә соңгы көннәрен көтеп ята булыр хәзер. Элек Сталин урамы булган, аннары ташкентлылар буталып бетәрлек итеп, тагын берничә мәртәбә исемен алыштырган урамдагы, еллар үтү белән зур мәчегә охшап калган шул арсланлы йорт яныннан үткән саен Дасаев ничектер дулкынлана, элекке Дворяннар җыены йорты каршындагы кызыл кирпеч йортта үскән Керенскийның Бөек Октябрьгә катнашы булган шикелле, үзен дә шул чор тарихына катнашы бар кеше кебек тоя иде.

Рушан үзенә кирәкле остаханәне һәм Марикны эзләп йөргәндә, тагын шул ук ишегалларының берсендә кайчандыр шагыйрь Максимилиан Волошин да тукташтыргалаганын хәтереннән үткәрде. Рушан Дасаев Ташкентны ярата, аның тарихы белән кызыксына һәм аның күләгәле урамнарында йөргән, унайлы-тыныч чәйханәләрендә утырган күренекле кешеләр турында шушы көнгә кадәр бер китап та булмавына гаҗәпләнә иде. Кыскасы, Марик Гольданскийга ул юлбашчының юбилее тарихи мөһим икәнлеген аңлап, әмма күңеленнән, кызыл кирпеч йортта үсеп, иленнән качарга, картлыгының соңгы көннәрен читтә үткәрергә мәҗбүр булган малайны—Керенскийны да кызгана-кызгана барды.

Бүлмә ишеге шар ачык, каралар түгелеп, тырналып-кыршылып беткән өстәл өстендә тәмәке төпчеге төтенләп ята, хуҗаның әле күптән түгел генә монда булганлыгы күренә, әмма хәзер генә Гольданский урынында юк иде. Остаханә үзе күптән юылмаган биек тәрәзәле иркен генә ике бүлмәгә урнашкан икән. Диварлары һәм түшәмнәренә караганда, бу бинаның бер утыз еллап ремонт күрмәгәнлеге аңлашыла. Бүлмәләрнең ишекләрендә «Студия № 1», «Студия № 2» дигән язулары да бар. Ләкин ул бүлмәләрнең берсендә дә Марик юк иде.

Бүлмәләр рамнарга тарттырылып куелган киндерләр белән тулган—кайберләре инде грунтланган, калганнарын ашыга-ашыга грунтлап маташалар, кипкәннәренә исә оста гына итеп тиз-тиз квадрат шакмаклар сызалар, шунда ук рәссамнарга охшашлыклары бик аз булган ир-атлар ул шакмакларга буяу сала да баралар. Зал буйлап чабышып йөрүчеләрнең күбесенә рәсемнәрнең зур булмаган аерым өлешләрен: пинжәк, галстук, күлмәк ишеләрен генә буярга рөхсәт ителә, ә юлбашчының шул пинжәкләренә тоташкан башын, шулай ук квадрат шакмакларга бүлгәләп, бердәй пычранып беткән берет кигән дүрт рәссам ясый, аларның берсенең

муенында хәтта күбәләк-галстук та бар иде. Зал буйлап әрле-бирле чабышып йөрүчеләр белән беретлы кешеләр арасында нинди дер каршылык бар иде, күрәсең, алар үзара сөйләшмиләр иде. Аеры-чөере ишетелгән сүзләреннән Рушан шуны аңлап алды: юлбашчының костюмын буяучылар үзләренең күбрәк эшләгәнлекләрен исбатларга тырыша һәм түләве дә артыграк булуны таләп итә бугай.

Рушанга әйләнеп карауччы да булмады—конвейер өзлексез үз эшен эшли бирде, шунлыктан Рушан тәмәке тартып алырга җыенган күбәләк галстуклы остага мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды, бу гамәлгә калганнары өнәмичә генә караштырып алдылар. «Марк Натанович кайда?» дигән сорауга оста аның күрше тыкрыктагы «Михнәт» спорт залында икәнлеген әйтте, ул залны болар өч айга арендага алганнар икән.

«Михнәт» җәмгыятенең спорт залын Рушан яхшы белә иде: Ташкентка килгән беренче елларында ул бокс буенча күнегүләрен янартырга тырышып карады, әмма ничектер бер сәбәпсез рингка күнеле суынды һәм ул бокс пирчәткәләрен чөйгә элеп куйды. Аркылыга өч волейбол мәйданчыгы иркен урнашырлык бу спорт залының көтмәгәндә генә ни өчен Гольданскийга кирәге чыкканын ул берничек тә аңлый алмады. Шау чәчәкле сирень куаклары котырып үскән ишегалдында яз хөкем сөрсә дә, чәчәк исләрен келәй исе басып киткән иде. Рушанның башыннан бер уй чагылып үтте: җир тетрәгәннән соң эзе дә калмаган «Регина» ресторанының атаклы оркестры барабанчысы Гольданский әллә соң берәр яна төр келәй әзерләү цехы ачып җибәрдеме икән?

Рушанның спортзалда күренүе андагыларга да, үзенә дә шулкадәр көтелмәгән хәл булды ки, аны бары тик «Ревизор» спектакленең соңындагы классик күренеш белән генә тиңләргә мөмкин иде. Һәрхәлдә, Рушанга югалып калырлык та бар иде: зур спортзалның бөтен мәйданын тутырып ашык-пошык кына ясалган кузлаларга озын-озын идән такталары сузып салынган, алар галәмәт зур өстәл-конвейер хасил иткәннәр, шул өстәл тирәсендә башкаланың Рушанга таныш та, таныш булмаган да иң күренекле хатын-кызлары—гранд-дамалары әрле-бирле йөреп тора. Колакларында бриллиант алкалар, башларындагы чәчләре ул заманда «хала» дип йөртелгән, яхшылап өелгән биек прическалы, әле яна гына модага кереп бара торган гаҗәеп кыйммәтле әкәмәт экстравагант итек-оеклар... Бу гүзәлләр матурлап буялган-маникюрланган, йөзекле-балдаклы нәфис бармакларын кызык кына тырпайтып, зур картон щитларга фоторәсемнәр ябыштыралар, ул картоннар биек булып ишек янында ук өелеп тора иде.

Рушан шәхсән бу гранд-дамаларның белсә дә бик азын белгәндер, алай да берничә таныш йөз күренә, ул аларны театр премьераларында, ешрак «Регина» ресторанында, сирәгрәк концертларда һәм ул заманнарда киң таралган шау-шулы зур туйларда очраткалый иде. Бер үк урыннарда очрашып йөргәнлектән, алар да, әлбәттә, аны таныдылар, аннары шәһәрдәге азмы-күпме зыялы һәрбер кеше балетмейстер Ибраһимны белә, ә Рушан һәркайда аның белән була иде. Ибраһимны белмәгәннәре чибәр Нариман аптекарьны белә булыр, аның шундый атаклы әйтеме дә бар: «Даруханә аша һәркем үтә»—аның белән дә Рушан төрле җирләргә бергәләп йөри иде.

Гольданский үзе залның түрендә, ишеккә аркасы белән басып тора иде, әмма янындагыларның йөзләрендәге үзгәрешне күреп, шунда ук нәрсәдер булганлыгын, көтелмәгән куркыныч янаганлыгын аңлап алды һәм кискен борылып карады. Ишек төбендә аптырашта калган Рушанны күргәч, хатын-кызларның ни өчен тәшвишкә төшенүләрен аңлады һәм көлеп җибәрде, шунын белән киеренкелекне дә бетерде:

—Эшләгез, тыныч кына эшләгез,—диде.—Бу ОБХССтан түгел, хәтта фининспектор да түгел, минем дустым Рушан бу—Балерун белән Аптекарьның да иптәше...

Дасаев янына килеп, ул аны иненнән кочып алды да тиз генә ишегалдына алып чыгып китте.

—Бу гөлбакчаны ничек жыя алдың син?—дип шаяртып сорады Рушан.

—Вакытлыча, вакытлыча... Теләсә кемгә шундый зур акчалар тарата алмыйм бит инде мин, моны Ташкентта беркем дә аңламас иде. Ә сине нинди җилләр ташлады? Кассиус Клейны рингка чакырырга җыенасыңмы, әллә минем бу залны арендага алганны белеп килдеңме?

—Мин сиңа йомыш белән, Марик... Коткар. Сине юлбашчының туган көненә йөз ел тулу уңаеннан ясала торган күргәзмә агитация материалларының республика күләмендәге монополисты, диләр... Безнең конторага өстән телеграмма килеп төште: табарга, әлеп куярга, урнаштырырга...

—Афәрин, егетләр! Шәп эшлиләр,—дип җанланып көлеп җибәрде Марик. Күрәсең, ул шәһәр яки район комитетының идеология бүлегендә эшләүче берәрсен күз алдында тоткандыр.—Бары тик бик зур блат белән генә, иске дус итеп кенә. Анда да акчасын чек кенәгәсе аша түләсәң генә, безгә аны алуы җиңел булсын өчен, дим.—Марик ачыктан-ачык әйтеп бирде шул.

—Чек тек чек, парторгка әйтермен, ул бухгалтерияне мәҗбүр итәр. Син соң хет күрсәт инде, без нәрсә өчен акча чыгарып салырга тиеш булабыз?..

Гольданский өстәлләргә картон таратып йөрүче үсмер малайны чакырып алды да әзер продукцияне китерергә кушты.

Берничә минуттан стенд Рушанның күз алдында иде инде. Аның «Ленин—безнең юлбашчыбыз һәм остазыбыз» дигән баш сүзләре юбилей уңае белән менә дигән шома ак кәгазьгә басылган ун тиенлек плакаттан кисеп алынган. Астарак ваграк хәрефләр белән, шулай ук плакаттан, әмма башкасыннан алынган язу: «В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңаеннан». Бу плакатларның әле ачылмаган рулоннары өстәл-конвейерларда тау-тау өелеп ята иде.

Стендның сул ягын юлбашчының атаклы рәссам Андреев ясаган, чынлап та, бик әйбәт портреты бизи, ул алтынсу-саргылт төстә, әмма монысы да яхшы ак картонга миллионлаган тиражлар белән басылган һәм гел юк кына бәя торган изопродукция. Бу портретларның өеме дә плакат рулоннары белән янәшә куелган иде. Ике квадрат метрлы стендның калган өлешенә күпсанлы фоторәсемнәр ябыштырылган. Аларны җентекләбрәк карап чыгу өчен Рушан иелә төште.

Ленин бала вакытында, Ленин әнисе тезендә утыра, Ленин абыйсенелләре белән, Ленин—гимназист, Ленин террорист абыйсы Александр белән, мәктәп медале һәм мактау кәгазьләре, Ленин—студент, Ленин эмиграциядә, Ленин велосипедта йөри, Ленин шалашта, Разливтагы шалаш үзе, Ленин броневикта, Ленин ниндидер крестьяннар белән, Ленин Луначарский белән, Ленин Крупская белән, Ленин Горкида коляскада, Ленин табутта...

Фоторәсемнәр бик начар сыйфатлы, Ленинны юньләп танып та булмый, бигрәк тә кышкы киемнән ул кысык күзле юлбасарга охшаган, аның белән рәсемгә төшкән башка кешеләр турында сөйләп тә торасы юк иде.

—Начар фоторәсемнәр, юбилей көнендә табутта яткан Ленин да кирәкмәстер,—диде Рушан, Гольданскийның иҗат җимешен карап бетергәннән соң.

—Ә мин әйбәт дип әйтмим дә. Кызганыч, дәүләтебез яхшы фоторәсемнәр буклеты бастырырга уйлап житкермәгән, без шуларны ябыштырган да булыр идек. Борчылма, Рушан, бәхәсләшә алам—аларны синең кебек җентекләп беркем дә карап тормаячак, табутына да игътибар итмәячәкләр. Табут мәсьәләсендә син хаклы, әлбәттә, уйлап бетермәгәнмен...—Марк сүзен бүлеп, ачык ишек ягына кычкырды:—«Ленин табутта»ны тиз генә алыгыз, «Ленин Шәрекъ хатын-кызлары арасында»ны

куегыз. Шулай иткәндә, сәясирәк тә, урынлырак та булыр.

Марик Рушанга борылып, бүленгән сүзен дәвам иттерде:

—Бер әрҗә коньякка бәхәсләшә алам: үземнең бала чагымда чүлмәктә утырган фоторәсемемне куйсам да—кем дә булса игътибар итәрме икән?—Аннан кинәт кенә көчешсез-нисез сорап куйды:—Майлы буяу белән ясалган зур портретын телисеңме, нибары мең сумга, дуслык хакына гына?

—Шакмакларга сызып эшләнгәненме?—дип көлемсерәде Рушан.

—Шакмаклымы, әллә буйлымы—анысы әһәмиятле түгел. Кемне ясаулары һәм һәр кабинетта кем эленеп торуы мөһим. Кипренский, Рокотов яки безгә ят ниндидер Гейнсборо ясаган рәсемнәр түгел иң, Айвазовский, Куинджи пейзажлары да түгел. Үзебезнеке! Син, кадерлем, сәяси өлгермәгән икәнсең әле, мөгаен, шуна күрә прораблыкта төртелеп калгансыңдыр да.

—Бу галәмәт әштер-өштер иттерүне үзең уйлап таптыңмы?—дип турыдан-туры сорады Дасаев. Әйтергә кирәк, аны Гольданскийның колачлы «предприятиесе» тан калдырган иде. Аптырабрак өстәп әйтте:—Идеология шушылай юмарт ашатырга мөмкиндер, дип уйламаган идем...

—Бары тик идеология, бары тик партия генә туйганчы ашата да инде, мыегыңа чорнап куй, иптәш прораб...

Гольданский канәгатьлек белән кулларын уып алды һәм, сабый балага аңлаткандай итеп, Рушанга аңлата башлады:

—Мондый зур чаралар йөз елга бер генә була. Мин аны озак көттем—ике ел алдан Ленинга багышланган символикаларны, плакатлар-рәсемнәрне күпләп сатып алып, җыя башладым. Идеясе-фикере, уйлап табуы—минеке, ләкин боларны сезгә сатып алырга мәҗбүри таккан, бары тик Гольданскийдан гына алырга кирәклеген өйрәткән кешеләрсез бу идея сукыр бер тиен дә тормас иде. Хәзер төшендеңме инде, ни өчен шәһәрнең иң кәттә гүзәлләре миндә вакытлы эштә икәненә? Бер атнадан бу синекура[1] тәмамланачак, алар туган илебезнең иминлеге-муллыгы хакына «ижтиһади» хезмәтләре өчен шундый сумманы кесәләренә салачаклар, кайсыдыр ки, мөгаен, премия вә артыгын эшләгән өчен өстәмә түләүләренне дә кушып, синең ярты еллык хезмәт хакыңны каплап китәдер. Акыллы кешеләрнең акчаны ничек ясаганнарын төшендеңме инде?..

Дасаев төшенде: «Ленин табутта», «Ленин Шәрекъ хатын-кызлары белән»ише фоторәсемнәрне бер ай чамасы ябыштырып утырганнары өчен партноменклатураның хатыннары вә сөяркәләре Рушанның төшенә дә кермәгән ярты еллык хезмәт хакына бәрабәр акчаны кесәләренә матур гына салып куйганнар икән бит! Андый акчага, аларның мөмкинлекләре һәм танышлыклары белән, «Волга» автомобилен дә,—ул нибары 5600 сум тора иде,—шул чама ук бәягә өч бүлмәле кооператив квартир да, әле өстәп, өч бүлмәгә житәрлек мебель—йорт жиһазлары да алырга була иде ул заманнарда.

Хәзер, менә-менә пенсиягә чыгам дип торганда, шымытыр байлыгы да булмаган Рушан кайбер аерым сөйләшүләрне, сирәк-мирәк укылган мәкалә-фәләннәрне исенә төшерә. Алар һәммәсе дә ничектер юлбашчының шул юбилее белән дә, бүген Ильичның һәйкәлләрен жимереп кенә түгел, социализмның барлык билгеләрен, шул исәптән, бронзадан һәм металлдан коелган, гранитка һәм мәрмәргә уелган «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг-шигарен дә вәхшиләрчә кырып-себереп, коммунизм идеяләрен бар дөньяда кире кагуга бәйләнгән булып чыга. Рушан, үз тормышының-яшәешенең төп өлеше хезмәт белән, төзелеш белән бәйле чагында, андый вак-төяк вакыйгалар, аеры-чөере күренешләр күнелендә эз калдырмый узган икәнлеген аңлый, ә менә

[1] Синекура—күп хезмәт куюны сорамый һәм яхшы түләнә торган вазифа. *Тәрҗемәче искәрмәсе.*

хәзер, кара әле син, ул жепнең очы шул заманнардан ук сузылып килә икән ич...

Рушан кайдандыр укыган иде: Фридрих Энгельсның әнисе,—югары зәвыклы, тирән белемле, бай һәм данлыклы гаиләдә тәрбияләнеп үскән ханым,—марксизм белән мавыгып киткән һәм Карл Маркска финанс ярдәме күрсәтеп торган улына үзенең бер хатында, аналарча йомшак кына, хәтер калдырмаслык кына итеп яза: «Фред, сөйкемлем, миңа син кирәкмәгән нәрсә белән шөгыльләнәсең шикелле тоела...»

Карл Маркс үзенең «Капитал»ын эшләп утырганда, нашириеннән янаулы хат ала: «Хөрмәтле Маркс әфәнде! Әгәр дә Сез килешенгән вакытка «Капитал» дигән хезмәтегезне китереп житкермәсәгез, без аны язарга башка авторга заказ бирәчәкбез...»

Ә Бисмарк, кирпеч калынлыгындагы фундаменталь «Капитал»ны укып чыккач, титул битенә язып куйган: «Кешелек бу бухгалтер белән изаланачак әле...»

Кызганыч, бөек юлбашчы һәм фикер ияләренең эксперименты уйлап табылган жирендә тормышка ашырыла башламаган, ә Россиягә килеп төртелгән. Коммунизм идеясе Европада, башкалаларның уңайлы-тын кафеларында, кунакханәләрнең, китапханәләрнең бүлмә-залларында туган, ә ул «ботканы ашарга» хәзергә хәтле башка халыкларга туры килә.

Бәлки, кайчан булса да, ул сер дә чишелер: ни өчен андый тәжрибәне Россиядә үткәрергә булдылар икән? Бәлки, халкы һәрвакыт беренчелекне яраткангадыр, гаделлеккә һәм тигезлеккә сусау көчле булгангадыр? Россиядә яшәүче халыкларның күпчелеге урыслар тарафыннан яулап-басып алынган, ничәмә-ничә гасырлар изелеп-жәберләнеп килгән халыклар бит. Гаделлек-тигезлеккә алар сусамый, кем сусасын тагын?

Коммунистларның үзара идеологик бәхәсләре аркасында Рушанга икенче өстәлгә күчеп утырырга туры килгән санаторийда тагын бер вакыйга булган иде.

Рушан анда бик тәкәббер бер карчыкка игътибар итте. Карчык үзен ачу китерерлек дорфа тота, теләсә нинди бәхәсләргә ярсып катнашып китә иде. Күршеләре Горбачевны ачыктан-ачык яманласалар, үзгәртеп коруны тиргәсәләр—әбкәй риза, ул бөтен бәлаләрне хәбәрдарлек һәм демократиядән күрә, шуларны пыр туздыра. Ә инде Горбачевны яклаучылар булса—бетте! Түзеп кенә тор әбекәйнең әче теленә!

Рушан үзен дәвалаучы табибтан кызыксынып: «Ни өчен карчык бернинди үзгәрешләрне дә кабул итми икән?»—дип сорады.

Бөтенесе дә бик гади булып чыкты: баксаң, әбекәй сынчы-скульптор икән, гомере буе Ленинны ясаган, юлбашчының бюстларын аннан да оста коючы булмаган икән, кепкалысынмы, яланбашлысынмы, бүлмә өстәленә куярлык кечкенәләренме, мәйданнарны бизәрлек мәһабәтләренме—һәммәсен дә коеп кына куя торган булган икән. Юлбашчының кибетләрдәге канцтоварлар бүлекләрен тутырып утыручы бронзадан, гипстан, чуеннан, мәрмәрдән эшләнгән кечкенә генә кулсыз статуэткалары да әлеге карчыкның ижат жимеше икән, дип шаярталар иде ял итүчеләр. Ничәмә-ничә еллар бу әбекәй һәртөрле күргәзмәләрдә һәм вернисажларда призлар вә медальләр алып килгән һәм кинәт, көннәрдән бер көнне, барысы да юкка чыксын әле—спецзаказлар, спецмашиналар, спецфәләннәр... Үзгәртеп коруга ярсып ташланмый хәлең дә юк. Сызгырырсың, кодагый!

Күптән түгел генә Рушан өлкә Офицерлар йорты янынннан узган иде—акшарлары кубып-кубып төшкән диварлар, күптән буявы янартылмаган, авыр бронза тоткалы ишекләр, ул тоткалар кайчандыр Дворяннар жыены йортына килеп, кичләрен бильярд уйнарга яраткан бөек кенәзнең кул жылысын да саклыйлардыр кебек әле...

Рушанның күңелендә юлбашчының портретын шакмакларга сызып мең сумга ясап бирә торган остаханә калкып чыкты. Социалистик дәүләткә нигез салучы Ленинның грандиоз юбилеена Ташкентның кәттә хатын-

кызлары «иҗтиһади хезмәт» куеп, мәш килеп «акча сугып» яткан «Михнәт» спорт залы исенә төште.

Болар берсе дә хәзер юк, гаип булды, эреп бетте, онытылды. «Су күмгәндәй, вакыт күмде һәммәсен дә...»—монысын да кайсыдыр шагыйрь әйтеп калдырган.

Моннан утыз еллар элек бу хәлләр булган урында хәзер Үзбәкстан Энергетика министрлыгының мәһабәт бинасы күккә үрләгән, Ташкентта Марк Натанович Гольданский да юк—ул күптәннән инде Нью-Йоркта яши, Брайтон-Бичтагы рус ресторанны (!) «Одесса» оркестрында уйный, «Регина» ресторанындагы шикелле, яңадан бәрмә уен коралларына кайтып төшкән, барабан суга, имеш, дип сөйлиләр.

Ихтимал, кайчандыр балалар бакчаларыннан башлап һәр учреждениене мәҗбүри «ленинчылаштырырга» күрсәтмәләр биреп, дәһшәтле телеграммалар җибәреп, ә хатыннары һәм сөяркәләре Ленинның 100 еллыгыннан файдаланып, «акча сугып» утырган түрәләр дә күптән үз кабинетларыннан башка җылы урыннарга очканнардыр яки шул ук кабинетларда, исемнәрен генә алмаштырып, утырып калганнардыр. Янә дә бер сызгырырсың, кодагый!

Теге «кәттә маржаларның» берәрсен дә күргәне-очратканы юк Рушанның, дөресен генә әйткәндә, үзе дә сирәк чыгып йөри, күбрәк кичләрен тәрәзә буенда уйланып уздыра ул: кая бара бу дөнья?..

## XXXVI

Үткән елларын һәм үзе белән аралашкан кешеләрнең язмышларын искә төшереп утырганда, Рушан кайвакыт гел дә әһәмиятсез булып тоелган хәлләргә барып юлыга, әмма ул хәлләр көтмәгәндә генә, кинәт алар буынының тормышында хәзер дә чагыла, һәммәсенә дә башкачарак карарга мәҗбүр итә.

Күптән түгел генә эшкә китешли, ул баскыч төбендә кемдер төшереп калдырган егерме тиенлек акча күрде. Акча ике бетон плитә арасындагы ярыкта, аны алыр өчен берәр чыбык-мазар кирәк, аның өше нәрсәләр чүпле-пычрак ишек төпләрендә аунап ята.

Күп квартирлы йорт ишек төбендә яткан шул егерме тиен көмеш мең тугыз йөз алтмыш беренче елгы акча реформасын искә төшерде. Берләшкән Милләтләр Оешмасының Генераль Ассамблеясында ботинкасы белән өстәл төеп, дөньяны таңга калдырган генсек Никита Сергеевич Хрущев, акча реформасының сәбәпләрен аңлатып, үзенең гадилеге белән трибунадан бик ышандырырлык дәлил китергән иде: «Һе, симерделәр, юлда бер тиен ятса—иелеп алучы юк. Ә менә хәзер, без аның бәясен ун тапкыр арттыргач, берәү дә узып китмәс...»

Башка бик күп нәрсәләрдә ялгышкан шикелле, бу юлы да ялгышты Никита Сергеевич. Бәясе ун тапкырга арткан егерме тиенлек тә күптән инде беркемне дә кызыктырмый—ә бит ул девальвациядән[1] соң утыз ел узды. Яңасы, тагын да явызрагы ишекне какты һәм, түргә узып, халык өстенә шундый көч белән килеп төште ки, тын алырлык та хәл калмады.

Девальвация... Арзанаю... Акча арзанаю белән генә бетсә икән әле! Кая карама—девальвация... Хисләрдә, мөнәсәбәтләрдә, бурыч тойгысында. Бер нәрсәнең дә бәһасе юк хәзер—кеше язмышларының да, тормышның үзенең дә.

Узган гомеренә нәтиҗә ясап, Рушан тагын шуны күрде: соңгы елларда аның аралашып йөри торган даирәсе-мохите бик нык тарайган икән бит. Билгеле, биредә яшь үткән саен була торган югалтулар да бар,

[1]Девальвация—яңа акча кертү юлы белән яки кулланышта булган акчаның рәсми курсын төшерү, арзанайту юлы белән үткәрелә торган акча реформасы. *Тәрҗемәче искәрмәсе.*

телисеңме-теләмисеңме, бер йодрык булып укмашкан төркемнәр таркала, дуслар каядыр югалып бетә, нәкъ атаклы шигъри юллардагыча: «Берәүләр юк инде, ә берләре ерак...»

Профком рәисе Рушанны, дөнья пролетариаты юлбашчысының юбилеена стенд табып кайтырга, дип, Марик Гольданскийга җибәргәндә әйткән иде: «Син яшьлегеңдә Кашгар егетләрен яхшы белә идең, алар шунда эш майтарып яталар»,—дигән иде.

Кашгар Ташкентның атаклы яһүдләр төбәге иде, җир тетрәп ул гомерлеккә юкка чыкты. Кашгарда сатира театры артисты Роман Ткачук туып үскән, кинорежиссер Юнгвальд Хилькевич та, Ленинград шагыйре һәм актер Владимир Рецептер да, Роксана Бабаян да шуннан иделәр. Кашгар илдә танылган күп кенә спортчыларны, ни өчендер боксчыларны гына, үстергән: Йосыф Будманны, ул хәзер Нью-Йоркта яши, Володя Огороновны, хәзер рингта рефери вазифаларын үтәүче Тимер Гулямовны. Мюнхен Олимпиадасында Абу Нидаль террорчылары тарафыннан үтерелгән Илья Люксембург та Кашгардан иде. Кашгарның үз Мишка Япончигы—Фима Боднеры, хәтта үз Мюллеры бар иде—актер Леонид Броневой да тумышы белән Кашгардан бит. Теләгәндә, бу исемлекне чиксез сузарга да була...

Кашгар Ташкент өчен Одессаның Молдаванкасы кебегрәк урын иде. Әйтергә кирәк, шәрекънекеме, гарепнекеме, әллә Кавказныкымы—мәсәлән, Баку яки Тифлис—көчле яһүд катламы булган шәһәрләр, андый диаспора булудан ота гына, аннан һәрвакыт рухи һәм эшлекле тормышның куәтле агымнары бөркелеп тора.

Әйе, Рушан андагы егетләрне яхшы белә, ә аның җеп очы Үзбәкстан урамындагы колонкадан аккан суы мәңге кипмәс ишегалдыннан башланган булгандыр. Шунда, Гольданскийларга күрше булып, аның аптекарь дусты, чибәр Нариман яши иде. Бүген, барлык халыкларның да милли хисләре көтмәгәндә генә кабынып китеп, бер-берләренә урынлы да, урынсыз да дәгъвалар белдерә башлаган заманда, Рушанның яшьлегендә исә паспорттагы бишенче графа—«милләт» графасы ташкентлылар тормышында бернинди дә әһәмиятле роль уйнамаганын, кешеләрнең бөтенләй башка сыйфатлар буенча дуслашу-аралашуын, якынаюын күз алдына китерүе дә кыен.

Менә алар өчлеген генә алыйк: Ибраһим—балалар йортында үскән Коканд үзбәге, Нариман—бакулы, Рушан үзе Оренбург татары, тумышы белән Көнбатыш Казакъстаннан.

Кемгә генә төртмә, алар янында уралучылар да шундый иде. Шәһәрдә мәгълүм бертуган Рожковлар—Славик белән Гера—урыс фамилияле булсалар да, чынлыкта нинди милләттән икәнлекләрен үзләре дә белми, рок-н-роллны искиткеч оста биюче Юра Толстой—урыс, Ваган Адамян, Урта Азиядәге бик күп әрмәннәр шикелле, тамырлары белән Карабахтан булса да, үзе ташкентлы әрмән. «Регина»ның атаклы саксофончысы Хәлил—үзбәк, «Пахтакор» футбол командасының легендар һөҗүмчесе Берадор Абдураимов (Абдерәхимов) Григорий Федотов исемендәге бомбардирлар клубындагы бердәнбер үзбәк... Бүген аның белән янәшә һәрвакыт сөйкемле, бик җанлы йөзле һәм акыллы карашлы Тайванец кушаматлы үсмер искә төшә. Ул малай футболны шулкадәр ярата, Берадорны Алла урынына күреп, ана шулкадәр табына иде ки, Абдураимовны Мәскәү «Спартаг»ына чакырып алгач, ул ана ияреп китеп барган иде. Рушан аны үсеп егет булгач, бер генә күреп калса да, искә төшүе юкка түгел иде.

1971 елның кара көзенә ике футбол клубы—Мәскәүнең «Динамо» һәм ЦСКА командалары ил чемпионатында очколар саны буенча тигез булып чыкты. Алар арасында өстәмә уен булырга тиеш иде һәм бу командалар очрашу урыны итеп Ташкентны сайлап алдылар, аларга кадәр Мәскәү «Торпедо» сы белән Тбилиси «Динамо»сы да шулай эшләгән иде.

Уен гаҗәп зур, күрелмәгән ажиотаж, шау-шу тудырып, «Пахтакор»

стадионы камалышта булды. Ләкин Рушан, уенны карарга эләкте генә түгел, ә гадәттә командаларның икенче алмаш—дубль составы һәм команданы озатып йөрүче күпсанлы кемсәләр генә кертелә торган матбугат ложасына үтеп керә алды. Ул вакытта Берадор Абдураимов ЦСКАда уйный, ә үсеп җиткән Тайванец шул клубның ниндидер хуҗалык эшләрен башкаручы вазифасына билгеләнгән иде инде. Ничектер шулай килеп чыкты, Рушан ложада Алик Тайванец белән янәшә утырды.

Уен армиячеләр өчен уңышсыз башланды: тәнәфескә алар инде 0:2 исәбенә оттыралар иде, мондый дәрәҗәдәге уен өчен нокаутка тиң исәп. Матбугат ложасында «Динамо» өчен янучы-көючеләр дә бар—алар командага ияреп, шәһәрдән-шәһәргә күчеп йөрүче, поезд тәрәзәләрен кырып төшерүче яшь фанатлар түгел, билгеле, ә житди һәм хәлле-бай меценатлар иде, андыйлар хәзер бөтенләй юкка чыкты. Тайванецны белгән бу кемсәләр, «Динамо»ның җиңүе хөрмәтенә «Ташкент» ресторанына банкетка алдан ук заказ биреп куйганнар икән. Алар Аликны «кыздырырга» керештеләр. Уен барышыннан күзен ала алмаган Алик аларга ул елларда акылдан язарлык суммага—ун мең сумга пари-бәхәс тәкъдим итте: ЦСКА җиңәчәк, диде. «Динамо»га табынучылар аңа шунда ук банк кәгазе дә ертылмаган йөзлекләрдән торган бер төргәк акча суздылар. Алик, эчке күкрәк кесәсеннән шундый ук төргәк акча алып, икесен дә Рушанга тапшырды—йоласы шундый, акча битараф кеше кулында булырга тиеш. Шуннан соң ложадагыларның уенны ниндиї кызыксыну һәм дулкынлану белән карап утыруларын күз алдына китерергә мөмкиндер!

Төп вакыт эчендә армиячеләр исәпне тигезләделәр: 2:2. Өстәмә тайм алдыннан Тайванец мангаена бәреп чыккан тирләрен сөртеп, әйтеп куйды: «Ну, хәзер безнекеләр егып салачаклар...»

Шулай булды да! Бу финал уенының герое элекке легендар бомбардир Григорий Федотовның улы Владимир Федотов иде. Ул хәлиткеч ике тупны кертеп, үзенең тормышында иң яхшы уенын уйнады, ә бит бу сезон аның футбол карьерасында соңгысы иде инде.

Рушанның хәтерендә Тайванец менә шундый комарлы футбол белгече булып сакланып калган да. Әмма аның искә төшүе футбол уены яратканы өчен генә түгел һәм хәтта пари-бәхәс аркасында гына да түгел.

Шактый вакытлар үткәч, Рушан аның Мәскәүдә атаклы итальян мафиозие дон Карлеоне шикеллерәк «абруйлы» кеше булып танылуын, башкаланы үз кулында тотуын һәм ташкентлыларга ярдәм итүдән бервакытта да баш тартмавын ишетте. Бервакыт «Лотос»ка кергәч, Аликның бер кичтә кәрт уйнап бер миллион сум откаңын да әйттеләр. Әле менә күптән түгел генә, үзгәртеп корунын кызган—әллә котырынганмы?—бер чорында «Правда» газетыннан укыды: безнең ил мафиясе киң фронт белән халыкара аренага чыккан һәм Көнбатышта шактый йогынтысы бар икән. Мәкаләдә Тайванец исеме дә телгә алынган иде. Алик хәзер Германиядә, зиннәтле-бай виллада яши һәм Мюнхенның «Бавария» футбол командасына үлеп гашыйк, шуңа табына икән.

Шулай итеп, Дасаевка кирәкмәсә дә, тагын бер сер, футболны бик тә яратучы үсмер малайның сере ачылды.

Әйе, Кашгар егетләре футбол ярата иделәр. Шагыйрь әйтмешли: «Ил корабын җил өрә...» Әмма ул елларда җилләр безнең җилкәннәргә уңайрак иде шикелле, шуңа күрә футбол белән мавыгучылар да күп иде. Бу мавыгу, танылган спортчыларны шулай ярата белү—шул заманны аңларга, шул заман кешеләрен аңларга ачкыч түгелме?

Рушан тагын бер хәлиткеч финал уенын хәтерли, анысы Тбилиси «Динамо»сы белән Мәскәү «Торпедо»сы арасында булган иде. Андый шау-шуны, андый ажиотажны, шулкадәр куначкларны Ташкент аңа кадәр дә, аннан соң да күрмәде. Ихтимал, футбол сөючеләрне Грузиядән Үзбәкстанга көнгә дистәләрчә самолет яллап ташу,—моны «чартер рейсы» диләр,—илебез тарихында беренче тапкыр булгандыр, ике республика

арасында хөкүмәт элемтәсе өзелеп тормады.

«Без шәһәрне грузиннарга өч көнгә бирдек»,—дип шаярттылар ташкентлылар. Һәркайда грузинча сөйләшүләр ишетелә, һәр жирдә аларның ул заманнарда бик тә модалы аэродром-кепкалары шәйләнә. Шәһәр халкының үзенә ул көннәрдә ни бер ресторанга, ни бер кафега керергә мөмкинлек юк—һәммәсендә дә кунаклар кәеф-сафа кора, күңел ача иде.

Уен буласы көнне аэропортта хәлләр хәйран иде. Кайдан гына самолет очып килмәсен—Мәскәүдәнме, Киевтанмы, Бакуданмы, Ереваннанмы, Ростовтанмы, Минеральные Водыданмы, Симферопольдәнме, Аллерданмы—пассажирлар гел генә грузиннар булды: шулай урау юллар белән булса да, яраткан командаларының уенын карарга Ташкентка килгән иде алар. Андый уенга керү билетының шәһәрдә нинди бәя торуын күз алдына китерүе кыен түгел иде, бигрәк тә футбол тирәсендә бихисап «коңгыз-кортлар» кайнашкан шәһәрдә...

«Пахтакор» стадионына тәпиләп барганда ун минутлык арада булган «Ташкент» кунакханәсе янында, әле уен башланырга сәгатьтән артык вакыт булса да, инде сөйләп биргесез ыгы-зыгы башланган. Илнең төрле якларыннан жыелган репортерлар, фотохәбәрчеләр, тележурналистлар, дәрманчы-табынучылар, грузин футболын сөюче үзбәкстанлылар, Казакъстанның һәм Тажикстанның якын-тирәдәге шәһәрләреннән килүчеләр, меңләгән грузиннар үзләренең кумирларын—иң яраткан футболчыларының кунакханәдән чыкканын көтеп торалар.

Ишекләрен киң итеп ачкан зур һәм «Икарус» автобусы да мәйданда иде инде. Көтеп торучыларны тагын да кыздыру ниятеннәндер, күрәсең, төп төркемнән шактый алданрак өч уенчы күренде, болар сакчы Гурам Петриашвили, Джемал Зейкеншвили һәм Гурам Цховребов иде. Хәзерге шикелле аунап-таушалып беткән спорт костюмнары кимәгәннәр, ә галстук таккан, чәчләрен әйбәтләп тараган егетләр иде алар. Көяз-купшылар, үз-үзләренә ышаныч белән атлый-атлый, алар тәрәзәләренә пәрдә тартылган чия төсендәге автобус эченә тиз генә кереп югалдылар.

Рушан белән аның дуслары милиция чылбырлап алган тере коридор аша карап тора, менә-менә бөтен команда килеп чыгарга тиеш, шул чагында, милиция сафын кысыла-кысыла ерып, Володя Огоронов үтеп китте, әмма ул стадион ягына түгел, ә Нариманның даруханәсе ягына таба атлады.

Огоронов белән Будман күптән түгел генә бокс буенча СССР халыклары Спартакиадасында чемпион исеме яулаган, илнең жыелма командасына кертелгән һәм Ташкентта зур шөһрәт казанган иделәр. Мөгаен, аны таныганга күрә, милиция кордоны үткәреп жибәргәндер дә. Рушан янындагы кемдер, Ибраһим булды, ахрысы, ана дәште:

—Володя, футболга бармыйсынмыни?

Огоронов кунакханә алдындагы мәйданда туктап калды, таныш тавышка әйләнеп, беркатлы-самими генә итеп сорады:

—Ә кемнәр уйный бүген?

Жыелган халык шаркылдап көлеп жибәрде, шул вакытта кунакханә ишегеннән килеп чыккан грузин командасы бу көлүнең сәбәбен тәки аңлый алмый калды.

## XXXVII

Хәзер инде Ташкентта Кашгар егетләреннән Рушанга танышлары аз калды. Язмыш жиле аларны дөнья буйлап таратты. Кайвакыт Дасаевның почта тартмасында, күршеләрнең күзен кыздырып, бик зиннәтле-матур открыткалар күренә, алар йә Тель-Авивтан, йә Хайфадан, йә Лондон белән Амстердамнан, Сан-Франциско белән Гамбургтан була. Дусларының илдән үз ирекләре белән һәм таза-тук тормыш кына эзләп китмәгәнлекләрен һәр күршегә аңлатып йөреп булмый.

Кашгар егетләренең монда да майлы ипиләре бар иде. Кайберләренең чит илләрдә күптән инде үз виллалары, «Мерседес» машиналары бар, әмма алар һаман да Кашгардагы уңайлыклары булмаган фатирларын, тәрәзә буендагы сирень куакларын, шау-шулы Алай базарын һәм үзләренең бәхетле көннәрен сагына. Балачак урамнарын бернәрсә дә алмаштыра алмый, сагынган минутларында аларның тамакларына төер утыра.

Яшьлегендә Рушан дуслашып йөргән Кашгар егетләре буыны шулай ук әтисезлектән иза чикте, аларның да күпчелеге югары белемне, Рушан шикелле, читтән торып алды. Аларның төзелеш факультетындагы группалары интернационал булса да, өчтән бере яһүдләр иде, тагын өчтән бере—греклар белән немецлар, соңгыларына кереп укуны шактый кысканлыктан, аларга бердәнбер мөмкинлек читтән торып уку булды.

Башка курс-факультетларда да чама белән шундыйрак нисбәт иде. Рушан укуын тәмамлап килгәндә, Корея милләтеннән булган студентларның нык артуы күзгә ташлана—аларның күпчелеге теләсә кайсы инженерлык эшендә дә әһәмиятле анык аналитик фикерләүгә сәләтле кешеләр иде. Ни өчендер ул елларда Үзбәкстанның төп халкын төзүче-инженер һөнәре кызыксындырмый, алар күбрәк юридик, сәүдә, халык хужалыгы, автомобиль юллары төзелеше белгечлекләренә омтыла иделәр.

Рушанның яһүдләр, греклар, немецлар арасында дуслары күп булды, ул немецча аңлый һәм аңлаша да ала—Мартукта Вуккерт белән дуслыгы эзсез калмаган икән.

Соңгы елларда, үзгәртеп кору дигән нәмәрсәнең көткән өметләрне акламавы һәм тупыйкка барып төртелүе бәхәссез икәне күренгәч, милли мөнәсәбәтләр бик кискенләшеп китте. Рушанның институтта укыган, Кашгардан ук аралашып йөргән танышлары күп кенә һәм алар гына да түгел, башкалар да илне ташлап китә башлады.

Алтмышынчы елларда Ташкент бик нык үсә, һәркайда төзелешләр күтәрелә һәм, дөресен әйтергә кирәк, барлык эре трест һәм идарәләрнең дә диярлек башлыклары яһүди инженерлар иде. Опера театрының гаҗәеп матур бинасын атаклы архитектор Щусев проекты буенча әсир японнар кулы белән Пикман күтәртте, театр алдындагы мәйданны төзетте, татар Булатов проекты буенча «Ташкент» кунакханәсен житкерде. Сугыш башланыр алдыннан гына Ташкентның иң матур Нәвои урамы төзелә башлаган, ул төзелешне Крайзман житәкләгән. Ташкентның су белән тәэмин ителеше бик камил уйланып эшләнгән, ә сугару системалары заманча элемтә челтәрләре, республиканың металлургия һәм химия предприятиеләре төзелешләренә хезмәт күрсәтүче беренче «Спецмонтажстрой» тресты башында Горенштейн тора, атаклы «Ангреншахстрой»да—Терман, «Высотстрой»да—Каменецкий. Ә Рушан эшли башлаган беренче идарәне Марикның әтисе Гольданский оештырган. Бу исемлекне чиксез дәвам иттерергә булыр иде, әле бит тагын сәламәтлек саклау, югары белем бирү, авыр машина төзелеше кебек тармаклар да бар...

Рушан төзелеш мәйданнарында, планеркаларда очрашып-аралашып йөргән байтак кешеләрнең бик азы гына торып калды, күбесе китте, бетте шул. Аңа һаман да күңелсез хәбәрләр килеп ирешә—фәлән киткән, барган, фәләннәр китәргә җыена, фәләннәр виза көтә... әйтерсең, кемдер аның тирә-юнендәге дусларын-танышларын чалгы белән чаба...

Америка илчелеге, башка илләрнең илчелекләре алдындагы озын-озын чиратларда—нигездә яһүдләр белән әрмәннәр. Бик күңелсез, хафага төшерерлек күренеш иде бу. Рушан хәзер үзенә ни өчен? ни сәбәпле кебек мәгънәсез сораулар бирми инде. Чөнки белә: яхшы тормыштан яки алда көткән рәхәтлекләрдән качмыйлар, берәү дә үз-үзенә, балаларына һәм оныкларына дошман түгел. Ул әлеге бөек таралуның төп сәбәпләре аңларга гына тырыша. Сумгаитта әрмәннәрне үтерәләр—яһүдләр кача, Үзбәкстанда месхет төрекләрен үтерәләр—яһүдләр кача, элеке союздаш республикалардан күпләп урыслар китә—янә дә шул ук хәл: яһүдләр кача...

Рушан үзенең үткән тормышын, кинотасма шикелле, артка табан сүтә-сүтә дә, балачагына, сугыштан соңгы ярлы Мартукка барып төртелә...

Поселокта төрле милләт кешеләре житәрлек иде, әмма яһүд гаиләсе берәү генә булды. Хәер, ул вакытта бишенче графа турында сүз дә юк, чөнки күпчелек халык сталинчыл билгеләмәгә туры килә—нацменнар. Рушан укытучы апаның, ниндидер рәсми кәгазьләр тутырганда, һәр баланы бастырып, нинди милләттән икәнлеген сораштырганын хәтерли. Җавап: чечен, ингуш, татар, башкорт, немец, чуваш, мордва. Укытучы, дәфтәрдән башын күтәрми генә, кыскача гына раслап тора: «Димәк, нацмен»,—ди. Аннан соң күп еллар үтте, хәзер Рушан ул кыскартылган кушма сүзнең мәгънәсен аңлый инде: нацмен—национальное меньшинство, ягъни милли азчылык. Сыйныфтан бары тик өч бала гына «нацмен» категориясенә керми калды—урыс, украин һәм казакъ. Калганнар балаларча беркатлы үзара мөнәсәбәтләрендә әнә шул көтелмәгән туганлыктан файдаланалар: «Син дә нацмен бит»,—дип кенә җибәрәләр. Сыйныфтагы бердәнбер яһүд малае Лева Бернштейн да шул категориягә керә иде.

Үсә төшкәч, алар милләтнең ни-нәрсә икәнлеген аңлый башлаганнар иде инде, әмма аннан да элгәре үзләренең нинди диннән булуларын төшенделәр, чөнки чиркәүнең дә, мәчетнең дә авылда үз йогынтысы бар иде. Мартуктагы бик күпләр шикелле, Рушан да сукыр Мәмлиева әбинең еш кына: «Әгәр дә чеченнәр безнең дин кардәшләребез булмасалар, кырык бишенче елның кышында туңып үлеп беткән булыр иде»,—дип әйткәнен хәтерли.

Бәлки, әби-бабайларның тырыша-тырыша балаларга иман нуры индерүләре сабыйлар күңелендә якынына, тирә-юньдәге һәр җан иясенә рәхим-шәфкатьлелек булып шытып чыккандыр да әле. Хәзер бар әшәкелеге белән өскә калыккан мәрхәмәтсезлек, әдәпсезлек, әхлаксызлык һәрвакытта да шундый иде, дип, Рушанны беркем дә ышандыра алмас. Әйе, алар, ул сыйфатлар да һәр заманда булган, әмма бу кадәр киң таралып, халыкның барлык катламнарына да үтеп кермәгән, хатын-кызларга исә бөтенләй диярлек кагылмаган. Ул вакытларда кемнән нәрсә көтәргә булганын чамаларга мөмкин иде. Җәмгыять рәхим-шәфкатьлелек белән, бер-берсенә ярдәмчеллек белән яшәде, шулай итеп кенә сугыш елларында исән калды, сугыштан соң тернәкләнеп китте. Моның ачык мисалы—яһүд малае Лева иде.

Лева Бернштейн чибәр, күркәле егет булып үсте, ләкин үҗәт-кире, күкерт кебек кабынып китүчән, әгәр дә ачык кына әйтсәк—ызгыш-талашсыз яши алмый иде. Кырыс тормыш җәмгыятьне дә кырыслыкта тәрбияли, Мартукта һәркем үзен-үзе яклый ала, шуңлыктан тәкәббер Лева еш кына һәм бик урынлы кемнендер йодрыгын татымый калмый иде.

Аны кайчан да булса бер, бигрәк тә мәсьәлә кызларга кагылганда, үтергәнче кыйнап ташларлар иде инде, ләкин бик кызып сугышып киткәндә дә кемдер:

—Җитәр, ул бит бездә бердәнбер яһүд,—дип әйтеп куяр иде.

Никадәр сәер тоелмасын, шул сүзләрдән соң сугыш туктала, «яһүд» сүзенә бернинди мәсхәрәле мәгънә дә салынмый, ә тиз һәм күп гашыйк булучан Лева моннан оста файдалана да иде бугай әле—әгәр җинелә башласа, коткарачак сүзләр яңгыраячагын белә: «Ул бит бердәнбер...»

Техникумда Рушан белән бер группада Ефим Ульман укыды, алар хәтта бер бүлмәдә ике ел бергә яшәделәр дә. Ефим детдом егете, үзенең кайдан икәнлеген, әти-әниләренең кемнәр булганлыгын белми иде. Аның укуы да шәптән түгел, уртачадан түбән һәм ул Рушаннар группасына курсыннан күчми калган укучы буларак килеп кушылды—детдомныкы булмаса, аны, мөгаен, техникумнан чыгарган да булырлар иде.

Ульманның ни өчен йомыкый, көтмәгәндә генә усалланып-ярсып китүчән, һавалы, үтә тәкәббер булганлыгын хәзер аңлый Рушан. Күрәсең, үзенә уку авыр бирелгәнне егет бик тирән кичерә торган булгандыр. Анысын да аңлап була: тимер юллар төзү аның күңеле тарткан эш түгел,

күнеле аның башкага омтыла-ымсына иде. Ә балалар йортында, ихтимал, егеткә һөнәр биреп, алгы тормышында ышанычлы икмәге булсын дип тырышканнардыр: ул елларда тимерюлчы иң отышлы һөнәр санала иде бит.

Тулай торакта гитара—гомер-гомердән беренче уен коралы. Рушаннар белән дә гитарада оста уйнаучы байтак кына егетләр яши иде. Ульман кинәт кенә гитарага чат ябышты, озакламый һәр компаниядә аның уйнавын үтенә башладылар, ул шундый чакларда бөтенләй үзгәреп китә иде.

Рушаннарга электротехника курсын Петербургтан килгән карт профессор Глузман укыды. Аларның гап-гади шул техникумнарында укытучыларның төп өлешен исемле кешеләр, Казакъстанга сөрелгән профессорлар тәшкил итә иде.

Һәркем белән бик тәкәллефле сөйләшә торган Глузман еш кына кәефсезләнеп Ефимга:

—Ульман, мин сезне шулкадәр тинтәк булырсыз дип көтмәгән идем,—ди.

Бу сүзләрне беркем дә җитди итеп кабул итми, йөрәгенә якын алмый иде. Рушан хәзер генә аңлый, Ефимга никадәр рәнҗеш, кайгы-хәсрәт китергәндер карт профессорның әлеге сүзләре.

Бер укытучы гына түгел, группадаш иптәшләре дә кимен куймый. Кайчакларда, Ульманның югары математикадан яки сопроматтан берәр эше барып чыкмаса, егетләрдән кем дә булса берәрсе әйтеп ташлый:

—Ә җитмәсә яһүд әле...—ди.

Ефим кызлар белән мөнәсәбәтләрендәге уңышсызлыкларын да бик авыр кичерә, юкса ул вакытта алар группасыннан кем дә булса мәхәббәт фронтындагы уңышлары белән мактана алыр идеме икән әле?

Дүртенче курста укыганда, язын, диплом алды практикасы башланыр алдыннан Ефим поезд астына ташланырга итеп караган, әмма машинист уяу булган, егетнең нервлары соң минутта түзә алмаган—Ефим рельслар арасыннан сикереп чыккан.

Бер бүлмәдә яшәгәч, Рушан белән Ефимның бер-берләреннән яшерерлек әлләни серләре юк, ул чорда һәркемнең тормышы уч төбендәгедәй күренеп тора, хәтта мунчага да төркем-төркем йөриләр иде. Ефимның үз-үзен үтерергә җыенуының сәбәпләрен берәү дә әйтә алмады. Әмма шул вакыйгадан соң һәр ике тулай торак—кызларныкы да, егетләрнеке дә—үзара сөйләшеп тормастан, аны шефлыкка алды, Ульманны вак-төяк өчен шаяртып үртәштерүдән дә туктадылар. Рушанга Мартуктан ук таныш: «Ул бит безнең бердәнбер...» дигән тылсымлы сүзләр монда да үз эшен эшләде.

Рушан, ялга кайтып, джаз яратучы прокурор каберенә беренче мәртәбә килгән елны очраклы гына белеп калды: Ефим тәки поезд астына ташланып һәлак булган, профессор Глузманга оныкы тиешле кызга гыйшык тоткан, тегесе моны яратмаган икән, дип сөйләделәр.

Инде утыз ел үткәч, курсташы Ефим Ульманны искә төшергәндә, Рушан ахыр чиктә үзе өчен яһүдләрнең ни өчен илне ташлап китүләренең сәбәпләрен ачыклады шикелле.

Яһүдләр ирексез яши алмый. Һәр нәрсә чикләнгән җәмгыятьтә үзләренә катгый билгеләнгән урын кысаларына сыешып яши алмый алар—бу очракта хакимият тә, партия дә көчсез, яһүдләр күнелләре ни тели, шуның белән генә шөгыльләнә ала.

Ефимның язмышы—моның ачык мисалы, аңа тимерючының ышанычлы тук-имин тормышы кирәкмәгән булып чыкты. Аның, мөгаен, гитарада уйныйсы һәм Глузманның оныгын сөясе килгәндер... Күнеле кабул итмәгәнне яратырга, күнеле ятмаганны эшләргә теләмәгән ул, аңа мондый тормыш кирәкмәгән һәм шуның өчен ул үз тормышы белән хушлашкан да.

Яткан туфрагың мендәр булсын, Ефим! Профессор Глузманны һәм,

сопромат белән машина детальләрен анларга көчен житмәгәндә, сине рәнжеткән барлык башкаларны гафу кыл... Күнеленнен андый белемнәргә ихтыяжы булмаганга күрә, син аларны кабул да итә алмагансың, сине башка нәрсәләр ымсындырган...

Нигезенә үзләре дә байтак чи кирпечләр салган яһүдләрнең СССРдан фажигале рәвештә күпләп китүләрен Рушан шулай гына, бары тик шулай гына аңлата ала.

Безнең бөтен тормышыбыз бер үк төрле стереотиплардан-калыплардан тора, мондый караш Рушанны пошаманга сала—дөньяны янача корып, һәркемгә тигез-гадел мөмкинлекләре булган җәмгыять төзергә, җәмгыять мәнфәгатьләрен шәхси мәнфәгатьләрдән өстен куя алучы, идея дигәндә үзенең иң хәләленнән дә ваз кичә белүче яна гармоник шәхес тәрбияләргә тырышып караганнарның бушка көчәнүләрен өйрәнгән очракта, менә кайда ул киләчәк философлар өчен бетмәс-төкәнмәс тема!

Шундый стереотип карашларның иң киң таралган берсе—яһүдләр үзләрен яклый алмый, аларны куркыту җиңел, дигән караштыр. Бу әкиятне үзләре шуны күрергә теләүчеләр генә сөйли.

1987 елны, үзгәртеп коруның иң кызган бер мәлендә, Ташкентның «Ереван» рестораны янында үзенең кулдашы һәм тән сакчысы белән бергә Нарик Каграмянны атып үтерделәр. Ул шәһәрдәге кооператорларга гына түгел, көн саен диярлек зур ришвәтләр алып яшәүче дәүләт хезмәткәрләре һәм партноменклатурага да үз ясагын салган, чын-чынлап шәһәр хуҗасы булып алган иде. Һәркем ачуланган кылана, Нарикны да, шәһәрдә нәрсәләр эшләнгәнен белмәмешкә салынган хакимиятне дә каһәрли, ләкин ясакны һәммәсе дә төгәл түләп килә. Бары тик яһүдләрнең генә түземе төкәнде, хакимият кешеләре, Нарикка күзләрен күтәреп карарга да курыккан бер заманда, яһүд егетләре әлеге дәһшәтле-явыз мафиозины халык күз алдында атып үтерде.

Хакимиятне үз кулларында тотучылар зурлыгы белән Рәшидовныкыннан аз гына калышырдай галәмәт җеназага җыелып килделәр. Әле бүгенгә кадәр көн дә чәчәк салынып тора торган Нарик һәйкәле кебек бер ун һәйкәл илдә табылырмы икән? Хакыйкый хак хакимият үзенең каһарманнарын зурлый, хөрмәт итә белә...

Мафиози Каграмянның үлеме Рушанның ирекле яһүдләр рухы турындагы фаразын тагын бер тапкыр раслады: оятсызлык, кабахәтлек дәрәҗәсе аларның абруен түбәнсетерлек чиккә җиткәч, яһүдләр, башкалар түзгән шикелле, түзеп тора алмады.

Халыклар аңында нык урнашкан тагын бер тотрыклы ялган стереотип караш бар: имештер, кавказлы милләт кешеләре, үзләренең шәхси абруйларын бик хөрмәт иткәнлектән, артык хисчән һәм күңелләре тиз яралanучан булганлыктан, иреклелекне гадәттән тыш зур бәһалиләр һәм кешене түбәнсетергә юл куймыйлар.

Әмма совет-партия режимы елларында кешенең абруе беркайда да Кавказдагы кебек оста мәсхәрәләнмәс һәм аяк астына салып тапталмас иде, түрәләргә тәлинкә тоту, ялагайлану анда шулкадәр мәгънәсезлекләргә, көлкеле мәзәк хәлләргә барып җитә иде ки, Кавказ ул яктан караганда үзенең Гогольләрен һәм Салтыков-Щедриннарын көтә әле. Партия җитәкчеләренең андагы кебек үзбелдеклеләнеп дуамалланулары, башбаштаклыклары, кешедән көлүләре, булса да, тагын Урта Азиядә генә булгандыр. Ә бит, үзләренең җиңел яралanучан булуларына һәм нәзакәтлелекләренә карамастан, яшәгәннәр, түзгәннәр, түрәләрнең ботинка бауларына чаклы бәйли торган булганнар, кешенең абруен түбәнсетүче-мәсхәрәләүче феодал байларча мөнәсәбәтләрдән котылырга бик үк атлыгып та тормаганнар.

## XXXVIII

Искә төшерергә теләгәннәрен хәтереннән үткәреп, заман, дуслары һәм сөйгәннәре, үзе һәм туганнары, әнисе һәм үги әтисе турындагы хатирәләрне әлеге дә баягы «мәңгелек гомер китабы»на теркәп калдырырга уйланып утырганда, Рушан таң кала: ничек итеп сәясәт һәр нәрсә өстеннән шулай өстенлек итә ала? Безнең бөтен тормышыбыз биләүдән үк диярлек ничек шулкадәр сәясиләштерелгән, идеология белән сугарылган? Ә бит ул үзенең язмаларында заманның исен һәм төсен, чәнечкеле шайтан таягы аралаш зәңгәр күзле күкбашлар чәчәк атып утырган, үлән арасындагы каен җиләкләре, юа-балтырганнары, кузгалагы-какылары белән балаларны куандырган басу-болыннарын, күбәләкләр, энә караклары, чикерткәләр, коңгызлар, тургайдан алып бөркеткә кадәр һәртөрле кошлар үз йорты иткән даланы сурәтләмәкче булган иде.

Ләкин хәтердә гел-гел генә якты, матур истәлекләр яңарып тормый шул. Әллә никадәр үлем-китем дә искә төшә.

Поезд астына ташланып, сукыр Мәмлиева әбинең оныгы Хәлил белән детдом баласы Ефим Ульман һәлак булды, самавыр күмере өчен тарткалашып, берничә малай шулай ук үз үлемнәрен тимер юлда тапты. Үткәннәреннән якты сәхифәләр эзләп, Рушан күңеленнән елга, урман, далаларны айкый, янадан Мартукка әйләнеп кайта.

Шулай да үги әтисенә «әти» дип әйтеп калырга өлгерде ул. Исмәгыйль абзыйның үлеменнән соң кайткан тагын бер вакытын исенә төшерде Рушан. Комбайнчы бер күршеләре соңгы еллардагы уңышлары өчен халык хуҗалыгы казанышларының Бөтенсоюз күргәзмәсендә бүләккә «Волга» машинасы алган икән, Рушанның Оренбургка барып кайтырга җыенганын белгәч, ул аңа, яңа машинаны юлда йөртеп сынап карау ниятеннән, машина белән барырга тәкъдим итте. Оренбургка барып житмәсә дә,—анысының үз сәбәпләре бар иде,—бу юл Рушанның күңеленә озакка кереп калды.

Мартукның бер чите урман полосаларына барып чыга, шул полосалар буеннан Оренбургка илтә торган юл сузыла. Рушан мәктәпкә йөри башлагач утыртылган агачлар, үсеп житеп, хәзер чын урман булган иде инде. Билгеле, Себер кинлекләрендәге яки Белоруссиядәге ише карурман түгел, әмма далалы як өчен—чын урман. Рушанның яшьлегендә, урман әле менә-менә күтәрелеп килгәндә, анда әле җәнлек-җанварлар да, каргадыр, чыпчык-күкедер кебекләрдән башка кош-кортлар да юк иде. Ничектер, мәктәптә: «Керпе күрдем»,—дип сөйләгән иде, аңа берәү дә ышанмады.

Ә хәзер куян-төлкеләр дә, бурсык-бүреләр дә, борындыклар һәм хәтта кабан дуңгызлары, пошилар да бар, дип сөйлиләр. Ә бит аларны беркем дә үрчетергә дип махсус җибәрмәгән—үзләре бар булганнар һәм вәссәлам! Табигать табышмагы...

Урман да түзеп булмаслык эсселектән әлсерәгән шикелле тоела иде. Юл читенә койма булып тезелешеп баскан агачлар иксез-чиксез казакъ далаларыннан искән коры чиллә жилләрен тоткарлый, әмма үзләренең яфраклары кибеп-куырылып, шыштырдап тора. Хәтта кошлар тавышы да ишетелми—үле тынлык. Кечке салкынны, тереклекнең жанлануын көтүче тынлык. Рушан, машинасын урман авызында кинәт кенә туктатты да, агачлар арасына кереп китте, үләннәре тапталмаган, кечкенә генә чиста яшел алан табып, курткасын салып ташлады һәм шуның өстенә хәл алырга утырды.

Алда, ике-өч разъездга житәрәк, шаулап килгән поезд тавышы ишетелде. Бу дөбердәп-шалтырап килгән состав түгел, ә иксез-чиксез кинлектә, гаҗәеп тынлыкта, артында дистәләрчә-йөзләрчә чакрымнар калдырып һәм алда да шулай булачагына ышанып, кешеләр далага таралып яшәгән яклардан чабып килүче поезд тавышы иде. Ул тавыш кечкенә авыл-фәләннәрдә яшәүчеләрнең йөрәкләренә үтеп керә, үзәкләрен өзә, чөнки аларның тормышка ашмаган яшерен хыяллары һәм кыюсыз

өметләре шул юлга бәйләнгән, бу тавыш күнелләрдә, тәгаен анык кына булмаган, әмма нииндидер куанычлы үзгәрешләр көтү тойгысын уята.

Зенләп торган урман тынлыгы, килгән-киткән поездларның әнә шул тигез һәм чиста тавышлары, бихисап агачларга бәрелеп, галәмәт бер органда ниндидер моңлы көйгә әверелә шикелле һәм ул Рушанны тагын сагышлы истәлекләргә алып китте: йомыкый балачагына, шәһәрдәге ышанычсыз, ярлы студентлык елларына кайтарды. Мартук шикелле вактөяк авыл-поселоклардан килгән аның ише егетләрне, укып чыкканчы диярлек, «колхозник» дип кенә йөртәләр иде. Берәүләр бу сүзне төрле төсмерләрдәге мыскыллау рәвешендә әйтә, икенчеләре исә, гадәтләнелгән буенча, начар гадәт буенча дип әйтик, болай гына ычкындыра, ләкин барыбер һәр ике очракта да күңел рәнжи—«колхозник»...

Хәтерендә, беренче курсны бетереп кайткач, Рушан, кызарына-бүртенә, ничектер унайсызланып һәм бик буташтырып, бу хакта үги әтисенә сөйләгән иде. Әмма Исмәгыйль абзый аңлап алды. Ул Рушанга текәлеп карап торды да, гадәттә ачуы килгәндә генә һәм риза булмагандагыча итеп, мыегын еш-еш сыпыргалап, тыныч кына әйтте:

—Монда, улым, сезгә беркем дә ярдәм итә алмастыр. Егет кешегә, чын егет кешегә берәү дә, бервакытта да мыскыл сүзе әйтмәс. Ә сез әле беркем дә түгел. Сез әле борын асты кипмәгән чебешләр генә...—диде. Аннары, бераз тынып торгач:—Кайда, кайчан тууың, нинди милләттән булуың тормышта бер өстенлек тә, ышаныч та бирми. Кеше үзендә булганны үзе тәрбияләп үстерергә тиеш, кеше җирдә эше-шөгыле белән генә таныла ала, менә шунда инде туган җире дә, туган елы да, хәтта милләте дә истә тотыла...—дип өстәде.

Шул чагында, әллә Исмәгыйль абзыйның ышанып, басым ясап әйткән сүзләреннән, әллә кабатлап сораган булып, «колхозник» сүзен әвәләвеннән Рушан югалып калды, үги әтисенең әйткәннәрен аңлаудан битәр, оялды шикелле, чөнки «колхозник» сүзе ана «Дасаев» булып ишетелде кебек...

Урман тынлыгында озаклап утырып булмады—юл алга дәшә иде. Сагарчинны үтеп, Куандыкка якынлашкач, Оренбургның үзенә дә кул сузымы гына калганда, күпер күренде. Аны төзәтеп-ремонтлап азапланалар иде. Мөгаен, язгы ташкыннарда зыян килгән булгандыр. Дасаев машинасының тизлеген киметте. Ярымачык тәрәзәдән балачак елгасы Илекне хәтерләтеп, су исе бәреп керде. Рушан күпердән сак кына чыкты да ирексездән машинасын туктатты.

Алда, күз күреме җирдә, яшел ярлар арасыннан, елан шикелле бормаланып-сырмаланып, иртәнге тын елга агып ята иде. Сай урыннарда әкрен генә чылтырап, сирәк култыкларда кара-кучкылланып, бөтерелеп, сазлыклардагы камышларны кыштырдата-кыштырдата, ашыкмый гына ага иде ул. Кайбер урыннарда су өстеннән ара-тирә, күзгә күренер-күренмәс иртәнге томан сызылып күтәрелә, ә тар урыннарында биек яр өстеннән салынып торган йөзьяшәр карама агачларының күләгәсе җемелдәп ялтырап яткан су өстен зонтик кебек каплап-карангылап тора иде. Елганың тәбәнәк икенче як ярын куе таллык каплаган, таллардан ары болын башланып китә—күрәсең, язларын елга шул болыннарга киң булып ташып җәеләдер. Елганың һәр борылышын борыла-сарыла кабатлаган тугайлыклар еракларга сузыла, әмма Рушан аның ары башын барыбер күрә иде.

Болынны күптән түгел генә чапканнар, анда да, монда да зур булмаган печән кибәннәре күренә, ә үлән яшелләнеп яңадан үсеп-күтәрелеп килә—елганың якынлыгы һәм юмартлыгы сизелә.

Тып-тын, бер кеше әсәре күренми, бары тик, Мартуктагы шикелле булып, еракттагы поезд тавышлары гына шәйләнә, ул тавышлар, уянып килгән иртәнге елга өстендә яңгырап, күңелдә матур, саф хатирәләрне уята.

Аста җәйрәп яткан болыннарга карап, Рушан бала чагында

төнгелеккә ат сакларга барганнарын, тышаулы атларны, шаян колыннарны, атаклы чабышкыларнның пошкыруларын һәм бияләрнең түземсез кешнәүләрен исенә төшерә, төнге учак ялкыннарын күрә шикелле иде. Тик, күрше казак станицалары һәм казакъ авыллары малайлары арасында үзен күрсә дә, тегеләрнең кем кайдан икәнен анык кына хәтерли алмый, чөнки болын барысы өчен дә уртак, кешеләргә тагын бер болын бүләк итәргә Илек суы артык кечкенә иде шул.

Юк, хәзерге транзистор-магнитофонлы малайларны төнге тынлыкта ат саклаган рәвештә күз алдына китерә алмый ул. Юкса станица һәм авылларда атлар әле дә бетеп житмәгән, һәр язда, жәй башында казакъ һәм татар авылларында Сабантуйлары үткәрелә, көзләрен казак станицаларында уныш бәйрәмендә ат чабышлары, ат өстендә кылыч айкап йөрү ярышлары уздырыла. Ул бәйрәмнәргә һәркайдан, хәтта шәһәрләрдән дә бихисап халык жыела иде. Ә ат өстендә нинди егетләр генә үзләренең осталыкларын күрсәтми, нинди егетләр генә егетләнми! Һәм алар һәммәсе дә төнге ат саклау мәктәбен үткән егетләр булыр иде.

Жир йөзендә атлар бетмәгәндә, төнге ат саклаулар да бетмәячәк, чөнки алар балачак, үсмерчакның иң матур, иң дулкынландыргыч чоры бит, димәк, жирдә асыл егетләр дә бетмәячәк. Мөгаен, хәзер башка заман—башка төрле куна баруларлдыр... Мөгаен... мөгаен...

Рушан биек яр өстеннән агымсуга, иркен болыннарга озак карап торды, биредә хәтердә гел якты истәлекләр генә янара, ул әле үткәненә әйләнеп кайта, әле киләчәгенә дә үрелеп карый шикелле иде. Шул сурәтләр күз алдында алмашынып тора. Менә ул күтәрелеп килгән яшь үлән арасында беленеп торган атлы печән чапкыч эзен күреп алды, карашы белән аны озата барып, болынга төшә торган юлны да шәйләде. Кузгалып, Оренбургка китәсе килми иде.

Карамалар үскән биек яр артында казак станицасы барлыгы сизелә иде. «Бүген якшәмбе, базар көне, әле житешермендер, мөгаен»,—дип уйлап алды Рушан, үзенең шактый ачыкканлыгын тоеп. Ул машинасын борып, авыл юлына чыкты да шул биек яр буйлап бара башлады, кайдадыр авылга борылып кергән юл булырга тиеш иде.

Бу казак станицасында Рушанның булганы бар, үги әтисе аны базарга бер генә алып килмәде, ә бервакыт, Исмәгыйль абзый станица тегермәнендәге тузып беткән, иске «әгелчән» двигателен төзәткәндә, алар икәүләп юлаучылар йортында бер атна торган иделәр. Рушан ул чагында аңлый алмый интекте: болар һәммәсе дә, Мартуктагы күршеләр шикелле, урысча сөйләшәләр, бары тик яше-карты елтыр козыреклы кызыл кырпулы фуражка киеп йөри иде. Ә ни өчен «казаклар» дип аталалар—шайтаным белсенме? Әле тагын станица гел генә ап-ак акшарланган йортлары—казакча «хаталары», чия бакчалары белән истә калган, Мартуктагы кебек иске-жимерек ник бер генә йорт булсын! Аннары үги әтисенең, тегермәндә эшен бетереп Мартукка кайткач әйткән сүзләре хәтерендә, күрәсең, авылдашлары казакларның тормыш-көнкүреше турында сорашканда әйтелгәндер инде:

—Казакларда тәртип кырыс: урманны сакла, елганы сакла, болыннарны сакла—шуңа күрә алар әйбәт яшиләр,—дигән иде Исмәгыйль абзый.

Ул вакытта әле борын асты юеш малай елганы, урманны, болынкырларны ни өчен сакларга кирәклеген аңламый иде. Алар бит гомергомердән булган, бар һәм булачак шикелле—ә кешенең монда нинди катнашы бар?

Бер ун минуттан барып кергән станица моннан утыз еллар элек булган казак станицасын хәтерләтми иде инде. Хәзер ул Мартукка охшап калган, вакыт дигәнең үзенекен эшли шул, үзенә генә хас сыйфатлары югалып беткән диярлек. Анда-санда күренгән эленмә такталарга карап, Рушан станицаның хәзер райүзәк булганлыгын чамалады.

Кайчандыр, беркемнән дә сорап тормастан, ничек кирәк алай

асфальт салынган, хәзер инде чокыр-чакырланып беткән тузанлы үзәк урамыннан, дангыр-донгыр дөбердәп узып, базарга барып чыкты ул. Әкренләп тарала башлаган, инде комарлыгы һәм жегәре беткән базар гына балачактагы станицаны бераз хәтерләткәндәй булды.

Базар коймасы буенда әле олаулы-тарантаслы, ачык арбалы атлар тора, хәтта пар ат жигелгән, чикылдашып-чинашкан ике-өч айлык дуңгыз балаларын сатып торучы ябык фургон да бар иде. Рушан машинасын төрле төсләре белән ялтыр-елтыр килеп торган «Жигули»лар рәтенә куйды да базар эченә кереп китәргә ашыкты. Әмма, ничек кенә ашыкмасын, дала аргамаклары кимереп бетергән борынгы араталар янынннан адымнарын әкренәйтмичә генә үтеп китә алмады. Тагын кайда һәм кайчан мондый урынны күрә аласын әле? Мөгаен, бүгенге балалар, хәзер автомобильләр һәм велосипедлар куярга махсус урыннар булган шикелле, элек аргамак атларны бәйләп куя торган урыннар да булганлыгын уйлап та карамый торганнардыр.

Араталарда үткән-сүткәннәргә куркынып караштыргалаган һәм нечкә аяклары белән борчулы-тынычсыз таптангалап торган бер унлап ат бар иде. Аларның икесенең сыртында зиннәтле, борынгы казак иярләре, бөтен дирбияләре каралтылган көмештән булганлыктан, алар бик тә авырдыр шикелле күренә, хәтта югары күтәртеп тарттырылган өзәнгеләренә кадәр көмешләнгән иде.

«Мондый атлар һәм аларны шулай тәрбияләп тоту бары тик атларны чынлап яраткан асыл казакларга гына хас, кызганыч, алар да бетеп бара шул инде...»—дип уйлап алды Рушан. Аның уйларын раслагандай, шул чак бер алмачуар ат янына кечкенәрәк буйлы, ябык бер карт якынлашты. Ат, хужасын танып, ана ирене белән үрелде, бер урында таптанып-биеп алды, «мин сине көттем, юксындым» диюе булды бугай. Күзләре дымланып-жылынып киткән хужасы:

—Йә, йә, акыллым, тынычлан,—дип, атның аркасына жинелчә генә сугып алды. Тавышына караганда, ул шактый өлкән яшьтә иде булса кирәк.

Кайбер төшләре тәмәке уты төшеп яндырылганмы, әллә булмаса пулялар тишкәләгәнме, буш газырлы,—газыр дигәнең чикмән күкрәгендәге патроннар тезеп куя торган кесә була инде,—яшь егет чагындагы чикмән-черкескасын кигән, фырт хром күнитекле һәм башына яна казак фуражкасын егетләрчә кырын салган карт үзе дә әле әйбәт кенә күренә. Кинәт кенә ул атлар тирәсендә кайнашкан Рушанны үзенең карчыганыкыдай үткен күзләре белән күреп алды—аның бу сынаучан карашында яраткан аты өчен гомер-гомердән килгән курку хисе чагыла иде. Ул, әйтерсең, яшь егет чакларында ат карагы чегәнне бер ялгышусыз сизенгән кебек булды. Карт бу юлы да ялгышмады—Рушан нәкъ менә аның чаптары белән кызыксына иде.

—Ә, жәяүле татар икән,—диде карт, сүрелеп һәм йөзендәге борчылу хисен жуеп. Аннары үртәгән һәм шелтәләгән шикеллерәк итеп өстәде:—Кара, кара, соклан. Хәзер сездә мондый чибәркәйләр юк шул инде, хәзер татарлар да башка...—дип көрсенде. Бераз тынып торгач, тагын өстәде:—Казак та хәзер элеккеге түгел...

Картның тавышындагы ихлас пошаманлыкны аңлап алган ат, аның көтелмәгән сүзләрен бүлдерергә теләгәндәй, хужасына таба атлап куйды. Карт аның матур башыннан кочып алды, Рушанның бар икәнен дә онытып, сөеклесенең яраткан иреннәреннән үбә-үбә: «Терек... Терек сөеклем...»—дип сөйләнергә тотынды, атның муенын сыйпаштыручы картларча нечкәреп калган кулында казак камчысы селкенгәләп тора иде.

Дасаев беренче мәртәбә фотоаппараты булмаганга һәм фотога төшерә белмәгәненә үкенеп куйды.

Базарда азык-төлек сата торган берәүдән ул Куба ромыннан бушап калган тартма сорап алды. Базардагы тавыш, шау-шу, ыгы-зыгы, көлешү тавышлары, шаяртып, кычкырып сөйләшүләр аны әсәрендергән, базарда-

гыча комарландырган иде. Ул тирә-ягындагы башка кешеләр кебек үк, күнелле шаярткалый-шаярткалый, тиз генә әллә никадәр ашамлык сатып алды. Сөт рәтләренә тукталып, бер банка өй катыгы эчеп куйды, бер кисәк атаклы казак брынзасы алды, шунда ук янәшәдән бер дистә йомырка өстәде. Инде беренче кыяр-помидорлар да чыккан икән, бәяләре «тешли» торгандыр, алучылар бик күренми, шунлыктан сатучы маржалар Рушанга бик сөенде. Базардан чыгышлый, ул йомшак-җылы бер бөтен ипине дә эләктерде. Авыл пекарняларына әле автоматлаштыру кереп җитмәгән, ипиләре өйдә пешергән күмәчтән берничек тә аерылып тормый иде.

Базар янындагы күперне исенә төшерүгә, Рушанның башында, кара уылдык һәм берәр кырпы балыгы сырты аласы иде, дигән яшерен өмет баш калкытты. Үги әтисе станица тегермәнендәге әлеге дә баягы двигательне төзәтеп йөргән заманнардан күнеленә уелып калган бер күренеш исенә төште, ул аны дусларына еш кына сөйләсә дә, аңа ышанучылар аз иде.

Исмәгыйль абзый, эшлисен эшләп бетереп, тегермәнне хутка җибәргәч һәм сынамактан беренче онны үзе тартып биргәч, тегермән хуҗасы,—станицада төшеп калганнардан түгел!—шунда ук, тегермәндә сый-хөрмәт оештырырга булды. Станица халкының шатлыгына тегермән озак эшләсен, дип, бер тәкә суйдылар.

Тәкәне мөселманча суеп, тиресен тунаучы да Исмәгыйль абзый үзе булды. Мәҗлескә тегермәнче ниндидер хөрмәтле картларны һәм, рәсми андый исеме булмаса да, казаклар арасында абруйлы старостаны да чакырган иде. Менә шул тегермәндә Рушан беренче мәртәбә кара уылдык татып карады, аны кунаклар юкәдән эшләнгән тирән табаклардан зур агач кашыклар белән ымырып-умырып ашадылар, башта Рушан ниндидер гомер күрмәгән иткә охшаткан симез, кызыл, тәмле балык кисәкләре дә зур-зур, калын-калын киселгән иде. Урдылар гына...

Барысы да үги әтисенең эшен мактады, шунда ук өстәл янында ана тиешле бәясе дә түләнде. Тегермән ишегалдында аларны Мартуктан алып килгән җигүле пар ат тора һәм шуның белән үк илтеп куярга да җыеналар иде. Исмәгыйль абзый китәргә кузгалгач, тегермәнче аяклары бәйләнгән тәкәне күтәреп чыкты да:

—Монысы сиңа, оста, шәхсән үземнән,—дип, тәкәне яңа чабылган печән арасына иплəп салып та куйды.

Староста дигәннәре, ат тотучыга нәрсәдер пышылдап, серле елмаеп, аның янына менеп утырды да кузгалырга кушты. Кайдадыр авыл читендә тукталдылар, староста Исмәгыйль абзыйларны күзгә бәрелеп тормаган бер подвалга кереп чыгарга чакырды.

Ике катлы калын бүрәнәләр ябылган тәбәнәк озын подвалда караңгы иде, староста белән ат йөртүче шунда ук ике керосин фонаре кабызды. Подвалда боз булмаса да, боз салкынлыгы бар—күрәсең, ерак та түгел җир асты сулары үтә торган булгандыр.

Сүрән генә лампалар атлаган саен караңгылыкны куып яктыртып тора, шунда Рушан тимер ыргакларга эленгән, баш түбән сузылган үзе кадәр һәм әле үзеннән дә зуррак балыкларны күреп алды. Сүрән ут яктысы житкән арада һәркайда—балык... балык... балык... Кырпы балыклары. Староста аларга кагылгалап, һәрберсен иснәштергәләп караган шикелле итеп узды. Үзенә ошаган берсе янында тукталып, күнитек кунычыннан киң генә пычак суырып чыгарды да, житез-оста хәрәкәтләр белән балыкның сыртыннан озын-озын калын өч кисәк телеп алды һәм аларны сүзсез-нисез генә Исмәгыйль абзыйга сузды. Аннары ул, ян диварга якынаеп, фонарен киң агач киштәгә куйды. Ике рәт итеп ясалган бу киштәләр караңгылыкка китеп югала, алар өстендә футбол тубы зурлыгындагы түгәрәк кара йомарлаклар ята иде. Ат йөртүче әллә кечкенәрәк агач чиләк, әллә мичкә сыманрак савыт бирде, староста кулындагы шул ук пычак белән бер кара түгәрәкне, йомарлам май кискән

шикелле генә итеп, урталай ярып жибәрде дә, шул савытны тутырып салып та куйды, аны исе киткән Рушанга тоттырып:

—Бу сиңа, оста, җәмәгатьчелектән, казаклардан,—дип, үги әтисенә башын иде...

Ләкин бу юлы, Рушан никадәр генә эзләнмәсен—базарда ачыктан-ачык та, яшертен дә ни балык, ни уылдык сатучылар күренмәде. Ә бу якларда аларның бихисап булуын ул үз күзләре белән күргән иде бит. Менә хәзер, сонлап булса да, үги әтисенең сүзләре хәтеренә килде: елганы сакларга кирәк...

Кара уылдык эзләп йөри торгач, Рушан чегәннәргә барып юлыкты—юк, ат каракларына түгел, аларны хәзер казакларның соңгы атлары бик кызыксындырмыйдыр да инде. Чегәннәр әллә кайда еракдагы әмеркәнски «Монтана» тамгасы тегелгән ялган, ясалма свитер һәм пуловерлар сатып йөри икән.

Рушанның сатып алган бөтен әйберләре теге тартмага сыеп бетте, ә ипи сатучы кыз аны, бик тиз генә итеп, келиндер бавы белән бәйләп тә бирде. Рушан ашыкмый гына, алган әйберләреннән һәм базардан канәгать булып, янадан да теге ат бәйләү араталарыннан узып бара иде, анда башын түбән иеп торган бердәнбер ала-кола бияне генә күрде, тукталып тормыйча, машинасын куйган җиргә ашыкты. Үз машинасын түгәрәкләп урап алган кешеләрне ерактан ук күреп-абайлап, борчылды: «Берәрсе, чыгышлый, бәрдереп уздымы икәнни», дип уйлап куйды.

Җыелган халыкны авырлык белән ырып-ерып үткәч, кулындагы тартманы машина капотына куйды да, кесәсеннән ачкычларын чыгарды.

—Син хуҗамы?—дип, бер бик әсәренгән казак аны җиңеннән тартып туктатты һәм тыр-тыр сөйләп китте:—Мин беренче, мин беренче алучы, мин иң алдан килдем...

Казакны бүлдерүче юк, әмма таза гына ике ир-ат, Дасаевның игътибарын үзләренә җәлеп итәргә теләп, теге бәндәне сүзсез-нисез генә кысрыклый иде. Ләкин казак та тиз генә бирешә торганнардан түгел, ахрысы, Рушанның беләгеннән йолкып ала алмаслык итеп кысып тоткан.

—Нәрсә сатып алмакчы соң син?—дип, аптырап сорады Дасаев, терсәген тартып алырга тырышып. Аңа бу гамәлендә теге таза ике ир-ат ярдәм итмәкче булып азаплана иде, кыяфәтләреннән күренә—алары монда яшәүчеләр түгел, ә читтән килгәннәр булса  кирәк.

—Син, туган, шаян кеше икәнсең!—дип, аның беләген ычкындырмый гына, үрсәләнеп көлеп куйды дулкынланган казак.—«Волга»ны, кадерлем, менә шушы чибәренне!

Булышучылары белән бергәләп, ниһаять, беләген анардан ычкындыра алган Дасаев, анга килеп әйтте:

—Ә кем сезгә аны сатыла, диде әле?

—Әллә син психмы? Базарның иң күркәм җиренә парадка чыгардай итеп ялтыратып куйгансың да, хәзер «сатылмый» димәкче буласыңмы? Әй-яй, хәйләкәр икәнсең, туган! Бәясен күтәрмәкчесеңме?—дип тузына ук башлады казак. Җыелган халык та шаулашырга тотынды.

Рушан шунда гына машинасын ерактан караганда автотукталыш кебек күренгән урынга—машиналар сатыла торган төшкә куеп киткәнлеген аңлап алды. «Ат базары, печән базары, кош-корт базары, ә менә хәзер автобазар икән. Һәр заманның үз җыры булган кебек, үз базары да бар»,—дигән кирәкмәс уй башыннан чагылып үтте.

—Гафу итегез, минем үтеп барышым иде. Белмәдем. Машинам сатылмый,—диде ул үртәлеп.

Халык әкренләп тарала башлады.

Дасаев машинаның багажнигын ачты, аның уң ягыннан да, сул ягыннан да теге таза ике ир-атның башы тыгылды. Алар аның тартмасын җайлап куярга булышкан кылана иделәр.

—Булдырдың, акыллы икәнсең, шырдый-бырдыйларны куып

тараттың. Машинанны без алабыз, безгә бик тә ошады, мөгаен, экспортка-чит ил өчен эшләнгән булгандыр,—диде аларның берсе.

—Юк,—диде Рушан, багажнигын ябып.—Чит ил өчен түгел, ә махсус эшләнгән.

—Алайса—бигрәк тә! Махсус эшләнгән икәнлеге бер чакрымнан күренеп тора,—дип шатланып гөлдерәште таза ир-атлар.—Вакланмыйбыз, утыз мең бирәбез. Машинасы да, хуҗасы да күнелебезгә хуш килде. Йә, килештекме?

—Әйттем бит инде, машина сатылмый,—диде арган кыяфәт белән Рушан һәм машинасының ишеген ачып кереп утырды.

«Волга» акрын гына кузгалып китте. Ярым ачык тәрәзәдә үҗәт ирнең башы күренде:

—Утыз биш мең, кадерлем! Соңгы бәям!—дип, рульгә ябышты ул.

—Сатылмый,—диде Рушан һәм тизлеген кинәт кенә арттырды, тирә-якта җыелган халык чәчелеп китте.

Бары тик станицадан чыгып, күпергә җитәрәк кенә тизлеген киметте ул. Шунда, болында туктап, көнен су буенда үткәрергә булды, бик арган иде. Башыннан базарда күргәннәре китмәде: Монтана штатының кайда икәнен дә, мөгаен, белмәгән һәм шундый сәер шөгыльгә тотынган чегәннәр, Терек исемле матур ат хуҗасы, катлаулы тормыш юлы үткән карт казак һәм автомобиль базарындагы тарткалаш тыңгы бирми йөдәтте.

—Утыз биш мең...

Бу санны кычкырып әйткән иде, аның гаҗәп зур сумма булуын, кайберәүләрнең гомер буена да андый акчаларны эшләп ала алмаслыгын аңласа да, күңелендә бер тойгы-хис тә тумады.

Рушан печән чапкыч үткән эздән болынга төште дә, үзенә җайлы урын эзләп, яр буенча шактый озак барды. Матур урыннар күп, шунлыктан сайлавы да кыен иде. Тиздән ул бер аланны күреп алды, печән чапкан вакытта печәнчеләрнең ял урынына охшаган булганга күрә, шунда тукталырга булды. Ватык кирпеч кисәкләре белән аралап казып куелган зәгыйфь кенә чишмәсе дә бар иде бу урынның. Илне аркылы-торкылы күпме генә йөрмәсен, менә шушындый казып чокырчык ясалган чишмәләр бары тик алар ягында гына очрый иде шул.

Әлләни ерак та түгел, кемнәргәдер кат-кат хезмәт иткән иске учак урынын да күреп алды. Якын-тирәдәге таллык арасыннан эзләштергәләп, өчаягы белән кормыланып беткән кечкенә казанны да табып алды, шунда ук станицадан алып киленгәнлеге күренеп торган утын да бар иде, әмма Рушан аларны кузгатмаска булды. Вакыты күп иде, елга буйларыннан, таллыклар арасыннан коры-сары, чыбык-чабык җыеп алды.

Елга ягыннан, болынга табан сизелер-сизелмәс кенә булып, су исе, юеш яр исе килгән дымлы йомшак җил искәне сизелә, ә чәчәкләргә күмелгән болында куе булып үлән исләре, эссе җәй исләре аңкып тора. Рушан тукталган шушы чишмә чокырчыгы янында, әйтерсең лә, шул елга-су һәм болын исләре бергә кушылган да, башларны әйләндерерлек, исертерлек кабатланмас бербөтен хуш искә әверелгән—бередән беркая да китәсе килми иде. Кояш шактый югары күтәрелгән, көн уртасы житкән, әмма бередә, су буе болынында әлсерәткеч эсселек сизелми—ашыкмый гына тирә-юньне күзәтергә, ял итәргә рәхәт, жылы-ягымлы бер талгынлык кына бар иде.

Кечкенәрәк бер учак ягып, Рушан табып алган казанда бернечә йомырка пешереп алды да, аларны тәмләп ашап куйды. Аннары, анадан тума чишенеп, озаклап-рәхәтләнеп су коенды, Паланганы хәтерләткән комлыкларында кызынып ятты, шунысы гына бар—бу елганың исемен-атын кешеләрдән дә сораштырмаган иде, үзе дә хәтерләми.

Кояш төшлеккә авышкач, печән кибәннәреннән сәер-сәер күләгәләр озынаеп сузыла башлады. Бу җәннәттәй урынны ташлап, бер дә кузгалып китәсе килми иде. Рушанның күптәннән инде мондый рәхәтлекне татыганы юк иде бит, ул үзе тукталган жирдәге бер печән кибәнен

ачкалады да машинасында утыргыч өстенә ябылган иске одеалны алып, шуны җәеп салды, шуна рәхәтләнеп сузылып ятты.

Печән кибәненең хуш исе иске йортларында кышкы салкыннар, кар-бураннар малайларны куып менгезә торган печәнлекне хәтерләтте. Шул печәнлектә печәнгә чумып-җылынып, алар бер-берсенә сихерче-тылсымчылар, җен-пәриләр һәм тагын әллә нәмәрсәкәйләр турында куркыныч-хәтәр хәлләр сөйләрләр иде. Ин гаҗәбе шул: тузга язмаган ул хикәятләр бик озын гомерле һәм һаман да дәвамлы була торган иде. Шуларны уйлап ята торгач, Рушан үзе дә сизмәстән йокыга талган...

Бары тик төн уртасында гына уянды ул. Нәкъ анын баш очында, җәйге биек күктә бихисап йолдызлар җемелдәшә иде—мондый күкне, берьюлы бу кадәр күп йолдызларны анын инде күптәннән күргәне юк иде. Төн бик җылы булгангамы, ул тунмый-нитми бик озак карап ятты әле. Зур Җидегән йолдызлардан һәм Киек Каз юлыннан башкаларынын исемнәрен белмәгәнлектән, ара-тирә төнге күкне ярып, якты сызыклар калдырып атылып төшкән йолдызларны озак кына күзәтте ул. Әй дөнья! Нинди иксез-чиксез бит син... Ул җем-җем җемелдәшкән йолдызлардан күзен ала алмады, алардан ана рәхәт бер талгынлык-тынычлык, наз-иркәләү агыла иде шикелле.

Рушан нииндидер бер эчке куаныч, әсәренү белән урыныннан сикереп торды, төн уртасы булуга карамастан, үзендә әйтеп бетергесез көч һәм дәрт тойды. Янадан учак үрләтеп җибәрде, казан асып, бөтнекле чәй кайнатты—төнгелеккә ат сакларга йә балыкка барганда алар шулай итә торган иделәр.

Мөгаен, анын төнге учагы әле гашыйклары таралып бетмәгән биек яр өстеннән дә, ә бәлки әле, галәмнең үзеннән дә күренеп торгандыр. Юкка гына, башынны күтәреп карасан, сине космонавтлар да күреп ала, дип сөйләнмиләрдер. Гагарин галәмне инләп төшкәч, бигрәк тә анын Казакъстан далаларыннан күтәрелгәнен белгәч, мондый сүзләр үзеннән-үзе таралган иде. Рушан, галәмгә сәлам җибәрергә теләгәндәй, учак күмерләрен актарып-таратып ташлады, менләгән очкыннар, җир йолдызлары булып, күккә күтәрелмәкче булдылар да сүнеп югалдылар. Әгәр дә Рушанны чынлап та югарыдан космонавтлар күзәтсәләр, алар, мөгаен, ана көнләшеп карар иде: төн, тынлык, хәтта чикерткәләрнен сайрашулары да ишетелми, бары тик ара-тирә төнге су өстендә йокылы-уяулы берәр зур балыкнын сикереп-чупылдап куйганы, ул-бу булмагае, дип, сискәнеп, берәр төнбоекнын кин һәм унайлы яфрагыннан куркынып суга чумган бака тавышы гына ишетелгәләп ала, күзләренне ала алмаслык учак яктысы сихерле, ул сине утнын гомер-гомердән килгән мәнгелек серләренә алып китә шикелле...

Учакка ташланган коры-сары янып бетеп килә, ут сүнә-сүрелә бара иде, әмма Рушаннын һаман да китәсе килми, шуна күрә ул су буена төшеп китте. Ә елга, тирә-юньдәге бар тереклекне куркытып уятудан үзе куркыпмы, үзенен суын тын гына Урал-Җаек ягына табан куып ятуында иде. Бары тик елгага буйсынмас, йокы белмәс шаян җил генә яр буе камышларын кыштырдатып куя: ботакларын суга хәтле салындырган, елгадан үзләренә яклау эзләгән һәм шуны үтенгән арган талларны йокыларыннан уятмак булып, исеп-исеп ала иде ул. Төнгә суынып өлгергән яр буе комлыгы Рушаннын ялан аягын иркәли, ашыкмый гына як-ягына каранып, йөреп килергә чакыра төсле иде—мондый хозурлыкны тагын әле кайчан күрерсен, шул, төшендә күрсән генә инде.

Рушан, озын җәйнен бар җылысын үзенә җыйган суны ера-ера,—ә ул су көндезгедән дә җылырак-ягымлырак тоела иде,—яр буе сайлыгыннан барды-барды да, түзмәде—тиз генә чишенеп ташлады һәм сак кына, тын гына йөзеп китте, төнге тынлыкны бозу нииндидер ярамаган, мыскыллы гамәл булып тоелыр иде шикелле.

Печән кибәне янындагы машинасына да болын исе сенгән иде. Еракка төбәлгән алгы утларын кабызып, төнгә йокымсырап башларын

игән чәчәкләрне, ятимсенеп утырган ялгыз кибәннәрне яктырта-яктырта, ул әкрен генә олы юлга барып чыкты. Күперне дә үткәч, радиоалгычын кабызып-көйләп җибәрде—машина эченә төрле тавышлар кереп тулды, әмма Рушан үзенә кирәкле дулкынны бик тиз тотып алды: аның кебек йокысызлар өчен төнге концерт тапшыралар иде. Юл таныш булып, каршыга килүче бер генә машина уты күренмәсә дә, үзе уйлаганча, ажгыртып, тиз генә китеп бара алмады ул.

Пестицид-гербицид ише агулар белән кат-кат агуланган, кирәксә-кирәкмәсә дә кат-кат сөреп ташланган, аулак юллар белән дә, автостралалар, тимер юллар белән дә аркылы-торкылы чуарланып, бензин-мазут исләре сеңеп беткән, Оренбург якларындагы нефтепромыселлар төтенендә тончыгып, арбалар, трейлерлар изеп бетергән, җир астына салынган нефть һәм газүткәргечләр челтәре, телеграф-телефон чыбыклары һәм башка шуның ишеләр белән уратып-чолганып алынган дала үзенен кызганыч-мескен тормышы белән һаман да яшәп ятуында иде әле.

Ара-тирә төнге юлны кисеп чыгучы еланнар, тузбашлар, бака өерләре күзгә чалынып кала. Яки ут яктысыннан сукырайган җир куяннары—кушаяклар, кая барырга белмичә, сикеренгәләп-чәчелеп югала иде. Йоннарын коя башлаган ябык төлкеләр дә ике мәртәбә ерактанрак кына юлны кисеп үтте. Әле бер мәртәбә туктап торырга да туры килде Рушанга: мөгаен, су эчәргә диптер, яшь бәрәннәрен ияртеп, юл аркылы сайгаклар көтүе үтте. Кызганыч ки, бу мескен җәнлекләргә браконьер-ларның машина утлары бик таныш булганлыктан, Рушан, үзем дә төнге даланың куркыныч юлында сайгак бәрәннәрен тагын да куркытып, таратып бетермим дип, машина утларын сүндерде дә, юл читендә озак кына туктап торды.

Юлда куяннар бигрәк тә күп очрый иде. Алар, күрәсең, юл тирәсендә яшәргә иялəшкән-күнеккәннәр, машинадан да курыкмыйлар шикелле. Әмма әгәр дә машина уты яктысы өсләренә төшсә, шул ук кушаяклар кебек, болары да кая барып бәрелергә белми, юлда әрле-бирле чабыша башлый икән. Тимер юл буйлап сузылган урман полосаларында керпеләр дә бик еш очраштырып торды. Анда да тизлекне киметергә туры килә иде. Бер тапкыр юл читендәге оясы янында бурсыкны да күреп алды Рушан—теге куркып, бер дә оясына чуммады, симез артын сикерткәләп, ашыкмый гына урман ягына кереп китте. Бодай басуларына килеп чыккач, Рушан әрлән патшалыгына тап булды—менә кемнәрне пестицид та, гербицид та алмый, симерүләрен һәм бихисап үрчүләрен генә беләләр, чукынчыклар! Шунда ук, бодай басуы буенда аңа зур, ялкау, картайган ябалаклар да очрады.

Гаҗәп инде, әле шул ук юлдан көндез үткәндә бернәрсә дә күрмәгән-абайламаган иде, ә төн аңа кешеләр күзенә күренмәстәй көтелмәгән дөньяны ачты да салды. Искиткеч сихри төн иде бу!

Яктырып килә, йолдызлар дәррәү сүнә башлады. Әле менә-менә генә бәрхет-кара күк йөзе, күз алдында соргылтланып, якты йолдызларын сүндерә бара, таңның беренче нурларыннан, җәйгә хас булганча, ачык зәңгәр төсләре белән җәелергә җыена иде.

Рушан Мартукка үги әтисе җирләнгән иске мөселман зираты ягыннан кайтып керде.

Мөселман зиратлары бик гади, гадәттә күзгә күрексез була, анда зиннәтле-бай һәйкәлләр дә юк. Хәтта күбесенчә зират сакчысы да булмый. Әмма транзисторлы бу заманның башларын кая куярга белмәгән акселератлары—буйга сузылып үскән, акыллары буйларыннан шактый калыша торган яшүсмерләр дә ул зиратларга кереп, нәрсәдер кыланып йөрми, чөнки күптән билгеле хакыйкать бар: андый әшәкелекләр эзсез үтми, гафу үтенүләр һәм акланулар игътибарга алынмый.

Зират вакытлар үтү белән бик нык ингән, язгы-көзге яңгырлар урыны-урыны белән юып-ишеп бетергән балчык үр белән әйләндереп алынган—шулай булса да, мал-фәлән кереп, таптап йөрерлек түгел иде әле.

Нииндидер казакъ көтүчесе үзенең үлеме алдыннан, зиратны яна койма белән тотарга дип, бик зур сумма акча васыять итеп калдырган булган икән дә, әмма балалары, менә икенче ел инде, әтиебез үз акылында түгел иде, дип, судлашып йөриләр, туган-тумачаларыннан кала, бу гөнаһлы эшкә шаһит булып бер генә күршеләре дә бармый икән. Моны Рушанга әнисе сөйләгән иде.

Зиратның элек-электән үк капка-фәләне юк, бары тик дүрт ягыннан да балчык үр аша кереп йөрерлек итеп ачык урыннар гына калдырылган. Мөселманнарда мәетне, зират никадәр ерак булса да, кәфенләп, махсус кабыкка салып илтәләр, зиратка бернинди машина-мазар керми, анда ир-атлардан башка беркем дә аяк басмый.

Рушан машинасын юлда калдырып, балачактан белгән, күнелендә калган догаларын эченнән генә укый-укый, зират эченә үтте. Мөгаен, кем булып үсеп житүенә, нинди генә белем алуына карамастан, һәр мөселман кешесе ул догаларны яттан беләдер һәм, кирәге чыкканда, кабатлый торгандыр.

Инде яктырган иде. Йолдызлар урынына күкне каплап алган төтен сыман жинел-аксыл болытлар да жәйге эссе кояшның беренче нурларыннан ук эреп бетәр. Иртәнге саф-салкынча күк йөзе тоныкланып, әлсерәп калыр төсле иде. Чык төшкән, зиратның төп үләне булган соргылт әремнәр дымланган, сукмаклардагы аяк астында тапталган вак-төяк үләннәр, жәйге эсселектән кибеп, шыгырдап тормаса да, зур зиратның төрле ягына таралып-тармакланып киткән сукмаклар тузанлы түгел иде. Менә шундый тын-тыныч иртәләрдә, мөселманнарның бәйрәм көннәрендә бигрәк тә, картлар зиратка килә, фани дөньядагы тормышларын төгәлләп, бирегә килеп ятканнарның рухына багышланган иртәнге намазларын укый.

Рушан да үги әтисе Исмәгыйль абзыйның каберенә изге сәгатьләрдә килгән булып чыкты. Тирә-юньдәге башка каберләр арасыннан ул аның каберен бик тиз эзләп тапты, колхоз тимерчелегендә койдырган чардуганы бизәкле челтәрләре һәм биеклеге белән башка каберләрдән ышанычлырак булып аерылып тора. Аннары ул кап-кара лак белән дә ялтыратып буялган иде. Соңгы кайтуында Рушан алып килгән, кадерләп кабер өстенә салган зур роза чәчәкләре шиңгән, кипкән икән инде.

Рушан чардуганны ачып эчкә үтте, кибеп корышкан чәчәкләрне бер читкә алып куйды, кабернең баш ягында әле янарак кына төртеп чыккан зәгыйфь шайтан таягы куагын күреп алды. Иң нечкә, иң озын сабагы, бәлки әле бүген генәдер, алсуланып, чәчәк атып азаплана иде. Жир-ананың зәгыйфь, әмма яшәү көче сизелеп торган соңгы шул бүләге әкрен искән күзгә күренмәс жилдә тирбәлеп, «тыныч йокла, Исмәгыйль абзый» дип әйтә төсле иде. Алтын куллы, батыр сугышчы Исмәгыйль абзыйның кабереннән ерак та түгел Сания апасының кабере дә. Ул бик иртә, егерме яше тулар-тулмаста үлеп китте. Рәтлерәк башка тормышта яшәсә, үпкә авыруын да жиңгән булыр иде, бәлки, нихәл итәсен— язмыш... Нихәлләр итәсен...

Рушан, үзен шулай иртә калдырып киткән якыннары белән тагын бер кат хушлашып, үзе яши торган зур шәһәргә юл тотты...

## XXXIX

Ташкентны Рушан Дасаев бер күрүдә үк һәм гомерлеккә яратты, хәзер еш кына башкалага килгән көннәрен исенә төшерә. Һәм һәрвакыт күз алдына Чыгытайдагы чәйханә килеп баса—ул аңа, мөгаен, Шәрекънең рухын аңларга мөмкинлек биргәндер, үз-үзен ничегрәк тотарга кирәклеген дә өйрәткәндер.

Шәһәрдә сүтәләр дә төзиләр, сүтәләр дә төзиләр иде...

Хан заманнарыннан калган кәкре-бөкре урамнар, чокыр-чакырлы,

тузанлы тыкрыклар, чатлар юкка чыкты, ишегалларын чит-ят күзләрдән яшереп торган биек балчык дуваллы тулы квартал—мәхәлләләр сыпырып алгандай булды.

Шәһәрнең борынгылыгы китә иде. Бөтенләйгә, мәңгелеккә китә. Тын гына да, шау-шу белән дә, шатланып та, кайгырып та китә...

Бөтен тирә-як шулай җимерелә барганга күрә, кемнеңдер хәтерендә маяк кебек юл күрсәтеп торган нинди дә булса чинар агачына ничә яшь икәнен бер Аллаһы Тәгалә генә белсә-беләдер, менә ул мескен агач та ничектер кечерәеп калган шикелле.

Еллар үтә тора, әнә үзеңә дә фәлән яшь булды, ә ул куәтле чинар, синең хәтереңдә тирә-юньдә иң биек булып, мәхәлләнең бер бизәге һәм горурлыгы булып, галәмәт ябалдашы белән рәхәт салкынча талгынлык таратып, һаман да үсеп утырган көенендә әле. Тагын күпме утырыр ул шулай? Колач җитмәс кәүсәсе тупасланып-яргаланып беткән булса ни дә, кояш өткән зур-зур тамырлары бүртенеп җир өстенә чыгып торса ни—син дә бит инде зифа тупыл сынлы, кара кашлы егет түгел хәзер.

Вакыт галиҗәнапләре һәр нәрсәгә үзенең тамгасын сала тора, беркем дә, бернәрсә дә аның кулаймәсеннән котылып кала алмый. Әмма вакыт дигәнең тирә-юньдәге ни-нәрсәләрнең асылын үзгәртеп торса да, хәтернең дә билге-тамгалары шактый күп бит.

«Чыгытай, икенче тупыйк...» Дасаевның күз алдында шунда ук Сагбан борылышы ачылып китте, Чыгытай урамы боргаланып-сыргаланып шунда агып төшәр төсле.

Әгәр дә ике арба хуҗасы бер-берсенә хөрмәт белән сак кына юл сабарлык, тар гына, елан кебек боргаланучы Чыгытай урамыннан өскә күтәрелә калсаң—шәһәр сәүдә үзәгенең элекке складларына барып чыгасың, аларны иске гадәт буенча «кәрван-сарай» дип йөртәләр. Кәрван-сарайның шау-шулы, шаулы вакытлары күптән узган инде, мөгаен, Җунаид ханның соңгы шпионнарын тотып алганнан бирледер, ә менә тузанлы, анда-санда гына тәрәзәле складларга тәки шул «кәрван-сарай» исеме ябышып калган.

Бу урамның һәр ике башыннан да эчкәрәк кереп китеп, аркылы-торкылы буталып беткән лабиринттай урамнардан ике мәчет манарасы күренеп тора. Берсе—биегрәге, күркәм генә күренә, ул шактый озын, зифа. Алласызлар буыныннан булган яшьрәкләр, бигрәк тә турист-фәлән ишеләр бу манараны юк кына берәр котельный яки фабрика моржасы дип кабул итәләр, әмма бер ун еллар чамасы элегрәк аның иң очына ләкләкләр оя коргач, бернинди дә моржа түгеллеге, манараның бөтенләй башка максатлардан чыгып төзелгәнлеге ачыкланды.

Чәйханәнең түр башында гына утырырлыгы калган, дөнья белән башка алыш-биреше беткән бер аксакал ул язда манарага карап:

—Аллаһыныкы дөнья эшләренә кысылып буталмасын өчен кирәк ул манара,—дигән, имеш.

Манараның ишек-тәрәзәләре аркылы-торкылы кадакланган, берәүгә дә комачауламый, мөселманнарны иртәнге намазга чакырып, аның текә баскычларыннан азан әйтергә мәзин күтәрелгән заманнарны, хәтерләсә—теге карт чинар гына хәтерлидер дә, калган гомерләрен чәйханәдә үткәрүче берничә карт кына искә аладыр.

Икенче манара яна чагында да әлләни искитәрлек булмаган, артык биек тә түгел, чи кирпечтән бернинди бизәксез-нисез генә өйгәннәр дә куйганнар аны, бер дә күзгә ямь бирми инде. Әллә вакыты җиткәнме, әллә башка берәр сәбәп беләнме, ашыгып ага торган сай гына инеш ягындагы чокырга табан шактый авышып та тора әле ул манара. Кайберәүләр аны, бик белдеклеләнеп, Авыш манара дип йөрткән булалар һәм нининдидер Италия шәһәрен искә төшерәләр иде. Мәхәллә халкы исә бик гади генә итеп Бөкре Мөхәммәт Хуҗа дип атый аны. Бөкре рибачы, ягъни әҗәткә акча биреп торып, соңыннан зур процентлар алучы, Мәккәгә барып хаҗ кылып кайтса да, саран һәм бик гаугачыл Мөхәммәт акчасына

төзелгән манара Корбан бәйрәме үткәннән соң ук шулай ава-янтая башлаган, дип тә сөйлиләр.

Әлеге сай гына инешкә таба янтайган манара, әйтерсең лә, саран Мөхәммәтнең, төзүчеләргә тиешлесен түләп бетермичә, аларны алдавына сүзсез ишарә булып тырпаеп тора иде. Хужа манараны турайтырга таутау акчалар вәгъдә итсә дә, ни өчендер ул эшкә алынучылар табылмаган. Бу имеш-мимешләр риваятькә әйләнгән, саран Мөхәммәтнең дә исе-эзе калмаган, ә манара һаман ава, әмма һич кенә дә авып төшә алмый әле.

Ә янәшәдәге шадра дувал артында, үткән-сүткән кешеләргә тузан бөркеп, Чыгытай урамыннан жирле минераль су төягән көмешсыман рефрижераторлар чабыша, юк-юк та, бормаланып сузылган урамнан чия төсендәге «Икарус» автобусы, мәхәллә малайларын куандырып, тавышсыз гына узып китә, ул әле әйбәт кенә уйный, әле түбәнгә тәгәри торган билгеле бер футбол командасын йөртә.

Посып торган урынын көн саен алмаштырып, урамның аулаграк бер читендә карап торышка йокылы күренгән юан ГАИ лейтенанты яшеренгән. Ул, үзләрен бик оста һәм тиз йөрүчеләр дип, тыз-быз чабышкан машина хужалары каршына, жир астыннан калыккан кебек, көтмәгәндә генә килеп чыга да, таягын ялкау гына уйнатып, юан гәүдәсе белән ярты юлны каплап куя:

—Чыгытай урамында берьяклы гына хәрәкәт! Штраф түлә!—ди.

Бу урамда әнә шул рәвешле иске белән яңа, кичәге белән бүгенге, үткән белән киләчәк үрелеп беткән, әмма мәхәллә өстендә киләчәк тирбәлә инде...

Дасаев бу мәхәлләгә беренче тапкыр бер утыз еллар элек килеп чыккан иде. Эшенә соңга калган бер көзге иртәдә, бара-барышлый эссе урам тузанын йотып, Чыгытай буйлап өскә таба элдерә иде ул. Россиянең жылы-йомшак төсмерләренә күнеккән күзе ут янып торган якын кояш яктысында чинарны да, манараларны да, тагын әллә нәрсәләрне абайлап алды.

Әле моңа кадәр күрелмәгән яңалык хисе, беренче тәэсирләре, яшь инженерның тормышында алда булачак матур үзгәрешләрне сиземләве аның күңеленә гомерлеккә үтеп керде шикелле. Шунадыр, ихтимал, шактый вакытлар үткәч, зур башкаланың инде икенче районында эшләгән чорында, шәһәрнең бу иске мәхәлләсенә килеп чыгарга туры килгәндә, кинәт кенә күңел күтәренкелеге тоя, яшьлегендәге шикелле, ниндидер анык кына булмаган, әмма шатлыклы үзгәрешләр көтәдер кебек, һәрвакыт матур жылы бер хис уяна иде.

Эшендә аны иптәшләрчә жылы каршы алдылар. Беренче мәртәбә Чыгытай урамыннан күтәрелгәндә ул, үзенә кирәкле тыкрыкны күзләре белән эзли-эзли, гажәпләнеп тә куйган иде: бу коелып-шадраланып торган биек дуваллар арасында берәр төрле хезмәт конторасы бармы икәнни? Адресын буташтырмадыммы икән, дигәнрәк шик тә кузгалып алган иде әле.

Төзү-монтаж идарәсе, дөресрәге, ул урнашкан бина, көнчыгыш төбәкләрендәге башка күп кенә нәрсәләр төсле, Рушан өчен гадәти түгел, хәтта бераз сәеррәк тә иде.

Жирдә масхалат челтәре төсле чуар күләгәләр ята, Рушан килеп кергән ишегалды тулысынча йөзем куаклары белән сарылган, хәтта кояш та күренми иде. Тагын бер сәгатьтән Дасаев үзенә тәгаенләнгән аерым эш бүлмәсендә утыра иде инде. Нәфис гарәп хәрефләре белән оста итеп бизәлгән биек түшәм өрлекләренә исе китеп карап торды ул: «Шәһрезадә әкиятләре, диярсең, валлаһи!»

Бу бина шау-шулы Чыгытай урамыннан читтәрәк бер тыкрыкта, калкурак урында иде. Тәрәзәнең тимер челтәрләрендә, ишек өсләрендә һәм бинаның маңгаенда «1911 ел» дигән язуы да шәйләнә.

Үз вакытында бина биек дуваллар артыннан тәрәзәләре урамга карап торган бердәнбер йорт булган. Хәзер Истанбулның төтенле

каһвәханәләренә китеп эзе югалган йорт хуҗасы Әхмәтхан сәүдәгәрнең мөгаен, үз компаньоннары арасында бик тә алдынгы карашлы булып күренәсе килгәндер... Шуңа күрә дә ул йортының тәрәзәләрен урам якка каратып уйган.

Тәрәзәләрне уюын-уйган, әмма аларга корыч пластинкалардан тезеп ясалган жалюзи куярга да онытмаган. Бу корыч пәрдәләр эчке яктан эленеп, әле һаман да булса хезмәт итәләр иде. Йортның тимер фурнитураларында һәм коеп эшләнгән чуен бизәкләрендә көтелмәгән язуы бар: «Одесса, г. Леммань» Әйе, ерактан китертелгән булган болар...

Көннәр, атналар бер-бер артлы ага торды. Дасаев килгән ерак Казакъстан якларында бәрәңге-яшелчә бакчаларыннан уңышны күптән җыеп бетергәннәрдер инде, каралып чыккан камыллы буш калган басу-кырларга иртәләрен кырау төшәдер, күңелсез, эчпошыргыч көзге яңгырлар явадыр. Ә биредә, алар идарәсенең ишегалдында куакларын сыгылдырып, авыр йөзем тәлгәшләре эленеп-эленеп тора, кипкән яфраклар арасыннан йомшак кына саркылып төшкән кояш нурлары, озын җәйдән арыган шикелле, тын гына җылысын сибә, бу рәхәтлекнең чиге булмастыр кебек...

«Кирәк бит! Бигрәк җылы... Сахара...»—дип еш кына уйлый иде Рушан, укып бетергәннән соң юллама белән кырысрак-салкынрак якларга эшкә җибәрелгән дусларын да исенә төшерә иде. Алар инде җиләндер-пәлтәдер кигәннәрдер, свитер-бүрекләре дә өсләренә менгәндер, ә биредә әле һаман да пинжәктән генә йөриләр...

Рушан Чиланзардагы тулай торакта яши иде. Күбесенчә бер катлы йортлардан булган шәһәр ул вакытта бик зур мәйданнарны биләп тора, әйтерсең, озакламый гөрләп үсеп китәчәген белгәндәй, күбрәк урын алып калырга тырышкан иде.

Һәркөнне иртән троллейбус белән Хадырыга кадәр эшкә йөрү Дасаевка күрелмәгән чит-ят якларга сәяхәт шикелле булып тоела. Ул еш кына салонның арттагы тузанлы тәрәзәсе буена барып баса да, ашыкмый гына үзенең өзек-төтек уйларына чума, шул ук вакытта кондукторның ялкау гына тавышын музыка тыңлагандай тыңлый: «Биш Агач... Караташ... Алзамар...»

Һәр тукталыш музыка кебек кенә яңгырамый, ә тагын ниндидер серләр дә саклый иде төсле: «Сәмәрканд—Дарбаза... Домрабад... Әхмәт-Даниш...»

Дасаев Хадырыда троллейбустан төшеп кала һәм җәяүләп кенә Чокырсайга таба юл тота, анда туристлар өчен чыгарылган матур, төсле буклет-проспектлар, маршрут карталарында да билгеләп куелган базар яныннан үтеп, Чыгытайга барып чыга. Төнгә суынып өлгергән тротуарлардан атлаганда, аяк астындагы юка асфальт аша да ишегалдына кергә торган юл өстенә электән түшәлгән йомры ташларны тоя иде.

Арыклар иртәнге якларда мул сулырак була һәм күңеллерәк челтериләр шикелле, бәлки, шулайдыр да. Капкалары киң итеп ачып куелган уң яктагы бакча эченнән иртәнге дымлы саф һава йөзгә бәрелә. Чәчәк атып утырган люцерна белән үрелеп-уратылып алынган тимер рәшәткә коймалар аркылы кызгылт ком сибелгән кешесез аллеялар күренә. Рушан белә иде инде: Вавилондагы шикелле күп телле шәһәрнең бу бакчасында ешрак татарча сөйләшүләр ишетелә—татарлар бу тыйнак бакчаны күптәннән ошатып, сайлап алганнар, шунда үзләренең иске дә, яңа да бәйрәмнәрен үткәрә иделәр.

Рушан базарда озаклап тукталып тормый. Тандыр миченнән әле генә чыккан, күпереп торган кайнар күмәч, тагын бер көмеш акчасына—берәр тәлгәш йөзем, ә кайвакытта ике шәфтәлу яки сутлары сыгылып торган груша ала, әмма күзе күбесенчә кызлар бите төсле нәфис алсу Кандиль алмасына төшә иде. Шунда ук базар эчендәге иртәнге якта ярым буш күпсанлы чәйханәләрнең берсенә сугыла, гадәттә Шәрекъта эчелә торган бер чәйнек яшел чәй алып, тәмләп ашап-эчеп чыга. Кызыксынып, чәйханәләрнең әле берсенә, әле икенчесенә кергә,

һәркайсында диярлек бер үк төсле алсу роза чәчәкләре төшерелгән калай подносларга күмәчләрен, юылган җимешләрен куя.

Беренче карашка барлык чәйханәләр дә бертөсле күренсәләр дә, алар төрледән-төрле иде. Берәүләрендә, як-якларына каракларча карангалап, пышылдап кына сөйләшеп, энә өстендә утыргандай, алыпсатар сәүдәгәрләр утыра, чәйләренә кагылып та карамаганнар, үзләре шәһәр шау-шуыннан аптырабрак калган авыл дехканнары булып кыланалар.

Икенчеләрендә тәкәббер-эре кыяфәтле, кычкырып-кычкырып сөйләшүче такырбашлы итчеләр булыр. Аларның эше җинелдән түгел—уникешәр килограммлы зур-зур балталар белән көне буена ит чабып кара да, берничәшәр потлы түшкәләрне әйләндереп кенә өлгер! Ә көндез чәйханәченен үсмер энекәшләре ит рәтләренә, бер китексез ин матур чәйнекләр һәм пиалаларны подносларга тезеп, чәйханәдән чәй илтәләр—базарда гомер-гомердән итчеләр ин кадерле, хөрмәтле кешеләр санала.

Рушан казакъча гына сөйләшеп утыра торган чәйханәгә дә тап булды—казакъ җирләре көнбатыштан шәһәргә үк килеп тоташа иде.

Бервакыт томанлы һәм юеш кышкы иртәдә ул эшенә ашыгып китеп бара иде. Күптән түгел генә алып кигән яна пәлтәсенен куен кесәсендә тәнен рәхәт җылытып торган ике кайнар нан—икмәге дә бар. Галәтенчә кереп иртәнге чәен эчеп чыгарга күнеккән чәйханә ни өчендер ябык булып чыкты—ул вахтер янына гына кереп, капкалап алмакчы булды, кыш көннәрендә тегенен плитәсендә һәрвакыт чәе кайнап торыр иде.

Рушан, куенындагы йомшак нанның җылысын һәм исен-тәмен тоя-тоя, юеш Чыгытай буйлап бара, нанның берәр кисәген сындырып кабасы килеп китте, ирексездән адымнарын әкренәйткән иде, шунда кинәт ана дәштеләр:

—Иптәш инжинир, хәерле иртә! Көн юеш-дымлы, чәйханәгә кереп, берәр пиала чәй эчеп чыгыгыз.

Ачык ишек янагына сөялеп, мех камзул кигән зур гына гәүдәле бер ир кеше басып тора, кулы белән ишарәләп керүен үтенә иде.

Эчкә кергәч, Рушан якты янып торган лампочканы һәм авыр, куе-кызыл келәм эленгән диварны күреп алды. Анын йөзенә җылы килеп бәрелде, агач күмере һәм шәрекъчә күп итеп эленгән келәмнәр исе дә борынын кытыклап куйды. Үзләренең идарәсеннән ерак та булмаган бу чәйханә Чыгытай урамында урнашкан, Рушан аны күптән шәйләп алган, анын мәхәлләнеке булуын да белә, ул инде сина базар чәйханәсе түгел, монда мәхәллә халкы белән даими килеп йөрүчеләр генә керә ала иде.

Рушан, ишек төбендә тукталып, керергәме-юкмы, дигәндәй, бераз уйланып торды да, чәйханәченен юмарт-ихлас елмаюын күреп, керергә булды.

Шуннан сон ул бирелә еш була башлады, бигрәк тә кара көздә һәм кышкы иртәләрдә керергә ярата иде. Пычрак-юеш яки салкын энгер-менгердә, саран ягылган мангал җылысыннан иске шәһәр теләр-теләмәс кенә йокысыннан уяна, Рушан, пәлтә якасын күтәреп, базар аша гына әлеге чәйханәгә ашыга. Тандыр миче кайнар пар бөркеп торган күмәчче, ана иске танышы итеп, кадерләп-сайлап кына ике нан суза, Рушан, адымнарын киметмичә генә, каршысына очраган, җылы киемнәренә төренеп бөгелә төшкән кешеләргә юл сабып үтә яки үзе алдыннан баручыларны узып та киткәли, базарга хас булмаган ниндидер акрын гына сөйләшкән тавышлар ишетелеп кала. Сәер, көн уртасында гадәттә төрле телдә сөйләшүчеләрнең тавышын үз тавышы белән басып, кычкырып үтә торган арбакеш та иртәләрен гаҗәеп тын, шауламыйча гына уза. Шәрекъ... Табышмак...

Рушан һәр көнне, Сагбанга борылуга, ерактан ук мәхәллә чәйханәсенен яктырып торган тәрәзәләрен күреп ала. Ул тиз килүдән тирләп чыккан мангаен сөртеп куя да, бусага төбендә үк куенынннан җылы наннарнын берсен чыгарып, ишекне киереп ача.

Гадәттә бу вакытта чәйханәдә кеше булмый әле. Рушанның сәламенә

каршы чәйнекләре-самавыры янында кайнашып маташучы Мәгъсүм әкә дәртле һәм күңелле итеп җавап кайтара:

—Ә-ә-ә, сәлам әлейкүм, инжинир, мәрхәбә, уз әйдә тизрәк,—ди.

Төсләре тоныкланып яшелләнә төшкән галәмәт зур җиз самавырлардан җылы бөркелә. Әле килүчеләр булмаганлыктан, ишек өстендә бер генә лампочка яна, караңгылыкка китеп югалган диварларга кара келәмнәр эленгән шикелле тоела, бары тик урамнан узып баручы берәр машинаның гына утлары тәрәзәне яктыртып ала да, бер мизгелгә генә диварлардагы кан-кызыл төстәге келәмнәр күренеп кала.

Сонрак, шәрекъ тәм-төмнәре булган нават һәм парварда капкалыйкапкалый чәй эчеп, Мәгъсүм әкә белән тәмләп сөйләшеп утырганда, ишектә тагын бер кеше күренә.

Гадәттә ул күрше йорттан берәрсе булып чыга. Мамыктан сырган, үкчәләренә кадәр төшеп торган озын чапанына өйдәгечә генә төренгән була ул, тәмле телле, тәкәллефле генә итеп чәйханәче белән матурлап исәнләшә, хәл-әхвәл сораша, түрдәрәк утырган Рушанны да күреп алып, ана да елмаеп эндәшә:

—Хәерле иртә, иптәш инжинир...—ди.

«Инжинир»... Бу кушамат мәхәлләдә Рушанга тәки ябышып калды бит, аны хөрмәтләп-зурлап әйтәләр иде, әйтерсен, кладовщик Миргаяз әкә бөтен мәхәллә халкы белән махсус репетицияләр үткәргән диярсең.

«Инжинир» сүзе ул елларда әле хөрмәтләнә һәм Дасаевка аны ишетү рәхәт иде.

Бәлки, хезмәттәшләре арасында да тиз хөрмәт казануы, мәхәллә халкының да ана үз итеп караулары сәбәпче булгандыр, бервакыт чәйханәгә төш вакытында барып кергәч, ул кинәт кенә шундый карарга килде: «Калам... үзбәк җирендә тамыр җибәрәм... өйләнәм...»—диде.

Миргаяз әкә аның белән бер өстәлдә утыра иде, «инжинир»ның йөзе үзгәрүен күреп, ашыгып сорап куйды:

—Нәрсә булды, Рушан?

Дулкынланудан бер генә мизгелгә агарынып киткән Дасаев, күз карашы белән залны сөзеп алды да, гүя бөтенесен дә яна гына күргән шикелле итеп, кладовщикка күңелле генә әйтеп салды:

—Өйләнергә уйладым, Миргаяз әкә!—диде.

Ә бит әле шул мизгелгә кадәр мондый уйның башына да кереп караганы булмаган иде.

—Бәрәкалла! Мәйлен, мәйлең... Бик хуп эш...—дип куанды Миргаяз әкә дә.

«Өйләнәм» дигән сүз ул әле иртәгә үк берәр чибәркәй белән ЗАГСка чабачак дигәнне аңлатмый иде. Ул «калам» дигән сүзенә: «Озакка, житди итеп, гаиләм-йортым... балаларым белән...»—дип әйтүе иде Рушанның.

Әлбәттә, аның сөйгән кызы бар иде. Ул бар яктан да усал җилләр искән, салкын җәяүле бураннар себереп торган далалы яктагы бер шәһәрдә яши. Рушанның барлык уйлары да әнә шунда, зәгыйфь сәрби куаклары чорнап алган «1905 ел» урамындагы йортка юнәлтелгән, кайвакыт ул аны күңеленнән генә «кәләшем» дип тә атый иде. «Кәләшем»...—нинди татлы сүз!..

«Өйләнергә кирәк» дигән карары тышкы яктан аңа бер үзгәреш тә кертмәде, әмма тормышында кискен борылыш булды шикелле: Рушан кинәт аңлап алды, ул моңа кадәр һәр нәрсәгә тыштан-өстән генә, килгән кеше күзе белән генә карап йөргән, ә хәзер барысын да булачак тормышына чамалап, төпченеп, асылына төшенеп карарга һәм күзалларга тырыша иде. Буш вакытларында ул сәгатьләр буе китап кибетләрендә йөри, еш кына концертларга бара—гастролер артистлар бер исеме белән генә дә нинди сер вәгъдә иткән җылы, икмәкле бу шәһәрне яраталар иде. Юкка гына «Ташкент—икмәкле шәһәр» дигән гыйбарә телгә кермәгәндер.

Рушан, мәхәлләдә арзан гына хакка аерым бүлмә тәкъдим итсәләр

лә, һаман әле шул тулай торагында яши бирә иде. Ләкин ул мәхәлләгә күчәсе итмәде—көн саен килеп-китеп йөрү рәхәтеннән баш тартасы килмәде анын. Кайвакытларда ул юлын бераз үзгәртеп тә куя: Хадырыдан сулга борылып, Чорсу мәйданына чыга, аннары базарны үтеп, янадан Чыгытай урамына таба атлый иде.

Ул шәрекъ кешеләренен ыгы-зыгы, ашыгучанлык-кабалануны өнәмәгәннәрен бик тиз анлап алды, шуна күрә ашыкмаска тырыша иде. Рушан тирә-юньне һәрвакыт игътибар белән карап-күзәтеп йөри, элегрәк күзе төшмәгән нәрсәләрне дә күреп ала. Борынгы шәһәрнен төс-буяуларын, тавышларын, хәтта тузанын да, эсселеген, күптеллеген, килүче-китүчеләрнен тыз-быз килеп йөрүен, шәһәр халкына гомер-гомердән хас салмак сабырлыгын ләззәтләнеп үзенә сендерә бара. Һәм еш кына, кәефе килгәндә, үз-үзенә бер биргән карарын кабатлый: «Әйе, мин шушында яшәргә тиеш...»—ди.

Иртән идарәгә эшкә барышлый ул бик күпләр белән баш иеп исәнләшеп үтә иде. Ана да кулларын күкрәк өстенә куеп, якты елмаеп җавап кайтаралар. Бары тик инде хәлсезләнгән, агарынып калган карт бохара яһүдләре генә баш кагып исәнләшеп китә. Рушан яшьлеге белән анлап бетерә алмый—бу бабайлар әллә тәкәбберлектән, әллә хәзер инде һәр хәрәкәт авыр бирелгән көчсезлектән шулай эшлиләр иде. Ә бәлки, изге китап Тәүрат гамәлендә инде без, сүзләргә караганда баш кагып узу абруйлырак-дәрәҗәлерәк, дип уйлыйлармы?

Рушанга бу тыныч бохара яһүдләре дә берсүзсез ошый. Шау-шулы нэпман заманнарыннан, яшьлектәге уңышлы елларыннан ук калган ак чесуча тукымадан тегелгән пөхтә костюмлы әлеге картлар ана йә язларын, йә көзнен озын җылы көннәрендә генә очраштыра. Пычракларда, салкыннарда, җәйге эсселәрдә алар биек дувал артларына кереп яшеренә иделәр.

Иртән кошлар базары яныннан тиз-тиз үтеп киткән чагында Дасаев аларны әтәчләр рәтендә очрата. Картлар бары тик тере кошларны гына сатып ала һәм кош-корт белән күз буучы гипнозчылар яки сихерчеләр кебек эш итә. Әле бер минут кына элек кыдрачланып-гайрәтләнеп бар базарга «кикрикүк» дип оран салган әтәч егетләре үзләренен кабыргаларын санап, капшап торучы картларнын хәлсез куллары астында кинәт кенә тынып, юашланып кала.

Шунысы сәер, бу карт яһүдләрнен һәрберсе һәрвакыт бер генә төсле әтәч сатып ала: яки уттай җирән-кызылны, яки ап-акны, яки чуар, беренче көз чебешләрен генә. Аларны аякларыннан күтәреп, баштүбән алып китәләр, әтәчләр шунлыктанмы—үзләрен гаҗәп тыныч тота, Рушан, картаеп, бер-берсенә охшап калган яһүд бабайларын бары тик кемнен нинди төстәге әтәч алганына карап кына аера иде.

Шәһәрне яхшырак белә барган саен Дасаевны мәхәллә чәйханәсе үзенә ныграк тарта. Чәйханәнен язылмаган канун-тәртипләрен Миргаяз әкә ана бер кичтә анлатып бирә алган булыр иде, ләкин Рушаннын һәммәсен дә үзе төшенәсе килде.

Кичләрен ул еш кына эшендә тоткарлана, ә кайтышлый чәйханәгә керә дә, гадәтенчә, бер-ике уен шахмат уйный. Чираттагы йөрешләрен ясаган араларда ул халык күп җыелган залны игътибар белән күзәтә, кичке якта киереп үк ачып куелган тәрәзә аша урамдагы айваннарнын да тулганын күрә. Анда Мәгъсүм әкәнен ирекле ярдәмчеләре, чиләкләрен шылтырата-шылтырата, ишегалдына арыктан су сибәләр, агачларны резин шлангілардан коендыралар—шуннан сон, янгыр явып үткән кебек булып, җир исе, бакча исе анкый.

Кичке тынлыкта Дасаев еш кына: «Клуб—ир-ат җыела торган урын гына»,—дип уйлый иде. Бирелә үткен сүзлелек, тапкырлык, кешеләр белән таныша-аралаша белү, ягымлылык һәм мәхәллә тормышында катнашу аеруча бәяләнә. Ул ишегалдына һәм агачларга таксопарк директорынын башкалардан ешрак су сиптереп йөргәнен абайлап алды,

чөнки ул бу эшне барысыннан да остарак эшли: тузан да туздырмый, артык пычратмый-чупырдатмый да, аның шөгыленнән соң җирдә әле бик озак гади шланг белән ясалган бизәкләр ярылып ята. Рушан директорның чәйханәгә кышлык күмер һәм утын китерткәнен дә, ремонт буяуларын кызганмаганлыгын да белә, әмма директор боларны үзенә нинди дер аерым мөнәсәбәт булсын дип эшләми, Рушан монысын да күреп тора иде.

Сонрак Рушан үзе дә чәйханә өчен игелекләрне аз эшләмәде, әмма мәхәллә халкының аңа булган мөнәсәбәте үзгәрмәде, һаман да элеккечә хөрмәтле, тигез булып калды. Аны һаман да һәрвакыттагыча «инжинир» дип, бу сүзгә һәрчак зурлау мәгънәсе салып атап йөрттеләр.

Японнарча кысан ишегалларында элекке бакчалардан берәр чикләвек яки өрек агачы, алмагач яки ялгыз тут агачы гына утырып калган иде, ә уртада—кечкенә генә чәчәк түтәлләре. Тәрәзәләре ишегалдына караган, икенче катларында балханасы—балконы булган бу йортларда, читтән килгән кешенең исен китәрмичә, ят күзләрдән яшерен тын гына тигез тормыш ага.

Рушанны чәйханә әнә шул гадилеге, нәрсә дә булса күрсәтеп шаккаттырырга омтылмавы белән үзенә тартып тора. Аңа беркая язылмаган тәртип кагыйдәләре дә ошый: мәсәлән, чәйханәгә исереп килеп кермиләр, ачыктан-ачык эчеп тә утырмыйлар. Өлкән генә житди кешеләрнең, мәхәллә хуҗаларының дип әйтергә дә була, үзләренә пылау китерер алдыннан чәйнеккә яшереп кенә аракы салып, шуны пиалаларга агызгач, дастархан янында утыручыларга өләшеп чыкканнарын да күргәләгәне булды. Юкса, нәрсәсе бар инде—куй шешәңне уртага, стаканнар җитәрлек, шаулаш, матур-матур тостлар әйт, кем гаепләп сүз итәр? Юк, кечкенәдән үзләштерелгән кагыйдәләр алай эшләргә ирек бирмиләр—ярамый, чөнки бер генә тапкыр вәсвәсәгә бирел, аннары әкренләп барлык гореф-гадәтләрне, ата-бабалардан калган йолаларны нигезенә кадәр җимерергә мөмкин.

Яшьләр дә монда үзләрен тыенкы тота. Бервакыт шәһәрнеке түгел икәнлекләре әллә каян күренеп торган, базардан килеп, очраклы гына чәйханәгә кергән ике яшь егетнең үзләренә гомер онытмаслык сабак алганнарының шаһиты булды Рушан.

Чиста-пөхтә чәйханәнең диварлары буендагы келәмнәр өстенә тагын курпачлар да—сырылган тар гына юрганнар да җәелгән иде, егетләрнең берсе йомшак юрганга рәхәтләнеп сузылып ятты, икенчесе аның янына утырды, алар, чәйханәдәге башка кешеләргә игътибар да итмичә, кычкырып көлә-көлә, кызып-кызып нәрсәләр турындадыр сөйләшүләрен дәвам иттерделәр. Алар дивар буена урнашкан, беркемгә дә комачауламыйлар иде шикелле, ләкин дисбесен сүзсез генә тартып утырган Мәгъсүм әкә, башкаларга сиздерми генә тегеләр янына килеп, егетләрнең колагына гына, йомшак кына ярым пышылдап нәрсәдер әйтте. Аның шул бер сүзе җитте, егетләр, оятларыннан кып-кызыл булып, урыннарыннан сикерешеп тордылар.

Мәгъсүм әкәнең артындагы самавыр янында кулдан язылган шундый язу бар иде: «Башкаларны хөрмәт ит—сине дә хөрмәт итәрләр».

Шахмат уйнап бетерер алдыннан, шәһәр өстенә төтенле эңгер-меңгер төшкән мәлдә, кайвакыт Рушан чәйханәгә килеп кергән балаларны күрә. Алар сүзсез-нисез генә үзләренә кирәк кешене эзләп табалар да, аның колагына нидер пышылдап, тавыш-тынсыз гына юкка чыгалар. Шуннан Дасаев киләчәктә дә үзенең кичләрен мәхәллә чәйханәсенә шахмат уйнарга яки ачык верандада утырып чәй эчәргә йөриячәген, шунда аны да, өйгә ашарга кайтырга чакырып, улы яки кызы йөгереп киләчәген күз алдына китерә. Ул, үзе дә сизмәстән, тәмле итеп елмая.

Әлбәттә, андый чакларда ул булачак балалары, хатыны турында хыяллана. Хатыны нindирәк булыр икән, тормышлары матур булырмы икән, дип уйлана. Дөрес, кулына нота папкасы тоткан кызчык вакыт еракрыкларында эри бара, менә-менә аның образы, төсе-кыяфәте бөтенләй

эреп бетәр шикелле була, ләкин, яшьлекнен сыек рәшәсендә томаннарга өретелеп калган ул ерак мәхәббәтне сызып ташлап булмаса да, күнелдә яна мавыгулар, яна хисләр кабына иде.

Андый чакларда Рушан һәммәсе дә үзе уйлаганча булачагына шикләнми иде. Тормыш ана сонынннан гына төрле көтелмәгән хәлләр әзерләгән булып чыкты, алар арасында йөрәк әрнеткечләре дә, куркынычлары да бар иде...

## XXXX

Рушан үзенең хәтер китабын актарганда, нәрсә турында гына уйламасын, Глорияне искә алмыйча калмый. Глориянен үз язмышыннан аерылгысыз язмышы рәхим-шәфкатьсез заманның ин җуелмас тамгасын салып калдырган иде шул.

Бервакыт энгер-менгердә, гадәтенчә, тәрәзә буенда истәлекләр кичәнә бирелгән бер мизгелдә, ул көндез актарып утырган иске хатлар өеме арасыннан бер зур фоторәсемнен почмагын күреп алды. Актүбә тимер юл техникумынын 1960 елгы чыгарылышыдыр, дип уйлап, рәсемне алып карады. Кемне күрергә теләде икән Рушан? Роберт Теләүмөхәммәтовнымы? Лом-Али Хәкимовнымы? Ефим Ульманнымы? Лидочка Журавлеванымы?

Ялгышты. Профессионал кул төшергән фоторәсем үз вакытында байтак газетларда басылып чыккан фоторәсем булып, анда СССР чемпионатынын бишенче зонасында «Б» классынын җинүчесе—«Металлург» футбол командасы сурәтләнгән иде. Заманында илдә спорт буенча әнә шундый әллә нинди квалификацияләр дә бар иде шул. Рәсемнең аскы ягына, сул як почмагына кыеклатып, каты картон өстенә ачык итеп, кызыл карандаш белән матур һәм табигый каллиграфик почерк белән мондый сүзләр язылган иде: «Рушан Дасаевка—«Металлург»нын беренче хуплаучысына, дустыбызга—җинүләребез истәлеге, яшьлегебез истәлеге». Һәм команда капитаны Джумбер Джешкарианинын нәкъ инде менә казначейларча эре имзасы ярылып ята.

Рушан рәсемнен артын әйләндереп карады. Анда футболчыларнын төрле төсле култамгалары сырланган булып чыкты.

«Металлург»ны көндәше куып житмәслек чемпион иткән уеннан сон ук төшерелгән фоторәсем иде бу. Чәчен матур итеп тараган, футболкасын пөхтәләп кигән Джумбер беренче рәтнен ин уртасына елмаеп чүгәләгән, ә анын тирәсендә—бер дә армаган-талчыкмаган, бәхетле командасы.

Еллар үтү белән безнен гадәтләребез, яраткан шөгыльләребез әллә ничек кенә үзгәрә дә бетә! Кем дә булса берәрсе, Рушан Дасаев берәр вакыт футболдан бизәр, уеннарга йөрми башлар, дисә—шаркылдап көлерләр генә иде. Җиде төн уртасында уятып сорасан да, ул, балалар санамышы шикелле генә итеп, «А» классы командаларынын теләсә кайсысынын алмаш составына кадәр исемләп әйтеп бирер иде, инде төп состав турында сорашып торасы да юк. Кайвакыт кышын, бернинди футбол уены турында сүз алып бармаганда да, төннәрен кинәт кенә анын колагына Синявский яки Озеровнын репортажы ишетелгәндәй була, ул, караваты янындагы тумбочка өстеннән «Спидола» транзисторын алып,—бу транзисторлар әле янарак кына чыккан сирәк әйбер иде,—шунын «колагын»borгаларга тотына: сон, ул бит трибуналардагы тавышларны, судья сыбызгысынын череллдәвен дә бик ачык ишетте, очып килгән тыгыз тупны да күргәндәй булды ич...

Тиз мавыгып китүчән Глория дә футбол карарга ярата иде. Ул тормышта күп нәрсәләргә мөкиббән һәм, нәрсәгә тотынса да, зур дәрт белән, теләк белән тотына, футбол уенына да ул искиткеч гашыйк кеше, ана онытылып табына иде.

Ул Рушан белән бергәләп яки «Муталлург» командасына ияреп, Ташкентка «Пахтакор» уенын карарга барырга ярата иде. Ул елларда футбол кырында атаклы уенчылар Красницкий, Стадник, Абдураимов, Искәндәр Фазылов, Ревал Закиров кебекләрне күрергә була иде. Глориянең дәртләнеп-шашынып уенны каравы искиткеч тәэсирле, аны үз күзләрең белән күреп, ишетеп торырга кирәк. Юк, ул урыныннан да сикереп тормый, тамаклары карлыкканчы кычкырып та утырмый, әче итеп сызгырырга да тотынмый, әмма бер ун минуттан анын тирәсендәге кешеләр дә дәртләнә-кыза иделәр. Ул уенны тирәнтен тоя, алдан күрүчәнлеге, сизгерлеге гаҗәеп, шуңа күрә прогноз-фаразларында бик сирәк ялгыша торган иде.

Үзләрендә—Заркентта уйнаган «Муталлург» командасының җиңүләренә анын кебек куанган, җиңелүләренә анын кебек уфтанган тагын берәр кеше булдымы икән? Уңышсыз уеннан соң пычранып-тирләп беткән Джумбер, Дасаевны чишенү бүлмәсендә күрсә, яктырып китә, әмма барыбер:

—Рушан, зинһар, Глорияне алып чыгып кит әле! Мондый уеннан соң анын күзенә карарга оят,—ди иде. Ә инде җинсәләр, алар шундый да бәхетле, шундый да горур атлыйлар! Егет белән кызнын даими урыннары булган трибуна яныннан узганда, һәр уенчы, әйтерсең, җиңүче гладиатор шикелле, Глория аягы астына җиңүен ташлагандай итә, ә кыз җавабында юмарт итеп, куанып елмая.

Команда читтәге уеннарын оттырып кайтканда, Глория шелтә сүзләре әйтсә, Джумбер шаяртып:

—Глория, син бит безнең тылсымыбыз-талисманыбыз! Анда уенны кемгә багышларга да белмәдек. Әгәр дә аны бүләк итәр кешең булмаса, ир-атка җиңү нигә кирәк? Менә иртәгә үзебездә уйныйбыз, син килсәң, егетләр тырышачак, әлбәттә...—ди.

Ә инде, буш көннәре булып, Глория команда белән бергә якындагы казакъ шәһәрләре Чимкент белән Җамбулга барып, анда «Металлург» көндәшләрен пыр туздырып, тар-мар итеп кайтканда, анын ничек куанганын күрсәгез икән! Футболчылар—ырымнарга ышанучан халык, алар Глориянең командага уңыш китерәсенә ихлас ышана иделәр.

Рушанга фоторәсемгә карамаса да була, ул кояшлы, якты, көздән бигрәк язга тартым көнне бик яхшы хәтерли, хәер, таулардан кыш алды салкыннарының сулышы сизелә иде инде, алар төзеп яткан зур комбинатның моржаларыннан да төтен чыкмый әле, Глория белән аны команда белән бергәләп рәсемгә төшәргә никадәр генә кыстасалар да, Глория нык торды:

—Бу сезнең җиңүегез, егетләр,—дип, дулкынлануын һәм күз яшьләрен тыя алмыйча, аларның юеш-пычрак битләреннән берәм-берәм үбеп чыкты, үзенең яраткан ак күлмәге Джумберның футболкасы кебек пычранганына да игътибар итмәде...

Рушанны Глория белән шул футбол таныштырган да иде. Дөресрәге—Джумбер. Хәер, болар икесе бер үк нәрсәләрдер.

Заркент...

Шәһәрнең исемендә Рушаннын үзе генә аңлый ала торган музыка ишетелә шикелле. Искә төшереп, телгә алганда, кинәт кенә сискәнеп китеп, эчендә нәрсәдер өзелеп төшкәндәй тоела, бер мизгелгә исертерлек, баш әйләндерерлек, үзең генә белгән-яраткан шәһәрең була да кала Заркент. Андый шәһәр һәркем өчен теләсә нинди булырга мөмкин—зур йә кечкенә, иске йә яңа, атаклы-данлыклы яки бөтенләй исеме ишетелмәгәне, әмма хикмәт анда түгел—ул синеке, ул синең йөрәгеңнең бер өлеше булырга тиеш. Һәм, мөгаен, соңыннан үзәкләрне өзеп: «Ә хәтерлисезме, безнең шәһәрдә...»—дип искә алмас өчен, синең соңгы көннәрең дә шунда тәгәлләнергә тиештер. Һәм ул, бер генә кешесе булса да, синең яшьлегеңне, уңышларыңны исендә тоткан, шуларның шаһиты булган бердәнбер шәһәр булып калырга тиеш. Бер генә мәртәбә

булса да: «И-и-и, син бит бөркет идең! Синен шундый гүзәл сөйгән кызың бар иде! Хәзер андыйлар юк шул инде...»—дип әйтерлек булсын.

Әмма... әмма...

Тормыш кырыс, язмыш явыз—алар сине шул бердәнбер шәһәреңдә генә калдырмый шул: дүңгәләк шикелле иттереп, ил буенча куып йөртә, шәһәрләреңне дә алмаштырырга мәҗбүр буласың... Менә, Рушанның да Заркенттан соң яраткан шәһәре Ташкент иде. Хәзер анысы да «иде» дип сөйләргә генә калды шул...

Ә Заркент Рушанның яшьлек шәһәре, яшьлек мәхәббәте. Кемдер ышанмаска да, хәтта кимсетеп елмаерга да:

—Заркент? Анысы тагын нинди башкала?—диярга дә мөмкин.

Әйе, торак мәйданнарын алыштыру турындагы белешмәлекләрдә ул бик түбән урында тора. Хәер, нәрсәдер аңлатырга, акланырга тырышу кирәкме икән? Үз шәһәре булмаган кеше кызганыч—ул барыбер йортсыз-җирсез яшәргә дучар ителгән шикелле...

Ул заманнарда Заркент өч йөзләп күтәрү краннарын эссе Азия күгенә төбәп, урман кебек булып утырыр иде, шәһәр көн-төн төзелә, әле кичә булмаган нәрсәләр, берсекөнгә күтәрелеп-калкып чыгарлар иде.

Рушан килгәндә, шәһәрнең аерым өлешләре шәйләнә башлаган иде инде. Үзәктәге зур булмаган табигый калкулыкта, зур үзәк урамның шау-шуыннан бераз еректарак, кечкенәрәк кенә бакчалы һәм фонтанлы «Космос» кинотеатрының мәһабәт бинасы күтәрелгән. Бу урын—шәһәр халкының иң яраткан урыны һәм әле озак еллар буена, шәһәр үсеп, башка менә дигән биналар да калкып чыкканчыга кадәр, гашыйкларның очрашу урыны да булып калды.

Әмма Заркентның аерым горурлыгы стадион иде. Ана урынны шулай ук үзәктән ерак түгел җирдә, зур парк-бакча зонасында тәгаенләгәннәр. Ул бик яхшы проектлаштырылган һәм оста, сыйфатлы итеп төзелгән, җиңел, нәфис. Кышкы спорт заллары да, су спорты сарае да бар—ул уртача яшьләре егерме дүрттән бераз гына артыграк булган шәһәр халкын үзенә тартып тора. Иртә язда бу стадион үзәк матбугатта, бигрәк тә спорт газет-журналларында еш кына телгә алына. Эш шунда ки, ул илдә шлак сибеп ясалган ярыш юллары булган икенче генә стадион иде, сезон башланыр алдыннан иң атаклы узышчылар, күбесенчә Уфадан, Заркентка күнегүләр үткәрергә җыела.

Әле бит тагын аларның ярышлары да була! Кайсы гына исемне алма, күп тапкырлар СССР чемпионы, һәр фамилия алдында спортчы өчен бик тә кадерле өч хәреф язып куела: ЗМС—заслуженный мастер спорта, ягъни атказанган спорт мастеры. Мондый афишаларны башкала шәһәрләрендә дә бик еш күрә алмыйсың. Бөтен дөньяга танылган мотоциклчы Габдрахман Кадыйровның кызыл шарфы Заркентның язгы җилләрендә бер тапкыр гына җилфердәмәде ул елларда. Соңгы хәлиткеч узышта Игорь Плеханов, Борис Самородов, Габдрахман Кадыйров һәм тагын дүртенче берәү чабышканда стадион ниләр генә кыланмый да, нинди генә шау-шу тудырмый! Бу ярыш бит, чынлап әйткәндә, әнә шул дүртенче узышчы өчен уздырыла да. Дүртенче булып күбрәк тректан, ягъни спорттан бер китеп, бер кире кайтып йөргән, шулай ук атаклы, әмма картаеп килүче Фәрит Шәйнуров яки әле бөтенләй яшь, гаять кыю-тәвәккәл, мотоциклын арт көпчәкләренә күтәреп чабучы Юрий Черканов катнашыр иде. Заркентта аны, яратып, Чика дип кенә йөртләр.

Әле яшьлеген җуймаган Борис Самородов ешрак җиңүче булып кала. Кызлар кебек оялчан Габдрахман Кадыйров исә, тамашачылар алдында гаепле кешедәй елмаеп, кызыл шарфын муеныннан сүтеп ала—барып чыкмады бу юлы, дигәндәй, акланган шикелле итә. Юкса, икенче урыннан да түбән төшми үзе, көмеш медаль язмышын да фотофиниш белән генә билгеләгән чаклары да күп була.

—Түзегез инде, кыш көне мин үземнекен алырмын, сынатмам,—дип өметләндерә Габдрахман кызларны, алар сузган кульяулыкларны

алмыйча, шлак тузанын хуш исле кулъяулыклар белән генә сөртеп бетереп буламыни? Чабышкан-узышкан чакларында спидвей ярышларында, бозда узышта ана тиннәр булмады, ул спорттан, җиде мәртәбә дөнья чемпионы, унике мәртәбә СССР чемпионы исемнәрен яулап, җинелмичә китте, спидвей короленең кызыл шарфын Европаның күп кенә башкалалары ареналарында озак еллар искә төшереп тордылар.

Сонрак Глория, ничектер, Рушанга Яшьләр йортынын яна бинасындагы фойэнын зур диварын «Мотоциклчылар» дигән мозаик панно бизәп торсын иде, дигән теләк белдерде. Юк, беркем танымаган абстракт спортчылар түгел, ә нәкъ менә тормыштагыча, чын-чынлап ярыш барышында вираж-борылыштан беренче юлга ашкынып килүче Самородов—Кадыйров—Плехановлар булсыннар иде алар, уртада—легендар кызыл шарфы җилфердәп торган Габдрахман, әлбәттә.

Яшь шәһәрнең кумирлары—яраткан каһарманнары спортчылар булуына һич тә гаҗәпләнергә кирәкми. Мотоциклда узышучылар бер хәл әле. Алар, тылсымлы шапито циркында шикелле, күн комбинезоннары, тимер дагалар сугылган күнитекләре, атаклы фирмалар эшләгән ачыкматур төстәге шлемнары белән мираж кебек кенә булып, өермәдәй узалар да китәләр, узалар да китәләр, йөзләрен дә юньләп күрми каласын, ә көннәрдән бер көнне, кыйммәтле машиналарын төяп, стадионда бензин һәм шлакның татлы исен генә калдырып, юкка да чыгалар. Яшьлек дәрте-җегәре юмарт ташып торган шәһәрнең иркәләре, чын кумиркаһарманнары футболчылар иде, билгеле. Алар Глориянең дә кумирлары булды. Чөнки алар үзебезнеке, Заркентныкы!

Глория...

Рушан анын фоторәсемен эзләп табарга теләде дә, аннары кире уйлады: нигә кирәк? Теләсен генә—ул һәрвакыт анын күз алдына килә дә баса.

Рушанга кинәт кенә Заркентның язгы җил исе тоелгандай булды, бу шәһәрнең җиле дә үзенә генә хас үзенчәлекле—Заркент таулар белән уратып алынган, бары тик Ахангаран белән Ташкент ягына таба гына киң-иркен дала сузыла. Ә тауларда язларын алсуланып миндаль һәм чикләвекләр чәчәк ата, карт алма бакчалары, мул кар күмеп киткән шикелле, ак күбеккә батып утыра, шактый гектарларга шулай сузыла бу күренеш. Шау чәчәктәге миндаль һәм алмагач исләре, күкрәп яшелләнгән тау битләреннән искән җил белән аралашып, шәһәр өстенә ишелеп төшә, болай да кайнар йөрәкле яшьләрне тәмам исертә.

Әйе, алар Глория белән язда танышканнар иде. Рушан ул чакта өлкән прораб булып эшли иде инде. Ул эш көне булган шимбә көннәрен яхшы хәтерли—бишкөнлек эш атнасы турында ул вакытларда әле сүзләр генә йөри иде.

Идарә башлыгы, төзелеш эшендә карт бүре, шимбәләрдә шелтәләптуздырып ташлаулар белән мавыкмый, монын өчен һәркөнне мәҗбүри була торган планеркалар да җитеп ашкан. Киңәшмә азагында башлык, ачык тәрәзәләр аша карашларын урамга ташлаштыргалап утырган мастерларына һәм прорабларына карап, канәгатьсезлек белдергәндәй әйтеп куя:

—Күрәм, күрәм: уегызда яз, футбол да, теге...—ничек әле... спидвей... Бөтен шәһәр акылдан шашкан, безнең стадионда кычкырышканакырышкан тавышлардан хәтта Ташкент зарлана, ди. Бетердем. Барыгыз, йөгерегез, бәлки, тавышларыгыз Мәскәүгә хәтле ишетелерлек булыр... Безнең гозерләргә дә колак салырлар...—ди. Ул үз кул астындагы халыкны гадәттәгедән кырык минутка алданрак җибәрә. Барысы да, малайлар шикелле, ишеккә ташлана, берсе өстенә берсе өелешеп, ишеккә сыймыйча, тыгылышып кала, кайсыдыр бер түземсезе хәтта тәрәзәдән генә урамга сикерә...

Рушан ул истәлекле көнне чит төзелеш-монтаж идарәсе машинасына эләкте, «Яз» кунакханәсенә кайтып җитеп туктар-туктамастан, кузовтан сикереп кенә төште дә, өчәр баскычны берьюлы сикерә-атлый, үз катына

очып менде. Анын күнеле дә, бүген тормышында ниндидер бик мөһим, гадәттән тыш хәл буласын сизенгән шикелле, уйнаклый-очына иде. Яшьлектә барысы да гади: душка кереп юынып чыктын, чиста-пөхтә күлмәк, үтүкләнгән костюм киден, көзгегә бер карап, чәчләренне тараштырдын да—син әзер, йончыткан тыгыз эш көне дә, үз яшенә һәм вазифана караганда шактый күп уй-борчылуларын да гүяки бөтенләй булмаган.

Һәр чорнын—үз стиле, үз килеш-килбәте, үз модалары. Әгәр дә Рушаннан үз яшьлек чорын кыска гына сыйфатлап әйтеп бирүне сорасалар, ул, уйлап та тормыйча, болай дип җавап бирер иде:

—Пөхтәлек-төгәллек һәм, мөгаен, һәрвакыт яхшырак булырга омтылудыр.

Көньяктагы шәһәрләрнен һәр урам чатында аяк киемнәре чистартучылар утырыр иде, хәзер елдан-ел аларнын будкалары юкка чыга бара, элек алардан башка шәһәрләрне күз алдына да китереп булмый иде. Ә бит көзгедәй ялтыратып кигән аяк киеменә үтүкләнмәгән чалбар, керләнгән күлмәкләр бөтенләй ятышмый...

Аларнын яшь шәһәре Заркентка ин сонгы модалы киемнәр киеп футболчылар—Тбилиси, Мәскәү, Ташкент егетләре килә. Команда футболга җаны-тәне белән бирелгән, менә дигән оста уенчы, һәрвакыт бик пөхтә, грузиннарга тумыштан ук салынган нәзакәтлелеккә һәм зәвыкка ия булган үз капитанынннан үрнәк ала. Хәзерге халыкара уеннарда да кырынмаган, гетр-оеклары сыдырылып төшкән, бөгәрләнеп-таушалып беткән футболкалы уенчы гадәти күренешкә әйләнде, ә Джумбернын командасыннан гап-гади уенга да пычрак бутсы-ботинкалар киеп берәү дә чыкмас иде...

Радиоалгычын кабызып җибәреп, күнелле музыка тынлый-тынлый, Рушан ашыгып киенә башлады һәм кинәт кенә үзләре эшләп бетереп килә торган төп бинанын түшәмен штукатурлаучы кызларны исенә төшерде. Озын көн буе эшләп арыгач, бер теләгән дә калмаган, тизрәк тулай торакка кайтып караватка авасы гына килгән булырга тиеш, ә юк, яшьлек үзенекен итә, кызлар көн азагында да тыпырдап биештерә-биештерә, үзләре уйлап чыгарган ниндидер күнелле бер җырны җырлый-җырлый эшлиләр, җырларынын кабатланып килгән кушымтасы да шаянщук иде: «Әй, шимбәкәй! Әй шимбәкәй-чибәркәй!..»

Ә урамда шимбә киче үзенен хокукларын яулый бара: бакча ягыннан музыка янгыраганы ишетелә, урам фонарьлары кабына. Рушан да ашыга төшә. Анын үзе яратып ял итә торган урыннары бар иде. Шунын өстенә ул шәһәргә мотоциклчылар килгәнен дә белә—афишалар иртәгә зур ярышлар-узышлар буласын вәгъдә итә, анда атаклы кунакларны да күрергә мөмкинлеген чамалый иде.

«Энҗекәй»гә якынлашып килгәндә, ул музыкантларнын уен коралларын көйләү тавышларын ишетте, идәннән өскә таба көчле утлар белән яктыртылган һәм, чынлап та, ачып куелган галәмәт зур энҗе кабырчыгына охшаш сәхнә, алсу-нәфис мәрҗән төсе белән ялтырап, ерактан ук сина бәйрәм күнеллелеге вәгъдә итеп тора.

«Энҗекәй»нен әнә шулай утлар яктысында матур төсләр белән уйнаклап торуы архитектор табышыдыр, мөгаен. Кафе башта ук архитектор тарафыннан күп кешелек итеп уйланылган, аерым сайланган катлам өчен генә булмаган, чөнки шәһәрдә—тулай торак өстендә тулай торак, дигәндәй, ә Заркентта тугыз ай җәй, менә дигән матур саф һава тора, ни өчен әле халыкны тимер-бетон читлекләргә һәм пыяла аквариумнарга куып кертү кирәк?

Энҗекәй»нен кабырчыгы кафедагы урыннарнын өчтән берен дә капламый. Зур идәне, төрле калынлыктагы бакыр пластиналар батырылып, секторларга бүленгән, ялтыратып шомартылган ул пластиналар идән өстендә ачык алтын сызык булып сузыла. Һәр секторга үзенә аерым бер төстәге мәрмәр вагы тутырылган һәм ул шомартып катырылган, сектор уртасында шул ук алтын сызыклардан үзенә генә хас экзотик чәчәк

ясалган. Өстән караганда, ул алтын кушып тукылган зур келәмне хәтерләтә, келәм өстендә—дүрт ачык кызыл түгәрәк, шулар арасына төрле формадагы һәм төрле зурлыктагы өстәлләр төрлечә итеп тезеп куелган, һәр секторның аерым бию мәйданчыгы да бар. Сирәк кенә була торган явымлы көннәрдә яки көтелмәгән язгы яңгырларда энҗе кабырчык астына сыймый калган кунаклар нәүмиз булмасын өчен, һәр секторның аерым бер урыныннан, мәрҗән кабырчыкның үзе шикеллерәк, гаҗәеп тропик агач «үсеп» чыккан, аның зур-зур әкәмәт кызык яфраклары калган барлык өстәлләрне дә каплап тора.

Рушан ишек янында тоныкк кына яктыртылган мәйданчыкта тукталып калды һәм өстәлләрне күзли башлады—бүген монда аның байтак танышлары булырга тиеш иде. Кинәт аңа дәштеләр:

—Рушан, кил безнең янга!—экзотик агач астындагы бер өстәлдән ана Джумбер, Тамаз Антидзе, Роберт Гогелия—»Металлург» командасының кырый һөҗүмчеләре, чакырып, кул изи иделәр.

Дасаев елмайды, чакыруларын кабул итеп, кулын күтәреп сәламләде. Өстәл янына якынлашкач, ул Роберт каршысында үзенә аркасы белән утырган кызны күреп алды. Кызның аккошныкыдай озын ак муены менә-менә сынып китәр төсле, авыр чем-кара чәчләре тыгыз һәм матур итеп баш артына өеп куелган иде.

—Сез таныш түгелмени?—дип гаҗәпләнеп сорады Джумбер, Рушанның кызга кызыксыну белән караганын сизенеп.—Глория, гафу ит, таныш бул: Рушан—безнең дустыбыз һәм бер үк вакытта зур начальнигыбыз да, тормышта андый хәлләр сирәк була,—дип шаяртып таныштырды.

—Глория,—кыз, урыныннан күтәрелә төшеп, бераз кызларга хас чытлыкланыбрак, тар өстәл аша Рушанга кулын сузды, егет, аның йөзеннән күзләрен алырга кыймыйча, кулының нечкә беләзеге тирәсеннән үбеп алды. Кызның йөз чалымында кемгәдер охшашлык бар иде шикелле.

Рушан аңлап алды: кыз Тамарага искиткеч охшаган иде, әйтерсен лә, табигать аңа гомерлеккә югалткан кадерлесен кайтарып бирергә теләп, шаяртырга уйлаган иде.

—Димәк, сез футбол тренеры, командагызның ничек ял иткәнен карарга кердегезме? Хәбәр итәм: Тамаз бишенче сигаретын кабызды инде, менә, төпчекләре барысы да тәмәке көллегендә ята. Бәлки, сез килгәч, бераз тыела төшәр, юкса «БТ» сигаретын кабы бушаганчы тартып утыруы бар...

—Шундый чибәр, акыллы да, диләр үзенне, ә баксаң—гап-гади әләкче икән,—дип, елмаеп, кызны бүлдерде Тамаз һәм кабыннан тагын бер сигарет тартып чыгарды.

—Мин тренер түгел, Глория...

—Джумбер, тагын шаярттынмы? Син бит ачык итеп әйттен: Рушан—безнең начальник, диден...

—Кадерлем, ул безнең, чынлап та, иң зур начальнигыбыз. Туендыручыбыз син безнең...—дип, Джумбер белән Тамаз, сөйләшеп-нитеп тормастан, уен уйнагандай итеп, икесе ике яктан Рушанны кочып алды.

Хәзер инде үзен өчәүләп шаярталардыр, дип шикләнгән кызның аптырап калуын күргәч, Рушан, ул үпкәләмәсен өчен, ашыгып аңлатуны кирәк тапты:

—Бер яктан караганда, мин аларның башлыгы да кебек. Үзләрен бик еш күрмичә, бары тик шушында яки «Космос» кинотеатры янында һәм, билгеле инде, уеннарын караганда гына күрсәм дә, һөҗүмчеләрнең айлык хезмәт хакларына нарядларны мин ябам. Бу өч бөркет минем төзелеш участогымда эшлиләр булып санала. Джумбер—алтынчы разрядлы балта остасы, ул капитан, лидер. Тамаз белән Роберт бишенче разрядлылар, бераз түбәнрәк, аз туп кертәләр...

Гомуми күңеллелеккә кушылып, ул да шаярта башлады һәм янә Глориягә генә карап:

—Әгәр алар үзләрен бүген әйбәт тотмаса һәм яныбызда утырган

бердәнбер кызга тиешле игътибарны күрсәтмәсә, мин аларның разрядларын, һичшиксез, төшерәчәкмен. Безнең башлык әйтә: иң нәтиҗәле сугу—кесәгә сугу, ди. Ә сез, капитан, мәкерле штраф туплар тибү остасы, ничек уйлыйсыз?

—Глория, күзләрегездә яшьләр күрәм, кирәкми, еламагыз, безне вакытыннан алда кызганмагыз әле. Рушан әйбәт кеше ул, футболны да бик ярата, андый әшәке адым ясамас, безгә этлек эшләмәс...

Джумберның бу шаяртуына да өстәл тирәсендәгеләр дәррәү көлеп җибәрделәр.

Мыштым Роберт Джумберның артыннан официант кызга ниндидер ым-шымнар ясап алды, официант Рушанга бокал һәм зур вазага таудай өелгән куе-кызыл, дымлы черешня китереп куйды.

—Димәк, сез төзүче?—дип сорады, ни өчендер шатланып Глория.

—Әйе, өлкән прораб.

—Ә без сезнең белән бераз коллегалар икән бит, мин архитектор. Ләкин мин төзүчеләр белән гел сугышып торам, тыныч кына эшләп булмый. Алар миңа: «Утыз яшьтә инфаркт сугачак сезне...»—диләр...

Ул кинәт Тамаздан урыннарын алышып утыруны үтенде, Рушан янәшәсенә күчкәч, хыялланып сүзен дәвам иттерде:

—Әгәр дә мин шәһәребез өчен үтә дә шәп ниндидер гадәти булмаган берәр нәрсә иҗат итеп, сез шуны төзеп бирсәгез, нинди шәп булыр иде! Миңа сез мине инфарктка ук житкермәссез, аңларсыз кебек тоела,—дип, чытлыкланыбрак, кулын Рушанның җилкәсенә салып, сүзен тәмамлады ул, әмма Рушан ни өчендер аның күзләрендә монсулык күрде.

«Сәер кыз...»—дип уйлады ул.

Алардан ерак түгел күрше секторда, берничә өстәлгә таралышып, мотоциклчылар һәм атаклы спортчыларны озатып йөрүче техник хезмәткәрләр утыра иде.

—Миңа Кадыйровны күрсәтегез әле,—дип үтенде Глория.

—Әнә, кара, «китлар» аерым утыра—оркестр янәшәсендә,—дип әйтеп куйды, әлегә кадәр сүзсез утырган Роберт.

Зур банкет өстәле тирәсендә җиде кеше иде. Өлкәнрәкләре—костюм-галстуклардан, яшьрәкләре джинсы чалбардан һәм атаклы спорт фирмаларының кычкырып торган эмблема-тамгалары сугылган пуловерлардан, Карденның бер төсле күлмәкләреннән иде. Бу мода әле тагын унбиш еллардан соң гына безгә керәчәк. Боларның дөньяны күргәннәре сизелеп тора. Артык шаулашмый гына, үз дәрәҗәләрен белеп кенә утыралар.

Оркестр уйнап җибәрде. Тамаз, иптәшләреннән гафу үтенеп, күрше өстәл янындагы бер кызны биергә чакыра китте, аның үзен ул өстәлгә кич буе дәшеп утырган иделәр.

—Мин Кадыйров белән биер идем. Мин ырымнарга ышанам—кайчандыр ишеткәнем бар: күренекле кешеләр белән аралашу уңыш китерә икән,—диде Глория. Күрәсең, уйлары белән ул «Энҗекәй»дә түгел, әллә кайларда иде инде.

—Биергә теләсәң, чакыр соң,—диде Джумбер тыныч кына, кызның сүзләренә артык әһәмият бирмичә.

—Ә кире какса?—дип куркынып әйтеп куйды Глория.

Аның бу сүзләреннән Рушан тагын да гаҗәпкә калды.

—Синеме?—дип ышанычсызрак һәм гаҗәпләнебрәк сорады Джумбер һәм кин итеп елмайды:—Глорияне кире каккан егетне күрергә телә́р идем мин!

—Әй, ни булса, шул булыр!—диде кыз.

Аның әле генә кыюсызланып, икеләнеп-шикләнеп утырганына да ышанасы килми иде.

Бер минуттан Джумбер Рушанга дәште:

—Кара әле, Рушан, ничек матур бииләр, иске дуслар кебек ничек чөкердәшәләр! Глорияне Габдрахманнан озынрак дип әйтеп буламы әллә?

Искиткеч әдәплелек, гүзәллек-нәфислек, партнерны кимсетмәү тойгысы, ә?! Ничек шулай булдыра, диген? Ә чибәрлеге... Кара, Рушан, гашыйк булып куя күрмә, мондый кыз без егетләр өчен—бәхет тә, һәлакәт тә, туган... Үзенең сөйкемлелеге өстенә, ул әле үтә дә талантлы, син моңа үзең дә ышанырсың әле, сез коллегалар бит...

Алар кичнең калган өлешен ике өстәл бергә кушылып үткәрделәр. Глория бердәнбер кыз булып кала бирде. Кунакларны кунакханәгә кадәр бергәләп озатып куйдылар, тегеләр юл буе Глорияне: «Иртәгә кем өчен янарсың-көярсең?»—дип интектереп бетерделәр. Ә кыз, уйлап та тормый, елмаеп:

—Заркенттагы барлык кешеләр кебек, мин дә Габдрахман өчен,—дип кенә җавап биреп барды.

Бу соклангыч кызның мөлаем ягымлылыгыннан югалып калган, болай да тартынучан Кадыйровны шул җавабы белән тагын да каушата иде Глория.

Кунакханә янында теләмичә генә саубуллаштылар—мотоциклчыларны иртәгә авыр көн көтә иде. Джумбер Рушанга мөрәҗәгать итеп үтенде:

—Рушан, зинһар, Глорияне озатып куй инде, мин бүген тренер урынына калган идем, үзем отбойга соңга калсам—яхшы түгел, иртәгә бик иртә күнегүләр дә бар. Йоклап калмасаң—кил, бергә туп тибәрбез...

Рушан җае килгәндә аларның күнегүләренә йөргәли, икегә бүленеп уйнауларына катнаша иде...

Егет белән кыз кешесез урамнардан атлап китте. Глория кинәт сорап куйды:

—Сиңа «Энҗекәй» ошыймы? Мин архитектурасын, интерьерын күздә тотам.

—Сүз дә юк, искиткеч кафе, яшьләргә фарт килде.

—Нигә соң син алай булгач, кич буе мине котларга да теләмәдең?—дип көйсезләнебрәк сорады кыз.

—Нәрсә белән?—дип аптырап калды Рушан.

—Син бер ай элек «Энҗекәй»нең ачылу тантанасына килмәгән идеңмени?

—Минем икенче сменам башланып килә иде, бара алмадым шул, ул вакыйганы ишетүен ишеткән идем.

—Ә, менә эш нәрсәдә икән,—диде Глория.—Архитекторы кем икәнен ишеттеңме соң?

—Ишеткән кебек идем, ниндидер әрмән фамилиясе бугай.

—Кароянмы?

—Нәкъ шулай! Житди фамилия, янгырый да, мөгаен, танылган архитектордыр.

Кыз барган җиреннән туктап калды, шаяртыбрак бөгелә-сыгыла кулын сузды:

—Танышырга рөхсәт итегез: мин—Глория Кароян,—диде.

—Димәк, син шул архитекторның кызы? Әтиеңне чын күңелдән минем исемнән котла—сокланырга лаеклы эш.

—Рушан, тагын бер рәнҗетсәң—мин бөтенләй китеп барам, син гомергә дә минем бәхилләвемне ала алмаячаксың.

—Син... «Энҗекәй»нең архитекторымы?! Шундый...—Рушан хәтта адымнарын буташтырып алды.

—Дәвам ит, дәвам ит... Житди түгел, димәкчесеңме? Их, бу ирләр, бигрәк тә төзүчеләре...—дип, тагын көйсезләнеп, әмма Рушанны шаккаттырганыннан канәгать калып, сүзен дәвам итте ул:—Сиңа өстәмә мәгълүмат: Кароян, бәлки, әрмән фамилиясен хәтерләтәдер дә, әмма миндә әрмән каны юк, бик күп каннар катнашкан-катнашуын: венгр, урыс, күбрәк немец каны. Минем ерак бабаларым—Европада танылган төзүче архитекторлар, Россиягә бер гасыр ярым элек килеп төпләнгән булган һәм менә хәзер, уннарча буыннардан соң, ихтимал, миндә аларның

геннары уянгандыр, хәер, бу гасырда безнен ыруда архитекторлар булмаганы төгәл билгеле.

Рушан исе-акылын жыя алмыйча басып тора иде, бары тик:

—Ничек булдыра алдың моны, Глория?—дип кенә сорый алды.

—Сиңа, дөрестән дә, кызыкмы минем язмыш?—Глория аны култыклап алды:—Алайса тыңла... Мин биредә ярты ел диплом алды практикасында булдым. Шәһәр миңа, архитектор буларак, ошады: һәммәсе дә буш жирдә нульдән башланып ята иде, үземне күрсәтергә сирәк мөмкинлек туды. Миңа шәһәр ошаган булса, мин «Градострой»га ошаганмын икән. Практиканы шунда үтә идем. Институтны тәмамлагач, Заркентка килүемне үтенделәр. Безнен буынны, мөгаен, биюче буын дип йөртерләрдер, үзем дә биергә бик яратам... Сине хәлдән тайдырмадыммы әле?

Глория Рушанның йөзенә күтәрелеп карады да бүленгән сүзен дәвам итте:

—Минем борынгы австро-венгр бабаларым заманнарында бию салоннарына биергә йөри торган булганнар, анда Штрауснын үз оркестры уйнаган. Ләкин минем максатым башка иде: хәзер инде юкка чыгып бара торган гадәти бию мәйданчыгы белән салонны берләштереп, ниндидер алтын уртасын табасым килде, юкса, салон мине бию араларында утырып ял итәргә, әңгәмәләр корырга мөмкинлек бирә торган өстәлләре һәм бәйрәмчә рухы белән генә кызыксындырган иде. Төп фикер-идеяне миңа шәһәр үзе бирде: аның климаты-һавасы, жиләк-жимешләр муллыгы һәм хәтта сусау—газлы һәм минераль суларга, туңдырмаларга даими мохтажлык... Нәкъ менә минем өчен генә әзерләп куелган шикелле буш урынны табып алгач, чын-чынлап комарым-дәртем кузгалды, менә шул төп этәргеч булды да инде. Кич саен мин шул ташландык буш жиргә киләм, күнелемнән кафены күз алдыма китерәм, әмма берсе дә әле ул түгел, мин теләгән түгел... түгел иде... Әгәр дә берәрсе күнелемә ошаса да—өсте-өстенә өелгән зур һәм авыр булып, кыйммәтле булып килеп чыга. Мин белә идем: корылма арзан булырга һәм ярты ел эчендә төзелеп бетәргә дә тиеш. Әйтәм ич, мин анда көн саен барып йөрдем—иртә таңда, кич кояш баеганда, көн уртасында, энгер-менгердә, әмма хәзер син күреп йөри торган «Энжекәй»не күрмәдем. Әле исеме дә юк иде.

Шул ташландык буш жирдә башыма тагын бер бик мөһим фикер килде. Шәһәр миңа аның ни-нәрсә буласын, нинди хезмәт башкарасын күнелемә салган булса, сайлап алган урыны хыялымның тормышка ашардай булуына ышаныч бирде. Мин кем соң әле? Менә шулай уйладым мин. Син елмайма, Рушан, миндә еш кына икеләнү-шикләнүләр була тора... Кем минем проектымны карар? Кем аны хуплар? Кем аны төзелешләрнең титул исемлегенә һәм кайсы елга кертер? Бер төрле генә һәм ышанычлы итеп мин бу сорауларның берсенә дә жавап бирә алмый идем. Әмма шуны беләм: иң яхшы очракта да боларны чишәргә еллар һәм еллар кирәк булачак иде. Ә миңа үземне хәзер үк күрсәтергә кирәк, көтеп тормыйча, менә шундый ижат шаукымымы, дәртеме бар иде миндә. Мин аңлап алдым, проектны жәмәгать башлангычы итеп эшләячәкмен, түләүсез, бушлай, ул минем шәһәргә бүләгем булыр. Мин үз эшемне комсомол шәһәр комитеты хөкеменә, яшьләр хөкеменә тапшырырга карар кылдым, ә нинди дә булса әйбәт, игътибарга лаек нәрсә эшләячәгемә шигем юк иде... Әйдә, бәя бирсеп карасыннар!

Төнге урам чатында көтелмәгәндә кабынып киткән кызыл светофор алдында тукталып, Глория сүзен шаяртуга борып әйтте:

—Менә шундый шөһрәт яратучан, үз сүзле кеше инде мин, Рушан!—диде.

Һәм янадан сөйләп китте:

—Бу фикерләремне мин практика житәкчем белән уртаклаштым. Билгеле инде, бу сөйләшү бик яшерен сер итеп тотылды. Миңа аерым бүлмә бирделәр, шунда иртән килеп бикләнәм дә төн уртасына кадәр

утыра идем. Беркем комачауламый, фикерләремне чуалтмый-таркатмый— баш архитектор барысына да минем махсус эш белән утыруымны гына әйтә.

Китәремә бер атна калганда, баш архитектор мине комсомол шәһәр комитеты секретаре белән очраштырды. Ул, синең кебек үк, төзүче булып чыкты. Монысы минем эшемне тагын да жиңеләйтеп жибәрде. Мин аны үземнең идеям белән кабызып жибәрә алдым. Секретарь миннән бары тик шәһәр комсомол активы алдында да шулай янып-ялкынланып, ышандырырлык итеп сөйли алу-алмавымны гына сорады. Мин теләсә нинди югары дәрәжәле урыннарда да фикерләремне ярып салырга әзер икәнлегемне әйттем. Секретарь егет алдында батырайсам да, очрашу алдыннан ике көн буена бик нык дулкынланып йөрдем. «Градострой»дагы яшь коллегаларым күргәзмә стендларны ясарга булыштылар, бу эшкә аларның тәжрибәсе житәрлек иде. Әмма мин шунысын да белә идем: күрсәтеп бирү генә житми, ышандырырга, исбат итәргә кирәк булачак. Мин чыгышымны кәгазьгә төшердем—машинкада бастыргач, ун бит килеп чыкты ул. Үз проектымдагы һәр нәрсәнең үзлегеннән генә тумаганын, ә менә нәкъ Заркент өчен, Урта Азия шартлары өчен исәпләп эшләнгәнлеген аңлатырга тырыштым.

Җыелышны мин проектымнан бигрәк, ышанычлы итеп, белеп сөйләвем белән үземә караттым шикелле. Бик күп сораулар бирделәр, залда бит күпчелеге төзүчеләр утыра иде, ә мин сораудан-сорауга кыюланып жавап биреп тордым. Мин хәтта төзелешкә акча туплау өчен ничә якшәмбе өмәләре үткәрергә кирәк булачагына хәтле белә идем. Әлбәттә, жыелыш эскизларымны да, макетымны да ошатты. Шул очрашуда Джумбер белән дә таныштым. «Металлург» командасы «А» классындагы командалар белән буласы язгы контроль уеннарыннан жыелган керемне тулысы белән яшьләр кафесы төзелешенә бирәчәген беренче булып ул әйтте шикелле.

Мин бик бәхетле идем, канатланып кайтып киттем. Төзелеш штабыннан Ленинградка ел буе шалтыратып тордылар: эшлекле сөйләшүләр, киңәш-унаш итешүләр иде бу. Кышкы каникулда комсомол шәһәр комитеты мине үз хисабына Заркентка янадан чакыртып алды, мин сызымнарны карап имза салдым, проектны төзелеш буласы урынга бәйләдем-яраклаштырдым. Ә институтны тәмамлап килгәч, хәтта соңгы бизәкләү-бизәү эшләренә автор буларак күзәтчелек итәргә дә өлгердем. Менә бөтен тарихым шул. Бәлки, мин кайчан булса да бер, «Энжекәй»не бөек төзүче Рушан Дасаев белән танышу өметеннән иҗат иттем, дип тә сөйләрмен әле,—дип, Рушанны үртәп сүзен тәмамлады Глория.

Ләкин Рушан аның шаяртуына артык игътибар да итеп тормады. Нинди сәләт, нинди зирәклек, булдыклылык икән бу кызыйда! Һәм ул Глориягә беренче күргәндәй итеп янадан бер карап алды: чибәр, көяз, нәфис, искиткеч сөйкемле, эшлеклелегенә ишарә итәрдәй бер чалымы да юк, үзенең башкалардан аерылып торуы, өстен булуы йөзендә берничек тә чагылмый. Ничек шулай булдыра ала, диген?!

Рушанның кыздан аерыласы килми, һаман аның сөйләгәннәрен тыңлыйсы килә, чөнки ул эше турында гына түгел, үзе турында да сөйли иде бит.

—«Энжекәй» синең диплом эшең булдымы?

—Юк. Мин аны Ленинградта телгә дә алып тормадым. Менә, якын көннәрдә Ташкенттан төсле фоторәсемнәр төшерүче оста фотограф килергә вәгъдә иткән иде. Ул «Энжекәй»не төрлечә төшереп биргәч, мин ул рәсемнәрне институтыма жибәрәчәкмен. Анда укып чыкканнарның эшләрен куя торган заллар бар. Ә диплом эшемне актауль түгел, кирәксез дип таптылар, көч-хәл белән генә якладым мин аны.

—Нәрсә кыландырган иден соң?—дип кызыксынды Рушан.

—Әй, анысының тарихы кыска. Сина, мөгаен, минем очышларым-ачышларымны гына түгел, егылышларым-ялгышларымны да белү кирәктер, юкса эреләнеп-тәкәбберләнеп китәрмен, йә! Тик шунысын исеңдә тот:

бу хакта минем әле беркемгә дә сөйләгәнем юк иде...

Институтта мин бераз волейбол уйнаштыргалап йөрдем, хәтта бервакыт, өченче курста укыганда, җыелма командага да эләктем. Миңа фарт килде—командабыз студент уеннарына Ташкентка барасы булды. Бу минем беренче зур сәяхәтем иде, әле үзе Урта Азиягә тагын. Билгеле, безгә Бохара белән Сәмәркандны да күрсәттеләр. Менә шул чагында мин Үзбәкстанга гашыйк булып кайттым, шуңа күрә практикага да Заркентны сорап алдым. Мондагы күп нәрсәләрнең искиткеч икәнлеген сиңа сөйләп торасы да юк инде. Рушан, көлмәм, дип сүз бир. Бирәсеңме?..

Шуннан шул... Булачак архитектор күзлегеннән караганда, Үзбәкстандагы сәяхәттә мине иң сокландырганы нәрсәләр булды соң? Гүр Әмир, Биби ханым, Сәмәркандның җәмигъ мәчете, Бохара әмиренең җәйге резиденциясе, Күкелдаш мәдрәсәсе яки Ташкенттагы Иске-Жува базарымы? Юк, боларның берсе дә түгел. Минем исем киткән әйбер... үзбәк наны, үзбәк көлчәсе булды. Әйе-әйе, гаҗәпләнмә, гап-гади көлчә. Шуннан матур әйберне гомеремдә күргәнем, шуннан тәмле ризыкны гомеремдә ашаганым булмаган икән. Үзе кайнар, үзе бераз кызарып пешкән, өстендә сипкел-сипкел кыздырылган көнҗет орлыклары, үзе ак, күпереп тора, ә исе-исе—һушларыңны алырлык! Могҗизаның нәкъ үзе инде менә! Шәрекъ базарында иң тотрыклы, иң көчле ис нәрсә исе дип уйлыйсың? Үлән-сәлән, тәмләткеч-фәләннәр яки җиләк-җимеш исләреме? Юк, белмәдең, мин сынап карадым—әнә шул нан-көлчә исләре! Теләсә кайсы базарга барып керсәм дә, кайда икәнлеген сорап тормастан, көлчә пешереп саткан урынны табачакмын мин. Исеннән.

Шулай исем-һушым китеп йөргәч, ул көлчәләрне ничек пешергәннәрен беләсем килмиме инде! Минем кызыксынуым шулкадәр ихлас булгандыр, мөгаен, мине көлчә сатучыларның берсенә кунакка чакырдылар. Шунда мин беренче тапкыр тандырны—көлчә пешерә торган мичне күрдем. Аны утка чыдам махсус кызыл балчыктан эшләнгән зур чүлмәккә охшатырга буладыр. Ул тандырны хәзер дә әле вак һөнәрчеләр генә ясый икән, үзе, күп булса, бер квадрат метр гына урынны алып тора, һәр үзбәкнең ишегалдында бар икән ул.

Әмма көлчә пешерүчедән осталык, уңганлык, житезлек-өлгерлек сорала. Хәер, һәр эштә дә кирәкле сыйфатлар инде болар. Гомумән, яхшы хезмәт, җиренә җиткереп эшләү сокландырмаска, ә галәти көндәлек эш булырга тиеш, юкса, бик ерак китә алмассыңдыр...

Нан-көлчә, тандыр, Ташкент мине диплом эшен үземчә бер кызыклы темага багышларга этәрде: «Пекарня-кибетләр» дип атадым мин аны. «Энҗекәй» белән чагыштырганда, моны эшләр өчен минем дөнья кадәр вакытым бар иде һәм мин әллә ничә вариант уйладым, үземчә иң яхшы дигәнен дә кире кактылар... Булмастай хыял гына бу, тормыш ихтыяҗларына җавап бирми, имеш. Бигрәк тә соңгы сүзләре кимсетә иде: «Совет кешесенең тормыш ихтыяҗларына җавап бирми». Ә мин французлар өчен тырышкан идемме?

Күрәсең, диплом эшен исенә төшерүе Глорияне нык дулкынландырган иде. Рушан аның әле рәнҗеше-үпкәсе һаман да үтмәгәнен, күңелендә ширпы кебек калалып торганын чамалап алды.

—... Беләсеңме, Рушан, архитектор буларак нинди йомшак ягым бар минем? Үлсәң дә, таба алмаячаксың. Ихтимал, мин бервакытта да гүзәл сәнгать әсәрләре—шедеврлар иҗат итә алмамдыр, чөнки мин ирексездән гел үз эшләремнең киң катлам халык өчен булуын телим. Моның ачык мисалы—шул ук «Энҗекәй». Миндә хезмәткә менә шундый сәеррәк социаль мөнәсәбәт тамырланыр дип һич тә уйламый идем. Мин, мәсәлән, бөтен күңелемне салып орган залы яки шуңа охшаш берәр нәрсә эшли алмас идем, юкса орган музыкасын аңлыйм да, яратам да үзем. Әти-әниләрем белән Рига култыгында, диңгез буенда ял иткәндә Домский соборда үткәрелә торган бер генә концертны да калдырмый идем... Моның бик отышлы эш буласын да беләм: орган концертларына

йөрүче халык теләсә кем түгел бит, минем эшемне лаеклы бәяләрләр, исемем телдә булыр иде. Ләкин андый заллардагы тар мохит, аерым элита рухы, сайланган зыялы катламга минем яраклашырга тиешлегем, үземне ачып салып, өлешчә булса да, иҗатчы буларак, үз зәвыгымны сендерә алмавым күнелемне кайтара. Юкса, бу минем танылган, күренекле шәхес буласы килү теләгемне һич кенә дә юкка чыгармый. Беләсеңме, «Энҗекәй»не бизәкләү-бизәү эшләре бетеп килгәндә мин кинәт кенә шуны аңлап алдым: анда ял итәргә йөрүчеләрнең берсе дә, беркайчан да: «Кем эше икән бу?»—дип сорамаячак бит. Бу ачыш мине бер дә пошаманга төшермәде, чөнки мин «Энҗекәй»гә кергән яшь кешенең күбрәк провинциал кешенең, гажәпләнгән, югалып калган һәм шул ук вакытта сокланулы шатлыклы карашы минем хезмәтем өчен бүләк булыр, ә иҗатым ана тәүге эстетик дәрес шикеллерәк тәэсир ясар дип ышана идем. Мин сиңа үземнең тормышка булган карашларымны сөйлим, нәкъ шул карашларым аркасында диплом эшем харап булды да бит. Хәер, ана әйләнеп кайтыйк әле...

Шулай итеп, Ташкентта күргән ун тиенлек нан-көлчә минем исемне күтәргән иде. Теләсә кайсы үзбәк чәйханәсендә бер чәйнек чәй—биш тиен. Әгәр дә якында чәйханә булса, Үзбәкстанда кешегә тамак ялгап алырга унбиш тиен җитә. Менә шундый уйлардан соң, кечкенә пекарня-кибетләр эшләү фикеренә килгән идем дә инде мин. Аларны мин күнелемнән студент тулай торакларында, стадионнарда, зур кинотеатрларнын фойэларында, вокзалларда, аэропортларда һәм хәтта аерым кварталларда булыр дип күрә идем. Билгеле бер сәгатьләрдә шул пекарня-кибетләр кайнар нан-көлчә, ләваш, хачапури, чурек, икмәк,—хикмәт исемендә түгел, ә җисемендә,—кыскасы, шундый ризыклар пешерәләр. Мичтән генә чыккан кайнар ризыктан авыз итүчеләргә, әлбәттә, кайнар чәе дә булсын. Һәр җирдә шулай булса, ипине сакларга, яратырга кирәк, дип акыл сатунын да хаҗәте калмас иде.

Менә шул унбиш тиен, аннары безнең галәмәт иркен-мул кылануыбыз харап итте дә инде мине, Рушан. Мине вакчылланула, халкыбызнын һаман саен үсә барган ихтыяҗларын аңламауда һәм мөмкинлекләребезнен асылын белмәүдә гаепләделәр. Диплом кабул итү комиссиясен бигрәк тә минем, соңыннан чыгып, көлчәле чәй янына атаклы Вологда маен һәм кара уылдык та өстәргә мөмкин бит, дигән искәртүем чыгырыннан чыгарды. Югыйсә болары бөтенләй башка җыр иде инде. Мин бит икмәк пешерү промышленностен юкка чыгарырга җыенмаган идем,—оппонентларым мине хәтта шулай дип тә гаепләделәр,—мин кешеләргә бәйрәмчә тәмле икмәкләр пешерү турында гына хыялланган идем, ә бәлки, минем Даша түтәйле яки Кодрәт әкәле кечкенә пекарня-кибетләрем ипи пешерүче зур завод-фабрикаларны да үз эшләренә яңача карарга өйрәтер, ипи-ипекәйгә булган караш алардан гына тормаганын, ипине саклап тотарга кирәк, дип пропаганда алып бару—акчаны җилгә очырту гына икәнен аңларлар дип уйлаган идем.

Менә шундый җиңелү ачысын татыдым мин, Рушан. Шундый фиаско... Ләкин борынгы бабаларым минем өчен кызармаслар иде, дип уйлыйм мин, сынатмадым-сынмадым, үземнен хаклыгыма бер минут та шикләнмәдем һәм хәзер дә шикләнмим. Мөгаен, әле вакыты гына җитмәгәндер, бары тик шул гына. Ә бәлки, шундый пекарня-кибетне син төзерсең, Рушан?..

Глория гадәти блоклардан салынган йортнын бер ишек төбендә тукталып калды.

—Ә без синен белән бу кварталны алты мәртәбә урап әйләндек инде,—диде.—Менә шушында яшим мин, иkенче катта. Керергә чакырмыйм, соң инде, синен күнегүләргә сонга калуынны теләмим. Уртак дусларыбыз булуы бик әйбәт. Сау бул, танышуыбызга бик шат мин, Рушан...

Һәм ул ашыгып хушлашып, ишек карангылыгына кереп югалды.

Рушан, икенче каттагы бер тәрәзәдә ут кабынып, шул ут янадан сүнгәнче китмәде, басып торды.

Ул Заркентның кешесез, йокылы урамнарыннан, бүгенге гаҗәеп кич, көтелмәгән танышу турында уйлана-уйлана, атлады да атлады. Шулай уйланып йөри торгач, үзенең янадан «Энҗекәй» кафесы янына килеп чыкканын да сизми калды.

Тоныкялтырап торган идәннәрне сүрән генә яктыртып, анда-санда гына сирәк фонарьлар яна иде. Рушанга бер мизгелгә генә, моннан берничә сәгать элек булган шикелле, музыка һәм көлү тавышлары ишетелгәндәй булды. Ул киртәләп алынган койма аша эчкә үтте һәм «Энҗекәй»не хәзер бөтенләй башка күз белән караштыра башлады.

Шунда ул, биюләр өчен калдырылган кызыл түгәрәкне алтынсу сызыклар белән каймалап алып, ниндидер экзотик чәчәкне хәтерләткән бизәкнең хәзер бераз сәеррәк, ничектер серлерәк булып күренгәнен күрүдән битәр, эчке бер сиземләү белән тоемлады. Аннары Рушан, гомуми охшашлыклары булуга карамастан, һәр дүрт түгәрәк биюләр мәйданчыгының төсләре төрлечә икәнен абайлады. Игътибар беләнрәк карый торгач, шул төрле төсләрдән ясалган дүрт сызыкка, криптограммадагыча итеп, ике хәрефле монограмманың—«Г» белән «К»ның бик оста яшерелгәнен дә аңлап, исе китте: «Глория Кароян...»

## XXXXI

Истәлекләргә бирелгән көнне Дасаев таң алдыннан гына йокыга китте һәм, ничәмә-ничә еллардан соң, беренче мәртәбә үзләренең туен төшендә күрде. Төсле слайд-рәсемнәр караган шикелле итеп, ул үзенең үткән тормышын карый башлады...

Глория Әдрән диңгезе буендагы Дубровник курортыннан, яшь архитекторларның халыкара конкурсыннан кайтып кына төшкән иде. Туй сәяхәтендәге яшь гаиләләр өчен диңгез буенда салыначак отель проекты Югославиядә Гран-при алган, Европаның конкурсны оештыручы атаклы төзелеш фирмалары, Европа архитекторлар ассоциациясе Глориягә әле тагын конкурста катнашучыларның иң гүзәле булганы өчен махсус приз да тапшырганнар иде.

Бер итальян фирмасы шунда ук проектны сатып алуга контракт төзеп, имзасын салды. Әрсезрәк итальяннар:

—Мондый гаҗәеп отель проекты иҗат итәргә сезне нәрсә, нинди уйлар этәрде?—дип сорадылар.

Глория:

—Мин үземнең туй сәяхәтемнең дә диңгез буендагы шундый отельдә тәгәлләнүен теләр идем,—дип җавап бирде.

—Исемегез ничек сезнең?—дип кинәт сорап куйды фирма вәкиле. Аның башына ниндидер уй-фикер килде булса кирәк.

—Глория.

—Глория?—дип кабатлап сорады итальян һәм кинәт куанып кычкырып җибәрде:—Глория! Отель өчен моннан да матур исем табып булмастыр, менә дигән исем! Мондый отельгә шуннан да ятышлырак нинди исем булыр тагын? Ышаныгыз, сеньорина, без Италиядә һәм Франциянең Зәңгәр диңгез яры буенда дистәләрчә шундый отельләр төзербез, проектыгызның бер сызыгын да үзгәртмәбез...

Фотоаппаратлар черт тә черт итә, итальяннар шул мизгелдә үк эшләнгән фоторәсемнәрен сузып, Глориянең култамга-автографын куюны үтенәләр.

Фирма вәкиле дә фоторәсем сузгач, Глория әйтеп куйды:

—Отель минем исемемне йөртәсе булса, мин сезгә бик рәхмәтлемен, әмма аның кайсы төшендә булса да минем монограммамны күрсәтергә булмасмы икән?—Ул шунда ук фоторәсемнең артына «Энҗекәй»дә яшертеп

ясалган монограммаларының берсен фломастер белән язып та бирде.

Эшлекле фирма вәкиле шунда сорады:

—Бәлки, сеньорина отель мангаена куелачак язулы такта үрнәген дә күрсәтеп бирер?—диде.

Кемдер кызга, альбом һәм фломастер сузды.

Глория, уйлап та тормыйча, гадәти булмаган латин хәрефләре белән исемен язып та куйды. Исеменең сул ягына монограммасын өстәде.

—Ә төсе?—дип түземсезләнеп сорады фирма вәкиле. Алар арасында һөнәри сөйләшү бара иде.

—Куе кызылга алтын хәрефләр белән, ә монограмма—ак белән карадан. Ул яхшылык һәм явызлык символы булыр, хәрефләрнең кайсысын сайласагыз да ярый.

Бу гамәл шулкадәр тиз, бер минут эчендә башкарылды ки, хисчән итальян гаҗәпләнүеннән хәтта сызгырып куйды...

Шул төндә үк Рушанның кунакханәсенә халыкара телеграмма китерделәр, мөгаен, Заркентка бик үк еш килмидер андый телеграммалар. Глория дүрт кенә сүз язган иде: «Рушан, сөеклем, мин җиңдем!»

Өч ел таныш булып йөреп, аның әле бер тапкыр да Рушанга болай эндәшкәне юк иде.

Рушан Глорияне Ташкент аэропортында каршы алды, кызның мондый бәхетле чагын аның бүтән бервакытта да күргәне булмады. Глориянең унышын «Энҗекәй»дә билгеләп үттеләр. Кафедан чыгып, төнге урамнарда йөргәндә Рушан моңарчы әйтергә базмаган сүзләрен ярды да салды:

—Глория, чык миңа кияүгә!—диде.

Кыз өчен бу көтелмәгән тәкъдим булды шикелле, кайчандыр «Энҗекәй»дә Габдрахман Кадыйровны биергә чакыргандагыдай, бер мәлгә югалып калды. Әллә Рушанның тәкъдимен үлчәп-исәпләп, әллә, гадәтенчә, хыялларына бирелеп, озак җавап бирми торды.

—Рушан, сөйкемлем,—диде ул аннары, кинәт кенә моңсуланып, аның күзләрендә яшьләр күренде. Рушан искәртеп куйды: кыз «сөеклем» димәде. Глория дәвам итте:—Мин кирәкме икән сиңа? Йә, кара әле миңа яхшылабрак, нинди хатын, нинди хуҗабикә чыксын инде миннән? Дуамал, холыксыз, архитектурасы белән җенләнгән бер кеше бит мин. Син бит минем белән җәфаланып бетәчәксең, бөтен йөрәгем белән сине дә, үземне дә бәхетле итәргә теләсәм дә, мин моны булдыра алмаячакмын. Безнең гаиләнең бәхетле булырына мин бик-бик тә шикләнәм. Ләкин, ни генә сөйләсәм дә хәзер, мин бәхетле, әле миңа моңа кадәр беркемнең дә тәкъдим ясаганы юк иде... Башкалар синнән акыллырактыр шул...

Аның аптырап-югалып калуы тиз үтте, ул янадан бик тиз генә ирония күләгәсе артына яшеренде.

Рушан моны тоеп, үз сүзен әйтте:

—Син миңа җавап бирмәдең,—диде.

—Әй, булса булмаса!—дип яраткан сүзләрен кабатлады Глория, ул шунда ук үзгәреп, күнелләләнеп китте.—Инде син үз һәлакәтеңә үзең атлыйсың икән, менә минем шартым: әгәр бер атнадан, шимбә көнгә кире уйламасаң, тәкъдимеңне кабатласаң—мин сиңа кияүгә чыгарга риза. Мин сиңа котылу мөмкинлеген калдырырга тиештер бит инде, Рушан...—шулай дип, ул кинәт кенә егетне үбеп алды да торып йөгерде.

Рушан аны куып җитәргә тырышмады, аның үз уйлары белән ялгыз каласы килә иде.

Атна авыр булды: градирняны—кайнар суны суыта торган яки тозлы суны парга әйләндерә торган корылманы тапшыралар, шуңа күрә өч смена эшләргә туры килә иде. Шимбәсе дә җинелгә килмәде. Глория кайтып төшкәннән соң алар әле кабат бер дә очрашмаган иделәр.

Шимбә көнне, идарә башлыгындагы кинәшмәнең озаккарак сузыласын чамалап, Рушан Джумберга шылтыратып алды. Капитанга ул

үзенең уй-ниятләрен әйтеп тормады, бары тик «Энжекәй»дә бәйрәмчәрәк әзерләнгән өстәл алып куярга һәм анда кемнәрне чакырырга кирәклеген генә исемләп әйтеп чыкты, кунаклар арасыннан Глория исеменә дә басым ясамады. Джумбер артык төпченмәде: «Грузинчамы?»—дип кенә сорады. Алар телендә ул, базардан үлән-сәлән, брынза, җиләк-җимеш, яшелчә ишесен дә алып, бай өстәл әзерләү, дигән сүз иде.

Рушан:

—Грузинча,—дип раслады.

Рушан «Энжекәй»гә бераз соңлап барды, әмма кинәшмә аркасында түгел, ә чәчәкләр алып йөрүе аркасында: кечке базарда ак розалар табылмады, чәчәк үстерүчеләрнең өенә барырга туры килде, чәчәкләрне аңа куагыннан кисеп алып кына бирделәр—ак розалар озын сабаклы, төнгә ябылган тыгыз-нәфис, зур төймәлеләр булды, нәкъ шундыйларны Глориягә еш бүләк итә иде Рушан.

Ул кафега килеп кергәндә, кичә башланган иде инде. Аларның утырырга гадәтләнгән секторында зур банкет өстәленә ап-ак эскәтер җәелгән, гадәттә «Энжекәй»дә кабул ителгән нәрсә түгел иде монысы, дуслары барысы да җыелып өлгергән һәм күңел ача башлаган икән. Өстәлгә күз төшереп алгач ук, Рушан Джумберга карап, рәхмәт хисләрен сүзсез генә аңлатырга теләгәндәй, киң итеп елмаеп куйды.

Алар үзләренең кечкенә генә шатлык-уңышларын да шушылай билгеләп үтәләр, бу утыру да беркемне дә гаҗәпләндермәде, бүген бары өстәл баерак һәм бәйрәмчәрәк иде.

Глория Джумберт белән янәшә утыра, аның кояш алмый торган искиткеч ак тәне белән Белградтан алып кайткан бик матур ак күлмәге генә йөзенең башкалар күзенә чалынмаган борчулы-дулкынланулы аклыгын яшереп тора иде. Рушан моны шунда ук күреп алды. Глория янына килеп, аңа чәчәкләрен сузды. Чәчәкләрне кабул итеп алганда, кыз, башкаларга сиздерми генә, рәхмәт хисе белән аның кулын кысты һәм шау-шу арасында: «Рәхмәт, сөеклем»,—дип пышылдады.

Менә ич! Тагын «сөеклем» сүзе чыкты Глория авызыннан. Рушан эченнән генә куанып куйды: «Ярата ул мине... ярата...»

—Тагын бер уңышлы проектмы әллә, Глория?—дип сорады аларны күзәтеп утырган Тамаз.

—Син үзең тупларны шулай еш кертә алсаң икән,—дип, аңа җавапны Джумбер бирде, кунаклар көлешеп алдылар.

—Беләсем килә, нинди унай белән болай матур утырабыз әле? Рушан, идарә башлыгы булдыңмы әллә? Яки безне Заркентта югары хезмәт хакы алучы рекордчы Силкиннар бригадасына яздыра алдыңмы?—дип сорады Джумбер, үзенең бүген ни сәбәпле шулкадәр тырышканын аңларга теләп.

—Картаясың, капитан, син: «Иң мөһиме—түземлелек, сабыр булу. Капкага таба тиктомалдан туп тибүне юләр дә булдыра ала, кайчан һәм кайда тибәргә кирәклеген оста уенчы гына белә»,—дип әйтә идең түгелме соң? Син миңа кирәк чагында гына тибәргә бирмәдең бит инде болай булгач. Хәер, минем үземнән дә әйтәсе сүземне тизрәк әйтәсем килә...

Шул сүзләрдән соң Рушан торып басты, өстәл өстеннән күз йөгертеп алды да сүзен җитди генә дәвам иттерде:

—Дусларым, мин Глориягә тәкъдим ясадым, бүген без сезнең белән туй көнен кайчангарак билгеләргә икәнен киңәшмәкче идек,—диде.

Кунаклар шау-гөр килеп шаулаша башладылар. Хәтта оркестр да бер мизгелгә тынып торырга мәҗбүр булды. Роберт, әйтерсең лә, футбол кырындагы шикелле, яшен тизлеге белән өстәл яныннан атылды, кемдер: «Шампан шәрабе!» дип кычкырган арада ул инде шампан шешәсен күтәреп килеп тә җиткән иде, килә-килешли, әле оркестрга да нәрсәдер пышылдап өлгерде, оркестр, уйный торган көен бүлеп, туш уйнап җибәрде. Өстәлдән-өстәлгә хәбәр тәгәрәде: «Рушан өйләнә... Глория кияүгә чыга...»

Глория өстәлнең Рушанга каршы ягында, Тамаз янында утыра иде,

гашыйкларны янәшә утыртырга теләгәч, Тамаз киреләнергә тотынды:

—Бүген, үтерсәләр дә, сине янымнан беркая да җибәрмим. Без Рушан ханны беләбез, ул янадан һичкайчан да гүзәл кыз белән утырырга бирмәячәк. Ичмасам, ул безгә йә йолым, йә калым түләсен, аны бит күренекле архитектор белән без таныштырдык. Глория, шулаймы, әйт әле?

Глория җавапка кесәгә кереп тормады:

—Шунын өчен дә Рушан белән без сезне—Джумбер белән икегезне ЗАГСта шаһитлар, ә туйда кияү егетләре булырсыз дип хәл итеп куйган идек,—диде.

—Алай булса, бирелəм,—диде Тамаз. Дуслар урыннарын алыштырып утырдылар.

Таныш та, таныш булмаган кешеләр дә килеп, Рушан белән Глорияне котлый башладылар, туйлары кайчан буласын сораштырдылар. Тамаз ул сорауларга җавапны үзе биреп утырды:

—Кичке газетларны караштырып барыгыз, экстрен чыгарылыш булырга мөмкин...

Котлаулар бетеп, өстәл тирәсендә чагыштырмача тынлык урнашкач, Джумбер Рушаннан сорады:

—Шулай да, туегыз кайчан?

Рушан, анык кына әйтә алмыйча, җилкәсен генә сикертеп куйды.

Шулчак мыштым Роберт мәҗлесләрнең алыштыргысыз, гомерлек тамадасы булган Джумбердан сүз бирүен сорады. Рөхсәт алгач:

—Минемчә, туй киләсе шимбәдә булса—нәкъ өстенә генә басачак,—дип сөйләп китте ул.—Анлатам: беренчедән, сузып-нитеп йөртерлек сәбәп юк, икенчедән, чәршәмбедә безнең уеныбыз бар, беренче әйләнештәге соңгы уен, аннары—ике атналык тәнәфес-ял. Димәк, без, Рушан, синең күпчелек дусларын, тренердан һәм җәмәгатьчелектән шикләнмичә генә, иркенләп туегызда күнел ача алабыз. Мин, бүген шушында утыручыларның һәммәсен кертеп, туй штабы сайларга тәкъдим итәм, ә үземне штаб башлыгы итеп билгелим—гомеремдә бер булса да, түрә булып карыйм әле! Көзен мин сенелемне кияүгә бирдем, тәҗрибәм бар. Джумбер, Тамаз, раслагыз сүзләремне... Рушан, Глория, безнең арадан сез беренче өйләнешүчеләр, сезнең туегыз калганнарыбызның һәркайсына өлешчә үз туена репетиция булыр. Туйны кайда үткәрү турында, ышанам, ике төрле фикер булмастыр—шушында, кәләшнең баласы «Энҗекәй»дә...

—Усал телләр, Глория «Энҗекәй»не үзе өчен махсус төзеткән икән, диячәкләр,—дип бүлдерде аны Тамаз.

Әмма Глория, гадәтенчә, анын авызын бик тиз япты:

—Юк, Тамаз, «Энҗекәй»не мин бары тик Рушан белән шушында танышыр өчен генә иҗат иткән идем,—диде.

—Бүлдермәгез әле,—диде Роберт.—Болай да тирләп чыктым. Кияү белән киленгә бер үтенеч: туйга чакырыласы кунакларның исемлеген сишәмбе көнне штабка тапшырасыз. Йомгаклап, игълан итәм: туй штабының киләсе утырышы чәршәмбедә, уеннан соң шушында булыр. Ул вакытка күп нәрсәләр ачыкланыр...

—Роберт, кадерлем, минем дә сина бер үтенечем бар: миннән алда өйләнә күрмә, яме. Минем туемда да синең начальник булуыңны телим,—дип, Тамаз дустын кочып алды.

... Туйдан соң ике көн үткәч, барысы да Глориянең өендә янадан җыелдылар, Рушан кунакханәдән шунда күченгән иде инде. Музыка тынладылар, туйдагы күңелле, кызык-мәзәк хәлләрне искә төшереп утырдылар. Глория, үзен урамда таныш-белешләре котлаганда яки, берәр атаклы кешегә карагандай итеп, артыннан кемдер карап калганда унайсызлануын әйтте. Шунда Джумбер тәкъдим кертте:

—Сезгә туй сәяхәтенә чыгып китәргә кирәкмиме икән? Берочтан мондагы эсседән дә, игътибар итеп йөдәтүчеләрдән дә котылырсыз,—диде.

—Мин уйлыйм,—дип сүз кыстырды Тамаз,—итальяннар отель төзеп өлгермәгәннәрдер әле. Глория бит кайтуга ук Рушанны бәхетле итәчәген әйтеп, аларны искәртеп куймагандыр.

Джумбер елмайды:

—Синнән аермалы буларак, Тамаз, мин акыллы кинәшләр генә бирәм, шуна күрә мин алтынчы разрядлы балта остасы-штукатур, ә синеке бишенче разряд кына. Дөресме, Рушан? Димәк, болай... Безнең алдагы уеннарга кадәр ике атналык ялыбыз бар, мин Гаграга, дингез буена барып кайтырга җыенган идем. Анда мина туган тиешле абзый яши, ике катлы йорты яр буенда ук. Әгәр шунда бергә китсәк, ничек булыр? Мин үз көннәремне бетергәч, кайтып китәрмен, ә сез теләгәнчә яки ялыгыз беткәнче кала аласыз...

Шул рәвешле, яшь кияү белән кәләш дингез буена барып чыктылар, шунда ике еллык ялларын үткәрделәр, аларның бергә торган чакларының иң бәхетле көннәре булды ул.

Студентлык елларында каникулларын Гаграда үткәргән Джумбер шәһәрне яхшы белүе өстенә, тирә-яктагы барлык кечкенә шәһәрчек-курортларны да белә, өчесе бергә чакта Гаградагы бөтен дуслары белән дә таныштырып өлгерде, күп җирләр дә күрсәтте.

Рушан белән Глория үзләре өчен Пицунданы очраклы гына ачтылар, Джумбер китеп баргач кына. Ул елларда Гагра янәшәсендәге Пицунда борынында зур төзелеш эшләре башланып кына килә, хәзер бар дөньяга билгеле курорт нигез ташларыннан калка гына иде әле.

Глория булачак төзелешнең колачын шунда ук аңлап алды. Дөрес, әле проектта гына булган уналты катлы биналар аны артык шатландырмады—бик гадәти һәм бик бертөрле, аның карашынча, күз тукталыр нәрсә юк. Аның каравы, урынын бик белеп, матур сайлаганнар, дип тапты.

Ял итү зонасын тулаем дингез җилләре үтәли өрдереп тора, борынгы нарат урманы йортларга ук килеп терәләчәк. Аллеялар-сукмаклар, юл чатларындагы, мәйданнардагы сыннар, җәйге ресторан-кафелар сокландырды Глорияне. Әлбәттә, болар барысы да кәгазьдә һәм макетларда гына иде әле.

Ул Тбилисидан килгән архитекторлар белән бик тиз уртак тел тапты, еш кына кичләрен бергәләп Гаграда үткәрә башладылар. Ачык төсләрдәге ялтыравык йөгертелгән глазурьлы, гадәти булмаган гипсокерамик әкияти аждаһалар, сигезаяклар, сугышчан кыяфәтле әтәчләр, горур оҗмах кошлары, йокылы ябалаклар, тылсымлы тирмәләр, тау куышлары, саклялар корылып ята иде инде—Гаградан Пицундага кадәр булган арадагы автобус тукталышларына куелган бу эшләр ул вакытта ук танылган Зураб Каргаретилиныкы иде.

Кайвакыт кичләрен алар шул оста белән генә үткәрәләр, беренче танышкан көннәреннән үк Глория аның белән дуслашып өлгерде, алар ешрак калганнар бик аңлап та бетерми торган архитектура телендә сөйләшәләр иде.

Соңыннан грузин архитекторлары белән кәеф-сафа корып утырулары Рушанның төшенә дә кереп йөдәтте, тегеләр ни өчендер кинәт кенә: «Ачы! Ачы!»—дип кычкыралар, имеш тә, Рушан белән Глория, «Энҗекәй»дәге туйдагыча итеп, үбешәләр, имеш...

Кайбер кичләрдә, мәҗлеснең иң кызган чагында, Зурабның башына нindидер уй-фикер килә, ул кабынып китә, аны инде бернинди көч белән дә тыеп калып булмый, иртәнгә чаклы калдыру турында сүз дә юк. Шунда ук машинасы табыла тагын һәм ул төн уртасында Пицундага чыгып чаба, күңелендә кузгалган иҗади фикерен урынга барып тикшереп карау ихтыяҗы шулай йөртә аны.

—Шаукымлы ул,—ди Глория Рушанга Каргаретели турында һәм, әлбәттә, архитектор шундый гына булырга тиеш дип уйлый иде.

Алар Заркентка Тбилиси аша кайттылар. Икесенең дә Грузиядә

беренче тапкыр булулары иде, киткәндә йөрәкләрендә бу искиткеч гүзәл якка, аның кешеләренә карата чиксез мәхәббәт хисләре алып китteләр. Бик күп вакытлардан соң да, тормышта ваемсыз битарафлык белән очрашканда, Глория һәрвакыт:

—Грузиядә мондый хәл булмас иде,—дип кабатларга ярата иде, чөнки, аның карашынча, ваемсыз-битараф грузин—сирәктән дә сирәгрәк күренеш, табигатьнең гайре табигый аномалиясе... Моның шулай икәнлегенә Глориянең иманы камил иде.

## XXXXII

Өйләнешкәннән соң өч ел дәвамында Глория, «Градострой»дагы төп эшеннән тыш, Заркент өчен Яшьләр йортының аерым проектын әзерләү белән мәшгуль булды.

Бу эш ана бик авыр бирелде, вариант арты вариант яраксызга чыгарыла, аларның һәрберсе көчне суыра һәм дөнья кадәр вакытны ала иде. Каргаретелига һәм аның дус архитекторларына эшләрен күрсәтергә дип, ул ике мәртәбә Тбилисига очып барып та кайтты. Канатланып кайта, грузин коллегаларының киңәшләрен, рекомендацияләрен язып тутырган блокнотлары була. «Аллага шөкер, таптым, ахрысы!»—дип куана ул. Әмма эшләнеп беткән эше бер атнадан янадан яраксызга чыгарыла, киңәш-унашлар соңлап әйтелгән, беркатлы-наив булып күренә, блокнотлар да чүп чиләгенә ыргытыла.

Архитектураны шигърият белән, җыр белән тиңлиләр, ләкин ул әдәбият түгел, аны миллионнар күз алдында даими тәнкыйтьләп, тикшереп торып та булмыйдыр. Әһәмияткә ия әдәби әсәрләр кешеләрнең игътибарын бик тиз яулап ала, кайнар бәхәсләргә, фикер алышуларга сәбәпче була. Архитекторлар арасында да үз эшләре хакында шундый ук кайнар бәхәсләр булып тора, ләкин шунысын да әйтергә кирәк—ул бәхәсләр ябык ишекләр артында, тар мохиттә, тар даирәләр тарафыннан гына үткәрелә, кызганыч ки, архитекторларның иҗаты бик азларга гына билгеле булып кала.

Глория шуны аңлап алды: Заркент ана үзен күрсәтергә мөмкинлек бирә-бирүен, әмма иҗатчыга кирәкле мохиттән аера икән бит. Илнең танылган архитектура үзәкләрендә ниндидер бик житди үзгәрешләр бара—ул моны, көтмәгәндә киң билгеле булып, шул рәвешле үрнәк-өлге итеп алырлык яна проектлар белән соңлап танышкач кына белде. Таулардагы коеп яуган язгы яңгыр ташкыны шикелле, бик тиз көч-куәт ала барган бу яна архитектура алымнары Глория өчен искәрмәстән, капылт килеп чыккан хәл булды. Ул, үрсәләнеп-үртәлеп, бер үк сүзләрне кабатлый башлады:

—Талантсыз... төссез-йөзсез... стандарт тартмалар...

Эшеннән ул, Рушан кебек үк, сонарып кайта, еш кына тавышы карлыгып беткән була—архитекторлар югарыдан көчләп тагылган «кыйммәтле күрсәтмәләрне» алай тиз генә «ләббәйкәләп» күтәреп алырга тормыйлар, хәл кадәри тартыша-сугыша иделәр.

—Рушан, бәгырем,—дип кайнарлана Глория.—Яңа кварталларда төзеләчәк торак йортларның түшәмнәрен ике метр ярым гына калдыруны таләп итәләр бит, шундый проектны мин ничек итеп раслый алыйм, ди? Заркентта болай да суларга һава житми. Җәйләрен эсселек хәттин аша, кырык градуска кадәр менеп китә бит. Ә ванна белән санузелны бер кечкенә почмакка сыйдырырга тырышу,—Урта Азиядә күп балалы зур гаиләләрдә ванна бүлмәсе әле кер юу урыны да булганлыгын искә-исәпкә алмау—бу бит тулы мәгънәсезлек, абсурд!

Глория, ашавын да онытып, тагын ярсый башлый:

—Ә сез, төзүчеләр, нәрсә әйтерсез? Архитекторлар акылдан язган, диярсезме? Чынлап та, үз акылыбыздамы соң без? Үз акылыбызда, әмма

файдасыз—ул проектка мин кул куймасам, икенче берәү рәхәтләнеп имза сала.

Глориянен язмышын бик нык үзгәрткән «архитектура артыклыклары» дигән гыйбарәне Рушан шул вакытларда хәтеренә сендереп калды да инде.

Үзбәкстанда берничә ел яшәп, Глория Урта Азия өчен эшләгәндә мәжбүри булган үз принципларын, үз карашларын булдырган һәм үз ачышларын Рушан белән кайта-кайта уртаклашкан иде. Ул үз корылмаларының берсен дә яшеллексез күз алдына китерә алмый, юк, һәр проектка көчләп кертелгән шөкәтсез клумбалар һәм «Зеленстрой»нын агач-фәләннәренә яраклашмый ул, аларга йөз тотмый, вакытлар узгач та, үз корылмаларын Азиядәге иң җимергеч көчләрдән—ком-тузаннан һәм өтә торган эсселектән саклап калырлык, тирә-юньдә кирәкле микроклимат—житәрлек дым, саф һава, салкынча рәхәтлек бирерлек бакча-парк архитектурасы булдыру турында хыяллана.

Үз иҗат җимешләрен Глория сусыз да күз алдына китерә алмый—фонтаннар, арыклар, каналлар, балалар чупырдарлык күл-буалар, эчә торган сулы фонтанчыклар булырга тиеш. Дөрес, ул бу очракта суны борын-борыннан изге санаган һәм архитектура элементы итеп таныган традицион шәрекъ төзелешләренә таяна иде. Бу мәсьәләләрне үзе өчен гомерлеккә һәм бергәйле хәл итү максатыннан,—ә Үзбәкстанда ул гомере буе яшәргә һәм эшләргә җыена иде,—Глория архивларда казына, Хива, Сәмәрканд, Бохараларны гына түгел, Китаб, Кокандише бик үк билгеле булмаган шәһәрләрне дә йөреп чыкты, аксакаллар белән сөйләштекиңәште, аларга күрсәтә-күрсәтә, хәзерге бассейннарга охшаш, әмма үзенчәлекле-оригиналь хаузларнын эскиз-рәсемнәрен ясады—ул хаузлар мәчет һәм сарайларның эчке ишегалларын бизәп торырга тиешләр иде.

Глория уйлаган фонтаннары һәм хаузлары булган ял итү бакча-паркларында күпсанлы унайлы урыннар булыр: эсседән әлсерәгән кеше дә, кызыксынып кына йөрүчесе дә һәм, әлбәттә, гашыйклар да—һәркайсы үзенә кирәкле почмакны табар. Утыргычлар, айваннар, чәйханәләр, ачык һавадагы лавка-кибетләр—бер кешелек, ике кешелек, берничә кешелек һәм зур төркемнәр өчен дә булыр алар... Глория аларны бетмәс-төкәнмәс хыялы, кыюлыгы белән дәртләнеп иҗат итә, алар формалары, материаллары белән генә түгел, оста урнаштырылулары белән дә сокландыралар, исне китәрәләр иде. Аның иҗат җимешләре җир астыннан, гөмбәләр шикелле, нәкъ менә шушы урында гына, табигый рәвештә үсеп чыгалар иде бугай.

Шәрекъ кешеләренең фонтаннарга мәхәббәтен белгән Глория чәчрәгән су тамчылары килеп житмәслек ераклыкта, фонтаннар тирәсендә кисәкләргә бүлгәләнгән таш божра утыргыч-эскәмияләр уйлап тапты. Берәүгә дә комачауламыйча, шул утыргычларда су янында түгәрәкләнеп ял итеп утырырга мөмкин булачак. Әмма барыннан да бигрәк аның гашыйклар өчен тәгаенләгән чатырлары һушны алырлык иде. Челтәрсыман җиңел, язларын йөзем куаклары, үрмә гөлләр белән чорналып-үрелеп яшеллеккә күмелгән, тирәсендә алсу-кызыл, ак-сары роза чәчәкләре янып утырган бу чатырлар, әйтерсең лә, шәрекъ әкиятләреннән җиргә ингән иде. Андый чатырларны Глория ун вариантта эшләде, аларның һәркайсысы җир өстеннән күтәрелебрәк тора—берләре биегрәк, икенчеләре тәбәнәгрәк. Чатыр-беседкага борма-борма җиңел челтәр баскычтан күтәрел дә, шәһәрнең биналарын, мәйданнарын, фонтанлы бакчаларын хозур кылып, чөкердәшеп утыр. Бирелә гашыйкларга беркем дә комачаулык итмәс.

Глория иллә бакча-парклар культурасы буенча белемле архитекторларның булмавына уфтана, үзенә, кайчан да булса, чын-чынлап нинди дә булса берәр бина тирәсендә скверлар, бакча-парклар ясарга житди, зур эш бирсәләр, ни кызганыч, кая барырга, кем белән киңәшергә, кемнәрне бергәләп эшләргә чакырырга икәнен дә белмәве өчен борчыла. Җае туры килгәндә хыялланып та куя: әле шәһәр күтәрелгән арада

кайдадыр бер читтәрәк буш урында шәһәр яны бакчасы ясыйсы иде, ул тыныч кына үсеп житкәндә, шәһәр үзе дә барыбер ана килеп терәлер иде. Кирәге чыгарына ышанып, үзе өчен генә булса да, бакча-парк серләрен дә өйрәнә иде ул. Еш кына Ташкентка бара, андагы ботаник бакчада, Шредер институтында була, Урта Азиядә үсә торган агач-куакларның, чәчәк-гөлләрнең үзенчәлекләрен өйрәнә—үзе төзеткән бина тирәсендә нинди үсемлекләрнең ничә елдан соң күрер күзгә күркәм булып үсеп житәселәрен, йөзенә кызыллык китермәслекләрен ачыклый иде.

Ләкин Глория зур әһәмият биргән агачлар да, су да төп максатка—бинаның үзенә интерьер хезмәтен үтәргә тиешләр. Яшьлегенә, эшләрендә чагылып-чагылып киткәләгән хатын-кызларча романтик хисләренә карамастан, анарда ир-атларча аек акыл, һәр нәрсәне дөрес исәпли белү тойгысы да бар—болары, мөгаен, борынгы бабаларыннан ук килгән сыйфатлардыр.

Бервакыт Гаграда жыелышып утырганда Зураб Каргаретели болай дип әйткән иде:

—Авторы билгесез теләсә нинди проектка бер күз төшерү белән мин аның кемнеке—ир-атныкымы, хатын-кызныкымы икәнлеген ялгышмыйча әйтеп бирә алам...

Зурабның архитектор дуслары шунда көлешеп куйдылар, андый сиземләү тойгысының бер анарда гына булмаганлыгын әйттеләр.

Ә Глория, нинди дә булса эшләрен архитектура буенча берәр конкурска жибәрсә, аңа гел ир-атка мөрәҗәгать иткәндәй итеп хат язалар иде. Конкурс жюриендә дә, мөгаен, ир-ат эшен хатын-кыз эшеннән аерлыксыз аера алуларына шикләнмәгән кешеләр утырадыр югыйсә...

Глориядә ирләргә хас сыйфатларны Рушан беренче танышкан кичләрендә үк, «Энжекәй» турында мавыгып сөйләгәндә үк тотып алган иде. Соныннан да моның шулай икәнлегенә кабат-кабат инанды ул. Ә инде өйләнешкәч, Рушан хатыны мәнфәгатьләре белән яши һәм архитектураны кайбер дипломлы белгечләрдән дә артыграк белә, анлый башлады—Глориядә педагоглык сәләте дә бар: ул акыллы, ни-нәрсәнен асылын, төп фикерен кыска гына итеп ачып бирә иде. Менә шунда Рушан аңлап алды: хатынының проектларында бер генә талантлы ир-ат та булдыра алмаган сыйфатлар һәрвакыт булачак—анын кабатланмас хатын-кыз нәфислеге, ягымлылыгы-сөйкемлелеге, искиткеч зәвыгы гел генә чагылып торачак иде. Юккамыни ул ирен, гаиләсен, йортын-кыскасы, бар дөньясын онытып, жаны-тәне белән эшкә бирелә? Анардагы рациональлек, жаваплылык тойгысы, астыртын исәп-хисапның булмавы, бер минутлык файда артыннан куа белмәве Глориягә үзенең төп эш принципларын, төп карашларын чарларга ярдәм итте дә инде һәм ул аларга хыянәт итмәскә тырышачак.

Урта Азиядә аерым проектлар белән төзелә торган биналар, шәһәрнең йөзен билгеләүче корылмалар өчен кояш һәм ком-тузан тәэсиренә бирешми торган төзү материаллары кирәклеген Глория тиз аңлады. Биредә бары тик югары сыйфатлы аксыл-сары кирпеч, шомартылган-ялтыратылган таш, металлардан—юка кызыл бакыр, цинк, кургаш, алюмин калайлар һәм шуларның эретелгән катнашмасы гына яраклы. Әле санап кителгән материалларны мөстәкыйль, аерым-аерым да кулланырга була, әмма Глория аларның барлык төрләрен дә аралаштырып эшләүне отышлырак саный иде. Эшләгәндә ул жирдән аерылып, жиде кат күкләргә ашып йөрми, көндез чыра яндырып эзләсән дә табып булмастай нәрсәләрне проектларына кертми, әле әйтелгәннәрнең, сыйфатлы кирпечтән кала, һәммәсе дә Урта Азиянең үзендә житәрлек. Ә илебез архитектурасына әлегә хас булмаган төсле металлны Глория киләчәктә киң кулланылышта булачак дип саный, бу металл Заркентның үзендә житештерелгәнлектән, нинди генә кытлыкта да шәһәр үз сарайлары өчен резерв чыганаклар табачак, дип ышана иде.

Кайвакыт, кәефсез чакларында Глория, пошынып, үзенен архитектурада бер ун елга сонга калганлыгы турында сөйләнә. Яшьләр йортын проектлаштырган чакта ул, әлбәттә, хәзер блоклы төзелеш, бетон, яна тышлавыч материаллар, пыяла заманы, серияләп-калыплап төзү, йортлар салу комбинатлары чоры икәнен белә иде. Белгәнгә күрә, еш кына кулына карандаш алып яза-сыза, беренче карашка арзанлы күренгән төзү материалларынын бары тик бүген генә файда биргәннәрен, ә иртәгә аларга ремонт өчен генә дә әллә никадәр артык чыгымнар китәчәген исбатларга тырыша иде. «Саран ике тапкыр түли»,—бу әйтем нәкъ менә архитектурага кагыла дип исәпли иде Глория.

Пыяла турында ул үзенең бер мәкаләсендә турыдан-туры ачык итеп язды: кайнар кояшлы Урта Азия өчен ул яраксыз, диде. Аннары, башка климат шартларында беренче куанычлар тиз үтәчәк, биналарны жылыту мәсьәләсе бөтен кискенлеге белән килеп басачак, ә пыяла биналарны жылыту—шул ук урамны жылыту белән бер. Анын фикеренчә, пыяла аквариумда эшләргә дучар ителгән кеше гап-гади психологик көчләүгә тап була—ул барлык күзләр өчен дә ачык, шәрә калган кеше шикелле була...

Мәкаләсе басылып чыккач, Глория өчен күнелсезлекләр башланды: Архитекторлар союзы аны шәһәр төзелешенен хәзерге заман куйган бурычларын анламауда һәм архитектуранын киләчәге булган яна материалларнын мөмкинлекләрен бәяләп бетермәүдә гаепләде. Глория жавапка бер генә жөмлә язды: «Барлык заманнарда да архитектор алдында бер генә бурыч торган һәм торачак: матур, сыйфатлы һәм озын гомерле итеп төзү бурычы.» Ләкин Рушан, бу хатны почтага илтеп салырга алынса да, жибәрми калды, чөнки белә иде инде: яшьләрнен дорфалыгын беркайчан да гафу итмиләр.

Инде менә хәзер, еллар үткәч, хатынынын Урта Азия архитектурасына булган үз карашларын яклап көрәшкән чакларын искә алып утырганда, Рушан анын никадәр хаклы булганлыгын анлый, хәер, ул вакытта да хатынынын фикерләре дөреслегенә һич кенә дә шикләнми иде ул.

Рушан жир тетрәгәннән сон Ташкентта төзелгән күп кенә биналарнын нинди дер бер ун ел эчендә бетоны, тышлау материаллары кояшта янып купканын, жимерелә барганын, картаеп-тузып килгәнен күреп яши—аларга хәзер бернәрсә белән дә ярдәм итеп булмый инде. Ә үз вакытында кызыктыргыч арзанлы материаллар белән тышланган күп кенә биек-биек биналарнын бүген тышлавыч плиткалары кубып-убырылып төшә тора. Хәзер ул галәмәт биеклектәге бер плитканы алыштыру да йөзләрчә сумга баса һәм асылда ул хәл ителмәслек мәсьәлә: чираттагы плитканын кубып төшкәнен көтеп, бөтен бинаны төзелеш басмалары белән уратып тотып булмый ич!

Глория Заркентнын Яшьләр йортын эшләргә өйләнешкәч, туйдан сон ук алынган иде. Хатыны ул проект белән чиләнгән өч ел гомер эчендә аларнын өендә дуслары белән очрашулар бер генә мәртәбә дә шул проект турында сөйләшүләрсез тәмамланмый иде.

Яшьләр йортына Глория ташнын кырлы-кырлысын да, шомартылганын да «салды», аннары югары сыйфатлы кирпеч, Заркенттагы барлык металларны да, бигрәк тә кызыл бакырны күпләп өстәде—ул: бакырны Шәрекъ мәгъдәне, дип саный иде. Бу чорда ул инде Үзбәкстанны аркылыга-буйга йөреп чыккан һәм беркайда да диярлек жәйләрен кешеләр янып-пешеп утырмаслык, заманча биналарны күрмәгәнлеген сөйли иде. Ул заманнарда хәзер һәр рәсми оешма яки учреждение тәрәзәләренә элenгән кондиционерларнын исе-исеме дә юк иде әле. Андый биналарга ничек итеп салкынча-саф һава бирү мәсьәләсе Глорияне барыннан да битәр борчый. Ул, ачынып, болай дип шаярта: «Хәзер, мәсәлән, концерт залларын кабул иткәндә, комиссия идәннәргә, түшәмнәргә, баскычларга—кыскасы, һәр вак-төяккә игътибар итә, ә ин әһәмиятле, ин кирәклесе—

ишетелеш-янгыраш ягы, акустикасы «онытылып» кала. Шуңа күрә дә «янгыравык тавышлы» заллар ил буена бармак белән генә санарлык, жырчылардан сорагыз әнә»,—ди иде. Глория Рушанның игътибарын тагын бер нәрсәгә юнәлтте: хәзерге архитектурада тулы бер элемент—түбә юкка чыгып бара икән. Хәзер инде яшелгә буялган калай түбәләрне гомерлеккә югалта барабыз бугай...

Төзелештә «онытылып» калган түбә Глорияне тагын бер фикергә этәрде. Баштарак ул кояш нурларын көзгедәй кире кайтарып тора торган, хромланган гап-гади цинк калай түбә ясарга уйлаган иде. Әмма Яшьләр йортын ул романтик бер бина итеп күзаллый, үзенә тартып торырга тиешле, тышкы күренеше белән үк яшьләрне ымсындырырдай бина булырга тиеш дип саный, шуңа күрә ул гадәти түбәдән баш тартты да. Ә икенче бер фикерне аңа Рушан бирде: ә ни өчен түбәдә кафе ясамаска, ди, әле?

«Энжекәй»дән дә кызыклырак кафе проектын Глория кәгазьгә бик тиз төшереп ташлады, иң мөһиме шул булды—ул кафе өстенә чатыр түбә уйлап тапты, димәк, шунын белән бөтен бинаны каплап куйды. Кафены ул янә дә шәрекъчә итеп эшләде: хромланган жинел цинк чатыр түбә бик матур бизәкләрне үзбәк милли алымы белән сырлап-уеп—ганча стилендә эшләнгән күпсанлы баганаларга ятып торырга тиеш. Глория бу элементны Сәмәрканд мәчетендә күзе төшкән бер бизәк үрнәгендә эшләгәнен яшереп тормады. Аның уйлавынча, бу түбә берьюлы ике мәсьәләне хәл итә: беренчедән, кояшның иң эссе, туп-туры төшә торган нурларын кире кайтара, икенчедән, бина өстендә һава агымы даими алмашынып тора һәм салкынлык бирә.

Кафенең исеме дә шуннан чыгып туды—«Җилкәй», ә эссе якларда җиләс җил, һай, бик тә кирәк ул. Глория моның белән генә тынычланып калмады, янә дә Рушанның тәкъдиме белән, диварларнын калынлыгын нормативтан шактый арттырды, дивар эчләренә торбалар сузды, җәен ул торбаларда салкын су йөреп, бинаны суытып торачак иде. Интерьер, баскычлар, ут-яктырту ишеләр Глориягә бик жинел бирелде—анын хыялынын чик-чамасы юк иде шикелле. Үзенен көтелмәгән ачышларын ул Рушан белән бүлешә, ә тегесе, хатыныннан яшереп кенә, барысын да язып-теркәп бара, соныннан ул язуларның кирәге бер генә тапкыр чыкмады. Шул чагында Рушан бер нәрсәне аңлап алды: архитекторнын уе-фикере, хыял очышы шигъри юл шикелле икән—вакытында язып куймасаң, кайтарып ала алмыйсың, югалтасың.

Холлның зур диварын «Мотоциклчылар» дигән зур мозаик панно бизәргә тиеш иде—Глория шлак җәелгән юлда мотоциклчыларнын жанфәрман узышып ярышуларын онытмаган иде әле. Ул панноны тизлеккә битараф булмаган Зураб Каргаретели үзе эшләп бирергә булды. Рушанга хатынының проекты ошый иде: түбә астындагы кафе да, концерт залы да, әмма барысыннан да бигрәк ул холлны яратты: анда икенче каттан астагы кантар-кантар ташлар өстенә шарлавык ага, зәнгәрсу хауз читендә фонтан челтери, ә үтә күренмәле кабиналы лифтлар астан-өскә, өстәнаска тавыш-тынсыз гына йөреп тора, алар кунакларны холлдан «Җилкәй»гә—кафега күтәрәләр.

Элек, «вакытында туу кирәк» дигән гыйбарәне ишеткәндә, Рушан аңа бернинди әһәмият бирми иде, ул гыйбарә еш кына кирәксә-кирәкмәсә дә әйтелә һәм йә мушкетер буласы, йә Чапаев белән рәттән ат өстендә кылыч айкап чабасы килгән романтик яшүсмер чакларга, ә кызлар зиннәтле сарайлардагы балларда бию, алар өчен дуэльләрдә атышу, иртәләрен мәгъшукларының кәрҗин-кәрҗин чәчәк җибәрүе турында хыялланган вакытларга гына кагыла төсле иде. Хәзер Рушан анлый инде, үз вакытыннан соңлап туган кешеләр бихисап һәм алар моңардан һич кенә дә иза чикмиләр, үз вакытыннан алда туучылар исә берән-сәрән генә, аларны йә бөек язмыш, йә, әгәр дә аларны анлап, ярдәм итүче булмаса, фаҗига көтә, хәтта вакыт та аларның онытылган исемнәрен һәрчакта да тарихка кайтарып бирә алмый.

Глориянен Яшьләр йорты проекты да шундый язмышка дучар булды, ул, айсбергка барып бәрелгән кораб шикелле, әле янарак кына хөкүмәт чыгарган «Архитектурадагы артыклыклар турында» дигән карарга бәрелеп, челпәрәмә килде. Соңыннан билгеле булды: бу карар озын гомерле түгел иде. Әмма ул үзенең кара эшен эшләп өлгерде. Нихәлләр итәсен?..

Әле исеме аз билгеле булган яшь архитектор тәнкыйтьнең беренче көчле утларын түземлек белән кабул итте. Бу тукмакның нәкъ үзенә төшүе очраклы икәнен Глория анлый, биредә ул кемнәрнеңдер явыз нияттән казынуларын күрми—гап-гади язмыш иде бу. Әлбәттә, яна агым күзлегеннән караганда аның проектында «артыклыклар» житеп ашкан иде.

Кыю, купшы, матурмы? Болар барысы да комиссия өчен бары тик артык бай зиннәтлелек булып кына күренә, хәтта бу сыйфатлар үзләре дә ярамаган, тыелган нәрсәләр итеп кабул ителә. Ә бинаны суыту нияте, гомумән, бариннарга хас иркәлек, эрелек, тәкәбберлек кебек кенә карала. Лифтлар, шарлавыклар, ишегалдындагы хаузлар, фонтаннармы? Яшьләр йортындамы? Заркенттамы? Әле исеме картага да төшерелмәгән шәһәрдә... Һәммәсе дә, фикер алышып тормастан, аяк өсте генә кире кагыла торды.

Ничек кенә сәер булмасын, иң күп бәхәсләр «Мотоциклчылар» панносы тирәсендә барды: ә биредә—металлурглар шәһәрендә мотоциклларның, узыш-ярышларның ни катнашы бар?

Глория тизлек, узыш-ярышлар, бәйгеләр—яшьлек билгесе, заман, чор билгесе, дип анлатырга тырышып карады. Жюри әгъзаларының берсе дә ни Кадыйровны, ни Плехановны, ни Самородовны танымады, ә бит бу спортчыларның рәсемнәре ул елларда газет битләреннән төшми иделәр—ни әйтсән дә, күп мәртәбәләр дөнья чемпионнары, совет спортының горурлыгы...

Комиссия житәкчеләреннән берсе кин күңелләләнеп әйтте: «Панно—төп мәсьәлә түгел, аны үзгәртүе кыен булмастыр»,—диде һәм, үзенчә бик «кыйммәтле фикер» бирде: бөтен буена бастырып, кулына кисәү агачы тоттырып (нәкъ шулай диде!), таза бер металлургны ясарга, ә янәшәсендә—ут булып агып торучы бакыр елгасы... Шушы юмарт әйтелгән «акыллы» сүзләреннән соң, житәкче куанычыннан үзе дә Заркент бакыры төсле кып-кызыл булып кызарып-янып чыкты. Глория түзеп тора алмады, моңа каршы тезеп китте:

—Бу сезне ванна янына кулыгызга чебен сугып үтергеч тоттырып кую белән бер булачак, чөнки Заркентта бакырны химик юл белән, гальваник ванналарда «кайнатып» алалар, ул ванналар сезнең йорт ваннасыннан бераз зуррак-зурлыгын, төпләре дә, чуенны эретмәсен өчен, винипласт белән капланган, шулай итеп, бакыр эретүнең бер батырлыгы да юк, зәнгәрсу төстәге эремәсе, карап торуга бик матур күренсә дә, бик агулы да...

Бу сүзләрне Глория бер тын белән, пулеметтан аттырган кебек аттырды.

Комиссия рәисе атаклы скульптор, кәйлә-чүкеч тоткан ир-ат, ишкәк яки чиләк тоткан хатын-кыз сыннарын күпләп коеп торучы автор иде. Аның «кыйммәтле киңәшен» колагына да элмәгәне Глориягә бик кыйммәткә төште: аны мөмкин булган барлык гөнаһларда гаепләделәр...

## XXXXIII

Аларның туйларыннан соңгы дүртенче еллары уңышсыз башланды. Иртә язда, футбол сезонының башында ук алар төркеменең якты-юмарт жаны, шук-шаян такылдык Тамаз аягын сындырып, бик каты имгәнде. Ташкенттагы травматология институтында өч ай ятканнан соң, аннан гарип булып чыкты. Ябыккан, таякка таянган Тамазны күргәч,

барысының да йөрәкләре әрнеде, табиблар аңа, гомер буе шул таяк кирәк булачак, дигәннәр.

«Энжекәй»дә аны озату кичәсенә жыелдылар. Һәркем күңеллерәк булырга тырышса да, өстәл тирәсендә куе томан шикелле таралмас сагышмоң тирбәлә иде. Тамазны озаткач, үзләренең кайчандыр дус төркеме озакламый бөтенләй таркалачагын, яшьлекнең китеп барганын, тормышның яңа, кырыс баскычына басканнарын, алда инде якты өметләрнең, нәрсәләрнедер ымсынып көтүләрнең аз булачагын, иң якын дусларның ихтыярсыздан сирәгәячәген, төнге юләр шылтыратучылар бетәчәген, әле кичә башка да кермәгән, керсә дә, бер сагышсыз-авырттырусыз чыгып очкан хисләр белән артка борылып карауларсыз гына яшәүләргә чик куелачагын һәммәсе дә аңлый, шул авыр тойгы аларның күңелләрен баскан иде.

Тамаз үзе, кәефе башкаларныкыннан күпкә төшенке булса да, шушы шәһәрдә яшьлеге бергә үткән дусларының күбесе белән соңгы мәртәбә күрешкәнен аңласа да, әле шаяртырга тырышып карады:

—Яхшылыксыз яман булмый, дуслар,—диде ул.—Ниһаять, минем футболны ташлаганыма өйдәгеләр шатланачак, мин бит юрист, калган көчемне Фемидага хезмәт итәргә бирәчәкмен... Иң әүвәл бюрократ түрәләрдән үземнең пенсиямне яулап-даулап алырга туры киләчәк, мин бит исереклек белән түгел, ә дистәләрчә мең халык күз алдында имгәндем. Димәк, юристлык практикасы өчен берәр ел бар да бар инде. Үтенәм, дуслар, куып таратыйк йөзебезгә кунган сагышны! Шушындый бәлагә тарысам да, футболга иң матур яшьлек елларымны биргәнем өчен тамчы да үкенмим. И футбол—зур дәрт-теләкләр! Глория, гүзәлем, минем өчен футбол—синең өчен архитектура кебек иде, син моны аңлыйсыңдыр дип ышанам...

Икенче көнне иртә таң белән Тамаз Грузиягә китеп барды, шуннан соң алар беркайчан да элекке кебек барысы бергә жыела алмый башладылар. Очрашу өстәле яныннан әкренләп, берәм-берәм сәер генә юкка чыга баралар, әйтерсең лә, чоңгылга төшеп югалалар иде...

Шул ук елда гигант комбинатның соңгы—өченче чиратын тапшырасылары бар иде, гадәттәгечә, көнне төнгә ялгап эшләделәр. Комбинатны файдалануга тапшыру—дәүләт күләмендә әһәмиятле вакыйга, ул көнгә төзүчеләр генә түгел, ә бөтен шәһәр әзерләнде.

Әле кияүгә чыкканчы ук Глория Рушанның үз улы турында хыялланганын, Дасаевлар ыруының, үзендә тукталып калмыйча, дәвамчысы булуын теләгәнен белә иде. Әмма иренең бала булдыру теләгеп никадәр уртаклашырга тырышса да, хыялларын эш каплый да тора. Ул иренә:

—Түз инде, жаным, Яшьләр йортын эшләп бетерүгә сиңа менә дигән хужабикә булам, әни булам, тупылдап торган бер малай табып бирәм, эшемне ташлап торам...—ди иде.

Проектын якларга киткәндә, ул үзенең көмәнле икәнлеген әйтте.

Ташкенттан Глория жинелеп кайтты. Монысы бик шикле булса да, жинелүе белән ризалашкан кебек булган иде. Рушан аны тынычландырырга тырышты:

—Менә, бер-ике атнадан, комбинатны эшләтеп жибәрәбез дә, озаклап ял итәргә Гаграга китәрбез, алдагысын күз күрер тагын...—дип сөйләнде.

Ләкин кайтып ике көн үтүгә, Глория, көтмәгәндә ял алып, Мәскәүгә барачагын белдерде, комбинатны тапшыру бәйрәменә, һичшиксез, кайтып житәчәген вәгъдә итте. Рушан аны бармаска ни үгетләп караса да, тыеп кала алмады—хатыны соңгы мөмкинлеген ахыргача сынап карарга теләде.

Ниндидер зур кунаклар килүен көтеп, комбинатны жибәрү ике мәртәбә кичектерелде. Глория кайтмый да кайтмый, сирәк шылтырата, хәбәрләре куанычсыз иде. Дәүләт комиссиясенә төзелешен тапшырмыйча торып, Рушан берничек тә, күпме теләсә дә, хатыны янына китеп бара алмый иде.

Заркентка Глория ай ярымнан соң гына кайтып төште. Ябыккан,

бетерешкән, бик борчылган, телеграмма-нисез генә кайтты да керде. Анын бар кыяфәте эшенен шәптән түгеллеген әйтеп тора иде. Бусагадан ук иренен муенына ташланып, ачы күз яшьләре белән үксеп-үксеп еларга тотынды ул. Озак елады, горурлыгы Мәскәүдә жебеп төшәргә ирек бирмәгән иде, өендә хисләренә ирек куйды. Анын температурасы күтәрелә башлаганын тоеп, Рушан Глорияне диванга илтеп салды, хәлсезләнгән хатыны анын кулында йокыга китте. Төн уртасында ул, бөтенләй йокламаган да шикелле, кинәт сискәнеп уянды, гасабиланып, ачынып әйтте:

—Рушан... мин... Мәскәүдә... синен улынны... үтердем...—диде һәм янә елап жибәрде.

Рушан ниндидер төзәтеп булмаслык зур бәла, хәсрәт килгәнен бөтен йөрәге белән сизенде, төн уртасында бөтен йортны күтәрерлек, ниндидер анлатып булмаслык кыргый тавыш белән кычкырып жибәрәсе килде, әмма көч-хәл белән булса да, үзен тыеп калды, ачы әрнүдән буыла-буыла, истерика өянәге кузгалып, бәргәләнеп яткан авыру хатынын тынычландырырга азапланды. Йончыган, авыруга сабышкан, өметсез гажиз хатынына шул сәгатьтә бер генә авыр сүз дә әйтмәгәне өчен гомере буена язмышына рәхмәт укыды ул. Глория өч көн урын өстеннән тора алмады, чыгып йөрмәде—Рушан гел анын янында булды. Глория бераз торып йөри башлау белән дингез буена китәргә булдылар. Икесенен дә хәлләре хәл иде...

Гаграда алар Джумбернын кунакчыл абзыйсы Дато Джешкарианиләрдәнерактарак булган бер фатирга керделәр, үзләренә яхшы мөгамәләдә булган кешеләр күзенә бу хәлләрендә күренеп йөрмәскә булдылар. Кеше күп катнашкан шау-шулы урыннардан да качарга тырыштылар. Кайчандыр бу якларда шат һәм бәхетле үткәргән көннәрен бер дә искә төшермичә генә, көннәр буе комлыкта яттылар, тирә-якта матур урыннар күп булса да, беркая да чыгып йөрмәделәр, Пицунда турында хәтта авыз ачып сүз дә кузгатмадылар. Фатирларынын хужабикәсе официант булып эшли торган ресторанга кичләрен ашарга гына барып киләләр—шундагы террасанын бер почмагында үз өстәлләре бар, кичке сменада эшләүче официантлар ул өстәлгә гел «буш түгел» дигән язу куя иделәр.

Сәер, элек күнел ачып, кәеф-сафа корып утырганда гына вакыт тиз үтә шикелле тоела иде, шуна да андый чакларда «вакыт үткәрдек әле», «вакыт үтердек әле» дип сөйләнәләр дә бит, ә менә хәзер дә, шат күнеллелек ташып тормаганда да, күрше террасада янгыраган музыка тыпырдап бию дәртен кузгатмаса да, кичләр сиздермичә үтә тордылар. Һәр икесенен дә эчтә нәрсәләредер өзелде-сынды кебек, алар, ике хәлсез карт-карчык төсле, бер-берсенә ярдәм итешергә, булышырга, таяныч-терәк булырга тырыштылар. Сөйләшкәндә дә, үз тормышларына кагылмыйчарак, саклык белән генә, әһәмиятсез нәрсәләр турында гына сөйләштеләр.

Ул җәйдә, һәр кичне террасадан дингезгә кояш баюын манзара кыла-кыла, әдәбият турында бигрәк тә күп сөйләште алар. Дөресрәге, Глория сөйли, ә Рушан, теге чакта «Энжекәй»дә беренче күргәндәге шикелле итеп, анын янадан жанланып килгән матур йөзеннән күзен ала алмыйча, тынлап утыра.

Алар өйләренә сентябрьдә генә әйләнеп кайттылар. Заркентта әлсерәтә торган эсселек сүрелгән, Үзбәкстанда елнын ин матур фасылы булган жылы, озын-озак көз кергән иде инде. Берәүгә дә әйтеп тормастан, тын гына кайтып керделәр, элекке төсле утыру турында уйлап та карамадылар, ни өйдә, ни «Энжекәй»дә кайту хөрмәтенә кунаклар жыелмады...

Ничектер бер төнне телефон шылтырады. Павлодардан Джумбер шылтырата икән. Ир белән хатын төн уртасындагы бу хәлгә бик тә шатландылар, мөгаен, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, берәр сәгать сөйләшкәннәрдер, югыйсә бер куанырлык хәбәр дә юк иде үзе. Әле киресенчә... Джумбер Робертны ашыгыч рәвештә «Пахтакор» командасына алачакларын әйтте, тегеләрнен ун як һөҗүмчеләре жәрәхәтләнгән икән дә, тренерлар советы «Металлург» һөҗүмчесенә тукталган икән. Команда

Павлодардан көннең икенче ягында кайтып төшәчәк, Робертның Заркентта бердәнбер буш киче булачак—ул икенче көнне үк «Пахтакор»ның Тбилиси «Динамо»сы белән уенында катнашырга китеп тә барачак икән.

Шулай итеп, дуслар тагын бер иптәшләрен югалталар, дигән сүз, Джумбер озату кичәсе оештыруны үтенде.

Түрәләр теле белән әйткәндә, Роберт югары үрләсә дә, мәҗлес бик күңелледән булмады—Роберт үзе дә, калганнар да бу «үрләтү»нең нык сонарганын аңлый иделәр. Бердәнбер куанычы шул: өч көннән егет туган шәһәре Тбилисиның футбол кырында уенга чыгачак, теләсә кайсы грузин футболчысының иң изге хыялы шул бит. Ләкин, яшереп торасы юк, әгәр дә үз клубы өчен уйнаса, ул тагын да бәхетлерәк булыр иде.

Шуңа күрәдер, мөгаен, Робертның бу уены аның «соңгы җыры» кебек кабул ителде дә. Уенны Дасаевларда телевизордан карап утырган Джумбер күз яшьләрен тыя алмады.

Үзенә таныш булмаган «Пахтакор» командасында беренче тапкыр гына уйнавына карамастан, Роберт могҗизалар күрсәтеп, илһамланып уйнады, ул мөмкин булмаганнарны да булдыра алды, ни-нәрсә теләсә, шуны эшләде. Тәҗрибәле иптәшләре бу яңа егетнең уенына илһам фәрештәсе кунганын тоеп, гел тупны аңа бирә тордылар. Роберт кертkән ике туп грузиннарны аякка бастырып, ярсытып җибәрде: каян килеп чыккан соң әле бу егет? Мөгаен, ул көннәрдә Тбилисидә Тамаздан да бәхетле кеше булмагандыр, чит-ят җирләрдә, чит-ят командаларда уйнап йөрүче грузин футболчылары турында сөйли-сөйли телләре калмагандыр.

Джумбер исә, дусты Робертның уенын карагач, кыска гына итеп үз фикерен әйтте:

—Безнең һәркайсыбыз туган җирдә—Грузиядә уйнаудан мәхрүм ителгән грузин, анда кайткач, уенга бары тик җанын-тәненне биреп кенә, нәкъ менә Роберт шикелле уйнарга тиешбез. Яки футбол кырында егылып үләргә...—диде.

Ул кичтә саубуллашканда, иртә чалара башлаган капитан ачынып әйтеп куйды:

—Тирә-якта дөнья тулы кеше, ә мина шәһәрдә без өчәү генә калганбыздыр төсле тоела...

Күңелсез вакыйгалар Глория белән Рушанны бер-берсенә тагын да якынайтты, аларның уртак тормышына гаилә төсмере инә башлады—өйләнешкәннәренә биш ел дигәндә мондый сүзләрне ишетү сәердер, мөгаен, әмма чыны шулай иде.

Бер көн кебек үтеп киткән ул еллар аларның һәркайсысы өчен гел эш тә эш белән тулган булган, як-якка баш күтәреп карарга да вакытлары җитмәгән. Кайчакларда, башына берәр фикер килсә, Глория төннәрен дә торып кульманы янына барып баса, ә Рушанның эшендә урын-җире җәюле раскладушкасы тора иде. Ул раскладушкаларны ни уйлап шундый тиз ватылучан итеп чыгара торганнардыр? Мөгаен, эштә йончылган, төннәрен дә тыныч йоклый алмаган прорабларга исәпләнмәгәннәрдер шул алар. Рушан да, әнә, берничәне алыштырды инде. Ә инде буш вакытлары килеп чыкканда дуслары белән аралашырга тырышырлар, кунак чакырырлар, мөмкин булган саен Ташкентка барып кайтырлар иде. Менә шулай яшәлгән инде.

Рушан студентларча яшәргә күнеккән, ашау-эчүдә нәзберек түгел, талымсыз, өй ашлары, унайлыклар таләп итми, ул Глориясен аңлый, аның белән горурлана, эшенә-иҗатына зур ихтирам белән карый һәм күңеленнән генә улының да, һичшиксез, әнисе шикелле архитектор булачагы турында хыяллана иде.

Глорияне архитектурадан суынды, күңеле бизде дип әйтеп булмый, юк, ул бары тик эштән башкалар кебек үз вакытында кайта башлады. Алгы яктагы кульман белән дистәләрчә сызымнар, планнар, эскизлар һәм төрле рәсемнәр дә каядыр җыеп куелды, бүлмә, проект институтының остаханәсен хәтерләтүдән арынып, гадәти бүлмәгә охшап калды, иркенләп

иткэн төсле булды. Гөлләр, сингапур розалары пәйда булды. Эштән айтышлый, Глория базарга да сугыла, ире кайтып кергәндә, кухнядан әмле-тәмле исләр килә башлады. Хатынының теленнә йотарлык тәмле азыклар пешерә белүен күреп, Рушанның исе китте. Глория, элекке ебек, өйгә дә эшләрен күтәреп кайтмый иде инде.

Рушанның да көне башкачарак үтә, ул да эштән вакытында кайта ашлады, ниһаять, балконына рамнар ясап куйды, такта идәннәр җәйде. ллар буе сузылып, калып килгән эш бер атна дигәндә төгәлләнде дә. Цуна икесе дә шаккаттылар. Шуннан соң фатирга үз көчләре белән емонт ясарга ниятләделәр. Глориянең күзләрендә янадан шашкын утлар абынды шикелле.

Рушан комбинат төзелешендәгечә үлә-ята эшләрлек көче калмаганын ойды, башка күп кенә коллегалары шикелле, тынычрак объект алырга ирәклек турында да уйлана, әмма анысы турында әлегә Глориягә әйтми эра иде. Ташкентта да ешрак була башладылар. Ул язда алар яна орган алына концертка йөрергә ияләшеп киттеләр һәм, әлбәттә, «Пахтакор»ның ер генә уенын да калдырмыйлар. Роберт өчен янып-көеп утыралар иде.

—Сезнең трибунада икәнегезне белгәч, мин дә үземне уенда шанычлырак тотам,—ди иде Роберт Гогелия уеннан соң.

Шул җәйдә дуслар бөтенләй таралышып беттеләр.

«Металлург» командасы нык янарды: буыннар алмашыну бара, элекке емпионнардан бары тик икәү генә соңгы елларын уйныйлар—алыштыргысыз капитан белән капка сакчысы гына. Тренерлары да лышынды, яна тренер үзе белән ярты команда яна уенчылар ияртеп илде. Джумберның беренче көннәрдән үк ни тренер белән, ни яна енчылар белән борчагы пешмәде—аларның футболга мөнәсәбәтләре үк ашкача булып чыкты. Менә шуннан соң инде Заркентта уен кырында еренче мәртәбә таралмаган озын чәчле, гетр-оеклары сыдырылып төшкән, утболкалары трусиклары өстенә чыгарып салынган футболчылар күренә ашлады, аларның һәркайсының муенында берәр мәгънәсез нәрсә сылынып тора, ул аларның тылсым-талисманы, тагын да ямьсезрәк теп әйтсән, бөтие, имеш...

Тизлеген-җитезлеген югалтса да, Джумберга уены өчен сүз әйтерлек үгел иде әле, уен тәҗрибәсе арткан, тактик тоемлавы үткенләнгән, ә иң өһиме—ике канаты—Тамаз белән Роберт булмаса да, әле күп туп кертә. Шулай булуга да карамастан, яна яшь һөҗүмчеләр ана туп биреп торырга ик үк ашыкмыйлар, монда инде ул яшьләрнең генә түгел, тренерның а мәкерен сизенә иде. Күрәсең, чынлап та шулай булгандыр, Рушан елән Глория, ни әйтсән дә, футболны анлап карый иделәр бит.

Үзләрендәге чираттагы бер уенда, икенче таймның иң кызган чагында сәп команда файдасына иде инде, Джумбер көндәшләре капкасына агын бер туп кертте, тренер шул вакытта уен кыры читенә килеп, уллары белән ишарә ясады һәм Джекарианины алыштырырга җыенганын елдерде. Джумбер башта анламады—аны алыштырамы? Ни өчен? Рушан елән Глория утырган секторга якын гына булды бу хәл, алар Джумберның лек кебек агарынып киткәнен күрделәр. Шул мизгелдә үк ул кыр читенә өгереп килде дә тренерны якасыннан эләктереп алды, хырылдап әйтте:

—Кыланып кына кара, кыланып кына!—Аннары, борылып та арамыйча, уенга йөгереп кереп китте.

Рушаннардан һәм запас уенчылардан кала, нәрсә булганын берәү ә анлый алмый калды бугай...

—Менә, дуслар, мина да футбол белән хушлашырга чират житте,—иде капитан, уен беткәннән соң.

Мона кадәр башкаларга купшы озатулар һәм каршы алулар ештырып йөргән Джумбер «Энжекәй»дә озату кичәсе үткәрүдән баш артты. Аның китүен Рушаннарның әле яна гына ремонтланып беткән йләрендә өчәүдән-өчәү генә билгеләп үттеләр һәм тан атканчы утырдылар. лай да әле сөйләшеп сүзләре бетмәде. Джумбер китеп барганнан соң,

әле бик озак Заркент ничектер тоныкланып калган төсле булды.

Заркентта футболның юкка чыгачагын Джумбер алдан ук сизенгән иде, күрәсең. Көзгә «Б» классын бетерделәр һәм шуннан соң инде бу шәһәргә чын футбол беркайчан да әйләнеп кайтмады.

Язларын мотоциклда узышучылар да килүдән тукталды, әмма монысы бик гади аңлатыла: илдә шлак сибелгән юллы трекларны теләсә кайда ясый башладылар, шунлыктан әллә кая җәһәннәм читенә килеп йөрүнең кирәге калмаган иде.

Айлар арты айлар тәгәри генә тора, аларның бер җайга салынган гаилә тормышында вакытның үткәне сизелми дә кебек. Рушан гаиләсе өчен куанып, Глориясенең, ниһаять, тынычланып калганына сөенеп, дигәндәй яши, әмма башында бер уй бөтерелә иде: «Тулы бәхет өчен тагын бер улыбыз да булса...» Ләкин бу хакта ул Глориягә беркайчан да әйтмәде, аның да шундый уйларда булуын сизенә дә иде юкса. Ул аның табибларга ешрак барып йөри башлавын да белә иде. Вакытлар үтә торды, әмма Рушан хатынының оялчан да, куанычлы да итеп: «Безнең бәбиебез булачак...»—дигән сүзләрен тәки ишетә алмады.

Бервакыт ул төнлә Глориянең үзенең җилкәсенә борынын төртеп, мышкылдап елап ятканын тоеп, уянып китте. Рушан уянганын сиздермәде: «Бәлки, төшенә берәр нәрсә кергәндер»,—дип уйлады. Ләкин бу хәл икенче, өченче мәртәбә дә кабатлангач, ул аны тынычландырмакчы булган иде, хатынының истерика өянәге кузгалды. Үзен-үзе белештермичә, йөрәген ашаган ачы хәсрәттән шашынган хәлдә, Глория кычкырынырга тотынды:

—Мин синең улыңны үтердем, нигә соң син мине куып чыгармыйсың? Нигә кумыйсың, ә?! Мин бит синең тормышыңны җимердем, синең беркайчан да миннән улың булмаячак, Рушан! Беләм бит, син аның турында көн-төн хыялланасың. Куып чыгар мине! Ку!!!—дип тыелгысыз үкседе ул, иренең аяклары өстенә авып төшеп.

Рушан, аны шашкан күзләреннән үбә-үбә, булдыра алган кадәр тынычландырырга тырышты, бу минутларда үзенең аңа кайчандыр улы турында, үзен бурычлы итеп тойган Дасаевлар ыруының дәвамчысы турында кат-кат сөйләгән сүзләре өчен ихластан үкенде. Хәзер ул хатынының күңелендә тынычлык урнаштыру хакына үзенең булачак ун улыннан да баш тартырга риза иде, Глориясе тынычлансын гына, тынычлансын гына... Рушан тоеп тора бит—хатыны сызып-үлеп бара... Һәлак була...

Бу хәлләрдән соң Рушан Глориягә карата тагын да игътибарлырак булырга тырышты, төнге сменаларга эшкә йөрми башлады—ул хатынын төнгә йөрәген өзгәләгән, күңелен җәфалаган уйлары белән ялгыз гына калдырырга курка иде.

Бу дөньяда аның өчен сөекле Глориясеннән кадерлерәк беркем дә, бернәрсә дә юк—хатынының шуны аңлавын жаны-тәне белән тели иде Рушан! Кайвакытларда бу теләгенә ирешкән дә кебек була, Глория тынычланып кала, бер-ике ай күңелле генә эшләп йөри, кием-салымнар сатып ала, һәр шимбә саен диярлек Ташкентка баралар.

Ялларын Болгариядә үткәрделәр. «Албена» дигән яна курортта ял иттеләр, Глориягә диңгез яры буендагы отельләр бик ошады. Ул биредә янә күпләп эскиз-рәсемнәр ясый башлады, болгар архитекторлары белән дуслашып алды.

Рушан, Глориядә кабаттан архитектура белән кызыксыну уянганын күреп куанды. Ул көйләнгән гаилә унайлыкларыннан да ваз кичәргә әзер, фатирлары янадан проект институты остаханәсенә әверелсен, бары тик хатыны төннәрен еламасын гына, үзен гаепле тоеп изаланмасын гына...

Ул вакытта Болгариядә дискотекалар байтак иде инде, рестораннарда менә дигән оркестрлар уйный, Глория, кайчандыр «Энжекәй»дәге шикелле онытылып, һәр кич саен ләззәтләнеп-рәхәтләнеп биеде. Ә Варнадан Одессага теплоходта кайткан чагында, өске палубадагы бию залында, ял

итүчеләрдән кайсыдыр Рушанга көнләшеп карап әйтеп куйды:

—Карагыз әле, хатыныгыз нинди шат, бер кайгысыз сезнең!—диде.

Рушан бу кешенең сүзләрен кире кагып тормады, эченнән генә шатланып уйлап алды: «Аллага шөкер, Глория үз асылына кайтты бугай».

Болгариядән кайтып, бер атна үткәч, Рушан эшеннән чәчәкләр күтәреп кайтып керде, кайтса—өстәл өстендә бер язу ята иде.

«Рушан, сөеклем, мине эзләмә. Безнең тормыштан бер яхшы нәрсә дә килеп чыкмаячак, барысын да яңабаштан башлап карарга тырыш. Синең бер гаебең дә юк, барысы өчен дә сина бик-бик рәхмәтлемен. Әгәр булдыра алсаң, гафу ит... Хуш. Үбеп—Глория.»

Рушан, язудагы сүзләрнең мәгънәсенә төшенә алмыйча, аны бер дә, ике дә, өч тә укыды—әгәр дә үзенә таныш, кадерле кулны танымаса, моны берәрсенең усал шаяртуы диеп уйлар иде. Өй эчендә бернәрсә дә үзгәрмәгән: һәммәсе дә чиста, җыештырылган, чүлмәкләрдәге гөлләр юылып, өсләренә су бөркелгән, кухнядан әзер кичке аш исе килә...

Рушан барып, гардероб ишеген каерып ачты, үзенең әйберләре белән аралаш Глориянең ике иске күлмәге һәм плащы эленеп тора. Чемодан юк та, хатынының яраткан юл сумкасы юк. Ул акчалар һәм документлар саклана торган шкатулкага ташланды—Глориянең паспорты юк иде. «Акча да алмаган ичмасам...»—дип уйлап куйды шикелле, аннары, әле хатынының исен саклап торган тахтага барып капланды да елап җибәрде. Бала чагыннан, бик күп еллардан бирле еламагандай, үкереп-үкереп елады ул.

## XXXXIV

Бер ай үтте, ике ай...

Рушан Глориянең үзен ташлап киткәнен берәүгә дә әйтмәде, хәер, әйтер кешесе дә юк иде—соңгы вакытларда алар кешеләр белән бөтенләй диярлек аралашмый башлаганнар иде инде.

Ул әле бу хәлгә үзе дә ахырынача ышанып бетми, ана Глория янә ниндидер шашкын хисләрдән соң, үзен-үзе белештерми ычкынып киткәндер, барысы да җайланыр, бераздан кайтып керер кебек тоела иде. Кайгы-хәсрәттән һәм йокысыз төннәрдән кара янып чыккан хәлендә ул эштән соң өенә йөгерә, һәр көнне Глория кайткандыр дип өметләнә. Эштә тоткарланасын белсә, ишектә язу калдыра: «Глория, мин фәлән-фәлән вакытта өйдә булырмын...»

Берсендә, баскычтан менгәндә үк, ишектәге язуның юкка чыкканын күреп алды да, шатлыгыннан сулуы кабып, чүт тончыкмады. Әмма шатлануы юкка булып чыкты—язуны, мөгаен, малай-шалай шаяртып алгандыр. Төннәрен ана кайвакытта кыңгырау шылтырый кебек ишетелә, ул шатланып сикереп тора да ишеккә ташлана, аннары, нәүмизләнеп, иртәнгә кадәр йоклый алмый ята.

Беренче айларында Рушан Глорияне эзләп табарга азапланмады—аны хурлыкка-оятка калдырудан курыктымы шунда. Ә бәлки, һичшиксез, әйләнеп кайтырына ышанганга күрә эзләмәгәндер.

Өченче айга киткәч, ышанычы эреп юкка чыкты һәм ул, ашыга-кабалана, таныш адреслар буенча хатынын эзләргә тотынды, әмма күңел юатырлык хәбәрләр юк иде. Кичләрен Рушан өйдән чыгып йөрмәс булды—аңа хатыны кинәт шылтыратыр яки үзе Глория турында хәбәр итәргә кушкан кешеләр шылтыратыр төсле тоела иде.

Бары тик кара көздә генә, бер ел чамасы үткәч, көтмәгәндә Норильскидан ике-өч сүзле генә телеграмма килеп төште: «Газаплама үзеңне, эзләмә мине.»

Бер атнадан Рушан Норильскида иде инде, бөтен шәһәрне актарып чыкты, милицияне аякка бастырды, әмма Глориянең эзләрен таба алмады. Бәлки, ул бу җир читенә килеп тә йөрмәгәндер, берәрсенә шуннан

телеграмма сугарга гына кушкан булгандыр? Барыннан да битәр, шулай булгандыр, кеше печән кибәнендәге энә түгел бит, ул елларда әле Норильск та зур шәһәр түгел иде...

Ике ел үтте...

Глориянең соңлап ачылган мавыгуы булган гөлләр, чүлмәкләрендә килеш утырып, көеп-үлеп беттеләр, шатлыклы көлү тавышларының һәм күңелле мәҗлесләрнең шаһиты, кайчандыр бәхетле йорт телдән калган кебек булды, ябык ишекләр артында шомлы тынлык хөкем сөрә иде.

Ярты елга бер мәртәбә, сирәк кенә Рушанның фатирында әкрен генә музыка яңгырый: Гайдн, Вивальди, Стравинский, Барток—Глориянең яраткан композиторлары. Бары тик үзенә мохтаҗ эш һәм шул эш өчен канга сеңгән җаваплылык тойгысы гына Рушанда тормышка кызыксыну тудыра, аны тышкы дөнья белән бәйләнештә тота иде. Дасаевны эшендә үстерү-күтәрү турында хәзер инде сүз алып барылмый, «сынды мужик» кына диләр. Аннары, яңа объект—көнкүреш химиясе заводы да комбинатның үзен төзегәндәгедәй күп көч, киеренкелек сорамый, шуның өстенә Рушан үзе дә, башлыклары әйтергә яратканча, «шомарган биш тиен» иде инде.

Әмма көннәрдән бер көнне бар нәрсә Глорияне искә төшереп тора торган бу шәһәрдә үзенә бик авыр икәнен, һава җитмәгәндәй, нәрсәнеңдер үзен буып торганын тойды ул, ә хатынының фатирында яшәү көннән-көн газаплырак була бара иде. Ул элеккечә үк һәр очраклы кыңгырау тавышына сискәнеп китә, нинди дә булса шатлыклы хәбәрне ишетми калудан куркып, кичләрен өеннән сирәк чыга. Әмма Глориядән һаман да хәбәр-хәтер юк иде. Ул нәрсәдер эшләргә кирәклеген дә аңлый, ләкин Глория китү белән аның бар көчен-җегәрен суырып алдылар, ихтыярын сындырдылар төсле иде.

Ничектер бер кичне Рушан эшендә элеккечә тоткарланды да, кайтышлый «Энҗекәй» кафесы янындагы тукталышта төшеп калды—өйдә суыткычы буш иде, шуна күрә, кая булса да кереп, капкалап аласы итте.

Яшь төзүчеләрнең үзара сөйләшкәндә «Энҗекәй»не гел генә телгә алып торганнарын ишетеп йөрсә дә, үзенең кафеда булмаганына бер дүрт ел бардыр инде. Элекке официант кызлар алышынып беткән, аны элекке кебек елмаеп каршы алмадылар, чәчләре чаларган шушы ирне—кайчандыр грузин егетләре гүзәл Глория белән таныштырган, аннары һәр кичне диярлек шау-шулы компаниядә шушында утыра торган Рушан Дасаевны хәзер тануы да кыен иде инде.

Беренче минутлардан ук Рушан вакыт дигәненең кафены да кызганып тормаганын аңлап алды. Элек «Энҗекәй», Глория уйлап эшләгәнчә, бәйрәмчә күңелле кечкенә кафе иде. Официантлар эшкә ял итеп, дәрт-җегәрләре ташып торган хәлдә килә, залны тәртипкә китерә, шланглардан су сиптереп, идәннәрне юып чыга, өстәлләргә чәчәкләр куя иде, бөтенесе дә ялт итеп тора һәм сәгать кичке җидедә кафе кунакчыл ишекләрен ачып җибәрә иде. Хәзер исә «Энҗекәй» иртәннән ачыла икән, официантлар, заводтагы шикелле, бер көн эшли, ике көн ял итә—шунлыктан Заркент эссесендә кечкенә сыгылган лимон төсле булып калалар икән. Еш кына көнлек план-керем инде үтәлгән була, кичке кунаклар булса ярый, булмаса ярый шикелле генә икән.

«Энҗекәй» ремонт шаукымын да кичергән: элекке нәфис мәрҗән алсу кабырчыкны аңлаешсыз тонык көрән буяуга катырганнар, кызыклы архитектур табыш булган утлар балкышы юкка чыккан—мөгаен, электр энергиясенә экономия кампаниясе вакытындадыр инде. Тундырма һәм тәмле сулар да юк, алар урынына кыйммәтле коктейльләр һәм стаканнарга бүлеп коньяк саталар.

Гадәттә дуслары белән утыра торган өстәл буш иде, Рушан шунда барып, үзенең күнегелгән урынына утырды да, як-ягына каранып, күзәтә башлады. Халык элекечә үк күп иде—кафе, картаеп, гүзәллеген җуеп барса да, әле шактый даны калган иде.

Кинәт Рушан бер нәрсәгә игътибар итте, моны Глория күрсә, шиксез шатланыр иде, ә бәлки, ул аның вакытлар үтү белән шулай булачагын күз алдына китереп эшләгән булгандыр да. Глориянең яраткан материалы—кызыл бакыр белән сары жиз, ничектер янача күренеп, күзне иркәләп тора иде. Традицион Шәрекъ бизәкләре коеп эшләнгән кызыл бакыр биек коймa, вакытлар үткәч, урыны-урыны белән яшькелт тутыкка өртелгән һәм шулай итеп бик откан, ул, әйтерсең лә, борынгы заманнардан калган һәм тузанланган бер кадими әйбер, бик чекерәеп тормаса да, күзгә ташлана иде. Ә элек Рушан Шәрекъне, борынгы кадими заманнарны хәтерләткән бу бизәкләргә, бу матур коелмаларга игътибар да итми иде шикелле. Һәркөнне йөзләрчә куллар тота торган бакыр култыксалар, барның мәрмәр өстәлләрен каймалаган сары жиз, бизәкләп-сырлап эшләнгән авыр ишек тоткалары шомарып беткәннәр дә алтынсыман ялык-йолык килеп торалар.

Оркестр күнелле, шатлыклы көйләр уйный, куәтле көчәйткечләр аша ишетелгән музыка «Энжекәй»нең галәмәт зур, буш залында колакларны тондырырлык булып яңгырый. Глория, ихтимал, музыканың шулай электрон үсеш-очышын да алдан күргән булгандыр.

Оркестрга төрле яктан, «тегене уйна», «моны уйна» дигән теләкләр белән, төрле суммадагы акчалар ява, аны, берәүдән дә яшереп тормыйча һәм хәтта әле бераз масаеп-мактанып та, музыкантларга сузалар, аннары бөтен залга: «Безнең кадерле дустыбыз Әхмәт хөрмәтенә башкарыла...» дигәнрәк сүзләр яңгырый. Димәк, ниндидер Әхмәт бу кичтә зурдан кубып кәеф-сафа кора, типтерә. Рушаннар заманында болай кылanучылар юк иде.

Әлеге билгесез Әхмәтнең юмартлыгыннан кинәнгән оркестр бер минутка да туктап тормый, залның дүрт секторында да яшьләр дәртләнеп бииләр. Вакыт-вакыт биючеләр сирәгәйгән арада исән калган көчле юпитерларның яктысы бию түгәрәкләре өстенә төшә дә, Глориянең йөзләгән аяклар ышкып шомарткан-ялтыраткан чәчәкләре тирә-юньгә алтын балкыш сибеп ала иде.

Бераздан Рушан өстәленә бер кызның туган көнен ашыгыч кына билгеләп үтәргә жыелган яшь-жилкенчәкне утырттылар. Рушан әле ул кызны кайсыдыр төзелештә күргән дә шикелле иде бугай. Кунакчыллык, тиз уртак тел табып аралашып китү—Шәрекънең шиксез матур сыйфаты, синдә ул электән булмаса да, бирегә килгәч йокмый калмый—һәм менә, инде биш минуттан Рушан бу мәжлеснең гүзәле, бүген туган көнен үткәрүче яшь кыз исәнлегенә бокал күтәрә.

Әхмәтнең чираттагы, бу юлы бигрәк тә купшы музыкаль заказы яңгырый башлады, яшьләр, дәррәү кубарылып, биергә кереп киттеләр. Рушан каршысында биисе килгәне йөзенә чыккан бер кыз гына утырып калган иде, кыз чибәрләрдән түгел, ләкин барыбер Рушан аны биергә чакырмый булдыра алмады.

Биегәндә Рушан ирексездән аяк астына карап-карап ала, моны сизенгән кыз сорап куйды:

—Әллә берәр әйберегезне югалттыгызмы?

—Менә бу чәчәк сезгә сәеррәк күренмиме?—дип, сорауга сорау белән жавап бирде Дасаев.

Кыз, игътибар беләнрәк караштырганнан соң:

—Әйе, ниндидер сере бар шикелле моның,—диде.

—Ә сез тагын да игътибарлырак булыгыз әле...

—Чәчәкнең менә бу каймалары үзара үрелгән «Г» һәм «К» хәрефләрен хәтерләтә шикелле. Әйе, әйе, хәзер мин ул хәрефләрне ачык күрәм! Сезгә алар нәрсә булса да сөйлиме, нәрсәнедер искәртәләрме әллә?—диде борчыла төшкән кыз.—Сез шулкадәр дулкынланасыз...

—Юк, мин дә ул монограмманы сез укыган төсле укыдым гына. Ихтимал, оста үзеннән истәлек калсын, дигәндер, аны таптап бетерә алмаячаклар...—дип жавап бирде Рушан, аның кайтып китәсе килә башлады.

«Энжекәй»дән күптән таныш юл буйлап Глориянең йортына кайтып барганда, Рушан күнеленнән генә Заркент белән хушлашты—ул төзелеш осталыгы серләрен үзләштерә башлаган яшьлеге шәһәре Ташкентка китәргә катгый карар кылган иде, анда аның балетмейстердан алып аптекарьга кадәр байтак дуслары да калды бит...

## XXXXV

Гомерләр үтә торды, ә Глориядән бернинди хәбәр-хәтер дә булмады. Вакыт-вакыт Рушан аны үлеп сагына һәм янадан шашынып эзләргә керешә: хатлар яза, телеграммалар суга, таныш-белешләренә кат-кат шылтыратып чыга. Ул «Архитектура» журналын махсус яздырып ала башлады, андагы мәкалә арты мәкаләләрне игътибар белән укый, берәрсендә Глориянең исем-фамилиясен очратмаммы дип өметләнә иде. Әмма бөтен тырышлыклары бушка гына булып чыга.

Ә бервакыт, Ташкентка күчеп кайтканнан соң беренче ялы якынлашып килгәндә, ул төшендә диңгез күрде, Гаграны, шунда Глория белән бергә үткәргән бәхетле көннәрен күреп, куанды. Көне буе шул матур төшен хәтереннән үткәреп йөрде ул. Имеш, Зураб Каргаретели аны бик үтенеп Пицундага чакыра, тормышка ашкан проектларын күрсәтмәкче була, имеш, серле елмаеп, әле җитмәсә көтелмәгән бер куаныч та вәгъдә итә...

Батып баручы саламга ябыша, дигәндәй, Рушан башына кереп утырган бер фикердән һич арына алмады, киресенчә, аңа тагын да ныграк ябышты: әгәр дә бу төш алдан хәбәр бирүче, күрәзә төш булса, язмыш булса? Хет багучыга йөгерерсең...

Берәр атна шулай изаланып йөргәч, ул диңгез буена китәргә карар кылды: ялы да зыян итмәс, ә иң мөһиме, аның күңелендә яңадан өмет уянды—ә кем белә?...

Ул Адлерга иртән килеп төште. Әле бик иртә булуга карамастан, һәр җирдә җанлылык хөкем сөрә иде. Кояшта кызынып ял иткән кешеләр Кара диңгез буен ташлап монсу гына кайтып китеп баралар, ә яңа килүчеләр әле диңгез кояшында каралмаган тәннәре белән генә түгел, бигрәк тә түземсез ашкынулары, ымсынулы дәртләре белән алардан аерылып тора—тизрәк диңгезгә, кайнар кояш астына!

Шундый түземсезләр ташкыны Дасаевны Гаграга бара торган беренче автобуска алып чыкты.

Безнең көннәрдә шәһәрләр үзләренең йөзен-кыяфәтен бик тиз үзгәртә, аларны кайчакта танып бетереп тә булмый башлый, бары тик үз йөзен, үз чалымын борын-борыннан ук тапкан курорт шәһәрчекләре генә еллар басымына бирешми, аларда һәр чор үзенең берәр билгесен калдыра килсә генә инде: духаннар—чәйханә, чәйханәләр—буфет, буфетлар—кафе, кафелар—бар, барлар—дискотека һәм шулай һич очына чыга алмастай исем алышынулар булып тора, әмма асылы һаман да бер булып кала бирә.

Ә бәлки, бу шәһәрчекләрнең гүзәллек серләре дә шундадыр: сезоннан сезонга тышкы бизәнүләрен үзгәртеп торсалар да, алар кипарислар ышыгында, мәгарәләр тынлыгында, тар гына тау сукмакларында, вак чуер ташлы, шау-шулы комлыкларда борынгы серләрен саклап, һәрвакыт үзләре булып кала алудадыр. Әгәр дә кемдер: «Сезнең эзләрегезне диңгез күптән ялмап алган, бәхетле көлү тавышыгызны кайтаваз тауларга таратып югалткан-йоткан»,—дисә—ышанмагыз, кире кайтыгыз, һәммәсе дә нәкъ элеккечә, сез кичә, өченче көн, күп еллар элек ташлап киткәндәгечә саклана... Бары тик яңадан килергә генә, күрә белергә генә кирәк!

Рушанга да Гаграда бернәрсә дә үзгәрмәгән шикелле тоелды, Хәер, яңа сәүдә нокталары ишәйгән—ул аларны шәйләми калмады, әмма андый

нәрсәләр ничек пәйда булса, шулай сиздермичә генә юкка да чыгучан булалар.

Тиз генә кереп, аяк өсте генә капкалап яки йөз грамм-мазар төшереп чыгарга көйләнгән, халык телендә «забегаловка» дип йөртелгән бу нокталар, тыштан караганда күркәм генә, атаклы курорт шәһәрчегенә лаеклы булып күренсәләр дә, тәҗрибәле төзүче күзе аларның вакытлыча икәнлеген тиз абайлап ала—көчлерәк җил иссә, аларның эзе дә калмаячак иде...

Әле Джумбер белән беренче кайтуда ук шәһәр яхшы ук өйрәнелгән, йөреләсе йөрелгән булганга күрә, Рушан бормалы текә урамнардан бик ышанычлы, кая барганын белеп атлый, күнеленә хуш килерлек фатирны да бик тиз тапты—үзәк ял паркыннан да ерак түгел, кайдан кайтсаң да, җәяү генә кайтырлык җирдә иде ул.

Дингездә су коенырга өлгереп, ял итеп алгач, кичен Рушан беренче килүләрендә Глория белән икәүләп йөрергә яраткан урыннарны манзара кылып кайтырга булды. Күзгедән үзен караштыргалаганда, соңгы бер ел эчендә чәче тагын да чалара төшкәнлегенә игътибар итте, әмма моңа эче пошмады, бу якларда иртә чалару сирәк күренеш түгел икәнлеген белә иде. Әйе, чал чәчләр грузиннарга үз тамгасын иртә һәм мәрхәмәтсез сала, әйтерсең лә, юмартлыклары һәм кин күңеллелекләре, шук-шаян һәм тормыш сөючән булулары өчен ясак ала.

Телеграф янынннан узып барышлый, Рушан ирексездән тукталып калды. Тбилисига телеграмма гына сук, дусларыннан берәрсе—Джумбермы, Тамазмы яки Робертмы хәзер килеп җитәчәк бит. Аның аларны бик тә күрәсе, элекке кебек, грузинча әзерләнгән табын янында сөйләшеп утырасы, яшьлекләрен, Заркентны, «Металлург» командасын искә аласы килә. Ләкин... Рушан алдында, әйтерсең лә, кичеп булмаслык упкын тора: дусларына ул Глория турында нәрсә әйтер иде? Аһ, югалды, тотып кала алмадым, саклый алмадым, эзләп таба алмадым, яклый алмадым, дипме? Аның әйтер сүзе юк, менә берниндн аклану табып булмый—шундый кешенне югалт әле! Рушанның дуслары өчен дә Глория дус кына түгел, тагын да кадерлерәк бер кыз—тормышларының, яшьлекләренең бер өлеше, тылсым-талисман иде. Дуслар белән очрашу шатлыгы нинди көчле булмасын, хатынының язмышын белгәннән соң, кайгы-хәсрәтләре дә шуннан ким булмас иде... Шуңа күрә ул телеграфка кермичә, бөрешә төшкәндәйрәк итеп алга атлады.

Глория белән бергәләп грузин архитекторлары арасында ачык һавадагы җәйге кафеларда утыра торган иделәр, ул кафеларның кайберләре бөтенләй юкка чыккан, ә кайберләре, әле бик популяр булсалар да, хәзер тоныкланып-сүрәнләнеп калганнар. Дасаев һәр заманның үз күңел ачу урыны булганлыгын тагын бер мәртәбә билгеләп узды. Шул кичтә ул, әгәр дә Глория кинәт кенә дингездә ял итәргә теләп, Гаграга килгән булса, аны да әнә шул яңа урыннардан эзләргә кирәклеген аңлады.

Ял көннәре бик тиз эреп юкка чыга барды. Рушан Глория белән беренче килгәч тукталган йорт яныннан да берничә мәртәбә үтеп китте. Капка янында Джумберның абзасы малайларын да күрде, малайлар үсеп, егет булып киләләр иде инде. Ул аларның һәркайсының исемнәрен хәтерли, әмма дәшәргә кыймады. Бер тапкыр Дато абзыйның үзен дә күрде, абзый һаман да элекечә төз гәүдәле, авызында һаман да шул алыштыргысыз сигареты иде. Дато Вахтангович, машинасына кереп утырыр алдыннан бер генә мизгелгә Рушанга карап та алды, ләкин хәзер үз йортында сөекле яшь хатыны белән ширбәт ае үткәргән Дасаевны алай тиз генә танырлык түгел иде шул инде. Бер-берсенә эндәшешмичә шулай аерылыштылар.

Икенчесендә, кич белән соң гына кайтып барганда, Рушан янә бу йорт яныннан сугылып узды. Ялт итеп яктыртылган ишегалдында, аның истәлекле көннәрендәге шикелле, мәҗлес шаулаша, ана хәтта арада Джумбер тавышы да ишетелеп киткәндәй тоелды. Ярым ачык калган

капкадан табын тирәсе әйбәт күренә иде, Рушан шулай да үрелеп карады—табында Джумбер юк иде.

Көннәр көнләшерлек матур тора, дингез тыныч, фатиры да уңайлы туры килде, хуҗалары да кунакчыл, ләкин көннәр, Рушанның соңгы өметен өзеп, бик тә, бик тиз үтә иде шул. Кайсыдыр бер кичтә, дингез буендагы ресторанда ашап утырганда, ул залда буш урыннарның күплегенә игътибар итте, юкса ял сезонының ин кызган чагы бит, официантка шул хакта әйткән иде, тегесе:

—Күпчелек ял итүчеләр кичләрен күнел ачарга Пицундага китәләр,—дип җавап бирде.

«Пицундага! Әлбәттә, Глория Пицундада!»—дип уйлап алды Рушан дулкынланып, сүнеп барган өмет чаткысы янадан гөлтләп кабынды да куйды.

Икенче көнне иртүк Пицундага китеп тә барды. Зураб Каргаретелинын әкияти автобус тукталышларын тынычлап карап бармакчы булып, автобуска утырды, ул Зурабның эшләрен бер өлеше эшләнеп яткан чагында, бер өлешен кәгазьдә проект һәм рәсемнәрдә күргән иде инде. Рушан егерме дүрт тукталыш санады һәм алар берсе-бер кабатланмый, хыял байлыгы белән күзләрне иркәләп, күнелне кытыклап тора иделәр. Юл буенда котырып үскән субтропик яшеллек арасына тезелгән сихри әкият каһарманнары, юл йөрүчеләрне эсседән һәм кар-яңгырдан саклапышыклап, кабат килүчеләрне дә үзләренең матур ачык төсләре белән тан калдырып торалар. Бу каһарманнар шулкадәр күп, кемнең дә булса башына, аларны бер кеше генә эшләгәндер, дигән уй һич кермидер, әмма Рушан җирдә шундый матур эз калдырган останың кем икәнлеген дә белә һәм анын өчен күнеленнән генә горурлана да иде.

Пицунда белән очрашуга Дасаев әзер иде. Аңа, төзүче кешегә, сызым-проектларда бер күргәнен җанландырып күз алдына китерүе берни тормый, композиторга яна партитура күрсәтсән—ул оркестрсыз да анын музыкасын ишеткән шикелле, Рушан да үзенә тиешлесен «ишетә» ала. Кин булып сузылган яр буеннан барганда ул Глориянең шушы манзараны күреп соклганын хәтерләде: төзүчеләр борынгы нарат урманын саклап калганнар, урман яр буенда биек булып күтәрелгән йортларга ук килеп терәлгән иде.

Юл чатындагы бронза скульптураны караганда: «Әгәр дингез буенда ял итә торган булса, мин Глорияне бары тик шушында, Пицундада гына очратачакмын»,—дигән карарга килде Рушан.

Кич үз көченә кереп бара. Киенгән-ясанган, шат-көләч кыяфәтле кешеләр яр буйларына чыгалар, тар урман сукмакларында йөриләр, һәркайдан музыка ишетелә.

Пицундада җәйге ресторааннар, кафе-барлар, дискотека-варьетелар шулкадәр күп булып чыкты ки, Дасаев югалып калды: кая барырга, кайда очратырга мөмкин ул үзенен Глориясен? Кайбер җирләргә тиз генә барып керерлек тә түгел икән—озын чират торырга кирәк.

Һәр биек йортнын проектында ин өстә, түбәдә үк ачык һавада җәйге кафе планлаштырылганлыгын исенә төшерде Рушан. Аннан дингез өсте күренеше һәм бөтен Пицунда борыны манзарасы ачыла, һәммәсе дә яхшы күренеп торырга тиеш. Ул, күп уйлап тормыйча, якындагы күпкатлы йортның ишегеннән кереп тә китте. Тиз йөрешле лифт аны уналтынчы катка күтәреп тә куйды, әмма монда да чиратка басарга кирәк булып чыкты—түбәдәге кафега керергә теләүчеләр дә хәттин ашкан иде.

Кафе галәмәт зур, «архитектура артыклыкларысыз» гына эшләнгән икән, Глория булса, «моннан да гадие булмас» дияр иде. Ләкин ял итүчеләрне бирегә күз алдында җәйрәп яткан манзара—саф дингез һавасы җәлеп итә, башка урыннарда кысанлык, ә монда бию мәйданы да иркен. Буш урын эзләп йөргәндә, Рушан анлады, күнеле белән тойды—Глория монда юк, була да алмый, ул анын зәвыгын яхшы белә иде. Бу уй

борчуга да салды һәм шул ук вакытта сөендерде дә—ахыр чиктә, башка күпкатлы биек йортларның түбәләренә менеп, эзләнеп йөрергә кирәк булмаячак.

Буш урын түбә читенә эшләнгән рәшәткә—парапет янында табылды. Рушан дингезгә карап урнашты, хәзер залдагы тамаша аны кызыксындырмый иде инде, ул хәтта торып чыгып китәргәме әллә, дип тә уйлаган иде, ләкин, кичкелекне ашап чыгар өчен тагын кайда булса да озын чират торырга туры киләчәген күз алдына китереп, калырга булды, шуның өстәвенә официант та бик тиз килеп житте һәм яңа тотылган форель балыгы тәкъдим итте.

Кояш, барлык билгеләре белән иртәгә матур көн буласын вәгъдә итеп, әкрен генә дингезгә төшеп бара. Катерлар, кечкенә теплоходларның кайсылары дингез эченә таба юл тота, кайсыларыдыр Пицунда причалына кайтып туктый, кайчандыр шушы яр буена, ә бәлки, шушы ук култыкка—Колхидага алтын сарык йоны эзләп килгән аргонавтларның кораблары туктала торган булгандыр. Сүз уңаеннан әйтеп үтик, «причал» сүзе үзе төрки сүз «чал, чалып куй» дигәненнән ясалган икән, ягъни «корабынны арканлап чалып куй»—монысын Рушан әле күптән түгел генә белде.

Кинәт кенә һәр нәрсәне төн төреп алды—йолдызлы, үзенчәлекле Колхида төне. Еракта, нейтраль сулар артында ук, зур Яңа ел чыршыларыдай булып, дәррәү тезелеп киткән утлар кабынды: бәйрәмчә утларын төнге дингез өстенә балкытып, өч палубалы галәмәт зур чит ил теплоходлары үтеп бара иде. «Төрекләр», «греклар», «шведлар»,—безнең портларга керүче чит ил корабларын дингез буе шәһәрләрендә яшәүчеләр һәм дингезчеләр шулай гына атап йөртә,—менә шуларның, тезелешеп, безгә—Ялтага килеп ятулары.

Җәй, диңгез, сәяхәт, бәйрәм...

Рушан хәтта еракдагы чит кораблардан яңгыраган музыканы да ишеткәндәй булды, әмма бу шулай тоела гына, аның колагын үз артындагы—залдагы оркестрның көчле тавышы тондырган иде.

Салкынайта, диңгездән сизелерлек булып жил исә, Дасаев туңып, калтыранып куйды. Залда күңел ачу әле кызып кына килсә дә, ул үзен уңайсыз тоя башлады. Официант белән исәп-хисабын бетергәч, ул түбән төшеп китте.

Гөлт итеп яктыртылган аллеяларда ял итүчеләр ашыкмый гына йөренә, шушы күпкатлы йортларда һәм кунакханәләрдә яшәүчеләрдер, мөгаен—аларның беркая ашыгасылары юк. Һәркайдан үзенә чакырып музыка ишетелә, рестораннарның пыяла диварлары аша ачык төсләрдәге җәйге киемле биючеләрнең шәүләләре шәйләнә, кая карама—бәйрәм. Тыштан карап торуга канәгать ял итүчегә охшаса да, Рушанның күңелендә бәйрәм хисе юк иде. Ул ашыкмый гына курорт зонасыннан чыгып китеп бара иде, инде чыгып життем, дигәндә—машиналарын туктатып, ял итү биләмәсенә керер өчен рөхсәт кәгазе күрсәтүләрен таләп итә торган шлагбаум янында—кинәт музыка уйнап жибәрде. Инде күңел ача торган бар урыннар артта калды, дип уйлаган Рушан ялгышкан—монысы Пицунданың иң баш ресторанны «Алтын руно» икән, оркестр тәнәфестән соң кичәнең икенче бүлеген башлаган булып чыкты.

Ресторан кечкенә, әле өч сәгать элек Рушан биредән үткәндә ул ябык иде. Җинел, нәфис корылма, өстәлләрнең бер өлешен, урман аланындагы шикелле итеп, агачлар астына ук куйганнар, барлык верандалары да куе субтропик яшеллек белән үрелеп алынган ресторан үзе дә бик килешле, бик матур күренә. Бакчадагы өстәлләрдә стильләштереп эшләнгән «керосин фонарьлары» янып тора, верандага анда-санда бик пөхтә итеп эшләнгән сарык тиреләре дә эленгән, алар, ихтимал, «алтын руно» символы булырга тиештер инде. Матур киенергә яратучы хатын-кыз затлары аларга кызыгып карыйдыр әле, бер иләнгән тунга таман гына булыр иде, дип ахылдыйлардыр. Ләкин тиреләрне бик игътибар белән саклыйлар булыр, әкияттәге «алтын руно»дан да болайрак

итеп саклыйлардыр, моны тик бирегә даими килеп йөрүчеләр генә беләдер.

Ресторанның үз йөзе бар, аны проектлаштыручылар да, төзүчеләр дә тырышканнар, шуна күрә Рушан «Алтын руно»га килеп кергәнен сизми дә калды.

Сүрән яктыртылган сәхнәдә оркестр шашына, ул болай да кызышкан залны тагын да кыздыра төшә, кысан мәйданчыкта якын өстәл хуҗалары бии, башкаларга көнләшеп, үз сәгатьләрен күтәргә генә кала, ә ул чират житмәскә дә бик мөмкин. Рушан, буш урын эзләп, өстәлләр арасыннан үтә башлаган иде, кинәт үзенә дәшкәннәрен ишетте.

—Рушан, безнең янга кил!

Дасаев шып тукталды: «Ялгыш ишетелде, ахрысы»,—дип уйлап өлгермәде, чакырулы тавыш янә кабатланды:

—Рушан, кадерлебез, кил безнең янга!

Бу тавыш бик зәгыйфь кенә шәм янып утырган өстәл янынннан ишетелә иде, үзләре шаулашалар-көлешәләр дә шикелле.

Рушанның аяклары тотмас булды, бер мизгел эчендә башыннан мең төрле уй йөгереп үтте: кем булырга мөмкин бу? Джумбертмы, Тамазмы, әллә Робертмы? Иске архитектор дусларымы?

Аны, әлбәттә, грузиннар дәшә, акцентларыннан сизелеп тора. Ул, шау-шулы өстәлләрне әйләнеп уза-уза, әкрен генә атлый, әмма күнеле инде шунда, көтмәгәндә чакырып дәшкән тавыш ягына очты... Ә бәлки?..

—Рушан, безнең монда карангырак, әллә син инде шәп кенә сыйланып та алдынмы? Безне танымыйсынмы?—дип, елмаеп сорады Тенгиз, үзе тукталган фатир хуҗабикәсенең улы.

Тенгиз янында тагын аларның беренче каттагы зур бүлмәләрен алып торган өч кыз белән егетнең дусты Заури да утыра иде. Кайбер көннәрдә кичләрен кайтып килгәндә Рушан аларны бакчада күргәли иде, берсендә хәтта алар белән ярты төн уртасына хәтле сөйләшеп утырган да иде.

—Утыгыз, чынлап та, кечкенәрәк икән шул,—диде арыган сүрән тавыш белән Рушан.—Ә сыйланып алу, дигәндә... Мин бүген сыйланып бетерә алмадым әле, сезне очратуым ярады. Берәр бокал шәраб булса, әйбәт булыр иде...

Официант Тенгиз артына килеп баскан иде инде.

—Ишеттенме, дустыбыз Рушан нәрсә диде? Ут һәм шәраб...

Озак еллар буена риза була алмаган, килешергә мөмкин булмаган усал чынбарлыкны Рушан менә хәзер генә тулысынча аңлады, аның бар асылына төшенде. Шау-шулы «Алтын руно» залында, шушында кайсыдыр бер мизгелдә миен ярып, ап-ачык бер уй йөгереп үтте: «Глория гомерлеккә югалды...» Ул, наркоздан айныган авырудай, барысын да ап-ачык күз алдына китереп бастырды, әнә хатынының бердәнбер телеграммасы: «Эзләмә мине...»

Әлләни күп калмаган соңгы ял көннәрен Рушан күршеләре белән бергә үткәрде, бу көннәрдә ул Гагра белән хушлашып йөрде, чөнки белә иде: ул бирегә янадан беркайчан да килмәячәк—чын-чынлап бәхет татыган жиренә бервакытта да кире кайтырга кирәкми...

* * *

Өч ел элек ул Глориядән хат алды, Гамбургтан. Глория инде күптән, бер ун еллар булыр, Германиягә китеп барган икән.

Глория Советлар илендә үзенең һөнәрен, сәләтен беркайчан да таныта алмаячагын, ниһаять, аңлаган, туган илендә яшәргә чыдар хәле калмаган аның, ул ватанында үзен нәрсә көтәчәген алдан сизенгән, шуңа күрә чыгып китәргә мәҗбүр булган. Боларның барысын да бик ачынып-өзгәләнеп язган иде ул.

Фоторәсемнәр дә жибәргән Глория—төсле рәсемнәр. Ерак Ницада,

Зәңгәр яр буенда ял иткәндә төшкән рәсемнәре. Рушанның ул якларда бөтенләй булганы булмаса да, алгы ишеге төбендә Глория басып торган отель аңа бик таныш шикелле иде. Хатыннан аңлашылды—Глория яшьлегендәге уңышлы иҗат җимеше булган отель янында төшкән икән.

Аның архитектор, өйләнгән яшьләр өчен Европада данлыклы отельләр проекты авторы икәнен белгәч, «Глория» отеле хуҗалары үзен ай буена бик зур кунак итеп, бушлай яшәткәннәре турында язган иде ул. Тагын әле ул Заркенттагы Яшьләр йортын проектлаштырганда бөтен җанын салып эшләгән хезмәте бушка китмәгәнен, шуның нигезендә Кувейтның бер бай шәехенә гүзәл сарай төзетеп биргәнен дә язган.

Чит җирдә Глориянең эшләре уңган, үз архитектура остаханәсен булдырган, эш бирүчеләрнең чуты-саны юк икән. Әмма Гамбургтан нинди генә матур, зиннәтле, төсле фоторәсемнәр җибәрмәсен, Глориянең хатларыннан әйтеп бетерә алмаслык тирән сагыш саркый: бернинди уңыш та, тук-рәхәт тормыш та алмаштыра алмый торган нәрсәдер Ватанында гомерлеккә торып калган иде—Рушан моны шулай ук яхшы тойды, әчке бер әрнү белән кабул итте.

Яшьлегендә Рушанга Аллаһы Тәгалә дә кайдалыгын оныткан ерак Мартукта бирәрсе:

—Дусларың, сөйгәннәрең дөнья буйлап таралып бетәр, кайсысы Парижда, кайсысы Лондонда, кайсысы Гамбургта булыр...—дип күрәзәлек кылса, ул мәсхәрәле елмаер һәм, кайчандыр Саня Вуккерт яшькелт күзле Томочка Солохога әйткән кебек:

—Син бага белмисең, мадам...—дип кенә әйтеп куяр иде.

Көннәр үтә—күңелсез, авыр, сагышлы көннәр чиратларда торып, салкын фатирларда яшәп үтә, алда шатлыклар күтәренә ышануы бик-бик тә кыен. Вакыты-вакыты белән гомер бөтенләй бушка үткәндер кебек тоела.

Әмма... әмма...

Күптән юылмаган, тузанланып беткән тәрәзәсе аша карап торганда, каршы яктагы йорттан кулына нота папкасы тоткан зәңгәр бантиклы кызчык чыгып килгәнен күргәч, Рушанның йөзенә елмаю куна: юк, бернәрсәгә дә карамастан, тормыш дәвам итә, чөнки әле җир йөзендә мәхәббәт бар, әле хәтер тутыкмаган, тоныкланмаган.

Ә хәзергә, мәхәббәт һәм хәтер—кешене биеклекләргә аккошлар шикелле күтәрүче шул тылсымлы ике канат әле сындырылмаган-имгәтелмәгән вакытта, тормыш чишмәсе кипмәячәк, төтендәй эреп бетмәячәк, таңдагы томандай очып юкка чыкмаячак...

Кипмәс... бетмәс... юкка чыкмас...

*Май, 1991 ел. Переделкино.*

*Марс Шабаев тәрҗемәсе.*

Хөрмәтле укучыларыбыз!

Менә сез Р. Мирхәйдәровның «Иртәләгән сагыш» исемле романын укып чыктыгыз. Роман сездә нинди уй-фикерләр, тәэсирләр уятты? Автор фикерләрегезне түбәндәге адрес белән язып җибәрүегезне үтенә (хат урысча да, татарча да булырга мөмкин):

*107207, г. Москва,*
*ул. Алтайская, 4, кв. 423*
*Мир-Хайдарову Раулю Мирсаидовичу*
*Өй телефоны: 466-72-00*

Р. Мирхәйдәровның басылып чыккан сайланма әсәрләре:

1. «Сайланма әсәрләр», 1 томлык. «Художественная литература» нәшрияты (Мәскәү), 1990 ел.
2. «Сайланма әсәрләр», 4 томлык. «Голос» нәшрияты (Мәскәү), 1992-1993 е.е.
3. «Сайланма әсәрләр», 3 томлык. «Грампус Эйт» нәшрияты (Харьков), 1995 ел.
4. «Сайланма әсәрләр», 4 томлык. «Южная Пальмира» нәшрияты (Днепропетровск), 1996 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Ренат Харис

### ҺАРУТ БЕЛӘН МАРУТ

ПОЭМА

1

Җем-җем йолдыз. Кап-кара төн...
Чиксез ераклыклар аша
бер якты тап Җир шарына
котылгысыз якынлаша.

Аны кемнәр күрә икән?
Икътисадчылар йокыда,
сәясәтчеләр күз йомган
һәр яңалыктан куркудан.

Эшчеләр бик арыганнар
башлыкларын сүгә-сүгә...
Җитәкчеләр... Ә аларга
төнге күкнең сере нигә?..

Күккә карамый исерек,
аекның башында күптән
өмет-ышаныч югалган
кара җиргә, зәңгәр күккә.

Ил башлыклары үзләре
сирәк нидер күзәтәләр,
ярдәмчеләре күргәнне
күргән булып сүз әйтәләр.

(Бу безнекенә кагылмый,
безнеке искиткеч уңган—
туганда ук ул теннисчы,
агроном һәм композитор,
язучы, галим һәм доктор,
төзүче, банкир, дирижер,
оратор һәм архитектор,
укытучы булып туган!)

Ә хәрбиләр күрә бары
күрергә боерык булгач,
әйтик, Кызыл мәйданга ук
шпион самолет кунгач.

Депутатлар күпне күрә,
хәтта кирәкмәс төшне дә,
тик ышаныч үтерелгән
алар сүзенә кешедә.

Руханилар ни күрсә дә
Ходай бирмеш! дип әйтәләр,
әнә шулай кеше аңын
тирәнәйтеп «киңәйтәләр».

Ә якты тап якынлаша...
Кометамы, метеормы—
беркем белми... Һәм дә белми
аның Җиргә төшәр турын.

Күрсә күрә шагыйрь генә—
хыялда адашкан кеше,
ерак китеп эзлисе юк,
әйтик, менә минем ише...

2

Кара урман. Җем-җем йолдыз
коелган Аккош күленә.
Елтыр-елтыр килгән «Волга»
төннең серенә күмелгән.

Кайтып бара әллә кайдан...
Якынлашты күл турына.
Кинәт фаралары сүнде
серле яктылык нурыннан.

Күл суына нидер чумды,
сазан коерык бәргән сыман.
Җып-җылы бу күтәрелде
җем-җем йолдыз тулы судан.

Машинадан төшеп, берәү
курка-курка килде күлгә.
Ничек кенә караса да
су күрмәде—күле үлгән!

Сыек ләмдә анда-санда
бәргәләнә бака, балык,
әйтерсең лә кинәт кенә
парламентсыз калган халык.

Авызларын шапылдатып
ача-яба бахырларың...
Ләкин галәм аңлый алмый
аларның сүзсез хырлавын.
Камышта бака бакылдый
йолдыз тулы күкне сүгеп.
Барлык бака—гади бака,
мандат алган вәкил түгел.

Җирдә беркем дә ишетми
бөек ризасызлык җырын—
ни Алласы, ни мулласы,
ни Госдума спикеры,

ни безнеке, ни БМО
Генеральный сәркәтибе...
Ишетсәләр дә файдасыз—
күлнең бу эчке тәртибе!

Спикер

Подумаешь! Күл кипкән дә
тончыккан икән сазаннар...
Во-первых, локаль һәлакәт.
во-вторых, ул күл Казанда...

Генераль сәркәтиб

Аккош күлендә петроль юк!
Шулай булгач, сүз дә кыска—
бака, балык—халык түгел!..
Грин-писка! Грин-писка!

Мулла

Лә хәүлә вәлә кувәте...
Алган шикелле бирер дә...
Догабыздан калдырмасак,
чыкканы кадәр керер дә...

Депутат

Суверенитетның безгә
һәр тамчысын саклау язган...
Милли дарелфөнүн кирәк,
но элгәре—су һәм сазан!

Яңа урыс

Әй, братва, күл төбенә
нидер төшкән, төбен тишкән.
Гуманитар ярдәм килсә,
банк аша—әйләнешкә!

Иске татар

Әйбәт булган—үзе беткән,
тишелгәнме, тишкәннәрме...
Кабанда барып чыкмагач,
алтын эзләп төшкәннәрдер...

Әллә кайдан яңгыраган
сүзләрдән колагы тонып,
теге берәү, бата-чума,
балык чүпләргә тотынды.
Балыклар коерык бәрә—
анда шап-шоп, монда шап-шоп...
теге берәү балык тота
шап-шоп иткән якны капшап.

Өс киемен ашык-пошык
чыклы чирәмгә ыргыткан.
Уч яссылык кәрәкәләр,
беләк юанлыгы чуртан...

Ә эчтәрәк бер авыры
ләмне кыйный—бу сазандыр!
Ходай кушса, төшке ашка
кыздырырга да язгандыр.

Азарт куркудан көчлерәк—
сузылды арырак кереп...
Шулчак аның беләгеннән
нидер алды эләктереп.

Теге берәү куркуыннан
акырды (Ничек языйк соң?)
Кыскасы—күлгә таралды
гаҗәеп таныш газ исе...

Куркырлык та иде хәле!
Кап-кара төн. Җем-җем йолдыз.
Җилемдәй ләм эчкә тарта,
аска сөйри кемдер комсыз.

Кемдер

Иблис кебек сүгенәсең,
әллә аның танышымы?
Сөйрә мине, сөйрә тизрәк,

чыгармыйча тавышыңны.

Югыйсә мин харап булам,
үзеңне дә харап итәм...

Теге

Әллә ни дип торам тагы—
син дә адәми зат икән!..
Ничек монда әләктең соң
шушындый мәхшәр төнендә?

Кемдер

Сөйрә диләр сиңа тизрәк,
озак салынма телеңә...
Бер сүз белән әйтеп булмый
ничек монда эләккәнне.
Ялгышырсың—уйлый калсаң
ихтыярый теләктән дип.

Теге берәү, каерылып,
чакырып алды шоферын.
Кыскасы—тартып алдылар
яхшылыкка юрый-юрый.

Таң беленеп килә иде,
Җирне төреп алсу нурга.
Болар юындылар төшеп
бераз су калган чокырга.

Теге

Тукта, тукта! Бу ни хәл бу?!
Зинһар тизрәк аңлат барын—
Үзең адәм, кулларың бар,
ә арканда—канатларың...

Кемдер

Мин—фәрештә!

Теге

Син—фәрештә?
Мин—атеист!.. Бераз галим.
Ләкин хәзерге хәлемне
аңлый һәм аңлата алмыйм...

Дөрес, кичен бераз каптык...
Ләкин чамадан узмадык—
ыштанда су кайнатырлык
дәрәҗәдә үк кызмадык.

Яле, тагы тотып карыйм—
җисемең булмаска тиеш!
Ләкин синең җисемең бар—
тыгыз, каты, җылы, юеш...

Кемдер

Мин—фәрештә! Натуральный...

Теге

Алай булгач, син җенессез!

Без-кешеләр арасында
йөри мондый бер кызык сүз:
ике хатын очрашкан ди,
кибеттәме, әллә эштә.
—Мин тагы кияүгә чыктым,
ир түгел бусы, фәрештә!
—Хәсрәтеңне уртаклашам!—
диеп әйткән ди тегесе,—
минеке дә ир түгел лә,
сизелми ирлек билгесе...

Кемдер

Мин җенесле! Бәла шунда!
Син бөек сер ишетәсең—
Аллаһының икәү генә
ирлеге бар фәрештәсе!..
Берсе аның каршыгызда.
Мәзәгегез сезнең—гайбәт.
Үзе белмәгәннән көлү—
кешегә хас көлке гадәт.
Фәрештәләр исермиләр,
йокламыйлар, арымыйлар...

Теге

Бездә дә андыйлар байтак!
министрлар, әйтик—мэрлар,
район, колхоз башлыклары
күрмиләр акны-караны.
Дөрес, алар очмыйлар да,
очарга чөнки ярамый.
Икенчегез кайда сезнең?

Кемдер

Җир астында... Бабилунда...
Мин дә озак шунда идем,
бүген инде менә монда.
Теге
Бабилун инде күптән юк...

Кемдер

Аның астындагы зиндан
һаман да бар! Минем дусым
газап чигә әнә шунда.

Без беренче гаепләдек
кешеләрне азгынлыкта.
Аллаһыдан без үтендек
куелсын дип моңа нокта.
Ә Аллаһы үзебезне
җибәрде Җиргә сынауга...
Адым саен без эләктек
ләззәт дигән хәтәр аугa.
Хәмер ләззәте татыгач,
татын югалтты сүзебез,
гүзәл хатыннар янында
өстен чыкты җенесебез.
Күпме гаиләне боздык,

нигез салдык сихер эшкә.
Үзебез дә, сихерләнеп,
барып җиттек үтерешкә.
Күңелгә кергән азгынлык
ирек куймады туктарга,
оныттык хәтта Аллаһны—
табындык төрле потларга.
Аллаһ моңа чыдамады—
ташлады безне зинданга...
Мин котылдым. Мескен дусым
Ахырзамангача анда...

Теге

Ә син ничек чыга алдың?

Кемдер

Әлегә сер!.. Сезнең илдә
бер яһүд бар. Ул коткарды...
Һәм әләктем шушы күлгә.
Мин бит инде ничә гасыр
су күрмәдем. Сусау—газап...
Бер голт! итеп йоткан идем—
Аккош күле судан азат...
Берәр эш булмасмы диеп,
менеп карадым гарешкә.
Ни күрәм—Аллаһ янында
бихисап яңа фәрештә...
Кабат сөрде Җир шарына—
тибеп торып җибәрде дә,
мәтәлдем, берни калмады
канатларым җегәрендә.
Элеккеге гөнаһларны
ярлыкамады, күрәсең...

Теге

Бездә дә еш алмашына
олы тәхетләр тирәсе...
Әйтик, өч-дүрт ел эчендә
илдән дүрт-биш Премьер узды.
Берсе берни төземәде,
һәммәсе үзенчә бозды.
Кеше түгел хәтта ташның—
бармы, юкмы—җаны сызлый...
Кеше эшли—акча алмый,
ашказаны инде бозлы.
Һәм әфьюн белән шаяра
бала-чага, егет-кызы.

Кемдер

Мин төшендем—сезнең яшәү
минем газаптан да тозлы!..

Нигә миңа Бабилунга
ашыгырга җирне ярып?!
Йә, танышыйк—Һарут булам!

Теге

Мин, алайса, булам... Марут!

Һарут

Нинди Марут? Син алдашма!
Марут Бабилун астында
нурдан хасил чылбыр белән
кайнар кыяга асылган,
бәйгә куйган күбәләктәй...

Марут

Һич алдашмыйм. Мин бит бары...

Һарут

Канатларың кая синең?
Кил, иңнәрең капшап карыйм...

Марут

Һич алдашмыйм! Сүзем шулай
образлы һәм шагыйранә...
Мин дә күңел азгынлыгын
җиңеп яшәргә өйрәнәм.
Бер ел инде кулда кодрәт,
учта төрле дилбегәләр
кот очарлык мөмкинлекләр
минем алда бил бөгәләр.
Илне ваклап саткан чакта,
һәр майлы калҗа-кисәккә
кул үзлегеннән сузыла!—
шуны да алыйк исәпкә.
Һәркемнең хәләл акчасы
ипи-тозлык—рәтләп тотсаң...
Ә кодрәтле кулны ипләп
дәүләт кесәсенә тыксаң?!.
Мин бирешмим—һәммәсеннән
әлегәчә ерак торам...
Миннән баераклар артты,
шунсы җанны авырттыра.

Һарут

Син сынатырсың, мөгаен...
Характерың—сып-сыек лай...
Шушы балыкка кызыктың...

Марут

Кызыкмыйча! Ул бит бушлай!
Аннары, бу—вак мәсьәлә,
очраклы бер туры килү!
Ил язмышын хәл иткәндә
принципның корыч биле
бөгелмәс тә, сыгылмас та—
бирешмәмен вәсвәсәгә...

Һарут

Белмим, белмим!.. Бусы инде
шактый четрекле мәсьәлә.
«Ил» белән «Мин» бер бизмәндә
очрашу—иң хәтәр мизгел.

«Мин» ен иленә биргәннәр
бик аз була! Алар—изге!
Бәлки ялгышамдыр, чөнки
кеше хәзер бик катлаулы...
Ә шулай да сине Җирдә
бик күп вәсвәсәләр аулый.
Еш эләктерер тозаклар—
малмы, данмы, яшь кочакмы...

Марут

Бер елдан соң очрашырбыз—
һәм ышанырсың шулчакны.

Һарут

Ә азгынлык өстен чыкса?
Үзеңә күрә син—түрә...

Марут

Барлык гөнаһымны җыеп,
органнарга үзем бирәм—
теләсә ни эшләтсеннәр,
суырсыннар җанның сүлен...
Илдә закон Алла булса,
органнар—закон рәсүле.
Түзә калсам, син үзеңә
нинди җәза алачаксың?

Һарут

Канатларны кисеп атып,
кеше булып калачакмын.
Фәрештәгә иң зур җәза—
Җирдә яшәү кеше булып!
Бигрәк тә сезнең дәүләттә—
сездә мәкер болыт-болыт!
Кешегә төшкән газаптан
мин бары тик үләчәкмен,
мәңгелек зинданга түгел,
гүргә генә керәчәкмен...

Марут

Ике фәрештә бар диләр
иңнәрендә кешеләрнең.
Шулар язып бара диләр
кешеләрнең бар эшләрен.
Мине шулардан азат ит!
Яшәп калыйм курыкмыйча,
Аллаһ биргән бар рәхәтнең
кочагында оча-оча...
Күңел бер дә тыныч түгел—
шик белән шом аслы-өсле.
Бер көнне чакырып алып,
мең гаеп тагарлар төсле.

Һарут

Ярар! Риза! Иңнәреңнән
фәрештәне куачакмын,
син дә мин дә барып җитсәк
шул изге мизгелгә чаклы.
Ә кешегә иң зур җәза—
фәрештә булып яшәүдер—
языклылар—Җир шартында—
языксыздан көнләшәдер,
чөнки кыек эшләр генә
көткәннәрдән дә алдарак
кешегә байлык китерә,
кеше байлыкка алдана!

Марут

Бер елдан соң очрашырбыз
нәкъ менә шушы урында.

Һарут

Килештек! Оттырачаксың...

Марут

Бу сынау миңа—ерунда!..

3

Якты кояш, җем-җем йолдыз,
типмичә космик тәртәгә,
Җир тирәли әйләнделәр
өч йөз алтмыш дүрт мәртәбә.

Өч йөз алтмыш бишенчесе
бер секундка соңга калды.
Аллаһ, бу хәлләрне күреп,
Җир күчәрен майлап алды.

Килеп җитте июль төне
Аккош күле буена да,
җып-җылы суда бер аккош
ялгыз гына коенганда.

Мондый хәлне илле еллап
Казан инде хәтерләми...

Ә бу аккош куптара бит,
кузгата бит хәтер ләмен.

Аккошларны күрер өчен
махсус килә торган булган
Зәки Нури, Нәби Дәүли,
Сибгат Хәким, Хәсән Туфан.

Бу гаҗәеп күл буенда
кәгазь-каләм осталары
хәзер дә еш күренәләр
диеп әйтергә дә ярый.

Озаклап йөзү буенча
Фәйзуллин рекорд куйгалый.
Кузгалак һәм гөмбә эзләп,
Мөдәррис Әгъләм булгалый.

Мансур Вәли бер бармагын
күл суына тыккан килеш
каттый тәнкыйть сүзе әйтә—
Н. романы кебек юеш!

Салих Маннап постулатны
тикшерә үзенчә борып—
кызларын су коендыра,
үзе ярда саклап торып.

Мостафин Аккош күлендә
ямь табалмый кебек бер дә—
ахры монда урын юктыр
уйдырмага, яңа сергә.

Карап күрми күлне Фоат—
чөнки мильон шөгыль тапкан:
декан, диктор, конферансье,
тәнкыйтьче дә, депутат та.

Зиннур Мансур газетасын
кулдан язып арыгач ук
күл буена килеп чыга,
йөрәген фикергә ачып.

Хәтта Ркаил Зәйдулла
үтешли генә туктала,
яр кибетеннән кыйммәтле
бер шешә минераль ала.

Ә Гаташ килми башлады,
чөнки бу тирәдә тормый.
Ә газәлдә кипкән гөлләр
Аккош күле суын сорый.

Мингалим канәгать диләр
кызы ясаган рәсемнән—
табигый урман-кырларны
килми диләр күрәсе дә.

Гәрәй китте дә югалды,
чумды контора эшенә.
Шагыйрьлеге качты мәллә
кино-лирик бу кешедән?

Кутуй курка барча судан—
коенганда Тирән күлдә
ыштан резинасы гына
коткарган аны үлемнән.

Ренат Харис тимер-бетон
поэмалар яза-яза,
тимер булган—күлгә керсә,
көт тә тор бер бәла-каза...

Җәй чилләсендә бар өмет
фәкать Зиннур Хөсниярда—
күл кипкәндә ул коенса,
Аккош күле чыга ярдан...

Әйе, җитте июль төне
Аккош күле буена да,
Аккош күлендә бер аккош
ялгыз гына коенганда.

Чума аккош... Алка-алка
дулкын чаба күл буйлата.
Дулкын, көмеш божра булып,
алтын комга чыгып ята

һәм юк була әкрен генә,
ярда кала дымлы эзе,
әйтерсең лә көнлек шигырь
язган шагыйрьләрнең сүзе...

Чыга аккош... Кага канат...
Җем-җем йолдыз тамчылары
чыңлап күлгә коелалар,
бәллүр тавышлар чыгарып...

Аһ, кызганыч, күренмиләр
меломаннар, шигъриманнар...
Чү! Автомобиль яктысы
саркылды төнге томаннан.

Килеп туктады «Мерседес»,
чыкты аннан безнең Марут,
тамырлары күлгә кергән
төпкә утырды ул барып

һәм күреп алды аккошны
җем-җем йолдыз алтынында...
Чумды аккош... Пәйда булды
Маруттан нәкъ бер адымда

Һарут үзе! Нараттай төз,
үзе көяз, үзе ыспай,
ап-ак туфли, ап-ак чалбар,
ап-ак күлмәк—җиңе кыска...

Һарут

Сәлам, дускай! Ни гаҗәп—
оныткансың дигән идем.
Син галәм механикасы
гамәледәй төгәл килдең.

Марут

Ашыктым отылганыңны
әйтергә дип сиңа тизрәк.

Һарут

Без лигитим сөйләшмибез—
әлегә уеңны үзгәрт,
ач машинаң багажнигын,
чыгарып куй тәмнишкәләр,
регламентта каралганча,
утырыйк бер чәкешкәләп.

Марут

Аны гына булдырабыз...
Кайсын ачыйк? Бусын... Әйдә...

Һарут

Чистайныкы булса кирәк—
тамакны майлады әйбәт.

Усадныкы да ярыйсы.
Бөгелмәнеке—чын агу.
Аларның сулары шундый!
Нишлисең бит—нефть ягы...
... минә телем дә аңкаудан
тәмам купты—чынлап менә!
Ел буе сусызлыктан үлдем
күреп кенә, тыңлап кына.

Марут

Кайда йөрдең, ниләр күрдең?—
сөйләп җибәр эчә-каба.
Түп башында утырсак та,
замана сәгате чаба...

Һарут

Тотыйк әле тагын берне.
Халыкка да бераз бүлик...
халыкара хокукларны—
яшәсеннәр шуны белеп...
Ни эшләдем? Ни эшләдем?
Әйтә алам сиңа шуны:
булыштым Аккош күленә
тутырырга шушы суны...
Аннары озак эзләдем
кешечә яшәү серләрен—
кайда гына йөрмәдем дә,
кайларга гына кермәдем!
Театр дигән урында
очраттым Әҗәлетдинне.
Әҗәл—Әҗәл генә түгел,
салым начальнигы димме?!
Университетлар бик күп!
Лекция тыңладым байтак.
Йөздән туксан профессор
белем биреп аңгырайта.

Барлык учрежденияләрдә
докторлар да кандидатлар—
кеше язган белән, диләр,—
галим булган рәсми затлар!
Һәммәсенең киләчәге
тау юлы күк ышанычсыз...
Шуңа да өстәл астында:
эвеш-түеш... кыштыр... тыз-быз...
База, банк, төрле фондларда
тормыш академиклары
туксан микъдарны—кесәгә,
дәүләткә—калган микъдары...
Хөкем сараена йөрдем...
Менә кайда ул тамаша!
Һәркем үтәргә тиештер
Җир «сират күпере» аша,
һәрбер кеше, чөнки, карак—
Россиягез, чөнки, ярлы...
Ә ярлы илдә кешенең
намуслы булганы бармы?!

Марут

Син нәрсә? Зинданда яшәп,
җирдәгеләргә үчлесең—
барыбызны, понимаешь,
бер аршин белән үлчисең...
Дөрес, безнең җәмгыятьтә
агы да бар, карасы да.
Нәрсә, андыйлар юкмыни
фәрештәләр арасында?
Син үзең дә гөнаһ өчен
Җиргә сөрелгәнсең ласа!..
Иң әүвәле үзеңне бел—
үзеңне аңла ичмаса...

Һарут

Фәрештә үзен аңлады
кеше белән чагыштырып.
Кеше үзен ничек аңлар?

Марут

Фәрештәгә каршы торып...

Һарут

Хәзер сиңа күчәчәкбез...
Чыгыйм тик сүзем очына.
Тагын берне тотыйк әле—
телемнең очы кычыта...
... Куәтле нәрсә, зәһәрең!—
уйны чәчрәтеп җибәрде...
Фикердәге киртәләрнең
йомшарып китте чөйләре...
Парламентыгызга йөрдем—
акыллылар нык утыра,
ләкин аларның фикерен
әллә нәрсә тотып тора.
Тәнәфес вакытларында
сөйләшәләр төркем-төркем,
шундый дөрес, ләкин чыгып,
уй-фикерен әйтми беркем.
Ә биш-алты депутатта
чын энциклопедик белем—
беркем дә бәйләп куялмый
аларның йөгәнсез телен:
салым турында дисеңме,
йә авыл, шәһәр исеме,
дуңгызның айлык үсеме,
китапта сурәт төсеме,
ничек юк итү кусене,
кисеп ыргыту бүсерне,
биметалл деталь кисеме,
үрчетү сиам песиен,
сөю-сөелү хисенме,
регламентның искесенме,
бу нәрсәме? кес-кесеме?
серләрен Фест дисбесенең—
барысын да компетентлы
итеп сөйләп тора алар.

Рәис урынбасарлары
тел шартлатып таң калалар...
Куба бәхәс... Кемнәрнеңдер
күңел читләре кителә...
Ахыр чиктә бик кирәкле
законнар кабул ителә.
Ләкин шундук ачыклана—
ул законнар акчасызлар!
Акчаларны Килештерү
комиссияләре сыза!..
Әнә шулар иң акыллы!
Алар фәрештәләргә тиң—
безгә бит акча кирәкми,
барлык нәрсә безгә тиген!
Аптырадым законнарны
тормыш белән сыный-сыный.
Законнар шундый тыгызлар—
тормышыгыз хәтта сыймый.
Сугышасыз, талашасыз,
сикерәсез үрле-кырлы.
Шуңа күрә һәрберегез
кадәри хәл җайлый, урлый...

Марут

Җитте, җитте! Кеше җанын
аңламаган башың белән
чумасың ич Оятсызлык
дигән тирән сасы күлгә.
Ничек инде «һәрберегез?»
Ник ягасың миңа яла?
Бу сүзләрең өчен сине
тотып судка бирә алам.

Һарут

Бирмичә генә тор әле—
кеше түгел мин, фәрештә!
Кирмән урамында түгел
минем суд! Әнә, гарештә!
Аллаһ кына минем хакта
хөкем карары чыгара...
Менә хәзер сиңа килик—
әзер булып тор чыдарга!

Марут

Үзем сиңа сөйләп бирәм
елымның һәрбер мизгелен.
Аның һәрбер манзарасы—
изгелек, тоташ изгелек.

Һарут

Күрәчәкбез, беләчәкбез,
борчылма син, аптырама—
иңнәреңдә фәрештәләр
барысын язып торалар:
изгесен дә, языгын да!
—Күренегез, нурлыларым!..
Сезгә сорау: Бу кешенең
берәр гөнаһ эше бармы?

Сул фәрештә

Адәм белән Хава кылган
гөнаһны бик еш кабатлый...

Уң фәрештә

Буш итми ич хатыннарны—
бу эше, димәк, саваплы!

Сул фәрештә

Берәү моңа кача-поса
бер «дипломат» акча төртте...

Уң фәрештә

Акча рәвешендә—рәхмәт!
Кызын бик шәп эшкә кертте.

Сул фәрештә

Хәер сораган бер картка
бер сум акчасын кызганды...

Уң фәрештә

Аракыга җыя иде,
бирмәде, димәк, бозмады!

Сул фәрештә

Коттедж сала! Хезмәт хакы—
бер морҗалык ике айга...

Уң фәрештә

Рәхмәтлеләре күп! Шуннан
акмаса да, тама файда!

Сул фәрештә

Берне уйлый... Сөйләгәне
уйларының нәкъ киресе.
Бигрәк тә дәүләт турында
сөйләми сүзнең дөресен...

Уң фәрештә

Аның каравы—рәнҗетми
ни үлесен, ни тересен.
Үз урынында дәүләтнең
һәм сарыгы, һәм бүресе!

Сул фәрештә

Меңләгән гөнаһ теркәлгән—
үзең санап карыйсыңмы?

Уң фәрештә

Миндә дә шулар язылган—
савап эшләр барысы да!

Марут

Йә, шуннан соң нинди хөкем
чыгарасың минем хакта?

Һарут

**Ничек аңлыйк—бер үк нәрсә**
**зур гөнаһ та, зур савап та?**

Фәрештәләр

**Протоколга теркәп бардык,**
**бернине дә югалтмыйча—**
**шушы нур дискеткаларда**
**гамәлләре кочак-кочак.**

Һарут

**Беләм, беләм, сез—бюрократ,**
**филигран һәрбер эшегез...**
**Ләкин бәһагезме ялгыш,**
**ялгышмы шушы кешегез?—**
**башым җитми... Кая әле,**
**шешәне бир, ачыйк кабат.**
**Нурдан үреп, уйларыма**
**өстим әле яңа канат.**
**Аллаһы аңлатыр иде,**
**гарше көрси ләкин ерак—**
**әллә күпме очасы бар,**
**йолдызларны ера-ера...**

Марут

**Нигә бик ерак йөрергә?**
**Син—сихер, тылсым иясе—**
**алып килсен фәрештәләр**
**берәр район судиясен,**
**прокурормы, адвокатмы,**
**берәр хокук идарәсе**
**җаваплы хезмәткәренме,**
**министрларның берәрсен,**
**үзәк сайлау комиссия-**
**сенең сәркәтибен димме,**
**спикер урынбасары...**
**Башкасы башыма килми...**
**Хөкем объектив булсынга,**
**килсеннәр башка каладан—**
**әйтик, Чабаксар, Сыктывкар,**
**Уфа йә Йошкар-Оладан...**

Һарут

**Моны эшләү миңа—пүчтәк.**
**Акыллы идея хакы—**
**(җәннәткә эләгә калсаң)**
**тулы түшле яшьтәш хатын!**
**—Нурлыларым, хәерле юл!**
**Алты-җиде минут сезгә.**
**Кайсы очрый—шуны монда!**
**Берсе булса, җитә безгә.**
**Мәсьәләне аңлатыгыз**
**алып килгәндә бирегә.**
**Өйрәтегез кыска итеп**
**сорауга җавап бирергә.**

Марут

**Яшьтәш хатын имеш.. Бераз**
**яшьрәк булсын инде булса.**
**Тән җылыту... ул да әйбәт!**
**Ә җан туңса, ә җан туңса?**

Һарут

**Кем әйтмешли—ноу проблемс!**
**Әүвәле нәтиҗә ясыйк—**
**изгедер, бәлки, эшләрең,**
**бәлки гөнаһ—олы язык?**
**... Әнә фәрештәләр кайта.**

Марут

**Беркемне дә тапмаганнар...**

Һарут

**Син күрмисең... бер урнына**
**егермене таккан алар.**
**—Артык күп алып килгәнсез...**

Фәрештәләр

**Хакыйкать хакына бары!**
**Тәннәре түшәктә калды,**
**биредә телле җаннары.**

Һарут

**Сәлам, акыл ияләре!**
**Без мохтаҗ сезнең җавапка:**
**ник кешенең бер үк эше**
**һәм гөнаһ та, һәм савап та?**

Кунаклар хоры

**Ник табынга чакырмыйсыз?**

Марут

**Тагын инде, тагын инде...**
**Табын диеп... табын түгел...**

Кунаклар хоры

**Шешә булгач, табын инде!**

Һарут

**Әйдә, әйдә, коеп җибәр**
**пластмасса бәллүренә.**
**Коллегалар монда саллы,**
**шешәнең төбе күренә.**

Фәрештәләр

**Алар эчми! Аларның бит**
**тәннәре юк әле бүген...**

Кунаклар хоры

**Нигә эчми? Аңа китсә—**
**алкоголь да җисем түгел!**

Һарут

**Озак сузма, ач шешәне,**
**сал тулырак—саранланма.**
**Сезнең илдә аек баштан**
**акыллы сүз чыкмый—аңла!**

Избирком вәкиле

**Эчик әле салганын,**
**сорамыйк кайдан алганын.**
**Дөрес цифыр җанга якын,**
**эшкә китсен калганы...**

Спикер урынбасары

**Җырга иртәрәк түгелме?**
**Әйтелмәде әле тост та...**

Министр

**—Кунакчыл Татарстанга**
**кунак күбрәк килсен, дуслар!**

Доцент

**—Байрагындагы өч төснең**
**өстәгесе ямь-яшел.**
**Дөрес эшли Татарстан—**
**налог түләми яши...**

Марут

**Без—донорлар! Без түлибез!**
**Иртәрәк тә башкалардан.**
**Ләкин җитми, һаман җитми**
**йолдыз очлы башкалага.**

Министр

**Казанда фәнни-гамәли**
**форумнарны сагынам—**
**йөзләп кунак, бай банкетлар!!!**
**Белмим кем хисабына...**

Һарут

**Сез монда нигә килдегез?**
**Төшерәмен исегезгә—**
**тост кирәкми, җавап кирәк,**
**компетентлы җавап. сездән!**
**... Бу нинди чибәркәй тагы?**

Хатын

**Адвокат булам ич мин...**
**Юридик фән өчен тотыйк—**
**ул фән Казанда көчле!**

Һарут

**Коллегалар, тост кирәкми,**
**без мохтаҗ сезнең җавапка:**
**ник кешенең бер үк эше**
**һәм гөнаһ та, һәм савап та?!**

Судья

**Әнә килә автомобиль,**
**кулясасы бумажный...**
**Ни эшләнгән важны түгел,**
**кем эшләгән—шул важны...**

Һарут

**Кешесенә күрә мәллә**
**Җирдә хөкем чыгарулар?**

Хокук идарәсеннән

**Бөтен нәрсә хәл ителә**
**югарыда... Югарыда!**

Прокурор

**Таслап аерып бирәбез**
**без оныннан көрпәсен.**
**Суд ул бәйсез! Үзе белә**
**эшне ничек йөртәсен.**

Һарут

**Бу нинди карт? Нинди кызчык?**
**Оныгымы?**

Фәрештәләр

**... Син ул хакта**
**бик сорашма инде... Болар—**
**профессор һәм аспирантка.**
**Мәхәббәт кодексына,**
**берсе астан, берсе өстән,**
**статья язалар иде,**
**билгелеләренә өстәп...**
**Икесен дә алып килдек...**
**Тәннәре дәвам итәләр...**

Һарут

**Иптәш галим! Җавабыгыз!..**

Профессор

**Башым әйләнеп китте лә...**
**... Әйтик, студент бер кыз белән**
**килеп капса... пикант чакта,**
**барысы да кызганачак,**
**аннары—яклаячаклар.**
**Доцентны шул ук эш өчен**
**урыныннан алачаклар!**
**Ә профессорга, сокланып,**
**«Молодец!» дип калачаклар...**

Һарут

**Тел төбеңнән аңлашыла:**
**хөкем—кешесенә карап!..**

Профессор

**Бөтен җәмгыятьтә була**
**сайлап тарый торган тарак...**

Аспирантка

**Җилбер-җилбер җил чуалта**
**ука чук киләпләрен;**
**оҗмахлардан чыкты мәллә**
**сөйкемле сөякләрең?**

Һарут

**Кара, ничек сырпалана!**
**Сырпаланмый гына утыр—**
**буш парик кебек башыңа**
**җәмгыяви акыл тутыр.**

Аспирантка

**Тау башына менәсең,**
**болыт килә, күрәмсең?**
**Үбим дигәч үбәм инде,**
**бер үбүдән үлмәссең.**

Һарут

**Әй исә җил, исә җил,**
**бөгеләдер нечкә бил.**
**Бер беткән баш ике бетмәс—**
**бар, тәнеңне киеп кил!**

Марут

**Азгын ат тайга иярә.**
**Онытылып китмә берүк.**
**Син куйган каттый сораугa**
**кумәкләшеп җавап бирик:**
**гонаһлымы, саваплымы?**
**Хәл ителә минем язмыш...**
**Ә син монда, понимаешь,**
**тай күрдең дә үзең азмыш.**

Һарут

**Дөрес, бераз кыздым бугай...**
**Тагын тынгы бирми ирлек!**
**Фәрештә булып яшәргә**
**Җир шарында һич юк җирлек.**
**Бигрәк тә—сезнең илләрдә!**
**Нәрсә генә эшләсәң дә**
**башың законга бәрелә.**

Избирком вәкиле

**Һәм акча чыга кесәңнән**
**төрле штраф, салым булып—**
**байлык җыю бездә кыен...**

Прокурор

**Коррупция чәчәк ата,**
**куллар йөри кыек-мыек...**
**Әллә ни килеп эләгә,**
**берәр эшкә салсаң кармак.**
**Салмыйбыз—беләбез чөнки:**
**silent lenter inter arma!**
**(Закон телсез корал барда!)**

Һарут

**Бәлки закон үтәлеше**
**бәйледер яңгырга, карга?**

Судья

**Прокурор әйтте ич инде:**
**закон телсез корал барда!**

Марут

**Туры сорау туры җавап**
**таләп итә, аңлыйсызмы?**
**Әллә шушы сорауга да**
**җавап бирә алмыйсызмы**

Министр

**Без дә университетта**
**латыйнны йоттык күпмедер.**
**Беләсегез килә икән:**
**homo novus—homo lider!**
**(Яңа кеше—ирекледер!)**
**Ул ирекле! Теләмәсә**
**селкетмәс мыек төген дә.**
**Сез тиле сорау әләсез**
**аның колак киртегенә.**

Избирком вәкиле

**Әчик әле салганын ла,**
**сорамыйк кайдан алганын.**
**Дөрес цифыр җанга якын,**
**эшкә китсен калганы.**

Кунаклар хоры

**Алай да бергә-бергә,**
**болай да бергә-бергә.**
**Җыен дуслар барыбыз бергә**
**булсак иде гомергә.**

Марут

**Аһ бирәннәр, оятсызлар,**
**инде таң килә беленеп.**
**Канса-канис әйтәсезме:**
**гаепсезме, гаеплеме?**

Спикер урынбасары

**Бу сорау беренчесенә**
**һич ялганмый...**

Министр

... Ул гел башка!

Адвокат

Мең гонаһлы гаепсезләр
җәмгыятьтә чиктин ашкан.
Шундыйларны яклый-яклый,
миебезне сөял басты.
За правосудие, егетләр!

Судья

Тутырып салып һәм басып!

Фәрештәләр

Таң беленә... Илтеп куйыйк
боларны үз тәннәренә...

Марут

Аермасын Ходай җанны
тәндә яшәү ямьнәреннән...

Һарут

Барыгыз, бар, нурлыларым,
боларны алып китегез!
Һәркайсысын җайлап кына
Үз тәненә беркетегез.
Ялгыша күрмәгез тагы!
Бик үкенерсез азактан—
сезне дә, җенесле итеп,
салыр адәми газапка...
Писарь-агентларың китте.
Файдаланыйк бу хәлеңнән—
гонаһ диеп бәялисең
үзең нинди гамәлеңне?

Марут

Андыйлар юк... бугай... ләкин
берсен үзем аңлый алмыйм—
сайлауда, бюллетень алып,
аларны урнага салмый
чыгып киттем. Шушы эшне
кайсы кенәгәгә языйк?

Һарут

Бу—Конституцияне
санга сукмау! Димәк, язык!

Марут

Кандидатлар арасында
лаеклысы юк дип санап...

Һарут

Ягъни намусың кушканча!
Бу гамәлең, димәк, савап!

Марут

Поты бер тиенлек берәү
шулай үтте парламентка.
Һәм шул кеше спикерны
зерә-пачум тотты утка.
Дөрес, аны күптән түгел
чөйделәр дә югарырак,
тавышыннан котылдылар!
Үзе монда, тавыш—ерак!

Фәрештәләр

Барысын да эшләп кайттык...
Күрсәң иде—чынлап җылап,
профессор әфәндебезнең
жаны алды чыгымчылап.
Прокурор тәнен күрде дә,
тәмам акылыннан шашты—
ул яшьрәк, ди, тазарак, ди,
шунда калырга маташты.
Этә-төртә бикләп куйдык
үз тәненә бичараны...

Һарут

Җен алмаштырган диярләр—
андый эшләр һич ярамый.
Сез савап эш эшләгәнсез...

Марут

Ә галим алдында—язык!
Яшь тән аның талантына
бирер иде күпме азык...

Һарут

Күрәсеңме—язык, савап
билгеләнә шартка карап.
Хәзер мин ачык аңладым—
Сездә икеләй стандарт
законда да, әхлакта да!
Нигезегездә шул ята.
Синең белән бәхәсем дә
хата икән... Олы хата!
Мин җиңелдем!
Ал пычагың,
канатларымны ат чабып...
Авырттырдың!..
Мәңгелеккә
аерылдык, фәрештә чагым...

Марут

Син әйттең һәм мин эшләдем!
Хәзер син вәгъдәңне үтә—
иңнәремнән фәрештәләр
юкка чыксын!
Йә, йә, көтәм!

Һарут

Үти алмыйм! Без ялгыштык

кисеп минем канатларны—
инде мин фәрештә түгел,
синең кебек бәндә бары.
Ялкын кузга күчкән кебек,
эчкә күчте тылсым көчем,
ул җитә бары үземне
кеше итеп тотар өчен.

Марут

Көчең, бәлки, җитәр әле—
тырышсана! Көтәм, көтәм!

Һарут

Күрәсең бит—булмый, булмый...
Кил, хушлашыйк... Һәм мин китәм...

Марут

Кая китмәкче буласың?

Һарут

Сез—кешеләр арасына...

Марут

Эшләреңне кем бүләчәк
агына һәм карасына?

Һарут

Беркем бүлми һәм теркәми.
Мин шундый бердәнбер кеше!
Алай ук түгел икән лә—
постта торган канцлерлар,
президентлар, спикерлар,
әмирләр һәм премьерлар,
корольләр, императорлар,
мөфтиләр, далай-ламалар
һәм Рим папалары эше!..

Марут

Кирәк булсаң, сине кайдан,
ничек итеп эзләп табыйм?

Һарут

Йөгәнсез яшәячәкмен!
Йөгәнсезне һәркем таный...

4

Җем-җем йолдыз таң нурында
эри торды берәм-берәм.
Күл өстеннән аккош сыман
ап-ак томан күтәрелә.

Ялтырап торган «Мерседес»
чыкларны коеп кузгалды.
Алтын комда шифр сыман
аның матур эзе калды.

Бераз тынгач, дымлы эзгә
чыгып ятты яшел бака...
Бака халкы кеше шифрын
укый белми әле пока...

Табын булган төп төбендә
ялгыз шешә ята аунап...
Әле генә ни булганын
бетералмый ул да аңлап—

югыйсә бит акыллыны
даһи итә торган шешә!
Аунап ята бит мескенкәй—
әнә нинди хәлгә төшкән...

Чоры шундый! Даһиның да
кадере юк! Бусы—хак сүз.
Алай дисәң, бу шешәгә
Җир шарында иң зур акциз!

Шул вакыт елгыр «Мерседес»
җитте Казан уртасына.
Анда—базар! Рим эчендә
Ватикан дәүләте сыман.

«Мерседес» шунда туктады.
Сатучылар йоклап ята.
Безнең герой чыгып басты—
чибәр, көяз, пөхтә, актан!

Уянды базар, кузгалды
баш бетәрлек ыгы-зыгы.
Һәм башланды фәрештәнең
кешечә яшәү кызыгы.

Очратырбыз әле аны
көтелмәгән урыннарда.
Танырбызмы? Бәлки, бәлки—
йөрәкләрдә күзләр барда.

Бик еш аңа охшаш кеше
очрый, эшли, йә сүз әйтә...
—Сәлам, Һарут!—дип эндәшәм,
—Юк, мин—фәлән!—дип төзәтә.

Ә Марут кайда дисезме?
Марут—тырыш! Өскә үрли...
Шактый кыю, шактый үҗәт,
йомыкый һәм бераз серле...

# ДРАМАТУРГИЯ



Илдар Юзеев

## ЭЗЛӘДЕМ. ТАПТЫМ. ЮГАЛТТЫМ...

ИКЕ АКТЛЫ ДРАМА

**Катнашалар:**

Алмас Уразов—эшкуар, 40 яшьтә.
Таңзифа Уразова—анасы, 70 яшьтә.
Инсаф Уразов—улы, 18 яшьтә.
Чаңбаев Шәмси Корбанович—72 яшьтә.
Халисә Сарманаева—эстрада артисткасы. Прологта—18, вакыйга дәвамында—40 яшьтә.
Айгөл—18 яшьтә.
Сәләх—40 яшьләр чамасы.
Мирхуҗа—төн сакчысы.

**Вакыйга 90 нчы елларда.**

Халисә тавышы:

Без—кешеләр—дөнья көтүчеләр,
Гомер буе нидер көтәбез.
Тал-тирәктәй җилдә бөгелсәк тә,
Егылмыйбыз, сабыр итәбез.
Озак-озак өзелеп көтүләрнен
Ни икәнен үзем беләм мин,
Тик ятларга берни сиздермимен,
Тыштан елмаям һәм көләм мин.
Озак көтеп мин картаям, ахры,
Еллар саргаймыйлар бит алар.
Хатирәләр синнән аерылган
Яшьлегемә алып китәләр.

**Пәрдә күтәрелә. Еракта тал-тирәкләр, каеннар урап алган Казансу манзарасы. Сәхнәнең уң ягында—тал-тирәк. Уртада—Изгеләр чишмәсе. Ул матур итеп бизәлгән—мәрхүм Сөләйман ядкаре.**

**Унсигез яшьлек Халисә бизәкле көянтә-чиләкләрен күтәреп чишмәгә килә. Яшеренгән урыныннан унсигез яшьлек Алмас чыга.**

Алмас *(әкрен генә)*. Халисә...

Халисә. Әбәү, кем бу?

Алмас. Тс-с-с... Кычкырма.

Халисә. Алмас?! Син?

Алмас *(чиләкләрен тотып)*. Әйдә, читкәрәк...

Халисә. Ни булды?

Алмас. Безне беркем дә күрмәсен...

Халисә. Берни аңламыйм.

Алмас. Мин синең белән саубуллашырга килдем.

Халисә. Күзең башкага төштеме?

Алмас. Кит әле, аның кайгысымы?..

Халисә. Миннән суындыңмы әллә?

Алмас. Әй, бәйләнмә әле...

Халисә. Мине калдырып кая китәсең? Укырга бергә китәргә уйладык ич! Мин—театр училищесына, син әтиең юлыннан—тарих бүлегенә...

Алмас. Төкерәм тарихка... Барсына кул селтәп, миңа китәргә туры килә.

Халисә. Кая китәргә?

Алмас. Әлегә үзем дә белмим. Кой чиләгеңне башка... янам. *(Чиләкне иеп башына коя.)* Белмим! Поезд кая алып китсә—шунда!

Халисә. *(Чиләкләрен җиргә куеп.)* Беркая да китмисең! Җибәрмим!

Алмас. Мин җинаять эшләдем.

Халисә. Ышанмыйм! Булмас...

Алмас. Качып котылмасам, мине төрмә көтә!

Халисә. Ни сөйлисең?! Алмас, ни эшләдең?

Алмас. Мин Чаңбаевны кыйнадым. Әйе, әйе, дөмбәсләдем!

Халисә. Ах...

Алмас. Башта аракы шешәләреннән төзи башлаган йортын җимердем. Аннары үзен... Гомер буе җыелган үчне алдым.

Халисә. Нигә? Ник!

Алмас. Үзең дә беләсең. Әтинең газапларда үлүенә гаепле адәм—шул Чаңбаев! Әти үлгәч, әнине үзенә көчләп кияүгә алган—шул Чаңбаев! Анам да гаепле! Аны да кичермим...

Халисә. Алмас, тынычлан, үзеңне кулга ал.

Алмас. Тагын бер минут торсам, мине кулга алачаклар. Сау бул...

Халисә. Бөтенләй ташлыйсыңмыни?

Алмас. Бөтенләйгә түгел, Халисә. Көтсәң, без бергә булырбыз. Көчең җитәрме көтәргә?

Халисә. Гомерем буе көтәрмен, Алмас. Исән генә була күр. Шуны гына әйт: кайчан кайтырсың?

Алмас. Кайчан да кайчан мине эзләүдән туктарлар, шунда кайтырмын. Дөнья бетереп эзләрләр-эзләрләр дә бер вакыт онытырлар. Ул кайтыр, но бу Алмас булмас. Ул баеп кайтыр!

Халисә. Ничек кенә булса да кайт!

Алмас. Минем атамны ярлы булганы өчен гомер буе кимсеттеләр, көн күрсәтмәделәр. Ул үзе дә гаепле инде. Мин аңладым, Халисә, безнең хәзер синең белән энәбез дә юк. Без бергә тормыш корсак та, син кайчан да булса, анам кебек, мине ташлап китәчәксең.

Халисә. Ни сөйлисең, Алмас, юк, юк!

Алмас. Анам да яшь чагында ташламаска вәгъдә биргән... Тормыш—анасын ормыш! Мине эзлиләр, озак торырга ярамый. *(Кузгала.)*

Халисә. Тукта, тагын бер генә сүз...

Алмас. Тотма, мин киттем... Миннән озак кына хәбәр дә килмәс, барыбер көт! Әллә нинди гайбәтләр килер—көт! Өйләнгән дисәләр дә ышанма! Көтеп арысаң—тот та бер картка кияүгә чык!

Халисә. Ахмак!

Алмас. Тагын бер әйт шул сүзеңне!

Халисә. Ахмак!..

Алмас. Үлсәм генә көтмә. Чао, старушка! *(Кочаклап үбә дә ашыгып югала.)*

Халисә. Алмас, бер генә сүз... *(Сәхнә караңгылана.)*

## Беренче акт

**Унсигез елдан соң...**

**Шул ук урын. Уң якта—ауган талтирәк. Сулда—буш шешәләрдән корылган йорт. Җәй көне. Шәмси сәхнәдә сәхнә кора.**

Сәләх *(тирләп-пешеп, әлсерәп керә).* Уф, яндым, харап булдым, беттем!

Шәмси. Ни булды?

Сәләх. Хәзер егылам да үләм!

Шәмси. Өең яндымы?

Сәләх. Юк шул.

Шәмси. Таладылармы?

Сәләх. Юк ла...

Шәмси. Хатының куып чыгардымы?

Сәләх. Лутчы булыр ие...

Шәмси. Милициягә эләктеңме?

Сәләх. Юк! Ычкынды!

Шәмси. Чуртанмы?

Сәләх. Чуртыма кирәкме ул! Пычаксыз суйды! Үзен суясы калган!

Шәмси. Исерекме?

Сәләх. Исеректән дә болайрак! Качты, кабахәт!

Шәмси. Милиция чакырт!

Сәләх. Чөеп кенә ыргыта ул милицияне! Качты дим ич!

Шәмси. Кем качты?

Сәләх. Мирхужа!

Шәмси. Кем соң ул?

Сәләх. Күрмәдегезме?

Шәмси. Бернинди Мирхужаны да белмим.

Сәләх. Таныттыра торган билгеләр: кәкере торба шикелле, ананны сатыйм дип акырып торган ике мөгез...

Шәмси. Әллә үзен исерек инде...

Сәләх. Мирхужа айныткы... качып киткәч... Уф, ардым... *(Ауган тирәккә утыра).* Тагын бер билгесе: кып-кызыл койрыгы елан кебек муенына уралырга тора! Төшенә килеп керсә, куркып качарсың!

Шәмси. Мирхужа булмады бу алайса, җен булды!

Сәләх. Син ни сөйлисең? Нинди җен? Үгез качты! Үгез! Их, бәйләп саласы калган!

Шәмси. Ә... ә... үгез... Мирхужа да Мирхужа дисең...

Сәләх. Авылның Мирхужа исемле үгезе. Күрмәдегезме? *(Тирән сортә.)*

Шәмси. Нишләп Мирхужа?

Сәләх. Безнең Кәкере Елгада Мирхужа исемле тагын бер мир үгезе бар. Мал-туарлы җиде тол хатынга йортка керде. Малын ашап бетерә дә икенчесенә күчә, хәрәсән. Әй хәрамләште дә инде көрәшкәндә... Соңгы тәкәне аяк чалып, сугышып алды, паразит! Егерме тәкә, уникe үгез ашадым дип мактана, салам-торхан! Җиде тол хатын моны тотып... печәргә булгач, читкә китеп олакты. Теге Мирхужа белән дошманнар ие. Күрмәденме Мирхужаны?

Шәмси. Кайсысын?

Сәләх. Икесен дә! Берсен дәүләткә тапшырасы! Икенчесе—аяк чалып мине аста калдырды соңгы сабантуйда. Очратсам, чын көрәшкә чакырам! Иң башта мөгезлесен табарга! Качты бит, качты!

Шәмси. Каян качты?

Сәләх. Ит комбинатына барабыз шулай, тәк. Без ветврач Гатуф белән кәефләнеп кенә кабинада утырган булабыз, бераз төшергән иек, кәничне. Тамак ешшы да сорап кыткылдый бит, малай, ни өчен дигәндә, менә шушы сумкадагы ярты—әтәч булып кычкыра, суккин сын. Туктаттык та шоферны, тәк, авызына токерим, чөмерәбез Гатуф белән прәме богазыннан шешәнең. Ни өчен дисәң, стакан юк инде, тәк, кәничне. Бераз баргач, шофер туктаткан да машинаны, әйтә бит безгә: «Карагыз малны!» ди. Карасак, тфү, бәләгенне чеметим, үгездән җилләр искән. Сикереп төшкән дә сызган, нәкъ шушы тирәдә, без салып утырган урында. Күрмәденме Мирхужаны?

Шәмси. Әллә кызыл иеме?

Сәләх. Точно! Үзе! Алкаш бите кебек кып-кызыл!

Шәмси. Маңгаенда агы бар идеме әллә?

Сәләх. Әй! Әйе! Бар ие!

Шәмси. Юк, күрмәдем шул.

Сәләх. Әй, сине тыңлап торган мин җүләр...

Шәмси. Үгезен койрыгын тоттырыр дип уйлыйсыңмы?

Сәләх. Тота торган җегет басып тора алдында! Тотмаган нәстә калмады. Тирә-юньдә сабантуй батыры дип дан алган, беркемгә дә почти бил бирмәгән Сәләх булыр бу, бик белеп тор, абзыйкай! Мир үгезен озатырга теләсә нинди селәгәй малайны җибәрми персидәтел. *(Кесәсеннән аракы шешәсен чыгара).* Бераз калган әле монда. Кил, әзрәк тамызасыңмы? *(Үзе эчеп куя).* Әгәренки шушы иблис котыртмаса, Мирхужага бирешер иеме Сәләх! Их, шушы булмаса, иң кимендә замминистр буладыем мин! Ну көчле сволочь, мине дә җинә! Кил, сал!

Шәмси. Мин салдым инде саласын. Әнә кара, шешәләрдән йорт салып куйдым.

Сәләх *(торып карый).* Шушы... эчкәч—без ыргытып бәргән шешәләнме?

Шәмси. Нәрсәдән булсын. Заманыбызның алкашларына мәңгелек һәйкәл!

Сәләх. Ну, малай, салгансың? Бер үзең салдыңмы?

Шәмси. Йортны бер үзем салдым. Төзү материалын үзебезнең татар эчкечеләреннән генә җыйдым. Нигездә шушы авылдан. Борынгы Болгарда булганың бармы?

Сәләх. Анын кайгысымы бездә...

Шәмси. Бабайлар калдырган манараларны күргәнең юкмы?

Сәләх. Рәсемдә күргән бар инде анысы.

Шәмси. Милли казанышыбыз саналырлык бу корылманы мин киләчәккә калдырам. Оныклар, бәлки, чит кавемгә иярган татарның ни өчен күтәрелә алмавын, егылуын аңларлар. Профессор Чаңбаев!

Сәләх. Профессор?! Киләчәккә минем дә өлеш керсен. Минем дә тарихта

каласым килә. *(Буш шешәсен бирә).*

Шәмси. Мин инде эшне төгәлләдем. Бер шешә белән эләгерсең микән, ай-һай... *(Ала.)* Патша жәяү йөри торган корылмага булса да файдаланырмын.

Сәләх. Ну даешь, малай. Сөенечтән күз яшьләре атылып чыкты. Мондый әкәмәтне күргән юк ие.

Шәмси. Дөньяда икәү генә. Берсе Японияддә. Пепси шешәсеннән.

Сәләх. Бик арзанга төшкән ич бу, авызына төкерим. Прәме бушлай! Кара, бездәге бу материал белән барлык өйсезләрне өйле итеп була бит! *(Аркасыннан кагып).* Маладис, профессор...

Шәмси *(ошатмады).* Кулыгызны алыгыз... иптәш...

Сәләх. Сә...ләх! Әлегә мин ләх түгел. Ыслушай, профессор, мин сине кайдадыр күрдем бугай. Карале, син нәрсә маташтырасың?

Шәмси. Сәхнә. Бүген монда шушыннан чыккан артистка Халисә Сарманаева концерт бирәчәк.

Сәләх. Сәхнә дисеңме... Яшь чакта абзагыз да жырчы булган. *(Чишмәдән су эчә.)* Коточкыч шәп ие аның тавышы. *(Тырышып.)*

Жидегән чишмәләрдә...

Шәмси. Хәзер буш шешә кебек шылтырый.

Сәләх. Шул мәлгунь харап итмәсә, атказанган әртис буладырыем... Чишмәгә авызны тидергәч, әллә нишләп жырлыйсы килеп китте. Мендер әле мине сәхнәгә. Эт әле арттан. *(Шәмси ярдәм итә.)* Арттан этүче булмады шул, арттан этүче, без дә төшеп калганнардан түгел иек. Без дә жырлаган булган иек сөю жырларын... Менә болай, кулны күкрәккә куйган булып, күзне йомып... *(Жырларга тырыша.)*

Яшьлегем чәчәк атканда
Сине сөйдем, гүзәлем...

Юк, чыкмый. Фермада дуңгыз мыркылдавын тыңлап, үгез артыннан куып узды гомер... Жыр жырланган, маңгай сырланган. *(Сәхнәдән төшә-төшә.)* Иптәшәфәнде пырафессор, үгезне табалмасам, мине персидәтел нишләтер икән?

Шәмси. Үзенне көтүгә үгез итеп куя.

Сәләх. Анысы булмас. Болай да хатын «бозау» дип тирги. Әйт, нишләтә?

Шәмси. Кисә.

Сәләх. Анысы да булмас. Ярты ел инде акча биргәннәре юк.

Шәмси. Үтермәс әле.

Сәләх. Үтерүен үтермәс, үземне дәүләткә тапшырмасын, чукынгыры!

Шәмси. Дәүләтнең төрмәләре шыгрым тулы—урын юк.

Сәләх. Вак-төяк белән эләккәннәргә урын табалар алар. Ыслушай, пырафессор, фамилияң ничек әле синең? Мин сиңа тагын сугылырмын.

Шәмси. Чаңбаев.

Сәләх. Иптәш Чаңбаев! Искә төште: кайда күрдем дисәм, без синең белән яттык...

Шәмси. Айныткычтамы?

Сәләх. Юк. Спесклиникада...

Шәмси. Син анда ничек эләктең?

Сәләх. Блат наркоман да өстен. Шунда санитар булып эшләүче апам салды. Тәк... Син дә, мин дә яшь ул чакта. Син аерым бүлмәдә бер үзең яттың. Икебез дә кабырга белән. Көрәшченең авырткан жирен беләсеңдер: бил, кабырга... Синең кабырганы кемдер сыйпаган и... дөрес эшләгән дигәннәр ие...

Шәмси. Бар, үгезенне эзлә!

Сәләх. Мирхужаны күрсәң, хәбәр ит, иптәш Чаңбаев: Кәкере Елга авылы, «Туры юл» күмәк хужалыгы, Шәмси батыр... *(Чыга.)*

Шәмси. Мирхужаларга сәлам! *(Эшен дәвам итә. Таяк белән кармаланып, сукырайган Таңзифа керә.)*

Танзифа. Авылдашлар, жаннарым, кем дә булса, мине ишетәсезме? *(Шәмси дәшми, әмма һәрбер сүзен игътибар белән тыңлый. Таңзифа чишмә янына килә. Күккә текәлеп.)* Илаһым, зинһар ишетә күр минем ялваруымны, кичерә күр кылган гөнаһларымны! Пәйгамбәрләр затыннан булган изге адәмне авыр хәлдә ташлаганым өчен биргән жәзаңны кабул кылдым: күзләрем сукырайды. Илаһым, соңгы гозеремне ишет: ят жирләрдә адашып йөргән Алмасымны кайтар. Шулай ук исәнлектәүфыйк бир баламның баласы, йөрәгем пәрасы Инсафка. Караңгы төннәрдә барасы юлларына таң нурлары сибә күр. Илаһым, мин гаепле синең каршыңда...

Шәмси *(якынрак барып).* Синең гаебең юк, Таңзифа. Хатаң гына бар.

Танзифа. Һай, кеше бар икән. Тавышың таныш кебек. Нидә хаталандым мин?

Шәмси. Сөләйманга кияүгә чыгып ялгыштың.

Танзифа. Ялгышымны әйт.

Шәмси. Сөләйман яши белмәде.

Танзифа. Аңа ничек яшәргә

кирәк иде соң?

Ш ә м с и. Ул тормыш агымына каршы йөздә, яраклаша белмәде. Тормыш ул—сәхнә, кешеләр анда үзләрен түгел, бөтенләй башка кешене уйныйлар. Диваналар гына шәрран-яра үзләрен ачалар. Сөләйман уйлаганнарны әллә мин уйламадыммы, әллә мин белмәдемме татар халкының бөек тарихлы икәнен? Нигә кирәк иде Сөләйманга безнең Болгардагы Кара пулатның Кырымдагы Хан төрбәсенә охшашлыгын исбат итәргә? Вакытыннан элек кычкырган әтәчнең муенын боралар.

Т а н з и ф а. Чаңбаев! Күзләрем сукырайгач кына, бик соң күзләрем ачылды: менә шулай уйлаучыга кияүгә чыгып, мин ялгышканмын. Мин сине яратмыйча чыктым. Сөләйманны милләтче дип эштән кугач, бик авыр хәлдә калдым шул. Имеш, Алмасымны кеше итәм...

Ш ә м с и. Юлдан язган ул малаенны искә дә алма. Көтмә син аны, кайтмый ул!

Т а н з и ф а. Кайтыр, Алла бирсә... Ул сине күрмәс өчен генә кайтмый читтә йөри, бахырым.

Ш ә м с и. Ярар. Минем эшем бар. *(Сәхнәгә менеп эшли башлый.)*

Т а н з и ф а. Нишлисең анда, исерекләрдән калган шешә җыясыңмы һаман?

Ш ә м с и. Усалланма! Бүген Халисә концерт белән килә. Сәхнә ясыйм.

Т а н з и ф а. И-х, Халисә кызым киләмени? Сагындым үзен. Шигырен, җырын сагындым. Күңел бөтенләй бушап, таштай катып калган чак. Сөләйманны да, ул монда дачада яши башлагач, беренче тапкыр сәхнәдә күргән идем. Тормыш ваклыклары йөрәгемне ураган вакыт иде. Ул югарыда иде, мин менә алмаслык югарылыкта иде. *(Шәмсигә.)* Менәргә ярдәм ит, минем бик аз гына булса да, Сөләйман югарылыгына күтәреләсем килә. *(Шәмси менәргә ярдәм итә.)* Ул сөйләгән шигырьне мин гел күңелемнән сөйләп йөрим.

Гомерем буе тауга-Күккә ашып,
Түбән төшә-төшә ялыктым.
Туктадым да Урал итәгенә,
Йөрәгемә ятып ял иттем.
Ишетелде шул чак серле бер җыр,
Ардым инде, талдым дигәндә:
«Төшсән дә син Җиргә—бик түбәнгә,
Төшә күрмә Җырда түбәнгә...»
Табигатьне, йөрәгемне айкап,
Яшәртте Җыр Җирне-Күкләрне.
Таулар күкрәгеннән чыккангадыр,
Ул мине дә биек күтәрде.

*(Шигырь дәвамында Шәмси әкренләп түбәнгә төшә, ауган тирәккә утырып уйга тала.)* Сөләйман, син шушында гына ятасың ич. Ишеттеңме? Уян, бәгърем, кичерә күр мине. *(Шул сүзләрне кабатлап, югарыдан төшә, Шәмсинең биргән кулын алмый.)* Кичер мине, Сөләйман... *(Чыга. Шәмси тирән уйда. Шул вакыт Алмасның тән сакчысы Мирхуҗа килеп керә. Ул килбәтсез олы гәүдәле, сакал-мыек үстергән. Күн тужуркадан. Ымлыклар белән генә сөйләшә. Тирә-якны барлап чыга, сәхнә асларындагы өсләрен тикшерә, чишмә тирәсен карый. Сәләх бушаткан шешәне алып, иснәп карый да чишмә ташына бәреп вата. Шәмсине күреп, аның янына килә.)*

Ш ә м с и *(торып, әдәпле генә кулын бирә.)* Чаңбаев!

М и р х у ж а *(кесәсен капшап).* Кит!

Ш ә м с и. Аңламыйм.

М и р х у ж а. Ычкын!

Ш ә м с и. Ни әйтергә телисез?

М и р х у ж а. Сыз!

Ш ә м с и. Әллә үгез киләме?

М и р х у ж а. Шым!

Ш ә м с и. Төшендем. Затлы машина килеп туктаган. Белдем—олы хуҗа килгән. Обкомда бүлек мөдире булып эшләдем. Профессор Чаңбаев!

М и р х у ж а. Тай!

Ш ә м с и. Мин моннан китмим. Минем дачам монда...

М и р х у ж а. Тәгәрә! *(Көч кулланып, Шәмсине чыгара. Сәхнә артында тавышлар.)* Чиген! Артка! *(Чыга.)*

Х а л и с ә т а в ы ш ы:

Без очрашкан, без аерылган урын—
Елга ярындагы тал-тирәк,
«Әллә кайта микән?» дигән кебек,
Җил искәндә куя калтырап.
Әйтә йөрәк: «Алай ашыктырма,
Газаплама, мина ял кирәк.
Күрәсеңме, сабыр итәлмәгән,
Усал җилдә ауган тал-тирәк...

**Кич. Эңгер-меңгер.**

Х а л и с ә *(сәхнәдә).* Исәнмесез-саумысыз, авылдашлар, туганнар, апалар, сеңелләр, абыйлар, энеләр! Иштирәктә һаман клуб булмагач, мин сезне Казансу буена чакырдым инде. Рәхмәт сезгә, килгәнсез. Әйдәгез, бүген барыбызга да кадерле булган Сөләйман абый Уразовны искә алыйк. Искиткеч кеше иде ул. Юкка гына без аны читтән алып кайтып, менә монда—Изгеләр зиратына җирләмәдек. Үзегез дә беләсез, шагыйрь булмаса да, ул җаны белән шагыйрь иде. Менә сезгә дә бер шигырен исегезгә төшерим:

Чит җирләрнең салкын туфрагы да
Якын күрә мине, үз итә.
Синнән башка туңган күңелемә
«Көтәм!» дигән тик бер сүз җитә.
Син яшәгән җирнең җылы җилен
Сулышларым белән тартырмын.
Өметенне өзеп, көтмәсәң дә,
Онытсаң да, барыбер кайтырмын.

*(Кинәт ут сүнә.)* Нишләп ут сүнде? Кем сүндерде? Борчылмагыз, мин аны ут кабынганчы сөйли торам. *(Соңгы юлны кабатлап әйтә.)*

Онытсаң да барыбер кайтырмын!

Алмас *(соңгы юл әйтелү белән, караңгыдан).* Мин кайттым!

Халисә. Кем ул? Мин күрмим.

Алмас. Танымыйсыңмы?

Халисә. Тавышың таныш кебек...

Алмас. Иске танышыңны оныттыңмы?

Халисә. Кем соң син?

Алмас. Мин сүземдә тордым. Син боздыңмы әллә вәгъдәңне?

Халисә. Берни аңламыйм.

Алмас. «Көтәм» дигән сүзеңне кемгә әйттең?

Халисә. Әллә төш күрәм инде?..

Алмас. Димәк, «көт, кайтам» диючеләр мин генә түгел?

Халисә. Нигә соң син күренмисең?

Алмас. Син дөрес әйтәсең: мин күренми торган адәм идем! Хәзер син мине күрерсең! Барс! Ут! *(Машина фарасының уты сәхнәне яктырта. Сәхнәнең бир читендәге креслода заманча затлы киенгән, сакал-мыек үстергән Алмас утыра. Аннан читтәрәк аның тән сакчысы Мирхуҗа урнашкан.)* Халисә, мине әле дә танымыйсыңмы? *(Пауза.)* Кайчан да кайчан мине эзләүдән туктарлар, кайчан да кайчан мине онытырлар, ул кайтыр... но...

Халисә. Алмас?!

Алмас. Таныдың тәки? *(Сәхнәгә сикереп менә.)* Чао, старушка!

Халисә. Үз күзләремә үзем ышанмыйм. Чыннан да синме бу, Алмас?

Алмас. Алмаска охшамаганмыни?

Халисә. Танырлык та түгел. Үзгәргәнсең.

Алмас. Дөнья үзгәртә адәм баласын. Син үзгәрмәгәнсең дияр идек. Мине күргәч нишләптер куркып калдың. Син шат түгел кебек...

Халисә. Үзем дә белмим. Каушап калдым әле.

Алмас. Әйт, син шатмы, түгелме? Мине оныттсаң, дөресен әйт!

Халисә. Онытмадым, Алмас.

Алмас. Ышанмыйм. Нишләп, алай булгач, кочакламыйсың көткәнеңне?

Халисә. Халык алдында... оялмыйча...

Алмас. Халык юк. Бу концертның бары минем өчен!

Халисә. Чыннан да... Ут кабынгач, карасам: ике генә кеше. Кем ул әнә тегесе... әллә нинди адәм?

Алмас. Төкер! Ул кеше түгел. Аны юк дип сана.

Халисә. Ул бездән күзен алмый.

Алмас. Һөнәре шул. Минем тән сакчысы. Әфганчы. Ә син—минем җан сакчысы бул! Барс, югал! *(Мирхуҗа китә.)*

Халисә. Ә халык кайда?

Алмас. Мин кусам китә, мин чакырсам—килә халык. Безнең бәхетле очрашуны карап тормасыннар. Кудым әлегә. Йә, сагындыңмы мине, Халисә?

Халисә. Безне очраштырган әнә теге тирәк сине көтә-көтә түзәлмәде, сынды. Мин саргайдым гына. Ә син үзең?

Алмас. Мин дә сынмадым, Халисә! *(Кочаклашалар.)*

Халисә. Кара, чәчләрең агарган ич... Күзләрең һаман да чем каралар...

Алмас. Синең күзләреңнең зәңгәр икәнен әле генә күрдем... Яшь чакта күрмәгәнмен.

Халисә. Бабай булгансың.

Алмас. Заманнан артта калып булмый. Акыл үстереп булмагач, сакал үстердем. Ә сакаллы адәмне акыллыга санийлар. Ни эшләсәң шул килешә...

Халисә. Өйләнмәгән егеткә... дисеңме. Чынлапмы?

Алмас. Законлы хатыным юк.

Халисә. Законсызлар?

Алмас. Алар белән шаярырга вакытым юк. Мин эш кешесе.

Халисә. Син кем соң? Бик зур начальникмы? Тән сакчысы белән генә йөрисең...

Алмас. Мин настоящий алмас! Мине беркем бөгә дә, сындыра да алмый. Беркем кимсетә, өркетә, куркыта алмый! Һәм сине дә! Мескенлек, коллык бетте!

Халисә. Сине көтә-көтә картаеп беттем, Алмас.

Алмас. Миңа ошый болай картаюың. Мин Иштирәккә сине яшәртү өчен кайттым, Халисә!

Халисә. Яшәрт инде, алай бик теләгәч...

Алмас. Яратканын унсигез ел көткән артистка Халисә Сарманаева шушы сәләмә сәхнәдә жырларга тиешме? Барс! Келәм! *(Мирхужа сәхнәгә затлы келәм җәя.)* Барс! Чемодан! *(Мирхужа заграничный чемоданны Алмас алдына куя да, хужасы кул селтәгәч, чыга. Чемоданны ачып.)* Сиңа! Мине көткәнең өчен! Хәзер мин халыкны чакыртырмын! Әтием яраткан жырны жырларсың, аңладыңмы? *(Халисә чемоданны алып чыга.)* Барс!

Мирхужа. Ау!

Алмас. Чакыр халыкны! *(Магнитофоннан музыка җибәрә.)* Халык, жыелдыңмы? Сәлам! Тамак туйдымы? Сыйландыгызмы? Кем куйды сезгә импортный эчемлекләрне и закускаларны дисәгез, мин-Уразов булырмын! Бу фамилия таныштыр сезгә. Яхшы беләсез дип уйлыйм сездә дача салып алып яшәгән Сөләйман Уразовны! Сез минем үземне танымыйсыз, кәнишне. Без үзебез Алмас Уразов, то есть Сөләйманның улы булабыз. Кайберегез может хәтерли торгандыр, мин әтинең дачасында тордым. Казансуда вак-төяк балык тоттым. Инде килеп мин, үлгәч кенә булса да, исән чакта кадер күрмәгән атамны хөрмәтләргә кайттым. Анысын үзегез күрерсез ничек икәнне. В то же время сез дә атамны үлгәч кенә булса да тоже монда Изгеләр зиратына алып кайтып жирләдегез, анысына да рәхмәт. Үзегезгә билгеле, атамны исән чакта типкедә йөрттеләр, юк, сезне әйтмим, аның коллегаларын сөйлим. Эшеннән кудылар, язган эшләрен басмадылар, янәсе дә милләтче дип... Ул, өметен өзеп, Йошкар-Олага китте, шунда жан бирде. Мин аның китапларын бүгенге көндә печатать итеп, сезгә алып кайттым. Барс! Тарат халыкка! Бушлай! Инде бу сәхнәгә чакырам Иштирәкнең генә түгел, татарның известный артисткасын—Халисә Сарманаеваны! Кул чап! Халисә, чык! Покажись! *(Музыка, кул чабулар.)* Хатынкыз шулай киенергә тиеш! Европаның иң соңгы модасы! Халисә, балкы! *(Затлы киемнәр кигән, зиннәтле алка-төймәләр таккан Халисә сәхнәгә чыга.)* Минем заявка! Атамның яраткан жырын! *(Аска креслога төшеп утыра.)*

Халисә *(прожектор нурында балкып жырлый).*

Урманнарга кереп кисеп алдым
Дугалыкка диеп төз элмә.
Йөрәккәем бигрәк түзем лә.
Гомер язларында аерылдык,
Очраштык тик гомер көзендә,
Яз да, көз дә чагыла йөземдә.

Әллә хәсрәт, әллә сөенечтән
Ике яшь бөртеге күземдә,
Йөрәккәем, чыда, өзелмә.

Кыңгыраулар булып яшьлек калды,
Чынлап калды гомерем эзендә.
Йөрәккәем, түз лә, өзелмә...

*(Кул чабулар.)*

Алмас. Халисә, нигә әле син бүгенге шатлыклы көндә хәсрәтеңне халыкка жырлап торасың. Биеп жибәр әле бер яшь чагыңдагы кебек, авылларын селкетеп! Халык! Давай, кул чап! *(Кул чабулар.)*

Халисә. Юк, Алмас, хәзер булдыралмыйм...

Алмас. Мин сорыйм! Музыка! *(Бию көе уйнала. Халисә соңгы чиккә житкәнче бии дә, хәле бетеп егыла һәм йөзтүбән капланып елый... Алмас сәхнәгә йөгереп менә, Халисә янына килә.)* Халык! Тарал! Барс! Сыйла! Ни булды, Халисә, әллә инде елыйсың? *(Күтәреп торгыза.)*

Халисә. Күңелем тулды...

Алмас. Әйдә төшик моннан, ял ит.

Халисә. Ә концерт... анда... минем иптәшләр...

Алмас. Мин әйттем: концерт тәмам. Иптәшләрең сәхнәгә чыгып тормасыннар. Менә аларның өлешен үзләренә бирерсең. *(Акча төргәген суза.)*

Халисә. Шул кадәр акча... безнең күргән дә юк...

Алмас. Минем белән булганда күрерсең. Мин әйткәч, ал!

Халисә. Рәхмәт.

Алмас *(аска төшеп).* Бир кулыңны.

Халисә. Хәлсезләнеп киттем. *(Төшкәндә туктап.)* Кала бит...

Алмас. Нәрсә?

Халисә. Келәм.

Алмас. Түкер. Миндә ул миллион... Артистларыңа бир. Әйдә, чишмә янына. Су эчеп жибәр.

Халисә. Рәхмәт, Алмас. *(Башын Алмасның жилкәсенә куя.)*

Алмас. Тынычландыңмы инде?

Халисә. Эчкәч хәл кереп китте... Сөләйман абый матурлаган чишмә.

Алмас. Әти—дурак. Ике айлык хезмәт хакын суга салды.

Халисә. Гажәеп бит. Тыңла аның чылтерәүләрен... Читтә йөргәндә төшләреңә кергәндер инде, шулаймы?

Алмас. Анда, Халисә, не только аның турында уйлау, төш күрергә дә вакыт булмады.

Халисә. Мин сине төшемдә гел яшь итеп күрдем. Берсен сөйлимме? Испаниягә барганбыз, имеш...

Алмас. Мин чыннан да анда бардым.

Халисә. Мин стадионда утырам. Ә син мәйданда тореодор... Кызыл материя тоткансың да үгезгә каршы барасың. Менәменә сине үгез сөзә дигәндә, уяндым...

Алмас. Мин үзем сөзәм хәзер! Беркем каршы тора алмый. *(Кулындагы магнитофонны кабыза, аннан Халисәнең җыры ишетелә.)*

Әллә хәсрәт, әллә сөенечтән—
Яшь бөртеге ике күземдә,
Йөрәккәем, чыда, өзелмә.

Халисә. Кара, язып та алгансың.

Алмас. Кассета ясатып миргә таратам әле мин синең тавышыңны...

Халисә. Алмас, чынлапмы?

Алмас. Син әле һаман җырлап кына йөрисеңме?

Халисә. Ярты гомерем сәхнәдә узды.

Алмас. Тамак туйдырырлык сәмән бирәләрме соң? Ничә лимон?

Халисә. Төрле чак була инде. Чәйне лимонсыз гына эчәргә туры килә.

Алмас. Моннан соң Халисә Сарманаеваның дөньяның төрле почмакларында ишетерләр. Кассета саткан табышның яртысы—үзеңә! Доллар белән!

Халисә. Шаяртма.

Алмас. Шаярмыйм. Дөньяның күп кенә нокталары минем кулда.

Халисә. Яшь чагына охшап калдың. Мактанырга ярата идең.

Алмас. Мин башка Алмас хәзер. *(Кесә телефонын ала.)*

Халисә. Нәрсә бу?

Алмас. «Эрикссон». Дөньяны кулда тота торган аппарат.

Халисә. Яшь чакта алдауларыңа рәхәтләнеп ышана идем...

Алмас *(номер җыеп)*. Истамбулмы? Әссәламәгаләйкем, Нурхан бей? Минем товар үтәме? Эшләр майлаган кебек бара? Хуп! Афәрин! *(Тагын номер җыя.)* Хельсинки? Кадыйр әфәнде, сезме, йөрәк маем? Миңа нинди сорауларың бар? Анысын миннән сорап та торма, үзең хәл ит! Мин сиңа ышанам. Миннән фатиха. Хуш, канәтем.

Халисә. Хәзер инде ышандым. *(Кайдадыр шартлау.)*

Алмас *(сикереп тора. Ул үзен гел киеренке тота, сөйләшкәндә вакыт-вакыт тирә-ягына карап ала.)* Барс!

Мирхуҗа *(кереп)*. Ау!

Алмас. Нинди шартлау? Тикшер!

Мирхуҗа. Момент! *(Чыга.)*

Халисә. Синең җаның тыныч түгел...

Алмас. Арылды.

Халисә. Әйт Алмас, син кем соң?

Алмас. Үзебезчә әйткәндә: Бай абзый! Яңа татар. Өр-яңа! Кайберәүләр малтабар да дип җибәрәләр. Ягъни дә мәсәләң, мал артыннан чабучылар.

Халисә. Шулай бик баймыни син?

Алмас. Бай, бик бай, Халисә! Син миннән ни телисең, шуны сорый аласың. *(Шәмси салган йортны карап.)* Бу нинди йорт?

Халисә. Буш шешәләрдән салынган.

Алмас. Шәп товар. Хуҗасы кем?

Халисә. Чаңбаев.

Алмас. Шул мин кабыргасын сыйпаган Чаңбаевмы?

Халисә. Шул.

Алмас. Ул әле исәнмени?

Халисә. Исән.

Алмас. Кеше гомерен кыскартучылар озак яшиләр. Үзе шунда яшиме?

Халисә. Дача йортында тора. Монысы—сату өчен.

Алмас. Әтинең үлеменә сәбәпче адәмнәрнең берсе.

Халисә. Алай ук түгел инде. Яши белеп яшәүче.

Алмас. Иң авыр чакта әтине якламады. Обкомда эшләвеннән файдаланып, әни дигән кешене үзенә алды.

Халисә. Алмас, нигә әни исәнме дип сорамыйсың?

Алмас. Аның исән булуы-булмавы мине кызыксындырмый. Әтигә хыянәтен мәңге кичермәм.

Халисә. Ул исән. Күзләре сукырайды.

Алмас. Ну и что? Мине менә бу сарай и аның хуҗасы кызыксындыра.

Халисә. Әнә үзе дә шунда йөри. *(Шәмси күренә. Балта белән нәрсәгәдер суга. Алмас сискәнеп, сикереп тора.)*

Алмас. Барс!

Мирхуҗа *(кереп)*. Ау! *(Шәмсигә таба бара.)*

Халисә. Зинһар тимәгез аңа! Ул карт инде. Алмас, тынычлан...

Алмас. Барс! Кире борыл! *(Мирхуҗа китә.)* Әй, син, монда кил әле!

Халисә. Алмас, бәйләнә күрмә.

Алмас. Мин ана тырнак белән дә кагылмам.

Халисә. Үзе бәйләнсә...

Алмас. Сонга калды... Хужа, кил минем янга!

Халисә. Бу киемнәрдән күренергә уңайсыз... *(Бер читкә китә.)*

Шәмси *(керә)*. Хәерле көннәр, Алмас Сөләйманович!

Алмас. Сәлам, Чаңбаев! Кил, якынрак кил.

Шәмси. Әлегә колакларым әйбәт ишетә. Аллага шөкер.

Алмас. Аллага ышанасыңмыни?

Шәмси. Мин элек тә күңелемнән ышана идем.

Алмас. Ялгышмасам, син коточкыч атеист иден?

Шәмси. Заманы шундый иде. Сезнең кебек игелекле бер бизнесмен Иштирәккә мәчет салып куйды. Әнә... шунда йөрим. Әмма халык бизгән, килүчеләр берике генә.

Алмас. Мактыйм. Заман белән бергә атлыйсың. Кабыргаларыңның җидесе дә исән-саулармы?

Шәмси. Әй, искә төшермик инде, оныттыйк...

Алмас. Бу сарайны үзең эчкән шешәләрдән кордыңмы?

Шәмси. Алла сакласын... Яшь чакта бераз капкаладым. Карт кешегә—гөнаһ.

Алмас. Минем янга якынрак кил, Чаңбаев... Нигә куркасын? Син бывший Чаңбаев булсаң да, мин элекке Алмас түгел. Син аласыңны алдың.

Шәмси. Тән ярасы онытыла, Алмас Сөләйманович...

Алмас. Тел яраларын мин онытмыйм, но мин үч алырга кайтмадым. Бу өеңне сатасыңмы?

Шәмси. Сезнең кебек хөрмәтле кешеләр белән килешергә булыр дип уйлыйм.

Алмас. Мин аны алам! Барс! Чемодан! *(Мирхуҗа дипломат алып керә.)* Мә!

Шәмси. Күпме?

Алмас. Йөз миллион.

Шәмси. Йөз миллион?

Алмас. Азсынасыңмы?

Шәмси. Мин алай ук сорарга батырчылык итмәс идем.

Алмас. Мин беләм, сезгә галимнәргә лимонны төштә генә күрергә туры килә.

Шәмси. Минем хәл ярыйсы әле. Кайбер коллегаларым тамак ялына чит илгә китте. Дворник булып эшләүчеләр дә бар, Алла сакласын...

Алмас. Сине Алла саклар. Дворник булмассың... Ал!

Шәмси *(шикләнебрәк)*. Шаяртмыйсыңмы? Чынлапмы?

Алмас. Яңа гына станоктан чыгып банкка кергән, буявы да кипмәгән. Барс! Оформить итсеннәр! Барыгыз! Тукта!

Шәмси. Тыңлыйм, әфәндем.

Алмас. Син пенсиядәме?

Шәмси. Профессор буларак ипитозлык бирәләр.

Алмас. Мескен профессорлар, гомерегезне укып, интегеп әрәм иткәнсез. Заман кая бара: бизнеска хезмәт итмәгән акыл белән яшәп булмый хәзер. Дөньяның тоткасы—акча, чамаладыңмы? Кемнең арты тегермән тарта ди әле татар?

Шәмси. Көчленеке. Кызганыч, әмма факт.

Алмас. Шушы миңа саткан өйнең каравылчысы буласың. Хезмәтең өчен мин хуҗа—түлим.

Шәмси. Риза!

Алмас. Сыпыр! *(Шәмси белән Мирхуҗа чыгалар.)* Халисә, кил!

Халисә. Сугышып китмәсеннәр дип котым очып торды.

Алмас. Хәзер ул минем кулда. Мин ни телим, шуны эшләячәк. Халисә, бу сарай—синеке!

Халисә. Кит аннан, мин анда нишлим...

Алмас. Безнеке! Ял итә торган резиденция! Барс! *(Мирхуҗа пәйда була.)* Тойотаны әзерлә! Югал! *(Теге китә.)* Халисә, жаның кая тели-шунда алып барам? Әйт, кая китәбез?

Халисә. Ин башлап әниеңнең хәлен белик. Борчылам. Концертта да күренмәде.

Алмас. Юк, ана—беркайчан да!

Халисә. Алмас...

Алмас. Исемен телгә алма.

Халисә. Хәзер Изгеләр зиратына, Сөләйман абыйга... керик.

Алмас. Төп максатымның берсе—шул. Мин аны мәңгеләштерергә кайттым. Башта Казансу буйларын әйләник. Тагын кемнәрне күрергә?

Халисә. Баланны.

Алмас. Тагын бер кабатла әле...

Халисә. Баланны.

Алмас. Нинди бала?

Халисә. Үзеңнең балаң.

Алмас. Минем балам? Ничек инде?

Х а л и с ә. Икебезнен балабыз.

А л м а с. Халисә, шаярма.

Х а л и с ә. Бала белән шаярмыйлар.

А л м а с. Валлаһи дин.

Х а л и с ә. Үзең дә ышанырсын.

А л м а с. Исеме ничек?

Х а л и с ә. Инсаф.

А л м а с. Фамилиясе?

Х а л и с ә. Әлбәттә Уразов.

А л м а с. Кемгә охшаган?

Х а л и с ә. Нәкъ Сөләйман абый.

А л м а с Кызмы?

Х а л и с ә. Малай.

А л м а с. Малай?

Х а л и с ә. Ир бала.

А л м а с. Аңа ничә яшь?

Х а л и с ә. Унсигез.

А л м а с. Халисә, ни җаның белән шуны әйтми торасың? Минем унсигез яшьлек малаем бар! Уразовларның нәселе корымаган! *(Кесә телефонын ала.)* Егетләр! Ура! Мине монда малаем көтеп торган. Котлагыз! Мичкәләрне тәгәрәтә башлагыз! Пир на весь мир! Миннән—йөз кешелек банкет! Сәлам! Рәхмәт! Халисә, ник син моны очрашкач та әйтмәден?

Х а л и с ә. Курыктым.

А л м а с. Нидән? Баладан баш тартыр дип уйладыңмы?

Х а л и с ә. Андый уй да булгандыр. Мин бит әле сине белмим. *(Шартлау . Алмас сискәнеп сикереп тора.)* Барс! *(Мирхуҗа керә.)* Кем атты?

М и р х у җ а. Мин. Котырган эт ташланды.

А л м а с. Пистолетка тотынма дип мин әйттем! Бар! *(Теге чыга.)* Их, Халисә, син мине бәхетле иттен. Чыннан да, баш тартыр дип уйладыңмы?

Х а л и с ә. Хәзер тынычландым.

А л м а с. Барс, өстәл! Аля-фуршит! *(Мирхуҗа тәгәрәтеп өстәл кертә. Шәраб коеп.)* Балабыз хөрмәтенә! Яшәсен Уразовлар һәм дә... Халисә Уразова! Инде, Халисә-җан, туп-туры Инсаф янына китәбез! Танышсын үз әтисе белән. Үзен ятим итеп тоймасын!

Х а л и с ә. Алмас, ул юк...

А л м а с. Ничек... юк?

Х а л и с ә. Әлегә Инсафның рәсемен генә күрә аласың. Менә... *(Фоторәсем ала.)* Менә...

А л м а с *(карап)*. Минем балам... Инсаф... Әллә... үлдеме?

Х а л и с ә. Исән... исән...

А л м а с. Кайда ул?

Х а л и с ә. Аны армиягә алып киттеләр.

А л м а с. Кайчан?

Х а л и с ә. Ике ай элек.

А л м а с. Их, Халисә...

Х а л и с ә. Ул киткәннән бирле йокы күргәнем юк.

А л м а с. Хаты килдеме?

Х а л и с ә. Килде шул...

А л м а с. Нигә «шул»?

Х а л и с ә. Соңгы хатында «безне Чечняга җибәрделәр» дип язган.

А л м а с. Анда бит үтереш...

Х а л и с ә. Хәбәрләр тыңлаган саен тетрәнәм. Харап кына итмәсәләр ярый инде балакайны...

А л м а с. Артык борчылма. Мин егетләргә хәбәр бирермен. Коткарырбыз.

Х а л и с ә. Коткара күр, Алмас.

А л м а с. Мин бик вакытында кайтканмын.

Х а л и с ә. Унсигез елдан соң...

А л м а с. Әле соң түгел. Туй ясыйбызмы?

Х а л и с ә. Картаеп беткәчме?

А л м а с. Без әле яшь генә башлыйбыз, Халисә. Кайда яшисен килә?

Х а л и с ә. Инсаф кайтмыйча хәл итә алмыйм.

А л м а с. Өчәүләп хәл итәрбез. Инсафның соңгы адресы бармы?

Х а л и с ә. Бар. Үзем белән. *(Бирә.)* Менә. Укы.

А л м а с. Борчылма. Эзенә төшәрбез. Дөнья Алмаслар кулында! *(Телефонда номер җыя.)* Серега, сәлам! Синен ярдәмен кирәк. Минем малайны коткарырга кирәк. Ут эченә җибәрәләр. Уразов Инсаф. Адресы: хәрби часть... *(Шул вакыт үгез үкергән тавыш ишетелә. Сискәнеп.)* Нәрсә бу?

Х а л и с ә. Үгез! Кызыл үгез!

А л м а с. Үкереп безнең өскә килә! Якыная...

Х а л и с ә. Ой! Мин куркам, нишлибез, Алмас?

А л м а с. Мин барында курыкма, Халисә... *(пистолетын чыгара.)*

С ә л ә х *(йөгереп керә)*. Тотарга ярдәм итегез! Безнең качкан үгез ул! *(Алмас янына килә, атарга җыенганын күреп, пистолетына ябыша.)* Зинһар, атма! Дәүләткә тереләй тапшырасы үгез. Атма! Ату минем үземне пычаксыз суеп, җиде кат тиремне туныйлар!

А л м а с. Халисә, әйдә машинага! Барс! «Тойота»! *(Ашыгып чыгалар.)*

## Икенче акт

**Шул ук урын. Июль ае. Шул ук көнне. Кич. Чишмә буе электр белән яктыртылган. Тирә-ягына карана-карана, кача-поса Инсаф керә. Кеше юклыкны шәйләп, чишмә янына килә. Йотлыгып су эчә, битләрен чылата. Котелогына су ала. Кемдер килгәнне күреп, ауган тирәк артына кача. Айгөл керә.**

Айгөл *(алдындагы сәхнәне күреп)*. Ой, сәхнә! Мөгаен, Халисә апа килгән! Казанда йөреп мин соңга калганмын. Әллә килеп житмәде микән әле? Сәхнә! Хыялым минем! Менә мин, каушый-каушый, дулкынлана-дулкынлана, сәхнәгә күтәреләм... *(Әкрен генә сәхнәгә күтәрелә.)* Тамашачылар мине көтәләр, кул чабып каршылыйлар. Мин сәхнә уртасына басам да хөрмәтләп башымны иям. Кайсысы үтемлерәк булыр икән дип, сөйлисе шигырьләремне күңелемнән барлап чыгам. Менә монысын, Сөләйман Уразовныкын...

«Сөясеңме мине?» дип сорыйсың.
Андый төче сүзләр, юк, әйтмәм.
Күзләреңә сүзсез карауларның
Хатирәсен мәңге югалтмам.
Матур сүзләр очып югалалар
Усал жилләрендә язмышның.
Сине генә өзелеп сөюемне
Әйтми калдым, бик тә ялгыштым.
Син йөрисең кайсы тарафларда,
Нинди хәбәр килер ул яктан?
Гомерем буе эзләп таптым сине,
Юк, югалтмам, сине, югалтмам!

Инсаф *(тирәк артыннан)*. Айгөл!

Айгөл. Ой! Кем дәшә миңа?

Инсаф. Монда кил.

Айгөл. Син кем?

Инсаф. Танырсың...

Айгөл. Мин белмәгән кеше янына бармыйм.

Инсаф. Күп сөйләшмә, тизрәк кил...

Айгөл. Кем икәнеңне әйтсәң барам... *(Үзе, әкрен генә сәхнәдән төшеп, Инсафка таба бара, аны күреп туктап кала.)*

Инсаф. Миннән курыкма, Айгөл.

Айгөл. Инсаф? Синме бу?

Инсаф. Әйе. Мин.

Айгөл. Сәламә киемнәр. Тавышың карлыккан. Ябыккансың.

Инсаф. Әйе, мин тудырган анам да танымаслык.

Айгөл. Үз күзләремә үзем ышанмыйм. Инсаф, ни булды?

Инсаф. Шулай... Язмыш жилләре какты.

Айгөл. Син бит армиядә... солдат...

Инсаф. Мин хәзер солдат түгел.

Айгөл. Котлыйм, Инсаф! Ура! Сине кайтардылар?

Инсаф. Тс-с-с... шаулама...

Айгөл. Хәзер үк документларыңны үзең теләгән тарих факультетына илтеп бирәбез! Бик вакытлы кайткансың.

Инсаф. Бу—мөмкин түгел...

Айгөл. Сине ялга гына кайтардылармы? Ничә көнгә?

Инсаф. Юк. Мин ялга кайтмадым.

Айгөл. Әллә авырып киттеңме? Дәваланырга кайттыңмы?

Инсаф. Дөресен әйткәндә...

Айгөл. Дөресен әйт...

Инсаф. Мин кайтмадым... бөтенләй кайтмадым.

Айгөл. Берни аңламыйм.

Инсаф. Мин дезертир.

Айгөл. Шаяртма миңе, Инсаф.

Инсаф. Мин... армиядән качтым.

Айгөл. Син... качтың? (Утыра.) Качтың?! Ышанмыйм...

Инсаф. Ышанма. Әмма бу факт.

Айгөл. Ничек качтың?

Инсаф. Мин хезмәт иткән частьны Чечняга илтеп тыктылар. Дошман дип мишеньга атарга боердылар. Күзләремне йомып аттым. Янына бардым: аккош кебек ак күлмәкле чечен кызы кан эчендә ята. Күз алдымда кан, кан... Гаепсез, гөнаһсыз кеше каны... Түзәлмәдем, автоматны ташлап, качып киттем...

Айгөл. Сиңа... нәрсә булыр?

Инсаф. Трибунал.

Айгөл. Сине эзлиләрме?

Инсаф. Эзлиләр.

Айгөл. Нигә монда кайттың соң?

Инсаф. Бабам белән киңәшергә...

Айгөл. Зираттагы бабаң белән?

Инсаф. Ни генә кылсам да, мин аның белән киңәшәм. Минем урында ул нишләр иде микән дип уйлыйм.

Айгөл. Бу юлы ул сине хупламастыр.

Инсаф. Тыныч халыкны аткан, кырган өчен, «дөрес эшлисең, Инсаф!» дип әйтер идеме? Юк!

Айгөл. Син бит... хәрби антыңны бозгансың...

Инсаф. Мин аны үзем дә беләм! Кит! Юкны сөйләмә! Син дә мине аңламагач... *(Кузгала.)* Мондый черек

армиянен уставын мин танымыйм!

**Айгөл.** Инсаф, тукта, ачуланма... Аптыраганнан әйтүем.

**Инсаф.** Әнием, әбием исәнсаулармы?

**Айгөл.** Исәннәр. Аларга хәбәр итимме?

**Инсаф.** Нинди хәбәр... Бу аларга сөенеч түгел. Беркемгә бер сүз әйтмисең.

**Айгөл.** Хәзер нишлибез, Инсаф?

**Инсаф.** Үзем дә белмим. Беркемгә күренмәскә...

**Айгөл.** Син болай да адәмгә күренерлек түгел. Инде караңгы. Халык печән әзерли. Монда килүче булмас. Син ачтыр бит? Ашарга алып килимме?

**Инсаф.** Үзеннең хәлләр ничек, Айгөл?

**Айгөл.** Әле генә Казаннан кайттым. Театр училищесына керергә йөрим. Августта имтиханнар. Шигырьне тыңладың әллә? Шуны әзерлим. Ә син?

**Инсаф.** Миндә университет кайгысы юк. Мин зиратка керәм, Айгөл...

**Айгөл.** Кермә анда... керә күрмә. Анда... куркыныч.

**Инсаф.** Миңа тере адәмнәр куркынычрак. Анда тып-тын. Анда мине аңлый торган затлар ята...

**Айгөл.** Анда сине эзләмәсләр дә... Аңладым. Ашарга нәрсә алып килим, Инсаф?

**Инсаф.** Бер бөтен ипи. Чишмәдә су бар. Башка берни дә кирәкми. Мин сине шушында көтәрмен.

**Айгөл.** Сак бул, Инсаф.

**Инсаф.** Кара аны, аны-моны сиздерә күрмә...

**Айгөл.** Борчылма, Инсаф.

**Инсаф.** Кәккүк булып миңа бер тапкыр кычкырырсың.

**Айгөл.** Ярар. Көт. *(Кәккүк булып кычкыра.)*

**Инсаф** *(җавап бирә)*. Мин сине күрергә дә кайттым, Айгөл... *(Зират ягына китә.)*

**Айгөл.** Мин хәзер киләм! *(Чыга. Алмас белән Халисә керәләр. Халисә киемен джинсыга алыштырган.)*

**Алмас.** Йә, Халисә-җан, икәү генә «Тойота»да гулять итү ошадымы?

**Халисә.** Рәхәтлек диңгезендә йөздеммени... Алмас, әйдә, утырыйк әле. *(Тирәккә утыра.)* Мин бик ардым, Алмас.

**Алмас.** Мине көтепме?

**Халисә.** Сине көтеп тә... Артист тормышын син әле белеп бетермисең...

**Алмас.** Чәбәкәй итүгә алданып йөрисез инде.

**Халисә.** Төрле чаклар була. Күчмә тормышның авырлыклары күп инде аның. Ягылмаган клублар. Буранлы-яңгырлы көннәр-төннәр, ачлы-туклы яшәү дигәндәй. Ашказан бозылып бетте инде...

**Алмас.** Авыр яшәвең йөзеңә чыккан, Халисә.

**Халисә.** Үзем дә сизәм. Ялгыз хатын—ятим бала белән бер.

**Алмас.** Ял итәргә вакыт, Халисә. Яшәртәм мин сине: үзем белән ял итәргә Анталиягә алып китәм! Сине Урта диңгезнең иркә жиле, кайнар комы, жылы дулкыны көтә. Үзем дә синең кебек сөйләшә башладым бугай.

**Халисә.** Чынлапмы, Алмас? Ә Инсаф?.. Аның язмышын хәл итмичә, нинди ял.

**Алмас.** Борчылма. Тиздән ул безнең янда булыр. Дөресен әйткәндә, мин үзем дә соңгы чиккә житеп ардым. *(Халисә янына утыра.)* Яраткан кешеңнән бер иркәләнәсе килгән минутлар да була. Ә вакыт, вакыт! *(Шартлаган тавыш. Алмас сикереп тора да кире утыра.)*

**Халисә.** Синең дә нерваларың какшаган, Алмас. Бездә монда карьерада таш чыгаралар.

**Алмас.** Син минем бердәнбер якын кешем, Халисә. Сиңа кайбер серләрне дә ачарга була.

**Халисә.** Сереңне эчеңдә саклама. Ач. Үзеңә жиңеллек килер.

**Алмас.** Мин мишеньдәге нокта, Халисә.

**Халисә.** Аңламыйм.

**Алмас.** Миңа мылтык көпшәсе төбәлгән.

**Халисә.** Ничек... төбәлгән?

**Алмас.** Мине һәр минутны атып үтерүләре мөмкин.

**Халисә** *(торып)*. Юк, бу—мөмкин түгел. Мин сине унсигез ел буе көтеп тә бик тиз югалту өчен көттеммени? Кемнәр, ни өчен?

**Алмас.** Киллер дип аталган төз атучы җәлладларым мине адым саен эзәрлеклиләр. Мин шуны аркам белән гел тоеп торам.

**Халисә.** Синдәге сәер ул халәтне сизгән идем шул.

**Алмас.** Минем фирма мәрмәр ташлар белән дә эш итә, читтән кайтартам. Мин сиңа каберләр өстендә калкып чыккан һәйкәлташлар урманын күрсәтер идем. Утыз-кырык яшьлек эзмәвердәй ир-егетләр ята ул таш асларында. Минем дусларым

да, дошманнарым да. Егетләр шәфкатьсез сугышта бер-берләрен кырып салганнар кебек...

Халисә. Мин синең өчен куркам; Алмас...

Алмас. Һәркемнән шикләнәм хәзер. Үземнең Барстан да.

Халисә. Аның күзләре чыннан да мылтык көпшәсе кебек... Атарга тора...

Алмас. Минем чын дошманнарым болай да муеннан. Бугазларына аркылы сөяк булып яттым. Тыңла: бердәнбер көнне чын ату тавышы ишетсәләр, ул мин—Алмас Уразов булырмын. Киллер бер эләктерсә, минем малларым гына торып калачак бу дөньяда...

Халисә. Ул турыда сөйләргә ашыкма, Алмас.

Алмас. Тыңла, әле әйтеп бетермәдем. Минем гомер буе җыйган байлыгыма кем хуҗа булачак?

Халисә. Әйтә алмыйм.

Алмас. Уразовлар нәселен кем дәвам итәр? Ни өчен мине кайткан дисең? Ул-бу була калса, мирасымны Инсафка... һәм сиңа калдырырга. Кәртләрне ачып бетермим. Мин Инсафның дөньяда барлыгын ишеттем, әмма ышанмадым, шик тә булгандыр, миңа аны үз күзләрем белән күрү кирәк иде...

Халисә. Әлегә күргәнең юк бит...

Алмас. Күрербез. Мин Сине дә, Инсафны да бәхетле итәргә кайттым, Халисә-җан. Төенчекләреңне төенлә. Алай дисәң, әртистнең нинди төенчеге булсын... Мин сине үзем белән алып китәм. Хәерче тормышың белән бәхилләш.

Халисә. Ә Инсаф?

Алмас. Мин әйттем: Инсафны без ял иткән Анталиягә, беренче разрядлы кунакханәгә китерерләр.

Халисә. Алла бирсә, диген.

Алмас. Доллар, доллар барсына да хуҗа! Ә ул миндә, Аллага шөкер! Исән чакта яшәп калыйк дөньяның артына тибеп! Атам Болгар ханының исемен биреп ялгышмаган. Хөрмәтнең иң олысы аңа! Хәзер мин максатымның икенче өлешенә күчәм: атам алдындагы бурычны үтим. Һәйкәлне күрдеңме?

Халисә. Күрдем. Бигрәк тә биек, затлы инде!

Алмас. Әллә каян күренеп торсын! «Алмас Уразов куйган!» дисеннәр.

Халисә. Сөләйман абый аңа лаек инде.

Алмас. Ә теге хәерчеләр куйган ташны алып ыргытабыз!

Халисә. Һәйкәл бик кыйммәткә төшкәндер.

Алмас. Уразовлар нәселе турында сүз барганда—вакланмыйбыз. Мәрмәр үзебезнең кулда. Иң шәбен лично үзем сайладым.

Халисә. Аны ничек кертерсез икән зиратка?

Алмас. Бәләкәй ташны алып ташларга кереп киттеләр инде. Иштирәкнең алкашларын яллadым. Һәйкәлне куябыз да... Халисә, әзерлән, без Төркия оҗмахына китәбез!

Халисә. Туктале, мин ничек эшемне калдырып китим?

Алмас. Сәхнәне димәкче буласыңмы?

Халисә. Ул—минем гомерлек юанычым.

Алмас. Моннан соң дуңгыз фермасы кебек салкын клубларда читятларны түгел, затлы ресторannarда, диңгезнең кайнар комнарында мине юатырсың, үзең дә юанырсың. Үзең дә күреп торасың, заман алышынды: сәхнәдә—без—мал табучылар! Йә, киттек! *(Телефонга.)* Һалло! Уразовтан сәлам! Анталиягә—өч урын! Аерым бүлмәләр! Үзем барам!

Халисә. Ашыкма... Нигә өч?

Алмас. Мин әйттем: Инсафны шунда китерерләр.

Халисә. Мин... риза.

Алмас. Бәхилләш сәхнә белән.

Халисә. Сәхнә белән бәхилләшергә? Юк, Алмас...

Алмас. Балабыз Инсафның бәхетле булуын теләмисеңмени?

Халисә. Инсаф өчен мин үземне дә корбан итәргә әзер.

Алмас. Икенең берсе: йә сәхнә, йә бала... Бар, соңгы тапкыр сәхнәгә менеп төш.

Халисә *(әкрен генә сәхнәгә менә.)* Сөләйман абыйның да тормышында шундый чагы булгандыр инде... *(Аның шигырен сөйли.)*

Канатларым кинәт хәлсезләнде,
Мин очалмый торган кош инде.
Әкрен-әкрен генә Күктән төшәм...
Җырлы иткән Күгем, хуш инде.
Үз баланны Күктә күрү өчен
Җаның белән кирәк түләргә.
Бигрәк авыр, бигрәк авыр икән
Зәңгәр Күктән төшү түбәнгә.

*(Теләмичә генә сәхнәдән төшә. Алмас аңа төшәргә ярдәм итә.)*

Алмас. Бар, өең белән дә хушлаш.

Х а л и с ә . Миңа хуҗама чылтыратырга, мондагы иптәшләрем белән дә хушлашырга кирәк.

**Прожектор нуры Изгеләр зираты ягын яктырта.**

А л м а с . Барс!

М и р х у җ а *(зираттан килеп чыга).* Ау!

А л м а с . Нигә озакладыгыз? Нигә ташны алып чыкмыйсыз?

М и р х у җ а . Бирми.

А л м а с . Нәрсәне?

М и р х у җ а . Ташны.

А л м а с . Кем?

М и р х у җ а . Бер селәгәй.

А л м а с . Кем?

М и р х у җ а . Бер малай ташны бирми.

А л м а с . Алып ыргыт!

М и р х у җ а . Булмый!

А л м а с . Син? Мирхуҗа!

Мирхуҗа. Тешли. Менә... бармак...

А л м а с . Ну-ка аны монда!

М и р х у җ а . Килми.

Алмас. Син тимә. Яхшылык белән...

М и р х у җ а . Момент!

А л м а с *(магнитофонны кабыза, аннан Халисәнең тасмага язылган шигыре ишетелә).*

Үз баланны Күктә күрү өчен
Җаның белән кирәк түләргә...

**Мирхуҗа Инсафны алып чыга.**

И н с а ф . Тотма! Мин үзем барам.

М и р х у җ а . Шушы! *(Инсаф белән Алмас арасына баса.)*

Алмас. Төнлә... зиратта нишлисең?

И н с а ф . Изгеләрнең рухын саклыйм.

А л м а с . Син үзеңне дә изге саныйсыңмы?

И н с а ф . Юк. Кызганыч, изгеләр көннән көн азая бара. Исән чакта аларга көн күрсәтмиләр.

А л м а с . Бу фикерең белән килешәм. Мин изге кешенең үлгәч кадерен белергә кайттым.

И н с а ф . Соңга калдың.

А л м а с . Нигә алай уйлыйсың?

И н с а ф . Үлгәч аның кадерен белделәр инде.

А л м а с . Ничек?

И н с а ф . Исемен, үзе кабатларга яраткан сүзләрен язып таш куйдылар.

А л м а с . Ул изге адәмнең исеме ничек?

И н с а ф . Ул пәйгамбәр затыннан.

А л м а с . Кем ул?

И н с а ф . Сөләйман.

А л м а с . Мин ныклап карамадым. Ташка нинди сүзләр язылган?

И н с а ф . «Эзләдем. Таптым. Югалттым.»

А л м а с . Ни әйтергә теләде икән ул?

И н с а ф . Мин үзем дә гомер буе бу сүзләрнең мәгънәсен эзлим.

А л м а с . Акыл иясе булса да, аның яшәве яшәү булмады. Шулай да ул татарның бөек кешесе. Үзенә адәм рәтле таш та куя алмаганнар. Мин ул бәләкәй ташны алып ташлыйм. Үзенә лаек затлы һәйкәл куям. Аңладыңмы?

И н с а ф . Мин рөхсәт итмим.

А л м а с . Син... кем?

И н с а ф . Кем булсам да, сиңа барыбер.

А л м а с . Минем кем икәнемне чамалыйсыңмы, малай?

И н с а ф . Синең кем булуың мине кызыксындырмый.

А л м а с . Кит юлдан.

И н с а ф . Китмим.

А л м а с . Яхшылап әйтәм: кит!

М и р х у җ а . Ыргытам!

А л м а с . Сабыр. Көч кулланмыйча хәл итәргә тырышыйк. *(Шәмси күренә, эшләпәсен салып, башын иеп.)* Хәерле төн сезгә!

Ш ә м с и . Нигә йокы алмый дисәм, сез икән әле монда...

А л м а с . Уразовка мин куясы һәйкәлне күрдеңме?

Ш ә м с и . Искиткеч. Гениально! Мондый һәйкәлнең татар тарихында булганы юк! Бер чакырымнан балкып торыр! Үрелеп караган идем, эшләпәм шуып төште.

А л м а с . Бу малайны таныйсыңмы?

Шәмси *(текәлеп карый, танымый).* Юк, күргәнем юк. Нииндидер сукбай... бомж...

А л м а с . Ул безне зиратка үткәрми. Син әйтеп карале...

Ш ә м с и . Әй, малай актыгы, бу абзаңның кем икәнен беләсеңме?

И н с а ф . Белергә дә теләмим.

Ш ә м с и . Нигә син аларны үткәрмисең. Синең ни хакың бар?

И н с а ф . Андый һәйкәл Сөләйман Уразовның рухына ят. Иштирәк халкы ана башка изгеләрдән аерылып тормаган таш куйды.

Ш ә м с и . Ялгышасың. Хуҗа дөрес әйтә. Сөләйман әнә шундый затлы

һәйкәлгә лаек! Син аңла: заман үзгәрде, заман—көчленеке!

**Инсаф**. Лаек булгач, син нигә исән чагында аның кадерен белмәдең? Нигә якламадың авыр чакларында? Ул заманда көч синдә иде бит!

**Алмас**. Мин бу сүзләрең белән килешәм. Шуның өчен ул үз заманында бер кабыргасы белән түләде.

**Шәмси**. Әй-й... Искә төшермик... онытыйк узганнарны.

**Алмас**. Малай, безгә каршы торсаң, син дә берничә кабыргаңнан колак кагуың бар. *(Шәмси куркып чыгып китә.)* Соңгы тапкыр әйтәм: кит юлдан!

**Инсаф**. Сез монда бары тик минем гәүдәм аркылы гына үтә аласыз.

**Алмас**. Барс! *(Әмер генә көтеп торган Мирхуҗа Инсафка ташлана, нокаут белән Инсафны ега.)*

**Инсаф**. Кабахәтләр! *(Шул вакыт кулына чемодан тотып, Халисә килеп керә.)*

**Халисә** *(улының тавышын танып)*. Туктагыз! Кемне кыйныйсыз? *(Инсаф янына бара.)* Инсаф?! Синме бу? *(Инсафны күтәрергә тырыша.)* Балам...

**Алмас**. Барс, кит... *(Мирхуҗа китә. Алмас Инсаф янына бара.)* Балам дисеңме? Инсаф?.. *(Инсафны күтәреп торгызырга ярдәм итә.)*

**Халисә**. Чынлап та Инсафмы син? Бер генә сүз әйт... Нишләттеләр сине?

**Алмас**. Ул үзе гаепле, каршы торды, атам янына кертмәде...

**Халисә**. Балам, хәлең ничек?

**Инсаф**. Борчылма, әни. Хәлем әйбәт.

**Халисә**. Танырлык та түгелсең. Сакал-мыек баскан үзеңне... иске-москы киемнәр... Ни булды сиңа?

**Инсаф**. Берни дә булмады. Тынычлан.

**Халисә**. Син армиядән котылып кайттыңмы?

**Инсаф**. Котылдым, әни.

**Халисә**. Бөтенләйгәме?

**Инсаф**. Бөтенләйгә.

**Халисә**. Сине җибәрделәрме?

**Инсаф**. Әйе, әни.

**Халисә**. Авырыпмы?

**Инсаф**. Әйе. Әз генә авырдым.

**Халисә**. Инде беркая да китмисеңме?

**Инсаф**. Китмим инде, китмим.

**Алмас**. Халисә. Инсафка минем кем икәнне әйт...

**Халисә**. Инсаф, таныш бул: бу— синең әтиең... *(Тынлык.)*

**Алмас**. Исәнме, Инсаф?.. Саумы, улым?.. *(Инсаф дәшми.)*

**Халисә**. Улым, дәш инде, бер генә сүз әйт...

**Мирхуҗа** *(керә)*. Тотыгыз!

**Алмас**. Кемне?

**Мирхуҗа**. Менә моны!

**Алмас**. Нигә тотарга?

**Мирхуҗа**. Кача!

**Алмас**. Кем кача?

**Мирхуҗа**. Аны эзлиләр!

**Алмас**. Кемне?

**Мирхуҗа**. Бу малай армиядән качкан.

**Алмас**. Качкан?

**Мирхуҗа**. Дезертир! Мин күрсәттем!

**Алмас**. Тукта, кычкырма!

**Мирхуҗа**. Зиратка качкан! Бәйләргә! *(бау чыгара.)*

**Алмас**. Авызыңны... яп!

**Халисә**. Чынмы бу, Инсаф?

**Инсаф**. Әйе, мин зираттан качкан дезертир. Армия дигән зираттан. Мин үзебезнең халыкны атарга теләмим. Мин монда кайтып Сөләйман бабам белән киңәштем. Сезне борчымаска уйлаган идем... мәҗбүр иттеләр менә болар.

**Халисә**. Харап иткәнсең бит үзеңне, балакай, хәзер нишлибез?

**Инсаф**. Ни генә булса да, минем җаным тыныч хәзер.

**Халисә**. Алмас?..

**Алмас**. Бер дә юкка борчыласың, Халисә-җан. Инсаф, бер дә кайгырма, барысын да үзем җайлармын.

**Халисә**. Хәзер сине ни көтә? Әйт, балам, ни көтә сине?

**Инсаф**. Мине трибунал көтә, әни. Әмма вөҗданым саф кала.

**Мирхуҗа**. Киләләр!

**Халисә**. Инсаф, кач!.. Зиратка кереп кач.

**Алмас**. Чыннан да, син зиратка кереп тор. Алар белән мин үзем сөйләшермен.

**Инсаф**. Беркая да качмыйм.

**Халисә**. Әнә... килеп җитәләр... Балам, мин сине беркемгә дә бирмим. Хәзер безгә атаң ярдәм итәр.

**Алмас**. Бер дә аптырап тормагыз. Атаңда сине генә коткарырлык көч бар... Лимон гына төртәсе. Лимон атаңда миллион... Сатылмаган адәм юк дөньяда. Офицеры белән үзем сөйләшермен. Тынычланыгыз...

**Инсаф**. Юкка борчыласың, ата кеше, мине берничек тә сатып алып булмый.

Мин мал түгел. Аннары кемнең чын дезертир булуы турында да уйлыйсы бар әле.

Халисә. Инсаф...

Инсаф. Тынычлан, әни... Мин үзем аларның кулына бирелəм... Әни, сау бул, үзеңне сакла, мин тиз кайтырмын. *(Кузгала.)* Мин Уразов Инсаф! Килегез, мин әзер!

Алмас. Улым... Инсаф... тукта... бер генә сүз... ике-өч кенә сүз...

Инсаф. «Эзләдем. Таптым. Югалттым.»

Айгөл *(йөгереп керә).* Инсаф, кач, сине эзләп киләләр!

Инсаф. Мин үз язмышымны хәл иттем. Сау бул, Айгөл, исән булсак, бер кайтырбыз... Алла бирсә...

Халисә. Исән булырсыңмы соң, балакаем?

Айгөл. Кайтырсыңмы соң?

Инсаф. Сезнең янга кайтмыйлар димени?

Халисә. Тамагың ачтыр бит, балакаем...

Инсаф. Безне инде ач торырга өйрәттеләр...

Айгөл *(чүпрәккә төрелгән икмәкне биреп).* Инсаф, ал...

Инсаф *(ала).* Тормышыгыз шушы ипи кебек түгәрәк булсын, авылдашлар...

Халисә. Котелогың бушмы? Бир әле, су алып бирим...

Инсаф. Бушаган икән шул... *(Халисә Инсафның котелогын алып, чишмәгә китә, Айгөл Инсаф янына килә.)* Кайткач кочакалармын... Чао, старушка!

Айгөл *(кочакларга ашыга).* Мин сиңа кәккүк булып кычкырырмын.

Инсаф. Кайда гына булсам да, мин ишетермен. Кара аны, бер генә тапкыр түгел, йөз тапкыр кычкырырсың...

Халисә *(котелогын биреп).* Зинһар үзеңне сакла, бала... Әнә килеп тә җиттеләр... Инсаф!.. *(Артыннан омтылып, туктап кала. Инсаф эзләүчеләргә каршы үзе китә.)*

Айгөл *(хәлсезләнеп тирәккә утырган Халисә янына барып).* Халисә апа, түз... Кайтам диде бит...

Халисә. Көтүнең ни икәнен беләм мин, Айгөл...

Таңзифа *(таягы белән кармаланып керә).* Нинди төн булды бу? Беркем йокламый. Зират ягыннан шомлы тавышлар ишетәм. Әрвахлар уянып чыкканмы әллә?

Халисә. Таңзифа апа, балаң кайтты...

Таңзифа. Кайсы балам? Югалганымы? Алмасымы, Инсафымы? Кайда алар?

Халисә. Алмас, кочакла инде әнкәңне...

Таңзифа. Күрсәтегез миңа Алмасымны, Инсафымны...

Халисә. Алмас... *(Алмас хәрәкәтсез басып тора.)*

Таңзифа. Күпме еллар зарыгып көткән Алмасыммы, чынлапмы? Йә Аллам! Кил, балам, кочаклашыйк әле. Син инде зур үскәнсеңдер. И күрәсем килә дә соң үзеңне. Күзләрем йомылды шул, күзләрем. Син нинди хәзер? Чәчләрең һаман чем карамы? Кайда син, алдыма килдеңме инде? И күзләрем, бер генә минутка, баламның нурлы йөзен күрү өчен генә ачылсагыз иде... Юк ла, мин болай да кармалап та таныйм үз баламны, тәнендәге һәрбер ноктасын беләм. Кил, балам... *(Алмас аның янына бармагач, Халисә аны көчләп Таңзифа янына китерә. Ул баласын капшап карый.)* Юк, бу адәм Алмас түгел. Юк... юк. Әгәр ул Алмасым булса, унсигез ел өзелеп көткән анасының хәлен белми калмас иде. Мин бит ул бәхетле булсын, үлем кочагында ятканда терелсен, югары белем алсын дип, яраткан Сөләйманымны калдырып, Шәмсигә кияүгә чыктым. Гомеремдәге иң үкенечле ялгышым... Әгәр ул Алмас булса, озак еллардан соң булса да үпкәсен онытып, тудырган әнкәсен кичерер иде. Юк... юк... бу минем Алмасым түгел.

Алмас *(артык түзә алмыйча, талпынып).* Әнкәй, тукта...

Таңзифа. Юк, ул минем балам түгел. Эзләдем. Таптым. Югалттым. *(Чыга.)*

Алмас. Атам ни әйтергә теләде икән бу сүзләре белән?

Халисә. Сөләйман абыйның соңгы сүзләре. Тагын әйткән: гаиләне саклый алмауга мин үзем гаепле, дигән, үз эшемә фанатикларча бирелеп, мин Танзифаны да, Алмасны да югалттым, дигән.

Алмас. Халисә, без монда артык кала алмыйбыз. Киттек... Ал чемоданыңны...

**Халисә икеләнеп тора да, чемоданын ала.**

Айгөл. Халисә апа, сез кая?

Халисә. Мин сәхнәдән китәм, Айгөл.

Айгөл. Сез... мине үзегез артыннан сәхнәгә әйдәгән, җанга якын остазым... китәсез... ышанмыйм...

Халисә. Гомеремдә бер генә булса да мин дә бер рәхәт тормыш күрергә тиеш.

Айгөл. Мин сина сәхнә бәхете телим.

Айгөл. Сез, Сөләйман абыйның шигырьләрен сөйләргә өйрәткән кадерле кешем, сәхнәдән китәсез?..

Халисә. Сау бул, сеңелем.

Алмас *(киеренке халәттә)*. Барс!

**Сәхнә караңгылана. Шул вакыт бөтен дөньяны ватып-җимереп, ямьсез үкереп үгез килгән, куркышып йөгергән, кычкырган тавышлар ишетелә.**

Алмас тавышы. Барс!

Мирхуҗа. Ау!

Алмас. Сакла! Халисә! Машинага!

Мирхуҗа. Момент! *(Пистолет аткан һәм Кызыл үгезнең үлем ачысы белән үкергән авазы ишетелә. Прожектор нурлары төшә: уртадагы сәхнә җимерелгән, аннан хәрабәләр генә калган. Аның янында—пистолетын тоткан Мирхуҗа. Кулында пычак. Ул шамакай көлүе белән көлә. Кулында кып-кызыл канлы зур пычак)*. Кых!

Сәләх *(керә)*. Мирхуҗаны син аттыңмы, кабахәт!

Мирхуҗа. Мин!

Сәләх. Ник аттың?!

Мирхуҗа. Дәүләткә тапшырасы хайван. Качкан. Дезертир. *(Көлә.)*

Сәләх. Яраткан хайваным иде. Үзем озатып бардым...

Мирхуҗа. Мин сине беләм: качарга үзең булышкансың...

Сәләх. Мин синнән курыкмыйм. Булыштым. Кузовны үзем ачтым. Ник син аттың?

Мирхуҗа. Мине гаепләмәкче буласың! Ул котырган!

Сәләх. Ул сине күргәч котырган. Ни өчен котырганын беләсеңме?

Мирхуҗа. Төкерәм!

Сәләх. Бисмилла әйтеп, тынычландырып эш кылсаң, мал тыпырчынмый, язмышына буйсына. Ул тоя: анда аны электр тогы белән үтерәләр...

Мирхуҗа. Какая разница?

Сәләх. Аерма зур! Синең исемеңне аңа биреп ялгышалар. Син ул котырган! Без ул—адәмнәр—котырган! Мирхуҗа, мин сине эзләдем, таптым...

Мирхуҗа, Ну и што?

Сәләх. Яшер пистолетыңны, куй пычагыңны! Мин сине хәләл көрәшкә чакырам.

Мирхуҗа. Синеңчә булсын. *(Коралларын яшерә.)* Көрәшкә? Ха-ха-ха!

Сәләх *(сөлге ала)*. Башладык!

*(Тигезсез көрәш, дөресен әйткәндә, сугыш башлана. Мирхуҗа Сәләхне тупас көч—нокаут белән ега. Үзе чыгып кача. Сәләх егыла, соңгы көче белән тора. Хәрабәләрдә Айгөлнең тавышын ишетеп, аны такталар арасыннан күтәрә.)* Сеңелем, син исәнме?

Айгөл. Мин... исән. Ә сез?

Сәләх. Сеңелем, ачу белән дөньябызны җимерсә дә, үгезгә ачуланма, ул гаепле түгел. Аны шул хәлгә җиткерделәр. Байлык, көч изге күңелле адәмнәрдә булмаса, сәхнәгә Мирхуҗалар менәчәк... Бирмик сәхнәне аларга!

Айгөл *(сәхнә хәрабәләре арасында Сөләйманның шигырен сөйли)*.

Ишетелде шул чак серле тавыш
Ардым инде, талдым дигәндә:
Төшсәң дә син Җиргә—бик түбәнгә,
Төшә күрмә Җырда түбәнгә!

*(Кире кайтучы Халисәне күреп.)* Халисә апа, син китмисең?!

Халисә. Әйе, мин сәхнәдә калам.

**Артта—ату тавышы.**

Сәләх. Кемнедер аттылар...

Халисә. Алмас?!..

**Үзәк өзгеч кәккүк авазы ишетелә...**

*Пәрдә*

*1997 ел*

*Язучы Вахит Юныска 70 яшь*

# ГОМЕРЛЕК МОСАФИР



*Вахит Юныс турында язу җиңел дә, шул ук вакытта авыр да. Чөнки ул күпкырлы шәхес: чын татар авылы малае—печән чабучы, ат караучы һәм әдәбият-тарих укытучысы да, гомере буе дөнья гизгән, 74 илдә булып, күп кенә сәяхәтнамәләр язган язучы да, 17 ел чамасы чит илләрдәге илчелекләребездә эшләп, дөньядагы тарихи вакыйгаларны үз күзләре белән күргән һәм күп чит ил дәүләт җитәкчеләре белән очрашып сөйләшкән дипломат та, шулай ук гаҗәеп зур үзгәрешләр кичергән илләрда хакыйкатькә тугры булып калган политолог-публицист та, кыска хикәяләр һәм юмор остасы да...*

*1996 елда Татар ПЕН үзәге делегациясе Мексикага Бөтендөнья Язучылар Ассоциациясе (ПЕН-Интернэшнл) конгрессына баргач та Исергәп авылы малае Вахит күпчелек илләр язучылары белән инглизчә, гарәпләр белән гарәпчә, ә кореялылар белән корейча сөйләшеп шаккатырды. Һәм ул халыкара конгресс трибунасына чыгып, инглизчә татар мәдәнияте һәм әдәбияты турында сөйләп биргәч, Татар ПЕН үзәген бертавыштан алкышлап Халыкара ПЕН-клуб әгъзасы итеп алдылар.*

*—Нигә соң ул олы яшьләргә җитеп килгәндә генә басыла башлады?—дип сорыйлар кайберәүләр.—Чыннан да, нигә 80 нче еллар ахырында гына матбугатта еш күренә башлады ул?*

*«Дөрес,—ди үзе Вахит Юныс.—Чынлыкта мин Исергәп җиде еллык мәктәбендә укыганда ук шигырьләр яздым һәм Баулы район газетасында бастырдым. Ватан сугышы бара, кайнар патриотизм чиктән ашкан, хәзер укыганда шаркылдап көләм... 1946-1951 елларда Бөгелмә педучилищесында һәм укытучылар институтында укыганда да шигырьләр, фельетоннар һәм мәкаләләр язып бастырдым. Тик Мәскәүгә килеп, Чит ил эшләре министрлыгының МГИМО институтында белем алганда бөтен вакытым чит илләрне өйрәнүгә китте. Ә чит илләргә барып, аларның тормышын күргәч, патриотик хисләр шундук җилгә очты. Үзебезнең тормышны мактап язарга кулым күтәрелмәде, ә чит илләр тормышын сүгәргә вөҗданым кушмады. Сүз ирене һәм хәбәрдарлык килгәч кенә яза һәм язганымны бастыра башладым».*

*1930 елда Баулы районы Исергәп авылында туган Вахит Юныс 10 яшьтә үк әтисез кала. Сугыш еллары, колхоз бер тиен түләми, бер кило икмәк бирми. Ә ашарга-яшәргә кирәк. Кышка утын кирәк, малларга печән кирәк. Ун яшьлек малай калдык-постык җирләрдән печән чаба, печәнне һәм урмандагы корыган ботакларны бәләкәй «уфалла» арбасы белән берүзе тартып ташый. Бөгелмәдә укыганда да җәйге каникулларда бәләкәй арба кулдан төшми.*

*Кышкы төннәрдә укыган китаплар ерак серле илләргә чакыралар, хыяллар әллә кайларга оча. Вакыт аз,—Исергәп малае уку елларын кыскарта: дүрт еллык педучилищены өч елда, ике еллык укытучылар институтын бер елда тәмамлый. «Стахановчы!»—дип көлә ул үзеннән соңыннан.*

*Аннан соң—бер ел Шөгер татар урта мәктәбендә укыту, бер ел Баулы район мәгариф бүлегендә эшләү (ә кичләрен кичке мәктәптә укыту). Театр белән мавыгу, үзешчән сәхнә*

*труппасы белән төрле авыл клубларында Хажҗи әфәнде ролен башкару.*

*Ә җан һаман еракларга тарта. Һәм сирәк элита вәкилләре генә укый ала торган МГИМО институтына кереп, 1959 елда В. Юныс аны әйбәт кенә тәмамлап чыга. Ә таләпләр анда бик катгый: I курска группага уналты кеше керсә, VI курсны исә тик өч студент кына тәмамлый.*

*Ниһаять, Каф тавы артындагы илләр, даими хәрәкәт, бетмәс-төкәнмәс сәяхәт... Үзе эшләгән илләрдә дөньяны шаулаткан зур вакыйгалар, фетнә һәм түнтәрелешләр, революцияләр һәм сугышларның шаһите була В. Юныс. Һәр илне тирәнтен өйрәнә, кешеләре белән нык аралаша, һәр халыкның милли, мәдәни, тарихи һәм рухи үзенчәлекләрен көндәлек дәфтәрләренә теркәп бара. Сәяхәтнамәләрендә болар ачык сурәтләнә: Гыйрак Германиягә охшамаган, Сүрия Швециягә, Әфганстан Тайваньга, Таиланд һәм Кампучия Мексикага якын түгел. Кайсы гына илдә эшләсә дә, кая гына барса да, андагы ил һәм халык тормышын безнең ил һәм халык тормышы-язмышы белән чагыштыра. «Нигә алар шулай, ә без болай?»— дигән сорауга җавап эзли ул.*

*Чит илдән туган авылына ялга кайткач, яше сигезенче дистәгә киткән әнисе аңа зур шатлык белән гомерендә беренче тапкыр унике сум айлык пенсия алуын сөйли. Чит илләрдәге карт-корының мул, бәхетле тормышын күз алдына китереп, моңа В. Юнысның җаны тетрәнә...*

*Язучы В. Юныс әсәрләренең күпчелеге—чит илләрдә язган сәяхәтнамәләр. 1989 елдан башлап ул чит илләрдән Татарстан матбугатына даими рәвештә материаллар җибәреп тора. Казанга килгәндә дуслары аннан шаярып сорыйлар:*

*- Ничек син «Татарстан яшьләре» һәм «Шәһри Казан» газеталарының чит илләрдәге үз корреспондентына әйләндең?*

*Ә ул җитди җавап кайтара:*

*- Татар милләте зур һәм сәләтле милләт, ул, һичшиксез, дөнья мәйданына чыгачак. XXI гасырда без чит илләр белән иркеле һәм еш аралашачакбыз. Чит илләргә барырга омтылган яшь татарлар өчен язам мин. Минем кебек чит илләрдә күп йөргән һәм озак яшәгән татар язучылары булса, алар да язсын!*

*Вахит Юныс иҗатында икенче урында публицистика тора. Бу очраклы хәл түгел, чөнки соңгы ун ел публицистика күтәрелгән һәм шаулаган заман булды. Дөнья хәлләрен һәм чит илләр тарихын күзәтеп барган В. Юнысның зур теләк белән публицистикага кереп китүе бик аңлашыла. Һәм ул үткәндәге авыр заманнан һәм бүгенге газаплы әзләнүләрдән милләтебезнең киләчәктәге иркеле һәм мул тормышын күрергә тырыша.*

*Вахит Юныс төп тормыш кагыйдәләренең берсе итеп «сәяхәттә бәрәкәт», «хәрәкәттә бәрәкәт» девизын ала. Гомерлек мосафир булып сәяхәтнамәләр остасына әйләнгән һәм татар укучыларының дөньяга карашын киңәйткән Вахит Юныс кебек шәхесләр безгә бик кирәк...*

**Разил ВӘЛИЕВ**

---

# Вахит Юныс

# ИБРАЙ АБЗЫЙ «КАРДИУНЫ»

ӘСӘРДӘН ӨЗЕК

Җиңү бәйрәме шаулап-гөрләп узды.

Күкрәкләрендәге медальләрен чыңлатып, аркаларына яшел хәрби капчык, кулларына чемоданнар тотып җиңүче авылдашлар кайтып төште. Аш-су, мәҗлесләр, кочаклашып елашу, шатлану, кичләрен кайткан солдатлардан фронт хәлләрен, җәбер-җәфа, чит ил тормышы хәлләрен тыңлау...

Сугышның азагына кадәр фронтта булып, җиңү көнен Германиядә каршылаган кайбер авылдашлар, чемоданнарыннан күзләр камашырлык трофей әйберләрен чыгарып, сәкегә өеп куюлары турында авыл халкында әллә нинди имеш-мимешләр йөри.

Авылны шаккатыручыларның иң беренчесе Тимай Ибрае булды. Ул кайткач, кичләрен тальян гармун моңына күнеккән авыл халкы колагына нинди-дер кызыктыргыч ят матур гармун тавышы ишетелә башлады. Кичләрен алар бакчасында үскән сирень куагы астына еш кына өстәл әзерләнә, анда сугыштан кайткан биш-алты ир җыела, өстәлгә тавык белән бәрәңге китерелә, шешәләр ачыла һәм моңа кадәр авыл белмәгән-күрмәгән тамаша башлана.

Ике-өч рюмканы җибәргәч, сугышта булган-булмаган бөтен батырлык бәян кылына, кешедән ишеткән маҗаралар үз башыннан үткәнгә әйләнеп, әллә нинди яңа төсләр белән сурәтләнә. Аннан соң программаның музыкаль бүлеге башлана. Дрезден осталары кулы белән ясалган, бик тупас тартуларына күнекмәгән атаклы «һоһнер» аккордеоны Тимай Ибрае кулында авыртуга түзә алмаган кебек ыңгырашып куя да, эчендәге бөтен тавышы белән «Алмагачлар» көен сыптыра башлый. Иң мәшһүр хорларда һәр җырчы үз тавышы белән җырлаган кебек, мәҗлес әһелләре дә көйне һәрберсе «үз тыкрыгына таба» суза.

Әй, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары!
Сайрый, сайрый, сайрый, сайрый
Сагындыра башлады...

Ләкин тиздән авыл халкын бу сандугачларның сайравы туйдыра башлады.

Атна-ун көннән Дрезден осталары ясаган көмеш телле «һоһнер» тавышы да, алмагачларның майның унбишләрендә чәчәк атуы да кинәт кенә туктады да куйды.

Нәрсә булган? Ибрай абзыйның бөтен тавыклары суелып, ашалып беткәнме? Александровкадагы спирт заводын капиталь ремонтка япканнармы? Ибрай абзыйның бармаклары авыртамы, әллә аның фронтовик дусларының тамагы шешкәнме?

Малайлар разведкасы бөтен хәбәрне түкми-чәчми китереп салды.

... Бер кичне Ибрай абзый компаниясе, бөтен түгәрәк җир шарын селкетеп типтергәннән соң, үз өйләренә таралганнар. Ибрай абзый да сәндерәсенә менеп йоклаган, тик «һоһнер» аккордеоны гына бакчадагы өстәлгә утырып калган, имеш. Ә бу төнне яшен яшенләп, күк күкрәп, бик нык коеп яңгыр яуган. Табигатьнең мондый авырлыкларына күнекмәгән мескен «һоһнер» гел җебеп төшкән, имеш. Шуның өстенә таң алдыннан бакчага ачык калган капкадан сыерлары кергән. Өстәлдә калган ипиләрне ашаганда, аккордеонның нинди марка икәнен абайламыйча, аны өстәлдән җиргә аударып төшергән. Шуның өстенә, өстәлдәге калган азыкларны чистарту белән мавыгып, юешләнеп беткән бичара «һоһнер»ны үзенең каты тояклары белән таптаган да икән бу надан сыер!..

Кояш югары күтәрелеп, фани дөньядагы җирне киптерә башлагач, башы авыртуга түзә алмаган Ибрай ага сәндерәдән төшеп, баш төзәтү нияте белән туп-туры бакчадагы өстәлгә юнәлгән. Ә өстәл нәкъ Сталинград сугышыннан соң калган хәрабәләрне хәтерләтә, ә җирдә җимерелгән патша сарае кебек сытылган-ватылган мескен аккордеон ята. Ул инде Дрезден осталары да төзәтә алырлык хәлдә түгел икән...

Мондый вәхшилеккә түзә алмаган фонтовик соңгы акчаларын һәм дусларын җыеп кибеткә бара. Кибет ябык. Фронтовиклар делегациясе сатучы Зәйтүнә өенә визит ясый. Зәйтүнә бакчасында бәрәңге утый.

—Сез нәрсә, кибетнең кайчан ачылганын белешмисезмени?—Балчыклы кап-кара куллары биләндә.

—Беләбез. Синең өйдә биш-алты ящик аракы булганын да беләбез!

—Анда сезнең эшегез юк! Колхоз кирәк-ярагына запас булырга тиеш!

—Зәйтүнә! Менә сиңа акча. Әгәр хәзер биш шешә чыгармасаң, өенә кереп тентибез, аракы тапсак, акт төзеп, барыбыз да кул куябыз. Онытма, фронтта кан түгеп кайткан ирләр без!

—Тәки жилегемә төштегез инде, бандитлар! Төне буе йокы бирмичә кардиун акыртуыгыз житмәгән, якты көндә дә иркенләп үз бакчанны карарга ирек бирмисез!

Ә үзе кулларын алъяпкыч итәгенә сөртә. Ибрай ага учыннан акчасын ала да, өенә кереп ак башлы шешәләрне чыгара.

—Ярар ачуланма Зәйтүнә, безнен буләсе мал юк! Элек исән кайту шатлыгыннан эчсәк, бүген кайгыдан эчәбез. Теләсән, әйдә безнен белән киттек, хет кыяр жыярсын, суган турарсын, ә?

—Бардым ди, бармыйни! Сезгә иярсән, тапмаганынны табарсын! Үз юлыгызны карагыз, тагын сорап килмәгез, кирәк булса, хәзер житәрлек алып китегез.

Әй, Зәйтүнә, барсан суга
Сөйләшербез барсын да...—

дип жырнын сүзләрен бозып суза-суза жырлап жибәрә элеккеге тракторист, ә фронттан танкист булып кайткан Хәйретдин.

Узган төнне булган хәлләрдән сон Ибрай абзыйнын үз бакчасына кайтырга аягы тартмый, күрәсен, фронтовиклар Хәйретдин өенә юл тоталар. Көннен икенче яртысында аннан вакыт-вакыт халык жырлары репертуарыннан экспромт-концерт янгырый, ләкин аккордеон булмагач, жырларнын әлләни тәме дә, канаты да юк, инеш буйларыннан шаулап-гөрләп янгырамый, ничектер зәгыйфь һәм мескен чыга.

... Колхознын чабылган печәннәре жыелып өелгәч, авыл халкы үз малларына болында-кырда һәм урманда калган үләннәрне кайтарып сәндәрәләренә тутырып куйгач, колхоз идарәсе кичен клубта гомуми жыелыш үткәрде.

Жыелышнын көн тәртибендә ике мәсьәлә: колхоз малларына кышка азык-төлек хәзерләү һәм урып-жыюга әзерлек.

Малларга печән хәзерләү турында докладны колхоз зоотехнигы Харис абзый ясады.

—Быел печән хәзерләү озакка сузылды шул, иптәшләр. Янгырлар да мишәйт итте инде, анысын үзегез беләсез. Әмма ләкин без өмет иткән кайбер ирләр кулларына чалгы тотып карамадылар, быел кышка әзерләгән печән кибәннәрендә алар чапкан бер генә учлам печән дә юк...—дип бетерде ул үзенен чыгышын. Зоотехникнын кем бакчасына таш ыргытуы турында залда утыручыларнын бер генә шик-шөбһәсе дә юк иде.

—Иптәшләр, кемнен әйтәсе сүзе бар?

—Минем бар!—дип сикереп торды да, сүз биргәннәрен дә көтеп тормыйча, сәхнәдәге трибунага юнәлде Сәхипжамал түти. Авыл халкы авылнын яна тарихында Сәхипжамал түти чыгыш ясамаган жыелышны хәтерләми. Анын чыгышы булмаса, жыелышнын яме дә, тәме дә булмас иде кебек. Йоклаган кешеләр йокыларыннан уянды, клуб баскычында махорка көйрәткән ирләр тәмәкеләрен сүндереп, бик тырыш мәктәп балалары кебек залга кереп утырдылар.

—Кәнишне, безнен зоотехник политиканы әйбәт беләдер, шуна күрә ул туп-туры әйтми, ә читләтә-читләтә генә урап уза печәнгә чыкмаган ирләр турында,—дип башлады Сәхипжамал түти. —Колхоз жыелышы бит ул аулак өй түгел, нигә монда күз бәйләү уены уйнарга? Нинди ирләр кызу печән өстендә жырлый-жырлый кардиун тартып, атналар буена кәеф-сафа корып утыруларын күрмәскә әллә без сукырмы?

Зал рәхәтләнеп кул чаба.

—Без, хатыннар, көне буе печән чабып, эт булып арып кайтканда Ибрай бакчасында гармун тартып әйттереп утырган типсә тимер өзәрлек тап-таза ирләрне күрү зур куанычмы безгә? Кәнишне, рәхмәт Ибрайга да, Хәйретдингә дә, Сәйфигә дә,—барысына да—сугышта окопларда ятып, әллә кайларда булып немецләрне жинеп кайтканнары өчен! Мен рәхмәт! Тик ул чакта без дә тик ятмадык, көн-төн эшләдек, аларны туйдырдык. Хәзер алар кайттылар, атна ял иттеләр, ай ял иттеләр. Нәрсә, алар гомер буе ял итәргә кайттылармыни? Әллә хөкүмәт закун чыгарганмы? «Сугышта катнашкан ирләрне авыл хатыннары

гомер буе ашатып-эчертеп, тәрбияләп торырга» дигән указ чыкканмы? Әллә безгә генә әйтмәгәннәрме аны?

—Давай, давай, Сәхипжамал!—дип көч-куәт биреп тора зал.

—Әгәр дә мәгәр, «фронттан кайткан ирләрне сорыкортлар кебек гел хатыннар гына туйдырып торсыннар», дигән закун булса, силсәвит прсидәтеле Мотыйгулла чыгып әйтсен менә шушында безнең каршыда!

—Артык күпне сөйләргә яратасың икән һаман да, Сәхипжамал!—дип карады икенче рәттә дуслары белән оборона тоткан Ибрай.

—Ярар, Ибрай, кардиуныңны тыңлап гарык булдык, сине дә тыңларбыз, бик сагындык, тыңлыйсыбыз килә!—дип дәвам итә Сәхипжамал.—Әгәр дә мәгәр шундый указ чыккан икән, иртәгәдән башлап бөтен авыл хатыннары җыелып, Ык буеның иң матур җиренә фронтовикларга ял йорты салып бирик! Патша сарае кебек булсын! Колхоз малларын суеп казан асыйк, бал-май илтик, иң йомшак түшәк-ястыкларыбызны илтеп аларга җәйик! Ожмахта кебек яшәсеннәр! Үзебез дә сирәк кенә мунчадан соң атнасына берәр кичкә алар янына ял итәргә баргаларбыз...

Зал ярылып көлә, шаулатып кул чаба, рәхәтләнә. Икенче рәттәге Ибрай дуслары белән клубтан чыгып сыза, ә алар чыкканда залдагы кул чабу тагын да ныграк котыра.

Төнге яшенле янгырдан һәм колхоз җыелышыннан соң Ибрай бакчасындагы концертлар туктады.

Ул төнге яшенле янгырда булган вакыйгалар турында хатыннар разведкасы өстәмә мәгълүматлар да китергән. Имеш, ире Ибрайның дуслары белән һәр кичне типтерүеннән тәмам гаҗиз булган Хөршидә, яшен яшьнәп күк күкри башлагач, коймага элеп куйган керләрен алырга чыкса, яшен яктысында бакчада бутылкалар тезелеп утырган өстәлне һәм бөтен перламутрлары белән ялтыраган аккордеонны күргән. Хөршидә апа эчендә нинди хисләр кайнагандыр, анысын сөйләмиләр. Ләкин керләрен өйгә кертеп куйгач, имеш, ул чиләк алып чыккан да, коедан биш-алты чиләк суны «фашист аккордеонына» китереп койган. Әгәр сөйләүләре дөрес булса, сыер да «ожмах нигъмәтләре» тезелеп яткан өстәлне үзе эзләп тапмаган, ә аны Хөршидә апа ашатырга үзе алып кергән кушкан, шуның өстенә дошман аккордеонын да үзе алып сыер аяклары астына ташлаган, имеш...

Ибрай абзыйның фронтовиклар труппасы концерт бирүдән бөтенләй ваз кичте дип әйтсәк, бераз хата булыр, билгеле. Вакыты-вакыты белән җыелып гармунсыз гына кәеф корулар булды инде булуын, ләкин «Алмагачлар» инде чәчәкләрен койды, «сандугачлар» да төне буе сайрауларыннан туктадылар.

Шулай итеп, Ибрай абзый «кардиунына» Ык буйларындагы климат ярамады. Әнә күпер башы Нурмыйның тальян гармуны Закуан туеннан соң бәкедә бозлы суда коенып чыккан, диләр. Ә бернәрсә булмаган, һаман да уйный, һаман да яшь кызларның йөрәкләрен җилкетә, үзәкләрен өздерә, төшләренә керә.

—Ни әйтсән дә, бездә ясалган әйбернең сыйфаты югары инде, аны Дрезден «кардиуны» белән чагыштырып булмый,—дигән бик төпле һәм тирән нәтиҗә ясадылар авыл хәкимнәре...

Ләкин фронтовик Ибрай абзыйның даны аккордеоны белән бергә яшенле янгырда эреп акмады, аннан соң да бераз яшәде.

Хикмәт шунда ки, Ибрай абзый Германиядән трофей итеп аккордеон гына түгел, тагын кайбер нәрсәләр алып кайтты. Хатын-кызларның иң йомшак җирләренә кия торган киемнәрен Хөршидә кияргә тырышып карады да, кул селтәде:

—Кит, Ибраһим, ачка үлә башлаган немец хатыннарына гына ярый торгандыр бу! Безнең авыл хатыннарына ким дигәндә дүрт мәртәбә зуррак кирәк шул.

Хөршидәгә нинди дер чиркәү төшкән яулык ярады, ә башка бөтен киемнәрне җыеп, Хөршидәнең сеңлесе Гөлнурның үсеп килә торган кызларына бирделәр.

Ибрай абзыйның ганимәт маллары арасында авыл кешеләрен шаккатырган тагын ике нәрсә бар иде: алтын белән йөгерткән шикәр савыты һәм немец чалгысы.

—И, Ходаем, шикәре генә житәрлек булсын, аны алтын савытка салдын ни, агач савытка салдын ни—шикәр барыбер шикәр инде ул,—диделәр бу трофейны күрергә кергән күрше хатыннары.

—Шалишь, алай димәгез, немец алпавыты шикәрне чекерт-чекерт ватып өстәлендә тоткан алтын савыт бу!—дип хатыннарның наданлыгын фаш итә иде савыт хужасы.

Әмма ләкин татар авылы һавасы немец алпавытының алтын савытына да ярамый торган булып чыкты. Базар көннәрнең берсендә Ибрай абзый Кандыз базарында шикәр савытын сарык ботына алыштырып алып кайткан.

—Нинди дурак шикәр савытына сарык боты биргән?!—дип бот чабып хәйран калдылар күршеләр.

—Ә какжы, Германиядә ул савытка ике-өч сарык биргән булырлар иде әле!—дип мактанды Ибрай абзый.

—Бу бит сарык боты, ә ул савыт кына, ничек аларны чагыштырасың?

—Савыт кына түгел, алтын савыт!

—Алтынмы, агачмы, савыт—савыт инде ул.

—Әй, сезгә сөйләп тел әрәм иткән мин җүләр,—дип сарык боты чабарга абзарга кереп китте Ибраһим абзый...

Шулай итеп, алтын савыт Кандыз базары аша Оренбург якларына китеп барды. Күрәсең, андагы климат немец савытына әйбәтрәктер. Ә сарык боты туралып, токмачлы аш һәм бәрәңге бәлеше белән ике атнада ашалып бетте.

Ибрай абзыйның Германиядән кайткан ганимәт маллары арасында авылда иң зур эз калдырганы «Золинген» сүзе язылган немец чалгысы булды. Күрергә килгән кешегә хужа чалгының төрле якларын күрсәтә, аннан ике бармагы белән иңләп кенә тотып, уң кулының имән бармагы белән чалгының уртасына чиртеп җибәрә. Матур музыкаль чыңлау тавышы Чаукалык тавын үтеп еракка, Европага, Германия якларына китеп югала.

—Ишеттеңме?

Горур чалгы хужасы «Золинген» коралын башкача формада асылындырып, чалгының башка җиренә чиртә. Атаклы Вуппертальь корычы тавышы Ык суы аша үтеп, Башкортостан урманнары аша Урал тауларындагы корыч коя торган заводларга таба юл тота.

Бу музыкаль эксперимент өч мәртәбә кабатлана.

—Ишеттеңме?—дип сорый ул тантаналы тавыш белән.

—Да-а-а, малай...—дип соклануыннан ни әйтергә белми күршеләр.

Ибрай абзый чалгыны ашыкмыйча ләззәтләнеп чүпрәк белән сөртә, аннан иске ашъяулыкка пөхтә итеп төрә һәм өйдәге сәке астына кертеп куя. Бөтен авыл кешеләре чалгыларын абзарда, сарайда, келәттә тоталар югыйсә. Юк, «Золинген» чалгысы мин йоклаган сәке астында булырга тиеш—дигән катгый карарга килде Ибрай абзый. Һәм атаклы чалгы җәен дә, кышын да сәке астында сакланды.

Киләсе елның язында чалгыга сап куелды, ул бик әйбәтләп чүкелде, үткенләнде һәм Ибрай абзый аның белән беренче тапкыр печәнгә чыкты.

Авылда музей юк, тамаша да сирәк була торган иде сугыштан соңгы елларда. Немец чалгысының ничек чабуын карау авыл кешеләре өчен тамашага әйләнде.

—Кара инде, чабуының тавышы да сизелми!

—Чисталыгын кара син, чисталыгын, җиргә чаклы кырып чаба, чапкан җире таз башы кебек тап-такыр!

—Корал эшләр, ир мактаныр.

—Эх, миндә дә шундый чалгы булса...

Сәхипҗамал түти «Золинген» чалгысының эшләгәнен озак кына күзәткәннән соң, нәтиҗәне үзенчә ясады.

—Юк, җәмәгать, дөрес түгел бу. Үзебезнең чалгылар белән Ибрайга караганда без, өч мәртәбә ким чабабыз. Ибрай бер дә көчәнмичә бездән өч тапкыр артык чаба. Кая монда дөреслек, кая гаделлек? Бирсен колхоз безгә дә немец чалгысын! Әгәр бирми икән, яки безгә хезмәт көнен өч тапкыр артык язсыннар, яки Ибрайга өч тапкыр ким язсыннар!

—Яңадан сугыш чыкса, сине фронтка җибәрербез, Сәхипҗамал. Әгәр исән калсаң, үзенә генә түгел, бөтен колхозга немец чалгысы алып кайтырсың. Алып кайтсаң, без сине бөтенләй эшләтмәбез, ә хезмәт көнен үзебез белән бертигез язып торырбыз,—дип шаяртты бригадир Мөсәяф абзый.

Ибрай абзыйның хезмәт көнен Золинген чалгысы өчен киметмәделәр, билгеле. Аннан соң хезмәт көне хисабы буенча көз көне ашлык бүлгәндә, авыл халкында быел хуҗалыкка кергән байлыкның аермасы сизелерлек булмады. Хезмәт көненә бүленгән икмәк ифрат аз булганга, аз эшләгән кешеләр дә, күп эшләгән кешеләр дә бертигез диярлек аз алдылар: кайсы колхозчыга ярты капчык, кайсысына ике капчык тиде. Ә инде ике капчык икмәк белән бөтен бала-чаганы, кош-кортны ел буе туйдырып булмаячагы бөтен кешегә билгеле. Димәк, бөтен өмет үз бакчаңда үстерелгән бәрәңгедә, яшелчәдә һәм үз мал-туарың биргән ит, сөт, май, йон, йомыркада. Тик хуҗалыкта булган бу продуктлар барысы да колхозчыга эләкми, билгеле, чөнки ит, сөт, май, йомырканы дәүләткә тапшыру өчен ел саен һәр колхозчыга мәҗбүри йөкләмә салалар. Әгәр шул йөкләмәне үтәп, дәүләткә бу продуктларны түгәл тапшырып бетерсәң, калганы—үзеңнеке. Ә калмаса? Анысы синең эш, яшисең килсә калдырырга тырыш, калмаса, киләсе елга чаклы бармакларыңны суырырсың...

Ә дәүләткә бушлай тапшырыламы, сатыламы? Бушлай түгел, сатыла. Дәүләт агенты колхозчы кулына «фәлән чаклы ит һәм май» бирде дип, квитанция тоттыра.

Ул квитанция буенча колхозчы сельсоветка кереп акча да ала, һәм алган акчасы кибеткә кереп тоз, шырпы, сабын алырга җитә. Башка нәрсә алырга бу акча калмый, билгеле, чөнки дәүләт түләгән хак базар хакларына караганда ун тапкыр ким.

Ибрай абзыйның шөһрәт казанган чалгысына тагын борылып кайтсак, аның да гомере бик кыска булды.

Бөтен авылны гына түгел, күрше авылларны да хәйран калдырган җәйге печән өсте үткәч, чалгы тагын чүпрәккә төрелеп, сәке астына кертелеп куелды. Кыш үтеп, икенче җәй җиткәч, Ибрай абзый аны кадерләп кенә сәке астыннан чыгарды, чүкеде, игәү белән үткенләде, янавыч белән янады, яна агач сап куйды. Ялтырап торган үткен корал, тантаналы бәйрәмне көткән музыка инструменты кебек, өйалды нигезенә асылып, печән өсте җиткәнен көтә иде.

Шул көннәрдә Ибрай абзыйны ниндидер эшләр белән Бөгелмәгә җибәрделәр. Хәршидә апа ундүрт яше киткән ай кебек түп-түгәрәк йөзле улы Әмирне урамнан чакырып алды.

—Әмир, бәрәңге бакчасының түбән башында инеш буенда кычыткан котырып үскән. Чап әле шуларны! Сиңа инде күптән печән чабарга өйрәнергә вакыт, ә кычыткан ул бик йомшак, өйрәнергә бик унайлы. Бар, улым!

—Теге чалгы беләнме?

—Шуның белән инде.

—Әткәй ачуланмасмы соң?

—Чабарга өйрәнсәң, рәхмәт әйтер. Әйдә, үзем күрсәтермен, мин бит әзмәз чапкаладым.

Кычыткан инеш буендагы дымлы җирдә котырып үскән, бик яшь һәм йомшак. Хәршидә апа бер урынны җиңел генә чабып ташлады.

—Мә, улым, монда бер көч тә кирәкми. Менә сул кулың белән менә болай, ә уң кулың белән моннан тот. Чалгы җирдән өстәрәк, тигез селтәнсен. Мә, әкрен генә башла!

Беренче селтәгәндә чалгы җиргә кадалса да, тиздән кычыткан тигез генә чабыла башлады. Хәршидә апа тынычланып, салган ашын карарга кереп китте.

Ун-унбиш минуттан өйдән ишек алдына чыккан Хәршидә апа бүкәндә башын иеп утырган Әмирне күреп, ниндидер хәвеф-хәтәр булуын сизенде.

—Бетердеңме, улым?

—Юк. Сынды...

—Нәрсә сынды, чалгымы?

—Ташка бәрелде дә, икегә сынды...

Койма буенда чалгының сабы белән кыска гына юан җире һәм ялтырап

торган озын чалгы йөзе ике җирдә аерым ятмалар иде.

—И, Ходаем, атана нәрсә әйтербез инде?! Мондый нәрсәгә кул тидергән мин җүләр!

Бөгелмәдән кайткан Ибрай абзый сынган чалгыны күргәч, кайгысыннан каралды, тик бер сүз әйтмәде, кибеткә барып ике акбашлы шешә алып кайтты.

Әтисе кайтканда Әмир өйдән чыгып сызган иде инде. Ул бер атна өйдә күренмәде, әнисенең сеңлесе Гөлнурларда куныл яшәде.

Сынган чалгыны заклепка белән ялгап булмасмы дигән өмет тимерчелектә юкка чыкты. Ләкин тимерче Габбас абзый чалгы кисәкләреннән төрле зурлыкта биш-алты пычак ясап биргәч, Ибрай абзыйның кәефе бераз күтәрелде. Бер атна чамасы ул пычакларына сап ясау һәм аларны шомарту һәм үткенләү белән мәшгуль булды.

Ноябрь ахырына тундырып, кар төшкәч, мал сую һәм каз өмәләре башлангач, Ибрай абзыйның абруе тагын күтәрелеп китте.

—Ибраһим абзый, иртәгә безнең каз өмәсе, рәхим итеп, пычагыңны биреп тормассың микән?

Ибрай абзый пычакның дәрәҗәсен белә, шуңа күрә ашыкмый.

—Казларыгыз ничәү?

—Ике оя, егерме бер баш.

—Да-а-а... Бирүен бирмәм, ну үзем кереп суеп чыгармын.

Шулай итеп, сугым суюның һәм каз өмәләренең берсе дә ул пычаклардан башка үтми торганга әйләнде.

Еллар үтеп, егет булып үсеп житкәч, Әмир кичләрен кесәсеннән пәке чыгара да, исе дә китмәгән сыман итеп:

—Теге чалгыдан инде бу,—дип куя.

Бер генә егет тә нинди чалгыдан икәнен сорамый, чөнки авыздан авызга сөйләнеп, бу чалгы авылда легендага әйләнгән иде инде...

...Тальян гармунда ярыйсы гына уйнарга өйрәнгән Вариста киләчәктә кайчан да булса шундый күркәм һәм матур тавышлы «hohner» аккордеоны эзләп табарга һәм аны сатып алып, рәхәтләнеп уйнарга дигән теләк туды. Бу теләкне ул беркемгә дә әйтмәде, тик вакыты-вакыты белән аның күз алдына кызыл һәм алтын перламутрлары ялтыраган аккордеон килеп баса иде.

Шул ук вакытта аның йөрәгендә шундый затлы әйберләр ясаган чит илләрне барып күрәсе килү елдан-ел үсеп, үзгәреп, төрле төсләргә, формаларга алмашынып, әкренләп ашкынулы теләккә әйләнә башлады...



# ПУБЛИЦИСТИКА

## Рафаэль Мостафин

# ТАТАР ЗОРГЕСЫ

ОЧЕРК

### Рихард Зорге турында бәхәс

Бервакыт әллә язучылар җыелышы тәнәфесендә, әллә язучы Ләбибә Ихсанованың фәлән еллык юбилей кичәсендә,—анысы төгәл генә хәтеремдә калмаган,—бәхәс кабынып китте: Рихард Зоргены урыс шпионы дип санарга буламы-юкмы?

—Нинди урыс булсын?!—ди кайберәүләр.—Ул бит чыйкылдап торган немец... Икенчеләре каршы төшә:

—Соң, ул бит Советлар Союзына хезмәт иткән, фашистик Германиягә каршы көрәшкән. Советлар Союзы Герое исеменә лаек булган разведчик!

—Японнар җәзалап үтергәннән соң егерме ел үткәчме?..

—Булса ни! Разведчикларның һәммәсенең дә язмышлары шундыйрак... Исән чакта аларны кем дә белми, һәлак булгач кына үзләренә герой исеме бирәләр.

—Алар турында китаплар языла, кинофильмнар төшерелә, урамнарны алар исеме белән атыйлар...—дип күтәреп ала кемдер.

—Эш анда түгел. Рихард Зорге—милләте белән немец, әмма ул үз халкына хыянәт итмәгән, ул фашизмга каршы көрәшкән...

—Сталин режимына таяныпмы?

—Ул елларда кайсы коммунист башкача эшләгән булыр иде? Зорге ихлас марксист булган, коммунизм идеалларына ышанган.

—Әйе шул. Мин дә кушылам бу сүзләргә. Кайсыдыр китаптан укыдым: аның бабасы Фридрих Зорге да Карл Маркснең турылыклы шәкерте һәм көрәштәше булган бит. Көнбатыш Европа илләрендә әле хәзер дә аны оныгына караганда күбрәк хөрмәт итәләр икән. Ул—Беренче Интернационалны оештыручыларның берсе, аның Генераль секретаре да булган. Рихард Зорге, димәк, бала чагыннан ук марксистик рухта тәрбияләнеп үскән, һәр эштә бабасына охшарга тырышкан, дигән сүз.

—Шулай. Ул демократик Германиянең якты киләчәгенә ышанган, шуның өчен гомерен биргән...

Шунда сүзгә Ләбибә Ихсанованың кызы Әлфия Минһаҗева кушылды.

—Әйе, хәзер Рихард Зорге—халыкара танылган мәшһүр шәхес. Анысы бәхәссез. Ә сез сугыштан соңгы елларда Зорге эшен Япониядә кем дәвам иткәнен беләсезме? Разведчик булып...—диде ул.

Жыелышкан халыкның колаклары торды.

—Белмибез...

—Кем ул, кем?—диештеләр.

Әлфия ханым, әле анык кына җавап бирмичә, елмаеп сүзен дәвам итте:

—Кем анда агентларны янадан булдырган? Кем Япониянең Америка булышлыгы белән коралланa башлавы турындагы кыйммәтле мәгълүматларны Мәскәүгә хәбәр итеп, андагы Америка хәрби базалары һәм кораллары турында да белеп торган.

—Йә, әйт инде, әйт!

—Безнең якташыбыз Шамил Хәмзин...—диде Әлфия ханым.—Ул үзенең хатыны, турылыклы көрәштәше Бибиирам Алимова белән бергәләп эшләгән. Хатыны да ярым татар кызы...

—Сез боларны каян беләсез?—дип кирәкмәгәнрәк сорау бирде кемдер.

Ул кешенең колагына гына пышылдап, Әлфия ханымның Татарстан Республикасының Дәүләт Куркынычсызлыгы Комитетында, җәмәгатьчелек белән элемтәләр бүлегендә эшләгәнлеген әйттеләр. Димәк, ул белә дә белә инде!

Мине, Бөек Ватан сугышы елларында татарларның, аерым алганда, җәлилчеләрнең һәм башкаларның батырлыклары турында күптәннән мәгълүматлар җыеп, китаплар язучы буларак, бу сөйләшү бигрәк тә кызыксындырды. Мин Әлфия ханымның эш телефонын алдым, аннары алдан шалтыратып, Черек күлгә—мәгълүм йорттагы аның эш бүлмәсенә киңдем. Һәм бик кызыклы мәгълүматларга тап булдым.

Шамил Хәмзин белән хатыны Бибиирам Алимовага кагылышлы мәгълүматларны, япон матбугатында алар турында мәкаләләр басылып чыкканнан соң, яңарак кына ачканнар икән. Шуңа чаклы алар «яшерен сер» тамгасы белән саклаңган.

—Миңа ул архив белән танышырга мөмкин булмасмы?—дип сорадым Әлфия ханымнан.

—Мөмкинен мөмкин,—дип җавап бирде Әлфия ханым сүзә төшеп.—Әмма башта кайбер рәсми шартларны үтәргә кирәк булыр.

Бу «рәсми шартлар» дигәнен үтәп бетерү өчен ике еллап вакыт сарыф ителде—оешмасы шундый бит: КГБ...

Һәм менә, ниһаять, Татарстан журналистларыннан беренче буларак, миңа ул бәһасез архив материалларын өйрәнергә рөхсәт иттеләр.

## Таш капчыкта

... КҮЗЛӘРЕ караңгыга иялөшә төшкәч, Шамил тирә-ягына карана башлады. Ул тәрәзәсез-нисез түгәрәк таш капчыкта—зинданда иде. Түшәмгә үк беркетелгән тонык лампочка ялангач бетон диварны, салам чыпта капланган тар гына ятак урынын сүрән генә яктырта. Сөрсегән, тынчу һава... Ишек янындагы балчык чүлмәктән нәҗес-бәвел исләре аңкый...

«Менә нинди икән ул Кытай төрмәләре! Хан заманнарыннан бирле шундый булганнардыр...»—дип, күңелсез ачыш ясады Шамил.

Кайда, кайчан, нинди хата ясады икән соң әле ул? Ничек «тишелде» икән? Әле бит «эшнең» башы гына иде...

Әгәр гомерең буена шушында калсаң?.. Терелөй черетсәләр?.. Исемең-җисемең кайларда юкка чыкканын туган илеңдә белми дә калсалар?.. Юк! Бу—мөмкин түгел! Мөмкин түгел!

Үзәк эшләгән «легенда»—фараз буенча, ул бит—Әнвәр Садыйк, уйгур. Туган җире—Төньяк-Көнбатыш Кытайның Кашгар төбәге. Аның документлары да ялган түгел, чып-чын—беркем бәйләнерлек-шикләнерлек урын юк. Ә үзенең «туган авылын» ул, Мәскәүдәге махсус мәктәптә укыганда ук, әнисеннән җибәнә кадәр итеп өйрәнде, җиде төн уртасында уятып сорасалар да, шартлатып сөйләп бирер иде. Ул «авылдашларының» бөтенесенең исемнәрен генә түгел, хәтта кушаматларына хәтле белә,

кайсы йорт кай тирәдә икәнен дә әйтә ала, авыл читендәге тауларны, җәйрәп яткан даланы биш бармагы кебек өйрәнгән. Уйгурларның гореф-гадәтләре, йолалары турында инде әйтеп торасы да юк. Хәтта төшләрен дә уйгурча күрергә өйрәнгән иде ул.

Болай тышкы төс-кыяфәте белән дә суйган да каплаган уйгур иде инде. Шунысы да бар, гомумән генә, уйгур кешесе түгел, ә исеме-аты тагаен булган уйгур Әнвәр Садыйк иде...


*Менә ул татар Зоргесы—Шамил Хәмзин*

Кырыгынчы елларның икенче яртысында,—Бөек Ватан сугышы беткәннән соңрак, дип өстик,—Шамил Хәмзинны совет-кытай чиге аша Кытайга юлладылар. Ул елларда әле Кытайның үзендә граждан-нар сугышы бара: Маоцзедун гаскәрләре белән гоминданчылар сугышып ята иде. Ә уйгур Әнвәр Садыйкның ул тарткалашу-ларга катнашы юк—ул сәүдә кешесе. Ул үзенең сатар малы белән бер шәһәрдән икенчесенә күчеп йөри-йөри, бөтен Кытайны диярлек иңли: колагы күпне ишетә, күзе күпне күрә. Шулай йөри торгач, Әнвәр Садыйк, ниһаять, Кытайның көнчыгышындагы диңгез буенда иң эре шәһәрләрнең берсе булган Тяньцзинь шәһәренә барып чыга. Монда—диңгез порты. Ә ул нәкъ шунда барып чыгарга тиеш тә була: Мәскәүдә расланган «легенда» буенча ул шунда бер кыз белән танышырга тиеш,—ул кыз Үзәктән җибәрелгән радист, Шамил шуңа «гашыйк булырга» һәм... өйләнергә дә тиеш! Менә шулай! Ошыймы әле ул кыз сиңа, юкмы—анысы Үзәк өчен «вак мәсьәлә». Өйләнешү чынлап, бернинди ясалмалыкларсыз булырга тиеш. Аннары яшь кияү белән кәләш Гонконгка юл тотар (туй сәяхәте!), анда сәүдә фирмасы ачып җибәрерләр, япон сәүдә фирмалары белән ныклы бәйләнешкә кергәч, бераздан алар булышлыгы белән үзләре дә Японияга китәр. Япония—төп максат. Күрдегезме, нинди катлаулы юл үтәсе бар...

Һәм менә юлның башында ук бөтенесе дә чәлпәрәмә килде шикелле. Шулай ук Шамил Хәмзин Кытайның шушы таш капчыгында эзсез-хәбәрсез череп югалырмы? Кайда һәм нәрсәдә ялгышты ул? Кайда һәм нәрсәдә?

## Пароль—«Юха—55»

БЕР ТӘҮЛЕК таш капчыкта ятканнан соң, Шамилгә ярты кружка тынчып беткән җылымса су белән ниндидер көрән төстәге болганчык нәмәрсә бирәләр—аш дисәң—аш түгел, ботка дисәң—ботка... Моннан да тамактан үтмәс ризыкны аның әле гомер күргәне юк иде. Әмма... ашарга кирәк! Укшуыңны басып булса да... Яшисе бар... Яшәү өчен көчеңне саклау кирәк. Ул әле көрәшәчәк! Аны шулай өйрәттеләр...

Тяньцзиньда ул шундагы уйгурлар һәм татарлар белән танышкан иде. Биредә берничә дистә гаиләдән торган татар төбәге (хәзергечә әйтсәк, диаспорасыдыр инде) бар икән—берәүләренең тамырлары Октябрь революциясенә кадәр үк әти-энилере Россия-Кытай тимер юлын салуда катнашкан заманнарга барып тоташа, икенчеләрен революция давыллары бу якларга китереп ташлаган, өченчеләре... Һи, нигә санап торырга, ди? Татарны язмыш җилләре кай тарафларга гына чәчмәгән?

Холкы-табигате белән шат күңелле, кунакчыл-юмарт «уйгур егете» алар арасында тиз арада дуслар таба, үз кеше булып китә, озакламый шунда яшәргә дә күчә.

Шамилгә шулкадәр ышанып карыйлар, элекке татар байлары гаиләсеннән чыккан берәү—кытай контрразведкасы офицеры—аны, зур хезмәт хакы һәм төрле өстенлекләр белән кызыктырып, үзләренә эшкә тартырга да уйлый хәтта. Шамил әдәпле генә итеп бу тәкъдимне кире кага: «Мин— сәүдәгәр,—ди.—Холкым-табигатем, телчәнлегем белән разведчик була алмыймдыр...» Шуннан соң әлеге офицер үзе бик тә ошаткан бу «уйгур егетенә» бер пароль әйтә: «Әгәр дә бик кыен хәлгә тарсаң, кулга ала-нитә калсалар, контрразведка вәкиле белән очрашу сора, аңа исә шуны гына әйт: «Юха—55». Шамил ихластан көлеп җибәрә, аңа—сәүдә кешесенә котрразведканың кирәге булырмы икән?

Әллә ул офицер алдан берәр нәрсә сизенгәнме, әллә башкачамы— чынлап та, бу сөйләшүдән соң берничә көннән Шамилне кулга алып, менә шушы таш капчыкка биклиләр. Аны монда күпме тотарлар икән? Әгәр дә бу гади тикшерү генә булса, аның документларының чынлыгына ышангач, аннары «туган җире» Кашгардан белешмәләр килгәч, аны азат итәргә тиешләр. Мондый очрак булу мөмкинлеген Үзәк алдан күреп, кисәтеп куйган иде: кулга алсалар, тыпырчынмаска, тикшерү нәтиҗәләрен тыныч кына көтеп утырырга.

Һе, көтеп утырырга... Әйтүе ансат! Менә шушы таш капчыкта утырып кара әле син. Шамил тәвәккәлләргә була—гоминдан контрразведкасы вәкиле белән очраштыруларын сорый. Аның теләгән үтиләр, сорау алырга китергәч, ул офицерга теге парольне әйтә: «Юха—55». Офицер аптырап кала: «Сез моны каян беләсез?»—дип сорый. Шамил—ләм-мим. Аның сүзләрен ишетми дә, тәрәзәгә таба борыла. «Юха—55» үз көчен күрсәтә бит! Шамилгә бөтенләй башкача карый башлыйлар. Сугучы-кыйнаучы да юк, ашау яклары да рәтләнә төшә. Хәтта укырга газеталар да бирәләр. Һәм... бер атнадан—ул иректә!

Бу «таш капчык» вакыйгасы тәки шулай ачылмый кала. Ни өчен аны кулга алганнар? Нәрсәдән шикләнгәннәр? Ничек шулай тиз азат иткәннәр? Биредә хикмәт «Юха—55» паролендә генә булмагандыр. Татар-уйгур милли теләктәшлеге-бердәмлегендә дә булгандыр, мөгаен.

## Ничек разведчик булалар?

МОНДЫЙ сорауны малайлар бирергә ярата, чөнки аларның һәркайсы хыялында батыр разведчик була.

Шамил Габдуллаҗан улы Хәмзин 1915 елда Архангельск шәһәрендә туа. Әти-әниләре ул якларга кайлардан барып чыккандыр—билгесез.

1923 елда Хәмзиннар гаиләсе Казанга күченеп кайта. Уң Болак урамында яши башлый алар. Туганнары һәм дуслары Шамилнең шат күңелле, шук-шаян, зиһенле малай булып үскәнлеген искә ала. Ул спортның төрле төрләренә йөрергә яраткан. Җәй көннәрендә Идел буйларында балык тоткан, су коенган, кызынган. Аның сугышка кадәр Түбән Осланда дус-ишләре белән төшкән фоторәсемнәре сакланып калган: таза-тыгыз тәнле егет комлыкта, кулларына таянып, баштүбән тора... Икенче рәсемдә ул, су чәчрәтә-чәчрәтә коенып чыгып килә. Кояшта янган тәненең мускуллары уйнап тора...

Урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, Шамил Хәмзин Ленинград электротехника институтының приборлар төзелеше бүлегенә укырга керә. Җиңел керә. Студентлык елларында хәрби сер булган өлкәдә шөгыльләнә: самолетлардан җибәреп, радио аша идарә ителә һәм тиешле урынга барып төшә торган торпеда уйлап таба. Ул вакытларда әле «ракета» төшенчәсе телдә дә булмый.

Менә шунда инде бу сәләтле егет белән тиешле оешмалар кызык-сына башлый. Егет сәләтле, бик тиз дуслашучан-аралашучан. Тырыш, намуслы, шактый зыялы. Шамил, техникадан кала, шигърият, музыка белән мавыга, күп укый. Сәламәтлеге дә, кем әйтмешли, Аллага шөкер— баһадирларча.

Укуын тәмамлап, Мәскәүдәге оборона предприятиеләренең берсендә эшли башлагач та, Шамил Хәмзинны күз уңыннан ычкындырмыйлар. Шунда ул коммунистлар сафына баса.

Бу вакытта инде илдә Бөек Ватан сугышы дөрли. Шамил Хәмзин, фронтка ирекле булып китәргә теләп, берничә мәртәбә рапорт яза, ләкин аны җибәрмиләр. Ә 1943 елда аңа куркынычсызлык органнарының тышкы эшләр разведкасы идарәсенә эшкә күчәргә тәкъдим ясыйлар. Немец-фашист илбасарларына каршы көрәшкә атлыгып торган егет ике уйлап тормый, шунда ук риза була. Чөнки ул, бераз укыткач-өйрәткәч, үзен фашистлар тылына ташларлар дип исәпли. Әмма язмыш аны башкага әзерли икән. Шамил Хәмзинны КГБның махсус мәктәбенә укырга җибәрәләр. Ул анда берничә ел дәвамында гаять катлаулы һәм куркыныч булган разведчик һөнәренең әлифбасыннан—«А»дан «Я»га кадәр генә үтеп калмый, ә чын мәгънәсендә аның төбенә төшеп өйрәнә.

Бу махсус мәктәпкә килгәндә аңа инде егерме сигез яшь була. Җитлеккән, акыл утырткан шәхес. Аңа баштарак авырга туры килә. Фәнни эштә, кирәксә—иртә торып, кирәкмәсә иркенрәк тә яшәргә күнеккән кешегә биредәге һәр минуты исәпле-санаулы эш сәгатьләренә тартылуы җиңелдән булмый.

Сәгать иртәнге алтыда сикереп торасың. Урын-җиреңне җыештырып, юынып-кырынып, саф һавада башта биш минутлык физзарядка ясап аласың да, өйдә—җиде кат тирләрең чыкканчы, кырык минут йөгертәләр.

Җиде сәгать утыз минутта—иртәнге аш.

Аннары—дәресләр, дәресләр, дәресләр... Һәр укучы өчен аерым укытучы, аерым программа. Бары тик төрле коралларны өйрәнү, пистолеттан ату, радио эше, психология (кешеләргә тәэсир итә белү, үзеңне кеше тәэсире-йогынтысыннан саклап кала алу, кирәкле кешене «эшкәртеп», аны үзеңә буйсындыру, гипноз нигезләре һ. б.), медицина (нигездә травматология), чит радиотапшыруларны тота белү һәм кирәкле элемтә чараларын тыңларга өйрәнү, шәһәрдәме-авылдамы, ялан кырда-урмандамы—күзәтә-әзәрлекли белү, икътисад фәне һәм башкалар... Аларны санап бетерерлек тә түгел.

Төшке аштан соң, көн саен спортзалда ике сәгать буена кул сугышы нечкәлекләренә өйрәтәләр. Самбосы да, дзюдосы да, башкасы да калмый.

Болардан тыш, вакыт-вакыт курсантларны төрле гайре табигый шартларда исән калу күнекмәләренә дә өйрәтәләр: салкын кышта урманда, эссе чүл-далаларда бер азыксыз-сусыз яшәргә кирәк. Аннары—тәүлекләр буе бер кешелек ялгыз камерада утыр! Сынма-сыгылма! Төрле психотроплы чараларны күтәрә бел! Монда да—һ.б. һ.б. һ.б. Ә инде йөзү, кылыч сугышы (фехтование) һәм башка спорт төрләрен Шамил Хәмзин үзе дә бик ярата.

Гомуми фәннәрне үзләштерә барган саен махсус фәннәргә тирәнрәк керәләр: илләр өйрәнү (Шамил Хәмзин нигездә Кытай белән Японияне җентекләп өйрәнә), көнчыгыш диннәре (буддизм, синтоизм, конфуцианлык), телләр (уйгур, төрек, кытай, инглиз, япон телләре), төбәкне өйрәнү («туган уйгур авылы», аның кешеләре, «туган-тумачалар» һ. б.).

Шамил Хәмзин үз һөнәрендә вак-төякләр булмаячагын күңеленә ныклап сеңдерә: ачы тәҗрибә шуны күрсәтә—хәтта дөньяның иң атаклы разведчиклары-шпионнары да нәкъ менә «вак-төяктә» яналар...

Кичке сәгать унда—отбой. Шамил шулкадәр нык арый, ятуга йокыга тала, хәтта төшләр дә күрми...

## Фәрман буенча өйләнү

«КӘЛӘШ» ТУРЫНДА да берничә сүз әйтеп үтик. Хәер, кәләш сүзен куштырнаклар эченә алмаска да була. Моның шулай икәнен алдарак күрербез әле.

Бибииран Алимова (Мәскәүдә аны Ирина дип кенә атап йөртәләр)

1918 елда Төрекмәнстанда туа. Аның әтисе Кәрим Алимов чыгышы белән Татарстанның Буа районыннан була. Гражданнар сугышы чорында Урта Азиягә барып эләгә һәм шунда төрекмән кызына өйләнә, төпләнеп кала.

Бала чагында Бибииран артистка булырга хыяллана. Чибәр була ул. Аның хыялы тормышка аша: урта мәктәпне тәмамлагач та, ул «Төрекмәнфильм» киностудиясендә эшли башлый. Баштарак төрле кечкенә рольләрдә уйный, аннары Төрекмәнстанда зур уңыш казанган «Умбар» фильмында баш рольне башкара. Ленинградта кинорежиссер Георгий Козинцев остаханәсендә укый. Артистлык сәләтеннән тыш, Бибииранның бала чагыннан ук чит телләргә һәвәслеге дә ачыла. Ул төрекмән, татар, урыс телләрен су кебек эчә, тагын немец телен яхшы белә, төрекчәне дә өйрәнә. Бөек Ватан сугышы башлангач, сәләтле кыз фронтка тәрҗемәче булып китә. Анда инде, әлбәттә, дәүләт куркынычсызлыгы оешмалары белән тыгыз элемтәдә эшли, вакыт-вакыт аларның бик тә четерекле йомышларын башкара.

1947 елда Бибииран туган Ашхабадына әйләнеп кайта. Яңадан артистлык һөнәренә керешергә ниятли ул. Әмма кызны янә тиешле оешмага чакырып алалар да Көньяк-Көнчыгыш Азиядәге тышкы разведканың резиденты бурычын үз өстенә алуын «үтенәләр». Бибииран Алимова, бераз уйланганнан соң, ризалык бирә: кирәк икән—кирәк! Ахыр чиктә, разведчиклык—шул ук уен, әмма куркыныч уен, аңа да артистлык сәләте дә, үз һөнәреңне яхшы белү дә хас ич. Әйе, бу «уенда» кат-кат кабатлауларсыз һәм хаталарсыз «уйнау» тиешле. Үзәк язган сценарий буенча, әмма режиссерларсыз һәм әйтеп торучы суфлерларсыз «уйна». Бары тик шул гына.

Үзәк оештырган «легенда» буенча Бибииран Алимова бик бай һәм нәсел-нәсәпле уйгур гаиләсенең Хатыча (татарча Хәдичә түгелме икән?) исемле кызына әверелергә тиеш. Аның «әти-әниләре» Садыйклар гаиләсе белән күптән таныш икән дә, кызны алар үзе гомердә дә күрмәгән Әнвәргә ярәшкәннәр, имеш. Чынлап та, Бибииранның Әнвәр-Шамилне бер дә күргәне булмаган. Менә шуның белән очрашу өчен ул Кытайның Тяньцзинь шәһәренә сәяхәткә чыга.

Килеп төшә Бибииран Тяньцзиньга кичләтеп... Әмма... бер каршы алучы да юк! Шамилгә ул кичтә нәрсәдер комачаулаган була. Кыз, аптырашта калып, як-ягына карангалап торганда, аның янына полицейский килә. Хатыча-Бибииран тиз генә үзен кулга ала һәм уйгурчалап тегеңә шундый сүзләр ядыра: «Урамда төн, ә сездә юньләп яктыртмыйлар да икән, күзгә төртсәң дә бернәрсә күрмәссең». Көтелмәгәндә үзенә эләккән шелтәдән каушап калган полицейский аңа рикша тотарга булыша һәм якындагы кунакханәгә юлны да өйрәтеп җибәрә.

Үзәкнең запас варианты буенча егет белән кыз икенче көнне иртән универмаг янында очрашырга тиеш була. Бу юлы Әнвәр-Садыйк вакытында килә һәм яшьләр күзгә-күз очраша...

Шундый четерекле-киеренке хәлне күз алдыгызга китерегез: очрашырга, гашыйк булырга һәм, өйләнешеп, гаилә корырга... Әйтергә генә җиңел! «Гашыйк булырга»—ә күңелең тартмаса, бер-береңне ошата алмасаң? Егет тә, кыз да,—Шамил дә, Бибииран да дигәнем,—бу очрашуны шөбһәләнеп вә шул ук вакытта өметләнеп тә көтә. Шулай булмыйни?! Шамилгә инде утыз ике яшь—ул әле һаман буйдак, Бибииранга да утыз тулып килә—бу яшендә кияүгә чыкмый калган шәрекъ кызын күз алдына да китереп булмый.

Йә Хода! Менә очраштылар һәм... бер күрүдә үк бер-берсен ошаттылар. Юк, монысы инде Үзәк фәрманы белән түгел, ә күңел кушуы белән була. Кыз да бик чибәр, егет тә төшеп калганнардан түгел ич. Ә иң мөһиме шул—алар бер-берсенә бик тә пар килә, бер-берсен тулыландырып тора. Үзәкнең психологлары үз икмәкләрен бушка гына ашамыйдыр шул!

Әй икегез, икегез,
Икегезнең битегез,

Икегез дә пар килгәнсез—
Тигез гомер итегез!

Менә шулай! Алга таба Үзәк «сценарие» белән ике яшь йөрәк «сценарие» кушылып китә: айлы төннәрдә очрашулар, көтеп-сагынып сөйләшүләр, «кочышу-үбешүләр» дип әйтмик—анысы кырыс ислам кануннарына сыеп бетмәс иде, әмма тыйнак кына иркәләшүләрсез дә калмагандыр.

Ниһаять, нәкъ ислами шәригать кысаларында өйләнешеп, Шамил белән Бибииран туй үткәрә. Гадәти гаилә тормышы шулай башлана.

Әмма... 1949 ел! Кытайда Маоцзедунның халык армиясе җиңеп чыга. Яшь гаилә, меңләгән бай кытайлылар агымына кушылып, Гонконгка кача. Элекке элемтәләрен дә югалтмыйча, яңаларын да булдыра алар...



*Яшь кияү белән яшь кәләш. Ш. Хамзин һәм Б. Алимова. Кытай, 40 нчы еллар ахыры*

Читтән караганда да Шамил белән Бибииран менә дигән пар була: икесе дә чибәр, затлы киенә, байлар! Гонконгта да аларның үз кибетләре ачыла, сәүдәләре гөрләп бара. Өйләрендә алар иң кунакчыл хуҗа була, аларга кемнәр генә килми дә, кемнәр генә кунак булмый! Шунысын да әйтергә кирәк, Үзәк бу чорда аларга акчалата берничек тә ярдәм итә алмый—моның шик уятуы мөмкин булыр иде. Шулай итеп, бай сәүдәгәр уйгур Әнвәр Садыйк белән аның гүзәл хатыны Хатыча үз көннәрен үзләре күрергә тиеш була. Ә моның өчен көнен-төнен эшләргә кирәк... Монда сиңа «алма, пеш, авызга төш» дип ятарга һич ярамый. Капиталистик Гонконг бу, абзыкай!

## Эшләре гөрли сәүдәгәрләрнең

1954 ЕЛНЫҢ көзендә—«салкын сугыш» дигән афәтнең иң кызган чорында Әнвәр Садыйклар гаиләсе Японияга күчеп китә. Әүвәле Кобэ шәһәренә, соңрак—Токионың үзенә үк. Бу гамәл беркемдә дә шик-мазар уятмый, чөнки бай сәүдәгәр Садыйкларны Япония эшмәкәрләре инде күптәннән—биш-алты ел белә килә. Әнвәр Садыйклар Токионың абруйлы районнарының берсеннән зур булмаган җир кишәрлеге сатып ала (ә Токиода зур мәйданнар сатып алырга мөмкин дә түгел!). Аларның ике катлы зиннәтле йортлары һәм кечкенә генә бакчалары була. Йортның беренче катында—кибет, икенче катында үзләре яши. Тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары, йорт җиһазлары, кием-салым, азык-төлек белән сату итә алар. Кыскасы, кайчан нәрсә яхшырак үтә—шул сәүдәдә була. Эшләре гөрләп барган сәүдәгәрләр исемен тотарга кирәк бит.

Капиталистик кырыс конкуренция-көндәшлек шартларында үз куышыңны табу, башкалардан «йоттырмау» зур маһирлык сорый. Монда—кем кемне! Бары тик шулай гына. Шунда гына Шамил Хәмзин КГБның махсус мәктәбендә, утлы кораллардан атуга өйрәтүдән битәр, игътибарны күбрәк икътисад нигезләре һәм эшмәкәрлеккә ни өчен юнәлткәннәрен ныклап аңлый.

Кытайдагы шикелле үк, Әнвәр Садыйкларның биредә дә дуслары-танышлары ишәйгәннән-ишәя бара, өйдән кунаклар өзелми. Ирле-хатынлы

Садыйклар Токиодагы америкалылар клубына сукмак сала, өйрәнеп төрки телле мөселман җәмгыятьләре белән тыгыз элемтә урнаштыра. Болардан тыш Хатыча абруйлы хатын-кызлар клубына да языла.

Акчага бик кытлык булган мәлләрдә («бай сәүдәгәрләрдә» анысы да булгалый!) Хатыча кичләрен утырып челтәр якалар бәйли, аларны үз кибетләренә куеп, «сиңа гына бирәм» дип, байбикәләргә сата тора. Зур зәвык белән бик матур итеп бәйләнгән ул якаларга сорау зур була. Ни әйтерсең—экзотика!

Бераздан Садыйклар чыгышлары төрек булган америкалы хәрбиләр белән аралаша, алар белән төрекчә сөйләшә башлый. Төрекләр «үз мөселманымыз-кардәшемез» йортын бик ярата. Бирегә аларны һәрвакыт күңел җылысы, кунакчыллык көтә, алар рәхәтләнеп үз ватаннарының җырларын тыңлый ала. Төрекләр үзләре үк Садыйкларда авыр хәрби хезмәттә каткан күңелләренең эрегәнлеген, беркемнән шикләнмичә ял итү мөмкинлеге барлыгын сөйли. Һәм, курыкмыйча, үзләре дә сизмәстән, мөһим хәрби серләрне дә үзара-сүзара чыгарып сала тора.

Ә төннәрен ирле-хатынлы Садыйклар Үзәккә хәбәрләр яза, аны микротасмага төшереп, кечкенә тартмачыкка сала һәм билгеләнгән яшерен урынга илтеп урнаштыра. Аннан инде хәбәрләр Мәскәүгә барып ирешә. Менә архивларда сакланып калган шундый хәбәрләрнең берсе (оригиналын тәрҗемә итми китерәбез): «Георгу. Стало известно, что в обстановке секретности спущена на воду подводная лодка нового типа, оснащенная новейшим оборудованием. Бир.» (Бир—Бибиранның псевдонимы). Әлбәттә, мондый хәбәрләр шифр белән языла һәм Мәскәүдә генә укыла.

Садыйклар, америкалыларның Көньяк-Көнчыгыш Азиядә яңа хәрби-сәяси төркем оештыру планнары барлыгын, бу төркемгә, Японнядән тыш, Көньяк Корея, Көньяк Вьетнам, Тайвань, Тайланд, Филлипин, Яңа Зеландия һәм тагын берничә илнең керү мөмкинлеген алдан белеп, Мәскәүгә үз вакытында хәбәр дә итә. Халеф (Шамил Хәмзинның псевдонимы) бу хакта Үзәкне берничә ай алдан кисәтә, сөйләшүләрнең Сеул шәһәрендә 1966 елның җәендә үтәчәген хәбәр итә. Бу хәбәр дөрес булып чыга: 1966 елның 14-16 июлендә Сеулда тугыз илнең чит ил эшләре министрлары конференциясе үткәрелә, шунда Азия—Тын Океан советы оештырыла.

Совет разведчигы полковник Шамил Хәмзинның (Халефның) архивында аның Мәскәүгә җибәргән хәбәрләре тупланган байтак папкалар бар. Алар арасында төрле дәүләтләрнең СССРга каршы хәрби көч кулланып каршы тору мөмкинлеге турындагы уй-ниятләре дә, чит илләрдә эшләнә башлаган яңа төр ракета һәм башка стратегик коралларның тактик-техник мәгълүматлары да, СССРдагы сәнәгать һәм хәрби объектларның кайсыларына карата шпионлык эшләре алып барылганлыгы да һәм тагын бик күп нәрсәләр бар.

## Унөч ел буена «ачылмыйча»

ИРЛЕ-ХАТЫНЛЫ Хәмзиннар (Садыйклар) Японнядә, ачылмыйча-тотылмыйча, унөч ел яши. Разведчиклар өчен, мөгаен, рекордлы вакыттыр бу! Унөч ел буе, бер генә хата-ялгыш та җибәрмичә, үз рольләренә «уйнап» яшәп кара әле. Әлбәттә, бик киеренке мизгелләр, четерекле хәлләр дә булган, булмыйча каламы соң?!

Бервакыт Шамил Хәмзин юл һәлакәтенә тара, машинасын җимертә, аягын сындыра. Ә нәкъ шул кичтә,—егылып үлсәң—үл!—ерак шәһәр читендәге билгеләнгән яшерен урынга шифрланган чираттагы хәбәрне илтеп саласы бар. Бибиран ханым, икеләнергә урын калдырмаслык итеп: «Үзем барам!»—ди. Әйтүе җиңел! Беренчедән—ерак, төн. Такси яки машина-фәлән алсаң, полиция әзеңә басачак: «Бу сәүдәгәр хатыны төн уртасында шәһәр читендә нишләп йөри әле?»—диячәкләр.

Ә җәмәгать транспорты дигәнең Токиода Казандагыдан да начаррак йөри. Аннары, ул әле шәһәр читенә үк барып та җитми. Икенчедән—куркыныч та бит. Ул тирәләр җыен әтрәк-әләм, җинаятьчеләр белән тулы,

төн уртасында ялгыз яшь хатынга кул сузарга телəүчелəр булмасмы? Əмма башка чара да юк...

Соңыннан, инде туган илгə кайткач, Ирина (Бибииран) Кəримовна журналист В. Головачевка бу хакта сөйлəгəндə «йөрəге ярылыр хəлгə җиткəнлеген» əйтə. Төнге шəһəр чите. Ярлы алачыклар. Йорт-җирсез сукбайлар (хəзергечə əйтсəк—бомжлар) картон тартмалар бөркəнеп урамда ук йоклап ята. Тартма астыннан аяклары гына тырпаеп сузылып чыккан... Бибииран əнə шул аяклар аша атлый, һəр мизгелдə берəрсе аяк чалырга, һөҗүм итəргə мөмкин бит. Урамнар буп-буш, ул-бу була калса, ярдəмгə чакырырга этле җан да юк.

Аллага шөкер, барысы да хəвеф-хəтəрсез генə үтə, Бибииран бурычын үти, Мəскəүгə җибəрелəсе хəбəрне урынына илтеп куя. Əмма кайвакытларда əле һаман да ул, куркыныч төшлəр күреп, шабыр тиргə батып уяна: менə ул, имеш, ярты төн уртасында, караңгыда шул сузылган аяклар аша атлый, тирə-юньдə гырлап йоклыйлар, кемнəрдер ыңгыраша, ниндидер сəер кыштырдаулар... Менə аңа ташланалар!.. Юк!!! Һəм ул куркып уянып китə...

Икенче вакыйга ирле-хатынлы икəүлəп шəһəрдəн читтəге ерак префектурага барып кайтканда була. Шулай ук төн уртасы. Коеп яңгыр ява. Тау битеннəн бормаланып узган авыл юлыннан кайтып килəлəр. Бер урында юлны яңгыр нык юган икəн. Шамил тормозга баса, əмма машина һаман аска шуа... Шамил хатынына: «Сикер!»—дип кычкыра. Бибииран: «Юк, син сикер! Син кирəгрəк»,—дип тарткалаша. Шуннан соң Шамил, бер кулы белəн рульне тоткан килеш, машина ишеген ача да хатынын төртеп диярлек төшерə. Аның артыннан үзе дə сикерə.

Аларны юлның бүлтəебрəк чыгып торган төше коткарып кала. Бераз бəрелгəн-сугылган җирлəре булса да, артык зыянлы түгел икəн. Ə машиналары аска таба тагын бер ун метрлап шуып бара да, упкынга мөтəлдем дигəндə генə, бер агачка элəгеп эленеп кала. Ир белəн хатын манма су булган, пычранып беткəн, тырналган-бəрелгəн килеш юлга күтəрелə: нишлəргə хəзер? Юл полициясе белəн бер дə очрашасылары килми. Юлда булган төрле хəллəр турындагы хəбəрлəргə исем-фамилияң элəксə—бетте! Шунда ук сорау туачак: америкалыларның хəрби базаларыннан ерак түгел җирдə төн уртасында нишлəп йөргəн əле алар? Һəрхəлдə, бу сəяхəт аларның сəүдə эшлəренə кагылышлы була алмый... Шуннан алар авыл халкыннан ярдəм сорарга була. Якындагы бер авылга барып куналар, иртəн əйбəт хак түлəп трактор яллыйлар да машиналарын тартып чыгаралар. Хуҗага да юмарт түлəнə, ниндидер уйдырма сөйлилəр, полициягə əйтеп тормаска булдык, дилəр. Машина шактый яньчелгəн-изелгəн икəн, аны калдырып, прокатка икенче машина алып, кайтып китəлəр.

Шулай итеп, бу юлы да Ходай Тəгалə саклап кала үзлəрен...

## Садыйклар турында япон матбугаты

ШАМИЛ ХƏМЗИН Япониядə алдырган фоторəсемнəрендə киң күңелле, таза гына бер ир-ат булып күренə. Еллар үтү белəн ул, чынлап та, тазарып-юанаеп киткəн, абруйлы-дəрəҗəле сəүдəгəр инде менə! Аны еш кына беркатлы кеше дип кабул итəлəр. Кунакчыллыгыннан, юмартлыгыннан тартынмыйча файдаланалар: əҗəткə акча алып торалар да кайтарып бирергə «оныталар». Əнвəр Садыйк исə кул гына селти: «Эшлəребез, Аллаһыга шөкер, əйбəт бара, борчылмагыз, аннан гына бөлмəбез əле»,—ди. Ə Бибииран, шулай ук тазара төшсə дə, елдан-ел чибəрлəнə, күркəмрəк була бара. Нəзакəтле, ефəклəрдəн генə затлы-зəвыклы итеп киенгəн, бармаклары тулы кыйммəтле ташлы йөзек-балдаклар... Аны, хөрмəтлəп, Хатыча-сан диеп йөртəлəр. Ул зыялылык, асыл сөяклелек, дисеңме, иң югары даирəлəр арасында да үз-үзен тотышы, дисеңме! Шунда аның бар булган артистлык таланты ачыла да инде.

Бибииранның чибəрлеге-сылулыгы гүя аның визит корточкасына

әверелә, аның алдында теләсә кайсы бай йортларның һәм чит ил миссияләренең ишекләре ачыла.

Бик тиз аралашып китүчән, кирәксә, һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер торган бу пар һәркайда җәмгатьчелекнең җаны булып таныла. Аларның йортындагы җомга чәй мәҗлесләренә (мөселманнар бит!) дистәләгән кунаклар җыела. Алар турында ник бер шик-шөбһә, ник бер начар сүз булсын!

Менә шулай унөч ел яшәгәннән соң, алар Япониядән төки ачылмыйча китеп бара.

Японнар өчен хакыйкать бары тик кырык (!) елдан соң гына—инде яшерүнең кирәге калмагач кына ачыла. Бер абруйлы япон газеты болай яза (озынрак булса да, бу өзек бик тә кызыклы): «Ирле-хатынлы Әнвәр белән Хатыча-сан Садыйклар «салкын сугыш» елларында Японияда ун елдан артык уңышлы эшләп килә. Ул елларда КГБ үзенең Япониядәге разведка челтәрен яңадан торгызу чараларын күрә. Көнбатыш Кытайдагы Уйгур автономияле районының Урумче шәһәренә тәпләнгән КГБ офицеры чыгышы белән Төрекмәнстаннан булган Бибииран Алимовага аның Уйгур районыннан уйгур кызы икәнлеген раслаучы тиешле документларны юнәтеп бирә. Үзләрен азык-төлек белән сәүдә итүчеләр сыйфатында таныткан бу пар Көнбатыш Японияның Кобэ шәһәренә 1954 елның көзендә Гонконгтан килеп урнаша.

Япониядә КГБның бу агентлары Әнвәр һәм Хатыча Садыйк исемнәре ала, Токиода үзләренең сәүдә компаниясен ачып җибәрә. Япониядә унөч ел яшәү дәверендә Садыйклар гаиләсе илнең, 1954 елда үзебезнең яклау көчләре оештырылганнан соң, ничек итеп яңадан кораллануын һәм Кушма Штатлар белән ике яклы элемтәләрнең үсешен җентекләп күзәтеп тора. Төрки телләрне камил белгәннәре хәлендә, алар төрек җәмгатьчелеге арасында кайнаша, төрекләрнең Токиодагы илчелегенә иркен кереп-чыгып йөри.

Шпион Садыйкларның уңышлы эшчәнлекләренең берсе АКШ хәрби базаларын, үзебезнең яклау көчләре базаларын һәм Японияның хәрби аэродромнарын һавадан алдырган фоторәсемнәрне кулларына төшерү була. Бу мәгълүматларны алар бары тик чыгышлары белән төрек булган американы солдатлардан гына ала алган.

Алар шулай ук Мәскәүгә иң башлангыч чорында ук Японияның үз көчләре белән су асты көймәсе ясарга тырышуын да хәбәр итеп өлгерә. 1950-1953 еллардагы Корея сугышы тәмамланганнан соң, үзара тыныч яшәү килешүенә кул куелгач, БМО гаскәрләренә килеп кушылган төрек офицерларының ял вакытларында ирле-хатынлы Садыйклар сәүдә компаниясен үзләренең икенче туган йортлары итеп санаулары да мәгълүм.

Шулай итеп, бернәрсә дә сизенмәгән кунаклар белән эш алып бара-бара, Садыйклар гаиләсе АКШның Көньяк Кореядә урнашкан гаскәрләре эшчәнлеге турында да кыйммәтле мәгълүматлар җыя ала. Файдалы бәйләнешләр булдыру максатыннан, Алимова шулай ук күп кенә дипломатларның һәм офицерларның хатыннары йөри торган иҗтимагый клубтан да файдалана».

## Пычак йөзендә йөрү

КЕМДЕР ӘЙТЕРГӘ мөмкин: «Йә, нәрсәсе бар инде? Бер-берсен яратышып яшәгән яр-пар, дус-имин гаилә бездән ерак экзотик Японияда тук тормышта яшәп ята. Ә без монда...»

Әмма Рихард Зоргеның фаҗигале язмышын онытмыйк. Ул, япон казаматларында күпме гомер җәфа чиккәннән соң, җәзалаулы сораулардан соң гына ачыла һәм... үлем җәзасына хөкем ителә...

Ә бит Шамил Хәмзин белән аның хатыны Бибииран Алимованы да, тотылсалар (!) шул ук язмыш көткән. Андый очрак була калса,—тьфү-тьфү!—Үзәк, ягъни Мәскәү: «Без андый уйгурларны белмибез»,—дигән

җавабын да өзерләп куйган булгандыр, бәлки. Хәзер дә бездә «иң югарыда» шундый ук сәясәт хөкем итә түгелме соң?..

Ярар, гади тормыш-яшәешкә кайтыйк. Хәтта өйдә, кунакларны озатып бетергәч тә, икәү бер түшәктә... кочаклашып ятканда да, алар бары тик уйгур телендә генә иркәләшәләр-назлашалар... Әгәр инде ниндидер ашыгыч мөһим сүз була-нитә калса, ым-хәрәкәт белән, язу белән генә аралашалар. Бу саклану чаралары һич тә «кирәкмәс, артык эш» булмый.

Бервакыт, үзләренең «сәүдә эшләре» белән Япония буйлап йөргәндә, алар, арып-талып, беренче очраган кунакханәгә туктала. Ике кешелек буш бүлмәгә урнаша.

Югыйсә, бу Ходай каргаган җәһәннәм тишегендә, Токиодан әллә кайларда әлеге ирле-хатынлы уйгур сәүдәгәрләре кемгә кирәк тә, нәрсәгә кирәк? Әмма...

Юл йөреп арып-талган Бибииранның иркенләп, рәхәтләнеп бер үз туган телендә—татар телендә!—сөйләшәсе килгәнен тоеп, Шамил тиз генә телефон аппаратын мендәр белән каплый. Ун-унбиш минут та үтми, ишек шакыйлар. Яшь кенә бер егет, янәсе, телефон станциясе кешесе буларак, гафу үтенә-үтенә, телефонны «тикшереп» чыгып китә. Күрәсез, бер генә адым да уйланмыйча ясалмаска тиеш. Һәм унөч ел буе шулай! Күпме түземлек, ихтыяр көче һәм нервлар кирәк булды икән аларга?!

Ә бит разведчик та (теләсәгез, «шпион» дип әйтик) шул ук, безнең шикелле, аяклы-куллы, җанлы кеше. Ул да үлеп-җирсеп туган илен сагына, якыннарын, туган-тумачаларын, әгәр дә исән булсалар, әти-әниләрен өзелеп күрәсе килә, үз туган телендә бер рәхәтләнеп сөйләшеп, үз халкының җырларын ишетергә тели ул...

КГБ архивында Бибиран ханымның әнисенә, Ашхабадка язган хаты саклана. Ул болай дип яза: «Кадерле әнекәем, озак яза алмаганга гафу итегез мине, шулай килеп чыкты инде. Сезне бик-бик сагынам, бик күреп сөйләшәсем килә, энемне сагынам... Нишлим соң, эшем шундый—тиз генә сезнең янга әйләнеп кайта алмам әле. Соңгы хатыгызда сез үзегез турында да, энем турында да бик аз язгансыз.

Мин кайвакытларда озын кичләрен күңелемнән сезнең белән сөйләшәм һәм миңа сез мине ишетәсездер шикелле тоела. Минем хакта кайгырмагыз-борчылмагыз, һәммәсе дә әйбәт. Әле ял көннәрен комлыкта булдык—кызындык, коендык, җиләк-җимешләр ашадык. Тыныч кына имин тормыш алып барам. Сезне яратып кочаклыйм. Исән-сау, шат күңелле, тормыш сөючән булыгыз. Сезне яратучы—И».

Үз кызының нинди «тыныч кына имин тормыш алып баруы» турында әнисе сизендеме икән? Бәлки, сизенгәндер дә... Чөнки яраткан кызыннан хатлар елга ике-өч кенә килә, аларын да почта аша түгел, ниндидер бик әдәпле егет китереп китә бит. Егет, Бибииранның әнисе хатны укып бетергәнче, бер читтә тыйнак кына басып тора. Аннары хатны алып, кире куен кесәсенә сала, ничек җавап язарга, күршеләргә ни-нәрсә дип әйтергә кирәклеген «өйрәтеп» тә китә...

Һәм унөч ел буе шулай!

## Япониядән китү

ҮЗӘКТӘН—Мәскәүдән Токиодан китү турында күрсәтмә-фәрман килгәч,—күрәсең, Садыйклар урынына инде башка разведчиклар әзерләнгән булгандыр!—Әнвәр белән Хатыча-сан Садыйк дусларына, таныш-белешләренә Көнбатыш Европага сәүдә эшләре белән барырга җыенулары турында хәбәр итә. Йорт-җирләрен, сәүдә компанияләрен, япон банкларындагы хәтсез байлыкларын калдырып, бер-ике чемодан белән генә китеп бара алар.

Соңыннан дуслары Шамил Хәмзиннән: «Япониядән баеп кайттыңмы соң?»—дип сораганда, ул шаяру катыш җавап бирә: «Әйе,—ди,—йөрәгемә

ике инфаркт алдым да, бер мең доллар акча туплаган идем. Каһәре, анысының да өчтән берен чик аша чыкканда таможняда басып алып калдылар, калганы «Москвич» автомобиленә дә җитмәде»,—ди.

Шулай итеп, ирле-хатынлы «сәүдәгәрләр» 1967 елда Мәскәүгә кайтып төшә. Үзәк аларны «кочагын җәеп» каршы ала: халык телендә «хрущевка» дип йөртелә торган йорттан башкала читендә ике бүлмәле фатир бирәләр. Токиодагы аскы катында кибете булган ике катлы таш йорттан соң, кухнясы биш кв. метрлы бу фатир «искитмәле» була инде! Кая, ди, монда кунаклар җыеп, мәҗлесләр оештырып йөрү!

Шулай да Шамил Хәмзин «Москвич» автомобиле сатып ала. Туган ил һавасын сулап туя алмыйча, Мәскәү тирәләрендәге урман-кырларда йөри алар. Беренче араларда, туган як каеннарын, тал-тирәкләрне күреп, күзләренә яшьләр килә...

Әмма тиешле ялын бетерергә дә өлгерми, Шамил Хәмзинны янә КГБга чакыртып алалар һәм яңа бурыч йөклиләр.

—Сез баш тарта аласыз,—диләр.—Аңлыйбыз: унөч ел яшертен эш алып бару—уен-муен түгел. Ләкин... бу очракта да сездән башка кеше җибәреп булмый.

Ә эш болай тора. Японияда Әнвәр Садыйк бер халыкара сәнәгать корпорациясенең җитәкчеләреннән берсе белән танышкан була. Ул кешенең исемен әле хәзер дә әйтергә ярамый. Шуңа күрә без аны шартлы рәвештә Рәшит әфәнде дип кенә атыйк. Әнвәр Садыйк, боларның көндәлек сәнәгать әйберләреннән тыш, бик яшертен хәрби заказлар да үтәгәннәрен белеп ала. Әмма бу бәһаләп бетермәслек мәгълүмат чыганагына кай яклап якын килергә соң?

Рәшит әфәндене ныклап өйрәнгән-күзәткәннән соң, Әнвәр Садыйк аңлый: бу кеше бик акыллы, үткен, яхшы һөнәрмән, белемле. Әмма бик кысмыр, комсызрак, акчага хирыс. Әһә! Менә шушы сыйфатларына «кармак салырга» кирәк тә...

Бер җай табып, Әнвәр Садыйк Рәшит әфәндене үз кибетенә чакыра: «Бик шәп мал кайтты, кереп кара әле»,—ди. Рәшит әфәнде килә һәм... бик затлы-кыйммәтле тунга күзе төшә: кара әле, бу аның сөяркәсенә менә дигән бүләк бит! Бүләгән бүләк, әмма Рәшит әфәнденең янында тунны алырлык акчасы юк икән шул.

—Хафаланма!—ди Әнвәр.—Эшләрем гөрләп бара, ал, әйдә, тунны. Җае чыккач, түләрсең әле.

Рәшит әфәнде тунны фәлән сумлык әҗәткә алуы турында бурыч кәгазе язып калдыра. Шуннан соң ул Әнвәр Садыйкның кибетенә ияләшеп китә бит, еш кына килгәләп, шундый бурыч кәгазьләре хисабына йә бик матур туфли, йә сөйгәненә затлы кичкә күлмәк, йә бизәнү әйберләре алып китә тора. Бурыч кәгазьләре бер дистә ярымлап җыелгач, Әнвәр Садыйк моны бераз «кыса»:

—Минем эшләр начараеп китте бит әле... Зур акча кирәк... Син бурычларыңны кайтара алмассыңмы?—ди.

Рәшит әфәнденең, әлбәттә, акчасы бар, ул сәүдәгәр Әнвәр Садыйктан күпкә артык «төшерә» акчаны. Әмма... бирәсе килми генә бит үз кесәсеннән чыгарып!

Шунда Әнвәр Садыйк әйтә:

—Бер чит ил корпорациясе сезнең хәрби заказларыгыз белән кызыксына,—ди.—Тиешле мәгълүмат бирсәгез, әйбәт түләрләр—бурычларыңны капларга да җитәр, артып та калыр әле.

Рәшит әфәнде акыллы кеше—Әнвәрнең тел төбен шунда ук аңлап ала, аның кемгә эшләгәнен туп-туры сорый. Әнвәр, тәвәккәлләп, әйтергә була. Мондый кешеләр белән башкача эшләргә мөмкин түгел.

Бу кичтә алар шактый озак сөйләшеп утыра. Әнвәр Садыйк «салкын сугыш» шартларында дөньяда тынычлыкны бары тик хәрби тәңгәллек-тигезлек белән генә саклап калып булуы турында сөйли. Ашкынып кораллану Рәшит әфәнделәр корпорациясенә гаять зур табышлар китерсә дә, чынлап торып атом сугышы башланса, җир йөзендә бернинди

тереклек тә калмаячак бит... Кыскасы, затлы туннар-фәләннәр өстенә менә шундый иделогик «ямаулык»та салырга туры килә.

Рәшит әфәнде шуннан соң бик кирәкле мәгълүматларны биреп кенә тора. Әмма, ни кызганыч, бер ел чамасы эшләгәннән соң, ул Япониядән китеп бара. Ә, бәлки, «җибәргәннәрдер»—кем белә?

Һәм менә, күп еллар үткәч, Рәшит әфәнденең Якын Көнчыгыштагы илләрнең берсендә төпләнеп калуын, төрле кораллар җитештерә торган эре бер корпорациянең бердәнбер хуҗасы булуын КГБ белеп ала. Нинди кораллар җитештерәләр анда? Кайсы илләрнең заказларын үтиләр? Менә шуларны Шамил Хәмзин ачыкларга тиеш була да инде.

## Таш яуса да—чигенмәскә!

БИК ӘЙЛӘНГЕЧ юллар белән, Көнбатыш Европа һәм Якын Көнчыгыш илләре аша, ниһаять, Шамил Хәмзин тиешле урынына барып җитә. Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк, бу илдә Советлар Союзының ни илчелеге, ни сәүдә вәкиллеге булмый, гомумән, бер генә совет кешесе дә юк ил икән бу.

Шамил Хәмзин бик зур кыенлыклар белән Рәшит әфәнденең үзен кабул итүенә ирешә. Әмма... Рәшит әфәнде сәүдәгәр Әнвәр Садыйкны танымамышка салына һәм аның белән сөйләшеп торырга да теләми. Күрәсең, үзен хәзер бик бай, беркем белән дә исәпләшеп тормаслык мөстәкыйль-бәйсез кеше итеп исәпли һәм үткәндә булганнарны «оныткандыр»...

Шамил Хәмзин Үзәккә үзенең уңышсызлыкка очравы турында хәбәр итә. Аңа максатыннан һич кире чигенмәскә, яңа юллар эзләргә боералар. Шамил Хәмзин башыннан үткәннәрен барлый да, «ни Алласы, ни мулласы» юк илдә Рәшит әфәнденең тулы хокуклы хуҗа булуын аңлый. Әгәр дә бу хуҗа бармагын селкетсә дә, Шамил Хәмзинның көле дә калмаячак бит... Нишләргә соң? Димәк, Рәшит әфәнденең чит илләргә чыгуын көтәргә кала...

Ниһаять, шундый көн килеп җитә. Рәшит әфәнде үз эшләре белән Лондонга юл тота. Аның артыннан ук Шамил Хәмзин дә шунда юнәлә.

Лондонда исә, Рәшит әфәнденең кайсы кунакханәгә тукталуын һәм телефонын белеп алгач, Шамил Хәмзин аңа, баш тартмаслык шартлар куеп, очрашу билгели.

Очрашу Ш. Хәмзин вакытлыча алып торган автомобиль эчендә була. Шамил, тегенең кайтарасы бурычлары-фәләннәре, үткәннәре турында сөйләнеп, Рәшит әфәндене куркытып маташмый, чөнки бу—файдасыз. Ул аңа бары тик халыкара сәясәт турында сөйли. Кайбер илләрнең, барлык халыкара килешүләрне бозып, атом-төш кораллары эшләүләрен искәртә. Бу исә дөньяда әлегә кадәр сакланып килгән паритетны бозарга һәм бу якты дөньяның асты-өскә килүенә китерергә мөмкинлеген әйтә.

Ул Рәшит әфәнденең «үз кармагында» булып, КГБга хезмәт иткәнен «тишсә», тегенең, бөлгенлеккә төшеп, «дөрләп яначагы» турында искәртеп тормый. Анысы болай да аңлашыла... Рәшит әфәнде акыллы кеше бит.

Рәшит әфәнде нишләсен? Риза булмый хәле юк. Ул Израиль белән Көньяк Африка Республикасының атом-төш кораллары булдыру турындагы планнары хакында бик яшерен мәгълүматлар бирә. Ул мәгълүматлар киң дөньяга әле хәзер генә билгеле булды. Ә безнең разведка аларны утыз елдан да ары элек белә иде инде.

## Тагын яңа бурыч

ШАМИЛ ХӘМЗИННЫҢ өстенлеге шунда була: аңа һәр атлаган саен яңа әкият сөйләп яки яңа документлар юнәтеп торасы юк. Ул капиталистик сәүдә дөньясында һаман да күренекле япон сәүдәгәре уйгур Әнвәр Садыйк булып кала бирә. Рәсми документлары да—чын, бер ялгансыз. Аны Япониядә булсын, Гонконгта булсын—дистәләрчә-йөзләрчә кеше белә, таный.

Бер генә хилаф эш эшләгәне дә юк... Гадел, намуслы сәүдәгәр.

Япониядән киткәннән соң, ул, имеш, Европаның кайсыдыр бер иленә барып төпләнгән. Бөтен җир шарын гизеп чыккан, беркем дә аның сәүдәдәме-башкадамы «гөнаһ» эшләрен сизмәгән.

Тик менә Бибииран белән генә вакытлыча аерым яшәргә туры килә. Ни әйтсәң дә, хатын-кыз бит: аның нервлары нык какшаган икән. Мәскәүдә, пенсиягә чыгып, шактый гына табибларга йөри Бибииран ханым. Табиблар беравыздан: «Сез—хатын-кыз, җитмәсә, артист кеше (ул, әлбәттә, разведчик та икәнен әйтеп тормый)—сез хис кешесе, хиссиятегез бик көчле, шуңа күрә, йөрәгегез дә тизрәк туза»,—дигәнрәк сүзләрне әйтә.

Ә Шамил Хәмзинга тапшырылган яңа бурыч шуннан гыйбарәт була: Америка Кушма Штатларының көнбатышындагы Юта штаты ракеталар төзелеше үзәге икән. Мәскәүгә шунысы да мәгълүм: НАТОның СССРга иң якын урнашкан илләрендәге хәрби базаларга корал һәм башка хәрби кирәк-яраклар шуннан җибәрелә. Ачыкларга кирәк: алар нинди базалар? Кайсы илләрдә? Саны ничә? Коралланулары ничегрәк? Безнең илгә беренче һөҗүм итү мөмкинлеге бармы? Менә шундый бик «гади» табышмаклар...

Үзәкнең бер «кармагы» да салынган икән. Европадан киткән бер белгеч,—Мишель дип әйтик,—америкалыларның ракета төзелеше үзәкләренең берсендә эшли. Ул безгә кирәкле мәгълүматларны белә, шуның өстәвенә, «салкын сугыш» сәясәтен дә өнәми, АКШның бар дөньяда өстенлек итәргә тырышуын да якламый, көч белән кара-каршы торуны көчәйтергә түгел, ә киресенчә, киметергә кирәк дип саный икән.

Шамил Хәмзинга менә шул Мишель белән якыннан танышып-дуслашып, тиешле мәгълүматларны алырга кирәк... Янә дә «кирәк... кирәк... кирәк...»

## Теннис уйный белү дә ярый

ШАМИЛ ХӘМЗИН (әлбәттә инде, сәүдәгәр Әнвәр Садыйк) Юта штатының үзәге булган Солт-Лейк-Сити шәһәренә үзенең «сәүдә эшләре» белән килеп төшә. Мишель яшәгән кунакханәгә урнаша. Бер атна чамасы вакыты Мишель турында мәгълүматлар җыюга китә аның. Баксаң—Мишель теннис уйнарга бик ярата икән, көн саен берничә сәгатен теннис мәйданчыгында үткәрә. Шамил шуннан файдаланырга була...

Теннис мәйданчыгы тирәсендә һәрвакыт карап торучы «ачык авызлар» күп була, алар кычкыра, сызгыра, кул чаба—шул рәвешле уйнаучыларны дәртләндереп тора. Менә шул «ачык авызларның» берсе Шамил Хәмзин була. Мишельнең уены иң кызган чагында, ул: «Җиңүчегә—миннән йөз доллар!»—дип игълан итә. Калганнар аны хуплап гүләп ала, уен тагын да кыза. Ниһаять, тирләп-пешеп чыккан Мишель җиңә бит әй! Үзенең отышыннан бик тә канәгать җиңүче үзенә телəктәш һәркемне якындагы барга кереп, «күктән төшкән йөз долларны юарга» тәкъдим итә.

Шау-гөр килеп сыйланалар. Озакламый башкалар таралып бетә. Ә Шамил белән Мишель әле бик озак гәп корып утыра. Шамил үзенең эре эшмәкәр, абруй-дәрәҗәле бер фирма вәкиле икәнлеген әйтә, акчасын хәрби сәнәгать өлкәсенә салмакчы була икән дә, тик шикләнә, Мишельдән киңәш сорый. Моның өчен төрле мәгълүматлар кирәк бит, имеш, нишләргә икән? Булышсаң, фирма хезмәтең өчен мул итеп түләр иде... Мишель дә бик үк ашыкмый, «уйларга кирәк» дигәнрәк вәгъдә бирә.

Икенче очрашуларында Мишель Шамилгә кайбер кирәкле «киңәшләрен» бирә, Шамил аңа зур гына сумма акча тоттыра һәм: «Бу акча фирманың ябык бүлегеннән бирелә, бер кайда да теркәлми, салым түләү декларациясенә дә кертү мәҗбүри түгел»,—ди.

Бу бик четерекле-тәвәккәл адым була. Көнбатышта, шул исәптән, Америкада да салым түләүдән качып котылырга тырышу авыр җинаять санала, сине озак елларга төрмәгә ябып куюлары да ихтимал. Мишель

Шамилнең бу «җимен» бик тиз генә «кабып йота», аны-моны уйлап тормый.

Шуннан эшләр майлагандай җайланып китә. Мишель кирәкле мәгълүматларны бирә тора, Шамил аңа тиешлесен түли бара һәм барысын да Үзәккә хәбәр итә тора.

Бу үзара «хезмәттәшлек» Мишель үз вакытын тутырып, туган иленә кайтып киткәч тә өзелми. Шамил үз «фирмасы» эшләре белән бу илгә килеп чыккалый, Мишель белән очрашып тора. Ә бервакыт, җае килеп, Урта диңгез буенда «безнең фирма хисабына» бергәләп ял итик әле, дигән тәкъдим ясый Шамил. Мишель рәхәтләнеп риза була.

Нәкъ менә шунда, җылы диңгезнең җәннәттәй кочагында ял иткәндә, Мишель үзенең дустына СССРның көньяк чикләрендәге бер дәүләттә бик көчле хәрби авиа-ракета базасы төзелеп ятканын тәфсилләп сөйләп бирә. Әлбәттә, шул ук төндә шифрланган яшерен хәбәр Мәскәүгә барып ирешә. Анда исә бу хәбәрнең дөреслеген тикшереп карагач кына ышаналар...

## Җиләнсез дә, хәнҗәрсез дә батыр

СОҢЫННАН, Мәскәүгә кайтып, пенсиягә чыккач, Шамил Габдуллаҗан улы үзенең «сәүдәгәрлек» эшчәнлеге турында сөйләгәндә, кырык ел буе яшерен оешмада, шуның егерме елын чит илләрдә эшләп тә, бер мәртәбә дә корал кулланмаганын, кемне дә булса үтерергә туры килмәгәнен әйтә. Ә бу сыйфат инде иң камил, иң маһир разведчикларга гына хас сыйфат! Ул, тыны-көне бетеп, үзен эзәрлекләгән дошманнан да качып йөрмәгән, түбәләрдән дә сикермәгән, үзе белгән-өйрәнгән шәрекъ көрәше ысулларын да бер дә кулланмаган... Чөнки аларның хаҗәте чыкмаган, хаҗәте чыкса—кем белә? Ул «шпионнар турындагы» кино-телефильмнарны караганда көлемсерәп кенә утыра торган була.

Разведчик, полковник Шамил Габдуллаҗан улы Хәмзинның бар «эшчәнлеге» калын-калын егерме папкага сыеп беткән, аларда «Халеф» дигән имза белән җиде меңнән артык (!) хәбәр-мәгълүмат теркәлгән. Ни-нәрсәләр икәнен тәгаенләп тормыйбыз, кайберләрен өстәрәк әйтеп уздык, ә кайберләренә әле «чират җитмәгән»...



*Ш. Хәмзин Мәскәү квартирында туганнарының балалары арасында*

Шамил Хәмзинның күп кенә фоторәсемнәрен карап утырам. Бер үк кеше, ә нинди төрле-төрле кыяфәтләрдә ул! Менә мәҗлесләр, шау-шу, кәеф-сафа корырга яратучы «сәүдәгәр»... Менә һәркемгә ярдәм итәргә әзер торучы гади бер кеше. Юк, берсендә генә дә «шпион» кыяфәте юк икән бит. Үзебезнең татарыбыз яки «уйгурыбыз» гына икән.

Тагын бер фоторәсем: үткен акыллы, сине үтәли күрә белүчән, бик сак-сабыр карашлы, һәммәсен дә алдан чамалаучан ир-ат заты... Менә монысы инде кырык ел разведчик булып та бер генә хата да ясамаган Шамил Хәмзин!

Аның зыялылыгы, белеме-эрудициясе исләрең китәрлек! Юк, төрле телләр белүе генә түгел, ничәмә-ничә төрле халыкларның гореф-гадәтләрен, мәдәниятын-әдәбиятын белүендә дә... Уйгур белән ул уйгур, хәтта уйлары-төшләре дә уйгурча. Төрекләр белән—төрек, европалылар белән дә нәкъ аларча: кирәк икән—немецча, инглизчә һ. б. телләрдә иркен аңлаша-сөйләшә ала.

Кемдер хәзер әйтергә дә мөмкин: «Ярар, шулай да булсын, ди. Әмма бит Шамил Хәмзин коммунистик режимга хезмәт иткән...» Гадәттә, мондый сүзләрне элек үзләре дә коммунист булып, хәзер «демократ»ка әйләнгән кешеләр әйтүчән.

Әйе, әтисе мулла булган гаиләдән чыккан Шамил Хәмзин колхозлашу чорындагы «бөгелеш-тайпылышларны» да, Сталинның нахакка миллионлаган кешеләрне җәберләвен дә, тоталитар режимның башка «матур» якларын да белеп-күреп яшәгән. Әмма шул ук вакытта ул коммунизм идеалларына инанган, якты киләчәккә өметләнгән һәм шуны якынайту өчен тырышкан. Ул туган иленә, халкына хезмәт иткән. Җирдә атом-төш сугышы башланмасын өчен көрәшкән, шул максаттан чыгып, чит илләрдә дә уртак тел таба алган, фикердәшләр булдырган.

Шамил Хәмзин, үз татар халкыннан озак еллар аерылып яшәсә дә, татарлыгын онытмаган. Аның архивында татар китаплары да байтак. Мәсәлән, анда Г. Тукайның әле революциягә кадәр үк чыккан шигырьләр китабы бар, мөгаен, әтисе мирасыдыр. Әбрар Кәримуллинның татар халкының килеп чыгышы турындагы кульъязмасы бар. Ә. Ерикәй, С. Хәким, Г. Зәйнашева һ. б. җырлары бар. Ул Һади Такташның улы Рафаэль белән дә дус булган, Рафаэль аңа, җылы сүзләр язып, әтисенең китабын бүләк иткән.

## Аны казанлылар да хәтерли

ЯШЬЛЕК ДУСТЫ Наил ага Гайнетдинов Шамилнең нык-таза булуы турында сөйли. Алар бергәләп Идел комлыкларында кызына, су коена, балык тота. Шамил волейбол, футбол уйнарга да бик яраткан, уеннан соң тирләп пешкән тәнен сафландыру өчен Югары Ослан тирәләрендә Иделне аркылы йөзеп чыга торган булган. «Көзгә,—дип сөйли Наил ага,—Шамил кояшта янып, күнитек шикелле кап-кара булыр, аның таза-тыгыз тәнен күргән кызлар биһуш китәр иде, валлаһи!»

Танылган җырчы Мөнирә Булатова да Шамил Хәмзинны яхшы хәтерли икән. Алар әле утызынчы еллар башында ук пионерлар клубында танышканнар. Барабаннар кагып, быргылар уйнатып, Ленин-Сталин эшенә һәм коммунистлар партиясенә турылыклы булырга антлар биреп йөргән алар. Шамилнең тотылмас разведчик булганлыгын Мөнирә Булатова бары тик соңгы елларда гына белә...

## Разведчик—сирәк һөнәр

МӘСКӘҮГӘ кайткач, гади генә ике бүлмәле «хрущевка»да яшәгән, иске «Москвич»та йөргән Шамил Хәмзинның пенсиясе дә әллә ни зурдан булмаган. Пенсиягә чыкканда ул полковник, ә Бибииран ханым

майор дәрәҗәсендә булган, орден-медальләре дә күп түгел—һәр кайсының ике-өч булыр...

Хикмәт, әлбәттә, байлык, дәрәҗәләрдә түгел. Хикмәт—аларның батырлыгын тануда. Ә бу җәһәттән, илебез, Мәскәү шактый сынаткан.

Шамил Хәмзин белән Бибииран ханым 1995 елда (бу Шамилнең соңгы җәе була) Төрекмәнстанга сәяхәт кыла. Аларны анда тантана көтә. Самолеттагы пассажирларга чыкмый торырга кушып, Шамил белән Бибииран ханымны оркестр белән, чәчәкләр белән каршы алалар. Мондый хөрмәткә күнекмәгән карт белән карчык, кино-видеокамераларның үзләрен төшерүләренә уңайсызланып, каушап кына самолет басмасыннан атлый... Аларны журналистлар, халык төркеме чолгап ала... Аннары дәрәҗәле кунаклар гына утырып йөри торган кара төстәге, өсте ачык «Чайка» автомобилендә, бөтен шәһәрне күрсәтеп, хөкүмәт йортына алып киләләр. Иң югары дәрәҗәдә кабул итү, газет-телевидениедә репортажлар, кайчандыр Бибииран Алимова эшләгән «Төрекмәнфильм» студиясендә очрашу, университет студентлары алдында чыгыш ясау, атаклы «Умбар» фильмын кабатлап күрсәтү, Бибииранның туган-тумачалары, таныш-белешләре белән рәхәтләнеп сөйләшүләре, кунактан-кунакка йөрү...—берсе дә калмый. Күңелләре тулган картлар әледән-әле күз яшьләрен сөртә...

Карт-карчык алдагы җәйдә Казанга кайту турында хыяллана. Әмма сиксән яшьлек Шамил Хәмзинның йөрәге түзми, ул 1995 елда бу дөньядан кичә... Урыны җәннәттә булсын күренекле милләттәшебезнең!

Бер елдан соң Бибииран (Ирина Кәримовна) Алимова Казанга ялгызы гына килә, сөекле иренең архивларын төяп алып килә ул. Аның килеп китүе һич тә Төрекмәнстандагыча булмый. Каршы алучылар да юк... Җәмәгатьчелек тә матбугатта Әлфия Минһаҗеваның берденбер кыска гына хәбәрен укыса укыгандыр... Моны безнең мокытлыгыбыз, дими, ни дисең?

Ә шул ук вакытта үзәк матбугатта—Мәскәүдә, дигәнем,—«татар Зоргесы» турында саллы-саллы гына берничә мәкалә басылып чыга. Бу җәһәттән, журналист Виталий Головачевның «Труд» газетында чыккан тулы бер серия очеркларын искә алып үтү кирәктер (1995). Аннары, 1998 елда «Правда» газетында (бар әле ул газет, бар!) Марина Эратованың Бибииран ханым (Ирина Кәримовна) Алимова белән әңгәмәсе басылды. Тагын да кайбер басылып чыккан әйберләр булгалады.

Әмма... татар телендә разведчик, полковник Шамил Хәмзин белән аның хатыны, разведчик, майор Бибииран Алимова турында беренче зур мәкалә-очерк шушы булыр. Аларның яшерен эшләрен хәзер яшермиләр инде. Хәзер тыюлар юк. Татар халкы үзенең каһарманнарын белергә тиеш. Алар турында фильмнар төшерелер,—әйтеп узыйк, Ш. Хәмзин исән чагында ук бер документаль фильм эшләнгән булган, әмма ул ни өчендер Татарстанга «кайтып җитмәгән»,—китаплар язылыр, спектакльләр куелыр дип ышанабыз. Андый каһарманнар күп булмый.

Разведчик—сирәк һөнәр ул.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

## ИР-АТ ТУРЫНДА

*—... Моннан миллион еллар элек ат булып яшәдем кебек тоела миңа...*

Р. Сибатның «Ялгызак» романыннан Заһидулла сүзләре.

Әйе, әдәбиятыбызның проза тармагы терелә, җанлана башлады шикелле. Ә бит берничә ел элек кенә бу өлкәдә эшләр бер дә мактанырлык түгел иде. Хәтта «Казан утлары»нда бастыру өчен әйбәт сыйфатлы әсәр сайлап алуы да шактый ук кыен бер мәсьәләгә әверелеп бара иде.

Аллага шөкер диик, хәзер инде бу чор узды кебек. Әмма әлеге өзеклекнең сәбәпләре нәрсәдә булды соң? Ул яңадан да кабатланмасмы икән? Башта кыскача гына шуңа тукталып узыйк.

Соңгы еллар прозасының шактый ук сүлпәнәюенә китергән иң зур сәбәп турында—тәҗрибәле өлкән әдипләрнең безнең арадан китеп барулары хакында—алдагырак язмаларда телгә алган идек инде. Чыннан да, Татарстан язучыларының XIII корылтаеннан соңгы бер ел эчендә генә дә безнең арадан әнә нинди корифейлар китте бит! Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Гариф Ахунов... Әдәби иҗаттан тукталып калган бүтән аксакалларыбыз булуы да гаҗәп түгел.

Прозабызның вакытлыча йомшавына китергән икенче сәбәп: туксанынчы еллар тирәсендә илдә сәяси хәлләрнең нык кына куеруы һәм шуңа бәйле рәвештә безнең татар матбугатында, әдәбиятында да публицистик юнәлешнең үтә активлашуы, күп кенә иҗади көчләрнең шуңа тартылуы, проза әсәрләренең азрак язылуы иде.

Әле генә әйтелгәннән килеп чыгучы өченче сәбәп: илдәге сәяси үзгәрешләргә һәм алар тудыра торган сәяси тотрыксызлыкка бәйле рәвештә килеп туа торган эчке, рухи тотрыксызлык. Юк, мин биредә кайсыбер иҗат кешеләрендә күзәтелгән иман алыштыру күренеше турында әйтергә теләмим. Бусы инде аның, гомумән, тәнкыйтьтән түбән нәрсә. Мин биредә иҗат кешесе өчен һәрдаим кирәкле эчке тотрыклылык—дөньядагы хәлләрне, күренешләрне, процессларны аңлап һәм төшенеп житү, аларны аның һәм йөрәгең белән үзләштерү хакында әйтмәкче булам. Әнә шундый аңлау һәм үзләштерүдән соң бит инде иҗатчы күңелендә «әдәби әсәр» дип аталган яңа төрле яшәү, яңа тормыш тудыруга, иҗат итүгә теләк, дәрт барлыкка килә.

Прозабызның тиешенчә үсә алмавы турында сүз барганда искә алмый узып китү мөмкин булмаган тагын бер фактор—матди стимулның, этәргечнең юкка чыгуы... Билгеле, соңгы араларда язучыларга түләнә торган каләм хакы бераз гына күзгә күренердәй була башлады.

Чыннан да, совет чорында без бер дә юкка гына «рухи тәрбия», «әхлакый тәрбия» дип сөйләшми идек бит. Тормышның бер дә искерми торган үтә мөһим мәсьәләсе ич ул! Әле бер көнне, «Америка тавышы» дигән радиостанцияне тыңлап яттым: Кушма Штатларның бер шәһәрендә халык фикерен тикшерү уздырганнар—«сез нинди коллективта эшләргә теләр идегез?» дип. Җавап бирүчеләрнең иң зур күпчелеге фикере мондый булган—«гадел әхлак кануннары өстенлек иткән коллективта эшләр идем!» Шулай шул: кеше һәр жирдә дә, һәр вакытта да кеше булып калырга тырыша инде ул!

Бик тә кызганыч: шәһәр тормышы, урам төркемнәре һәм сугышырга, кеше үтерергә өйрәтүче Рәсәй телевидениесе тәрбияләп үстергән бандитлар хәзер безнең арада болай да күпләп арта бара. Кемне гаепләргә дә белмәссең?! Гел сугышу һәм яңа җирләр басып алу сәясәте үткәргән Рәсәй житәкчеләренме? Үзебезнең Татарстанда әхлакый тәрбия буенча зур һәм киң колачлы эш оештыра алмаган түрәләребезнеме? Бүген матур һәм рәхәт яшәүгә омтылып, иман һәм киләчәк турында, яшь буын хакында бөтенләй истән дә чыгаручы шәхсән үзебезнеме?

Шулай—гаеп атта да, тәртәдә дә бардыр. Ләкин менә бу арада әдәбиятыбызның һәм аерым алганда аның проза жанрының күтәрелә башлавын, барыбер, әйбәткә юрыйсы килә. Һәм ул күтәрелеш-үсеш озын гомерле булыр дип тә ышанасы килә! Безнең әдипләребез соңгы елларда үз күңелләреннән бик күп гыйбрәтле хәлләр кичерделәр, бик күп нәрсәне аңладылар, үзләштерделәр һәм хәзер ныклап торып Олы Иҗатка тотындылар дип уйлыйсы килә.

Чыннан да, узып киткән 1999 елны гына алсак та, «Казан утлары» белән «Идел» битләрендә генә дә нинди матур проза әсәрләре басылган бит!

Бүгенге көннең иң оста прозаикларыннан берсе булган Фоат Садри «Идел» дә «Өченче кеше» дигән менә дигән повесть бастырды. Соңгы елларда бик тә нәтиҗәле эшләүче Нәбирә Гыйматдинова исә шул ук журналда үз укучыларын «Таң ата да кич була» дигән күләмле әсәре белән сөендерде.

Үзебезнең «Казан утлары» да үткән елда әдәбият сөючеләрне сан саен яңа һәм кызыклы әсәрләр белән таныштырды. Камил Кәримов белән Радик Фәизовның уңышлары бигрәк тә күзгә күренерлек иде. Беренчесенең «Ком сәгате» исемле романы әдәби җәмәгатьчелек тарафыннан берсүзсез зур уңыш диеп бәяләнде, укучылар да аны яратып кабул итте. Радик Фәизовның «Тәнре хөкеме» дигән хыялый повестенең хикмәте исә тирәндәрәк ята. Чөнки автор безне бүгенге кыргый, киләчәктә үз-үзебезне үтерәчәк яшәеш рәвешебезне ташлап, матур һәм гармоник яшәү юлына басарга өнди. Чынлыкта моның бик үк барып чыкмаслыгын аңлаган тәкъдирдә дә бу әсәр, барыбер, әдәбият күренеше, кешенең рухи, аң дөньясы җимеше буларак бик яратып кабул ителә. Әдип әйтергә теләгән мәгънә безнең йөрәк тибеше белән бик тә аваздаш ишетелә.

Ә инде Айдар Хәлимнең шулай ук былтыр дөнья күргән «Татар вакыты» турында әйтеп тә торасы юк! Ул әсәр авторның үзенең дә, тулаем прозабызның да уңышы иде. Әле бит былтыр шулар өстәвенә Ә. Моталлаповның «Нигез»е дә, Ә. Галиевнең «Чигенгәндә»се дә һ. б. лар да булды.

Менә шушылардан соң ничек инде прозабыз күтәрелә башлады диеп сөенмисең ди?!

Әмма соңгы елларда иҗади активлык байрагын үз кулында ныклап тотучы әдип, ул—Рафаэль Сибат. Бу автор байтак кына каләмдәшләре турында саллы-салы иҗат портретлары һәм эсселар язды, әдәби тәнкыйть мәкаләләре белән кыю-кыю чыгышлар ясады. Аның шулай ук «Исабәт» һәм «Атлар рәнҗеше» исемле романнары дөнья күрде. Ниһаять, журналыбызның быелгы апрель-май саннарында Рафаэль Сибат «Ялгызак» дигән моңсу романын бастырды.

Иң башта ук шуны әйтеп китик: бу роман «Казан утлары»нда чыга башлау белән укыган кешеләрдә зур кызыксыну уятты. Минем үземә очраган һәр язучы диярлек шушы әсәр турында сүз кузгатмыйча калмый иде. Һәм аларның роман хакындагы беренче тәэсирләре бик тә әйбәт иде. Шунысы кызык—әсәрне ошату белән бергә алар күңелендә бер үк вакытта төрле характердагы сораулар, автор белән килешеп җитмәгән фикерләр дә байтак булды. Хәтта мина кайбер язучылар белән әдәбият һәм иҗади дөнья күренешләре хакындагы кызыклы гына бәхәс-дискуссияләргә дә кереп киткәләргә туры килде... Менә болар барысы да, һичшиксез, роман файдасына сөйләүче фактлар...

Ә хәзер, әйдәгез, романның үзенә күчик. Ул кайсы ягы белән кызыксыну уята соң? Бүгенге укучыга нинди мәгънәләр, нинди эчтәлек алып килә?

Әйе, бу моңсу романга «Ялгызак» дигән бик тә кызыклы һәм укучыны ымсындыргыч исем куелган. Ләкин, минем уемча, бу исем бик отышлы булса да һәм үзенә тартып торса да, ул үзенең мәгънәсе белән бары тик әсәрдәге вакыйгаларның бер өлешенә генә туры килә, шуларны гына гомумиләштерә. Ягъни, икенче төрле итеп әйткәндә, ул романга өлешчә генә туры килә.

Ә вакыйгаларга килгәндә «Ялгызак»та безнең өчен кызыклы нинди хәл-әхвәлләр тасвирлана соң?

Утызынчы еллар. Күмәк хуҗалыкка керергә теләмәгән Заһидулла Нократ елгасының теге ягына чыгып үзенә йорт тергезергә уйлый.

Дөресен әйтим: романның беренче битендә үк күрсәтелгән бу фикер, бу мәгънә укучы өчен бераз сәеррәк тоела. Чөнки авылда аның әле генә һәм бик яратып өйләнгән яшь хатыны Заһидә бар бит. Яшь парның әле сөеп-сөешеп яши башлаган чагы гына бит... Автор безгә Заһидулланың яшь хатыннан туюы кебек нәрсәнең тамчысын да күрсәтмәде, сиздермәде бит әле... Аннан соң, икенче яктан: күмәк хуҗалыкка кермим дисең икән—моның өчен авылдан читкә китү мәҗбүри түгел иде ич. Әнә, безнең авылда бер гаилә гомер буена аерым хуҗалык булып яшәде, авыл уртасында йорты һәм каралтысы булган килеш...

Шуңа күрә Заһидулланың Нократ аръягында йорт тергезергә уйлавы утызынчы еллардагы күмәк хуҗалыкка каршы торудан бигрәк үз холкының сәерлеге, ачыграк итеп әйтсәк: аның табигый яшәешкә, табигать кочагында яшәүгә ныграк тартылуы буларак аңлашыла. Хәер, без әйткән менә бу фикер дә үзенең төбендә, үстерелешендә күмәк хуҗалыкка каршы тору белән килеп ялгана инде ахыр чиктә. Кешенең чын яшәүгә, үз хезмәте белән үзе көн күреп яшәүгә омтылуы буларак кабул ителә ул. Бердәнбер дөрес яшәү үрнәге буларак...

Ярый, безнең Заһидулла Нократнең теге ягындагы урманда үзенә өй салыр өчен әйбәтрәк урын сайлап йөри... Менә шул чагында инде ул урман аланлыгында чеган баронының кызы Тамараны очрата. Искерәк киемнәр кигән Тамара баштарак егеткә ямьсез тоелса да, сөйләшеп китеп танышканнан соң елмаеп та җибәргәч Тамара бөтенләй үзгәрә... Аның ерак та түгел куышы бар икән. Алар учак тергезәләр, Тамара Заһидулланы пешкән балык белән сыйлый. Учак янында юка гына киемнән йөргән Тамарага Заһидулла тәмам гашыйк була. Якындагы куыш алар өчен Мәхәббәт Чатырына әверелә.

Гомер уза, Заһидулла үзе теләгән йортын тергезә. Ул арада авылда калган яшь хатын Заһидә малай таба. Бу шатлыклы хәбәрне ишеткән Заһидулла сөенеченә чыдый алмыйча Нократны йөзеп чыга! Ә коймәле Әхмәдулла аны арттан озата бара. Ярга чыгып җиткәчтен дә ул эчке ыштанын гына эләктерә дә, өенә авыл артлап кына чаба. Заһидулланың өйгә килеп керүе дә кызык—ул: «Ник елатасыз баланы?!»—диеп кайтып керә Заһидәсе янына!

Авылда күмәк хуҗалык оештырып йөрүчеләр исә Заһидуллага тынгылык бирми, аны гел-гел чакырып сүгә. Әнә шундый сүгүләрнең берсеннән соң Заһидулла ишекне каты итеп япкач, дивардагы Сталин портреты идәнгә төшеп ватыла. Икенче көнне Заһидулланы килеп кулга алалар. Төрмәдә ул Малмыж мулласы, бик тә ипле-акыллы карт белән таныша. Алар анда үзләрен кыерсытырга теләгән өч урысны кыйныйлар. Ә инде акланып төрмәдән чыккач Заһидулла читкә чыгып китә, бөтен ил буенча йөри. Әмма бер генә җирдә дә озакка төпләнә алмый... Иң ахырда, ул инде нык картайгач, вакыйга безнең көннәргә үк килеп җиткәч, Заһидулла Парижлан хат ала—Тамара исән икән, ул әтисенең алтыннары белән чит илгә киткән булган, кияүгә чыккан, ләкин аның малае Заһидулладан икән... Димәк, Парижда да Заһидулланың улы яши...

Роман «Ялгызак» дигән исемле булса да анә шундый оптимистик рухта тәмамлана.

Әлбәттә, әле генә әйтеп кителгән вакыйгалар—болар романның төп канвасы гына, скелеты гына. Ә тулаем алганда роман уй-фикерләр һәм хис-кичерешләргә бик тә бай. Бу яклап караганда ул хәтта Нократ кебек кенә дә түгел, олы Иделебез хәтле бар. Тагын шунысы бик тә истә кала: автор үзе дә, аның каһарманнары да чын табигать баласы булып, яшәеш гүзәллеген бик тә нечкә, бик тә тирәннән тоеп баралар. Алай гына да түгел, иң заманча, иң актуаль фикерләргә дә бай бу роман. Һәм шуның белән бергә әсәргә мул булып публицистик агым да бәреп керә, анда бик иркенләп яши. Мондый агым һәр чагында да акланып ук бетмәсә дә, аннан романга тулаем алганда зур зыян да килми кебек. Ни өчен дисәң, әсәрнең бөтен барлыгы, бөтен тукымасы шундый. Ярый, ә инде бу романның төп мәгънәсе нәрсәдән гыйбарәт соң?

Әлбәттә, әдәбият-сәнгать әсәренә салынган мәгънәләр бик тә күп була. Чөнки бу дөнья, әдәбият-сәнгать дөньясы ул «образлылык» дигән хикмәти халәткә нигезләнгән. Әнә шул образлы яшәешнең эченәрәк кергән саен яңа һәм кызыклы мәгънәләр ачыла бара. Синең кеше һәм яшәеш турындагы фикерләрең байый, тирәнәя бара. Юк, әсәр эченә керә барган саен сиңа очраган яңа фикерләр, яңа мәгънәләр алар үз элгәрләрен дә кире какмыйлар, аларны юкка чыгармыйлар. Алар, яңа мәгънәләр, элеккеләрен тагын да тулыландыралар гына. Әсәрнең образлы яшәеш мохитен тагын да тирәнәйтәләр генә

алар. «Ялгызак»та да әнә шундый янадан-яна мәгънә катламнары бик күп. Мисал өчен менә кайберләре генә: кешенең, шәхеснең үзе теләгәнчә, үзе дөрес диеп санаганча яши алырга тиешлеге, шуңа хакы барлыгы; бүгенге урбанизация бик көчәйткән көтү, төркем, күч психологиясе һәм кешенең табигый рәвештә үзе генә калырга омтылуы, ялгызлыкта калырга теләве—чөнки бу аның исән калуы, сәламәтлеге, алда яши алуы дигән сүз; гаилә һәм шәхес иреге; татар милләтенең үтә нык чәчелгән булуы һәм туган җир проблемасы; төрле милләтләрнең үзләренчә, үзгә холык-фигыльгә ия булуы һәм аларның үзара тату яши алу мәсьәләсе һ. б.

Әмма романның иң үзәгендә өскә калкып, менә бу югарыда әйтелгән мәгънәләрнең «башларына басып», аларның иңнәренә таянып татар ир-аты Заһидулланың монументаль образы тора. Ул чын мәгънәсендә Ир-Ат.

Житмешенче еллар ахырында Г. Камал исемендәге театр Т. Миңнуллинның «Ир-егетләр» дип аталган әсәрен куйгач, шушы әйбәт спектакльнең исеменә мин бик тә гаҗәпләнгән идем. Чөнки бу бер дә ишеткән сүзем түгел иде. Безнең якта егет дигән сүз бар, ир дигәне бар, ир-ат бар—ә менә мондый «ир-егет» дигән юк иде. Шуңа күрә мин аны драматург уйлап тапкан ясалма сүз кебегрәк кабул иттем. Тора бара дус-ишләрдән кайсы бер якта шулай әйткәннәрен ишеткәч тә, бу хакта белгечтән дә, баштагы әлеге шигем, ул сүзне кабул итә алмавым кимемәде.

Ә инде менә Ир-Ат сүзе бөтенләй башкача. Чын, саллы, төпле сүз ул! Чын ир-атның үзе кебек ул!

Әйе, бу романның үзәгендә дә татар ир-аты Заһидулла тора. Аның язмышы һәм аның холык-фигыле, табигате тора. Алдарак без бу каһарманның башыннан кичкән хәлләрне бераз күреп үттек, хәзер инде Заһидулланың холкын аңларга тырышып карыйк.

Ул үз көченә, үзенең хәләл хезмәтенә ышанып яши торган тырыш, эшчән кеше. Нократ аръягында да ул бер үзе өйлек агачларны ега, бер үзе өй салып керә. Әлбәттә, бу урында автор өй салу мәшәкатьләренең эченә бигүк кереп тормый һәм мондый алым тулаем әсәр рухы белән аклана да кебек. Шуңа күрә бер кешенең өй сала алуына күңел кайчакларда шикләнебрәк калса да, нигездә, тулаем алганда бу эш мөмкин булгач—авторга аның өчен генә бәйләнеп торасы килми. Заһидулланың бераз үҗәтрәк, бераз башсызрак, бераз хыялыйрак һәм нык ук сәер холык-табигате әнә шуның ише факт-күренешләрдән җыела ич инде ул!

Зур физик көчкә ия, сау-сәламәт ир Заһидулла рухи яктан да таза: ул ихлас күңелле, садә җанлы, саф йөрәкле. Язучының үз героен менә шушындый итеп тасвирлавы, минемчә, бер дә юкка түгел. Бу—безнең еллар өчен үтә актуаль проблема. Чөнки шәһәрдә туып, шәһәрдә үскән адәмнәр бик еш очракларда физик яктан гына түгел, ә рухи-әхлакый яктан да шактый ук зәгыйфь булалар: үз яшәүләрен алар салкын акылга, сату-сатылуга, хәйләгә, астыртын эш йөртүләргә коралар. Әнә шундый эчке авыруларын алар күп белү, тыштан зыялы булып күренергә тырышу (киенүдә һәм сөйләшү рәвешендә әлбәттә!) белән капламакчы да булалар.

«Ялгызак» романының герое Заһидулла бүгенге шуның ише типларга юри каршы куела. Ул физик һәм рухи яктан сау-сәламәт булгач, бернидән дә һәм беркемнән дә курыкмыйча—үзе ничек теләсә шулай яши. Менә шушындый яшәү мисалында инде без Кеше буларак яшәүнең чын матурлыгын, чын кыйммәтен күреп алабыз! Ирекле яшәү матурлыгын!

Үзе пакь җанлы, чиста күңелле булгач, Заһидулланың кечкенә генә әшәкелеккә дә нык ачуы чыга, ул ярсып кабына, еш кына кызып та киткәли. Ләкин шулай ук тиз суына да, үз эзенә кайтып та төшә.

Әмма Заһидулла үзе кешеләргә бер начарлык эшләмәсә дә, кешеләр аңа әшәкелекне байтак кына эшлиләр. Хәләл көче белән салган өен ут төртеп яндыралар, сөекле хатыны Заһидәне үтереп китәләр, үзен төрмәгә дә ябалар... Боларның барысының да сәбәбе, мотивы ачык—Заһидулланың үзенчә, баш бирмичә яшәргә теләве күпләрнең ачуын китерә. Әсәрне укыган чагында боларны без дә яхшы аңлап барабыз.

Ләкин менә хатын-кызлар белән мөнәсәбәттә әле безгә Заһидулла табигатен аңлап, төшенеп бетәргә кирәк. Бу яклап караганда әсәрдән нинди яңа мәгънәләр килеп чыга икән соң?

Үз хатыны Заһидәгә ул яратып өйләнә. Һәм Заһидәнең соңгы минутларына кадәр шулай ярата да аны Заһидулла. Ләкин ул чагында Тамара белән булган хәлләрне ничек аңларга микән соң?

Әйе, без моңа кадәр, бигрәк тә совет чорында, үрнәк, әйбәт гаиләне ир белән хатынның кайнар мәхәббәте һәм балалар тәрбияләп үстерүе диеп аңладык. Бу нигездә дөрес тә. Чөнки ике арада мәхәббәт тә кирәк, матур гаилә булмаса әйбәт балалар да үсә алмый. Ләкин бүген реаль чынбарлыкка игътибарлы булсак, без бу эшнең, бу проблеманың катлаулырак икәнлеген аңларбыз. Инде турысын әйтеп, ачыктан ачык сөйләшә башласак: элек электән үк ни өчен күпхатынлылык булган? Хәзер, менә соңгы елларда, бу мәсьәлә нилектән янадан көн тәртибенә куела башлады?

Җавап шул булыр: бу—реаль чынбарлык, тормыш таләбе! Хатын-кыз һәм ир-ат табигатенең төрлечә булуыннан килеп туа торган күренеш. Табигатьнең үзе тарафыннан, Ходай тарафыннан яратылган мондый үзенчәлек белән санлашу—әлбәттә, һич кенә дә гөнаһ була алмый. Әлбәттә, билгеле бер чик-чама сакланган тәкъдирдә.

Хәзер инде күз алдына китереп карыйк: әгәр дә Нократның теге ягында өй салырга урын эзләп йөрегән чагында Тамара очрагач Заһидулла ана карата битараф калса—бу дөрес булыр идеме, бу эш табигый булыр идеме? Шундук һәм кистереп әйтеп була: юк!

Әнә шуңа күрә, чын ир-ат холкына ия булганга күрә, Заһидулланы ярата да инде Тамара. Һәм сөешүләренең беренче мизгелләрендә үк ул Заһидулла гомере буена оныта алмастай хикмәтле сүзләр әйтә ул:

—... мой татарский конь!

Беренче карашка тән ләззәтенә генә бәйле булып күренсә дә, тора-бара бу сүзләрнең очраклы гына әйтелмәве дә ачыклана башлый. Заһидә белән бер сөйләшеп утырганда да Заһидулла: «... моннан миллион еллар элек ат булып яшәдем кебек тоела миңа» дигән иде бит... Аның әнә шул сүзләреннән соң бөтен Ауразия киңлекләрен бер итеп атта чабып узган борынгы төрки бабайлар да күз алдына килә... Әнә шул күренешләр арасында шифалы яңгыр сыман булып, яңадан да күңелдән «ир-ат» сүзе үтеп китә... Аннары тагын Заһидулла искә төшә—аның ерак Тын океан буендагы Татар бугазыннан алып Балтикага хәтле сәфәр кылулары... Байтак калаларда сөйгән ярлар табуы—йөрәген яндырып алуы... Шушы урында Бакый ага Урманчедан ишетелгән борынгы җырыбыз да хәтергә килеп ала: «Шәһәрләр саен сөйгән ярым бар ие...»

Менә болар барысы да элеккеге татар дөньясының зурлыгын, киңлеген күрсәтеп тора. Шул зурлыкны раслый, безнең күңелләрдә яшәтә.

Ләкин әсәрне укымаган кешедә Заһидулла турында ялгыш фикер кала күрмәсен—мәхәббәт диеп бөтен дөньясын оныта торган зат түгел ул. Әнә бит, дусты Мәкчимнең хатыны Анна үзе аның янына килгәч, Заһидулла аны кискен рәвештә кире бора! Хәтта өйдән үк чыгып китә! Һәм бусы да бик ышандыра, табигый. Чөнки Заһидулла саф күңелле, керсез җанлы кеше!

Кайсыдыр бөек бер философның: «Хатын-кызга һәм табигатьтәге җан ияләренә булган мөнәсәбәтеннән чыгып кешенең нинди икәнлеген әйтергә мөмкин»,—дигән бик акыллы сүзләре бар. Бу фикер «Ялгызак» романының төп каһарманы Заһидуллага бигрәк тә туры килә. Чыннан да, аны хатын-кызлар ярата. Ә бу инде, гомумиләштереп әйткәндә, тулаем тормышның, тулаем табигатьнең аны яратуы, аны үз күрүе дигән сүз. Димәк, Заһидулла—табигатьнең, яшәешнең үз кешесе дигән сүз. Заһидулла—тормыш һәм табигать кушканча баручы, яшәүче дигән сүз. Төп юлдан, олы юлдан баручы дигән сүз.

Әсәрдә бик кызыклы һәм истә кала торган башка образлар да бар. Тамара белән Заһидәдән соң иң хәтердә кала торганы—керәшен Мәкчим бугай. Аның сүз саен диярлек «чәпчим» диеп сөйләшүе генә түгел, ә бөтен килеш-кыяфәте, холкы-табигате үзенчә сөйкемле һәм яраттыра торган. Тик менә аның Заһидулла төзегән өйне яндыруы гына ул үзе әйткәнчә: «Тегеләр сине шул утка салып яндырмасыннар дидем» гә түгел, ә бүтәнрәк сәбәптән булып аңлашыла. Хатыны Анна Заһидуллага кызыга башлагач, шуның ачуын Заһидулла өеннән алу дип аңлашыла бу эш роман барышыннан чыгып карасак. Ләкин автор үзе бу турыда анык кына бер сүз дә әйтми—ул күрсәтеп кенә бирә. Бирелә безнең үзебезгә уйларга һәм логик фикер йөртергә кала. Әдәби әсәр әнә шундый урыннары белән көчле дә бит инде ул!

Заһидуллага төрмәдә очраган Малмыж мулласы да бик колоритлы фигура булып чыккан. Ул тирән акылы, сабырлыгы, төпле холкы белән истә кала һәм, гомумиләштереп әйткәндә—бер Заһидулла өчен генә түгел, ә безнең күпләгән милли көрәшчеләребез өчен дә үрнәк булып тора. Ул безгә «милли көрәшнең үзәгенә сабырлык һәм акылны салыгыз, егетләр!» дип яши сыман.

Романда төрле милләт вәкилләре шактый күп күрсәтелгән. Урыслар да, яһүдләр

дә, Балтыйк буе халыклары да һәм Урта Азиядә яшәүчеләр дә үзләренә хас холыкфигыльгә ия итеп, кызыклы күренешләр аша бирелә. Икенче төрле итеп әйткәндә, татар милләтеннән булган Заһидулла әнә шулар белән янәшә куела, чагыштырыла кебек. Әнә шул янәшәлектә татарның эш сөюе, ихлас ярдәмчеллеге, оптимизмы, сабырлыгы күзгә ташланып ук тора. Билгеле, бүген кайсыбер яшьләр татарның хезмәт сөючәнлегеннән көләргә дә тырыша. Бер каләм әһеле «Идел»дә хәтта бу хакта язып та чыкты. Ләкин егетләр шуны онытмыйк: бу безнең милләтебезне гасырлар аша саклап килгән сыйфат! Татарның рухи пакьлеген, чисталыгын һәм хезмәт сөючәнлеген башка милләт вәкилләре дә билгеләп үтте, язып чыкты. Ул әйбәт бәһаләр безгә бер дә зыянга булмады. Хәвефле елларда тулаем халкыбызны өр-яңа һәм зур фаҗигалардан да саклап калды! Әлбәттә, әлеге тырыш хезмәтнең җимешләре дөрес бүленмәү—анысы бар һәм ул хакта әйтергә, ул проблеманы дөрес, гадел хәл итәргә кирәк. Ул яктан гаделлек булырга тиеш. Бусы турында ике төрле сүз дә булырга мөмкин түгел! Ләкин, моңа карап кына, без татарның хезмәт сөюеннән көләргә тиеш димәгән. Мисал өчен, хәзер Татарстан дигән үз йортыбызда, башка милләтләр бигүк эшләргә яратмый сылтавы белән татар үзе эшләмәсә—безнең Татарстан дигән бу илебез, бу йортыбыз ни хәлгә калачак соң?! Көлкегә калачакбыз бит дөнья күләмендә!

Кайсыбер яшь әтәчләргә бу яклап та акыл бирә Рафаэль Сибат. Аның үзәк герое Заһидулла бер генә эштән дә чирканмый, курыкмый. Чын ир-ат булып кала!

Әнә шуңа күрә дә Тамара һаман аны сагынып Париждан хат яза. Көнбатышның алдынгы бер иле Франция башкаласыннан килгән бу хат символик мәгънәгә дә ия кебек. Мәгъриб иленең дөрес яшәү юлын, иманлы һәм табигый яшәү юлын сагынуы, юксынуы кебек тә кабул ителә. Ә инде Заһидулла малаеның анда үсеп белүебез, шулай ук соңгы елларда газеталар хәбәр иткән факт—Ауропада Ислам тәгълиматы тарафдарлары көчәя бару—болар һәммәсе безнең укучыда киләчәккә булган оптимизм хисләрен тагын да көчәйтә.

Әйе, «Ялгызак» романы безнең Егерменче гасыр тормышын бик тә киң колачлый. Әсәрнең төп герое Заһидулланың гасыр башында ук тууы (автор моны төгәл әйтмәсә дә, күмәкләшү елларында төп геройга 29 яшь булгач—без уйлаганча чыга ич инде!) һәм бу көннәргә хәтле яшәве дә аның турында «гасыр кешесе» дигән фикер тудыра. Моңа хәтле дә татарның типик бер вәкиле, гомумиләштерелгән үзәк фигурасы дигән тәэсир уяткан Заһидулланың инде вакыт ягыннан да шушындый дәвамлылык алуы укучы күңелендәге масштаблылыкны, монументальлекне тагын да көчәйтә. Безнең көннәрдә яшәүче Заһидулланың күңел көрлеге һәм аның малайлары-оныклары алдында ачыла башлаган зур перспектива—шулай ук укучыга бик тә матур, рухландыргыч тәэсир ясый. Күңелдә яңадан Тукайлар, Әмирханнар, Исхакыйлар чорындагы Яңарыш дулкыннары уйный башлый. Бу гасыр башы да шундый матур башлансын иде, диеп тели йөрәкләр.

Романны укыган чагында тешкә тия торган урыннар да байтак кына очрый. Менә әсәрнең башланып китүен алыйк. Беренче биттә үк Заһидулланың күмәк хуҗалык төзүгә кискен каршы чыгуы күрсәтелә. Бәлки ул реаль чынлыкта шулай буладыр, булгандыр да. Ләкин безнең көннәр укучысы өчен мондый башлам инде артык сәяси булып кабул ителә. Моны бирү бик кирәк булган очракта да нык психологик мотивлаштыру, нечкәләп үрү сорала иде. Ә турыга ярып, примитив сөйләшү рәвешендә түгел! Яңа төсмерләр салып, кызыклырак итеп кирәк иде. Бүгенге көн бәхәсләренә дә саллы дәлил булырдай сүзләр белән. Роман хәтле романның башлануы бигрәк тә шундый эчтәлек сорый ич.

Аннары тагын бер гомумирәк пландагы фикер, теләк туа. Автор биредә утызынчы еллардагы күмәкләшүне берсүзсез гаепләп чыга, вакыйга-күренешләргә шулайрак бәя бирә. Ләкин объектив дөреслеккә якынрак булсак, барыбер, «монда тормышның үз таләбе дә көчле булды ич» диярргә туры килә. Күмәкләшү үзе түгел, ә ул эшне көчләп оештыру ялгыш булды бит! Авыл кешеләре әле хәзер дә күмәкләшмичә эшли һәм яши алмыйлар. Чит илләр чынлыгы да шуны күрсәтә: анда да иң зур продукцияне зур хуҗалыклар бирә, ә вак фермерлар түгел.

Романның беренче битләрендә үк сизелгән һәм ышандырып бетермәгән менә шушындый сәяси мотивлар, билгеле, әсәрнең обьектив агышына ышануны киметә төшә. Күңел әсәр авторын шактый ук субъективлыкта гаепли. Һәрхәлдә, әдәби әсәр тукымасында сәяси карашлар белдерелгән очракта да, алар инде бөтен катлаулылыгында чагылырга тиеш иде.

«Ялгызак»ның соңгы өлешендә вакыйгалар җирлеге бик нык киңәя. Шуңа бәйле

рәвештә катнашучылар саны да шактый ук арта, аларның байтагы истә дә калмый. «Алар кирәк идеме икән соң?» дигән сорау да туа. Билгеле, монда да кызыклы күренешләр бар, «читтә яшәүче татарлар эреп, юкка чыгып бетеп баралар» дигән мәгънәле фикер бар—ләкин романның бу өлеше урыслар әйткәндәй «галопом по Европе» дигәндәйрәк тәэсир тудыра.

Ә моннан котылып була идеме соң? Бәлки Заһидулла йөргән урыннарны болай ук күп күрсәтмәскә кирәк булгандыр? Ерак Көнчыгышны һәм тагын берәр урыннан гына биреп тә шундый ук тәэсир калдырып булмас идеме икән? Кешеләр саны да кимер, нәтиҗәдә алар истә кала торганрак, тулы канлырак образларга әверелер иде. Мәгънәви тирәнлек арта төшәр иде. Бәлки күләм ягы да байтак кына кимер иде...

Романдагы образлар нигездә тулы канлы кеше булып яшиләр. Ләкин минә кайберсенең сөйләшүләрен индивидуаль үзенчәлекле итәм диеп Рафаэль Сибат артыграк тырышып җибәргән сыман. Заһидулланың хатыны Заһидәнең (исемнәре дә ничек туры килеп тора—кара әле син аны!) сөйләгәндә сүз саен диярлек «аh, аh!» диеп әйтүе дә бер дә табигый кебек кабул ителми, моңа ышануы да кыен. Аннары ни өчендер бу «аh»лар әсәрнең беренче өлешендә бөтенләй юк, ә инде икенче өлештә җөмлә саен диярлек! Туйдыра башлый, билләһи!

Мәкчимнең сөйләмендәге «чәпчим» сүзе дә аның хәтле үк кирәк булды микәнни соң?! Бирелә дә чама хисе югалган дигән тәэсир кала.

Аннары минә мондый экзотик сүзләр шушы ике герой телендә бар, ә бүтәннәрнекендә бик үк колакка чалынмый, күзгә ташланмый. Бу хәлне ничек аңларга? Алайга китсә, һәркемнең сөйләме үзенчә кызыклы, кабатланмас сөйләм була бит әле ул... Димәк, бу яктан да авторның эшләп бетерәсе урыннары калган.

Ләкин ничек кенә булмасын: безнең алда бик кызыклы роман, әйбәт әдәби әсәр! Аны тулаем укып чыккач минем хәтергә житмешенче еллар башында безнең прозабыз да күзәтелгән бер күренеш искә килеп төште. Үтә талантлы һәм бик үзенчәлекле әдип Мөхәммәт Мәһдиевнең әле яңа гына проза яза башлаган еллары иде бу. Әнә шул чагында редакцияләрдәге һәм нәшрияттагы кайсыбер әфәнделәр «мондый проза булмый» дигән тавыш чыгарды. Ягъни аларга яңа авторның яңача язуы ошамый иде! Күнегелгән, ияләшелгән кануннарның санга сугылмавы ошамый иде! Мөхәммәт Мәһдиевта лирик башлангыч та бик көчле, субъективлык та алагаем ага, җиренә килеп житмәгән урыннар да байтак кына күзгә ташлана... Ләкин, ничек кенә булмасын, анда—ирек рухы, иркенлек көчле, тормыш сулышы көчле иде! Теп-тере кешеләр, характерлар яши иде анда! Шуңа күрә ул бик тиз арада укучылар, халык мәхәббәтен казанды да!

Соңгы елларда Рафаэль Сибатның прозага килүе дә әнә шул чактагы хәлләрне искә төшерә. Чыннан да, аның әсәрләрендәге зур шәхесләр, киң масштаблылык, күп чагында күзгә үк бәрелә торган монументальлек, вакыйгаларның киң агымы һәм тирәнлеге кайсыбер стиляга-стилистларга ошап та житмәскә мөмкин. Бары тик матур җөмлә төзү уе белән генә яшәүче, стиль турында гына уйлаучы яшь прозаикларны күздә тотам мин әнә шулай дигәндә!

Әмма сез Лев Толстойлар һәм Гаяз Исхакыйлар, Чехов белән Бунинар һәм безнең Еникилар иҗатын алып карагыз—аларның һәммәсендә иң башта, иң элек тормыш, яшәеш көче тантана итә! Яшәеш фәлсәфәсе, трагедиясе һәм матурлыгы ургылып ага аларда! Шуңа күрә без, проза әсәрләренә бәя биргән чагында, көзге каршында сәгатьләр буена бизәнгән хатын-кыз кебек «чибәр» әдәби әсәрләр белән Олы Тормыштан килүче әдәби әсәрләрне бергә бутамасак иде... Әйе, бәлки әдәби әсәрләрнең һәр ике төре дә кирәктер. Хатын-кызның сәгатьләр буена көзге каршында бизәнүен дә начар диеп булмый... Ләкин... Ләкин—барыбер: әсәрдәге зурлык, чынлык, тирәнлек әллә каян сизелә, күренә һәм ул безнең күңелләрне үзенә ныграк тарта!

«Ялгызак» романы белән беренче танышу күңелдә әлегә әнә шундый тәэсирләр уята.

**Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ**



*Коръән татар телендә*

## 3–ГЫЙМРАН (МӘРЬЯМНЕҢ АТАСЫ) СҮРӘСЕ

***(Гыймран сүрәсе 200 аятьтән тора. Мәдинә-и Мөнәүвәрә шәһәрендә иңгән. Бу сүрәдә Мәрьямнең атасы Гыймран турында сөйләнә. Исеме шуннан килә.)***

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

**1**. Әлиф, Ләм, Мим. ***(Мин, Аллаһ, яхшы белүче.)***

**2**. Аллаһ—бер генә! Аллаһның Үзеннән башка ***(һичберкем, һичбер нәрсә)*** илаһ була алмый. Ул—мәңге тере. Ул—каййумдыр.

***(«Хайи вә каййум» гыйбарәсен болай аңлаталар. Хайи—тере, үлемсез, мәңге дәвамлы, дигән сүз. Каййум—бөтен Галәмнең, барча җанлы-җансызларның тәрбиячесе, барысын да күзәтеп-белеп, хисапка тотучы кодрәт вә камиллек иясе.)***

**3.** ***(Ий, Мөхәммәд)*** Ул сиңа китапны ***(Коръәнне)*** әүвәл иңдерелгән китапларны ***(дөресләп)*** раслау өчен, өлешләп-өлешләп иңдерде. Моннан алда да Тәүрат белән Инҗилне иңдергән иде. ***(Ул китаплар)*** инсаннар өчен тугры юл күрсәтүче иде.

**4**. Хак белән ялганны ***(яхшыны яманнан)*** аера белер өчен ***(хөкемнәр)*** Фуркан иңдерде. Аллаһның аятьләренә көфер иткәннәр юкмы? ***(Бар, әлбәттә.)*** Андыйлар өчен бик читен газаплар әзерләнгән. Аллаһ—кодрәт иясе һәм җәза бирүчедер.

**5**. Шөбһә юк ки, Җирдә дә, Күктә дә Аллаһтан яшерен нәрсә юктыр. **(6)** Аналарыгыз карынында ук, Үзе ничек теләсә, сезгә шундый рәвеш бирүче дә Улдыр. Аллаһтан башка һичбер тәңре юк. Аллаһ мотлак ***(абсолют)*** җиңүче. Аллаһ бердәнбер хөкем чыгаручы вә хикмәт иясе.

**7.** (***Ий, Мөхәммәд)*** сиңа Китапны Ул иңдерде. Анда мәгънәсе ачык аятьләр байтак—алары Китапның нигезен тәшкил итә. Башка бер бәгъзеләре мөтәшабиһләрдер ***(ягъни мәгънәсе ачык түгел һәм хәзергә аңлатуы да мөмкин булмаган, кыска аятьләр)***. Күңеле бозык булганнар, мөтәшабиһ аятьләрне фетнә чыгарырдай итеп, үзләренчә аңлатырга маташалар, шуларга ябышып яталар. Гәрчә, аларның мәгънәсен Аллаһтан башка беркем белмәс. Гыйлем ияләре исә:

—Без аңа ***(Коръәнгә)*** ышандык. Барысы да Раббыбыздан килгән,—диләр. Аларны ***(мөтәшабиһ аятьләрне)*** сәламәт акыллылардан башкалар яхшы аңламас!

*«**Мөтәшабиһ аятьләрне** аңлатуга ике караш яшәп килә. **Сәләф**—борынгылар мәсләге. **Халәф**—варислар мәсләге. Сәләфчеләр фикеренчә, бу аятьләрне аңлатудан качарга кирәк. Аңлатмыйча гына, Аллаһ сүзенә ышанырга кирәк».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

*Соңгылары, халәфчеләр аңлату ягында тора. Кайберәүләр «уәр-рәсихунә» сүзенең башындагы «уау» хәрефен теркәгеч итеп укыйлар. Алай укыганда аңлашыладыр ки: хәлбуки, аның мәгънәсен бары тик бер Аллаһ вә гыйлемдә югары дәрәҗәләргә ирешкән галимнәр генә беләчәк. Моны хакыйкать итеп алсак, мөтәшабиһ аятьләр фән-гыйлем камиллеккә ирешкәч кенә, киләчәктә генә аңлатылачак икән».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.

---

Журнал өчен Рабит Батулла әзерләде.

**8.** Йа, Раббыбыз, тугры юлга бастырганнан соң, безне адаштырма. Безгә Үз Җанәбеңнән рәхмәт бир. Шик юк ки, Син иң юмарт ярлыкаучы. **(9)** Йа, Раббыбыз, хактыр ки, Син, һичшиксез, көннәрдән бер көнне кешеләрне бер урынга туплаячаксын. Һичшиксез, Аллаһ Үз сүзендә торачак!

**10.** Алла хозурына килгәч, кяферләрне маллары да, балалары да коткара алмас. Менә шулар була инде җәһәннәм кисәүләре. **(11)** *(Аларның юлы)* Фиргәвен токымының вә алардан элек яшәгәннәрнең юлы кебек. Алар аятьләребезне ялганга чыгарды, Аллаһ та аларны, гөнаһларына күрә, *(хөкемгә)* тотты. Аллаһның җәзасы бик тә каты булыр.

**12.** *(Ий, Мөхәммәд)* көфер итүчеләргә әйт син:

—Якын арада сез тар-мар ителәчәксез вә бөтенегез җәһәннәмгә сөреләчәксез,—диген.

Ул *(җәһәннәм)* котчыккыч яман урындыр.

**13.** Кара-каршы килгән ике гаскәр *(Бәдер)* сугышында сезгә гыйбрәтләр бар. Бер гаскәр Аллаһ юлында сугыша, икенчесе исә мөшрикләр иде. Болары тегеләрне *(мөселманнарны)* мангай күзләре белән ике итеп күрә башлады. Ярдәм итәсе килгән кешеләренә Аллаһ ярдәм итәр. Шик юк ки, күңел күзләре сукыр булмаганнарга монда катгый сабаклар бар.

*(Бәдер сугышында мөшрикләрнең гаскәре мең кешедән тора иде. Мөселманнар нибарысы өч йөз кеше иде. Мөшрикләр күзенә мөселманнар икеләтә артык булып күренде, кяферләрнең күңеленә курку иңде һәм алар җиңелде.)*

**14.** Нәфесе булган кешеләргә: хатыннар, угыллар, батман-батман тагылган алтын-көмеш, тамгаланган чабышкы атлар, *(мул сөт бирүче)* хайваннар, иген тарлаулары, шашып сөю галәмәтләре гүзәл итеп күрсәтелде. Ләкин боларның барысы да дөньядагы тормышның тиз узып китә торган рәхәт мизгелләре генә. Аллаһ хозурындагы *(җәннәттәге)* тормыш тагын да гүзәлрәк.

**15.** Син әйт:

—Сезгә боларыннан да яхшырак тормыш турында сөйлимме?—диген.

Тәкъва *(саф)* мөселманлыкка ирешкәннәр өчен Раббы катында, *(тау-таш)* асларыннан бәреп чыгучы чишмәләре белән җәннәтләр булыр. Алар анда мәңге яшәп калачак. Саф-пакь хатыннар *(янында)* алар Аллаһның ризалыгында яшәр. Хактыр ки, Аллаһ колларын күзәтеп тора.

**16, 17.** Сабыр-чыдам булганнар, иманнарына тугры калганнар, итагатьле булганнар, ятимнәрне асраганнар *(ягъни тәкъвалыкка ирешкәннәр)*:

—Йа Раббыбыз, без иман китердек. Инде безнең гөнаһларыбызны кичер вә безне җәһәннәм газапларыннан коткар!—дип сәхәрләрдә Аллаһтан ярлыкау сорарлар.

**18.** Аллаһ хакыйкатьне-гаделлекне өскә чыгарып, Үзеннән башка һичбер тәңре булмаганлыгын *(аятьләре, дәлилләре белән)* исбат итте. Фәрештәләр дә, гыйлем ияләре *(нәбиләр, галимнәр дә)* моны раслады:

—Аннан башка һичбер тәңре юк!—диделәр. —Ул—мотлак җиңүче, хөкемгә вә хикмәткә ия бердәнбер Аллаһтыр.

**19.** Хак дин, Аллаһ дине—Исламдыр. *(Үзләренә)* Китап иңдерелгәннән соң *(Корьән иңгәч)*, белем алгач, көнләшеп, *(артык горурланып)*, үзара талашып таралыштылар. Аятьләрне инкарь итүчеләр белсен ки, һичшиксез, Аллаһ җәзасын бик тиз бирер.

***«Дин»** кәлимәсе: итагать вә җәза, хаклык һәм шәригать мәгънәләрендә килә. Корьәндә «дин» сүзе төрле мәгънәләрдә кулланыла. Югарыдагы аять исә, бәндәләр тарафыннан кабул ителергә тиешле Илаһи канун буларак фаразлана. Ягъни, дин—ул кешеләрне дөньяда ничек итеп дөрес яшәргә өйрәтүче һәм Ахирәттә сәгадәткә ирешү юлын күрсәтүче, Аллаһ хозурыннан пәйгамбәрләр аркылы кешеләргә иңдерелгән Илаһи кагыйдәләр, кануннар. «Ислам» кәлимәсе түбәндәге мәгънәләргә ия: итагать итү, бирләшү, рухи һәм физик сәламәтлеккә ирешү, гыйбадәттә ихлас булу. Югарыдагы аятьтә исә «Ислам» сүзе бер Аллаһка иман китерү вә хәзрәти Мөхәммәд аркылы күндерелгән дин нигезләрен кабул итү, диган мәгънәдә бирелгән».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән һәм Абдурахман Каянын «Иман вә гыйбадәт» исемле китабыннан.

**20.** Әгәр *(кяферләр)* синең белән бәхәсләшә башласа, әйт:

—Вәгазьләремә ияргәннәр белән мин Аллаhка буйсындым!—диген. Үзләренә Китап иңдерелгәннәрдән вә жаһил мөшрикләрдән сора:

—Сез дә Исламны кабул итеп, *(Аллаhка)* буйсындыгызмы?—диген.

Әгәр Исламны кабул иткән булсалар, тугры юлны тапкан булырлар. Әгәр инкарь итеп, йөз чөерсәләр, сиңа бары тик аларны *(җәһәннәм газабы белән)* кисәтергә генә кала. Хактыр ки, Аллаһ бәндәләренең кылмышларын күзәтеп тора.

**21.** Аллаһның аятьләрен инкарь итүләре аркасында, кяфер булганнардан, хаксызга пәйгамбәрләрне үтерүчеләр вә гаделлеккә өндәүче инсаннарның җаннарын кыйганнарны:

—*(Сезгә)* бик тә хәтәр җәза булачак!—дип «сөендер». **(22)** Боларның дөньядагы эшләре дә, Ахирәттәгеләре дә бушка чыкты. Аларга беркем дә ярдәм итә алмас. **(23)** *(Рәсүлем)* үзләренә Китаптан бер парча бирелгән кавемне күрмәдеңмени? Алар арасында гаделлек урнаштырыр өчен, тугры юлга чакырыр өчен, аларга Аллаһның Китабы бирелде. Ләкин аларның бер өлеше *(Китапка)* арка белән борылды. **(24)** Моның сәбәбе шулдыр ки, алар янә дә әйттеләр:

—Безгә мәңгелек ут беркайчан да ирешмәячәк, мәгәр санаулы көннәрдә генә ирешәчәк, *(без җәһәннәмдә озак калмаячакбыз)*,—диделәр. Дин мәсьәләләсендә алар уйлап чыгарган бу нәрсә *(үзләрен-үзләре)* алдау гына. **(25)** Киләчәге шик уятмый торган бер Көндә аларны бер урынга җыярбыз; аларга гаделсезлек булмаячак, ләкин аларга дөньядагы кылмышларына күрә, тап-таман түләү *(җәза)* биреләчәк, менә шул вакытта аларның хәле ничегрәк булыр икән?

**26.** *(Рәсүлем)* әйт син:

—Әй, мөлкәтләрнең хуҗасы Аллаһ. Син милекне кемгә теләсәң, шуңарга бирәсең, кемнең милкен алырга теләсәң, аңардан аласың. Телләгән кешеңнең кадерен арттырасың, теләмәгәнеңне мескенлеккә төшерәсең. Игелек бары тик Синең ихтыярыңдадыр. Шик юк ки, Син барча нәрсәгә кодрәтлесең,—диген. **(27)**—Төнне көн белән, көнне төн белән аралаштырасың. Үлене терелтәсең, терене үтерәсең*(җансыздан җанлыны чыгарасың, җанлыны җансыз итәсең)*. Телләгән бәндәңә чиксез мул ризык бирәсең,—диген.

**28.** Мөэминнәр мөэминнәрне ташлап, кяферләр белән дус булмасын. Шулай эшләгән кеше Аллаһтан берни дә *(ярдәм)* күрмәс. Мәгәр ки, алар тарафыннан дәһшәт янаса гына *(дус булырга мәҗбүрсез)*. Аллаһ *(сезгә җәзасыннан)* куркырга боерды. Ниһаять, *(бу дөньядан китеп)* Аллаһ хозурына бару да Аллаһ әмерендәдер.

*(Кяферләр золымында калган мөселманнарга алар белән дус булырга рөхсәт итә, ләкин мөселман кеше күңеле белән Аллаһка табынырга тиеш, аның иманына зарар килмәскә тиеш.)*

**29.** Әйт син:

—Күңелләрегездәгене яшерсәгез дә, ачып салсагыз да Аллаһ белә. Күкләрдә, Җирдә ниләр бар—Аллаһ барысын да белеп тора,—диген. Аллаһның бөтен нәрсәгә кодрәте житә.

**30.** Аң булыгыз, ул Көнне *(Кыяматтә)* дөньяда игелек кылган булса да, яманлык кылган булса да, һәркем үз әҗерен табар; кеше кылган яманлыкларыннан ерак арада торырга теләр. Аллаһ асылда сезне *(Үзенә каршы килүдән)* куркырга боера. Аллаһ колларына чиксез шәфкатьледер.

**31.** *(Рәсүлуллаһ)* син әйт:

—Әгәр Аллаһны сөйсәгез, миңа иярегез *(Исламны кабул итегез.)*. Аллаһ та сезне сөяр вә гөнаһларыгызны ярлыкар,—диген. Аллаһ ярлыкаучы, киң күңелле, гафу итүче.

**32.** Әйт син:

—Аллаhка вә Пәйгамбәргә итагать итегез,—диген. Әгәр йөз чөерсәләр, шөбһәсез ки, Аллаһ та ул кяферләрне сөймәс.

**33-34.** Хакыйкатән, Аллаһ Адәмне, Нухны, Ибраһимны вә аларның токымнарын, Гыйммран гаиләсен—барысын да бер нәселдән буларак, халыкларга *(өстен)*мәшһүр кылды. Аллаһ чынлыкта барысын да ишетүче, мөкәммәл белеп торучыдыр.

**35.** Гыйһмранның хатыны:

—Раббым, карынымдагы яралгыны Сиңа *(дөнья мәшәкатьләреннән)* азат кол итәргә ант иттем. *(Минем антымны)* кабул ит. Шөбһә юктыр ки, Син ишетәсен дә, күреп тә торасың,—диде.

*«Хәннә белән Гыймранның балалары булмый, картаеп барганда Хәннә бер агач төбенә утырып ана кошның ничек итеп баласын ашатканын карап тора да: «Йа Раббым, миңа да бер бала бирсәң, ул баланы дин хезмәтенә тапшырыр идем»,—ди. Аллаһ аның теләген кабул кыла. Хәннә Мәрьямгә йөкле була. Ул бала Гайсә пәйгамбәрнең булачак анасы иде».*

Шәех Ногмани тәфсиреннән.

**36.** *(Мәрьямнең анасы)* кыз тапкач, әйтте, Аллаһ анын кыз табачагын белә иде:

—Раббым, мин аны кыз итеп тудырдым. Ир бала кыз бала кебек булмый инде ул *(ягъни ир кебек хезмәт итә алмас).* Мин аңа Мәрьям исеме куштым. Бу баланы һәм аннан туган балаларны куылган шайтаннан саклар өчен Сиңа тапшырдым,—диде. **(37)** Шулай итеп, Раббы аны бик теләп кабул итте. Аны бер гүзәл үсемлек кеби тәрбияләп үстерде. Зәкәрияне аңа тәрбияче итеп куйды. Бала ята торган бүлмәгә кайчан гына керсә дә, Зәкәрия анда мул ризыкка тап була иде:

—Мәрьям, бу сиңа каян килде?—дип сорады Зәкәрия. Кыз:

—Бу— Аллаһ тарафыннан. Шөбһә юктыр ки, Аллаһ кемгә теләсә, шуна чиксез ризык бирер,—диде.

*«Мәрьямнең атасы белән Зәкәрия бажалар иде. Зәкәрия Мәрьямнең тутасына өйләнгән, Мәрьямгә җизнә тиешле кеше иде».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**38.** Анда Зәкәрия Раббыга дога кылды:

—Раббым, Син миңа бер пакь бала бир. Әлбәттә, Син минем догаларымны ишетәсен. **(39)** Ул гыйбадәт бүлмәсендә дога укып утырганда фәрештәләр әйтте:

—Чынлыкта Аллаһ сине Яхъя исемле бер бала белән куандырачак, ул *(Яхъя)* нәфсенә хуҗа була белүче, Аллаһ әйткән сүзнең *(Китапның)* тугры икәнлеген исбатлаучы Пәйгамбәр булачак,—диделәр. **(40)** *(Зәкәрия)* әйтте:

—Раббым, чынлыкта инде мин картаеп барам, хатыным да кысыр булган килеш, ничек итеп минем улым булыр икән?—диде. *(Аллаһ әйтте):*

—Шулай! Аллаһ ни теләсә, шуны башкарачак,—диде. **(41)** *(Зәкәрия)* әйтте:

—Раббым, *(ул эшнең)* галәмәтен өйрәт,—диде. *(Аллаһ)* әйтте:

—Синең галәмәтең шул булыр, син өч көн кешеләр белән сөйләшмә, *(ишарә белән)* ым кагып кына аңлашырсың. Шулар өстенә, Раббыңны гел исеңдә тот вә ахшам-сабах, тәсбих әйт *(намаз укы)*,—диде.

**42.** Фәрештәләр әйтте:

—Әй, Мәрьям, шик юк ки, Аллаһ сине сайлады, сине аеруча саф итеп тәрбияләп үстерде, сине дөньядагы башка хатыннардан өстен кылды,—диделәр.—**(43)** Ий, Мәрьям, чын күңелдән Раббыңа гыйбадәт кыл, сәҗдә кылучылар белән сәҗдә кыл, *(намаз укы).*

*«Әхмәт бине әл-Мөбарәк әйтәдер ки: бу аять хәзрәти Мәрьямнең пәйгамбәрлегенә дәлил була аламы, юкмы, дип мин Абдул-Азиз Әддәббагтан сорадым, ди. Муса (галәйһиссәләм)ның анасы кеби, Фиргавеннең хатыны Асия кеби, Сара, Хаҗәр, Һәува кеби хатыннар пәйгамбәр саналамы, юкмы, шуны беләсем килде. Чөнки галимнәребезнең кайберләре аларның пәйгамбәр икәнлекләре турында сөйли, икенчеләре пәйгамбәр түгелләр, ди; бәгъзеләре исә хәзрәти Мәрьямнең пәйгамбәр икәнлеген раслый кебек. Әһле сөннәт вә җәмәгатьнең рәисе Шәех Әшари кебекләре бу мәсьәләдә фикер әйтүдән тыелып тора. Борынгыларыбыз әйткән ки: фәрештә пәйгамбәрләрдән башкаларга иңмәс, бу аять исә хәзрәти Мәрьямгә фәрештә иңгәнлеген ап-ачык әйтә. Өмми мөршидем Абдул-Азиз Әддәббаг миңа шушы җавапны бирде: хатыннар чынлыкта пәйгамбәр булмаганнар. Хәзрәти Мәрьям ул сыйтдикадыр (пакь, тугрыдыр, изгедер). Пәйгамбәрлек белән изгелек Аллаһның нуры вә серенә бәйләнгән булса да, пәйгамбәрлек нуры изгелек нурына тиңгәл түгел».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**44.** *(Мөхәммәд)* болар *(Хәннә, Зәкәрия, Яхъя, Мәрьям вакыйгалары)* сиңа вәхий буларак, яшерен рәвештә төшерелә. Кем Мәрьямне тәрбиягә ала, дип шобага урынына каләмнәрен суга ыргытканда син алар янында түгел идең. Алар тарткалашкан вакытта да син анда түгел идең.

*«**Вәхий**—гарәпчәдә «уахий» буларак языла. Бу сүз, Аллаһ Тәгаләнең пәйгамбәрләргә ерак арадан торып, Үз ихтыярын, Үз теләгәнен йөкләве, ерактан торып сөйләшү алымы, әмерләр җиткезү ысулы кебек мәгънәләрне үз эченә ала. Тәфсирчеләрнең язуына караганда, Исраил угыллары Тәүратны күчереп язганда каләмнәрен суга ташлыйлар. Кемнең каләме беренче булып өскә калыкса, шул кеше Мәрьямне үз тәрбиясенә алачак, дип, шобага салалар. Шобаганы уклар атып ясаганнар, дип тә сөйлиләр».*

Хәйретдин Караман тәфсиреннән.

**45.** Фәрештәләр:

—Ий, Мәрьям, Аллаһ сина бер кәлимә әйтеп, сине сөендерәчәк: исеме Гайсә, *(кушаматы)* Мәсих, *(сыйфаты)* Мәрьям углыдыр. Дөньяда да, Ахирәттә дә данышөһрәте зурдан булыр. *(Ул)* Аллаһның бик якыннарыннандыр. **(46)** Бишегендә дә, үскәч тә ул кешеләргә *(хикмәтле)* сүз сөйләячәктер. Ул изгеләрдән булыр.

*«Хәзрәти Мәрьям хәзрәти Гайсәне тапкач, хатынның гыйффәте турында имеш-мимеш тарала. Бу гайбәтләргә каршы әле яңа гына туган Гайсә, Аллаһның кодрәте илә сөйләшә башлый вә үзенең Аллаһ җибәргән илчесе вә колы икәнлеген, үзенә китап иңдереләчәге, Аллаһ тарафыннан мөбарәк кылынганлыгы турында сөйләп бирә. **Гыйффәт**—кызлык, сафлык».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.

**47.** *(Мәрьям)* әйтте:

—Йа Раббым, миңа бер генә ирнең дә кагылганы юк. Ничек итеп балам булыр соң?—диде. *(Фәрештәләр аша)* Аллаһ әйтте:

—Шулай! Аллаһ ни теләсә, шуны башкара ала. Ул берәр эшкә ният итсә: бул, дисә, Ул теләгән нәрсә шунда ук була да. **(48)** —*(Аллаһ)* аны язарга, аңа хикмәтләр, Тәүратны, Инҗилне өйрәтәчәк,—*(диделәр фәрештәләр)*. **(49)**—Аны Исраил угылларына пәйгамбәр итеп күндерәчәк,—*(диделәр фәрештәләр). (Гайсә аларга әйтәчәк):*

—Дөресе шулдыр ки, мин сезгә Раббыбыздан аять *(сөенче)* китердем. Дөресе шулдыр ки, мин сезгә үзле балчыктан кош сыны ясармын, аңа тыным белән өрермен дә, Аллаһ куәте илә, җанлы кошка әверелер. Аллаһ ярдәме илә, мин тумыштан сукырны күзле итәрмен, тилчәле хасталарны сәламәтләндерермен, үлеләрне тергезермен. Өегездә ни ашаганыгыз, нәрсә яшергәнегез турында мин сезгә әйтермен. Әлбәттә, бу галәмәтләрдә сезнең өчен, әгәр дә сез иман китерсәгез, катгый гыйбрәтләр бар. **(50)** Миннән элек иңдерелгән Тәүратны дөресләүче буларак вә сезгә харам ителгән бәгъзе бер нәрсәләрне хәләл итәр өчен *(килдем)*. Сезгә Раббыбыздан *(пәйгамбәрлегемне исбат итәр өчен)* аять *(хикмәт, могҗиза)* китердем. Инде хәзер Аллаһның нәфрәтеннән куркыгыз, миңа итагать итегез. **(51)** Шөбһә юк ки, Аллаһ минем дә Раббым, сезнең дә Раббыгыз. Шулай булгач, Аңа коллык итегез. Тугры юл шул булыр.

**52.** Гайсә аларның инанмаганнарын аңлап алгач, әйтте:

—Аллаһ юлында кем миңа ярдәмче булыр?—диде. Хаварилар:

—Без ул Аллаһ илчесенең ярдәмчеләре. Аллаһка инандык. Син дә *(Гайсә)* шаһит бул, без чын мөселманбыз,—диделәр.

*«Хаварилар, Гайсәгә ияргән кешеләр, сәхабәләр мәгънәсендә булыр. «Хавари» хабәшчәдән гарәпчәгә кергән сүздер. Ярдәмче, иярчен мәгънәсендә». **Хавари**—апостол.*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.

**53.** —Йа Раббыбыз, Син иңдергән *(ул Китапка)* инандык, бу пәйгамбәренә дә баш ордык. Инде безне шаһитләр белән рәттән теркәп куй,—*(дип)*. **(54)** Кяферләр мәкерле хәйлә кордылар *(Гайсәне яшертен генә үтерергә уйладылар)*, Аллаһ та аларга каршы хәйлә корды. Аллаһ *(бөтен хәйләкәрләрдән дә)* хәйләкәррәктер.

*«Мөселманнар арасында кяферләргә сатылган бер монафикъ бар иде. Шул тегеләрне Гайсәнең өенә алып килде. Ләкин Аллаһ Гайсәне күккә күтәргән иде. Аллаһ теге монафикъны Гайсәне үтерәбез дип, монафикъны астылар».*

Шәех Ногмани тәфсиреннән.

**55.** Шунда Аллаһ болай диде:

—Ий, Гайсә, шөбһәсез ки, *(алар түгел)* Мин сина әҗәл җибәрәчәкмен, сине Үз яныма күтәреп, сине көферлектән коткарып, сина ияргәннәрне Кыямәт көненә

кадәр көфер итүчеләрдән өстен тотачакмын. Сонгы кайтышыгыз да Минем ихтыярымдадыр. Арагызда булган каршылыклар-гаугаларнын хөкемен дә Мин бирәчәкмен. **(56)** Көфер итүчеләргә килгәндә, Мин аларны дөньяда да, Ахирәттә дә иң хәтәр җәза белән газаплаячакмын. Аларга һичбер кем ярдәм итә алмас.

**57.** Иман китереп, игелекләр эшләгәннәргә килгәндә, *(Аллаһ)* аларның әҗерен тәгәл итеп бирәчәктер. Аллаһ залимнәрне сөймәс. **(58)** Без боларны сиңа аятьләрдән *(хикмәт тулы Корьәннән)* укыйбыз.

**59.** Хакыйкать шулдыр ки, Гайсәнең хәле дә *(атасыз дөньяга килүе дә)*, Адәмнең язмышы да Аллаһ хозурыннандыр. *(Аллаһ)* аны *(Адәмне)* туфрактан яралтты. Сонра аңа:

—Бул!—диде.

Адәм бар булды.

*«Аллаһ хәзрәти Адәмне анасы да, атасы да булмаган килеш, туфрактан яралтты. Мәрьям дә, Аллаһ кодрәте илә, кыз килеш, ирсез бала тапты. Могҗизалар шулардыр. Аллаһның башкаларда булмаган тиңсез кодрәте дә шундый могҗизалар барлыкка китерүендә чагыла».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.

**60.** Хакыйкать Раббыдандыр. Шуңа күрә, шикләнүчеләрдән булма.

**61.** Сиңа гыйлем килгәч, синең белән тарткалашучылар булса, әйт:

—Килегез, угылларыбызны, угылларыгызны, хатыннарыбызны, хатыннарыгызны, үзебезне, үзегезне чакырамын, соңра дога кылып ялварырбыз да, Аллаһның ләгънәтен ялганчылар өстенә орырбыз,—диген.

*«Нәҗран христианнарыннан бер төркем Гайсә пәйгамбәр янына килеп, могҗиза рәвешендә, атасыз туган Гайсәне Аллаһ диеп танымакчы булдылар. Гайсә аларны бер җиргә туплап: Аллаһ ялганчылар өстенә ләгънәт орсын, дип дога укырга чакырды. Ләкин христианнар Гайсә белән килешмәделәр, куркып калдылар. Алар мөселманнар кул астына кереп, салым түләргә риза булып киттеләр».*

Мостафа Чагрыжы тәфсиреннән.

**62.** Менә бу *(хәбәр)*, әлбәттә, иң дөрес булган вакыйганың хәбәредер. Аллаһтан башка һичбер тәңре юк. Аллаһ, һичшиксез, бердәнбер кодрәт иясе. Аллаһ, чынлап та, кодрәт вә хикмәтләр хуҗасыдыр.

**63.** Әгәр *(Хакыйкатьтән, иманнан)* йөз чөерсәләр, хактыр ки, Аллаһ ул бозыклык таратучыларны белә.

**64.** Әйт:

—Әй, дин әһелләре, сезнең өчен дә, безнең өчен дә кулай булган уртак бер сүзгә килегез, менә болай әйтегез: Аллаһтан башкага табынмыйбыз. Аңа һичбер нәрсәне тиң итеп танымыйбыз, Аллаһтан башка ия эзләп йөрмәбез һәм бер-беребезне Аллаһ дип атамаячакбыз.

Моннан соң да алар йөз чөерсә, әйт:

—Шаһит булыгыз, без чын мөселманнарбыз,—диген.

*«Китаплылар, китап әһелләре, үзләренә китап иңдерелгәннәр» дигән гыйбарәләрнең барысы да яһүдләргә яки христианнарга кагыла. Чөнки гарәпләргә Корьән иңдерелгәнчегә кадәр, күпкә элек Яһүдләргә—Тәүрат, христианнарга Инҗил мөкатдәс иңдерелде.*

**65.** Әй, китап әһелләре, Ибраһим хакында ни өчен тарткалашасыз? Тәүрат та, Инҗил дә аннан *(Ибраһимнан)* соң иңдерелде. Шуңа да акылыгыз җитмиме?

*«Яһүдләр Ибраһимны үз динендәге кеше итеп саный, христианнар Ибраһимны үзләренеке, ди. Ләкин һәр ике дин дә Ибраһимнан соң килде бит. Ул инде әллә кайчан Аллаһны бер дип танучы мөселманнардан иде. «Тәүрат» борынгы яһүдчә «шәригать, хак сүз», дигәнне аңлата. «Инҗил» исә «күз нуры» мәгънәсендә йөри».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**66.** Менә сез дөреслекне белгән көе сүз көрәштерәсез, белмәгәнегез турында ни өчен тарткалашасыз? Гәрчә, Аллаһ барысын да белеп тора, сез белмисез.

**67.** Ибраһим яһүд тә, христиан да түгел, ул фәкать Аллаһны бер дип таныган *(хакыйкый мөселман иде)*. Ул мөшрикләрдән дә түгел. **(68)** Дөресе шулдыр ки, Ибраһимны бик тә якын күрүчеләр, һәрхәлдә, аңа ияргәннәр вә шул Пәйгамбәргә *(Мөхәммәдкә)* һәм *(аңа)* иярεп, иман китергәннәр иде. Иман китергәннәрнең ярдәмчесе—Аллаһ Тәгалә.

**69.** *(Ий, мөселманнар)* китаплы халыкның бер өере сезне юлдан яздырырга, аздырырга тели. Хәлбуки, алар үзләреннән башканы аздыра алмасларын чамаламыйлар да.

**70.** Әй, китап әһелләре, үзегез *(Тәүратта вә Инҗилдәге дөреслекне)* күрә торып, Аллаһның аятьләрен ни сәбәпле инкарь итәсез? **(71)** Әй, китап әһелләре, нигә сез хакны ялган белән бутыйсыз, дөреслекне яшерәсез? Моның шулай икәнен белеп торасыз, юкса.

**72.** Китаплы халыктан бер гөруһ әйтте:

—Үзләренә иңдерелгәнгә *(Коръәнгә)* иман китергәннәр алдында көндезен ышанган булыгыз, көн азагында кәфер *(инкарь)* итегез. Бәлки алар диннәреннән язарлар? **(73)** Һәм динегезгә инанганнардан башкасына ышанмагыз,—диделәр. *(Рәсүлем аларга)* әйт:

—Аллаһның юлы иң дөрес юл икәнлектә шик юк,—диген.—Сезгә бирелгәнгә *(Тәүратка, Инҗилгә)* охшаш *(Коръән)* башка берәүләргә дә бирелә ала.

Әгәр бу турыда бәхәсләшә башласалар, син әйт аларга:

—Чынлыкта юмартлык Аллаһ кулында. Ул теләгәненә әҗер бирер. Аллаһның рәхмәте киң, хакыйкатән, ул бөтен нәрсәне белеп торучы. **(74)** Ул кемгә теләсә, шуңар рәхмәт иңдерер. Аллаһ—иң бөек игелек иясе.

**75.** Китап укыганнар арасында шундыйлары бар: аларга син бер батман алтын бирсәң, ул аны сиңа киметмичә кайтарыр. Шундыйлары да бар, син аңа бер динар бирсәң—кайтармас, артыннан йөреп, өстендә торып алганчыга чаклы. Моның сәбәбе шулдыр, алар әйтә:

—Надан халык белән безнең алыш-бирешебез юк,—диләр. *(Янәсе, надан халыкны, гарәпләрне, мөселманнарны алдасаң да гаеп булмас.)*

Алар белгән көе, күзләрен дә йоммыйча, Аллаһка каршы *(ялган)* сөйлиләр.

*(«Китап укыганнар» гыйбарәсен «китап әһелләре—китаплы халык, яһүдләр, христианнар» дип аңларга кирәк.)*

**76.** Хактыр, үзенең вазифаларын *(әманәтен, вәгъдәсен)* бозмыйча үтәгән кеше, гөнаһлардан сакланса, шик юк ки, Аллаһ сакланганнарны саклар.

**77.** Хактыр ки, Аллаһка биргән сүзен-антын дөнья малына саткан кешеләргә Ахирәттә һичбер насыйбы булмас. Аллаһ Кыямәт көнендә алар белән сөйләшмәс, аларга бакмас, аларны пакьләмәс-акламас. Андыйларны хәтәр газап көтә.

**78.** Китаплы халык арасында шундый гөруһлар да *(төркемнәр)* бар, алар китапта язылганнарны *(Тәүратны, Инҗилне)* бозып укыйлар, шуны дөрес язу, диләр; гәрчә, ул сүзләр бу китапларда язылмаган иде. Бу—Аллаһтан ингән сүзләр, диләр; ул *(өстәлгән сүзләр)* Аллаһтан түгел. Алар, дөреслекне белгән көе, күз дә йоммыйча, ялган сөйлиләр. **(79)** Аллаһтан китап алып, акыл-зиһнияткә ия булып, пәйгамбәрлекне кабул итеп, соңыннан:

—Аллаһка гына буйсынмагыз, аның урынына миңа кол булыгыз,—дип гамәл кыла башласа, ул килешә торган эш булмас. Үзегез өйрәнеп, башкаларны да өйрәткән Китаптагыча:

—Аллаһка тугры кол булыгыз!—дип әйтергә кирәк.

*(«Мөшрикләр: Мөхәммәд үзенә табынырга, аңа гыйбадәт кылырга куша, диделәр. Пәйгамбәр, китап ярдәмендә бары тик Аллаһка гына инанызыз, дип аңлатырга тиеш. Христианнарның динендә Гайсә пәйгамбәр (Иисус Христос) илаһ буларак сурәтләнә. Аять шуңа ишарә итә.)*

**80.** —Фәрештәләргә, пәйгамбәрләргә Тәңрегә табынган кебек табыныгыз,—дип Аллаһ боермады. Яки сезне мөселман иткәннән соң, *(чын пәйгамбәр)* яңадан сезне кяферлеккә өндәрме?

**81.** Аллаһ пәйгамбәрләрне ант иттерде. Менә Мин сезгә Китап белән хикмәт *(Тәүрат белән Инҗилне)* бирдем. Бераздан сезнең кулыгыздагыларны раслау-дөресләү өчен тагын бер Пәйгамбәр киләчәк. Аңа шиксез иман китерерсез вә аңа һәрвакыт ярдәм итәрсез. Шушы шартларны кабул итәсезме?

*(Алар):*

—Кабул итәбез,—дип икърар кылдылар.

*(Аллаһ)* әйтте:

—Алайса, бер-берегез алдында шаһит булыгыз, Мин дә сезнең белән бергә шаһит,—диде.

***(Икърар****—инкарьның киресе; раслау, риза булу, кабул итү, дөресен сөйләү.)*

**82.** Кем дә кем шушы шаһитлектән баш тарта, йөз чөерә, менә шундыйлар фасикъ, зиндикъ *(иманнан качканнар)* булыр.

**83.** Хәзер алар Аллаһның диненнән башка бер дин эзләп китteләрме? Хәлбуки, күкләрдә вә Җирдә ни булса, теләсәләр дә, теләмәсәләр дә Аңа буйсына, ниһаять, аларның барысы да Аллаһ каршысына китереләчәк. **(84)** Әйт:

—Аллаһка иман китерик. Безгә иңдерелгән *(Корьән-и Кәрим)*гә, Ибраһимга, Исмәгыйльгә, Исхакка, Ягъкубка вә угылларына иңдерелгәннәргә, Мусага, Гайсәгә вә пәйгамбәрләргә, Раббыларыннан бирелгәннәргә дә инандык. Алар арасыннан һичберсен артык-ким күрмибез. Без Аңа бирелгән бәндәләрбез,—диген. **(85)** Исламнан башка дин эзләгән кешенең кылганнары кабул булмас, ул Ахирәттә дә *(оттырачак)* хәтәр җәзага дучар булачак. **(86)** Иманга килеп тә, Рәсүлнең хак булганлыгына шәһадәт биреп тә, үзләренә ап-ачык аятьләр инеп тә, соңыннан инкарьчылыкка *(Аллаһны, Пәйгамбәребезне танымауга)* кереп баткан кавемне Аллаһ ничек итеп ярлыкасын, ди? Аллаһ фасикъ-зиндикъларны тугры юлга чыгармас. **(87)** Хактыр ки, Аллаһның, фәрештәләрнең, бөтен кешеләрнең ләгънәте алар башына. Менә аларның җәзасы шул булыр. **(88)** Алар моның эчендә *(ләгънәттә вә җәһәннәмдә)* мәңгегә калачаклар. Аларның газаплары һич кичектерелмәс, жиңеләйтелмәс, аларга игътибар итүче дә булмас. **(89)** Моннан соң тәүбә итсәләр вә тугры юлга бассалар, башкача булыр. Чөнки Аллаһ, чыннан да, кимчелекләрне кичерүче, киң күңелле, ярлыкаучы. **(90)** Хактыр ки, иманга килеп тә, соңыннан кяферлеккә күчкәннәр, алга таба көферлеген тагын да арттырганнарның тәүбәләре кабул ителмәс. Менә шулар инде адашкан бәндәләр. **(91)** Хактыр ки, көфер итүчеләр вә кяфер буларак үлгәннәр Җир йөзен тутырырдай микъдардагы алтыннарын түләсә дә, садакалары катгыян кабул булмас. Менә шундый алар. Бик хәтәр газап аларның өлешедер. Андыйларның һичбер ярдәмчесе дә булмас. **(92)** Сез сөекле нәрсәләрегезне *(мал-мөлкәт, садака, зәкятларыгызны Аллаһ юлында)* сарыф итмәсәгез, игелеккә ирешә алмассыз. Сез нәрсә сарыф иткәнегез-итмәгәнегезне дә Аллаһ белеп тора.

*«Бу аять иңгәннән соң Әбү Талһа үзенең иң яраткан бакчасын Аллаһ юлында корбан итәчәген әйтә. Рәсүлуллаһү-саллаллаһү галәйһи вә сәлләм-садака буларак, ул бакчаны якын туганына вә агасының угылларына бирергә кыстый. Һәм бу шулай була да. Хәзрәти Гомәр иң сөекле җариясен азат итә. Зәед бине Харис Сәел исемле мәшһүр атын кешегә бүләк итә. Гомәр бине Габдел-Газиз хәзрәтләре фәкыйрьләргә мул итеп шикәр өләшеп чыга. Нигә алай иттең, дигәннәргә каршы ул: мин бик тә шикәр яратам, дигән».*

Хәсән Чантай тәфсиреннән.

**93.** Тәүрат иңдерелгәнгә кадәр Исраилның үзенә ашарга ярамаган ризыклардан *(дөя ите, дөя сөтеннән)* башкасы Исраил угылларына харам түгел иде.

Әйт син:

—Әгәр дә сез тугры юлда икәнсез, Тәүратны алып килегез дә укыгыз,—диген. **(94)** Моннан соң *(ягъни Тәүратны укыганнан соң)* Аллаһ аятьләренә каршы ялган уйдырып сөйләсәгез, сез залимнәр-зиндикъլар булырсыз. **(95)** Әйт:

—Аллаһ дөресен сөйли, шуңа күрә, Аллаһны бер дип белсәгез, Ибраһим ышанган дингә йөз тотыгыз, ул мөшрик түгел иде,—диген.

**96.** Хактыр ки, адәмнәр өчен салынган вә тугры юл күрсәтүче беренче Йорт ул, әлбәттә, Мәккәдәге Йорт *(Кәгъбәдер)*.

**97.** Анда ап-ачык галәмәтләр, үрнәк вә гыйбрәтләр, Ибраһим баскан җирләр бар. Анда кергән кеше иминлектә булыр. Юлын тапкан *(көче җиткән, хәленнән килгән)*

кешеләрне Аллаһ анда *(Хаҗга)* барырга бурычлы итте. Берәрсе инкарь итә икән, Аллаһ аңа *(галәмдәге бернигә дә)* мохтаж түгел.

**98.** Әйт:

—Әй, китап тоткан кавем, сез ни генә кылсагыз да, Аллаһның, хакыйкатән, барысын да күреп торганын беләсез, бәс, ни өчен Аллаһның аятьләрен инкарь итәсез?—диген.

**99.** Әйт:

—Әй, китап тоткан кавем, үзегез *(Исламның хак дин икәнен китапларыгыздан укыган килеш)* күреп торган көе, нигә сез иманлы кешеләрне Аллаһ юлыннан яздырырга тырышасыз, үзегез анда кимчелек табарга маташасыз. Аллаһ кылганнарыгызны белми түгел. **(100)** Әй, иман китергәннәр, әгәр дә үзләренә китап иңдерелгәннәр арасындагы гөруһларга баш иясе булсагыз, сезне иманыгыздан ваз кичтереп, кяфер итәчәкләр. **(101)** Аллаһның аятьләрен укып торганда, пәйгамбәре дә арагызда утырганда, ничек итеп сез Аллаһка көфер итәсез? Кем Аллаһка *(диненә)* ныклап тотынса, хактыр ки, ул чынлыкта тугры юлны тапкан булыр. **(102)** Әй, иман китергәннәр, Аллаһның җәзасыннан ничек куркырга кирәк булса, шулай куркыгыз. Сак булыгыз ки, мөселманлыктан башка сыйфатта җан бирмәгез *(мөселман булып үлегез)*. **(103)** Барчагыз да бер булып, Аллаһның арканына *(Коръәнгә, Ислам диненә)* тотыныгыз. Сез бер-берегезгә дошман идегез, Ул сезнең күңелләрегезне берләштерде. Аның нигъмәте аркасында кардәшләр булдыгыз вә янә сез астында ут янып торган упкынның кырыенда идегез, аннан сезне Ул коткарды. Аллаһ сезгә аятьләрен менә шулай ап-ачык итеп аңлата. Шаять тугры юлга ирешерсез. **(104)** Сездән шундый бер өммәт булырга тиеш ки, алар һәркемне хәерле эшләргә, игелеккә өндәрләр, яманлыктан ваз кичәргә чакырырлар. Менә шундыйлар морадларына ирешкән кешеләр булыр. **(105)** Сез үзләренә ап-ачык аятьләр килгәннән соң да талашып, аерылышып беткәннәр кебек булмагыз: менә шундыйларның хәле бик тә яман булачак. **(106)** Ул Көндә ничә йөзләр *(чырайлар)* акланыр, ничә йөзләр кап-кара булачак. Кара йөзлеләргә килгәндә:

—Иманыгыздан ваз кичтегез бит, менә көферлегегезгә таман газап татыгыз,—дип әйтеләчәк. **(107)** Йөзләре ак булганнар исә Аллаһның рәхмәтенә юлыгачак. Алар шул рәвешчә мәңгегә анда *(җәннәттә)* калачак.

**108.** Болар Аллаһның хак аятьләре, аларны сиңа укый киләбез. Аллаһ бәндәләренә һичбер хаксызлык кылырга теләми.

**109.** Күкләрдә ни бар, Җирдә ни бар—бөтенесе Аллаһныкыдыр. Бөтен эшләр дә Аллаһ каршына китерелер. **(110)** Сез—кешеләрнең иминлеге өчен *(Ләүхел Мәхфүздә сайланып)* дөньяда мәртәбәгә күтәрелгән иң игелекле бер кавем. Игелеккә өндәп, яманлыктан ваз кичәргә чакырдыгыз. Аллаһка ышанасыз. Китаплы кяферләр дә шулай ышанса иде, үзләре өчен хәерлерәк булыр иде дә бит. Алар арасында да иман китергәннәр бар. Ләкин аларның күбесе фасикълар.

**111.** Алар вак рәнҗетүдән башка сезгә һични эшли алмас. Әгәр сезнең белән сугыша башласалар, алар табаннарын ялтыратып качачаклар. Соңыннан аларга ярдәм итүче булмас. **(112)** Алар кайда гына булсалар да котыла алмас, чөнки аларга җиңелү тамгасы орылган инде. Бәс, алар Аллаһның бавына *(Коръәнгә)* тотынсыннар, кешеләргә *(мөэминнәргә)* сыенсыннар. Алар Аллаһның ачы каһәренә дучар булды. Өсләренә мескенлек сирпелде. Моның сәбәбе шулдыр ки, алар Аллаһның аятьләрен инкарь иттеләр, кяфер булдылар, пәйгамбәрләрне хаксызга үтерделәр. Буйсынмаганнары өчен вә чыгырдан чыкканнары өчен *(Без кяферләрне җәзага тоттык)*. **(113)** Аларның барысы да бер түгелдер. Китаплыларның арасында диндә нык басып торучы өммәт тә бардыр, алар төнлек сәгатьләрендә сәҗдәгә китеп, Аллаһның аятьләрен укыйлар. **(114)** Аллаһка вә Ахирәт көненә ышанганнар, игелеккә өндәүчеләр, яманлыктан ваз кичтерүчеләр, игелекле эшләрдә ярышучылар—менә шулар изгеләрдер. **(115)** Алар никадәр хәерле эш кылсалар, әлбәттә, Аның әҗереннән мәхрүм калмаслар. Аллаһ тәкъва кешеләрне яхшы белә. **(116)** Хактыр ки, ул көфер иткәннәрне *(андыйлар юкмы?)* аларны маллары да, балалары да, һич нәрсәдән *(Аллаһның газабыннан)* коткара алмас. Алар—җәһәннәм әһелләре. Алар анда мәңгегә калачак. **(117)** Кяфер кешеләрнең бу дөньяда халыкка *(ихлассыз)* биргән маллары *(садакалары)* салкын җилгә охшаштыр, ул җил үз-үзләренә золым итүче кавемнең

игеннәрен һәлак итте. Аллаһ аларга золым итмәде, алар үзләренә үзләре золым китерде.

**118.** Ий, иман китергәннәр, үз токымыгыздан *(мөселманнардан)* башкаларны сердәш итмәгез. Алар *(кяферләр)* сезгә яманлык вә хөсетлек кылу эшләрендә үҗәт булачаклар, алар сезнең бәлагә тарганыгызны көтәр. Хактыр ки, аларның нәфрәте бугазларыннан чыкты. Күңелләрендәгесе *(хөсетлек)* тагын да яманрак. Уйлый белгәннәр өчен без аятьләребезне ачык итеп иңдердек. **(119)** Менә сез аларны сөясез, алар сезне сөйми. Сез китапларның барчасына инанасыз, алар сезнең белән бергә булганда гына: «инанабыз», диләр. Үзара калган чакларында алар зәһәрлектән бармакларын чәйни башлыйлар. Әйт аларга:

—Ачуыгыздан шартлагыз!—диген.

Шөбһәсез ки, Аллаһ аларның эчендә ни бар, барысын да белеп тора.

*(Сез аларны сөясез, ягъни аларның мөселман булуларын телисез, аларга булачак мөселманга баккан кебек сөеп багасыз. Чөнки Ислам һәр нәрсәгә өмет багларга куша. Хәлбуки, алар сезне сөйми, ягъни алар сезнең кяфер булуыгызны тели, кяферлек исә яманлык белән бер.)*

**120.** Сезгә яхшылык килсә, алар кара көя. Сезгә бериәр бәла килсә, алар куана. Әгәр сез чыдам булсагыз, гөнаһлардан саклансагыз, аларның хәйләләре сезгә һичничек тә зарар китерә алмас. Шөбһә юк ки, Аллаһ ни кылсалар да, гөнаһлыларны *(җәзасы белән)* чорнап алучыдыр.

**121.** Менә син мөселманнарны сугыш өчен уңайлы урыннарга тезәргә дип, иртән иртүк өеңнән чыгып киттең. Чынлап та, монафикълар, кяферләр ни кылса да, Аллаһ барысын да мөкәммәл ишетеп, белеп торучы.

*(Мөхәммәд Пәйгамбәр мөселманнарны Ухуд сугышына ничек итеп әзерләве турындагы аять.)*

**122.** Шул вакытта сезнең арадан ике гаскәр куркуга төште. Аллаһ аларга ярдәм итте. Мөэминнәр фәкать Аллаһка гына ышанырга тиеш.

*«Ухуд сугышында хәзрәти Пәйгамбәребезнең уң вә сул канатларында орышырга тиешле Харәҗ кабиләсенең Сәләмә угыллары белән Әвес кабиләсеннән Харисә угыллары дошман алдында каушап кала һәм кача башлыйлар. Шулвакыт өч йөз кеше белән идарә итүче Ибен Үбәй болай дип кычкыра: үзебезне вә балаларыбызны да хурлыкка калдырабыз бит, ди. Шуннан соң мөселманнар кире борылып, дошман белән хәтәр сугыша башлыйлар һәм җиңеп чыгалар».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**123.** Хактыр ки, сез Бәдер сугышында көчсез вә каушаган идегез, Аллаһ сезне җиңүгә ирештерде. Аллаһның җәзасыннан куркыгыз, Аңа шөкер итегез. **(124)** Шул вакытта син мөэминнәргә:

—Иңдерелгән өч мең фәрештә белән Раббыбызның ярдәме сезгә житмимени?—диден. **(125)** Әлбәттә, сез түземлек белән Аллаһ юлында булсагыз, көтелмәгәндә *(дошман)* һөҗүм(е) булса, Раббыбыз сезгә сайлап алынган биш мең фәрештә белән ярдәм итәчәк. **(126)** Аллаһ моны *(фәрештәләр белән ярдәм итүне)* фәкать сезне куандырыр өчен, күңелегез тынычлансын, дип эшләде. Җиңү, хөкем вә хикмәтләрнең хуҗасы бары тик Аллаһ Җанәбедер.

**127.** Кяферләрнең өндәрләрен чабып үтерсеннәр дип, аларның башлары аска килсен, морадларына ирешә алмыйча, качсыннар дип, Мин сезгә ярдәм иттем.

*(Бәдер сугышында мөшрикләрнең җитмеш батыры үтерелде, җитмеше әсир ителде. Өндәр—өндәүче, юлбашчы, җитәкче.)*

**128.** Бәндәләремнең эшләрендә синең һичбер галәкәң юк. Аллаһ аларның тәүбәсен кабул итәр яки аларны залим булганнары өчен, газапларга салыр. Чөнки алар чыннан да залим.

*(Галәкәң—эшең, катнашың, бәйләнешең.)*

**129.** Күкләрдә ни бар, Җирдә ни бар—бөтенесе дә Аллаһның милке. Кемне тели, шуны ярлыкый Ул, кемне теләсә, шуңа җәза бирә. Аллаһ киң ихтыярлы, ярлыкаучы, хакыйкатән, гөнаһларны кичерүчедер.

**130.** Әй, иман китергәннәр, рибаны кат-кат арттырып алмагыз. Аллаһның нәфрәтеннән куркыгыз. Шулай булганда, морадыгызга ирешерсез.

*(**Риба**—әҗәткә биреп торган акча, мал өчен арттырып түләтү, ломбард, процент акчасы, ростовчылык.)*

**131.** Кяферләр өчен хәзерләнгән уттан *(җәһәннәмнән)* сакланыгыз. **(132)** Аллаһка вә Пәйгамбәргә итагать итегез, ярлыкау һәм рәхмәткә ирешерсез. **(133)** Раббыбызның ярлыкавына вә тәкъва мөселманнар өчен хәзерләнгән җәннәткә, күкләр һәм Җир кебек иркен урынга омтылыгыз.

**134.** Алар—саф мөселманнар; муллыкта да, юклыкта да юмарт булганнар, ачу сакламаучылар, кешеләрнең кимчелекләрен кичерә белүчеләр *(өчен ул җәннәт)*. Аллаһ игелек кылганнарны сөядер.

**135.** Җирәнгеч эшләре белән гөнаһкяр булганнарны, үзләренә үк начарлык эшләгәч, сонра Аллаһны искә төшереп, тәүбә итеп, гөнаһларын ярлыкатырга теләгәннәрне Алла ярлыкар. Аллаһтан башка аларны кем ярлыкар? *(Әлбәттә)*, алар гөнаһ кылуларын күрәләтә дәвам итмәсәләр. **(136)** Менә аларга шундый әҗер—Аллаһның ярлыкавыдыр: гөлбакчалар арасында агып ятучы чишмәләр игелек кылганнар өчен гаять гүзәл бүләк һәм алар анда мәңгегә калачак.

**137.** Чынлыкта сездән әүвәл бик күп илаһи кануннар *(гыйбрәтле вакыйгалар)* булып узган иде инде. Шуңа күрә, Җир йөзе буйлап сәяхәт итегез, *(аятьләрне)* ялган дип хисаплаганнарның хәле ничек булганын күрерсез *(гыйбрәт алырсыз!)*.

**138.** Бу *(Коръән)* инсаннар өчен бер хәбәрдер, *(яманлыклардан)* саклану өчен диндар кешеләргә бер котылу юлы вә үгет-нәсихәттер.

**139.** *(Мөселманнар)* каушамагыз, хафаланмагыз, әгәр дә сез мөэмин-мөселман икәнсез, сез барчасыннан өстен булырсыз.

*«Ухуд сугышы вакытында Абдулла бине Камия исемле бер кяфер таш атып, Рәсүлулла (с.г.с.)ның йөзен җәрәхәтли. Кяферләр: Мөхәммәд үлде, дип кычкыралар, мөселманнар бу ялганны ишетеп, кача башлыйлар, каушап калалар. Ләкин Мөхәммәд галәйһиссәлләм: мин монда, минем тарафка килегез, дип кычкыра. Утызлап җегет аны уртага алып, саклап кала. Аять шушы вакыйгага ишарә итә».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**140.** Әгәр дә сез *(Ухуд сугышында)* яраланган булсагыз, *(Бәдер сугышында)* башка кавемгә дә *(кяферләргә)* шундый ук хурлык килгән иде. Андый көннәрне без чиратлаштырып торырбыз. *(Бер көнне кяферләр җиңәр, икенче көнне мөселманнар җиңүче булыр.)* Аллаһ иман китергәннәрне ачыкласын өчен вә арагыздан шәһидләр *(һәм шаһитләр)* сайласын өчен, мөэминнәрне пакь кылып, кяферләрне *(мордар кылып)*, һәлак итсен өчен шулай хуп күрде. Аллаһ гаделсезләрне сөйми.

*«Иман китергәннәрне ачыкласын өчен» гыйбарәсе «ли ягъләмә»нең мәгънәсен аңлатадыр. Аллаһның мәңгелек гыйлеме белән мөселманны кяфердән аера белергә тиешлебез. Шуның сәбәбе илә «шәһидләр» мәгънәсендә килүче «шүһәдә» сүзен «шаһитләр» диеп тә тәрҗемә итәләр».*

*Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.*

**141.** Аллаһ иман китергәннәрне гөнаһлардан йолып, пакьлеккә чыгарыр өчен, кяферләрне һәлак итәр өчен шулай эшләде.

**142.** Юкса, сез Аллаһ юлында *(Җиһадта, Газаватта)* сугышканнар белән сугышмаганнарны, түземлекләр кичергән сабырларны ачыкламыйча гына, Аллаһ сезне җәннәткә кертер, дип уйлыйсызмы?

**143.** Хакыйкатән, әҗәл килгәнче үк үлем *(шәһидлек)* теләдегез, менә инде сез бер карауда ук үлемне *(күрдегез)* татыдыгыз.

**144.** Мөхәммәд ул—Пәйгамбәр булудан гайре беркем дә түгел. Аннан элек ничә пәйгамбәр *(бу дөньяга)* килеп киткән. Хәзер ул үлсә яки үтерелсә, баскан җирегездән кирегә борылырсызмы? *(Янә кяфер булырсызмы?)* Кем дә кем иманын ташлап, динсезлеккә күчә икән, Аллаһка һичбер зарар кыла алмас. Аллаһ шөкер иткәннәр вә сабыр-чыдам булганнарга әҗер бирәчәк.

*(Мөхәммәд Пәйгамбәр яраланды, үтерелде, диеп, йөрәгегезгә курку иңмәсен, Җиһад сугышын батырларча дәвам итәргә кирәк, Пәйгамбәр үлде, диеп, Ислам үлмәс, сез аны дәвам итүчеләр.)*

**145.** Аллаһтан хәбәр иңмәенчә, һичберкемгә әҗәл килмәс; *(үлем)* тәкъдирдә язып куелган сәгатьтә генә килер. Кем дә кем бу дөньяда нигъмәт-савап теләсә— бирербез, кем исә Ахирәт савабын теләсә, аны да бирербез. Без шөкер итүчеләргә әҗер бирәбез.

**146.** Ничәмә-ничә пәйгамбәрләр килеп китте, алар белән ингә ин куеп, күпме мөэминнәр *(Җиһад юлында)* орышты, алар Аллаһ юлындагы көрәшләрдә куркаклык, вак җанлылык күрсәтмәделәр, *(дошманга)* буйсынмадылар. Аллаһ чыдамнарны сөя. **(147)** Менә алар әйткән сүз:

—Йа, Раббыбыз, безнең гөнаһларыбызны вә эшебездә хәттин ашкан хаталарыбызны ярлыка. *(Сугышканда)* тез буыннарыбызны ныгыт. Кяферләр гөруһына каршы безгә ярдәмче бул,—дигәннәреннән башка сүз юк. **(148)** Ниһаять, Аллаһ аларга һәм дөнья нигъмәтен *(мал, шәрәф, дан-шөһрәт)*, һәм Ахирәт савабының гүзәллеген бирде. Аллаһ игелекле гамәлдә булганнарны сөя.

**149.** Әй, иман китергәннәр, әгәр кәфер иткәннәргә буйсынсагыз, алар сезне иманыгыздан яздырып, янәдән кяфер ясарлар һәм хәтәр бәлаләргә тарганнар хәленә төшерерләр.

*«Ухуд сугышында «Мөхәммәд үтерелде» дигән ялган хәбәр таралгач, мөселманнар каушап кала, кяферләр аларга: Исламнан йөз чөерегез, пәйгамбәрегез үлде, дип кычкыралар. Ялган коткылардан сак булырга өндәүче аять иңдерелә».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**150.** Хактыр ки, сезнең ярдәмчегез Аллаһтыр. Ул ярдәм итүчеләрнең иң хәерлесе.

**151.** Без кяферләрнең күңелләренә курку салдык, чөнки алар, Аллаһтан әмер килмәгән көенчә, Аллаһка тиңдәш итеп мәхлукка табына. Аларның барачак җире дә җәһәннәмдер. Гаделсез залимнәрнең барасы җире бик тә хәтәр урын.

**152.** Аллаһ сезгә биргән вәгъдәсен үтәде. Аллаһ ярдәме белән сез кяферләрне җиңә башладыгыз. Ниһаять, шундый бер форсат ачылды ки, Аллаһ теләгегезне *(җиңүгә омтылышыгызны)* башкарырга сезгә мөмкинлек бирде, ләкин сез каушап калдыгыз. *(Пәйгамбәрнең)* әмере хакында тарткалаша башладыгыз, гыйсъян иттегез. Сезнең дөнья теләкләрегез дә, Ахирәт теләкләрегез дә бар иде. Соңра Аллаһ сезне сынап карау өчен *(бер-берегезгә кемнең кем икәнен күрсәтер өчен)* сезне уңыштан читкә борды һәм Ул сезне гафу итте. Аллаһ чынлыкта мөселманнарга миһербан ияседер.

*(**Гыйсъян**—баш күтәрү, бунт, каршы көрәшү. Ухуд сугышында башта мөселманнар җиңүгә ирешә. Соңра алар куркып, кача башлый. Пәйгамбәр ике тау арасында поскын гаскәр урнаштырып куйган була. Кяферләрнең җиңелүен күргәч, поскын гаскәрдәгеләр качкан урыннан чыгу-чыкмау турында бәхәсләшә башлый. Әмерне бозып, алар качкан урыннарыннан вакытыннан элек чыгалар, кяферләр камалышына эләгәләр һәм җиңеләләр. Шулай итеп, бу мөселманнарның Пәйгамбәр сүзеннән чыкканнарын, гөнаһ кылганнарын ачыклап күрсәтү була.)*

**153.** Ул вакытта сез, күзегезгә ак-кара күренмәстән *(сугыш мәйданыннан)* тауга таба кача идегез. Пәйгамбәр исә сезнең артыгыздан *(минем янга җыелыгыз, дип)* кычкырып калды. Шуңа күрә, Аллаһ сезне афәт өстенә афәт биреп җәзалады. Кулыгыздан ычкынганга *(ганимәт малына)* да, башыгызга төшкәнгә дә кайгырмагыз. Аллаһ сез ни кылсагыз да белеп тора.

*(**Ганимәт**—сугышта җиңелгән дошманның, дәүләтнең малын җиңүчеләр ала. Менә шул мал «ганимәт» дип атала. Сугышта үтерелгән дошманның шәхси әйберләрен: атын, коралларын, хатыннарын җиңүче ала. Менә шулар «үлҗә» дип атала. Урысчасы—трофей.)*

**154.** Соңра, кайгыдан соң, Ул сезгә тыныч йокы бирде, бер төркемегезне йокы алды, икенчеләрегезнең күңеленә шом кереп ятты. Алары Аллаһ хакында җаһилият заманындагы кебек *(Коръән иңгәнчегә чаклы вакыттагы кебек)* кәфер фикер йөртә башлады:

—Бу эштән безгә ни файда?—диделәр. Әйт син аларга:

—Барча эшләр дә Аллаһныкы,—диген.

Алар күңелләрендә сиңа әйтмәгән мәкер саклый. Алар:

—Бу эшләрдән безгә файда булса, без бу урында үтерелмәгән дә булыр идек,—диләр.

Шулай да, сез өйләрегездә калган булсагыз да, тәкъдиренә үтереләчәге язылган булганнар, үтереләчәк урынга үзләреннән үзләре чыгып киткән булырлар иде. Аллаһ сезнең эчегездәге мәкерле уйларыгыздан арындырмак һәм күңелләрегезне пакьләндермәк өчен шулай кылды. Күңелләрегездә ни бар—бөтенесен дә Аллаһ белеп тора.

**155.** Хактыр ки, *(Ухуд сугышында)* ике гаскәр кара-каршы килгән көнне сезне ташлап качканнарны бәгъзе хаталары аркасында шайтан абындырды. Янә дә Аллаһ аларны гафу итте инде. Аллаһ ярлыкаучы вә сабыр-салмактыр.

**156.** Ий, иман китергәннәр, сез көфер итүчеләр вә дөнья буйлап сәфәргә чыккан яки сугышта катнашкан кардәшләре хакында:

—Әгәр безнең янда *(өйдә)* калган булсалар, үлмәгән булырлар иде, аларны үтермәгән булырлар иде,—дип әйтүчеләр кеби булмагыз.

Аллаһ моны, аларның йөрәкләре хәсрәткә талсын, дип башкарды. Җанны иңдергән дә, җанны алган да—Аллаһтыр. Сез кылганнарның барысын да Аллаһ күреп торыр. **(157)** Әгәр Аллаһ юлында үтерелер яки үләр булсагыз, шуны белеп торыгыз ки, Аллаһның ярлыкавы вә рәхмәте алар җыйган бөтен байлыктан да хәерлерәктер. **(158)** Хакыйкать, үлсәгез яки үтерелсәгез дә Аллаһ хозурында җыелачаксыз. **(159)** Аллаһның рәхмәте илә син аларга миһербанлы булдың, әгәр дә син аларга рәхимсез булсаң, һичшиксез, алар синнән качар иде. Аларны син кичер инде. Аларның гөнаһлары кичерелсен, дип дога кыл, алар белән киңәшеп эш башла. Ныклы бер карарга килсәң дә, Аллаһка тәвәккәллә. Чөнки Аллаһ Үзенә тәвәккәлләгәннәрне сөя.

**160.** Аллаһ сезгә ярдәм итеп торганда сезне һичкем җиңә алмас. Әгәр ул сезне ташласа, аннан башка сезгә кем ярдәм итәр? Мөэминнәр бары тик Аллаһка гына таянырга тиеш.

**161.** Пәйгамбәр әманәткә хыянәт итмәс. Кем әманәткә хыянәт итсә, Кыямәт көнне шул хыянәт йөген күтәреп, Аллаһ хөкеменә килер. Соңра һәркем үз гөнаһысына тәңгәл җәза алыр, һичкем хаксызга артыгы белән җәзаланмас.

**162.** Аллаһның ризалыгына ияргән кеше белән Аллаһның ачуына дучар булган кеше тигез булырмы? Соңгысының урыны җәһәннәмдер. Җәһәннәм исә бик тә хәтәр урындыр.

**163.** Аларга *(Аллаһ ризалыгын алганнарга)* Аллаһ катында дәрәҗәләр бар. Аллаһ аларның кылмышларын белеп торучы.

**164.** Хактыр ки, *(җаһиллек заманнарында)* ап-ачык вә мотлак адашкан булсалар да, үз араларыннан пәйгамбәр сайлап, Аллаһ мөэминнәргә гаять киң рәхмәтле булды. Пәйгамбәр аларга Аллаһ аятьләрен укый, аларны яманлыклардан арындыра, аларга Китапны *(Корьәнне)* вә хикмәтләр өйрәтә.

**165.** *(Бәдер сугышында дошманыгыз башына)* ике кат бәла китердегез, *(Ухуд сугышында)* үзегезгә кайгы килгәч, сез:

—Бу кайгы кайдан *(ни өчен)* килде?—дидегез. Әйт син:

—Ул кайгы үзегездән,—диген. Шөбһәсез ки, Аллаһның кодрәте һәрнәрсәгә житә.

*«Мөселманнар Бәдер сугышында җитмеш мөшрикне үтерделәр, җитмешен әсир иттеләр. Ухуд сугышында исә мөшрикләр җитмеш мөселманны үтерде. Бу бәла сугышчыларның Аллаһ күндергән пәйгамбәр боерыгына буйсынмаганнары өчен җибәрелде».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**166.** Ике гаскәр кара-каршы сугышканда сезгә килгән кайгы *(җиңелүегез)* Аллаһ ихтыяры белән булды. Чын мөэминнәрнең кем икәнен ачыклар өчен. **(167)** Һәм монафикъларның чын йөзен ачу өчен иде. Аларга:

—Килегез, Аллаһ юлында орышыгыз яки үзегезне коткару ягын карагыз,—диелде. Алар:

—Сугыша белсәк, сезгә ияргән булыр идек тә,—диделәр. Алар ул көнне иманлы

булуга караганда, көферлеккә якынрак тора иде. Күнелләрендә булмаганны алар авызлары белән сөйләп тордылар. Хәлбуки, Аллаһ аларнын күнелендәге яшерен уйларын белеп тора. **(168)** Үзләре сугышка бармыйча, сугышка киткән туганнары турында:

—Безнең сүзне тоткан булсалар, үтерелмәгән булырлар иде,—дип сөйләүчеләргә әйт:

—Әгәр дә сез, чыннан да, хаклы икәнсез, алайса, үзегезгә килә торган үлемне дә кире борыгыз, кулыгыздан килсә,—диген. **(169)** Аллаһ юлында һәлак булганнарны *(шәһидләрне)* син үлгәнгә хисаплама. Киресенчә, алар тередер һәм Раббы янында ризыклыдыр. **(170)** Аллаһ рәхмәте илә бирелгән нигъмәтләр өчен куанып, алардан соң да киләчәк шәһидләр хакында:

—Аларга һичбер куркыныч булмас, аларга кайгы-җәза да булмаячак,—дип кавышудан алдан ук хисләнеп, сөенәләр. **(171)** Алар Аллаһтан килгән нигъмәтләргә вә аның юмартлыгына сөенәләр. Иман китереп, изге гамәлләр кылганнарга тиячәк әҗерне Аллаһ җуймас. **(172)** *(Ухуд сугышында)* җәрәхәтләнгәннән соң Аллаһның вә Пәйгамбәрнең өндәвен кабул итеп, игелек кылганнар, тәкъва диндар булганнар өчен бик олы әҗер булачак.

**173.** Бер төркем кешеләр мөэминнәргә:

—Дошманнарыгыз сезгә каршы гаскәр туплады, берүк сак булыгыз,—дип әйткәч, мөэминнәрнең иманы тагын да арта төште, алар әйтте:

—Аллаһның ярдәме безгә җитәр Ул яхшы *(ярдәмче)* вәкилдер.

*«Риваятьләргә күрә, Ухуд сугышында кяферләр башлыгы Әбү Суфиян сугыш кырын ташлап киткәндә хәзрәти Мөхәммәдкә: ий, Мөхәммәд! Киләсе ел Бәдер мәйданында синең белән кабат очрашачакбыз!—диде. Мөхәммәд Пәйгамбәр дә: иншаллаһ!—диде. Икенче елны Әбү Суфиян сугышка бик хәтәр әзерләнә. Бу турыда Мәдинәгә хәбәр килеп ирешә. Мөхәммәд пәйгамбәр атлы гаскәр белән дошман каршысына чыга. Бу аять мөселманнарның дошманнар тарафыннан салынган коткыга бирелмичә, каушамыйча дошманны каршы алырдай рухи көчкә ия булганнары турында»*.

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**174.** Шулай итеп, алар үзләренә һичбер зыян китермәенчә, Аллаһның юмартлыгы биргән нигъмәтләрне төяп кайтты. Алар Аллаһның ризалыгына лаек булды. Аллаһ—миһербан вә юмартлык иясеదер.

*«Хәзрәти Пәйгамбәр җитәкчелегендәге гаскәр Әбү Суфиян белән бер ел әүвәл сөйләшкән урында бер атна чамасы дошманын көтә, Әбү Суфиян куркып, чигенгәч, мөселманнар үзара сату-алу оештырып, Мәдинәгә мал төяп кайта»*.

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**175.** Чынлыкта исә, мөселманнарны *(кяфер гаскәре килә, дип)* үз дуслары белән куркытучы шайтандыр. Иманлы булсагыз, алардан курыкмагыз, бары тик Минем җәзамнан гына куркыгыз.

*«Мәккә мөшрикләре Мәдинәдәге мөселманнар арасында коткы-курку таратыр өчен, Нуаем исемле кешене җасус итеп җибәрә»*.

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**176.** Көферлектә ашкынып ярышучыларга карап, син хафаланма. Алар Аллаһка һичбер зарар китерә алмас. Ахирәт көнендә Аллаһ аларга яхшы өлеш чыгармас. Аларга бик тә хәтәр җәза әзерләнгән.

**177.** Шунысы хактыр ки, иманын ташлап, кяфер булганнар Аллаһка һичбер зарар кыла алмас. Алар өчен хәтәр газап әзерләнгән.

**178.** Көфер иткәннәр *(җәзалары кичектерелгәнгә күрә)* үзләре өчен хәерле, дип ялгышмасыннар. Гөнаһларын арттыра төшсен дип, Аллаһ аларга форсат бирә. Аларга хәтәр газап бар.

**179.** *(Ий, монафикълар!)* Яхшыны яманнан аермыйча, Аллаһ мөэминнәрне сез яши торган хәлдә калдырмас. Соңрак нәҗесне пакьтән аерачак. Аллаһ сезгә күз күрмәс яшерен серләрне дә бәян итмәс. Ләкин Аллаһ пәйгамбәрләрне үзе теләгән кешеләр арасыннан сайлап ала. Аллаһка вә аның рәсүлләренә иман китерегез. Иман

китерсәгез, *(тәкъва диндар булсагыз)* сезнең өчен галәмәт олы әҗер әзерләнгән.

*«Тәфсирләрдә бу аятьнең ни сәбәпле иңдерелгәне турында болай язалар. Кяферләр: Ий, Мөхәммәд! Син безгә кемнәрнең иман китергәнен, кемнәрнең иман китермәгәнлекләрен әйт, дигәннәренә җавап итеп, Аллаһ шушы аятьне иңдергән».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**180.** Аллаһтан нигъмәтләр алып та, саран булган кешеләр: саранлыгыбыз үз файдабызга, дип уйламасыннар, киресенчә, бу *(саранлык)* алар өчен бик тә начар булып чыгачак. Саранлыкларына күрә, җыелган маллары Кыямәт көнендә аларның муеннарына чорналачактыр. Күкләрнең, Җирнең мирасы—Аллаһныкыдыр. Аллаһ сез кылганнардан хәбәрдардыр. **(181)** Чындыр ки, аларның:

—Аллаһ—фәкыйрь, без—бай,—дигән сүзләрен Аллаһ ишетте.

Без алар әйткәнне дә язып куярбыз һәм аларның хаксызга пәйгамбәрләрне үтергәннәрен дә теркәрбез вә әйтәчәкбез ки:

—Татыгыз шул утта яну газабын! **(182)** Бу *(утта яну)* дөньяда чакта үз кулларыгыз белән кылганнарыгыз *(гөнаһларыгыз)* өчен түләүдер. Аллаһ *(урынсызга)* колларын рәнҗетмәс. **(183)**

—Дөресе шул, Күктән иңгән ут көйдереп, күмергә әйләндерердәй бер Корбан алып килмәсә, Аллаһ безгә һичбер пәйгамбәргә ышанмаска боерды,—дигән *(кяферләргә)* болай әйт:

—Сезгә миннән алда могҗизалар һәм сез теләгәннәр белән бергә ничә пәйгамбәр килде. Әгәр дә сез хак адәмнәр икәнсез, ни өчен аларны үтердегез?—диген.

*(Кяферләр Мөхәммәд пәйгамбәрне үз йолаларын үтәргә өнди. Ягъни, әгәр Мөхәммәд пәйгамбәр кяферләргә корбан китереп, кяферләр ул корбанны чалып, утта яндырып, уйдырма илаһларына гыйбадәт кылачак һәм шуннан соң алар Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә иман китерәчәк, имеш.)*

**184.** *(Рәсүлем!)* Әгәр дә сине ялганчыга чыгарсалар, *(хафаланма)* чынлыкта, синнән элек ап-ачык могҗизалар, сәхифәләр вә сезнең күңел күзегезне ача торган китап китергән ничә пәйгамбәрләрне дә алар ялганчыга санадылар.

**185.** Һәр җан иясе үлемне татыячак. Кыямәт көнендә *(дөньяда)* кылганнарыгызга таман итеп әҗер биреләчәк. Кемдер җәһәннәмнән еракка җибәрелеп, җәннәткә барып урнашса, ул чынлап та морадына ирешкән булыр. Бу дөньядагы тормыш исә алдавыч җим генә.

**186.** Хакыйкатән, малларыгыз вә җаннарыгыз аркасында сез сынауга дучар, сездән элек килгән Китаплы кавемнән вә потпәрәстләрдән сез байтак кына рәнҗетүле сүзләр дә ишетерсез. Әгәр шуларга сабыр итәр булсагыз, тәкъва диндар булсагыз, хактыр ки, иң гүзәл гамәл шул булыр.

*(**Пот**—сын, һәйкәл; потпәрәст—шул сынга, шул потка тәңре итеп табынучы.)*

**187.** Аллаһ Китаплы кавемне:

—Аны *(Китапны)* инсаннарга аңлатып бирәчәкбез, аны кешеләрдән яшереп тотмаячакбыз,—дип ант иттерде.

*(Алар исә бу антларын тотмадылар.)* Аны дөнья малына саттылар. *(Китапны арка якка томырдылар.)* Аларның бу алыш-бирешләре никадәр яман гамәлдер. **(188)** Кылганнарына шатланучы, кылмаганнары өчен дә макталырга теләүчеләр газаптан котылдык, дип ялгышмасыннар, син дә *(аларны газаптан котылды дип)* уйлама. Алар өчен хәтәр җәза бар. **(189)** Күкләрнең вә Җирнең хөкемдары Аллаһтыр. Аллаһның кодрәте һәрнәрсәгә житә. **(190)** Күкләрнең вә Җирнең яралтылышында, төн белән көннең чиратлашуында акылы сәламәт кеше өчен, чынлап та, гыйбрәт бирүче дәлилләр бар.

**191.** Алар *(мөселманнар)* аягөсте торып та, утырып та, янга яткан килеш тә Аллаһны зикер итәләр, күкләрнең вә Җирнең яралтылышы хакында тирән фикерлиләр, *(һәм әйтәләр)*:

—Раббыбыз! Син боларны тикмәгә генә яралтмадың. Сине тәсбих итәбез *(мактыйбыз, Син барча кимчелекләрдән пакьсең).* Безне җәһәннәм газабыннан коткар! **(192)** Йа, Раббыбыз! Дөрестер ки, Син җәһәннәмгә керткән кеше рисвай була.

Гаделсез кешеләрнең ярдәмчесе булмас. **(193)** Йа, Раббыбыз! Дөрестер ки, без:

—Раббыгызга инаныгыз!—дип иманга өндәүчене (*Пәйгамбәрне, Коръәнне)* ишеттек һәм шундук иман китердек. Инде безнең гөнаһларыбызны кичер, яманлыкларыбызны ярлыка, җаныбызны игелекләләр хисабыннан ал, йа, Раббыбыз. **(194)** Раббыбыз! Безгә пәйгамбәрләрең аша вәгъдә иткән җәннәтне бир. Кыямәт көнендә безне хурлыкка калдырма *(рәхмәтеңнән ташлама)*, шик юк ки, Син сүзеңдә торырсын.

**195.** Шулай итеп, Аллаһ аларның догаларын кабул итте. *(Һәм әйтте):*

—Ирләрдән булсын, булсын хатыннардан, мин алар кылган гамәлне юкка чыгармаячакмын. Сез бер-берегездән хасил. Сез бер-берегезгә мохтаҗ. Алар һиҗрәт иттеләр *(ватаннарыннан көчеп китәргә мәҗбүр булдылар)*, йортларыннан куылдылар, Минем юлымда җәфалар күрделәр, орыштылар, үтерелделәр, хактыр ки, Мин дә аларның гөнаһларын юармын вә аларны бакчаларында чишмәләр агып торган җәннәткә кертәчәкмен. Бу бүләк Аллаһ тарафыннандыр. Нигъмәтләрнең ин күркәмнәре Аллаһ хозурындадыр.

**196.** *(Аллаһны, Коръәнне, Пәйгамбәрне танымаучы инкарьчылар, ягъни)* кяферләрнең ил буйлап йөргәннәре *(сәүдә белән баеганнары)* сине кызыктырмасын. **(197)** Аз файдадыр *(ягъни ул вакытлыча гына байлыктыр)*, соңыннан аларның барачак җире—җәһәннәмдер. Ул котчыккыч хәтәр урын.

*«Кайберәүләр: күрдегезме, Аллаһның дошманнары байлык-муллык эчендә яши, ә без, Аллаһның мөселманнары, фәкыйрьлектә яшибез, дип зарлангач, шушы аятьләр иңгән».*

Ибраһим Дөнмәз тәфсиреннән.

**198.** Әмма Раббыдан *(гөнаһлы булудан)* курыкканнар өчен Аллаһ тарафыннан әҗер буларак, бакчаларында чишмәләр агып яткан мәңгелек җәннәтләр корылган, алар анда—мәңгелектә калачак. Алар өчен Аллаһ хозурындагы нигъмәтләр тагын да сыйфатлырактыр.

**199.** Китаплы халык арасында шундый кешеләр дә бардыр ки, Аллаһка, сезгә иңдерелгән *(Коръәнгә)* һәм дә үзләренә иңдерелгәнгә самимилек белән ышанып, Аллаһка буйсынып, иман китергәннәр бар, әлбәттә. Андыйлар Аллаһның аятьләрен дөнья малына сатмаслар. Менә шундыйлар өчен Раббы катында әҗерләр бар. Шөбһәсез ки, Аллаһ исәп-хисапны тиз тотар.

**200.** Ий, иман китергәннәр! Сабыр итегез, *(дошман каршысында)* чыдам булыгыз, *(Җиһад өчен)* хәзерлекле вә уяу булыгыз һәм Аллаһ каршысында *(гөнаһ эшләүдән)* куркыгыз, уңышка ирешерсез.

آمين. الله اكبر

## Авторлар игътибарына

***Кульязма җибәргәндә түбәндәге мәгълуматлар булу мәҗбүри:***

1. Фамилиягез, исемегез, әтиегезнең исеме
2. Яшәү урыныгыз
3. Туган ел, ай, көнегез
4. Паспорт мәгълүматларыгыз
5. Дәүләт пенсия страховкасының страховка таныклыгы номеры
6. Телефоныгыз *(шәһәр кодын да күрсәтеп)*.

*Сәнгать*

# ЗУР ИҖАТ БАЛКЫШЛАРЫ

КОМПОЗИТОР АЛМАЗ МОНАСЫЙПОВКА 75 ЯШЬ

Татарстан радиосының җырлар язу студиясендә чираттагы эш көне башлана. Радио һәм телевидениенең Рөстәм Үтәй җитәкчелегендәге оркестры музыкантлары урындыкларга җайлашып утыралар да уен коралларын көйли башлыйлар. Тавыш операторы микрофоннар җайлап куя, пианиночы Юран Шәмсетдинов исә эшкә дәрт-дәрман, көч биреп тора. Оркестр Алмаз Монасыйпов җырларын язарга җыена. Бүген автор үзе дирижерлык итә. Уйнап караганнан соң, тынлы уен кораллары яңгырашы аерым язып алына, аннары кыллыларныкы. Композитор бәрмә коралларга күп вакыт бирә, уйнап карый, кулына маракасларны ала.



Дирижерлык иткәндә, Алмаз Закир улы гадәттәгедән башкачарак халәткә күчә: кулына таякчык тоткан, өстенә концерт фрагы кигән бу останың йөзе бик җитди, хәтта бераз сагышлы да сыман. Ә ул үзе коллегасының чираттагы мәзәгенә елмаеп та ала, көлкеле искәрмәләр дә ясый. Музыкантлар еш тукталып торалар, аерым кисәкләрне яңадан уйнап карыйлар. Вакыт тиз уза.

Җырчылар белән эшләү өчен Алмаз ага радиокомитетның тәрәзәләре Горький урамына карап торган күрше бинасына чыга. Урамда яңгыр ява, машиналар, кул чыбылдыгы тоткан кешеләр узып тора. Берсе туктап кала: тәрәзәдән Зөһрә Сәхәбиева үрелеп карый, аннары бераздан ул монда килеп керәчәк. Ә бүлмәдә музыка хакимлек итә. Автор рояльдә һаман илһамланыбрак уйный, Лидия Әхмәтованың гүзәл тавышы көйне үзенең иң югары ноктасына китереп җиткерә...

Менә инде дүрт дистә ел буена эстрададан татар композиторы Алмаз Монасыйпов әсәрләре яңгырый. Бу вакыт эчендә башкаручыларның инде берничә буыны үзе өчен аның музыкасының искиткеч бай һәм катлаулы дөньясын ачты, тыңлаучыларның рәхмәтле берничә буыны төрле жанрларда нәтиҗәле эшләүче останың иҗади үсешенә шатлана. Аның музыкасын шунда ук танып аласың, ул шулкадәр гадәти түгел булып тоела ки, каләмдәш дусларында даими рәвештә бәхәс тудырып тора. Анда нинди генә йогынтыны күрми алар! Урта Азия, Кавказ, якын һәм ерак чит илләр халыкларының музыка мәдәнияты аһәңнәре... Әледән-әле әйтеп куялар: «Монда нәрсәдер көнчыгышныкы бар,—аннары, көнчыгышның конкрет кайсы йогынтысына өстенлек бирергә белмичә, ышанычсыз гына өстәп куялар: ихтимал, үзбәкнекедер...» Менә шулай: әзәрбайҗанныкы, төрекнеке, әрмәннеке дип тә әйтергә мөмкин.

Мондыйрак бәяләмәне моннан егерме еллар чамасы элек ишетергә туры килә иде, хәзер дә ишетәсең, өстәвенә болай дип авыл мәктәбе укучы кызы да, инде танылган җырчы да шулай әйтә алыр иде.

Нинди дер гадәти булмаган аһәнне ишетеп аласың икән, бер үк вакытта яңгыраучы күп традицион билгеләрне еш кына игътибарга да алмый каласың. Милли стиль турындагы стереотип төшенчәләр дә үзләрен сиздерә. Казанлылар нигездә радио һәм телевидение аша композиторларның Казан татарлары музыкасын, иҗади фикерләү нәтиҗәләрен күрәләр. Ә бит татарлар кайда гына яшәми! Әйтик, бу якта теге төбәктәге кебек җырламыйлар. Аннары халык авыз иҗатындагы тарихи катламнар да бер-берсеннән нык аерылып тора. 1972 елда Композиторлар берлегендә Ульяновск татар-мишәрләренең фольклор экспедициясе алып кайткан халык җырларын тыңлаткач, музыка белгечләре һәм композиторларның аларга мөнәсәбәте бердәй булды: болар бит бик үк татарча яңгырамый. Шул ук елны нота кибетләре шүрлекләрендә Мәхмүт Нигъмәтҗановның яна җыентыгы пәйда булды, анда беренче тапкыр мишәрләрнең, керәшен татарларының «татарча булмаган» җырларыннан бөтен бер тупланма нәшер ителде. Шуңа күрә композиторның стиле формалашуга нинди дә булса мәдәниятларның йогынтысы турында сөйләү мәҗбүри түгел.

...Аның балачагы Казанда узган, шуңа күрә музыка ташкыны да шактый мул булган. Сәнгать әһеле тыңлап, күзәтеп карарга, каләмен сынау өчен нәрсәнедер сайлап алырга хаклы. Әмма халык җыры иң төп чыганак саналды һәм шулай булып кала да. Алмаз Монасыйповның нәсел тамырлары да җирле туфракта—алар Татарстан төбәкләреннән.



*Алмаз Монасыйповның әтисе—Закир Монасыйпов, әнисе—Фатыйма Шәрәф. 1924 ел.*

Композиторның бабасы хәзерге Биектау районының Әйшә авылыннан. Җәмилә исемле кыз белән өйләнешкәч, алар Казанга күчеп киләләр һәм үзләренә өй төзи башлыйлар. Гайнетдин агай бер унайдан хәзерге Шәриф Камал урамында кечкенә генә типография оештырып, анда китаплар, календарьлар бастыра, китаплар тышлау белән шөгыльләнә. Типография эшләре белән төрле шәһәрләрдә йөргәндә, 1912 елда, ул чума авыруы эләктерә һәм кырык яше дә тулар-тулмастан сәфәрендә үлеп китә. Гаиләдә биш бала ятим кала, шуларның иң өлкәне композиторның әтисе—Закир була.

Шул еллардагы кино геройларына охшаган көләч һәм чибәр бу кеше Салих Сәйдәшевнең театр оркестрында скрипкада уйнаган, аннары Татарстан китап нәшриятында эшләгән. 1934 елда кулга алынган, ун ел буена Себер лагерьларында җәфа чиккән. Гомеренең соңгы тугыз елын Казанда гаиләсендә уздырган.

Композиторның әнисе Фатыйма Шәрәф кызы Шәрәф—мәгълүм китап нәширләре гаиләсеннән. Бертуган Шәрәфләрнең типографиясе безнең гасыр башында иң алдынгы татар полиграфия предприятиеләреннән берсе була, дөньяга ул традицион әдәбиятны гына түгел, ә замандашларының—Г. Тукай, М.Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Камал һәм башка гүзәл әдәбиятчыларның да әсәрләрен бастырып чыгара.

Бу гүзәл гаиләнең тамырлары, хәзерге Буа районындагы Аксу авылына барып тоташа—узган гасырның 60 елларында анда крәстиян Хөснетдин яши. Өйгә яшь хатын китергәч, аның олы улы, унтугыз яшьлек Шәрәф Самарага китә,

анда сәүдәгәр кибетендә башта йомышчы малай, аннары приказчик булып эшли. Берничә елдан сон туган авылына өйләнеп кайтып, йорт сала, өйләнеп җибәрә, авыл хуҗалыгы белән мавыгып китә, хәтта «Кишер Аксуы» дигән китап та яза башлый. Шәрәфетдин Хөснетдин улы һәм аның хатыны Гайнетдин гаиләсендә биш ул һәм биш кыз үсә: Шиһаб, Шәһәр, Зифа, Борһан, Гыйльми, Сара, Һаҗәр, Галимҗан, Халисә һәм Фатыйма. Өйгә даими рәвештә газитә-журналлар яздырып алып торалар. Әниләре балаларына шигырьләр укый, әкиятләр сөйли, бәет һәм мөнәҗәтләр җырлый, ул курайда да уйный белә. Шул заманнарда гадәткә кергәнчә, балаларның барысы да үз авылларында башлангыч белем ала. Аннары уллары укуларын Казандагы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә дәвам итәләр.

Укуны тәмамлаганнан сон, ир туганнардан өлкәне Шиһаб туган авылына кайта, сәүдә белән шөгыльләнә башлый, аннары мулла була. Шәһәр укыган урынында ук укытып кала, Мәрҗани турында китап яза. Борһан Ырынбурда революцион хәрәкәттә актив катнаша, очерклар, мәкаләләр, китаплар яза. 1906 елда Гыйльми, Шәһәр һәм Борһан «Шәрәф матбагасы» типографиясен ачалар, аның эшендә төп рольне оештыру сәләтенә, бетмәс-төкәнмәс энергияле, белемле һәм тәҗрибәле Гыйльметдин Шәрәфетдин уйный. Ул чагында ана нибары 21 генә яшь булса да, аның инде эш тәҗрибәсе шактый тупланган була, китап бастыру эшен яхшы белә, чөнки ул хәреф җыю эшенә Петербургта, ул чагында Россиядәге иң яхшы көнчыгыш типографиясендә—Ильяс Борһанский типографиясендә өйрәнә, аннары Ырынбурда Фатих Кәрими кул астында хәреф җыючы һәм корректор булып эшли.

Типография 1 ноябрьдә «Болгар» кунакханәсе бүлмәләрендә ачыла. 1906 елның көзеннән 1912 елның декабренә хәтле анда Габдулла Тукай яшәгән (хәзер бу Киров һәм Татарстан урамнары чатындагы ярымҗимерек йорт). 1908 ел ахырында типографияне бикләп алалар. Типографиянен кулга алынуына юл куймас өчен, Гыйльметдин Шәрәф аны сату турында ялган килешү ясый. Яна хуҗа фамилиясе буенча башта ул Саинов типографиясе дип атала, аннары «Үрнәк» дип йөртелә башлый. Жандарм агентлары тиз арада Г. Саиновнын ялган хуҗа булуын, типографиянен чын хуҗасы булып Гыйльметдин Шәрәф калуын билгелиләр. В. Е. Казаков чираттагы хуҗа булып әверелә. 1913 елда «Мәгариф» типографиясе ачыла, ул «Шәрәф типографиясе»нен дәвамы була.

1917 елга кадәр Гыйльметдин Шәрәф Казан губерна «Милли Шурасы» составында, аннары икътисадчы, банк идарәчесе урынбасары булып эшли. Аны 1927 елда, валюта сатып алуда гаепләп, кулга алалар. 1942 елнын 5 гыйнварында, бераз вакыт пеллагра белән авырып, Краслагнын беренче лагерь пунктында Красноярскида үлә.

Гыйльметдиннен кулга алынуы аның ир туганнарын вакыйгалар барышын ничектер үзгәртергә тырышып карарга мәҗбүр итә. Борһан Ташкентка китеп бара, ләкин тиздән ул да кулга алына. Шәһәр Уфага күченеп килә, анда җирле мөфтият мөхтәсибе һәм китапханәче булып эшли. Мөфти Риза Фәхретдин вафат булганнан сон, 1936 елда Шәһәр кулга алына һәм тиздән Эчке Россия, Себер, Казакъстан мөселманнары Дини идарәсе эше буенча атып үтерелә. Шиһаб исә, авылда яшәп, типографияне оештыруда катнашмаса да, туганнарынын язмышын уртаклаша: 30 нчы елларда аны кулак дигән сылтау белән сөрәләр, 1939 елда ул тоткынлыкта үлә.

Алмаз Закир улы үзенен гаиләсе турында һәрвакыт аз сөйли иде. Бәлки, беркем дә сорашмагангадыр, бәлки вакыты килеп җитмәгәнгәдер. Шәрәфләр турындагы беренче язма, фоторәсем белән, 1989 елда «Азат хатын» журналынын 4 санында дөнья күрә. Бер битнен яртысын алып торган кечкенә күләмле фоторәсемдә 37 кешедән торган бөтен гаилә диярлек урын алган: анда Зифа белән Сара гына юк.

Зурайткыч пыяладан карасан, һәркайсын аерырга мөмкин.

Фоторәсемнен уртасында—әниләре Гайнелнәвәл (ул чагында әтиләре исән булмый инде). Анын тирәсендә уллары—хатыннары белән, кызлары—ирләре белән бергә басканнар. Икенче рәттә сул яктан кырыйда унсигез яшьлек Фатыйма Шәрәф басып тора. Рәсем 1923 елда алынган, бер елдан ул кияүгә чыгар, ә 1925 елнын 11 июлендә беренче балалары Алмаз дөньяга килер. Рәсемнен аскы

өлешендә бала-чагалар. Төркемнен үзәгендә Халисә кызы ике яшьлек Энже Сәгыйтова утыра—булачак библиограф, педагогия фәннәре кандидаты. Ул М.Е. Салтыков-Щедрин исемендәге Дәүләт халык китапханәсендә милли әдәбият бүлегенә житәкчелек итә, анын фондларында исә Габдулла Тукайнын үзе исән чагында ук Шәрәфләр типографиясендә басылган әсәрләре саклана. Энжедән ун якта объективка житди итеп Гыйльметдиннен сигез яшьлек кызы Шәфика—булачак физика-математика фәннәре докторы, Петербург университеты профессоры карап тора. Еллар узар, ул кечкенә бер планетаны ачар да аны халыкара каталогта «Шәрәф» исеме белән теркәр. Әнисе Һажәрнен тезләрендә Җәвад Тәржеманов үзе утыра—ул язучы һәм публицист булып танылачак әле....



Болар барысы да—композиторнын туганнан туган кыз һәм ир туганнары. Фоторәсемне игътибар белән караганда ин көчле тәэсир итә торган беренче нәрсә шуллыр: басып торганнардан берсе тышкы кыяфәте белән Алмаз Закир улына искиткеч охшаган—шундый ук бөдрә чәч, мангай рәвеше. Әгәр дә аны күзлек кигән һәм елмайган кыяфәттә күз алдына китерсән, нәкъ бер йөз инде менә. Ул—бертуган ир Шәрәфләрнен кечесе Галимжан Шәрәф, Татарстан милли дәүләт төзелешенә генә түгел, тарих, этнография һәм филологиянен күп мәсьәләләрен эшкәртүгә зур өлеш керткән күренекле татар галиме һәм жәмәгать эшлеклесе. Олы ир туганнары кебек үк, «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен, аннары Казан икенче реаль училищесын тәмамлап, ул Петербург тимер юл инженерлары институтына укырга керә, бер үк вакытта профессорлар һәм академикларнын—университетнын Көнчыгыш телләре белгечләре Бартольд, Крачковский һәм башка галимнәрнен лекцияләренә йөри.

1917 елнын кышында Галимжан Шәрәф Эчке Россия һәм Себер мөселманнарынын Милли жыелышын—«Милли мәжлес»не үткәрүгә эшлекле төстә катнаша. Корылтайда игълан ителгән бәйсез «Идел-Урал штаты» Совет хакимиятен таныса да, милли мәсьәләдәге күп кенә эшләрдә большевиклар сәясәтен якламый. Шуна күрә чынлыкта корылтайнын барча делегатлары да «буржуаз милләтчеләр» дип карала һәм, ахырда, алар эзәрлекләүгә дучар була.

1937 елнын март аенда Эчке эшләр халык комиссариатындагы аерым кинәшмә Галимжан Шәрәфне сигез елга иреге нән мәхрүм итүгә хөкем итә, ул аны Төньяк тимер юл лагерында уздыра. 1945 елда азат ителгәннән сон, ана Казанда яшәү һәм эшләү тыела һәм аны Апастагы мәктәпкә татар теле һәм әдәбияты укытырга жибәрәләр. Әмма сонрак, сәламәтлеге какшау сәбәпле, ул аерым карар белән эшеннән азат ителә һәм сонгы биш елын эшсезлеккә дучар ителгән хәлендә гаиләсе белән яшәп уздыра.

Берничә ел Казан дәүләт университетында Галимжан Шәрәфнең 100 еллыгына багышланган конференция уздырылды. Фойеда фотосурәтләр күргәзмәсен күрсәттеләр, кунак-туганнар белән очрашу оештырылды. Университет укытучылары белән беррәттән, конференциягә студентлар да катнашты. Алар оештыру эшләренә дә булышты. Алмаз Закир улы бу уңайдан Мәскәүдән Казанга килде, үзенең туганнары белән очрашуга ул бик шат булды. Килгән кунакларны студентлар теркәп утыра торган өстәлдә конференция программалары өеме ята, аларны исемлек буенча бирәләр дәнә өләшәләр. Исемлектә Алмаз Монасыйпов исеме юк булып чыкты.

«Мин аның бертуганының улы»—диде Алмаз Закирович горурлык белән. Бер студент аңа гамьсез генә карап куйды да монда инде аңдыйларның күп булганлыгын әйтте. Чыннан да күп: туганнар, туганнан туганнарның балалары, Галимжанның улы Арслан... Шуларның ин атаклыларын президиумга чакырып алдылар, башкалары залда калды. Аларның барысын да гаилә охшашлыгы билгеләре, хәтта кайсысының кем нәселеннән булуын да чамаларга мөмкин иде. Президиумда утыручы Альмира Әсхәт кызы Әминова (ул филология фәннәре докторы, Казан университеты доценты) үзенең бабасы Борһанга бик охшаган. Аның янәшәсенә утырган Сания Шәһәр кызы Шәрәф-Акжитова Шәрәфләр турында доклад ясады һәм музейга фотографияләр ябыштырылган, гаиләнең һәр тармагы тасвирланган берничә кульязма альбом бүләк итеп тапшырды.

Конференция тәмамлангач, анда катнашучыларның барысы да Жуковский урамындагы Галимжан яшәгән 15 йортка киттеләр. Ерак түгел—урамның шул ягында ук ул яшәгән 7 йорт тора. Композиторның балачагы һәм яшьлеге шунда узган. Икенче каттагы өч тәрәзә ишегалдына балкон белән һәм тагын өч тәрәзә—урамга, туп-туры музыка училищесы бинасына карый. Мөгаен, мәгънәле хәлдер бу: бу мохитта иртәдән кичкә кадәр музыка яңгырый; төрле уен кораллары, җырчыларның тавышлары ишетелеп торган бина белән янәшәдә яшәү үзенә күрә бер мәгънәле хозурлыктыр. Ленинградка күчеп киткәнче, музыка училищесы белән янәшәдәге 8 йортта Халисә Шәрәф-Сәгыйтова гаиләсе яшәгән. Фатыйма Шәрәф кызы тәрәзәләреннән Халисәнең өченче каттагы бүлмәләренең тәрәзәләре күренеп торган. Көн саен менә-менә кулга алырга килерләр, дигән шик-шөбһәдә яшәгән кешеләр бу куркыныч Сталин эзәрлекләве елларында шушы фатирның тәрәзә төбенә янып торган өстәл уты куя торган булганнар: янәсе, хәзергә тыныч әле...

Библиографик мәгълүматларга караганда, 1906 елдан 1913 елга кадәр бертуган Шәрәфләр типографиясендә 348 исемдәге 2 миллион нөсхә китап нәшер ителгән. Болар—татар шигырьләре прозасы, рус һәм чит ил классикларыннан тәрҗемәләр, дәреслекләр, авыл хуҗалыгына кагылышлы китаплар, календарьлар, медицина турындагы брошюралар, фәнни-популяр басмалар, рус, фарсы телләрен үзлегеннән өйрәнү кулланмалары, халык авыз иҗаты юнәлешендәге җыентыклар—җыр китаплары, әкиятләр, әйтемнәр һәм урта гасырның халык аеруча яратып файдалана торган әсәрләре.

Халык китапка һәрвакыт изгеләштереп караган, аны ихтирам, кадер-хөрмәт иткән, сүзнең хакыйкатенә ышанган. Китаплар төрле булган: иясенең үз рәсемнәре белән бизәлгән кульязма китаплар, басма китаплар, бөтенләй юка һәм күләмле зур китаплар. Шуларның кайберләре безгә гасырлар тирәнлегеннән килеп җиткән: билгесез иясенең дидактик рәвештәге «Бәдәвам» китабы башлангыч сыйныфларда уку дәреслеге сыйфатында файдаланылган, Кол Галинең «Йосыф кыйссасы» дигән лирик поэмасы, Чәләбинең Мөхәммәт пәйгамбәр тормышы турындагы «Мөхәммәдия» фәлсәфи хикәяте...

Ул чорларда халык арасында фәлсәфи лирика жанры—мөнәҗәтләр аеруча киң таралган булган, аларда узган гасырның билгеле иясенең дә, исемнәре танылмаганнарының да шигырьләре һәм поэмалары шигъри нигез булып хезмәт итә. Бәетләр—халык яки аерым бер адәми зат тормышындагы мөһим вакыйгалар турындагы җыр-хикәятләр үз итеп файдаланыла. Танылган лирик җырлар белән бергә, бәет һәм мөнәҗәтләр: «Менә сезгә яхшы җырлар», «Төрле кызыклы җырлар», «Ял итү өчен яхшы җырлар» дигән атамалар белән күләме һәм микъдары кечерәк китапчыклар рәвешендә бастырып чыгарылганнар.

Узган гасырның икенче яртысында татарча китаплар арзан кәгазьдә, кырны

киметү һәм текстта бүлекләрне бүлеп бирү исәбенә бит мәйданын мөмкин кадәр файдаланып, тышсыз нәшер ителгәннәр. Китаплар күп нөсхәдә чыгарылган. Кагыйдә буларак, аларның иясләренә каләм хакы түләнмәгән. Болар исә китапларның үзкыйммәтен киметкән, тыйнак кына бизәлгән басмаларны халык сатып алырлык иткән.

Һәр өйдә диярлек кечкенә китапханә булган. Чәчмә әсәрләрне кычкырып, шигырьләрне җырлап укыганнар. Балачактан ук инде мәктәпләрдә шигырьләрне җырлап өйрәнгәннәр, телдән сөйләү гадәтен буыннан-буынга тапшыра барганнар. Укырга-язарга барысы да өйрәнгән: кемдер моны яхшырак башкарган, ә гадәттә мондый кешегә кышкы озын кичләрдә кунакка килә торган булганнар, чәй эчкәннән соң, күз яшьләрен сөртә-сөртә тынлап утырганнар. Шигырьләрне җырлап уку гадәте халыкта шулкадәр таралган булган ки, шагыйрьләр, үзләренең әсәрләрен, нинди дә булса мәгълүм көйне күздә тотып, аларның җыр буларак яшәячәген күздә тотып иҗат иткәннәр. Шуннан яңа моң килеп чыккан, монсу җыр киң таралган.

Китаплардагы шигъри образларны аерым бер кешеләр китереп чыгарып, башкаручыларның җирле үзенчәлекләре булуга карамастан, ул җырларда уртак уй-фикер, моң-зар бар: бу бетмәс-төкәнмәс, иксез-чиксез рәвеш, сурәт, тасвирлау байлыгы. Мондый җырларны тыңлаган вакытта алар чын-чынлап әсир итә, күңелне били.

... Алмаз ага классик музыка мирасы белән үнбер яшеннән—беренче музыка мәктәбенә укырга кергәч, аннары музыка училищесында музыка белеме бирүне оештыручы, бик күп композиторларга һәм музыкантларга тормышка юллама биргән Рувим Львович Поляковның виолончель сыйныфына кергәч таныша башлый.

1943 елның гыйнварында училищеның өченче курсыннан Алмаз Закир улын Совет армиясенә алалар. Бәхеткә, ул алгы сызыкка эләкми. Аларның зенит артиллериясе часте Рига янында торган арада, сугыш тәмамлана. Поездга утырып өйгә кайтканда, ул нинди дә булса заводка эшкә керермен, дип уйлый. Ләкин башкача килеп чыга: ул чагында әле генә ачылган консерваториядә уку елы башлана һәм Алмаз аның беренче студентлары һәм Александр Владимирович Броунның виолончель сыйныфы буенча аны беренче булып тәмамлаучылар (икенче номерлы «кызыл» диплом) арасында булып чыга.

Тынычсыз еллар була бу. Мураделиның «Бөек дуслык» операсы турында ВКП(б) Үзәк Комитетының 1948 елгы карарыннан соң кайбер совет композиторларының, шул исәптән Дмитрий Шостаковичның иҗаты җимергеч тәнкыйтькә дучар ителгәч, илнең музыка уку йортларында, шул исәптән Казанда да, бу музыкантларның карашларын гаепләүче «митинг-протестлар» булып уза. Өченче курсның комсомол җитәкчесе буларак, Алмазны нотык сөйләргә дип мөнбәргә чыгаралар, әмма анардан таләп ителгән нәрсәне ишетә алмыйлар. Хәлнең нинди җитди булганлыгын ул күп еллар узгач кына белә: аны күңелсез нәтиҗәләрдән абруйлы педагогларның катнашуы гына коткарып калган икән.

Консерваторияне тәмамлагач, Алмаз Закир улы элек үзе укыган, радиога язып алуларда катнашкан музыка мәктәбендә виолончель сыйныфын алып бара. Шулай, бервакыт, алар ул чакта әле яшь композитор Әнвәр Бакировның виолончель һәм фортепиано өчен сонатинасын язып алу алдыннан күнегү ясап утыралар. Үз уен коралын яхшы белүче Алмаз авторга уен ысулларын, музыканың аһәңен арттыручы өстәмә эффектларын күрсәтә, аннары аның яңадан-яңа вариантларын ача-ача, көйне үзенчә үзгәртеп карарга тотына. Сонатинаны язып алалар. Әнвәр Бакиров аңа бер кинәш әйтеп куя: «Синең урыныңда мин үзем музыка язып карар идем». Һәм 1952 елда Алмаз Монасыйпов Альберт Леманның композиция сыйныфына яңадан консерваториягә укырга керә. Зур композитор, остаз һәм педагог була бу. Яшь авторның беренче әсәрләрен менә шушы елдан башлап санарга кирәк: скрипка һәм фортепиано өчен соната, романслар һәм җырлар—болар тизләп аның топ иҗат үзенчәлегенә әверелә.

1956 елда консерваторияне икенче тапкыр тәмамлагач, Алмаз Закир улы биредә камера ансамбле сыйныфын һәм музыка училищесында теоретик дәресләрне алып бара. Укучылар аның аккордлар өчен уйлап тапкан үзенчәлекле

образларын, кызыклы дәресләрен беркайчан да онытмаслар.

Уку елларында ул—совет джазынын үсеше тарихындагы легендар шәхес Олег Лундстрем белән таныша, бу елларда ул үзенен туганы Игорь һәм күп кенә башка «шанхайлы»лар белән консерваториягә укырга керә. Менә шул студент елларыннан бирле Олег Лундстрем белән Алмаз Монасыйповны ярты гасырлык диярлек дуслык җепләре бәйләп тора. 1956 елда Мәскәүдә Татар сәнгате һәм мәдәнияты декадасы алдыннан язылган эстрада-джаз миниатюралары язмалары—«Румба», Александр Ключаревнын «Яз җыры» дигән җыр темасына «Фантазия»се, Сара Садыйкованын «Танго»сы, Алмаз Монасыйповнын—«Хыяллар»ы татар радиосынын алтын фондына кереп калды. Алардан сонгысын язып алуда Алмаз әфәнде үзе катнашты, ул анда виолончельдә, ә Ключаревнын «Фантазия»сендә тамтамда уйнады.

1959 елдан алып ун ел дәвамында Алмаз Монасыйпов М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында дирижер булып эшләде, профессор Исай Эзравич Шерман сыйныфында опера-симфония дирижерлыгы белгечлеге буенча аспирантура тәмамлады. 1968 елдан башлап, ул консерваториядә композиция сыйныфын алып бара. Яна әсәрләр саны да арткannан-арта. Балет сюитасы, Беренче симфония, «Муса Җәлил» симфония-поэмасы...

Китаптан укунын борынгы речитатив көенә һәм нәфис ритмлы мөнәҗәтләргә мөрәҗәгать итү композитор өчен бик нәтиҗәле булып чыкты. Ләкин бу күренешнен икенче ягы да була. Ул чагында «мөнәҗәт» дигән сүзне күбәүләр әйтергә дә куркалар иде. Әле күптән түгел генә аларны магнитофонга язып алу өчен җырларга риза булган әбиләр үзләренен исем-фамилияләрен сорагач, хафага төшәләр иде бит.

Нәкъ шул вакытларда Рафаэль Мостафин Кол Галинен «Кыйссаи Йосыф»ын «Таҗлы бриллиант» дип атады. Ә бит аны җырлап уку ислам традицияләренә бәйле—ул тыела иде. Шуна күрә халык мәдәниятынын шушы катламын беренче булып файдалана башлаган композитор иҗаты—гражданлык батырлыгынын бер чагылышы ул. Ул чагында мондый «җинаятьчел» материал белән эшләргә батырчылык итмиләр иде әле. Әйе, аны беркем дә башкармаячагын, ә нәшриятнын кульъязмаларны кире кайтарачагын алдан белә торып, кемнен инде үз әсәрләрен күнелсез язмышка дучар итәсе килсен?

КПСС өлкә комитетынын сагаюлы мөнәсәбәте, Нәҗип Җиһанов белән катлаулы мөнәсәбәтләрдә булу Алмаз Монасыйповны Казаннан Мәскәүгә китү турындагы фикергә килергә мәҗбүр итә. Һәм 1972 елдан башлап, анын тормышы яртылаш бүленә: «монда» һәм «тегендә» булу вакытлары. Дуслары шаярталар: «Татарстан» поездына билет алырга вакыт җитте». Мәскәүдә 3 нче һәм 4 нче симфонияләр, «Тукай ритмнарында» дигән вокаль-симфоник поэма иҗат ителә. Анда аеруча тәэсирле бүлекләр «Туган җиргә», «Туган авыл» дип атала; фортепиано өчен музыка (пианист кызы үсеп җитә), оркестр белән скрипка өчен концертино-серенада (скрипкачы улы үсеп җитә). Балачак шәһәре, туганнар һәм дусларга бәйле сагыш йөрәкне һаман ныграк сызлата...

Ә ул вакытта Казанда консерватория эчендә ниндидер бер бушлык барлыкка килә: җыр кафедрасында анын җырларын һәм романсларын беркайчан да башкартмыйлар, пианистлар да аны уйнамый. Консерваториянен ярты гасыр яшәве чорында музыка теориясе белгечләре арасында нибары бер үрнәге—беренче симфония буенча диплом эше башкарыла. Бу ниндидер бер сихерле, һәлакәтле боҗрага охшап тора.

Сонгы берничә ел композитор өчен авыр була: ул озак авырый. Шунын аркасында, Казанга әүвәлгечә еш килә алмый. Эше дә элеккегечә ташып тормый. Анын хәл-әхвәле ниндидер сагыш һәм күнел төшенкелеге аркасында шактый начарая. Ул үзенен әсәрләре язмышы өчен борчыла. Вакыты белән ачынып әйтеп куя торган иде: «Җырларым алдында үз гаебемне тоям. Җырны һәрвакыт күзәтеп торырга кирәк, ә мин аны яздым да ташладым...»

Ул фәкать моннан ике ел элек кенә Казанга килә алды, «Аурупа-Азия» фестивале концертларын карады. Һәм, акрынлап, артистларнын күп сәгатьләргә сузылган ялыктыргыч чыгышларыннан сон сәнгатьтәш дуслары белән аралашунын

күнегелгән даирәсенә кайта башлады. Казанда булу өчен һәр мөмкинлектән файдаланып,—аның музыкасы башкарылган симфоник оркестр сезонын ачумы ул, консерваториянең 50 еллыгы уңаеннан юбилей тантанасымы—ул радиога язып алуны оештыру, җырчылар белән күнегүләр үткәрү һәм башка «рәхәт» мәшәкатьләргә кереп чумуына шатлана иде.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрында өченче ел инде Ю. Сафиуллинның Алмаз Монасыйпов музыкасы белән «Идегәй» спектакле бара. Телевидениедә бәйрәм концертлары программаларында бик яхшы аранжировка белән Дәүләт телерадио оркестры башкаруында аның җырлары ишетелә башлады. Узган ел ахырында Мәскәүдә татар милләтеннән «яңа руслар» Алмаз Закировичның авторлык кичәсен оештырдылар. Башкортстан җырчысы Идрис Газиев тенор өчен яңа дерäкциядә эшләгән фонограмма астында «Тукай ритмнарында» дигән поэманы башкарды. Клара Хәйретдинова, аның уйнавына кушылып, ул иҗат иткән романсларны җырлады. Оныгы Мартина Монасыйпова фортепиано музыкасын уйнады. Бирeдә композитор зур уңыш казанды, залда елап утырдылар. Санкт-Петербургтан килгән кунак ханым бу кичәне үзләрендә кабатлау теләген белдерде. Әйе, композиторны сонрак анда да җылы кабул иттеләр. Шундый озак җибәрми тордылар ки, ул Мәскәү поездына чак кына соңга калмады. Өенә кайту белән үк, икенче көнне иртән Галимҗан Шәрәфкә багышланган конференциягә өлгерү ниятендә «Татарстан» поездына җыена башлады.

Конференциядән соң—җырчылар белән яңадан күнегүләр, яңадан радиога язулар...

Дөрес, Алмаз Монасыйпов җырлары җиңелдән түгел. Бездә җырчылар күп, ә аның җырларын һәммәсе дә башкармый. Алар кызыксыз булудан түгел, ә бәлки моңа теләсә кемнең дә көче җитмәүдән. Аларны тыңлау бер нәрсә, ә менә өйрәнү... Ритм башка сыеп бетми, хикмәтле бизәк челтәрләренә яшеренеп, кой истә калмый.

Бөтенесен бергә җыйганнан соң тагын бер сынау алда тора—гади аккомпанементтан бигрәк, миниатюрадагы симфониягә охшаш фонограмма белән очрашу. Шуңа күрә җырчыларга җиңел түгел. Җырчылар арасыннан берәү сорап та куя:

—Алмаз Закирович, сез үз җырларыгызны үзегез өчен язасызмы?



Алмаз Монасыйпов улы Җанбәк, кызы Светлана һәм оныклары белән (1989)

—Әйе,—дип җавап бирә аптырап калган композитор.

Шунысы да хак: ул үзенең җырларын һәркемнән яхшырак башкара. Әгәр үтенсәң, беркайчан да баш тартмый. Дипломатыннан, кирәк була калса дип салынган, җыр текстлары язылган кәгазь битләрен алыр да, комачаулык итмәсен өчен күзлеген салып, дулкынландыргыч баритон тавышын артык күтәрмичә генә җырлый башлар. Ә мангаенда гарәпчә «ләм» хәрефе рәвешендәге кан тамыры тибәргә керешер.

Алмаз Закир улының зур горурлыгы—олы кызыннан һәм улыннан биш оныгы. Алар консерваториядә уку алдыннан аның

каршындагы мәктәп-лицейны тәмамладылар. Лицейнын тулы исеме бик озын: Казан дәүләт консерваториясе каршындагы урта махсус музыка мәктәбе. «Кайда укыйсын?»—дигән сорауга балалар гадәттә горурлык белән нindилер бер серле нәрсәне әйтеп бирәләр: «КДК каршындагы УМММда». Һәм өлкәннәрнен зур ачылган күзләренә карап торалар. Республиканын һәм күрше төбәкләрнен «музыка кадрлары мәктәбе» күптән түгел үзенен утыз еллыгын билгеләп узды. Олы оныгы Мартина бу мәктәпне тәмамлады инде, хәзер укуын Мәскәүдә—Гнесиннар исемендәге Россия академиясендә дәвам иттерә. Ә ул укуны, мондагы барлык балалар кебек, фортепиано артына урындыкка биегәйтүче әйберләр куйган хәлдә утырып, биш яшендә башлады. Нәни Тина—тан калдыргыч сөйкемле бала була: әбисе Кызыл Калфак костюмын бизәкләп тегеп кигезгән. Аны яхшырак күрү һәм ишетү өчен, әкияттәге бүре кебек, ана иеләсен икән, ул сикереп торыр иде дә синен битеннән үбеп алыр иде... Кече сыйныфлардан өлкәннәренә күчә барды, «хезмәт исемлеге» дә үсте: «Яшьләр сәнгатьләре ассамблеяләре» конкурсы дипломанты, Д. Кабалевский исемендәге конкурс лауреаты, Дварионас исемендәге яшьләр халыкара конкурсы лауреаты...

Калган оныклары: Тимур, Лиза, Максим, Рөстәм шул ук мәктәптә скрипкада уйнарга өйрәнәләр. Аларнын ин бәләкәе—өченче сыйныфны тәмамлаган Рөстәмнен инде зур унышлары бар. Ул региональ (Түбән Новгород) һәм бөтен Россия конкурсларынын лауреаты. Ә Мартинанын инде улы үсә, димәк, Алмаз Закир улы икеләтә дәү эти.

Алмаз Монасыйповнын сөйләшү рәвеше үзенчәлекле: фикерләрен ачык, төгәл итеп, акрын һәм канатлы сүзләр белән әйтеп бирә, а тавышы күнелгә үтәрлек. Берничә дистә еллар дәвамында анын белән якынча менә болай сөйләшәбез:

—Йә, сөйлә, ничек яшисен, нәрсә яхшы, нәрсә начар? Начардан башла.

—Нигә начардан, Алмаз Закирович?

—Бәлки, ярдәм итә алырмын.

Ул кайда да булса бер почмакта, әйтик, музыка мәктәбендәге үзенен виолончель буенча элекке шәкерте, хәзер инде утыз еллык стажлы, абруйлы педагог белән сөйләшеп утырырга ярата. Анын тормышындагы барлык авыр нәрсәләрне тынлап, уйга кала һәм, ниһаять, әйтеп куя:

—Барысы да җайга салыныр. Моннан да начаррак булмас, шәт.

—Начаррак булыр урын юк инде,—дип көрсенә шәкерте.

Мона башын чайкап, Алмаз Закирович өстәп куя:

—Начарракнын чиге булмый, яхшыракнын булуы бик ихтимал.

Анын композиция сыйныфында алты укучы булган. Барысы да төрледән-төрле, һәркайсы үз халкына үз сүзен әйтергә теләгән. Эшкәртербез дә—татар, удмурт композиторлары булырбыз дип уйлап, класска халык көйләрен алып килә торган булалар. Алмаз Закирович аларны фольклорга җаваплы мөнәсәбәттә булырга өйрәткән—эшкәртү бер нәрсә, ә халык көенә салынган орлыкны тишелдерә белү—башка бурыч ул. Җинел бурыч түгел. Алмаз Закир улы шуны әйтә килде: материалнын каршылыгын аны үз йөрәгеи кайнарлыгы белән мен градуслы температурага кадәр жылыткыч кына жинеп була...

**Наилә ШӘРИФУЛЛИНА,**
*Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать*
*академиясенең музыка теориясе*
*һәм тарихы кафедрасының өлкән укытучысы*

*Татар шигърияте антологиясеннән*

# Шәмсетдин Зәки

(1821-1865)

Унтугызынчы йөз татар шигърияте зур исемнәргә—үзенчәлекле шагыйрьләргә бай булган: Утыз Имәни, Г. Кандалый, Акмулла, Г. Чокрыйларны гына искә төшерик. Шулар рәтендә, әлбәттә, Шәмсетдин Зәки атлы шагыйребез дә мактаулы, мәртәбәле урында дип беләм. Аның гомере генә дә, мөгаен, зур әсәрләр язарга лаектыр: тумыштан сукыр килеш белемле, заманның алдынгы кешесе булып яшәү. Төрле һөнәрләргә ия булу... Гаилә—хужалык алып бару... Казанда, Эстәрлебашта, туган авылында балалар укыту. Шигырьләр язу... Акмулла, Г. Чокрыйларга остаз булу, шигъри моназаралар. Берничә юлдашы белән хаж сәфәренә чыккан жирдән Таганрогта вафат булу... Оренбург ягы Зәк-Ишмәттә туган сукыр шагыйрьнең халыкта икенче төрле исеме—Шәмсетдин Суфый... Аның ижатын иң башта өйрәнеп, «Асар»да мәкаләсе белән шигырьләрен бастырган мәшһүр Риза Фәхретдин шагыйрьне юкка гына гарәпнең Мәгаррие белән тиңләмәгән (Мәгарри дә сукыр булган, әмма шигърияте, бөек фәлсәфи карашлары белән Шәрекъне соклandырган; ул—безнең Муса Бигиевларны да илһамландырган фикер иясе шагыйрь. 973-1057 елларда яшәгән). Безнеңчә, Шәмсетдин Зәки фарсы шагыйре Хафизга якын. Коръәнхафизлык, исемнәре Шәмсетдин булу белән дә... Газәл кебек лирик жанрны үз итүе дә шуны сөйли.

Әмма Р. Фәхретдин бу жәһәттән—ягъни газәлләр остасы булу ягыннан аны төрки Фозули белән тиңли—«безнең Фозулиемыз идекендә шөбһә юк», ди. Гасыр башында һәм дәвамында шагыйрь ижатын Г. Рәхим һәм Г. Газиз, М. Гайнуллиннар өйрәнеп югары бәһаласа, безнең көннәрдә М. Госманов, Х. Миңнегулов кебек галимнәребез аны Уфада Дини Назаратта табылган кульязмасы буенча өйрәнеп, язып чыктылар. Х. Миңнегулов исә 1982 елда дөнья күргән «XIX йөз татар әдәбияты ядкярләре» китабының яртысын Ш. Зәкигә багышлап, әлеге кульязманы, шәрехләп бастырды; соңрак төрле дәреслек-хрестоматияләрдә дә этрафлы яктыртты...

Шагыйрьнең ижаты, Оренбург Каргалысы шагыйрьләре Ә. Каргалый, Һ. Салихов кебек чордашлары кебек үк, борынгы әдәби телебездә язылып, гарәп-фарсы сүзләре күп. Кайбер шигырьләре һәм хезмәтләре тоташ фарсыча язылган. Бу, әлбәттә, бүгенге укучы өчен түгел. Әмма шигырьләрендәге фикер, фәлсәфә аңлашылыр дип беләбез. Соңрак бу шигырь мәктәбендә бит Тукай, Дәрдмәнд, Бабичлар да тәрбияләнгән—димәк, традицияләребез бүгенгегә күчә, үсә килә. Укучыларыбыз игътибарына бу сәхифәдә шагыйрьнең ике газәлен тәкъдим итәбез.

**Рәдиф ГАТАШ**

### [«... кирәкдер»]

**Бу сүзе кәгазә йазмак кирәкдер,**
**Бу дөрре бер йибә тезмәк кирәкдер.**
**Вафасызлык—бу дөньяның эшедер,**
**Вафасыз нәснәдән бизмәк кирәкдер.**

**Беколли хакта йөз тотыб һәмишә,**
**Бу батыйлдан күңел өзмәк кирәкдер.**
**Сафа вә нигъмәтә ирмәклек өчен,**
**Җафа вә михнәттә дүзмәк кирәкдер.**
**Бу фани эвләре вәйран кылубән,**
**Ад бакый йөрүңе төзмәк кирәкдер.**
**Бу нәфсем гакыйла галеб килмәдән уң,**
**Аның тәдбирене бозмак кирәкдер.**
**Кичүбән бәррә сурәтидән сәрасәр,**
**Мәгани бәхредә йөзмәк кирәкдер.**
**Болай диб әүлийаның сөхбәтене,**
**Җәһан этрафыны гизмәк кирәкдер.**
**Исеб йил дик, акыб су дик тәмамәт,**
**Бу юлда уд кеби кызмак кирәкдер.**
**Ходага гарыз, хаҗәт вә мөнәҗат**
**Кылыб, күз яшен акызмак кирәкдер.**

## [«... булгай, булмагай»]

**Эстәсәм галәмдә сәндик йар булгай, булмагай.**
**Булса булгай, сән кеби гамьхар булгай, булмагай.**
**Ат сәнеӊ астындадыр, йөргел бу йирнеӊ хәдден ал,**
**Нагяһан ул ат сәнеӊ астында булгай, булмагай.**
**Карчыга кулыӊдадыр: аула бу күӊлеӊ шәһрине,**
**Нагяһан ул карчыга өндәүгә килгәй, килмәгәй.**
**Хафиза! Ширин кәлам, сүзлә телеӊ(неӊ) баридә,**
**Нагяһан килсә әҗәл тел сүзгә килгәй, килмәгәй.**
**Җан илә иман-икәүләр—бер өйүдә бал эчәр,**
**Нагяһан ул икесе бер әүдә булгай, булмагай.**
**Бу җәһанның шәһринеӊ базарының сәүдәсе күб,**
**Кыйл бу сәүдәне янә-базары булгай, булмагай.**
**Кил, йөрер булсаӊ җиһанда дидем үзрә бас кадәм.**
**Дидәмездән үзгә йул һәм бар булгай, булмагай.**
**Та терек сез, дустларым, бер-береӊә гыйззәт кылыӊ,**
**Ваһ, бу үлем! Үзгә дәм нагяһ булгай, булмагай.**

---

Дөрре—дөррене—энжене. Йибә—жебкә. Нәснәдән—нәрсәдән, әйбердән. Беколли—тәмам, бөтенләй, тулысынча. Һәмишә —һәрчак, һәр даим. Ирмәклек— ирешер. Эвләре—өйләре. Мәгани бәхредә—мәгънә дингезендә.

Гамьхар— кайгылы, хәсрәт жыючы. Хәдден—чиген. Нагяһан—кинәт, бер вакыт. Баридә —бар чакта, барда. Бас кадәм -аяк бас, атла. Та терек—терек *(тере, исән)* чакта. Үзгә дәм— үзгә мизгелдә, тиз вакыттан.

*Фән*

# ДАСТАННАРДА—ХАЛЫК ЯЗМЫШЫ

Тугандаш төрки халыклар иҗатында уртак сюжетка корылган күләмле әсәрләр бар. Аларны «эпос» дип тә, «дастан» яисә «хикәят» дип тә атыйлар. Киң танылу тапкан «Алпамыш», «Кобланды батыр», «Гыйса улы Амәт», «Күр углы», «Кыйссаи Йосыф», «Түләк һәм Сусылу», «Кузы Көрпәч белән Баянсылу», «Гашыйк Гариб», «Идегәй» кебек эпик ядкарьләрне бер генә халыкка нисбәтләп булмый, алар бер үк вакытта татар, башкорт, казакъ, нугай, үзбәк, азәрбайҗан, төрекмән һ.б. төрки халыкларның әдәби-мәдәни мирасын тәшкил итәләр.

Төрки телле халыклар иҗатының эпик әсәрләр рәте гаять бай катламнан гыйбарәт. Чура батыр исеме белән бәйле дастаннар —фәнни, тарихи, иҗтимагый, тәрбияви һәм мәдәни әһәмияткә ия шушы катламның бер буыны. Героик—эпик характеры, бердәй тематикасы, сюжет һәм мотивлары, каһарманны сурәтләү чаралары, һәм, ниһаять, уртак идеяне чагылдыруы Чура батырга багышланган төрки эпос-дастаннарны бер җепкә тезә.

Тарихи вакыйгалар җирлегендә барлыкка килеп, үзәктә реаль шәхес образын гәүдәләндергән халык иҗаты җәүһәрләрен героик эпос яисә тарихи дастан дип атау бар. Исеме эпик биография югарылыгына күтәрелгән тарихи шәхесләрне әллә ни күп дип әйтеп булмый. Татар-монгол империясенә нигез салган Чыңгызхан, Алтын Урданың көнбатыш өлкәләрендә хөкемдарлык иткән Мамай, Нугай Урдасына нигез салган Идегәй—боларның исемен халык үзенең шигъри иҗатында мәңгеләштергән. Шушы атаклы затлар янәшәсендә татар, кырымтатар, нугай, казакъ халыклары героик эпосында Чура образының да балкуы гаҗәп түгелме? Гаҗәп, чөнки үз чорында дөнья шаулаткан Бату хан, абруйлы Үзбәк хан, шулай ук Алтын Урданың зур өлешен биләп торган хөкемдар Нугайга, йә булмаса Казан ханлыгының мәшһүр Сөембикәсенә дә тиешенчә күрсәтелмәгән игътибарга чама белән 1500-1546 нчы елларда шул ук ханлыкта яшәп эшчәнлек иткән дипломат, сәясәтче, хөкүмәт әгъзасы Чура бәк Нарыков лаек булган! Монда хикмәт чор таләбендә булса кирәк. Чурага багышланган дастаннарның темасын төрки халыкларның милли каһарманы Чура батыр турында дип тә, Казан ханлыгының җимерелү трагедиясенә мөнәсәбәттә һәм тагын да киңрәк мәгънәдә татар ханлыкларының бер-бер артлы Мәскәү тарафыннан тез чүктерелү процессына протест белдерү дип тә билгеләргә мөмкин. 1552 нче елда Казанны урыс гаскәрләренең яулап алуы татар халкы гына түгел, башка төрки-мөселманнар өчен дә зур фаҗига буларак кабул ителгән. Тарих белән тыгыз бәйләнештә торган халык иҗаты бу вакыйгага үз мөнәсәбәтен белдерми калмаган, шул уңайдан ил азатлыгын яклап көрәшүче милли каһарман Чура образын бик теләп чагылдырган. Шуна күрә Чура батырның төрки халыклар эпосында гәүдәләнешен иҗади ихтыяҗ нәтиҗәсе дип карау дөрес булыр.

Тарихи шәхес буларак, Чура Нарыков—XVI йөзнең 20 нче елларыннан Казан ханлыгында сәяси һәм дипломатик эшчәнлеге белән мәгълүм шәхес. Биредә ул Мәскәү белән союзга йөз тоткан «көнбатыш» төркем тарафдары булган. Заманында аның фикердәшләре дип атаклы Булат һәм Нурали Ширин, Гәүһәршад, Сәед Боерган, Калыш, Отуч, Баубәк, Борнаш, Колыш мирзалар кебек сәяси һәм иҗтимагый эшлеклеләрне күрсәтергә мөмкин. Шунысы мәгълүм: «көнбатыш» төркеме Казан ханлыгында кырымлы Гәрәйләр династиясенә оппозициядә торган фирка булган. Моны берьяклы гына бәяләп, урыс хөкүмәте ориентациясендә торган әлеге төркем тарафдарларын, шул исәптән Чура Нарыковны да Мәскәүгә иман саткан җаннар дип санау зур хаксызлык булыр иде. Документаль чыганаклар раслаганча, Чура бәк партиясе ханлыкны чит ил баскынчыларына бәйлелеккә төшермәү, дәүләт иминлеген, мөстәкыйльлекне мөмкин булганча саклау юнәлешендә торган. Казан ханлыгы өчен гаять катлаулы елларда алар күп тапкыр конфликтлы хәлләрдән чыгу җаен тапканнар,

дипломатик осталык нәтиҗәсендә, тәхетне Кырымнан килгән ханнар биләгәндә дә, Мәскәү утырткан ханнар заманында да, алар белән килешеп, эшчәнлек алып барганнар. Чура Нарыков та—гомере буе ханлык мәнфәгате өчен көрәшкән сәләтле шәхес. Илдәге хәлләрдән һәрвакыт хәбәрдар Чура бәк халык белән еш аралашкан, аның ышанычын яулаган оста сәясәтче булган.

Тарихи Чура белән дастаннар каһарманы Чура батыр арасында охшашлык та, аермалар да шактый. Чура Нарыковка теге яки бу мөнәсәбәттә торган шәхесләрнең дастаннарда чагылышы, чор һәм вакыйгалар уртаклыгы, ягъни тарихи җирлек бу ике образны һичшиксез якынайтса, читләтеп үтеп булмый торган принципиаль каршылыклар да очрый. Менә шуларның берсе: 1546 нчы елның көзендә Сафагәрәй хан тарафыннан җәзалап үтерелгән Чура бәк язмышы төрки дастаннарда 1552 нче елга—Казан алыну фаҗигасенә үк килеп тоташа. Бу урында без тарихи төгәллектән бераз читкә китеп, дастаннарның реаль вакыйгалар, риваятьләр җирлегендә иҗат ителгән фольклор әсәре булуын янә бер кат искә төшерергә тиешбез. Халык иҗаты әсәрләренә, бигрәк тә аның эпос-дастаннар жанрына тарихилык хас, әмма алар чынбарлык вакыйгаларының күчермәсе дә түгел. Төрки халыкларның Чура батырга багышланган дастаннары тарихны ничек бар шулай яктыртуны түгел, ә героик эпос каһарманын халык батыры, ыру-ил мәнфәгатьләрен яклаучы итеп сурәтләүне алга куя.

Чура батыр исеме белән бәйле дастаннарның татар, кырымтатар, нугай, казакъларда таралуы бу халыкларның заманында Алтын Урда дәүләтенә берләшкән булуыннан киләдер. Аларның үзара тыгыз мәдәни-рухи бәйләнешләре соныннан, һәркайсы мөстәкыйль дәүләтләр төзеп яши башлагач та, халыкның уртак сюжетка мөрәҗәгать итеп, бердәй традицияләргә нигезләнгән дастаннар иҗат итүенә китергән дип карарга мөмкин. Шушы әдәби-тарихи процесслар нәтиҗәсендә татарлардан тыш нугайларда—ике, казакъларда—өч, Кырым татарларында хәтта дүрт вариантта Чура батырга багышланган дастаннар барлыкка килгән (күбрәк тә булуы бик мөмкин). Әлеге образ башкорт халык иҗатында да бик популяр, әмма ут күршеләребездә күләмле эпос-дастан табылмады.

XVI йөздә Казан-Мәскәү арасындагы киеренке атмосфераны чагылдырган «Чура батыр» дастаннары, уртак эпик мотивларны, идея-сюжет элементларын берләштерү белән беррәттән, һәркайсы үз үзенчәлеге белән сугарылган мөстәкыйль әсәрләр буларак та кыйммәт.

Төрки версияләр арасында иң беренче басылып чыккан дастан— татар халык «Чура батыр»ы. Ул 1862 нче елда И.Березин тарафыннан төзелгән «Турецкая хрестоматия» китабына кертелгән. Дастанның һәм, гомумән, Чура образының иң әүвәл безнең фольклорда популяр булуы шик уятмый. Дастанда гына түгел, татар халкының бәет, риваять кебек жанрларында да шул ук батыр образы чагылыш тапкан. Шунысы әһәмиятле: аларның да тарихи җирлеге XVI йөз уртасында Казан ханлыгы вакыйгаларын тасвирлауга кайтып кала.

Татар халкының «Чура батыр»ы—темасы һәм сюжеты ягыннан шактый үзенчәлекле булуы белән бергә, реаль вакыйгаларга да иң якын торучы версия. Моның тарихи нигезе бар: Казан ханлыгының Мәскәүгә көчләп буйсындырылуы, әлбәттә, иң беренче нәүбәттә безнең халык өчен зур фаҗига булган. Шуңа күрә дастан бер-берсе белән тирән керешкән ике зур теманы яктырта дияргә мөмкин: милли каһарман Чура язмышы һәм Казан ханлыгы җимерелү вакыйгасы. Шул ук вакытта бу әсәр, татар ханлыкларының бер-бер артлы урыс дәүләте тарафыннан буйсындырылу фактын искәртеп, теманы тагын да киңәйтә. Чит кавем, чит дәүләттән җиңелгән ханлыкларның кайчандыр дан-шөһрәтле илләр булуына ишарә дә, трагик вакыйгаларга мөнәсәбәт тә биредә ачык сизелә һәм уйланырга мәҗбүр итә. Дастан кардәш халыклар арасында бердәмлек идеясен алга сөрә дисәк, бер да хата булмас. Эпик-географик масштаблар да шушы фикерне яклый кебек. Татар версиясеме, кырымтатар, нугай яисә казакъныкымы, традиция буларак, Чура батырны Казанга читтән—мөселман иленнән (гадәттә Кырымнан) китертә һәм шул каһарман, кулына кылыч алып, Казан халкын һәм ханлыкны дошман явыннан азат итү өчен көрәшә. Төрки дастаннар Казан ханлыгы батырын милли герой, ә ханлыкның дошманын үз халкының дошманы буларак кабул итәләр!

Чурага багышланган төрки дастаннарның һәркайсы нигездә төп каһарманның атасы Нарык тормышын сурәтләүдән башлана. Нарыкның чибәр (ару) кыз Миңле Сылуга өйләнүе, алар кичергән тормыш кыенлыклары, илдән чыгып китәргә мәҗбүр

булып, юлда Миңле Сылуның Чура исемле бала табуы, ниһаять, Кырымга килеп төпләнү— дастаннарның Нарыкка багышланган өлешендә төп сюжет сызыклары. Татар версиясе тасвирны Нарыкның балачагыннан ук башлый. Ул олуг бер мирза тәрбиясендә үскән ятим бала була. Кырымтатар, нугай версияләре аны хан хезмәтчесе буларак сурәтләсәләр, казакъ эпосында ул, гадәттә, бай нәсел баласы, хәтта бер вариантында—хан. Дастаннар, билгеле булганча, чичәннәрнең иҗат җимеше. Чичән мәгълүм эпик әсәрне байлар аудиториясенә бер төрле, ярлырак катлам өчен башкача яңгыраштa бирә алган. Түрәләр яисә гади халыкка махсус атап та әсәрләр иҗат ителгән. Әлеге социаль дифференциальләшү Чура батырга багышланган дастаннарда үзен әллә ни сиздерми. Шулай да бирелә казакъ халкының эпик традицияләре һәм тарихи үсеш юлы үзенчәлекләрәк булуны исәпкә алырга кирәктер. Казан татарлары 1552 елда ук кичергән фаҗигане аларга XVIII-XIX, хәтта XX йөз башында гына килүе дә әдәби процесска тәэсир иткән булса кирәк.

Дастаннарның икенче зур өлеше Чура батыр тормышын бәян итә. Гомумтөрки эпоска хас мотивлар— балага «бәхетле» исем кушу, булачак баһадирның батыр балачагын тасвирлау, героик эпизодлар, каһарманлык сыйфатларын, аның үзенә тиң атын, кылыч-садагын сурәтләү, ата-анасы, кардәшенә, туган җиренә мөнәсәбәтен белдергән эпизодлар—болар Чура батыр дастаннарының төп нигезен тәшкил итә.

Кырымтатар «Чора батыр»ының һәркайсы геройны Казанга китереп тәмамлана, 2 вариантта исә батыр үлгәннән соң каланы урыс явы алу турында да сөйләнә. Кырымтатар дастаннарының идея-эчтәлегендә Казан ханлыгының дошманы булган урыс дәүләтенә һәм урысларга тискәре мөнәсәбәт, аларны чит итү, Казан ханлыгына теләктәшлек үзен сиздерә. Кырымтатар «Чора батыр» дастаннарында чәчмә һәм шигъри форма үрелеп бирелгән. Героик сәфәргә киткәндә каһарманның ата-анасы, кардәше, хатыны белән хушлашуын бәян иткән шигъри юллар кырымтатар дастаннарының гаҗәеп тәэсирле урыннарыннан берсен тәшкил итә:

Ал инде, анам, ал инде,
Саулык белән кал инде.
Ун ай мине күтәрден,
Ун ай мине имезден.
Алкалы бишек яптырдын,
Таң йокысын дүрт бүлден,
Тартып имчәк имгәндә
Бавырыңа, ай, анам, сеңгәнмен...
Имгән сөтем хәләл ит...

Кырымда гаделсезлеккә каршы көрәшеп ихтирам казанган баһадир Казанга юл тота. Каһарманның аерылмас юлдашы—ат. Төрки халыкларның атка мөкиббән китү сыйфаты аларның дастаннарында да чагыла. Кырым татарларындамы, татар, нугай, казакътамы, Чураның атаклы Тасмалы Кере (Кер Турысы, Тасмагере) бар. Бу толпар—атны аңа гадәттә изге карт бүләк итә.

Җилдән житез аты булган кебек, дошманнарын җиңәр өчен, төрки эпик герой үзенчәлекле сугыш коралына—кылычка да ия. Мәсәлән, кыргызларның атаклы «Манас» поэмасында баһадирның Ачалбарс кылычы, Ак кәлтә дигән мылтыгы аңа дан яуларга булыша. Чура батырга багышланган дастаннарның күп кенә версияләрендә каһарманның Күк Чыбык исемле кылычы шундый ук роль уйный. Аны Чурага Казан ханының кызы бүләк итә.

Чура батыр исеме белән бәйле нугай дастаннарында да XVI йөздә Казан белән Мәскәү арасында үзара конфликтлы мөнәсәбәтне һәм ханлыкның үз эчендә барган каршылыклы сәясәт атмосферасын тою кыен түгел. Нугай дастаннары Казан алыну вакыйгасына эмоциональ якын килү, образлылык ягыннан үзенчәлекле. Алар нугай халык эпосына хас булганча, каһарман һәлакәте уңаеннан китерелгән классик дәрәҗәдәге елау-сыктау монологлары белән дә аерылып торалар. Нугайларның «Шора батыр»ында героик эпизодларның иң әһәмиятлесе— Кырымнан Казанга күчеп килгәч, Шораның кала өстенә килгән яуга каршы көрәшү моменты. Нугай халык иҗаты пәһлеванны канлы вакыйгалар мәйданына китереп чыгара. Шора батыр, Казанда манара җимерекләре өстендә яулар белән кылычка-кылыч килеп, соңгы сулышынача сугыша. Соңыннан, әсир төшәргә теләмичә, Иделнең текә ярыннан суга ташланып һәлак була. Казанга улын эзләп килгән Миңле Сылу—ана болай дип елый:

Карчыгадан туган тургайдай,
Ханнан туган солтандай,
әй, бикәләр, тутайлар,
Кайсыгыз ул тапкансыз,
Казан каласын казанган
Кан яралы Чурадай?
Бармактагы уймагым,
Ак көмештәй тырнагым.

Төрки халыкларның Чура батырга багышланган эпик әсәрләре рәтендә казакъ версияләре һәм вариантлары үзенчәлекле урын били. Болар—бер-берсеннән эчтәлеге белән, башка төрки Чура батыр дастаннарыннан казакъ халкына гына хас тарихи жирлектә барлыкка килүләре белән аерылып торучы әсәрләр.

Күзәтүләр шундый нәтиҗә бирә: казакъ дастаннары каһарман язмышын Казан ханлыгы фаҗигасе белән бәйләүдән читкәрәк тайпыла яисә тарихи чынбарлыкка кайтып төшкән сюжет әлеге трагик вакыйгага битарафлык төсмере белән тәмамлана, төрки халыклар иҗатында мәгълүм сюжетка корылган дастаннар үз чоры өчен казакъ халкына якынрак торган мәсьәләләрне яктырту юнәлешен ала. Гадәттәге урыс гаскәрләрен биредә казакъ халкының тарихи дошманы—калмыклар алыштыра. Шулай булуга карамастан, Чура батыр турындагы казакъ дастаннарында да башка төрки версияләр белән уртак рух сизелә. Һәр вариант Чура (Шора) батырны эпик каһарманга хас сыйфатларга ия милли герой итеп тасвирлый һәм, иң әһәмиятлесе, аның язмышын Казан каласы белән бәйли. Мәгълүм бер вариантта хәтта Казан ханлыгының төрки дөнья өчен гаять мөһим үзәк булуы ачыктан-ачык әйтелә.

Казакъ дастаннарында күп кенә хәлләрне илаһи көч кодрәте ярдәмендә аңлату шактый куәтле. Кайбер эпизодлар тамырлары белән мәҗүсилек чорына ук барып тоташа. Мәсәлән, каберлеккә табыну, Баба-Тукты-Чәч образына бәйле гамәлләр, каһарманны изгеләр өне озата бару һ.б. Бу—урта гасырларга хас фикерләү үзенчәлегеннән килә булса кирәк. Һәм, әлбәттә, эпоста мәсьәләне әлеге юл белән хәл итүне иран һәм төрки халыкларның мәдәни-тарихи традицияләренең чагылышы дип тә бәяләргә мөмкин. Казакъ халкының тикшерелгән дастаннарында шушы аңлатманы бирердәй күренешләр шактый. Томанлырак мәгънәдә булса да, фикерләү үзенчәлегенә бәйле әлеге эпик традиция нугай, кырымтатар, татар версияләрендә дә очрый. Балачагында Чура (Чора, Шора) бозаулар бакканда каяндыр пәйда булып, батырга ат бүләк иткән карт образы шул күренешнең бер чагылышы түгел микән?

Татар, кырымтатар, нугай, казакъ дастаннарының һәркайсында Чура батыр исеме бары уңай һәм югары бәя алган, героик идеаллаштырылган. Образның берничә халык иҗатында киң чагылышы дастаннарның халыкара әһәмиятен үстерә. Нарык углы Чура батырга багышланган уннан артык төрки дастаннар үзләренең идея-эстетик кыйммәтләре һәм югары сәнгатьчә эшләнешләре белән дә игътибарга лаек. Туган жир, Ватан бәйсезлеге, халык бәхете, ыру-кабилә иминлеге өчен көрәш темасы, батырлык, гаделлек, тугрылык кебек рухи сыйфатларны зурлау, бердәмлек булмау һәм кызулык күрсәтү китереп чыгарган нәтиҗәләргә ишарә ясау бу әсәрләрнең төп эчтәлеген тәшкил итә. Мондый югары идеяләр бүгенге көн өчен дә бик актуаль. Чура батырга багышланган һәрбер дастан—мөстәкыйль эпик әсәр, татар, кырымтатар, нугай, казакъ халыкларының күңел җәүһәрләре. Шушы төрки ядкарьләрнең Казан ханлыгы язмышын бәян итүләре, шул ханлыкта яшәгән мәгълүм шәхесне уртак дошманга каршы ил азатлыгы өчен көрәшүче милли каһарман буларак сурәтләве бердәмлеккә өндәүнең матур үрнәге түгелмени?

**Лилия ИБРАҺИМОВА,**
*Г. Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*кече фәнни хезмәткәре.*

## *Заһир Бигиевнең тууына 130 ел*

# БӘХТИЯР ӘДИП

“Шура” журналының 1908 ел 5 нче санындагы бер язмада *(аның авторы баш мөхәррир Ризаэддин Фәхреддин үзе булса кирәк)* «Заһир әфәнде яшьли үлсә дә, бәхтиярдер» диелгән (149 б.). Бу кыска гына җөмләдә Заһир Бигиев язмышының мөһим бер үзенчәлеге тотып алынган. Чыннан да ул, гәрчә Тукай, Бабич, Такташлардан бераз озаграк яшәсә дә, гомумән бу якты дөньядан бик иртә китеп бара. 32 яшь — бу бит әле кеше гомеренең уртасы гына. Әмма Заһир Бигиев әдип буларак чыннан да бәхтияр, ягъни бәхетле: аңа Ходай Тәгалә әдәби талантны мул итеп биргән, шуңа да ул 16-19 яшьләрендә үк төрле чор укучылары яратып укырлык романнар тудыруга ирешкән. Аның әсәрләре автор үзе исән чакта да (1887, 1890, 1895, 1896...), аннан соң да (1908, 1925, 1960, 1991...) даими басылып тора, мәктәпләрдә, югары уку йортларында өйрәнелә, галимнәрнең, әдипләрнең игътибарын җәлеп итә.

Тормышта еш кына шушындый хәл күзәтелә: кешенең сыйфатларын, эш-гамәлләрен, хезмәтләрен күреп, тоеп йөрисең, әмма алар хакында фикер әйтергә, ничектер, җае чыкмый, сылтау табылмый. Заһир Бигиев турында да әүвәл шулай була. Әмма аның 1908 елда “Мавәраэннәһердә сәяхәт” исемле китабының басылып чыгуы *(“Китап” нәшрияты.— 108 б.)* җәмәгатьчелекнең әдип хакындагы тәэсоратларын, уй-кичерешләрен белдерүгә бер этәргеч ясый, сәбәп була. Чорның күп кенә күренекле шәхесләре узыша-узыша матбугатта З.Бигиев турында язмаларын бастыра башлыйлар. Ф.Әмирхан “Дамелла” кушаматы белән басылган бер язмасында (*Әлислах.— 1908.— 21 нче сан.— 5-6 б.)* әдипне “Татар милләтенең соңгы еллары йитешдергән вә иртәрәк күзе ачылган мөхәррирләрендән” берсе, дип саный. “Заһир әфәнденең бу әсәре *(ягъни “Мавәраэннәһердә сәяхәт”.— Х.М.)*,— ди ул,— хәзергә кадәр татар әдәбиятында назыйрәсездер *(тиңсездер.— Х.М.)*, рәгъбәт *(теләк.— Х.М.)* белән укып чыгарлык сурәттә тәрләндереп язылган”. Шунысы кызыклы: бу сөйләшүдән хәтта ерак сөргендәге Гаяз Исхакый да читтә калмый. “Бәянелхак” гәҗитендә басылган язма *(1908.— 16 март.— 294 нче сан)* — шуның бер мисалы.

Г.Исхакый “Мавәраэннәһердә сәяхәт” әсәренең, соң булса да, аерым китап рәвешендә басылуын хуплый. «Бу сәяхәтнамә,—ди ул,— Заһир әфәнденең соңгы әсәре булганга, бу яшьли әрәм булган мөхәррирнең укучылар берлә актык сөйләшүе, аларга үзенең йөрәгенең кайнаганнарын актык әйтүе булганга, безнең әдәбият тарихымызда да бу китап, шөбһәсез, бер әсәр булачакдыр. Бу китап хакыйкать Заһир әфәнденең кем идеке вә ничек уйладыкы вәниләр теләдеге берлә танышдырганга, Заһир әфәндене таныр өчен бу китап бик зур ярдәм итәчәкдер. “Мавәраэннәһердә сәяхәт” моннан 15 ел элек язылганыны искә төшерелсә, Заһир әфәнденең шул вакытта башын вата торган фикерләр татар әдәбиятына 1901 нче ел Риза Казыйның “Сәлимә”сенә кадәр кермәве хисап кылынса, Заһир әфәнденең бик алдагы бер мөхәррир, татарның халендән бик хәбәрдар бер язучы булуында аз гына да шик калдырмыйдыр. Шуның өчен Заһир әфәнденең яшь вакытта әрәм булуы безнең татар әдәбиятын сөйгән кешеләр алдында, шөбһәсез, бер зур кайгырырлык эшдер”. Рецензент фикеренчә, “Заһир Бигиев—безнең татарларның Габделкаюм Ән-Насыйридан соң иң карт мөхәррирләреннән” берсе, “татар дөньясында мәгълүм бер кеше”; шуңа күрә “аның әсәрләре

хакында газеталарда язу вә әсәрләрен тәнкыйд кылу бик файдалы эш...". Г.Исхакый әдипнең сәяхәтнамәсе хакында аерым тәнкыйть фикерләре дә әйтә. Мәсәлән, мәкалә авторы Заһир Бигиевнең "госманлычарак" тел белән язуын, мәшһүр шәрыкшенас Вамберины "шпион ясау"ның "хаксыз" икәнлеген искәртә. Рецензент үз язмасын мондый юллар белән төгәлли: "Гомумән караганда, китап бик файдалы, матбугатымызның тулмаган йирләрен тутыра торган, халкымызның бик күп аңламаган мәсьәләләрен аңлата торган бер әсәрдер. Шуның өчен Заһир әфәнденең бу соңгы әсәрен һәркемгә укырга тәүсыя *(киңәш.— Х.М.)* итәмез".

* * *

Татар рухи тормышында тирән эз калдырган агалы-энеле, ягъни бертуган шәхесләр бар: Хөсәен һәм Габделгаллӛм Фәйзханов, Һади һәм Садрый Максудый, Нил һәм Илдар Юзиев... Заһир Бигиев тә — әнә шундый затларның берсе. Аның энесе Муса *(24.12.1875—12.11.1949. Кайбер язмаларда туган елы 1871 ел дип күрсәтелә)*—дин галиме, шәрыкшенас, педагог, журналист, җәмәгать эшлеклесе, мөселман дөньясының күренекле шәхесе. Татар зыялылары арасында Муса Җарулла кебек күп җирләрдә укыган, җиһанның төрле почмакларында яшәгән шәхесләр, мөгаен, башка юктыр. Булса да, бик аздыр. Ул әтисенең туган авылында, Казанның Зәңгәр мәчет мәдрәсәсендә, Ростовтагы реаль лицейда, Бохарада, атаклы Әл-Әзһәр югары уку йортында, Санкт-Петербург университетында укый, Казан, Оренбург, Петербург, Мәскәү, Ташкент, Истанбул, Хельсинки, Берлин, Каһирә, Һиндстан, Япуния, Кытай, Иран һәм башка күп кенә шәһәрләрдә, мәмләкәтләрдә була, эшли, үз чорының мәшһүр кешеләре белән очраша, аралаша. Болар арасында Тукай һәм Исхакый кебек әдипләр дә, Ленин һәм Ататөрек кебек дәүләт эшлеклеләре дә бар. Муса Бигиев, дини-сәяси карашлары өчен, өч ай буе Лефортово *(Мәскәү)*, алты ай Пишавар (элеккеге Һиндстанда) төрмәләренең "рәхәтлекләренә"дә дучар ителә. Шунысы мөһим: аның хатыны Әсмаи-Галия дә — затлы нәселдән. Ул — Чистайның атаклы Закир хәзрәт кызы. Аның абыйсы Ибраһим Шәүкәт Кәмал Каһирәдә Муса белән бергә укый. Әсмаи-Галия белән Мусаның Чистайда үткәрелгән туй мәҗлесендә *(ул 1905 елның 20 маенда була)* Рәшит казый Ибраһимов *(1857-1944)*, Нәҗип Әмирхан (1859-1921) һәм бүтән могтәбәр затлар катнаша *(Равил Әмирхан. Соңарып килгән гаделлек // Шәһри Казан.— 6.06.2000)*. Муса Җарулла 1949 елның 12 ноябрендә Каһирәдә вафат була. Татар, урыс, гарәп, фарсы, төрек һәм кайбер башка телләрне "мөкәммәл" белгән бу затның шәхси китапханәсе үзенең васыяте буенча Анкарадагы Милли китапханәгә тапшырыла.

Заһир Бигиевның туганнары күп була. Алар арасында да, гәрчә Муса Җарулла кебек булмаса да, шактый билгеле шәхесләр бар.

* * *

Заһир Бигиевнең тормыш юлы һәм иҗаты дәреслек-хрестоматияләр, әдәбият тарихы китаплары, төрле мәкаләләр аша укучыларга, киң җәмәгатьчелеккә шактый таныш. Безгә дә инде бу әдип хакында берничә мәртәбә язырга туры килгән иде *("Исмең синең милләт яшәдекчә яшәр" (Тууына 125 ел тулу уңае белән) // Мирас.— 1995.— 11-12 саннар.— 38-47 б.; Татар әдәбияты. Рус мәктәпләренең 10 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен дәреслек-хрестоматия.— К.: Мәгариф, 1996.— 172-185 б. һ.б.)*. Шуңа күрә биредә, Муса Бигиевның "Мавәраэннәһердә сәяхәт..." китабына *(К., 1908)* кереш рәвешендә бирелгән мәкаләсенә, А. Баттал-Таймасның Истанбулда нәшер ителгән "Муса Җаруллаһ Биги" *(1958.—61 б.)* монографиясенә һәм кайбер башка материалларга нигезләнеп, әдипнең тәрҗемәи хәле, иҗаты хакында кайбер мәгълүматлар биреп китәрбез.

Мөхәммәдзаһир Бигиев 1870 елның көзендә Ростов-Дон каласында

рухани гаиләсендә дөньяга килә. Әтисе Җарулла (Ярулла) һәм әнисе Фатыйма — һәр икесе дә Пенза төбәгендәге "Алтыавыл"ның берсеннән — Мачалидан (Кикин авылына нисбәт итүчеләр дә бар). Мөхәммәдзаһирның әнисе ягыннан бабасы Хәбибулла Биги углы авылның укымышлы имамы була. Җарулла Габделкәрим углы анда укый, гарәп, фарсы телләрен үзләштерә, урысча да өйрәнә. Мәскәү-Ростов тимер юлында сәүдә белән шөгыльләнә. Мөфти Сәлимгәрәй Тәфкилев, исламча гыйлемлеген исәпкә алып, аны Ростов-Дон шәһәренә имам итеп билгели. Әмма булачак әдипнең әтисе 45 яшьләрендә 1881 елда, нининдер "бөек бер бәлагә очрап", үлеп китә. Гаиләнең бөтен авырлыгы, балаларны тәрбияләү Фатыйма абыстай җаваплылыгында кала. Ул үз балаларын еш кына авылга әби-бабалары янына алып кайта, аларга Мәскәү, Петербург, Казан калаларын да күрсәтә. Укымышлы, дини гаиләдә туып үскән, үзе дә шактый гыйлемгә ия булган бу хатын балаларын белемле иманлы итүгә күп көч түгә. Фатыйма абыстай, сукыраеп, 1908 елда вафат була.

Муса Бигиев язуынча, "Заһир әфәнде яшь бала икән *(ягъни яшь вакытта ук.— Х.М.)* урысча уку, язу вә үгрәнеп, соңра валидәсе *(әнисе.— Х.М.)* Фатыйма ханым банате дамелла Хәбибулла хәзрәтләренең тәрбиясендә иске мәдрәсәләрнең берендә күп еллар калып, иске ысул үзрендә *(искечә.— Х.М.)* гомуме диния, гомуме гарәбия укымышдыр". Шул елларда аның урыс, француз, госманлы авторларының әсәрләрен күпләп укуы мәгълүм. Заһир Бигиев бигрәк тә маҗаралы, детектив романнарны ярата. Болар бар да табигый сәләткә ия булган үсмерне әдәби иҗат белән шөгыльләнүгә китерәләр. Һәм ул 16 яшендә "Өлүф яки гүзәл кыз Хәдичә" исемле атаклы романын яза. Мәгълүм булганча, Заһир Бигиев 1886 елда Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укый башлый. Биредә ул "Өлүф..." янсә "Меңнәр..." романын төгәлләп, 1887 елда "Вячеслав" басмаханәсендә нәшер итә. Әдипнең Казандагы тормышы әллә ни билгеле түгел. Чыганакларда аның күпләп укуы, төрле кешеләр белән аралашуы, әдәби иҗат белән шөгыльләнүе гомуми планда гына искәртелә. 1890 елда Казанның шул ук басмаханәсендә әдип үзенең "Гөнаһе кәбаир" ("Зур гөнаһлар") исемле икенче романын нәшер итә.

Мәдрәсәне тәмамлагач, 1891 елда З.Бигиев Ростов-Донга кайта һәм шунда шәһәр мөселманнарының имамы булып эшли башлый. "Имам улмыш исә дә,— ди аның хакында энесе Муса Бигиев, — гомеренең ниһаясенә *(ахырына.— Х.М.)* кадәр валидәсенең *(әнисенең.— Х.М.)* тәрбиясендә калды... Ростов шәһәренең көтебханәи гомумиясенә варып, даимән рус әсәрләрене моталәга идәр *(укыр.— Х.М.)* иде". 1893 елда З.Бигиев Мавәраэннәһергә, ягъни Урта Азиягә сәяхәт кыла. Шуның нәтиҗәсе буларак, аның атаклы сәяхәтнамәсе языла. Бу язма 23 яшьлек авторның гаять зыялы, укымышлы, Шәрык һәм Аурупа гыйлемен шактый тирән үзләштергән шәхес икәнлеген ачык күрсәтер тора.

З.Бигиевның Төркестан якларына баруында ике төп сәбәп бар. Әдип, Исмәгыйл Гаспралы кебек, татарча гәҗит чыгарырга хыяллана. Әмма бу ният гамәлгә ашмый. З.Бигиевнең Бохарада укырга калырга да теләге була. Әмма андагы уку йортларында белем бирүнең түбән дәрәҗәдә икәнлеген күргәч, ул бу ниятеннән баш тарта.

З.Бигиев Төркестаннан күңел төшенкелеге белән кайта. "Мавәраэннәһердә сәяхәт" язмасының ахырында ул болай ди: "Гаять көчле авырулы бер хәлгә төштем. Башлануы кайгыдан юану өчен бер кәеф-сафа кору сымаграк булып күренсә дә, ахыры соң дәрәҗәдә һәлакәтле булды. Кулыма каләм алмас бер хәлгә килдем. Тормыш ләззәтләреннән өмет өздем. Моннан соң яшәвемдә файда булмас дидем дә, әҗәл сәгатен, Газраилнең визитын көтә башладым...". Шушындый төшенке халәт алга таба да дәвам итә. Муса Бигиев тә абыйсының "гаять бөек мөдһәш *(куркыныч.— Х.М.)* бер бәлая (*бәлагә.— Х.М.)* ибтилясы (төшүе, дучар булуы.— Х.М.)" хакында яза. 1902 елда әдипнең йөрәге тибүдән туктый. Аның кайчан, кемгә өйләнүе хакында кулыбызда мәгълүматлар юк. Муса Бигиев абыйсының урын өстендә хыянәт кулы белән үтерелүен яза *("дәсте хыянәт илә катыйл улынып, шәһид улды")*. "Валидәсе *(әнисе.— Х.М.)* баласының җәсәдене *(гәүдәсен.— Х.М.)* табиблар әлендә *(кулыннан.— Х.М.)* тугратмак өчен бөек-бөек парәләр (акча.— М.Х.) сарыф идеб, ун сәгать

мөкаддәм *(ягъни 10 сәгать үтүгә.— Х.М.)* ... дәфен итдермеш *(күмдермеш.— Х.М.)"*. М.Гайнуллин да әдипнең тууына 75 ел тулу уңае белән язылган мәкаләсендә *(Совет әдәбияты.—1945.— 9 нчы сан.— 74-83б.)* шушы ук фикерне куәтли: "Язучының соңгы көннәре матур узмаган. Үзе әйткәнчә, башта тынычлану нияте белән куллана башлаган кәеф-сафасы *(эчүе)* һәм хатынының аңа карата хыянәте Заһир Бигиевне һәлакәткә алып килгән. 1902 елда үзенең түшәгендә хатыны тарафыннан үтерелгән".

1999 елның 30 маенда Татарстан радиосы "Мирас" циклының З.Бигиевкә багышланган тапшыруын кабатлап бирде *(Аны без алып барган идек.— Х.М.)*. Шул тапшырудан соң әдәбиятчы галим Шакир ага Абилов, чыгышның "әйбәт, мәгънәле булуын искәртеп, болай диде: "Мин заманында Бохарада әмир архивында З.Бигиевкә мөнәсәбәтле кулъязмалар белән кызыксындым. Әмма алар арасында "Катыйлә" белән "Мөртәд" юк иде *(Бу ике әсәрнең кулъязмасын автор 1892 елда Ростов-Донга килгән Бохара әмире Габделәхәдкә биргән була.— Х.М.)*. Әйтүләренә караганда, Бохара әмире инкыйлабтан соң Әфганстанга кача. Шәхси китапханәсенең дә зур өлешен шунда алып китә... Мөхәммәд Гайнуллин 50 елның урталарында Ростовта була. З.Бигиевнең бик өлкән яшьтәге хатыны белән очраша *(балалары булмый)*. Шундый сүз таралган була: имеш, хатыны З.Бигиевне мунчада үтерә. М.Гайнуллинга әдипнең хатыны бу версиянең дөрес түгеллеген әйтә. М.Гайнуллин Ростовта әдипнең каберен дә күрә. Бәлкем, фотосын да алгандыр. Соңыннан баручылар исә З.Бигиев каберен таба алмадылар. Үзенең Ростовка сәфәре хакында М.Гайнуллин Тел, әдәбият һәм тарих институтының гыйльми Советында сөйләгән иде". Кайберәүләр З.Бигиевнең үз-үзенә кул салуы хакында язалар. Әдипнең Ростовта стачкалар вакытында христиан карагруһчылары тарафыннан кыйнап үтерелүе, әзне жую өчен бу җинаятьне аның хатынына ябештерүләре хакында да *(имеш, ул ирен агулаган дигән)* хәбәрләр бар *(М.В.Гайнутдинов. Татарская литература XIX века...— К., 2000.— С. 82-83)*.

* * *

Әйткәнебезчә, З.Бигиевнең ике романы, бер сәяхәтнамәсе басылган. Әмма чыганаклар аның янә "Мөртәд" *(диннән язган, иманын алыштырган; юньсез.— Х.М.)* һәм "Катыйлә" *(үтерүче хатын—кыз.— Х.М.)* исемле романнар язуын да искәртәләр. Дөрес, Рәфыйк Нәфыйгов "Катыйлә"не "Гөнаһе кәбаир"нең беренче варианты дип саный. Ул Ленинград *(С.-Петербург)* Үзәк дәүләт архивында цензура комитетыннан кергән "Катыйлә хатын" әсәренең кулъязмасын таба *(Бу текст цензурага 1889 елның 22 июлендә тапшырылган була)*. Цензор авторның "Инҗил"дән өзекләр китерүен, аларны шик астына алуын һәм башка сәбәпләр белән әсәрне басудан тыя. Шуннан З.Бигиев, романны төзәтеп, "Гөнаһе кәбаир" исеме белән бастыра *(Рәфыйк Нәфыйгов. Җитмеш дүрт ел үткәч // Совет әдәбияты.— 1963.— 5 нче сан.— 142-144 б.)*. Бу—кызыклы караш. Әмма З.Бигиев үзе һәм аның энесе бу романнарны тәңгәлләштермиләр, аерым карыйлар. Һәм "Мөртәд", һәм "Катыйлә" 90 еллар башында инде төгәлләнгән була. "Мөртәд"—"Гөнаһе кәбаир"нең дәвамы. "Катыйлә" хакында Муса Бигиев менә нәрсәләр яза: "Шу(л) әсәр... бөек бер мәһарәтилә *(осталык белән.— Х.М.)* язылмышдыр, әсәрләре арасында иң беренчеседер. Бән ул "Катыйлә"дә Мәрьям ханым илә кызы Әсманың адәм күңеле тәхәммел итмәз *(түзмәс—Х.М.)* дәрәҗәдә дәһшәтләренә күреп, соңра "Сәфилләр"дә *(Виктор Гюгоның "Хокуксызлар" романы күздә тотыла.— Х.М.)* Фантина илә кызы Козетта дәһшәтләрене укыдым. Шу(л) ике китап арасында гаять бөек бер мөнасибәт булдым *(ягъни бәйләнеш күрдем.—Х.М.)*. Белмәдем: Заһир әфәнде Виктор Һийуго җәнабләренең "Сәфилләре"не "Казан романы" калыбында язмышмы? Яхуд кәндүсенең *(үзенең.— Х.М.)* куәи шигъриясе илә... бер китап мәйданә чыкармышмы? Уйлә *(ничек.— Х.М.)* улса да, бөйлә улса да, бәһре тәкъдир у(л) китап Заһир әфәнде намәнә *(исеменә.— Х.М.)* һәрвакыт фәхер улачак *(дан, шөһрәт китерәчәк.— Х.М.)* бер китапдыр. Бер кач сәбәбләр илә кәндүсенең хәятында *(үзе исән чакта.—Х.М.)* тәбыг улынмады *(басылмады.— Х.М.)*. Инша Алла,

ганкариб *(тиздән, тиз көндә.— Х.М.)* тәбыг улыныр". Бу ике романның чыгачагы хакында "Китап" нәшрияты 1908 елда белдерүләр дә бастыра. Әмма, ни сәбәптәндер, ул китаплар дөнья күрми кала. Кульязмалары да юк. Монда кайберәүләр Муса Бигиевне дә гаеплиләр. Дөрес, ике туган арасы соңгырак елларда киеренкерәк булганга охшый. (Биредә, әлбәттә, абыйсының эчүчелеккә бирелүе дә билгеле бер роль уйнагандыр). Моны энесенең абыйсы хакындагы кереш сүзе дә сиздереп тора. Әмма шулай да без романнар нәшер ителмичә калуда Муса Бигиевне шелтәләргә җыенмыйбыз. Бәлкем, без белмәгән башка сәбәпләр булгандыр?

* * *

Заһир Бигиевнең әдәбиятка кергән еллары—татарның милли үзаңы уяну, тәрәккыятенең җанлану чоры. Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Х.Фәйзханов хезмәтләре халкыбызның тарихи офыкларын киңәйтте, Кандалый, Акмулла шигырьләре әби-бабаларыбызның рухи дөньясын баетты. XIX йөзнең икенче яртысында Шәрык телләреннән күпләгән әсәрләр тәрҗемә ителә. Урыс, Аурупа әдәбиятлары белән кызыксыну көчәя. Госманлы сүз сәнгате биредә арадашчылык ролен дә үти. Исмәгыйл Гаспралы эшчәнлеге, бигрәк тә аның "Тәрҗеман" гәҗите мәдәни үсешкә, мәгарифкә көчле этәргеч ясый. 80 нче елларда татар драматургиясе туа. Иҗтимагый-мәдәни вазгыять, рухи ихтыяҗлар нәкъ менә Муса Акъегетзадәнең тормышчан эчтәлекле, милли аһәңле, инсани фикерле "Хисамеддин менла" әсәрен (1886) тудыруга китерде. Аңа табигый рәвештә З.Бигиев романнары һәм сәяхәтнамәсе килеп кушылды. Гасыр азакларында бу башлангычны Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, Г.Исхакый һәм башка әдипләр уңышлы дәвам иттерде. Кыскасы, З.Бигиевнең әдәбиятка килүе һич тә очраклы хәл түгел, ә татар рухи үсешенең зарури бер буыны, баскычы иде. Кайбер авторлар аның урыс, Аурупа әдипләреннән файдаланып язуын искәртәләр. Мәсәлән, Муса Бигиев "Өлүф..." романының "Погоня за миллионами" исемле урыс әсәренә ияреп иҗат ителүен әйтә. Ф.Әмирхан да шул фикерне куәтли. "Бу романнарның һәр икесен дә, — ди ул, — мөәллиф *(автор, язучы.— Х.М.)* рус әсәрләренә тәкълид итеп, бәгъзән дә бөтенләй рус типларын татар ясап чыгарадыр" *(Әдәбиятка гаид // Әлислах.— 1908.— 8 сентябрь).* М.Гайнуллин "Гөнаһе кәбаир" романының француз әдибе Эмиль Габорио *(1832-1873)* әсәрләреннән *("Господин Лекок", "Преступление в Орсивале" һ.б.)* файдаланылып язылуын ассызыклый *(Совет әдәбияты.— 1945.—9 нчы сан.— 81 б.).* Күчеш чорында башка халыкларның әдәби казанышларына мөрәҗәгать итү, алардан теге яки бу дәрәҗәдә файдалану мәдәният тарихында табигый һәм гадәти хәл. Пушкинның Байрон иҗаты белән кызыксынуы да—шуның күркәм бер мисалы. Тәнзыймәт чорындагы госманлы әдипләре дә француз әдәбиятыннан шактый мул файдаланалар, үзләре әйтмешли, "франк каһарманнарын госманлаштыралар".

З.Бигиев эшчәнлегенең әһәмияте шунда: ул, үз халкының һәм башка кавемнәрнең эстетик казанышларына таянып, Муса Акъегетзадә белән берлектә, милләттәшләре кызыксынып укырлык, татар сүз сәнгатенең заманча үсешен билгеләрлек әсәрләр тудырды. Нәкъ менә шуңа күрә дә аларны шул чорда ук "яңа әдәби, агымның җимеше" *(Тәрҗеман.— 10.08.1890),* "әдәбият бәһарыбызның *(язының.— Х.М.)* иң әүвәлге чәчәкләре" *(Тукай),* татар телендә "роман диярлек әсәрләрнең әүвәлгеләре" *(Ф.Әмирхан)* дип атыйлар да.

"Бу романнарда,— ди Ф.Әмирхан,— камилән, татар тормышыннан алынган типлар *[бер-икене истисна белән (исәпкә алмаганда.— Х.М.)]* юк дияргә мөмкиндер. Шулай да булса, бу әсәрләрдәге типларны Заһир Бигиев, булачак мәгыйшәтне алдан сизенеп чыгарган шикелле, вөҗүдкә чыгарадыр. Муса вә хатынына *(ягъни Маһруйга.— Х.М.),* җинаяте соңында да, гуманный мөгамәлә итеп гафу итә алырлык хөр фикерле татар *(биредә Җиһангир образы күздә тотыла.— Х.М.)* менә бу көннәрдә генә вөҗүдкә килә башларлык типлардыр. Шулай итеп, бу романнар кыйсмән *(өлешчә.— Х.М.)* безгә яз якынлашканын күрсәтә торган кышкы якты кояшлы көннәр булып хезмәт

иткәннәрдер. Заһир әфәнде, әгәр гомере мөсагадә *(мөмкинлек.— Х.М.)* иткән булса, бәлки дә бик үткен милли әсәрләр вөҗүдкә китергән булыр иде" *(Әлислах.— 8.09.1908).*

Әмма Ф.Әмирханның миллилек турында бу искәрмәләре бераз бәхәсле дә. Чөнки З.Бигиев романнарында, аеруча "Гөнаһе кәбаир"да татар мәгыйшәте, татар рухы шактый тулы гәүдәләнеш тапкан. Мәсәлән, карт хәзрәтнең укырга китүче Габделгафурга биргән теләкләре тулысы белән ислам дине, милли гореф-гадәтләр рухында. "Һәлакәт юлы, яманлык вә кимлекнең башы һәм чыганагы—шул хәрам исерткечтер", диелә анда. Шулай ук карт "зур гөнаһлар"ның "аз-азлап башланып", аннан "күбәеп вә куәтләнеп" китүен искәртә. Мәгълүм ки, татарның бер өлеше элек-электән шәһәрләрдә башка халыклар белән аралашып яши. З.Бигиев шундый тормышны гәүдәләндергәндә, әлбәттә, милли персонажлар белән генә чикләнә алмый. Аның әсәрләрендә Муса, Габденнәсыр, Зөләйха образлары белән беррәттән, Андреев, Шубин кебек затларның да сурәтләнүе нәкъ шуның белән аңлатыла. Бу яктан автор XIX йөзнең икенче чирегендә иҗат иткән Гомәр Мөхәммәд углы традицияләрен дә дәвам иттерә. Романнарда аерым кимчелекләрнең булуы авторның яшьлеге, иҗади тәҗрибәсе җитмәү белән дә аңлатыла.

З.Бигиев— халкыбызның зирәк, гыйлемле вәкиле. Шуңа күрә ул нәрсә турында язса да, аны, иң беренче чиратта, үз милләтенең язмышы, хәле борчый. Автор үз халкын ярата, аны алдынгы, тәрбияле итәсе килә. Әмма ул милләтпәрвәр булса да, үз халкына тәнкыйди күзлек аша да карый. Мондый алым алга таба Г.Исхакый, Г.Тукай, Ф.Әмирхан тарафыннан аеруча нәтиҗәле кулланылды.

З.Бигиевнең һәр ике әсәре дә детектив характерда, ягъни җинаять кылу һәм аны ачуга юнәлтелгән. Бу, бер яктан, укучыны мавыктыруны күздә тотса, икенче яктан, гадәти булмаган, киеренке шартларда кешеләрнең холык-табигатен, үз-үзен тотышын, үзгәләр белән мөнәсәбәтен тулырак ачырга мөмкинлек бирә. Шунысын да искә төшерик: З.Бигиев ахун гаиләсендә туып үскән, үзе дә шул вазыйфаны башкарган. Гадәттә, андыйларга шәһәр һәм округ судларында катнашырга, төрле җинаять эшләре белән танышырга туры килгән. Шуңа күрә автор андый вакыйга-хәлләрне шактый белеп тасвирлый.

Һәр инсан үз гамәле өчен үзе җаваплы. Бу әхлакый принцип — Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбиятының төп сыйфатларыннан берсе, З.Бигиев өчен дә катгый канун. Зөләйха, Габденнәсыр, Ягъкуб Галиев һәлакәтләрен, Габделгафурның төрмәгә эләгүен автор, иң беренче чиратта, аларның үзләренә бәйләп карый. Әмма З.Бигиев тирәлек, мохитнең дә кешегә тәэсир итүен аңлый, инсанны табигый яктан гына түгел, иҗтимагый-социаль мөнәсәбәтләр җимеше рәвешендә дә карый. Шунысы мөһим: автор кешенең үзгәрүенә, камилләшүенә ышана. Маһруй, мәсәлән, үз гамәлләре өчен җәзага тартыла, газаплар кичерә, тәүбә кыла, "кабат терелеп", рухи яктан пакьләнә.

З.Бигиев тугрылыкны, әхлакый сафлыкны, иманлылыкны яклый, эчүчелекне, икейөзлелекне, җинаятьчелекне, фәхешлекне кискен тәнкыйть итә. Татар әдәбиятында алга таба төп проблемаларга әверелгән мәсьәләләрнең бер өлеше "Өлүф..."тән, "Гөнаһе кәбаир"дан яисә алар аркылы юл ала.

З.Бигиевнең "Мавәраэннәһердә сәяхәт" язмасы татарның һәм әдәбияты, һәм публицистикасы, һәм гомумән рухи тормышы өчен аеруча әһәмиятле. Ул, бер яктан, авторның өлгергән шәхес икәнлеген, күңел дөньясын күрсәтсә, икенче яктан, тарихның, сәясәтнең гыйбрәтле сәхифәләрен ачып бирә. З.Бигиев моңа кадәр татар табынып яшәгән Төркестанның мәгълүм сәбәпләр аркасында гадәттән тыш артта калуын, андагы кавемнәрнең хокуксызлыгын тасвирлый. Сәяхәтнамәдә патша хокүмәтенең традицион колониаль сәясәте, аның рәхимсезлеге күрсәтелә.

"Мавәраэннәһердә сәяхәт"— әдипнең җәмгыять, тормыш, мәдәният, милләт турында уйлануларының бер хисабы, килер буыннарга бер васыяте.

* * *

Мәгълүм ки, Тукай — тәнкыйди рухлы шагыйрь. Аның мактавына, хөрмәтенә бик сирәк затлар гына лаек була: Мәрҗани, Ямашев... Шундыйлар арасында Заһир Бигиев тә бар. Бу күп нәрсә хакында сөйли. Тукай "Төшемдә күргәннәрем" исемле язмасында (1908) әдипне "ахирәттәге сарайда" күрүен искәртә. Имеш, ул сарайның диварларына, идәнтүшәмнәренә алтын хәрефләр белән әдипнең әсәр исемнәре язылган.

Тукай "Мавәраэннәһердә сәяхәт" язмасын кулъязма хәлендә үк укып чыга һәм, шуннан илһамланып, үзенең мәшһүр "Мәрхүм Мөхәммәдзаһир әфәндегә" дигән мәрсиясен яза. Бу шигырь "Мавәраэннәһердә сәяхәт"нең тәүге басмасында (1908) алгы өлештә үк урнаштырыла.

... Гәрчә "үлде" дисәләр дә, син бөтенләй үлмәдең;
Яхшы исмең калды, син мәнсийү мәтрүк улмадың
*(Ягъни: "онытылып калмадың".—Х.М.).*

... Иртәрәк милләтне сәүкайлар *(сәвык әйләр — алга әйдәр.— Х.М.)* идең чын әзгә син!
Нинди гали *(бөек.— Х.М.)*, нинди зур эш эшләр идең безгә син!

Шунда да исмең синең милләт яшәдекчә яшәр,
Милләт үсдекчә үсәр һәм милләт ашдыкча ашар
*(ягъни: һаман югарыга ашар.— Х.М).*

Бөек Тукайның мондый бәясенә лаек булган Заһир Бигиев,— чын мәгънәсендә, бәхтияр әдип. Аның әсәрләре даими укыла, исеме милләт белән бергә "аша", ягъни бергә бара, бергә яши.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*филология фәннәре докторы.*

*Фән*

# ТУРЫ СҮЗЛЕ, БАШ БИРМӘС ШӘХЕС

## ТАРИХЧЫ ГАЛИМ ӘГЪДӘС БОРҺАНОВКА 80 ЯШЬ

**1965 елда** Казан дәүләт университетына аспирантурага кергәч, партия тарихы кафедрасы житәкчесе, профессор (хәзер Татарстан фәннәр академиясенең академигы) Рафикъ Измайлович Нәфыйгов мине үзенә чакырып:

—Сезнең тема буенча бездә бер генә кеше эшли, ул Әгъдәс Хөсәенович Борһанов,—диде.

Шуннан соң мин булачак житәкчемне эзләп таптым. Ул Казанның Горький урамында Татар Дәүләт академия театры янындагы йортта яши иде. Беренче очрашуыбыз аның фатирында шактый рәсми төстә узды, әлләни озакка да сузылмады. Минем өчен иң мөһиме—житәкчелек итәргә аның ризалыгын алдым.

Безнең алга таба фәнни эшчәнлегебез-хезмәттәшлегебез ул Мәскәүгә киткәнгә кадәр бергә барды. Хәер, ул Мәскәүдә яшәгәндә дә бер-беребезнең хәл-әхвәлен белешеп, сирәк булса да очрашып торабыз. Әйтергә кирәк, хәзер мин үзем дә аспирантларга житәкчелек итәм һәм бу эштә остазымның карашларына таянам. Алар шуннан гыйбарәт: кыюлык, дөреслек, намусыңа хыянәт итмәү.

Хакыйкать, намус дигәннән, аның белән булган бер сөйләшү колагымда яңгырый кебек. 1966 елның октябрь ае, ә Борһановның докторлык диссертациясен якларга әзерләнеп йөргән көннәре иде. Диссертация темасы—«Октябрь революциясе һәм вак буржуаз партияләр. 1917 ел март-ноябрь айлары». Зур күләмле, саллы хезмәт. Һәрберсе 600 битлек ике томлык бу хезмәтнең кайбер битләрендә саннар-даталарны ачыклауда аңа булышырга алындым. Бу эш белән шактый утырдык без. Диссертациянең тарихи хезмәтләргә күзәтү-анализ бүлегендә Әгъдәс Борһанов Мәскәү тарихчылары—Ижтимагый Фәннәр академиясе кафедрасы мөдире И. Ф. Петровны, КПСС Үзәк Комитеты бүлек мөдире С. П. Трапезниковны һәм шулай ук П. Н. Соболев, Д. Коваленко кебек галимнәрне, әлбәттә, Йосиф Сталинны да шактый нык тәнкыйть иткән иде.

Бераз шүрләп:

—Әгъдәс Хөсәенович, болай ук тәнкыйтьләгәч, сезнең эшегезне расламаулары мөмкин бит,—дип әйткәнемне сизми дә калдым (Хәер, шөбһәләнеп әйткән сүзләрем, кызганыч ки, рас килде. Чыннан да, аның эшен 24 ел дәвамында Югары аттестация комиссиясе (ВАК) расламый тинтерәтте.). Әмма фәнни житәкчем бераз уйланып:

—Юк, үзгәртмим, язылганча калдырачакмын,—диде.

—Нигә инде алай үзегезне удар астына куясыз?—дип сорадым.

—Башкача эшләргә минем фәнни намусым кушмый,—дип сүзен төгәлләде Әгъдәс Хөсәенович.

Әйтергә кирәк, аның кайберәүләр тарафыннан гади үжәтлек дип бәяләнгән фәнни намуслылыгы диссертациясен яклау вакытында да һәм тагын 24 елга сузылган көрәшендә дә ачык расланды.

Дөрес, аның диссертациясе университет гыйльми советында зур алкышлар белән якланды. Әмма шуннан соң ул шактый гыйбрәтле хәлләргә сәбәп булды. Өнәмәүчелек жиле аның диссертациясе язмышын хәл итү белән генә чикләнмәде, Ә. Х. Борһановның аспирантларына да кагылып узды. Аны без 1967 елның сентябрендә үк сизә башладык. Аз гына алданрак яклаганлыктан, минем диссертациям андый каһәрләнүгә эләкми калды. Ә инде М. А. Мөлеков, М. Х. Хәйдәров, В. Н. Николаевка кыенга туры килде. Алар Казанда яклаган кандидатлык диссертацияләрен раслату өчен ике ел Мәскәү юлын таптадылар. ВАКка барып, һәркайсы

диссертациясен тагын бер тапкыр якларга мәҗбүр булды. Безнең фәнни житәкчебездән намуслылыгы өчен менә шулай үч ала башладылар...

Тиздән «Коммунист» журналында жимергеч мәкалә пәйда булды. Конкрет атап әйтмәсәләр дә, «кайбер» галимнәргә «троцкист» һәм башка ярлыклар тага башладылар. Шәхес культы шаукымы кабат уяна, баш калкыта башлады. Күп тарихчылар тындылар, кәтеп тору позициясенә күчтеләр... Әмма Әгъдәс Хөсәенович, чын галим буларак, фәнни эзләнүләрен туктатмады, яңа аспирантлар туплады (ул барысы 10 фән кандидаты әзерләде, шулардан икесе инде фән докторы, өчесенең докторлык диссертациясе әзер), студентлар аның артыннан кәтү-кәтү булып йөри, аның лекцияләре тирән эчтәлекле һәм кыю фикерләргә бай була иде.

Югары аттестация комиссиясе (ВАК) шулай ук үз эше белән мәшгуль: фәнни этиканың иң гади нормаларын да бозып, Ә. Х. Борһановның диссертациясен рецензияләү өчен ул тәнкыйтьләгән галимнәргә тапшыра! Алардан фикер туплаужыю өчен 16 ай вакыт кирәк була. Большевиклар революциядә үзләренә якын торган вак буржуаз партияләр белән хезмәттәшлек итәргә мөмкин иде, дигән ленинчыл положение катып калган сталинчы тарихчыларга ошамый. Үзгәртеп кору чорында Ә. Борһанов бу хакта «Вопросы истории» журналында болай дип язды: «Рецензентлар тәнкыйтенең бөтен пафосы хезмәтемдәге шәхес культына каршы ориентациягә юнәлдерелгән иде. Алар Сталинның төп ударны демократик партияләргә юнәлдерүен кагылгысыз итеп калдырырга теләделәр». «Озакка сузылган эш» дигән бу мәкаләсендә ул үз хезмәтенә карата гаделсез тәнкыйтьне тулысынча кире кага.

Хәер, ул аны 1967 елда ВАКның эксперт комиссиясендә дә кире кагучы, ВАКның ул вакыттагы рәисе В. П. Елютинга диссертациясен ВАК пленумында карауны сорап мөрәҗәгать иткән. В. П. Елютин, аны кабул итеп: «Диссертациягез Казан университеты ректорына кире соратып алырга тәкъдим ителде»,—дип белдергән. Ижтимагый Фәннәр академиясе галимнәренең аңа каршы кампания оештырулары уңаеннан Ә. Х. Борһанов Л. И. Брежневка да мөрәҗәгать итә. Моның нинди файдасы булды дисезме? Шул ук 1967 елда басарга дип кул куелган монографиясенең наборы таратыла. Университет нәшриятында Әгъдәс Хөсәенович үтенече белән бу китапның корректурасын берничә көн үзем укыдым. Ул үз заманы өчен бик кызык һәм хәтәр язма иде. Сталинга, Троцкийга кагылышлы урыннары һич тә гадәттәгечә түгел, тәнкыйть күзлегеннән чыгып янача язылган иде. Большевиклар, меньшевикларга булган бәяләр дә үзгә иде. Авылдагы крестьян инкыйлабы да коммунистлар һәм Сталин язганча түгел, ә Ленин язганчарак иде. Кыскача гына әйткәндә, авылда инкыйлаб 1917 елда түгел, ә бары тик 1918 елда гына булды, диелгән иде.

Безнең университетның ректоры Михаил Тихонович Нужин чын галим-профессор иде. Ул тыныч, сабыр холыклы. Ул һәркемне дикъкать белән тыңлый, кулыннан килгәнчә булышырга әзер тора, күп вакытта бәлагә тарган галимнәрне коткарырга көчен, вакытын кызганмый иде. Аның Әгъдәс Борһановка мөнәсәбәте дә шулайрак булды. Ул аның белән даими аралашып торды. Әлбәттә, монда Ә. Борһановның берара партиянең өлкә комитетында вузлар бүлеге мөдире булып эшләве дә тәэсир иткәндер. Фикер ияләре буларак, алар икесе дә партиянең тар кануннары белән бик үк санашмаска тырышты. Докторлык диссертациясен яклау алдыннан ректор Ә. Борһановка журналистлар кафедрасының мөдире урынын тәкъдим итә, әмма Борһанов моннан баш тарта.

Кайсыбер көннәрне алар сәгатьләр буена фикер алышып утыралар. Коммунистлар партиясенең тарих кафедрасы доцентының башкалардан аерылып торган фикерләре ректор өчен, әлбәттә, кызыклы була. Математика галиме М. Нужин Ә. Борһановның яңача карашларын тиз шәйләп ала. Шулай бер сөйләшеп утырганда ректор аңа:

—Әгъдәс Хөсәенович, лекцияләрегезне бик иркен укыйсыз, артык кыю фикерләр ычкындырасыз, дип сөйлиләр. Сөйләгәннәрегезне язып алып, тиешле оешмаларга да житкерәләр икән,—ди.

Әгъдәс Борһанов болай җавап бирә:

—Мин советка каршы сүз сөйләмим: бары тик партияне һәм социализмны Ленинча яхшыртырга гына телим.

Бу чорда Ә. Борһанов аларны яхшыртып булмаячагын аңлау дәрәҗәсенә житмәгән була әле. Ул моны соңрак аңлаячак. Бу үзсүзле татар доцентының кыю

җавабын тыңлап утырган ректор тагын да җитдирәк төс белән:

—Шушы көннәрдә генә мина өлкә комитеты секретаре янында булырга туры килде,—дип сүзен дәвам итә. Үзсүзле татар егетен тикшергән сымак, тукталып калып, әйтер сүзен әйтми тора да кырт итеп:—«Сез ул троцкист Борһановны кайчан эштән куарсыз?—дип сорады секретарь.—Ректор, гадәтенчә тамак төбен кыра-кыра, коры йөткерү белән йөткереп ала. Әсәрләнгәндә, дулкынланганда йөткереп җәфалана иде мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын.

—Ә сез нәрсә дип җавап бирдегез соң?—дип сорау бирә Борһанов, бер дә исе китмәгән кыяфәт белән.

—Минме?—дип аның сүзен бүлә Нужин. Ул, кесәсеннән кулъяулыгы алып, мангаен, битен сөрткәләп, тагы «ых, ых» йөткергәләп куя:—«Сез үзегез куалагыз, ул бит сезнең кадр!»—дидем мин аңа.

Икесе дә сүзсез тынып калалар. Тынлыкны тагын ректор боза. Ул:

—Мин аңа әйттем: без аны бер мәртәбә, срогы җитми торып сайлау уздыру юлы белән, 1964 елны эшеннән куган идек—барып чыкмады. Лекцияләрендә укыту эшләрендә җитешсезлекләре булмаганлыктан, Мәскәү янадан кайтарды,—дидем.

Өлкә комитеты җитәкчеләре, Әгъдәс Борһановны болай да җинә алмагач, сонрак башка институтларга «ычкындыру» турында уйлана башлый. Башта аны финанс-икътисад институтына күчермәкче булып маташалар, әмма андагы кафедра хуҗасы «Без аны ала алмыйбыз, чөнки коллектив каршы»,—ди. Консерватория ректоры Нәҗип Җиһанов: «Без дә ала алмыйбыз, безнең уку йорты иҗади, махсус ВУЗ»,—дип кире кага.

1968 елда КПСС Үзәк комитетының фән бүлеге мөдире С. П. Трапезников «Борһанов эше» белән үзе җиң сызганып шөгыльләнә башлый. Бу турыда Әгъдәс Борһанов үзе болай сөйли:

—1968 елның ахырында КПСС ҮК фән бүлеге мөдире С. П. Трапезников Ә. Х. Борһановның докторлык диссертациясенә багышланган киңәшмә үткәрде. Киңәшмәдә академик И. И. Минц, СССР Фәннәр Академиясенең тарих бүлеге академик-сәркатибе Е. М. Жуков, КПСС ҮКнең фән бүлеге секторы мөдире В.Т. Долгих, СССР Фәннәр Академиясенең СССР тарихы институты парткомы сәркатибе П. В. Волобуев диссертациянең оппоненты профессор Ф. Т. Константинов катнашты. Күрдегезме, нинди тузлар! Һәм... мин—бер «кечкенә шөреп», диссертант Ә.



*Утырганнар (сулдан уңга): Әгъдәс Борһанов, Мархан Хәйдәров (үзбәк галиме). Басканнар: Рәмзи Вәлиев, Марат Мөлеков, Борис Николаев. 1960 еллар азагы.*

Борһанов... Трапезников башта Константинов, Минц һәм Волобуев фикерләрен тыңлады. Иң сәере шул, болар һәр өчесе Ә. Х. Борһановның диссертациясенә КПСС ҮК каршындагы Иҗтимагый Фәннәр академиясенең кайбер профессорлары гадел булмаган тәнкыйть белән чыкканнар, шуның аркасында Ә. Х. Борһановның фән докторы дәрәҗәсе алуы ВАКта тоткарлана, дип сөйләде.

Шуннан соң Трапезников минем диссертациянең ВАК аша үтүен үзе тикшерәчәген әйтте һәм минем... кинәшмәдән чыгып китүемне үтенде. Мин чыктым, кинәшмә тагын бер ярты сәгать дәвам итте шикелле. Соңыннан Константинов белән Волобуев миңа сөйләделәр: Трапезников, бу Борһановка башта докторлыгын якларга кирәк булган, аннары инде бүтән галимнәрне тәнкыйть итсә дә ярар иде, дигәнрәк фикер әйткән икән.

Бу урында шуны да өстәп куярга кирәк: Әгъдәс Борһановның диссертациясендә С. П. Трапезниковның ике томлык хезмәтенә дә «эләгә». Октябрь инкыйлабы чорындагы аграр мәсьәләләрне сталинчыл карашлардан торып бәяләгән хезмәт була ул. Әлбәттә, Ә. Борһанов аны «сүтеп» ташлый.

КПСС ҮКнең фән бүлегендә гаделлек эзләүче галимгә менә шулай «ярдәм» итәләр.

Бу авыр чорда без Әгъдәс Хөсәенович Борһанов белән тагын да якыная төштек. Һәр кич очрашып, бәхәсләшә, мәсьәләләрне уртаклаша идек. Өстәвенә бер үк вакытта икебезнең дә хатыннарыбыз авырып китте. Тиздән Әгъдәс Хөсәеновичның хатыны вафат булды. Бәла дигән нәрсә кешегә бер килсә, бер-бер артлы килә икән ул...

—Җитмешенче еллар азагында—дип искә ала Әгъдәс Хөсәенович—диссертациядәге аеруча бәхәсле дип саналган мәсьәләләр теге яки бу формада расланганнан соң, фәнни хезмәтемне яңадан карауларын үтенеп, кабат ВАКка мөрәҗәгать иттем. ВАК диссертацияне яклау материалларын Казаннан соратып караган иде, аларны таба алмадылар. Шуннан соң КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Партия Контроле Комиссиясенә апелляция бирдем. Яклау материаллары «табылды», ул КПССның Татарстан өлкә комитеты секретарьларының берсенең өстәл тартмасында яткан. Аны ВАКка җибәрделәр, тик диссертация үзе «югалган» булып чыкты. Шунлыктан ВАК аны яңадан карау мөмкин түгел дип тапты.

Ниһаять, Әгъдәс Борһанов көткән чор житә.

1988 ел. СССР Фәннәр Академиясенең Фәнни советы Бөек Октябрь социалистик революциясенең комплекслы проблемаларын өйрәнү буенча мәсьәлә күтәрә. Бераз соңрак Мәскәү Тарих-архив институты белән Казан университеты гыйльми советлары да бу мәсьәләне кузгата. Бу юлы университетның бер бүлегендә «Для служебного пользования» дигән гриф белән «ябылып» яткан диссертация дә «табыла». Әйе, Ә. Х. Борһанов диссертациясе.

1989 ел. Безнең гыйльми советтан Ә. Х. Борһановның үзе һәм аның хезмәтләренә карата фикеребезне белдерүне сорадылар. Бу әлбәттә, табигый хәл иде, чөнки ул диссертациясен бездә яклаган, байтак еллар бездә эшләгән, безнең кеше иде. 1998 елның 23 февралендә тарих факультеты гыйльми советы утырышында бу мәсьәләне карадык. Анда, профессорлардан И. Р. Таһиров, Г. Н. Вульфсон, А. Л. Литвин, доцентлар Р. К. Вәлиев, Р. А. Шәйхиевләр чыгыш ясап, бертавыштан Әгъдәс Хөсәен улы Борһановның «Бөек Октябрь революциясе һәм вак буржуаз партияләр» дигән докторлык диссертациясе өчен аңа докторлык дәрәҗәсе бирү турындагы мәсьәләне Югары Аттестация Комиссиясе алдына яңадан куярга дигән фикергә килделәр. Шундый ук карар да кабул ителде. Бу карарны университет гыйльми советы да хуплады.

Ниһаять, Әгъдәс Хөсәен улы Борһанов—тарих фәннәре докторы! Җитмеш яшен тутырган көннәрдә аны Мәскәү Тарих-архив институтында профессор итеп тә сайладылар.

* * *

Хәзер Әгъдәс Борһанов Мәскәүдә яши. Бер уйласаң, кызык бит: ни өчендер, үз төбәгендә кыерсытылганнарга шул Мәскәүдә урын табыла. Әлбәттә, Ә. Борһановны Мәскәү махсус чакыртып алмады. Ул анда үзе китәргә мәҗбүр булды. «Телен тыя алмаган», яисә теләсә кемгә уйлаганын әйтергә батырчылыгы җиткән галим, үз Казанында тынычлык булмагач, ни эшләсен?!

Бу аның өчен бик авыр вакытлар иде. Хәләл җефетенең вафат булуы аның хәсрәтләрен тагы да арттырды. Мин укытучымның фатирыннан ерак тормый идем. Әгъдәс Хөсәенович һәр кич диярлек безнең тулай торакка килеп керә дә:

—Исәнмесез, Люция ханым!—дип елмаеп хатыным белән озаклап сөйләшеп утыра иде. Соңыннан икәү генә калгач:

—Рәмзи, ай-һай акыллы хатының!—дип мактап та куя.

Мин ана үзем ясаган эчемлекне тәкъдим итәм. Ул аз гына эчә.

—Әйдә бакчага киттек,—ди. Без өчәү Горький бакчасына барып һава сулыйбыз. Туктап-туктап һавадагы йолдызларны саныйбыз, сөйләшәбез, хыялланабыз. Әйтерсең лә берни булмаган... Әгъдәс Хөсәенович һәрвакыт тыныч йөзле, уяу фикерле булып калды. Бер вакытта да зарланмады. Эче пошкан көннәрендә Фукс бакчасы янындагы чаңгы базасыннан Дәрвишләр бистәсенә кадәр чаңгыда йөреп кайта да:

—Менә, Дербоградка барып килдем әле—ди. Үзенең бите алмадай кызыл, аркасы тирләгән...

Озакламый Ә. Борһанов Мәскәүдәге Гражданнар авиациясе инженерлары институтына эшкә урнашты.

Монда эшкә урнашу да Казандагы кебегрәк каршылыклар белән бара. Ул үзе бу турыда шаяртып:—Казан мескеннәрен миңа эш табудан коткарырга булдым, җәлләдем, кызгандым үзләрен,—дип сөйли.

Мәскәүгә барып төшкәч тә институттан институтка йөгерә остазыбыз. Вакыт тиз уза, кесәсенең сайлыгын да искә алсаң, безнең галимебез бөтенләй авыр хәлдә кала. Бар ышаныч—дус-ишләр, фикердәшләр, танышларда. Әгъдәс Борһановны ул вакытта ук күпләр белә иде инде. 1999 елның март аенда, Әгъдәс Хөсәенович Казан санаториенда ял иткән көннәрдә мин аннан Мәскәүгә китүе турында сөйләвен үтенгәч, ул:

- Ярый, мин сиңа язып бирермен,—диде. Тиздән без аның белән минем эш урынымда, тарих факультетының декан кабинетында очраштык. Ул кызыклы гына язма алып килгән иде. Текст урысча язылган, без аны татарча китерәбез.

«... 1973 елны мин Мәскәүгә китеп бардым.

Табигый ки, бөтенләй күченеп китәргә җыенганчы, иң әүвәл эш табарга кирәк иде. КПСС ҮК каршындагы Югары партия мәктәбенең читтән торып уку бүлегендә дустым В. Н. эшли иде. Ул кафедра мөдире белән мине эшкә алу турында сөйләште. Моны КПСС ҮКнең Фән бүлеге ризалыгы белән эшләргә кирәк булды. Мин, шундагы күптәнге танышым, оештыру бүлеге мөдиренең беренче урынбасары Н. К. га мөрәҗәгать итеп, аның югары партия мәктәбенә шылтыратып алуын үтендем. Ул исә миңа болай дип җавап бирде: «Кадерле Әгъдәс Хөсәенович, син, безнең тәгълимат белән яраша алмаган хаталарыңны танып, бер мәртәбә дә матбугатта чыгыш ясамадың, төп коммунистик журнал булган «Коммунист» битләрендә сине тәнкыйть итеп чыккан күренекле галимнәребез фикере белән килешмәдең, инде хәзер югары партия мәктәбендә эшләргә телисеңме? Синең оппортунист икәнеңне белмәгән берәр тынычрак пединститут яки техник вузда урын тап!»

Югары белем министрлыгында да күптәнге танышларым бар иде, анда методика идарәсенә инспектор кирәк икән, мине шунда «кодаладылар». Бөтен кирәкле ишек-тишекләрне үттем, партком секретаре белән генә очрашасым калды, әмма ул авырый иде. Шулай да министрлык коллегиясендә мине эшкә раслау көне билгеләнде. Шунда килдем, партком секретаре дә терелгән. Ул үзе башкорт, КПСС райкомы бюросының әгъзасы һәм алыштыргысыз партком секретаре икән, хәзер фамилиясен хәтерләмим инде. Коллегия утырышы алдыннан ул мине чакырып алды да: «Сез «Коммунист» журналы тәнкыйтьләгән Борһановмы?»—дип сорады. «Әйе,—дидем,—шул үзе». Аның башка сораулары юк иде. Коллегия утырышы булмый калды.

Шул ук таныш-белешләрем аннары мине Гражданнар авиациясе институтына тәкъдим иттеләр, кочак җәеп каршы алмасалар да, мин шунда эшләп киттем».

1973 елны бу хәлләрне без белми идек шул. Ә. Борһановның Казанда калган шәкертләре Марат Мөлеков, Владимир Бохараев белән без, унайсызлыклар сизсәк тә, бирешмәдек, тавыш-тынсыз эшкә керештек.

Мин булачак докторлык диссертациямнең кулъязмасын 1976 елда университет нәшриятына тапшырдым, әмма ул анда дүрт ел ятты. Нәшриятның директоры Әскәр Хәйретдинов мине бик якын итә иде. Университетның комсомол комитетында мин

секретарь чагында ул идеология комиссиясенең житәкчесе иде, ә университет бетергәч, нәшрият директоры булып китте. Монографиянең листажын да ул биргән иде. Тоткарлау мәсьәләсе аннан тормады, киресенчә, ул булмаган булса, минем монографиям дөнья да күрмәгән булыр иде, бәлкем. Хезмәтем «Назревание общенационального кризиса и его проявление в Поволжье и на Урале в 1917 году» дип атала. Әлбәттә, ул елларда «кризис» сүзе хакимият башындагыларга һич ошамый иде. Бары тик сиксәненче еллар ахырында гына бу мәсьәләләр актуаль булып китте һәм мин, биш ел Мәскәү юлын таптаганнан соң, 1990 елда Екатеринбургта докторлык диссертациясен якладым. Менә шул вакытта тагын бер мәртәбә остазымны искә алдым, ә бит аның диссертациясен 24 ел буе расламадылар. Ничек түзгәнен Әгъләс Хөсәенович үзе генә беләдер инде...

Шуны да әйтеп узарга кирәк. Ә. Х. Борһанов диссертациясен сейфка салып куйгач, газет-журналларда аны тәнкыйтьләү башлангач, безнең факультет каршындагы докторлык диссертацияләрен яклау Советын да яптылар. Эшләр авырайганнан-авырая барды. 1980 елда язган хезмәтем 1990 елга кадәр портфелемдә йөрде. Хәтта: «Рәмзидә кризис»,—кебек шаяртулар да булгалады. Чыннан да...

Житмешенче еллар азагында Бионика лабораториясендә уңышлы эшләп килгән хатыныма да унайсызлыклар туа башлады. Физика факультеты деканы, мәрхүм Поминов: «Лаборатория житәкчесе сезнең хатыныгыз өстеннән көн саен деканатка яза башлады»,—дигән иде. Бу Люциянең кандидатлык диссертациясен яклап, докторлык диссертациясен эшләгән чаклары иде.

—Аның житәкчесе белән ничек сөйләшергә соң?—дип сорадым.

—Иң яхшысы, бәйләнешмәскә... эштән китәргә кирәк... Ахыры начар булуы мөмкин,—диде декан. Шулайрак булды да. Хатынымның үзенә әйтми генә Совет уздырып, эшеннән азат иттеләр. Ул шикаятьләр белән йөрмәде, мин дә кинәш итмәдем.

Михаил Тихонович Нужин монда да безгә булышу юлларын эзләде. Ниһаять, хатынымны биология факультетына доцент итеп «Биофизика» курсын укырга чакырдылар. Бу инде аны аклау иде. Шулай итеп «троцкист-оппортунист» Ә. Х. Борһанов жилләре безгә дә кагылгалап узды. Кафедрабыз мөдире И. М. Ионенко хәлемне аңлады, артык борчымады. Дустым И. Таһиров һәр көн диярлек сораштырып торды, Алексей Литвин, Булат Солтанбәков, Марат Мөлеков һәм башкалар рухи көч биреп, теләктәш булдылар. Ниһаять, 1990 елны китабым дөнья күрде. Әлбәттә, аңа чын күңелдән шатланган кеше Әгъләс Хөсәенович Борһанов булды.

—Молодец, Рәмзи, булдыргансың!—диде ул. Бу минем өчен барлык рецензияләрдән дә зур бәя иде инде. Шатландым.

—Эх! Сез монда булып, сезнең мәктәбегез тагын да үскән булса иде...—дидем.

Ул елмаеп:

—Ерунда! Мәктәпсез дә әйбәт эшлисез бит,—диде.—Әнә Марат Мөлеков, Володя Бохараев эшли, Мурхан Хәйдәров,—дип санап китте.—Павел Васильевич Волобуев бик булыша,—диде ул.—Беләсең бит, ул «Хлебная монополия» хезмәтен язган кеше. СССР тарихы институтының элекке директоры, академик...

Әйе, хәтерлим. Мин Мәскәү университетында аның янында булган идем. Ул анда Октябрь революциясе темасына багышланган махсус курс укый иде. Лекциясе тәмамлангач, тәнәфес вакытында аның янына килеп:

—Павел Васильевич, исәнмесез!—дидем. Ул кирәк кебек кулын сузып:

—Сез каян, кем буласыз соң?—дип сорады.

—Мин Вәлиев Рәмзи, Әгъләс Борһановның шәкерте, Казан университетыннан,—дигәч, көр тавыш белән үз итебрәк:

—Ә-ә-ә, гафу итегез инде мине, теге вакытта сезнең авторефератыгызга отзыв жибәрә алмадым бит,—диде ул.

—Павел Васильевич, инде һәммәсе тәртиптә, ВАК минем эшне хуплады. Хәзер мин сездән булачак докторлык диссертациямнең консультанты булуыгызны сорарга килгән идем,—дидем.

—Мин риза,—диде Волобуев. Диссертациянең темасын да хуплады, ә аерылганда кулын биреп:

—Казанга киткәндә шалтыратыгыз,—диде.

Күпме вакыт узгандыр, хәтерләмим, Павел Васильевич Волобуевны эшеннән

азат итеп. Табигать белеме институтына гади хезмәткәр итеп җибәрүләрен Әгъдәс Хөсәенович Борһанов аша белдем. Үзгәртеп кору елларына кадәр янадан тавышсыны ишетелмәде. 1987 елда гына «Выбор путей общественного развития: теория, история, современность» дигән зур хезмәте дөнья күрде һәм үзе дә яңадан тарих институтында эшли башлады.

Хәзер инде ул вафат булды. Бу зур кайгы иде. Ул кешелекле кеше, зур галим иде. Ә. Х. Борһановка 70 яшь тулган көннәрнең берсендә академик П. В. Волобуев шалтыратып:

—Әгъдәс Хөсәенович, сезнең докторлык диссертациясен раслау мәсьәләсен ВАКта яңадан кузгатсак, риза булырсызмы?—дип сорый ул.

—Риза, әйдә, бар гаделлек тантана итсен әле,—ди Ә. Борһанов.—Әмма үзем кыл да кыймылдатмыйм, туйдым.—Безгә сезнең ризалыгыгыз гына кирәк,—ди академик Волобуев.

Менә шуннан соң боз кузгала—аклау процессы башлана.

1996 елны Әгъдәс Борһановның «Кайлардан киләсең, кайларга барасың, Рәсәй?» дип аталган зур күләмле китабы дөнья күрде, ә 1998 елда ул татар телендә дә нәшер ителде. Бу китабында ул Октябрь революциясеннән соңгы чордагы Россиянең хәле һәм аның киләчәге турында сүз алып бара.

Үз вакытында академик П. В. Волобуев аның бу монографиясенә бәя биреп: «Аның яңа китабы Россиянең узганы һәм киләчәге турында тирән уйланулар нәтиҗәсендә туган. Ул Россиянең киләчәге өчен борчыла. Яңа китап озак еллар дәвамында тормышта дөреслек эзләүнең нәтиҗәсе»,—дип язган иде.

Әгъдәс Борһанов орден-медальләр белән бүләкләнмәде, макталмады. Ул беркайчан да, беркем алдында да билен бөкмәде, башын имәде. Хәтта артык горуррак та булгандыр, дип әйтсәк тә, ялгышмабыздыр.

Бу хезмәте әле аның барлык зыялылар тарафыннан да укылып, аңлашылып беткәндер, дип әйтү дөрес булмас. Әмма фикер алышулар булмады түгел, булды һәм ул дәвам итә.

Әйе, Ә. Х. Борһанов үзен көчле фикер иясе, эзләнүче һәм тынгысыз галим, көрәшче итеп күрсәтте.

Аның «Үзәк һәрвакыт эгоист булды» («Комсомольская правда», 1992 ел, 20 март), «Рус булмаган кешеләргә рус телендә сөйләшү мәҗбүри түгел» («Общая газета», 1993 ел, 19(21) нче сан), «Федерация милләтләр берлеге сыйфатында» («Утро России», 1995 ел, 17(77) нче сан), «Мин ни өчен татар?» («Идел» (русча), 1995 ел, 7-8 нче саннар, «Идел» (татарча), 1995 ел, 8 нче сан), «Россиядә татар диаспорасының киләчәге» («Панорама-форум», 1995 ел, 3 нче сан), «Безне бөгү мөмкин түгел» («Татарские края», 1996 ел, 36, 37, 39, 40 нчы саннар), «Европа Советына» («Татарские края», 1996 ел, 41 нче сан), «К вопросу о национальной идее» («Татарские новости», №7-8 (41-42) 1997 ел), «Федерацияме? Юк ул!» («Идел», 1999, № 2). Үзгәртеп коруга багышланган «Борһанов публицистикасы» әле туксанынчы елда ук чит илдә дә дөнья күрде. (Burga№ov Agdas. Perestroika a№d the co№cept of Moskow, 1990).

«Татар халкының киләчәге нинди?» («Татарстан», № 12, 1999) дип аталган мәкаләсендә ул: «...безгә, татар халкына, тарихи тупиктан чыгу юлын гамәлдәге системадан читтә эзләү зарур. Милләтнең үсешен, беренче чиратта аның икътисадының юнәлешен үзгәртергә кирәк», дип яза. Татар халкы бу эшне бары тик үз көченә генә таянып эшләргә тиешлеген әйтә. Россиянең бу эшне эшләргә теләге дә, икътисади хәле дә юк. Цезарь әйтмешли, үз-үзенә булыша алмаган Россия ничек итеп татар халкына булышсын? Бу эшне башкару өчен «бөтен халыкны тату, кешеләрне бөтенләй яңа сыйфатка ия итеп, Татарстанның үсешенә үз стратегиясе һәм тактикасы булырга тиеш». Ә. Борһанов фикеренчә, эшләрне матди нигез төзүдән башларга кирәк. Шул чагында гына ул базар мөнәсәбәтләре объектыннан шул мөнәсәбәтләрнең субъектына әверелә һәм милли капиталны булдыруда реаль төстә катнаша ала.

«Халык байлыгының байтак өлеше дәүләт бюрократиясе инициативасы белән малкуарлар кулына... күчсә дә, төп милли байлык әлегә дәүләт карамагында кала бирә. Республика карамагындагы бөтен байлыкны исәпкә алырга, анда һәр гражданның өлешенә тигән көмешен билгеләргә, аннары кыйммәтле кәгазь рәвешендә халыкка бирергә кирәк»,—ди ул. Шулай итеп, ул хосусый милекчелек

идеологиясен яклап чыга, хосусый милекчелек татар халкының киләчәгенә нык тәэсир итәчәген ышандырырлык итеп исбатлый, фәнни әдәбиятта мондый фикер яна гына әйтелгән булса да, чынлыкта ул татар эшмәкәрләре тарафыннан әле гасыр башында ук тормышка ашырыла башлаган. Әмма бу мәсьәлә әле аз өйрәнелгән, билгеле тарихи фактлар да онытыла бара иде. Гасыр башында ук инде татар эшмәкәрләре үз кулларында шактый матди байлык туплап өлгерәләр. Бу байлык табигый рәвештә хезмәт итеп, көч түгеп туплана. Фәнни терминология теле белән әйткәндә, бу юл—эволюцион юл, иң ышанычлы юл.

Бу уңайдан Мәскәү тарихчысы М. Водоланинаның татар халкына карата әйтелгән сүзләре кызыклы. Бер студентның: «Татар халкы нинди халык?»—дигән соравына ул болай дип җавап бирә:

«Татармы? О, ул мәһабәт халык!

Син аларның эшчәнлекләрен җәелдерергә мөмкинлек кенә бир, бөтен дөньяны кармап алачаклар. Әгәр Ульянов, үз вакытында килеп өлгермичә, аз гына ун-утыз ел гына соңарган булса, бөтен хакимият өч йөз аек татар миллионеры кулына күчкән булыр иде. Чөнки алтын да, уран рудалары да, нефть тә, төрле кыйммәтле ташлар да—һәммәсе дә алар кулына күчеп бетәр иде.

Газизов һәм Азимовлар, Рәмиев һәм Шәкүровләр, Скуратов һәм Строгановлар...

Урал, Кавказ, Себер..., ат, икмәк, җир асты байлыклары—һәммәсе дә, һәммәсе дә!

Акчуриннар, Хәйруллиннар, Мансуровлар, Ишморатовлар, Морозовлар, Дәгиловлар! Хәтәр бит!

Ә идеологияләре-инанулары нинди? Яшел! Тыйнаклык, гыйлемлек... Һәм шул ук вакытта—батырлык, курку белмәслек, егетлек, байлык, көч, тугрылык, чисталык. Аннары бу илнең ничек аталуы хакында да уйланырлар иде: Русияме әллә Татарстанмы?!» («Дөнья», 1992, февраль).

Ә. Борһанов борчылып болай яза: «Мин атап киткән юл—кыскарак юл (халыклар һәрвакыт кыскарак юл эзлиләр, әмма җиңел юллар юк—Р. В.) Татарстан үз байлыкларына хуҗа түгел дигән мәгънәдә әйтмим. Хикмәт шунда: байлык халык карамагында түгел һәм татар халкының (бөтен халыкның) МИЛЛИ МАЯСЫ формалашмаган. Бу җәһәттән дөнья күләмендә башкарасы эшләрнең исәбе-хисабы юк.

Соңгы 10-15 ел эчендә татарның элек югалткан этник бердәмлеген торгызырга омтылышы, аның уянуы—халыкта, милли идея буларак, үз-үзен саклап калу хисе тууның мөһим күрсәткече. Татарларның яшәешендә тел һәм милли мәдәниятне торгызу процессы бара. Аны татар милләтендәге гражданнарның акционерлык, кооператив, житештерүче, сәүдә итүче һ. б. предприятиеләр, компанияләр, шулай ук шәхси хосусый гаилә предприятиеләре төзү юлы белән милекчеләргә әйләндерергә, ярдәм итеп ныгытырга һәм үстерергә кирәк. Гражданнарның һәм татар эшкуарларының байлыкларын махсус оештырылган Татарстан халык банкында туплап татар МИЛЛИ МАЯСЫН формалаштыру өстендә эшлисе бар.» (Ә. Борһанов. Татар халкының киләчәге нинди? «Татарстан», 12, 1999.)

Үзгәртеп кору чоры башлангач, Ә. Х. Борһановка да «кояш елмайды». Соңгы унөч ел эчендә генә дә аның ике йөздән артык хезмәте дөнья күрде. Шуларның җидесе—китаплар. Фәнни хезмәтләре өчен Россия гуманитар университеты аңа махсус академик стипендиясе билгеләде. Үзе шул ук гуманитар университетта (ректоры Юрий Афанасьев) социология кафедрасында «Философия и социология собственности» дигән темага махсус лекцияләр укый, аспирантлар белән җитәкчелек итә.

Казаннан «үз теләге» белән китәргә мәҗбүр булган Ә. Х. Борһанов шушы елларда гына Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы итеп сайланды.

Әгъләс Хөсәенович Борһанов һәрвакыт эштә: яза, Рәсәй буйлап лекцияләр укып йөри, ә бит аңа инде 80 яшь. Халык әйтмешли, «Карама беләккә, кара йөрәккә!» Аллага шөкер, аның йөрәге әле нык. Фидакарь хезмәтендә яңа уңышларга ирешүен телик!

**Рәмзи ВӘЛИЕВ,**
*тарих фәннәре докторы*

*Балалар өчен хикәяләр*

# Алмаз Гыймадиев

## «Пахан»

Безнен мәктәп авылның нәкъ уртасына салынган. Мәктәп директоры Хәбир Хәбриеч әйтмешли, «значит шулай кирәк булган». Авыл дигәч тә сез тагын җәһәннәмнең аръягында, урман буена сыенып утырган ун-егерме йортны күз алдына китермәгез! Безнең авылдан шәһәр күренеп кенә тора. Ара — төп-төгәл уналты бөтен уннан ике километр. Хәбир Хәбриеч көн саен шуннан йөреп эшли. Фатиры шәһәрдә аның. Сез аны җәяү йөри дип уйлыйсыздыр инде. Юук, автобус белән дә түгел. Чия төсендәге тугызынчы модель«Жигули»е белән генә җилдерә.

Күптән түгел шәһәрдән кайтартылган бер башкисәрне китереп тыктылар безнен класска. Кемнең туганы булуын, кемдә торганын, хәтта исемен дә белмибез. Ну түлке аның «текә»леген күрсәгез! Чәче төбенә хәтле кырып алынган, өстендә—тар чалбар белән тар куртка. Кулында нәзек тимер чылбыр. Шул чылбырны бертуктаусыз әйләндерә. Ту унга, ту сулга. Ник әйләндергәнен беребез дә анламый. Класстагы иң күп белүче «Саескан Надиры» гына: «Эспандер кебек, бармак мускулларын ныгыта ул, бик беләсегез килсә!»—дип маташты үзе...

Башкисәребез туктаусыз сагыз чәйни, чәйнәп туйгач сагызын колак артына ябыштырып куя. Беребез белән дә аралашмый, тәнәфес житүгә колагына наушник киеп куя да, күзләрен шарландырып, иреннәрен кыймылдатып аудиоплеердан музыка тынлый башлый. Андый чакта психушкадагы җүләргә охшап кала ул. «Саескан Надиры» әйтә, бу малай шәһәрдә бозылып беткән дә, монда денгә кермәс микән дип кайтарганнар аны ди. Ләкин бу шпанадан кеше чыгуына шикләнәм мин. Хәбир Хәбриеч әйтмешли, «едва ли...»

Әлеге шакалның безнен класска килүенә ике-өч көн дә үтмәгәндер, көтмәгәндә мина директор янына керергә куштылар. Хәбир Хәбриеч гадәтенчә бераз сынап карап торганнан сон сүз башлады:

—Заһидуллин!—диде ул теш арасыннан чыккан сытык тавыш белән. —Синен класста гына түгел, бөтен мәктәптә авторитетлы малай икәнлегенне беләбез... Сина «партийный задание» йөкләнә...

Хәбир Хәбриечнен Павлик Морозовлар, Мальчиш-Кибальчишларны мисалга китерүләрен, Бөек Ватан сугышын телгә алуларын сөйләп тормыйм, озынга китә, мәгәр,кыскача гына әйткәндә, мин теге башкисәрне тәрбияләргә, ягъни «тәртә арасына кертергә» тиеш булдым.

—Уку елы ахырына шул шәһәр хулиганыннан кеше ясый алсан, сина... «Мактау кәгазе» тапшырырбыз!—диде Хәбриеч тантаналы итеп.

Директорның сүзе—закон! Мин төне буе төрле планнар корып яттым. Иң элек, Маяковскийнын «Что такое хорошо, что такое плохо» китабын укыйсы булыр мона, аннары...

Иртәгесен, мәктәпкә килеп керешли ни күрим, теге башкисәр кроссовкаларын салмый гына фойега кереп бара.

—Стоп! Кая барасын?—дип беләгеннән эләктереп тә алдым монын. Малаебыз аптырап мина карады.

—Аягынны сал дим!

Шәһәр ышпанасы мина тилегә караган төсле күз ташлады да, куртка кесәсеннән чын (әйе,әйе, чып-чын!) радиотелефон тартып чыгарды.

—Пахан!—диде ул эре генә трубкага иелеп.—Монда мине бер ахмак туктатты, аякны салырга куша...

Кинәт тез буыннарым калтырап китте. «Пахан?!.. Пахан бит ул... банда башлыгы дигән сүз! Димәк... димәк, бу теге... кемнәр кешесе... маф.. мафия!!»

Шыпырт кына таярга җыенган идем инде, кинәт... кинәт малаебыз кроссвкаларын салырга тотынды.

—Пахан шулай кушты!—ди бу ирен чите белән генә елмаеп. Үзе радиотелефонын эре генә түш кесәсенә шудырды да, сызгыра-сызгыра чишенү бүлмәсенә кереп китте.

Мин бу хәлләрне малайларга сөйләдем. Алты минутка сузылган тынлык хасил булды. Тынлыкны әлеге дә баягы «Саескан Надиры» бозды.

—Беттек!—диде ул. Башка сүз әйтүче булмады.

Зур киеренкелектә тагын ике көн үтеп китте. Яна малай берни булмагандай йөри, берәү дә аның белән сөйләшергә җөрьәт итми... «Что такое хорошо...» ны укырга да никтер минем җай чыкмый...

Беркөнне озын тәнәфестә класска керсәм... бүлмә зәңгәр төтен белән тулган! Тәмәке төтене! Шикләнүем урынлы булып чыкты—«мафиоза»быз музыкасын тыңлый-тыңлый сигарет төтәтә!

—Ташла тәмәкенне!—дип боердым мөмкин кадәр кырыс тавыш чыгарырга тырышып. «Мафиози» янә телефонын тартып чыгарды:

—Пахан! Тагын теге әҗәл корбаны килеп җиткән... Класста тәмәке тартма, ди. Ну... Ну пахан, теге школда тарта идек бит... Ну...

«Пахан» трубканы куйды ахры, малаебыз канәгатьсез генә телефонын сүндерде, нәфрәт белән мина карап алды һәм тәмәкесен тәрәзә төбендәге гөл туфрагына батырды.

Мин җинел сулап куйдым. Кара, ул хәтле начар кеше түгел икән ич бу «Пахан» дигәннәре!.. Күр, ничек берсүзсез буйсына ана шәһәр башкисәре. Малайлар белән җыелыштык та, мафиядән курыкмаска сүз беркеттек. Хәтта «Саескан Надиры» мондый фикер әйтте: «Яна малайны үзешчән сәнгатьтә сынап карарга кирәк,—диде ул. —Музыка тыңларга ярата бит, бәлки җыр-биюгә дә һәвәслеге бардыр?» Бу кызык идея иде. Киләсе атнага «Кошлар бәйрәме» була. Анда безнен малайлар хоры «Яз килә» җырын башкарачак. Ә нигә хорга яна малайны да тартып карамаска?!.

Дәресләрдән сон кайтырга җыенган җиреннән туктаттык без моны. Ниятебезне житкердек. Бу юлы да радиотелефонына үрелер дип көткән идек, алай булмады, малаебыз безнен тәкъдимне ишеткәч, буыла-буыла көләргә тотынды. Көлеп бетергәч, «черт!» итеп идәнгә төкерде дә, ишеккә юнәлде. Чыгып китсә, бу безнен тарафтан зур җинелү булачак иде, сүз берләшкәндәй, аррәү каршына чыгып бастык.

—Карале братан,—мәйтәм.—Бәлки «Пахан» белән кинәш итәрсен, ә?..

Күрәсен, үзе дә шулай эшләргә җыенган булган ахры, берсүзсез телефонын өстерәп чыгарды бу:

—Алло, Пахан, монда бер клоун җитми ди, ниндидер тусовкага...

Каян башыма шундый тәвәккәллек килгәндер, кинәт тегенен кулыннан телефонын йолкып алдым:

—Пахан!—дип акырдым трубкага. —Пахан! Синен яхшы бәндә икәнлегенне беләбез, булыш, Пахан! Анлат шуна, «Кошлар бәйрәме»ндә җырларга кирәк, диген, Пахан! Пахан дим, ишетәсенме?!

Бер-ике секунд тынлыктан сон трубкада гаҗәп дәрәҗәдә таныш тавыш ишетелде:

—Кемгә Пахан, кемгә Хәбир Хәбриеч... Кызма, Заһидуллин! Бир телефонын минем малайга! Өйдә үзем сөйләшермен мин анын белән... Бәлки риза да булыр...

Трубканын кулдан төшеп китүе һәм «Саескан Надиры»нын «Әрәм булды!» дигәне истә калган. Бүтәнен хәтерләмим. Әле һушыма килгәч тә анлый алмый интектем —телефон трубкасы турында әйттеме Надир, әллә минем хактамы?

## «Бөек математик»

Математика буенча үткәрелгән олимпиадаларда Идрис беренчелекне бирми. Анын башы—компьютер. Малайнын әлеге сәләтенә һәркем шакката. Мәсәлән, өч урынлы санга өч урынлы санны күнелдән тапкырлау Идрис өчен майлы коймак ашау белән бер. Квадрат тамыр алу, пропорция төзү ише нәрсәләрне дә күнелдән генә исәпли ала ул. Талант тек талант инде менә!

Беркөнне физика дәресендә укытучы абыйлары Жирдән Айга кадәр 384 400 км. дигән иде, Идрис шундук телен шартлатты:

—Минем абыйның «Опел»е йөз алтмыш көн дә дүрт сәгать барыр иде! Диманың әтисе «Москвич»та ике йөз көн... Ә Фәниянең апасы трамвай белән...

Кыскасы, малай, айга нинди транспорт ничә көн баруын ике минут дигәндә санап та чыкты. Физика укытучысының күзләре мангаена менде!

Биология дәресендә Идрис ун кулында ничә күзәнәк булуын әйтеп бирде.

Класс житәкчеләре Камәрия апаның туган көненә бүләк алу мәсьәләсе килеп баскач та, «Бөек математик»ның «компьютер башы» нык булышты. Теш пастасы, шампунь, сөлге, хушбуй ише нәрсәләр белән шыплап тутырылган набор-пакет алмакчы иде алар. Идрис тиз арада һәр вак-төяк әйбернең бәясен белешеп, шуларның суммасын исәпләп чыгарды—баксаң, шул ук әйберләрне аерым-аерым сатып алсаң 1 сум 78 тиенгә арзангарак төшә икән!

—Әле тагын менә бусына да игътибар итегез!—дип хәйләкәр генә елмайды ул классташларына.—Теш пастасының 75 граммлысы ун тәнкә тора, ә 50 граммлысы—7 сум 30 тиен. Димәк, кайсын алу отышлырак?..

Берәү дә әйтә алмады. Бизнесмен малае Альберт кына күзләрен чепе-чепе китереп:

—«Блендамед» алу отышлырак! Ул кариесны булдырмый!—дип куйды.

Ә бүген... бүген Идрис классташ кызы Илсөяр белән кинода утыра. Илсөярнең кулында Идрис алып биргән тундырма. Экранда үзәк өзгеч тавыш белән Джимми жырлый. Кыз онытылып шуны карый. Идриснең башында исә бөтән нәрсә. «Тундырманы сатып алганда хата жибәрдем,—дип борчыла ул.—Стаканлысы 120 грамм, майлылыгы да 2,5 процент кына. Вафлилысы үзе арзан, граммы да артыграк, майлылыгы —3 процент. Соңгысын алырга кирәк булган да бит...»

Шулчак Илсөяр аның беләгенә кагылды:

—Әннекәйгенәм! Әллә чынлап та Джиммины үтерәләр инде?!

—Үтермиләр...—дип мыгырданды малай битараф кына. «Ике кешелек кино билеты да утыз тәнкә, «Танцор диско»ның видеокассетасы да шул ук бәя—дип уйлады ул.—Кинотеатрда бер карыйсың да—бетте! Ә «видик»ны күпме телисең әйләндерергә була...»

—Бүтән жырламас инде ул...—диде Илсөяр яшьле күзләрен экранга төбәп.

—Жырлый...—дип мыгырданды Идрис. Ә үзенең башында мондыйрак уй бөтерелде: «Илсөяр Ленин проспектында яши, аны озату өчен ике төрле транспортка утырырга, икебез өчен дә түләргә кирәк. Үзебезнең йортта тугызынчы катта яшәүче Светаны чакырган булсам, алты сум янга калыр иде... Тукта, ә нигә мин Илсөярне озатырга тиеш соң әле? Үзе генә кайтса дүрт сум янга кала лабаса!..»

Идрис әкрен генә торып, караңгы залдан кармалана-кармалана үтеп, «выход» дигән яшькелт язуга атлады. Джимми белән хисләнеп утырган классташ кызы аның чыгып киткәнен абайламады да.

## Изге эшләр дәфтәре

Динар быел бишенче класска күчте. Юк, аның бишенчегә күчүе гайре табигый хәл түгел. Ел саен укучылар бердән—икегә, өчтән — дүрткә, тугыздан—унга күчәләр бит инде, бу да шундый гадәти бер күренеш. Киресенчә, күчмәсә сәер булыр иде әле...

Бүген сөйлисе сүзнең башы аның алты ел буе парталарда, коридор идәннәрендә һәм шугалакларда күпне күреп, чит-читләре ашалып, чүбекләнеп беткән соры (бәлки яңа вакытында кара төстә булгандыр) портфелендә, портфель эчендәге шулай ук чүбеккә әйләнеп беткән шакмаклы бер дәфтәрдә. (Игътибарлырак укучылар бишенчедә укучы Динарның портфеле ни өчен алты ел «дөнья гизгән» дигән сорау бирергә мөмкиннәр. Динар өченче класста ике ел «утырган»).

Әлеге дәфтәр өченче ел табигать белеме дәресеннән башланган булган. Мәгәр, никтер ике битенә генә язылган аның. Кичә, класс житәкчеләре Мөэминә апа барлык укучыларга да яңа дәфтәр алып килергә кушкач, Динар әлеге дәфтәрне чормадан эзләп табып, тузанын кагып, баштагы ике битен ертып, бүген шуны укытучы хозурына күтәреп килгән. /Игътибарлырак укучылар ни өчен Динар яна

дәфтәрне сатып кына алмаган, дип сорарга мөмкиннәр. Динарның әти-әнисенә хезмәт хакын узган елның февраль ае өчен генә биргәннәр, акчалары юк/.

Мөэминә апалары дәфтәрнең тышына «Изге эшләр» дип яздырды. Кыскасы шул— һәр укучы, шул исәптән Динар да кылган һәр изге эшен, изге адымын шушы дәфтәргә теркәп барырга тиеш икән. Өстәвенә, бу изге гамәлләр кененә өчтән дә ким булмаска тиеш, ди. Ягъни, сыерчыкларга оя ясау, күрше әбинең утынын ярып бирү, уптәшенә укуда булышу һ.б. шундый эшләр инде болар. Кем күпме изгелек кылган — киләсе атнада җыелып тикшерергә сүз куештылар.

... Уйлана-уйлана мәктәп бинасыннан чыгып килгәндә Динарның күзе юлдан бераз читтәрәк ачык канализация коесына төште. Капкачы янәшәдә ята. «Берәр ачыгавызы ялгыш төшеп китәр әле...» дип уйлап куюы булды, шатлыктан авызы ерылып та китте. Урраа! Менә сиңа беренче изге эш!

Малай йөгереп килеп капкачны коега каплап куймакчы иде, тот капчыгын —кыймылдата да алмады. Ярдәмгә Мансурны, Илшат белән Әмирне һәм Мәхмүтне чакырырга туры килде. Бишәүләп тырыша торгач тәки кое авызын томалау бәхетенә ирештеләр.

Динар ниндидер бер җиңеллек тоеп өенә атлады. Кайтып житкәнче аның башында «гениальный» план формалашкан иде инде. Ул хәзер сыерчык оясы ясаячак! Дөрес, тышта көз инде үзе, сыерчыклар бәлки китеп тә беткәннәрдер, әмма киләсе язга тагын кайта бит алар! Менә бу ичмасам бик зур изге эш булачак!

Малай кайнарланып портфелен, гадәттәгечә, юынгыч белән мич арасына томырды да, формасын да салмый тышка чыгып китте. Тә— әк, кайда әле безнең балта, пычкы, такталар? Ә —ә —ә, ие, күптән түгел генә ломны пычкы белән кисеп караганы өчен әтисе Динардан яшереп куйган иде шул аларны... Стоп! Чоланда агач тартмалар бар ич безнең! Ясап торасы да юк, бер ягына сыерчык сыешлы итеп тишек кенә тишәсе дә... Малай үзенең тапкырлыгына сокланып, карангы чоланга ашыкты. Тартмалар дөрестән дә күп, ләкин бушлары юк икән. Ничава! Бушатабыз аны! Тартмадагы дөге икенче бер тартмадагы ниндидер ак әйбер өстенә очты. Ак төстә иде, мөгаен анысы да дөге булгандыр.

Ярты сәгатьтән аскы өлешендә почта конверты зурлыгындагы тишеге булган сыерчык оясы абзар түбәсендә кукраеп утыра иде инде. (Игътибарлырак укучылар нигә оянын тишеге шулай зур дип сорарга мөмкиннәр. Беренчедән, Динарның, авыл малае булса да, монарчы сыерчык күргәне булмады, икенчедән, эш кораллары булмау сәбәпле, тишекне ул күрәк белән тишәргә мәҗбүр булды).

...Сәхәбетдин бабай кулын кесәсенә тыгып, бераз бөкрәебрәк басып торган малайны күргәч аптырап калды.

—Сон, бабай, неужәли аңламыйсын, менә шундый дәфтәр башлаттырдылар... ие... әби-бабайларның утынын ярырга куштылар...—дип авыз эченнән ботка пешерде Динар.

—Ә—ә—ә... сез теге кемнәр мәллә, тимерчеләр... тимурчылар мәллә? —дип җанланып китте Сәхәбетдин карт эшнен асылын аңлап алгач. —Утыным ярылган бит минем улым. Мунчага бер-ике бидон су алып кайтсаң ярар иде үзе...

—Бабай, безгә мунча турында бер сүз дә әйтмәделәр,—малай «лышк» итеп борынын тартып алды.—Ату, утынын ярылган булгач, Динар ярды, дип менә бу төшкә кулыңны гына куй инде, җәме!

Кояш офыкка якынлашканда, Динар «физкультурадан булышырга дип», футбол тубын кыстырып, югары урамга —Әмирләргә юл тоткан иде инде. Шулай итеп, малаебызның чүбекле дәфтәренә бер көндә дүрт изге эш теркәлде.

Кичен, «планны хәтта арттырып үтәдем» дип кәефләнеп, диванга кырынаеп «Каникулы в Простаквашино»ны карап ятканда, чоланга чыгып кергән әнисе бөтен кәефен төшерде.

—Тоз белән дөгемне кушкансың, дуңгыз сырты!—дип шәрран ярырга тотынды. Кәрәкне яньчеп бетергән өчен әтисеннән дә шәп әләкте. Кыскасы, ниндидер юк-бар аркасында, бер көндә күпме изге эш эшләгән малайның бәйрәм рухын тәмам бетерделәр.

Әмма, «Почтальон Печкин»нын посылка китерүен карап яткан малай бәйрәмнен зурысы иртәгә булачагын әле башына да китерми иде. Әйе, әйе, мәктәп астындагы су торбаларын тикшерергә дип канализация коесы аша подвалга төшкән сантехник Әбелбәкер абзый «бәйрәм»нен зурысын иртәгә, якты дөньяга чыккач күрсәтәчәк, һичшиксез күрсәтәчәк иде әле ана...

# БЕРГӘ БУЛЫЙК!

Хөрмәтле укучыларыбыз!

2001 елның беренче яртыеллыгы өчен вакытлы матбугатка язылу башланды. Ул декабрь ахырына кадәр дәвам итәчәк. **«Казан утлары»ның индексы - 73210, бер елга язылу бәясе 84 сум, ярты елга—42 сум.**

Журналга язылуны җиңеләйтү максатыннан быел да абонемент үрнәген тәкъдим итәбез. Шушы квитанцияне кисеп алып, анда үзегезнең тулы адресыгыз, исем-фамилиягез һәм язылырга теләгән айларны күрсәтеп, үзегез яшәгән җирдәге элемтә бүлегенә тапшырырга кирәк.

Казанлылар игътибарына тагын бер яңалык: быелдан башлап «Казан утлары»на «Горпечать» киоскларында язылырга мөмкин. Бу очракта журналны да шуннан барып аласы була. Әлеге киосклар әбүнәчеләрне кабул итә башлады инде.

Әдәбиятыбызның, гомумән, мәдәниятебезнең елъязмасы, рухи көзгесе булган «Казан утлары»на язылырга онытмагыз! Яңа гасырда да бергә булыйк!

Ф.СП-1

Управление почтовой связи
"Татарстан Почтасы"

**АБОНЕМЕНТ на** ~~газету~~ журнал **73210**
(индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

Количество комплектов

на **2001** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

**ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА**

| ПВ | место | ли-тер |
|---|---|---|

на ~~газету~~ журнал **73210**
(индекс издания)

***Казан утлары***
(наименование издания)

| Стоимость | подписки | ____ руб.____ коп. | Количество комплектов |
|---|---|---|---|
| | пере-адресовки | ____ руб.____ коп. | |

на **2001** год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | |

Куда
(почтовый индекс) (адрес)

Кому
(фамилия, имя, отчество)

## *Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан*

### СУВЕРЕНИТЕТНЫ НЫГЫТУ ЮЛЫННАН

29 августта Татарстан Дәүләт Советының Татарстан Республикасы Дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул ителүенең ун еллыгына багышланган IҮ пленар сессиясенең тантаналы утырышы булды.

Сессиядә Россия Хөкүмәте вице-премьеры В. Матвиенко Россия Федерациясе Президенты В. Путин котлавын, Россия Министрлар Кабинеты һәм аның Рәисе М. Касьяновның котлау телеграммасын укыды.

Дәүләт Советына, республика житәкчеләренә һәм Татарстанның бөтен халкына тәбрикләүләр белән Кабарда-Балкар Республикасы Президенты В. Коков, Башкортстан Республикасы Президенты М. Рәхимов, Төньяк Осетия-Алания Республикасы Президенты А. Дзасохов, Удмуртия Республикасы Дәүләт Советы Рәисе А. Волков, Саха (Якутия) Республикасы Хөкүмәте житәкчесе В. Власов чыгыш ясады. Алар үз халыклары исеменнән Татарстан Илбашына истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

Россия Федерациясе Федераль Җыелышы житәкчеләре—Федерация Советы Рәисе Е. Строев һәм Дәүләт Думасы Рәисе Г. Селезнев котлаулары укылды. Сессия ахырында халык депутатлары Президент М. Шәймиевнең «Суверенитетны ныгыту юлыннан ун ел» дигән доклады буенча Дәүләт Советы резолюциясен кабул иттеләр.

### БӘЙРӘМ ХӨРМӘТЕНӘ

22 августта Рәссамнар берлегенең күргәзмәләр залында «Суверен Татарстанга 10 ел» дигән республика күргәзмәсе ачылды. Биредә Чаллы, Бөгелмә, Лениногорск, Зәй, Чистай, Алабуга һәм республикабызның башка шәһәр-районнарыннан җибәрелгән 300 дән артык экспонат күрсәтелде.

### ТАНЫЛУЛАР ЮЛЫНДА

Германиянең Ганновер шәһәрендә 2000 елның 1 июненнән эшли башлаган «Экспо-2000» Бөтендөнья күргәзмәсендә Татарстан Республикасы көннәрен тәкъдим итү булды һәм анда Дәүләт Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин житәкчелегендәге делегация катнашты.

### АЛТЫН УРДА ХӘЗИНӘЛӘРЕ

30 августта Татарстан Сынлы сәнгать музеенда Татарстан бәйсезлеге турында Декларация кабул итүнең 10 еллыгына багышланган «Алтын Урда хәзинәләре. Чыңгызлылар алтыны. Алтын Урданың мәдәни мирасы» дигән күргәзмә ачылды.

Дәүләт Эрмитажы һәм Дәүләт Тарихи музее тупламаларыннан торган 600 дән артык XIII-XV гасыр экспонатлары Алтын Урда мәдәниятен күз алдына китереп бастыра.

### «ГАСЫРЛАР АВАЗЫ»НА 75 ЕЛ

«Фәнни-документаль басмалар һәм Идел буе-Урал яны халыкларының тарихи үзаны барлыкка килү»—«Гасырлар авазы—Эхо веков» («Архив язмалары») тарихи документаль журналының дөнья күрүенә 75 ел һәм аның янадан чыга башлавына 5 ел тулуга багышланган күргәзмә һәм фәнни-гамәли конференция булды. Аның эшендә Татарстан, Башкортстан, Чувашстан, Удмуртия, Мари Иле, Түбән Новгород һәм Самара өлкәсеннән архивчылар, күренекле галимнәр, язучылар, журналистлар катнашты.

### МЭРИЯДӘ ЯҢА БАШЛЫК

Казан шәһәре мәдәният идарәсенең башлыгы итеп Әлфия Әмир кызы Тутаева билгеләнде. Ул—Казан дәүләт университетының тарих бүлеген тәмамлаган. Соңгы дистә елда Ә. Тутаева Казанның Горький музеен житәкләде.

### ЮНЕСКО БЕЛГЕЧЛӘРЕ КАЗАНДА

Казанда православие дөньясында Ислам мәдәнияте мәсьәләләрен өйрәнүче ЮНЕСКО белгечләре булып китте. Алар Казан Кремлендә булдылар, археологлар һәм аларның соңгы хезмәтләре белән таныштылар, тәэсирләре белән уртаклаштылар.

### *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** Казан дәүләтенең соңгы хөкемдары Ядегәр хан.
*Нияз Хажиахмәтов рәсеме.*

**Тышлыкның дүртенче битендә:** шагыйрә Эльмира Шәрифуллина.

# ХУШЛАШУ СҮЗЕ

Татар халкы һәм академик фән зур югалтуга дучар булды. 18 сентябрьдә 76 нчы яшендә каты авырудан соң күренекле галим һәм җәмәгать эшлеклесе, филология фәннәре докторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең гамәли әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Бөек Ватан сугышы ветераны Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин вафат булды.

Ә. Г. Кәримуллин 1925 елның 29 маенда Татарстанның Саба районы, Чәбия-Чүрчи авылында туа. Хезмәт эшчәнлеген «Память Ильича» колхозында башлап җибәрә. 1943-1948 елларда Бөек Ватан сугышы фронтларында була һәм Совет Армиясендә хезмәт итә. 1 дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. 1948-1953 елларда Казан дәүләт университетында укый. Аны тәмамлаганнан соң университетның фәнни китапханәсендә башта китапханәче, соңыннан фәнни эшләр буенча директор урынбасары була.

Ә. Г. Кәримуллин академик фәнгә 60 еллар уртасында килеп керә. Ул Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының кече фәнни хезмәткәреннән алып баш фәнни хезмәткәренә кадәр юл үтә. 1968 елда кандидатлык диссертациясе, ә 1985 елда исә докторлык диссертациясе яклый. Диссертация монографияләре басылып чыкканнан соң илдә, гомумән, дөньяда да китап белеме һәм татар китабы тарихы өлкәсендә танылган белгечкә әверелә. Ул—татар фәнни библиографиясенә нигез салучы һәм милли культураның төрле өлкәләре буенча фундаменталь библиографик күрсәткечләр булдыручы да.

Ә. Г. Кәримуллин—35 тән артыграк китап һәм 600 фәнни язма авторы. Аның күп кенә эшләре татар, рус һәм башка телләрдә басылып чыкты.


Ә. Г. Кәримуллинның фәнни кызыксынулары күпкырлы: татар теле һәм әдәбияты, фольклор, археография, вакытлы матбугат һәм басма китап тарихы, татар халкының этногенезы, чит илләрдә яшәүче татар диаспорасының тарихы, халкыбызның бүгенге вәзгыяте һ. б.

Ә. Г. Кәримуллин дистәләрчә ел дәвамында Россия Дәүләт китапханәсенең, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, Казан дәүләт университетының диссертация советлары әгъзасы һәм мәдәният, мәгариф һәм фән учреждениеләренең фәнни советлары әгъзасы сыйфатында күпкырлы иҗтимагый эшчәнлек алып барды. Ул Татарстанның Язучылар берлеге әгъзасы иде.

Әбрар Гыйбадулла улы Кәримуллин гомеренең соңгы көннәренә кадәр актив фәнни һәм иҗтимагый эш алып барды.

Күренекле галимнең йөрәге тибүдән туктаса да, аның фәнни мирасы безнең белән калачак.

**М. Ш. Шәймиев, Р. Н. Миңнеханов, Ф. Х. Мөхәммәтшин, Ә. С. Гобәйдуллин, И. К. Хәйруллин, Р. М. Миңнуллин, М. Х. Хәсәнов, И. Г. Тарханов, К. Ш. Исхаков, Р. Н. Миңнеханов, М. З. Зәкиев, Ю. Г. Коноплев, Р. И. Вәлиев, Ф. Г. Галимуллин.**



**Әбрар Кәримуллин**
**1925—2000**

Индекс 73210



Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)